Ульям Шекспир
Избранные произведения
В ДВУХ ТОМАХ

ТОМ
1
Трагедии, комедия, историческая драма
Казань
Татарское книжное издательство
2006

Сайланма әсәрләр
ИКЕ ТОМДА

1
ТОМ

Трагедияләр, комедия, тарихи драма
Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 821.111-2
ББК 84 (4 Англ.)-6
Ш39
Шекспир У.

Сайланма әсәрләр: 2 томда / Уильям Шекспир; Кереш сүз авт. Ю.Сафиуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5-298-03997-9

1 т.: Трагедияләр, комедия. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 614 б.

ISBN 5-298-03998-7
Бөек инглиз драматургы У.Шекспир (1564 — 1616) әсәрләренең бу томына аның татар театры сәхнәләрендә дә уңыш белән куелган иң популяр трагедияләре, комедиясе һәм тарихи драмасы керде.
Китап татар театрының 100 еллыгы уңаеннан чыгарыла.
ISBN 5-298-03998-7 (1 т.)
ISBN 5-298-03997-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2006

ШЕКСПИР ТӘРҖЕМӘЛӘРДӘ

Татар тыйнак дигән гыйбарә бар. Тәрҗемә мәсьәләсенә килгәндә, татар тыйнак кына түгел, ә кирәгеннән артык тыйнак милләт. Театр сәнгате нәкъ менә тәрҗемә сәхнә әсәрләре ярдәмендә үзенең эшен олы итеп башлап җибәрә алуына һәм татар театрын тәрҗемәләр ярдәме белән дә елдан-ел үстерә, баета баруына карамастан, беренче тәрҗемәләр күренү белән үк, «безгә тәрҗемә әсәрләре кирәкме-юкмы?!» дигән кискен бәхәсләр кабына, һәм аның әле бүгенгәчә сүрелгәне юк. Ә бит театрның кайсы гына бәхетле чорын алсак та,

Марсель Сәлимҗанов дәверен искә төшерсәк тә, театр репертуарының яртысы диярлек тәрҗемә әсәрләрдән торганын күрәбез. Тәрҗемә кирәкми, милли әсәрләр генә куелсын, шул юл белән милли драматургияне тагын да көчәйтеп була, дип шаулаган элекке кешеләрне әле аңларга була, чөнки бу мәсьәләдә тәҗрибә тупланмаган, күп нәрсәдә билгесезлек, ә менә бүгенгесе көндә инде, театр 100 еллык юбилеен уздырганда, кабат шуңа чын күңелдән ышанучылар барлыгын күрү таң калдыра. Дөнья йөзендәге бер генә милли театрның да тәрҗемә әсәрләреннән гайре яши, үсә алганы юк. Классик драматургия әсәрләренең тәрҗемәләрендә артистларның һәм режиссерларның осталыклары чарлана. Татар театрын бөтендөнья театр хәрәкәте белән бергә атлату мөмкинлеге туа. Ә бу инде, үз чиратында, милли драматургиягә гаять шифалы йогынты ясый. Татар театр тәнкыйтьчеләренең атасы, нашир һәм тәрҗемәче Габдрахман Кәрам әйтмешли, классик драма әсәрләрендә уйнап талантлары ачылган татар артистлары милли әсәрләрне дә яңа биеклеккә күтәрәләр. Башка халыкларның яшәү рәвешләреннән үз милләтенә үрнәк яки гыйбрәт алырга мөмкинлек тудыралар. Халыклар сәнгать аша танышса, дуслашса, илләрдә иминлек өстенлек итә башлый. Әлбәттә, шунысын да онытмау кирәк, тәрҗемәләр сәхнәбездә артык күбәеп китәргә тиеш түгел. Ф.Бурнашның «тәрҗемәләр милли әсәрләрне репертуардан кысрыкламаска тиеш» дип әйткәне заманында нәкъ менә Мохтар Мутинның тәрҗемәләр белән артык мавыгып китүенә бер шундый хаклы кисәтү-ишарә булган.
Шекспир, Шиллер, Һейне кебек дөнья драматургиясенең классиклары әсәрләренең татар театры сәхнәсендә уйналулары Мутин исеме белән бәйле. Чөнки ул әсәрләр аның инициативасы белән тәрҗемә ителгәннәр, аның режиссерлыгында куелганнар һәм аның башкаруында уйналганнар да.
1908 елны Казанга килгән М.Мутинны реакцион көчләр, политик яктан ышанычсыз дип, унтер сагы астында кире Уфага озаткан булалар. Талантлы артистны «Сәйяр» театры үзенә кат-кат чакырып торса да, әлеге сәяси сәбәп М.Мутинга театр белән бәйле эшчәнлеген башка шәһәрләрдәге труппаларда гына алып барырга мөмкинлек калдыра. Мутин Казанга кабат ун ел үткәч кенә килә ала. Һәм ике ел буена театр бүлеге мөдире буларак та, Татарстан Мәгариф халык комиссариатына күчкәч тә, Татнаркомпростагы театр бүлеге җитәкчесе сыйфатында да тәрҗемә эшләрен җайга салу өчен көрәшә. Замандашлары үзләренең истәлекләрендә Шекспирныкыдай чәч үстергән Мутинның Шекспир, Шиллер һәм башка классикларның калын-калын томнарын һәрчак үзе белән бергә йөртүен, төрле концертларда дөнья классиклары әсәрләреннән, аеруча Шекспир трагедияләреннән күпсанлы монологларны татарча да, русча да искиткеч осталык белән укуы турында язып калдырганнар. Нәтиҗәдә дөнья классикасы белән «җенләнгән» Мохтар Мутин ярдәмендә 75ләп сәхнә әсәре, шул исәптән Шекспирның атаклы трагедияләре дә тәрҗемә күрә.
Театр белгече Ш.Рахманкуловның: «Даһи Шекспир әсәрләре татар театры репертуарында ныклы урын ала һәм дөнья әдәбиятының мәшһүр трагедияләрен тирән аңлап укый белүче артистлар тәрбия итүдә тәрәккый чараларның иң әһәмиятлесе була», – диюе дә М.Мутин эшчәнлегенә килеп тоташа. Трагикларны берәмләп кенә саныйлар. Азәрбайҗаннарда– Араблинский, осетиннарда–Тхапсаев, грузиннарда –Хорава, үзбәкләрдә–Һидаятов, әрмәннәрдә–Папазян, безнең андый югарылыктагы артистыбыз Мутин була. Шагыйрь Хәсән Туфанның:

Мутин түгел, ә Отелло булып,
Гамлет булып яши хәтердә, –

дигән шигъри юлларында да чагыла бу.
Әмма ләкин М.Мутинның дөнья классиклары әсәрләренә мәхәббәтен, Ф.Бурнаштан аермалы буларак, милли репертуарлы театрны җимерү дип тә бәяләүчеләр табыла. Репертуарда фәкать милли әсәрләр генә булырга тиеш дигән фикерне алга сөрүчеләр күбәя. Кариев белән Мутин исемнәре капма-каршы куела башлый. Баимбетовның төрле газеталарда басылган «Мутин–Кари» дип исемләнгән мәкаләсендә «Кариев – төзүче, Мутин – җимерүче» дигән ялган фикер күпертеп бирелә. Янәсе, Кариев милли репертуарны үстергән, ә Мутин гел тәрҗемә әсәрләргә өстенлек биргән. Әмма һәр ике артист та тәрҗемә әсәрләрен дә, милли

пьесаларны да яратып уйнаганнар, зур иҗади уңышларга ирешкәннәр. Шуңа аларны капма-каршы куярлык сәбәп юк. Ә инде Баимбетов һәм башкаларның ялган яки ялгыш фикерләре Мутинның «Миңа татар сәхнәсе тар. Көндәлек вак-төяк талашлар, гаилә ызгышлары мине канәгатьләндерми. Миңа каһарманнар дөньясы кирәк» дигән ифрат мөһим сүзләрен дөрес аңлатмаудан гына килеп чыккан дип әйтергә була.

Инглизләрнең даһи драматургы Уильям Шекспир иҗат иткән чор (XVI йөз) фикер азатлыгы хөкем сөргән, сәнгать чәчәк аткан дәвергә карый. Феодал җәмгыятьнең таркалып, алмашка капитализм дөньясының килүе, урта гасыр карашларының яңа фән ярдәмендә җиңелүе, кешене галәмнең тажы итеп тануга омтылыш тудыра. Тормышның бөтен өлкәләрендә дә титаннарча уйлый, иҗат итә алучылар җитешә. Яңарышның туган җире булган Италиядә сынлы сәнгать үзенең иң югары күтәрелешен кичерсә, Англия Ренессансының бөек казанышлары драматургиядә Шекспир иҗатында гәүдәләнә. Шулар белән бергә Шекспир гасыры зур фаҗигаләр белән дә тулы. Кешене илаһи югарылыкка күтәрү, аны сәнгать һәм фәннең табынган кыйбласы итү уе белән башланган Яңарыш тиз арада аксый башлый. Берәүләрнең сөйләп бетереп булмаслык байлык эчендә коенуы, икенче берәүләрнең хәерчелек баткагына бата баруы җәмгыятькә бик зур тетрәнүләр алып килә. Котырып баючыларның коточкыч комсызлыгы, яңадан-яңа җирләр басып алуга юл ачылу, зур табышлы сәүдәләрнең арта баруы, җирбиләүчеләргә җәмәгатьчелекнең уртак саналган җирләрен үзләштерү белән бергә крестьяннарның җирләрен тартып алырга да мөмкинлек бирелүе, бөтен илне йортсыз-җирсез, ач-ялангач, бәхетсез кешеләр белән тутыра. Аларның газаплары даһи драматургның иҗатында бөтен тирәнлеге, чын зурлыгы белән чагылыш таба. Моннан дүрт гасыр элек язылган «Король Лир»ны бүген кулына алган зыялы кеше сискәнеп куя, уйга кала. Чөнки анда тасвирланган вакыйгалар әйтерсең менә безнең дәвердә бара, хәзерге кешеләр белән кабатлана. Шескпирның үз сүзләре белән әйтсәк, «Һәр яңа да күптән таныш, иске нәрсә». Шуңа да Галиәсгар Камал театры 1999 елны «Король Лир»ны куярга алынган иде. Бу әсәр беренче тапкыр татар сәхнәсендә 1944 елны Н.Исәнбәт тәрҗемәсендә рус режиссеры М.Бебутов куелышында дөнья күргән. Әлеге спектакль турында мактау сүзләре дә, тәнкыйтьләп язылганнары да байтак. Соңгы тапкырында аны, ниһаять, үзебезнең татар егете Ф.Бикчәнтәев сәхнәләштерергә кереште. 1991 елны «Ромео һәм Джульетта»га зур сәхнә тормышы биргән режиссерның «Король Лир»га алынуы бик күпләрне шатландырды. Әмма тәрҗемәсе булган өстенә яңа тәрҗемә эшләтә башлавы гына берникадәр гаҗәпсенү тудырды. Беренче тәрҗемәнең авторы Н.Исәнбәт язучы буларак кына түгел, тел галиме буларак та шанлы шәхес... «Илдус Әхмәтҗанов Н.Исәнбәттән дә остарак тәрҗемә итә аламыни?» дигән сүзләр дә ишетелде. Әмма бу кызыксыну урынлы, табигый булса да, «Кабат-кабат тәрҗемә иттерү нигә кирәк?» диючеләр шуны оныталар — сәхнә әсәрләре өчен бу зарури хәл. Русларда «Король Лир»ның уннарча тәрҗемәсе бар. Шекспир әсәрләренең кайберәүләре аңардан да күбрәк тәрҗемә күргән. Әйтик, «Гамлет»ның тәрҗемәләре утыздан арткан. Камиллеккә омтылу белән бергә, сөйләм телебезнең заманалар узган саен туктаусыз үзгәрә баруы да этәргеч була мондый эшләргә. Һәр чор үз телендә аңлаша. Шуңар да Г.Шамуковның «Ромео һәм Джульетта»га эшләгән оста тәрҗемәсе янәшәсенә И.Әхмәтҗановның заман таләпләренә җавап бирә торган яңа тәрҗемәсе өстәлде. Ф.Бикчәнтәевнең нәкъ менә И.Әхмәтҗанов белән бергә эшләве дә очраклы хәл түгел. 22 яшьлек студент чагында ук Ф.Бикчәнтәев Лопе де Веганың «Причуды Белисы» әсәрен куя башлады һәм, шуны тәрҗемә иттерер өчен, җаны-тәне белән шигъри булган И.Әхмәтҗановны тапты… Тәрҗемә итү унынчыны бетергән теләсә кемнең кулыннан да килә диючеләр бар. Әмма нәкъ әнә шулай караучылар татар сәхнәсен начар тәрҗемәләр белән тутырып, татар тамашачысы күңелен тәрҗемә әсәрләрдән суыттылар да бит. Шекспирны бөекләр югарылыгында аңлаган М.М.Морозов турындагы истәлекләрендә Станиславский артисткасы, М.Чехов фикердәше, тарихта үз урыны булган режиссер, Эфрос кебек театр сәнгатенә зур борылышлар алып килүче режиссерларны, шул исәптән безнең татар режиссеры Ф.Бикчәнтәевне дә укыткан остаз М.О.Кнебель тәрҗемәче эшенең хәрефкә-хәреф, сүзгә-сүз, җөмләгә-җөмлә күчереп утыру гына түгеллеген, чөнки андый эш өчен

бернинди рух киеренкелеге дә, тәрҗемәче талантының да кирәкмәвен, ягъни тәрҗемә итүнең гаять газаплы иҗат эше булуын язып калдырган. Мария Осиповнаның әлеге истәлегеннән бер мисал: «Икесе дә Шекспирның чын белгечләре дип танылган Морозов һәм Т.Л.Щепкина-Куперник арасында әсәрдәге һәрбер юл өчен аяусыз сугыш барды. Ике зыялы кеше ачы тавышлар чыгарып, ярым елап, ярым ыңгырашып бер-беренә төртмәле, усал сүзләр яудырып талашкан чакларда, тәрҗемә эше барган Ермолова фатиры(тәрҗемәче Татьяна Львовна анда бөек актрисаның гаиләсе белән торган) Шекспир яшәгән чордагы Стратфорд *(Стрэтфорде-на-Эйвоне.* — Ю.С.) урамына охшап кала торган иде». Мария Осиповнаның тагын бер мөһим фикерен онытмаска кирәк: Шекспир әсәрендәге күп сүзләрне, сәхнәләрне, фикер агышларын үз варианты белән алыштырырга керешкән тәрҗемәче дә Шекспир әсәрләренә зур зыян китерә, һәм андый тәрҗемәләргә дә алмашка яңа тәрҗемәләр эшләтергә кирәк.

Инде бу ике томлыкка тәрҗемәләре кергән авторларның тәрҗемә өлкәсендәге иҗатлары турында да берничә сүз. «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмә Н.Исәнбәт 1947 елда Шекспирның «Гамлет» белән «Король Лир»ын һәм Грибоедовның «Акыллылык бәласе»н татарчалаштырды дип күрсәтә. Әмма монда ялгыш бар кебек. Татар тәрҗемәсе өлкәсендә махсус эшләүче галимнәребезнең булмавы күптөрле ялгышларга урын калдыра…

1930 елны СССР халыклары сәнгатенең Беренче Олимпиадасы Татар театрының җитешсез якларын ача. Жюри чыгарган карарның төп фикере татар режиссурасының замана югарылыгында булмавы һәм милли драматургияне дә үстерү кирәклеге хакында була. Г.Кутуй бу уңайдан Татар театрында дөнья һәм рус классикларының тәрҗемәләрен куяр өчен СССРның иң-иң талантлы режиссерларын чакырыйк дип язып чыга. Һәм, чыннан да, Олимпиаданың уңай йогынтысы буларак, театрда төрле юнәлештә үзгәрешләр башлана. Бер-очтан Шекспирның Г.Кәрам тәрҗемәсендәге «Отелло» һәм Гали Рәхим тәрҗемә иткән «Гамлет» трагедияләре кабат репертуарга кайта. 1935 елны баш режиссер булып килгән Г.Хавис «Король Лир»ны куярга әзерләнәм дигән интервью бирә. Әмма «Король Лир» сәхнәләштерелми. Моның сәбәбен Хависның ике сезоннан соң ук театрны калдырып китүе белән бәйләп аңлатып буладыр. Режиссер Г.Хависның кайсы тәрҗемәче әсәрен куярга теләве дә билгесез. Авторлар икәү булган дип фаразлыйк. Чөнки «Король Лир»ны рус, төрек, француз телләрен камил белгән һәм русча-татарча сүзлек төзүдә катнашкан югары белемле Г.Кәрамның татарчалаштырган булуын әйткән идек. Аның да күп тәрҗемәләре, шул исәптән «Отелло»сы да сәхнәдә зур уңыш белән барган. «История советского драматического театра» дигән 6 томлыкны язган авторларның берсе Баян Гыйззәт «Отелло»ның 1921, 1929, 1932, 1935 елларда кат-кат яңартып куелганын әйтә. Боларның һәммәсенә дә, мөгаен, Г.Кәрам тәрҗемәсе нигез итеп алынгандыр. Ә менә 1953 елда сәхнә күргән «Отелло»ны режиссер Р.Тумашев Г.Шамуков тәрҗемәсендә сәхнәләштерә. Әйе, әнә нәкъ шуның кебек, Г.Кәрамның «Король Лир»ы булганы өстенә яңасын эшләп бирүне Н.Исәнбәткә тапшырган булулары да бик ихтимал. Аның бу дәвердә тәрҗемә өлкәсендә дә ныклап иҗат итүе мәгълүм. Исәнбәтнең Академия театрына махсус эшләгән беренче тәрҗемәсе — Мольерның «Тартюф» комедиясе — 1936 куелып уңышка ирешсә, А.Пушкинның «Таш кунак» трагедиясе 1937 елда сәхнәгә күтәрелеп зур резонанс ала. Ә Бебутов куйган «Король Лир»га килсәк, ул 1944 елны, нәкъ менә Н.Исәнбәт тәрҗемәсендә сәхнә күрә — язучыларның биобиблиографик белешмәсендә күрсәтелгәнчә — 1947 елда түгел. Белешмәдәге «Исәнбәт «Гамлет»ны 1947 елны тәрҗемә итә» дип әйтүләре дә шик уята. 1936 елны сәхнәдә Г.Рәхимнең проза белән тәрҗемә ителгән «Гамлет»ын күрүгә үк шагыйрь Исәнбәт аны шигырь белән татарчалаштыра башлаган булса кирәк. Чөнки аның шигырь белән тәрҗемә ителгән «Тартюф»ы һәм дә «Таш кунагы» да шушы елларда гөрләп бара. «Гамлет»ны ул, әлбәттә, ашыкмый гына тәрҗемә итә. Үз ирке белән. Чөнки аны берәү дә куябыз дип ашыктырып тормый. 1952 елны «Гамлет»ны китап итеп чыгарырга әзерләгәндә, тәрҗемәче болай ди: «Гамлет»ны инглизчә оригиналыннан файдаланып эшләдем һәм рус телендәге яңа тәрҗемә — 1937 елгы Лозинский тәрҗемәсе буенча редакцияләдем». Н.Исәнбәт «Гамлет»ны сәхнәдә күрә алмады... Тәрҗемәсенә җиде дистә ел тула дигәндә, аны режиссер Олег Ханов

Туймазы татар дәүләт театры сәхнәсендә куйды. «Гамлет» спектакле Мәскәүдә узган «Кечкенә шәһәр театрлары фестивале»ндә җиңү яулады. А.Грибоедовның «Акыллылык бәласе»нә килсәк — авторның шушы көнгә кадәр сәхнәләштерелмәгән бердәнбер тәрҗемәсе булып кала. Бусы да Н.Исәнбәт тарафыннан шигырь белән тәрҗемә ителгән әсәр. Н.Исәнбәттән соң тәрҗемәдә Г.Шамуков дәвере башлана. Мөгаен, тәрҗемәчеләребез арасында иң күп эшләүче улдыр. Шамуков татарчалаштырган авторлар саны гына да дистәдән артып китә. Лопе де Вега, П.Бомарше, Ж.Б.Мольер, Ф.Шиллер, А.Грибоедов, Н.Гоголь, А.Пушкин, А.Островский, М.Горький, Г.Боровик, Ю.Фучик һәм, әлбәттә, У.Шекспир. Ике томлыкка Г.Шамуковның «Отелло», «Чамасына күрә чарасы», «Тылсымлы айлы төндә» һәм «Венеция сәүдәгәре» кебек әсәрләре керде. Болардан соңгы икесенең, бигрәк тә «Венеция сәүдәгәре»нең, сәхнә тормышы күргәне юк. Ул заманында Марсель Сәлимҗанов соравы буенча тәрҗемә ителә. Г.Шамуков төп рольдәге яһүд кешесе Шейлокны үзе уйнарга хыяллана. Әмма аларны обкомга чакырып алалар һәм бу әсәрне, «милли мөнәсәбәтләргә кирәкмәгән кызыксыну уята» дип, куймаска киңәш итәләр. «Тылсымлы айлы төндә» комедиясенә килсәк, анысы 1999 елны Ф.Бикчәнтәев укыткан курс студентларының диплом спектакле буларак күрсәтелгән иде. Шул кичтә аңа зуррак сәхнә тормышы теләүләре хәтердә. Ф.Бикчәнтәев үзе дә диплом эшен караучыларның теләкләренә: «Ярый, уйлап карарга кирәк булыр», — дип ризалык бирде. Димәк, бу әсәр үз чираты җитүне генә көтә. Язылышы, комедия өлкәсенә алып килгән искиткеч зур яңалыклары белән Шекспирның хәтта «Буря» («Давыл») һәм «Мера за меру»(«Чамасына күрә чарасы») комедияләреннән дә камилрәк, үзенчәлеклерәк бу әсәрнең дөнья әдәбиятында тиңдәше юк. Әгәр татар театры аны «күтәрә» һәм «алып та бара алса», дөнья халыклары алдында татар театрының шанлы исемен тагын да калкурак итеп күрсәтә алыр иде. Үз вакытында татар тамашачысы «Чамасына күрә чарасы»н да яратып, аңлап карады. Празат Исәнбәт куйган бу спектакль Шекспирдагы шигъранәлеккә үк күтәрелә алмады диючеләр дә булды булуын, әмма режиссерның Шекспирны сәхнәләштерүдәге беренче тәжрибәсе генә икәнен, шуңа да карамастан аның әсәрдәге иң төп фикерне бөтен зурлыгы белән ача алуын да икърар итү кирәк. Әйе, хакимиятнең каты куллысы да (Анджело), либераль булганының да (Герцог) асылы бер үк — буйсындыру! Алар омтылган максатка төрле юл, төрле ысул сайласалар да, әйтик, беренчесе үзенең кызлык намусын Аллага багышлаган Изабелланы көчләп, алдап үзенеке итәргә теләсә, икенчесе кызны кызыксындыру юлы аша үзенә каратырга тырыша — ахыр нәтиҗәләр бер үк — кызны сайлаган изге юлдан аздыру, адаштыру. Власть, кем кулында булса да, изгелеккә хезмәт итә алмый, ди Шекспир… Шекспирның бу бөек әсәре 2006 елда яңа сулыш алды. 2 нче курс җитәкчесе Ф.Бикчәнтәев һәм курсның педагоглары Р.Бариев һәм Р.Фазлиевлар үзләренең студентлары белән «Чамасына күрә чарасы»н имтиханда күрсәттеләр. Алкыш өстенә алкыш алган бу имтиханнан соң «Чамасына күрә чарасы»н кабат театр репертуарына кайтарасы иде дигән теләкләр яңгырады.

«Тискәрегә — авызлык» кебек тәрҗемәсе белән үк үзен Шекспирны да тәрҗемә итә алучы талант иясе итеп күрсәтә алган Зөлфәт Маликов әлегә Шекспирның шул бер әсәре белән генә билгеле. «Тискәрегә — авызлык» үз заманында бик озак сәхнә тотты. Зөлфәтнең тәрҗемә өлкәсенә аяк басуы 70 нче елларда Р.Бикчәнтәев соравы буенча Лопе де Веганың «Биюче» әсәрен тәрҗемә иткәч башланды. Тәрҗемәсе искиткеч камил булса да, режиссерына «Биюче»не Күчмә театрда (К.Тинчурин исемендәге дәүләт драма театры) куярга ирек бирмәделәр. Әмма Зөлфәт «Биюче»се югалмады, башта аны яшь щепкинчылар 1988 елда эшләп карадылар, аннары тәрҗемә ителүенә 23 ел тулганда, аны Р.Бикчәнтәевнең улы Ф.Бикчәнтәев сәхнәгә күтәрде. Шуннан Зөлфәт театр өчен Шиллерның «Юлбасарлар»ын тәрҗемә итте. Анысы да уңыш казангач, Шекспирның югарыда әйтелгән, тәрҗемә өчен ифрат авыр шигъри комедиясе, «Укрощение строптивой»ны татарчалаштырды. Шигырь белән язылган пьеса кат-кат рифмалашкан юллардан торса да, тәрҗемәсендә дә нәкъ Шекспирдагыча булуы белән соклану уята, хәтта әсәрнең тәрҗемәдәге исемен генә дә елмаймый укып булмый иде. Ягъни «Тискәрене буйсындыру» гына түгел, ә «Тискәрегә — авызлык». Шагыйрь дөрес сизгән, «буйсындыру» сүзе бу очракта Шекспир комедиясе таләп

иткән образны тудырмый. Сәнгать ул акыл сату урыны түгел, ул — образлар дөньясы. Зөлфәтнең комедиягә тапкан исеменнән Шекспир яшәгән дәвернең утлы сулышы аңкып тора кебек. Иреклесез, табигать кануннарына баш бирмәскә теләп упкынга таба ыргылып чапкан ярсу аргамакны һәм аның тискәрелегенә чик куючы авызлыкны күз алдына китерәсең. Ул Шекспир сонетларындагы төп фикергә дә барып тоташа:

Мавыкканың кем дисеңме? — һаман үзең,
Гомер ямең үз-үзеңнән урлыйсың син.

Әйе, моннан дүрт гасыр элек яшәгән ярсу рухлы кыз һәм аны нәселе, кешеләрнең киләчәге хакына үзен-үзе җиңәргә мәҗбүр иткән мәхәббәт авызлыгы. Ат кебек гүзәл җан иясенә гашыйк татарга аеруча якын бу «Тискәрегә авызлык» дигән исем. Милләт белән милләтләрне дуслаштырыр өчен, аларның йөрәкләре арасында образлардан күпер салу кирәк...
Ике томлыкка дүртенче тәрҗемәче булып кергән Шәрәф Мөдәрриснең «Ричард III» трагедиясенә ярты гасыр элек ясаган тәрҗемәсе дә авторның бердәнбер эше. Аның сәхнә күргәне юк. Инглиз теленнән турыдан-туры тәрҗемә булган бу эш белән вакытында Р.Бикчәнтәев тә, М.Сәлимҗанов та кызыксынды. Р.Бикчәнтәевнең теләге үзе куйган спектакльдә Ричард ролен уйнау иде. Соңрак ул бу әсәрдән «Макбет»ны өстенрәк куя башлады. Ә М.Сәлимҗанов Ричардны Ринат Таҗетдиновтан уйнатырга теләде. Күңеленда Отеллоны уйнау хыялы булган Р.Таҗетдинов шундук бу тәкъдимнән кабынып китте. Тик М.Сәлимҗанов күпмедер вакыттан соң Шиллерның «Фиеско фетнәсе» белән әвәрә килә башлады. Рольләрен дә бастырып алды. Беравыктан кабат «Ричард III»кә әйләнеп кайтты. Бик күп тәрҗемәләр үз вакытында китап булып чыкмый калганга югалалар. Берара хәтта Ш.Мөдәрриснең «Ричард III»е дә югалып торды, аннары бәхетебезгә диикме, табылды. Китапта басылып чыккан тәкъдирдә, ул инде сакланыр һәм сәгате суккач куелыр да дип өметләнергә була.
Соңгы иң яшь авторыбыз Илдус Әхмәтҗановка килик. Рус тәрҗемә мәктәбе үрнәгендә башланган татар тәрҗемә эше бүген яңа сулыш алды дип әйтүчеләр иң әүвәл И.Әхмәтҗан тәрҗемәләрен күз алдында тоталар. Китапка аның өч эше керде. «Антоний һәм Клеопатра», «Ромео һәм Джульетта» һәм алда телгә алынган «Король Лир» трагедиясе. Король Лирны Шәүкәт Биктимеров уйнарга тиеш иде. Репетицияләре гаҗәп кызык башланды. Лирның Шамакае итеп Искә ндәр Хәйруллин куелган иде. Калган артистлар да бик уңышлы сайланган иде… «Король Лир»ның әле һаман сәхнә күргәне юк, театрның да аңардан баш тартканы юк, ул гүзәл әсәр дә үз вакыты җиткәнне көтә. И.Әхмәтҗановның Шекспирдан иң беренче булып тәрҗемә иткән «Антоний һәм Клеопатра»сының да язмышы кызык. Аңа тәрҗемәгә заказны искиткеч талантлы, трагик сиземләүгә ия режиссер Дамир Сиражиев тапшыра. Дамир, театр дөньясына килеп кергәндә үк, күпләрне сискәндереп җибәрде. Диплом эше итеп аның Брехтның «Мамаша Кураж»ын куясы килгән иде. Рөхсәт итмәделәр. Т.Уильямсның «Трамвай «Желание»сен куя башлады — туктаттылар. «Ахырзаман»ны сәхнәләштергәч, «Антоний белән Клеопатра»ны да башлап карады. Төп рольләрдә Әзһәр Шакиров һәм Зөлфирә Зарипова иде. Әмма сәнгать корбаннар сорый дигән гыйбарәнең дөреслеген тагын бер кат раслагандай, И.Әхмәтҗановның шәп тәрҗемәсен Сиражиевтан алып ТЮЗның баш режиссеры Цейтлинга тапшырдылар. Төп рольләрне Р.Таҗетдинов белән А.Гайнуллина башкарды.

Югала барган яки вакытында бастырып чыгарылмавы аркасында гомум әйләнештән төшеп калган тәрҗемәләр турында уйласаң, күңелгә авыр булып китә. Театрның, һичьюгы, Шекспир әсәрләрен, китап итеп чыгарып, коткарып калырга тырышуы, әлбәттә, күркәм күренеш. Шуны да онытмыйсы иде, киләчәктә башка бөек драматургларның, шул исәптән Лопе де Вега, Мольер, Шиллер, А.Островский, А.П.Чехов әсәрләренең тәрҗемәләрен дә бастырып чыгару җаен табарга иде. Әйтик, И.Әхмәтҗановның Ф.Бикчәнтәев соравы буенча Брехттан тәрҗемә иткән «Өч тиенлек опера»сы бар. Шиллерның Зөлфәт каләме аша туган «Юлбасарлар» трагедиясе килер буын тәрҗемәчеләренә дә үрнәк булырлык. Чехов юбилее уңае белән чыгарылган китабына юбилейны үткәрүчеләрнең Г.Шамуковтан бик ашыктырып эшләтеп алган «Өч сеңел» тәрҗемәсен дә театр И.Әхмәтҗановтан кабат тәрҗемә иттерергә

мәҗбүр булган иде. Спектакль казанган зур уңыш тәрҗемәченең дә уңышы. Димәк, ул да басмада калырга хаклы. Бәхәсләр булган, булып тора һәм булачак та, әмма алар театрның үсеше өчен зарури булган тәрҗемә ижатын туктата алмаганнар, туктата да алмаслар. Тәрҗемәчеләр остарганнан-остара бара, тәрҗемәләре дә камилләшкәннән-камилләшә.

Юныс Сафиуллин,
Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының
әдәби бүлек мөдире.
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Король Лир

Трагедия

Биш пәрдәдә

Илдус Әхмәтҗанов *тәрҗемәсе*

КАТНАШАЛАР:

Лир — Британия короле.
Гонерилья — Лирның олы кызы.
Регана — Лирның уртанчы кызы
Корделия — Лирның кече кызы.
Олбания герцогы (Олбани) — Гонерильяның ире.
Корнуэль герцогы (Корнуолл) — Регананың ире.
Франция короле.
Бургундия герцогы.
Граф Кент.
Граф Глостер.
Эдгар — Глостерның улы.
Эдмунд — Глостерның никахсыз туган улы.
Освальд — Гонерильяның баш хезмәтчесе.
Шамакай.
Куран — Глостерның хезмәтчесе.
Сарай йомышчысы.
Карт — Глостердан биләмәгә җир алып торучы.
Табиб.
Офицер.
Сөрәнче.

Лирны озатучы рыцарьлар, офицерлар,
хезмәтчеләр, чапкыннар, солдатлар,
сарай хадимнәре.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Король Лир сарае. Кент, Глостер һәм Эдмунд керәләр.

Кент. Мин король йөрәгенә Корнуоллга караганда герцог Олбани якынрак тора дип уйлый идем.
Глостер. Барыбызга да шулай тоела иде. Ләкин хәзер, корольлекне бүлгәндә, кем якынрак торганын чамалый да алмыйсың, чөнки өлешләр шулкадәр тигез бүленгән, күпме генә чагыштырып карасаң да, аерма юк.
Кент. Бу сезнең улыгызмы, милорд?
Глостер. Әйе, сэр, минем җимеш. Мин әвәләгән нәрсә. Шул хакта сөйләгәндә, оятымнан гел кызара торган идем, инде оят качты, кызармый башладым.
Кент. Мин сезне аңламыйм.
Глостер. Ә аның анасы шундук аңлады, шуңа күрә, корсагы борынына терәлүгә, уйнаштан бала тапты. Шушы гөнаһ шомлыгын.
Кент. Мондый җегет тудыру гөнаһ түгел.
Глостер. Минем законлы улым да бар, моннан бер яшькә олырак, тик бу уйнаштан туганны аннан ким яратмыйм. Бу җир бит дөньяга чакырылмаган кунак булып килсә дә, анасы бик чибәр иде, баланың оеткысын туглаганда, икебез дә рәхәтләнеп тир түктек, шуңа күрә улым итеп танырга туры килә дә. Эдмунд, син бу затлы әфәнде белән танышмы?
Эдмунд. Юк, милорд.
Глостер. Бу — граф Кент. Минем иң хөрмәтле дустым, исеңдә тот.
Эдмунд. Хезмәтегезгә әзермен, галиҗәнап.
Кент. Танышуыбызга шатмын. Киләчәктә сез миңа ошарсыз дип уйлыйм.
Эдмунд. Ышанычыгызны акларга тырышырмын.
Глостер. Ул тугыз ел читтә яшәде, озакламый тагын шул якларга китәчәк. Әнә бирегә король килә.

Сәхнә артында быргы тавышлары. Таҗ тоткан сарай хадиме, Лир, Корнуолл,
Олбани, Гонерилья, Регана, Корделия һәм иярченнәре керәләр.

Лир

Глостер, бар, бирегә чакырып китер
Француз һәм Бургунд хакимнәрен.

Глостер

Хәзер, хөкемдарым.

Глостер һәм Эдмунд китәләр.

Лир

Шул арада
Ниятебез өстенә төшкән шик пәрдәсен
Алып ташлыйк. Яле, картаны бир.
Мәгълүм булсын: калган гомер юлын
Тыныч кына узу ниятеннән,
Тормыш йөген хәлсез җилкәбездән
Яшьрәк җилкәләргә йөкләү өчен,
Корольлекне бүген өч кисәккә
Бүләргә без катгый карар кылдык.
Сез, Корнуолл, һәм дә сез, Олбани,
Тигез күргән ике киявебез!
Киләчәктә гауга чыкмасын дип,
Сезнең алда хәзер кызларыбыз
Бездән нинди бирнә алачагын
Һәммәгез дә ишетерлек итеп
Игълан итәчәкбез. Өстәвенә

Төпчек кызыбызның кулын сорап,
Француз һәм Бургунд хакимнәре
Кунак булып ята әнә күптән,
Йөрәкләре яна көнчелектән,
Һәм алар да бездән җавап көтә.
Йә, кызларым! Шулай итеп сезгә
Тапшырыла бүген бөтен җир-су,
Хакимият эше һәм ил белән
Идарә итү, әмма аңа кадәр,
Һәркайсыгыз үз телегез белән,
Үз атасын ничек яратуын
Сөйләп бирсен, һәм без шуңа карап
Билгеләрбез сезгә бирнәне дә.
Табигате белән кем баерак,
Өлеше дә аның булыр мулрак.
Гонерилья, син бит өлкәнебез,
Әүвәл сине тыңлыйк.

Гонерилья

Хөкемдарым,
Сезне ничек сөюемне сүзләр белән
Аңлатырлык булса икән. Ирек, хөрлек,
Сәламәтлек, хакимият, дан-дәрәҗә,
Бу тормышны бөтен гүзәллеге белән
Сөйгән кебек сөям сезне. Күз алмамдай
Кадерлем сез. Моңа кадәр бу җиһанда
Мондый сөю күрмәгәндер һичбер ата.
Аңлатырга сүз табалмыйм... Сулышым каба...

Корделия
(читкә)

Корделия нәрсә әйтер? Нәрсә әйтсен?
Дәшми генә яратырга язган аңа.

Лир

Бу сызыктан менә шушы чиккә кадәр,
Күләгәле карурманнар, елга-күлләр,
Иксез-чиксез көтүлекләр, бай үзәннәр —
Һәммәсе дә сиңа булсын. Бу җирләрне
Синең белән Олбанидан туган токым
Мәңге биләр. Инде хәзер уртанчыбыз
Корнуоллга яр булганы нәрсә сөйләр?
Йә, сөйкемле Регана, без тыңлыйбыз.

Регана

Апам белән бер үк безнең асылыбыз,
Бер мәгъдәннән коелганбыз — бәябез бер.
Йөрәгемнең иң яшерен почмагында
Нәкъ шундый ук сөю сүзен саклап йөртәм.
Өстәп шуны әйтә алам: мин ваз кичәм
Безнең хисләр сыйдыралган бар шатлыктан.
Сезне сөю белән генә бәхетле мин.

Корделия

Әй бичара Корделия! Димәк, күңелең
Мәхәббәткә коргаксыган? Юк, юк, бай ул —
Минем сөю сүзгә генә сыя алмый.

Лир

Бар дәүләтнең өчтән берен тәшкил иткән
Шушы өлешен, кызым, сиңа тапшырабыз.
Бөтен нәсел-нәсәбеңә мәңгелеккә.
Күләме һәм гүзәллеге, уңдырышы
Гонерилья өлешеннән һич ким түгел.
Күз нурыбыз-төпчегебез нәрсә әйтер?
Француз йөземе Бургундия сөте белән
Синең өчен бертуктаусыз бәхәсләшә.
Бирнәбезнең башкалар да кызыгырлык
Иң мул өлешен алыр өчен син ни дисең?

Корделия

Берни әйтмим, хөкемдарым.

Лир

Берни?

Корделия

Берни.

Лир

Бернидән бит берни чыкмый! Уйлап сөйлә.
Өр-яңадан башла әйдә.

Корделия

Ни кызганыч,
Күңелемдәген телем белән аңлатырга
Мин сәләтсез. Галиҗәнап, сезне исә,
Үз атасын бала ничек сөйсә,
Шулай сөям. Артык та һәм ким дә түгел.

Лир

Әй, әй, Корделия! Төзәт җавабыңны,
Язмышыңа әгәр аяк чалмыйм дисәң.

Корделия

Мәрхәмәтле хөкемдарым, сез бит миңа
Гомер биреп, назлап, сөеп үстергәнсез.
Мин дә сезне кыз балага тиеш микъдар
Яратамын, хөрмәт итәм һәм буйсынам.
Сөю хисен тулысынча сезгә биргәч,
Ник кияүгә чыкканнар соң апаларым.
Әгәр дә мин никахлансам, сөюемнең
Нәкъ яртысы насыйп булыр хәләлемә.
Иргә чыккач, тик этине яратам, дип
Антлар итү кирәкми ул һич кенә дә.

Лир

Чынлап әйтәсеңме?

Корделия

Әйе, хөкемдарым.

Лир

Япь-яшь көе күңелең шундый катымыни?

Корделия

Яшьлеккә яшь, әмма күңелем туры минем.

Лир

Алай булса киләчәктә турылыгың
Бирнәң булып хезмәт итсен. Ә мин бүген
Изге кояш нурлары вә сихри төннең
Серле ае белән һәм дә галәмдәге
Безгә яшәү яки үлем китерүче,
Йолдызларның тәэсир көчен шуңа кушып,
Ант итәмен. Бүгеннән соң йөрәгемдә
Сиңа урын булмаячак. Бүген синнән
Тулысынча ваз кичәмен. Һәм хәзер мин
Кыргый скиф йә булмаса ата-анасын
Тере килеш ашый торган бер вәхшине,
Элек кызым булган заттан, ягъни синнән
Кадерлерәк, якынрак күрәчәкмен.

Кент

Мәрхәмәтле хөкемдарым!

Лир

Син дәшмә, Кент!
Аждаһаның нәфрәте һәм аңа корбан —
Монафикъның арасына син тыгылма.
Ул бит минем иң сөекле кызым иде.
Карт көнемдә тәрбиячем булыр дисәм...
Күз алдымда торма, югал! Үз сүземнән
Әгәр дә мин кире кайтсам, ул чагында
Каберемдә ятар туфрак ташка әйләнсен.
Чакырыгыз француз һәм бургундлыны!
Ни торасыз? Әй Олбани һәм Корнуолл!
Аңа тигән өлешне дә бүлешегез.
Горурлыгы белән әнә туры күңеле
Табып бирсен аңа ирне, ә мин сезгә
Икегезгә дә тулы хокук, өстенлеккә
Ия булган власть бирәм, ә без исә
Нәүбәт белән һәр ай саен берегездә
Яшәргә дип карар кылдык. Хадимнәрем
Йөз рыцарь тәшкил итә, аларның да
Тәрбиясе, чыгымнары сезнең өстә.
Король дигән исемебезне, титулларны
Үзебездә калдырабыз, ә калганын —
Хакимият, власть һәм дә казна эшләрен
Улларыма, ягъни сезгә тапшырабыз.

Бу сүзләргә дәлил — менә тажыбыз сезгә,
Урталайга бүлешегез.

Кент

Әй бөек Лир!
Галиҗәнап күреп сине хөрмәт итәм,
Үз атамдай күреп сөеп хезмәт итәм,
Яклаучым дип догам саен телгә алам...

Лир

Җәя тарткан, ук каршына килеп басма.

Кент

Әйдә, тишсен йөрәгемне ук, ичмасам.
Король акылын жуйган чакта, югал әдәп.
Нәрсә уйлап чыгардың син, әйтче картлач?
Мактауларга түзалмыйча хакимият
Җимерелеп барган чакта, әллә мине
Күрә торып дәшмәс диеп уйладыңмы?
Бел, олпатлык ахмаклыкка кереп батса,
Намуслыны бурычы әйди туры сүзгә.
Бу коточкыч ашыгудан арын, зинһар,
Хакимият эшен кулдан ычкындырма.
Башым белән жавап бирәм, төпчек кызың
Сине һич тә ким яратмый. Гәрчә сүзгә
Артык юмарт булмаса да. Купшы сүзләр
Буш күңелдән чыга күбрәк. Акылыңа кил!

Лир

Башың исән калсын дисәң, дәшмә, тукта.

Кент

Лир һәм дәүләт файдасына сугышканда,
Баш кайгысы түгел миндә.

Лир

Ычкын моннан!
Күз алдымнан югал хәзер үк!

Кент

Ашыкма, Лир!
Акылыңа кил! Ышанычлы күз караң мин.

Лир

Изге Аполлон шаһит әнә...

Кент

Нигә юкка
Аллаларны кыстырасың син бирегә?

Лир

Көферлеккә барып життең? Йә, ярый, кол!
(Кылычына тотына.)

Олбани белән Корнуолл

Сабыр, хаким, зинһар, сабыр.

Кент

Юк, юк, нигә?
Үтер, үтер, табибыңны һәм чиреңне
Баштанаяк алтынга күм... Бирмә таҗны!
Юкса тавыш җепселләрем өзелгәнче:
Бирмә, бирмә, дип кычкырып торачакмын!

Лир

Инде тыңла, хыянәтче. Әлегә кадәр
Беркайчан да ант бозмаган хөкемдарны,
Көчләп антын боздырырга ниятләдең.
Син тәкәббер горурлыгың аркасында
Безнең әмер юлларына киртә кордың.
Моның белән килешалмый һәм җаныбыз,
Һәм корольлек дәрәҗәбез. Ал җәзаңны!
Биш көн вакыт сиңа бездән — юлга җыен.
Һәм әзерлән горбәт чигү җәфасына.
Алтынчы көн чәнчелеп кит — юлыңда бул!
Ун көн узгач, без биләгән биләмәдә
Үзең түгел, эзеңне дә күрмәсеннәр.
Юкса үлем. Хөкемебез һич үзгәрмәс,
Ант итәбез Юпитерның үзе белән.

Кент

Сау бул, король. Намуслыга биредә сөрген,
Чит җирләргә эзләп китә ул иреген.
(Корделиягә.)
Ачык акылың, туры сүзең өчен, кызым,
Исән-сау бул, Ходай үзе сакчың булсын.
(Гонерилья белән Реганага.)
Сез бик матур сөйләдегез сүзегезне,
Инде эштә күрсәтегез үзегезне.
Йә, хушыгыз. Чит җирләрдә мин үзгәрмәм,
Сагышымны алам чөнки үзем белән.
(Китә.)

Бырғы тавышлары. Глостерга ияреп, Франция короле, Бургундия герцогы һәм хадимнәр килеп керәләр.

Глостер

Француз һәм Бургундия хакимнәре
Сезнең алда, галиҗәнап.

Лир

Яхшы. Герцог,
Бу мәхәббәт бәйгесендә катнашучы
Көндәшләрнең берсе буларак сезгә сорау:
Кыз артыннан килер бирнә күпме булса,
Өметегез акланыр дип уйлыйсыз сез?

Бургундия герцогы

Мәртәбәле, шанлы король, сез биргәннән
Артыгын мин һич сорамыйм, шуннан да ким
Бирмәсегез билгеле бит.

Лир

Әмма, герцог,
Элек безгә ул кадерле, якын иде.
Хәзер исә бәя төште. Әгәр сезне
Туры сүзле булам диеп саташучы,
Өстәвенә фатихадан мәхрүм калган,
Киребеткән шушы йолкыш кызыктырса,
Алыгыз соң, әнә ич ул.

Бургундия герцогы

Галиҗәнап,
Ни дип җавап бирергә дә белмим инде.

Лир

Калдырыгыз, герцог. Аның байлыкларын,
Ант итәмен, һәммәсен дә санап чыктым.
(Франция короленә.)
Инде сезгә килсәк, бөек галиҗәнап,
Сезне артык яратам мин, шуңа күрә
Табигать тә кул селтәгән бу йолкышны
Хәтта тәкъдим итәргә дә теләмимен.

Франция короле

Ничек алай? Әле күптән түгел генә
Күз нурына тиң иде бит һәм мактаулы.
Картлык көнен нурландырыр бер куаныч,
Һәммәсеннән яхшырак һәм кадерлерәк
Бер зат иде. Ничек алай кинәт кенә
Шәфкатегез канатларын көйдererлек
Зур җинаять эшли алды икән соң ул?
Сөюегез әллә инде тыштан гына?
Корделия зур явызлык кылды дигән,
Коточарлык булмас эшкә ышанырга
Мәҗбүр итсә итәр мине тик могҗиза.

Корделия
(Лирга)

Хөкемдарым, мин сөйләргә оста түгел.
Миңа мактау сәнгате дә чит-ят нәрсә.
Эштән алда мактаналмыйм — гадәтем шул.
Үтенәм сездән, зинһар өчен, аңлатыгыз:
Ни сәбәпле каһәрегез миңа яуды?
Мин һичкемне суймадым һәм каһәрләрлек
Яман адым ясамадым, мин гаепсез.
Сәбәп, бәлки, башкададыр: миндә юк бит
Күккә чөеп мактый торган матур сүзләр,
Сорау катыш ялварулы күз карашы.
Булмавына мин хәтта шат. Бар гаебем
Шуннан гына тора минем.

Лир
Бу кадәрле
Ачуымны чыгарганчы, син дөньяга
Тумый калсаң әйбәтрәк булыр иде.

Франция короле

Шул гынамы гаеп? Ә ник аңа җәза?
Сабырлыгы өчен, кылган гамәлләрен
Купшы сүзгә төреп әйтә белмәгәнгә?
Йә, ни дисез инде, герцог, сез туташка?
Мәхәббәткә комсызлыкны юлдаш итсәң,
Ул мәхәббәт һич мәхәббәт түгел инде.
Аласызмы аны, герцог? Ул бит үзе —
Бар торганы белән бирнә.

Бургундия герцогы

Йә, бөек Лир,
Игълан иткән өлешегезне бирегез дә,
Корделия шул минуттан герцогиня.

Лир

Юк, бирә алмыйм. Мин ант иттем. Ә антым нык.

Бургундия герцогы

Ни аяныч, атагызны югалтып сез —
Ирегезне югалттыгыз.

Корделия

Комсызлыкны
Мәхәббәттән өстен күргәч, югалтуның
Икенчесе, герцог, мине һич борчымый.

Франция короле

Корделия, зур бәлагә тарыгач та,
Хәсрәтеңә баткач та син искитәрлек.
Ярлы килеш син тагын да сөйкемлерәк.
Бүген синнән һәммәсе дә йөз чөерде.
Алам сине, асылташым. Син — минеке.
Алар сине кимсеткәннән мәхәббәтем
Арта бара, арта бара һәм хөрмәтем.
Бирнәсез кыз! Кабул итеп ал син мине,
Сиңа бирәм йөрәгемне һәм илемне.
Бәя биреп бетергесез бәясезем!
Таш йөрәкле бургундларга юк бирәсем!
Аш белән ат син таш белән атканнарга,
Саубуллаш син, тик, кадерлем, сагышланма,
Яманлыкны яхшылыкка алышканда.

Лир

Ул синеке, король. Безгә андый кызның
Кирәге юк. Әйдә, бөтен гомере буе
Безнең хәер-фатихадан, безнең наздан
Мәхрүм калып, сагыш диңгезенә чумсын.

Киттек, герцог.

Бырғы тавышлары ишетелә. Лир, Бургундия герцогы, Корнуолл, Олбани һәм сарай хадимнәре чыгып китәләр.

Франция короле

Апаларың белән хушлаш.

Корделия

Әткәемнең җәүһәрләре! Мин биредән
Күземне яшь томалаган көе китәм.
Мин үтәли күрәм сезнең җаныгызны,
Әмма сезне кызганудан асылыгызны
Ачмый китәм. Онытмагыз антыгызны:
Әтиебезне яратырга ант иттегез.
Әгәр илдән сөрелмәсәм, мин мәңге дә
Аны бүген сезнең кулга бирмәс идем.

Регана

Син өйрәтмә безне, без өйрәнгән инде.

Гонерилья

Оста булсаң әгәр, әнә үз иреңне
Юмаларга өйрән, җайла, күңелен күр,
Ул бит сиңа кызганудан өйләнә тик.
Килешмәгән сүз сөйләдең әтигә дә,
Моннан ары иреңнән дә шуны ишет.

Корделия

Хәйләгезне ничек оста үрсәгез дә,
Бер сүтелер. Читен булыр үзегезгә.
Сау булыгыз.

Франция короле

Киттек әйдә, Корделия.

Франция короле белән Корделия китәләр.

Гонерилья. Сеңлем, икебезгә дә кагыла торган бик әһәмиятле бер эш турында сөйләшеп алырга иде. Әти кичке якта биредән китә булса кирәк.
Регана. Китә, китә, сезнең белән китә. Ә киләсе айда безгә киләчәк.
Гонерилья. Тинтәк түгел диген инде картлачны. Кыланып та күрсәтте. Сеңлебезне һәрвакыт бездән артыграк ярата иде, инде менә уйлап-нитеп тә тормыйча, нинди мәрхәмәтсезлек күрсәтте.
Регана. Акылы зәгыйфьләнеп бара. Хәер, ул элек тә акылга чамалы иде инде.
Гонерилья. Әйе, әти әле элегрәк, яшьрәк чагында да котыргалап ала иде. Ә картайгач, тагын коточкыч дуамаллык, картлык көйсезлеге дә өстәлде.
Регана. Бүген Кентны тотты да сөрде. Аның андый кыланышларын күрү киләчәктә безгә дә насыйп булыр, ахры.
Гонерилья. Йә, булмаса Француз короле белән саубуллашуын ал. Безгә бер сүздә булып эш йөртергә кирәк, әгәр дә әти киләчәктә дә шулай башбаштаклана калса, аның тәхетеннән ваз кичүе бездән көлүгә генә әйләнеп калачак.
Регана. Безгә бик әйбәтләп уйлашырга кирәк.
Гонерилья. Тик ятмаска, ни дә булса эшләргә кирәк. Тимерне кызуында сук, диләр.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Граф Глостер кирмәне. Кулына хат тоткан Эдмунд керә.

Эдмунд

Табигать, син минем өчен илаһия.
Буйсынам тик бары синең кануннарга.
Яман чирле бәндә сыман кешеләр таккан
Тамга йөртеп ник үземне кимсетәм соң?
Үз агамнан унике айга соң туганга,
Минем язмыш дучар мәллә мыскыллауга?
Ни сәбәпле «законсыз» мин, ә ник «затсыз»?
Буй-сыным да нәкъ шундый ук — ыспай һәм төз.
Акылым тулы, кыяфәтем нәкъ әти күк,
Тыйнак ханым тудырганнан кай җирем ким?
Ник уйнаштан туган диеп мыскылларга?
Йокы аралаш, тынчу гаилә түшәгендә
Әвәләнгән җыен тиле-милеләрнең
Егермесе алалмаган көч-җегәрне,
Табигать бит бездәйләрнең һәркайсына
Яралгыда чагыбызда салган була.
«Мин законсыз» дигән фикер, кач син миннән!
Син законлы законлысын, агам Эдгар,
Миңа синең җир-су кирәк, ә атабыз
«Законлыдан» кимрәк сөйми «законсызын».
Сүзе ни бит! Ярый, ярый, законлы агам,
Әгәр дә ки хат белән эш барып чыкса,
Мин законсыз туган Эдмунд, «законлыны»
Таптап кына үтәчәкмен. Мин ныгаям!
Югарыга үсәм һаман! Әй, аллалар!
Законсызны яклагыз һәм саклагыз сез!

Глостер керә.

Глостер

Кент куылды. Ә француз хөкемдары
Ачуланып китеп барды. Король исә
Тажыннан һәм казнасыннан ваз кичте дә
Сарайдан ук чыгып китте! Бик кызганыч!
Ашык-пошык булды бар да, кызган баштан!..
Йә, Эдмунд, сөйлә, нинди яңалык бар?
Эдмунд. Бернинди дә, галиҗәнап.
Глостер. Хатыңны нигә алай кабаланып яшерәсең?
Эдмунд. Миндә бернинди дә яңалык юк, милорд.
Глостер. Нинди кәгазь укып тора идең?
Эдмунд. Юк, берни дә юк, милорд.
Глостер. Берни дә юк? Алай булгач, нигә кабаланып кесәгә тыгарга? Берни дә юк икән, яшерер нәрсә дә булмаска тиеш. Кая, карыйм әле. Әгәр берни дә булмаса, мин күзлексез дә күрәм.
Эдмунд. Гафу итүегезне ялварып сорыйм, сэр. Бу хат — абыйдан. Мин әле укып та бетермәдем, ә укыган кадәресен сезнең күзгә күрсәтергә ярамый.
Глостер. Бир хатны.
Эдмунд. Бирмәскә дә ярамый, бирергә дә ярамый. Минем аңлавым буенча, бу хат гаеп итәрлек эчтәлеккә ия.

Глостер. Күрик әле, күрик.
Эдмунд. Абыйның башында яман уй булуына ышана алмыйм. Ул, әлбәттә, мине сынап кына карамакчы булган, нишләр икән дип.
Глостер *(укый).* «Картларга хөрмәт дигән сүзнең төбендә йоладан бигрәк хәйлә ята. Ул безнең гомеребезнең иң матур өлешен агулый, шуның аркасында картаеп, байлыктан ләззәт алалмаслык дәрәҗәгә җиткәнче, үз байлыгыбыздан файдалана алмыйбыз. Картлар безне тираннарча коллыкта тоталар. Алар көчле булганга түгел, без күндәм булганга шулай ул. Бу хәлгә ахмакларча түзеп тору мине тәмам туйдырды. Кил, бу турыда тәфсилләбрәк сөйләшербез. Әгәр дә әти тирән йокыга талып, шул ятуыннан мин уятканчы уянмаса, аның табышының нәкъ яртысы сине яратучы абыең Эдгар тарафыннан сиңа тапшырылыр иде». Нәрсә? Миңа каршы сүз берләшү! «Мин уятканчы уянмаса... яртысы сиңа...» Һәм бу кеше минем улым Эдгар! Моны язарга ничек кулы барды икән? Мондый мәкерле уйга килергә ничек йөрәге җиткән? Бу хатны кайчан алдың? Кем китерде?
Эдмунд. Беркем дә китермәде, милорд. Бөтен хикмәт тә шунда. Тәрәзәдән ташладылар.
Глостер. Язуы — абыең кулымы?
Эдмунд. Бу хатның эчтәлеге әйбәт булган булса, абыем кулы дип ант итәр идем. Ә бу очракта аның кулы түгел дип уйлыйсы килә.
Глостер. Юк, аныкы.
Эдмунд. Ярый, аның кулы да булсын ди, милорд. Әмма, минем уемча, ул шаярган гынадыр.
Глостер. Элегрәк ул сине үзенә иярергә өндәми идеме?
Эдмунд. Юк, милорд, беркайчан да. Әмма аңардан: «Бала балигъ булгач, атасының комы коела башласа, баланы ата түгел, киресенчә, атаны тәрбияләү бурычын бала үз өстенә йөкләргә һәм байлыгына да хуҗа булырга тиеш», — дигәнен ишеткәләргә туры килә иде.
Глостер. Ah, кабахәт, кабахәт. Нәкъ хаттагы фикер. Хайван икән. Чирканыч кабахәт! Явыз, әшәке җан, хайван. Хайваннан да яманрак. Бар әле, күгәрченем, эзләп тап әле үзен. Кулга алырга ул хайванны! Кайда ул хәзер?
Эдмунд. Белмим, милорд. Сез җәнабе галигә саллырак дәлилләр табылганчы, абыема булган ачуыгызны тыебрак торсагыз, дөресрәк булыр иде, чөнки хаксызга ябырылган нәфрәт аңарда булган атаны хаклау хисен нигезеннән җимерәчәк, шулай ук графлык намусына да бик зур хилафлык китерәчәк. Абыемның ул хатны минем сез җәнабе галигә булган мәхәббәтемне сынар өчен генә язуына башымны кисәргә бирәм.
Глостер. Шулай дисеңме?
Эдмунд. Әгәр дә сез галиҗәнапләре теләсәгез, безнең аның белән хат турында гәпләшүебезне бүген кич белән үк үз колакларыгыз белән ишетергә җай чыгачак.
Глостер. Аның андый явыз булуы мөмкин түгел...
Эдмунд. Әлбәттә, шулай.
Глостер. Аны чын күңелдән өзелеп сөйгән атасына явызлык кылырга! Җирдәге һәм күктәге илаһи көчләр! Эзләп тап аны, Эдмунд. Үтенеп сорыйм, күңеленә ачкыч тап. Бөтен акылыңны, тырышлыгыңны сал. Дөреслекне белү бәрабәренә графлыгымны да кызганмас идем.
Эдмунд. Мин аны хәзер эзләп табам, милорд, сезнең теләкне җиренә җиткереп үтәргә тырышачакмын, нәтиҗәсен шунда ук хәбәр итәрмен.
Глостер. Юк, күптән түгел генә булган ай һәм кояш тотылу галәмәтләре безгә яхшылык вәгъдә итмиләр булса кирәк. Фән ничек кенә аңлатырга тырышса да, табигать аларның нәтиҗәсен үз җилкәсендә татый: мәхәббәт суына, дуслык юкка чыга, туганнар арасында гауга куба. Шәһәрләрдә чуалышлар, авылларда үзара ызгыш, сарайларда хыянәт, аталар һәм балалар арасында табигый туганлык җебе өзелде. Минем кабахәт тә шулар рәтендә — улы атасына каршы. Һәм король дә шул юлдан китте — ата кеше үз балаларына каршы. Бәла-казалар чоры килә: кансызлык, күңел бушлыгы, сатлыкҗанлык, фетнәләр тыныч кына үтеп китәргә дә ирек бирмиләр. Кабахәтне фаш ит, Эдмунд. Буш итмәм. Бөтен тырышлыгыңны сал... Ә Кент? Изге күңелле, тугры Кент читкә сөрелде! Сәбәбе ни бит — намуслы булган өчен. Аптыраганнан авыплар китәрсең. *(Китә.)*

Эдмунд. Адәм баласының ахмаклыгы искитәрлек! Башыбызга берәр бәла-каза килсә, гәрчә, үзебез гаепле булсак та, без һәрвакыт гаепне кояшка, айга, йолдызларга аударабыз. Әйтерсең лә күкләр безне әшәке, юләр булырга, йолдызлар исә хыянәтче, карак, ялганчы булырга мәҗбүр итәләр, күк җисемнәре эчкечелеккә, азгынлыкка, ә аллалар үзләре безне үзебез эшли торган барлык кабахәтлекләргә этәрәләр. Йолдызларны гаепләү — үзенең кәҗә тәкәсенә хас хайвани теләкләрен аклау өчен азгын кешегә менә дигән сылтау. Әти белән әни мине Аждаһа койрыгы астында мәтәштергәннәр, ә тууым Җидегән йолдыз астында, шуңа күрә дә, имеш, мин әдәпсез һәм азгын. Юк сүз! Мине ясаган вакытта күктә нинди генә гыйффәтле йолдыз балкып торган булса да, мин менә хәзер нинди булсам, нәкъ шундый булган булыр идем. Эдгар...

Эдгар керә.

Ә, менә ул үзе дә, гомере озын булыр — иске комедияләрнең финалындагы сыман нәкъ вакытында килеп керә. Кайгы-сагышка баткан, гаиптән хәбәр бирүче дивана булып кыланыйм әле. *(Кычкырып.)* Аһ, бу ай, кояш тотылулар җәнҗал, гауга чыгасын алдан хәбәр иткәннәр иде бит. *(Җырлый.)* Фа, соль, ля, ми.
Эдгар. Нәрсә булды, энекәш? Нинди тирән уйга чумдың?
Эдмунд. Мин, хөрмәтле абыем, күптән түгел генә укыган — ай һәм кояш тотылулардан соң безнең белән ниләр буласын алдан хәбәр иткән күрәзәчелек турында уйланам.
Эдгар. Сиңа шул кызыкмы?
Эдмунд. Ә бит, кызганычка каршы, күрәзәчеләрнең сүзе хак: аталар һәм балалар арасында каршылыклар арта, үләт тарала, ачлык килә һәм борынгыдан килгән дуслык, туганлык җепләре өзелә. Илдә үзара ызгышлар, корольне һәм аның якыннарын яманлыйлар, аларга яныйлар, урынсызга шикләнүләр, үз дусларын читкә сөрүләр, гаскәрләрдә таркаулык, ирләр — хатыннарына, хатыннар ирләренә хыянәт итәләр — саный башласаң очына чыгарлык түгел.
Эдгар. Йолдызларга карап күрәзәчелек итү белән күптән шөгыльләнәсеңме?
Эдмунд. Көл әйдә, көл. Син әти белән соңгы мәртәбә кайчан очраштың?
Эдгар. Кичә кич белән.
Эдмунд. Син аның белән сөйләштеңме?
Эдгар. Тоташ ике сәгать буе сөйләштек.
Эдмунд. Аерылышканда сүзгә килмәдегезме? Аның чыраенда яки сөйләшүендә сиңа карата канәгатьсезлек сизелмәдеме?
Эдгар. Юк, андый нәрсә сизелмәде.
Эдмунд. Исеңә төшер әле, аның ачуын китерерлек нәрсә эшләдең икән? Һәм мин синнән үтенеп сорыйм, ярсуы сүрелгәнче күзенә чалынма — хәзер әтинең ачуы кайнаган чак, йодрыкларына юл кую белән генә тукталып калмаячагына иманым камил.
Эдгар. Кайсыдыр кабахәте минем өскә яла яккан.
Эдмунд. Мин дә шул ук фикердә. Син, зинһар, сабыр ит, саклан. Минем бүлмәгә кереп качып тор, мин сиңа әтинең ничек котырганын үз колакларың белән ишетергә мөмкинлек тудырачакмын. Менә сиңа ачкыч, бар, бүлмәгә кер, ялварып сорыйм. Урамга чыкма, әгәр чыксаң, үзең белән корал ал.
Эдгар. Корал?
Эдмунд. Туганым, мин сиңа яхшы булсынга тырышам. Синең баш очыңда кара болыт куера, шулай булмаса, кабахәт булыйм. Мин күргәннәремне, ишеткәннәремне өстән-өстән генә сурәтләдем әле. Әтинең ачудан коточкыч кыяфәткә керүен йомшартыбрак сөйләдем. Бар, зинһар, качып тор.
Эдгар. Сине тагын тиз генә күрәмме соң әле мин?
Эдмунд. Бу эштә мин тулысынча синең карамакта. *(Эдгар китә.)*

Эдмунд

Безнең әти — ышанучан, ә абыем —
Вөҗданлы һәм намуслы бер җан иясе,

Күңелендә башкаларга явызлык юк,
Аның шушы ахмаклыгы миңа файда.
Затлылыгың җитми икән — акыл белән
Ирешергә туры килә максатыңа.
(Китә.)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Олбания герцогының сарае. Гонерилья белән Освальд керәләр.

Гонерилья. Шамакаен орышкан өчен генә дә әти минем хезмәтчемә суктымы?
Освальд. Нәкъ шулай, ханым.

Гонерилья

Сәгать саен ни дә булса килеп чыга.
Кыланышы кырга сыймый. Көне-төне
Бөтен йортның астын өскә әйләндерә.
Моңа күпме түзеп тору мөмкин тагын?!
Сакчылары — җәнҗалчылар, ә ул үзе
Бер дә юктан даулашырга әзер тора.
Аудан гына кайтсын әле, янына да
Чыкмыйм хәтта. Булды, җитте. Гарык булдым.
Авырый дип әйт син мине һәм үзең дә
Ә дигәнгә, йә дип торма, катырак бул.
Куркып торма, аңа ярап булмаячак.

Освальд

Әнә кайта. Ишетәсезме, бырғы тавышы.

Гонерилья

Хезмәтчеләр тыңламасын, әйтеп куй син,
Һәммәсе дә начар хезмәт күрсәтсеннәр.
Дорфа, тупас кыланыгыз. Ошатмаса,
Юлы такыр — сеңелкәшкә китеп барсын.
Аның белән бер уйда без һәм бер сүздә,
Үзебезне җәберләргә юл куймабыз.
Хакимлектән ваз кичкәч тә баш булмакчы.
Сабый акылы кергән андый карт юләргә
Каты тору — бу бердәнбер дөрес чара.
Әйткәннәрне исеңдә тот.

Освальд

Тыңлыйм, ханым.

Гонерилья

Рыцарьлар белән булган мөгамәлә
Мөмкин кадәр салкын булсын һәм курыкмагыз,
Миңа хәзер сылтау кирәк, күңелемдәген
Яшермичә турыдан-туры әйтер өчен.
Бу турыда сеңелкәш тә белеп торсын
Һәм теләктәш булсын безгә, хат җибәреп,
Хәбәр итик. Ә хәзер, бар, аш әзерләт.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук сарай залы. Киемен алмаштырган Кент керә.

Кент

Элеккеге кыяфәтне тулысынча
Минем йөздән сөртеп аткан максат өчен,
Тавышны да үзгәрталсам — инде була.
Сөрелгән Кент, сине читкә кагучыга
Хезмәтче бул, әйдә, тырыш, хөрмәт иткән
Һәм яраткан хөкемдарың файдасына.

Сәхнә артында бырги тавышы. Лир һәм рыцарьлар керәләр.

Лир. Ашарга кичекмәстән аш бирелсен. Бар, әйт әле, хәстәрен күрсеннәр.

Беренче рыцарь китә.

Сиңа ни кирәк? Кем син?
Кент. Кеше мин, милорд.
Лир. Кәсебең ни?
Кент. Кәсебем — үз-үзем булып калу, кем миңа ышана, шуңа тугры хезмәт итү, намуслыны ярату, аз сүзле һәм акыллының сүзенә колак салу. Күңелемдә аллалардан курку йөртәм, эш сугышуга барып җитсә, сугышам һәм католиклар балыгын ашамыйм.
Лир. Ә кем соң син?
Кент. Мин — гади кеше, тугры йөрәкле һәм король күк ярлы.
Лир. Әгәр дә син гади халык арасында, ул корольләр арасында бай булган кебек бай булсаң, ул чагында син чыннан да ярлы. Инде әйт, теләгең ни?
Кент. Хезмәт итү.
Лир. Кемгә?
Кент. Сезгә.
Лир. Син бит мине белмисең.
Кент. Белмим. Әмма сезнең йөзегездә хезмәт итәргә боеручы бернәрсә бар.
Лир. Нәрсә соң ул?
Кент. Хөкемдарлык.
Лир. Ә нинди хезмәт күрсәтә аласың?
Кент. Телне теш артында тота беләм, ат менеп тә чабам, йөгерәм дә, хикмәтле вакыйгаларны хикмәтеннән арындырып та сөйләп бирә алам һәм, беркемнән дә курыкмыйча, дөреслекне ярып салырга да булдырам. Мин гади халык башкара алган бөтен эшкә дә ярыйм, ә иң зур өстенлегем — тырышлык.
Лир. Сиңа ничә яшь?
Кент. Мин тавышы матур булган өчен генә хатын-кызга гашыйк булырлык яшь түгел, сэр, шулай ук теләсә нинди калтыравык тавышлы хатыннар өстендә мышкылдап ятарлык карт та түгел. Артымнан кырык сигезенче яшем куып килә.
Лир. Ярый, миңа хезмәт итеп кара. Әгәр әбәттән соң да күңелем бизмәсә, үз янымда калдырырмын. Әй, кем бар анда?! Ашарга китерегез! Кайда минем Шамакаем? Бар әле, чакыр үзен.

Икенче рыцарь китә. Освальд керә.

Әй, хезмәтче, нишләп кызым чыкмый?
Освальд. Сезнең рөхсәтегез белән...
(Китә.)
Лир. Ул ни диде? Кире борыгыз әле шул тинтәкне!

Өченче рыцарь китә.

Һәй, кайда минем Шамакаем? Әллә бөтен дөньясы мәрткә киткән инде.

Өченче рыцарь әйләнеп керә.

Йә, шуннан? Кайда ул теге хайван?
Рыцарь. Галиҗәнап, ул әйтә, кызыгыз сырхаулап тора, ди.
Лир. Ә ни өчен ул мин дәшкәч кире борылмый?
Рыцарь. Галиҗәнап, ул миңа турыдан-туры, теләмим, дип җавап бирде.
Лир. Теләми?!
Рыцарь. Хөкемдарым, мин, әлбәттә, сәбәпләрен белмим, әмма минем уемча, сез галиҗәнаплары биредә тиешле хөрмәт һәм игътибар күрми. Хезмәтчеләрдә дә, герцогның үзендә дә һәм хәтта кызыгызда да сезгә карата булган ихтирамның кинәт кенә юкка чыгуы сизелә.
Лир. Шулай дисеңме?
Рыцарь. Галиҗәнап, әгәр дә ялгышсам, зинһар, кичерә күрегез. Әмма сез галиҗәнапларын кимсеткәнне күрә торып дәшми калырга бурычым кушмый.
Лир. Андый уй минем үземнең башка да килгән иде — шушы араларда үземә карата җиңелчә генә игътибарсызлык, санга санамау ише нәрсәләр сизә башладым, ләкин мин аларга начар ният белән эшләнгән эш итеп түгел, ә үземнең шикчеллегем нәтиҗәсе дип кенә караган идем. Моның төбенә төшәргә кирәк. Кайда соң минем бу диванам? Инде икенче көн күзгә-башка күренми.
Рыцарь. Төпчек кызыгыз Франциягә киткәннән соң, ул бөтенләй боегып калды.
Лир. Бу хакта җитәр. Үзем дә күрәм. Бар әле, кызыма әйт, минем аның белән сөйләшәсем килә.

Өченче рыцарь китә.

Ә син Шамакайны эзләп кил.

Тагын бер рыцарь китә. Освальд керә.

Ә-ә, якынрак килегез әле, хөрмәтлем. Сезнең алда кем тора?
Освальд. Минем бикәмнең әтисе.
Лир. Синең бикәңнең әтисе? Ah син, хуҗаңның адәм актыгы! Сарай хәшәрәте! Эттән туган.
Освальд. Гафу итегез, милорд, тик мин боларның беренчесе дә, икенчесе дә, өченчесе дә түгел.
Лир. Әле син миңа курыкмыйча кararга җөрьәт итәсең, кабахәт!
Освальд. Кулларыгызга ирек бирмәгез, милорд.
Кент. Әллә аякларга ирек биргәнне телисеңме, үләксә? *(Освальдны сугып ега.)*
Лир. Рәхмәт, рәхмәт. Яхшы хезмәт итәсең. Болай булсаң, мин сине яратырмын.
Кент *(Освальдка.)* Яле, тор әле, милорд. Перес моннан! Мин сине әдәпкә өйрәтермен. Перес! Әллә тагын берне тондырганны көтәсеңме? Нәрсә казык кебек каттың? Миең агып беттеме әллә? Перес, дим! Менә шулай. *(Освальдны төрткәләп чыгарып җибәрә.)*
Лир. Хезмәтең өчен рәхмәт, дустым. Мә, әлегә шуны алып тор. *(Акча бирә.)*

Шамакай керә.

Шамакай. Мин дә аны яллыйм. Ал минем чуклы кәпәчемне.
Лир. Нихәл, күгәрченем! Ничек яшисең?
Шамакай. Син, туган, юкка минем кәпәчне алмыйсың.
Кент. Нигә ул миңа?
Шамакай. Бәхетенә кырау тигән кеше белән әшнәләнмә икенче. Җил каян искәнен чамаламасаң, томау төшкәнен сизми дә калырсың. Юк, сиңа кәпәчсез ярамый. Менә бу абзыкай ике кызыннан берьюлы ваз кичте дә өченчесенә үзенә дә теләмәстән фатихасын бирде. Аңа хезмәт итәр өчен кәпәчле булырга кирәк. Ah, абзыкай! Менә минем ике чуклы кәпәчем һәм дә ике кызым булсын иде ул.
Лир. Нишләр идең инде, тилекәй.

Шамакай. Бар булган байлыгымны аларга бирер идем дә, кәпәчләремне генә үземдә калдырып, төпсез чуманга утырып калыр идем. Мә, берсенә минекен ал, икенчесен кызларыңнан сора.
Лир. Кара аны, дивана, сыртыңа камчы төшмәсен.
Шамакай. Дөреслек дигән этне әүкатлы халык өеннән куа. Камчы белән ор аңа, камчы белән, оясына кереп качсын! Ә галиҗәнап ялагайлык атлы сасып беткән урам эте мич янында җылынып ятса да ярый.
Лир *(Освальдны исенә төшереп).* Шул кабахәт миңа тупаслык күрсәтергә батырчылык итте!
Шамакай. Абзыкай, бер шигырь өйрәтимме үзеңә?
Лир. Өйрәт.

Шамакай

Тыңла да
Мыегыңа чорнап куй:
Күп сөйләмә, телең тый.
Тапкырла, бүлмә, алма.
Җаныңны ачып салма.
Һәркемгә игелек эшләп,
Калма син терсәк тешләп.
Һәм ышаныч тудырма,
Юкка итек туздырма.
Кукиш күрсәт шәрабка,
Хатын-кызга бигрәк тә.
Үзеңне дә сакларсың,
Файдасын да табарсың.
Кент. Сукыр бер тиен тормый синең бу шигырең.
Шамакай. Мин бит аның өчен акча сорамыйм. Мин — бушлай хезмәт күрсәтүче. Абзыкай, ә юктан табыш алып буламы?
Лир. Юк, наяным. Юктан берни дә юк.
Шамакай *(Кентка).* Дустым бул, зинһар, шуңа әйт әле: аның хәзер үзенең дә бөтен җир-суларыннан алган табышы нәкъ шуның кадәрле генә, ягъни — юк. Үзем әйтсәм, Шамакайга ышанмас, шаяра, дияр.
Лир. Әче син, тилекәй.
Шамакай. Ә сиңа әче тиле белән шыр тиле арасындагы аерманы әйтергәме?
Лир. Әйт.

Шамакай

Җир-суыңны өләшергә
Кем сиңа киңәш биргән, —
Ул бәндәгә чуклы кәпәч,
Димәк ки, ул тилергән.
Без монда ике тиле:
Шамакай — әче тиле,
Икенчебез — шыр тиле,
Тилелектә юк тиңе.
Лир. Син миңа тиле дисеңмени?
Шамакай. Башка дәрәҗәләреңне өләшеп бетердең, ә тумыштан килгәнен тартып та алырлык түгел.
Кент. Бу Шамакайны мин җүләр генә димәс идем.
Шамакай. Бөтен җүләрлекне лордлар, графлар, теләсәм дә, үземә генә бирмәячәкләр. Хәтта үземә генә алган сурәттә дә, барыбер өлешкә кереп тинтерәтәчәкләр. Затлы ханымнар да бу эшкә юл куймаячаклар. Алар шундый иттереп тарталар, шундый йолкыйлар... *(Кулы белән гульфигын каплый.)* Абзый, күкәй бир әле, ә мин сиңа ике гөмбәз, ике таҗ бирермен.

Лир. Син аларны каян аласың?
Шамакай. Күкәйне урталай бүлеп ватам да агы белән сарысын ашыйм, шуннан ике гөмбәз кала. Син үзеңнең тажыңны урталай бүлеп биргәндә, озын колаклы ишәгеңне җилкәңә салып, пычрак аша күтәреп чыгардың. Пеләш гөмбәзеңдә, күрәсең, миең бик аз, юкса алтын гөмбәзеңне бирмәс идең. Кем беренче булып минем хакта: «Бу сүзләрне җүләр баштан сөйли», — дип әйтсә, шуны ыштанын төшереп суктырырга кирәк. *(Җырлый.)*
Акыллылар маймыллана —
Шамакайга бәласе!
Минем икмәкне ашыйлар
Җыен акыл иясе.
Лир. Нигә болай җырларга булдың әле, наяным?
Шамакай. Син үз кызларыңда малайлыкта йөргәнгә күрә. Аларның кулларына чыбык тоттырган чакта, үз ыштаныңны үзең төшердең дә:
Алар шатлыктан җылады,
Мин җырладым кайгыдан.
Тәхетеннән туйган король
Инде акылын җуйган.

Абый, хәлфә ялла әле, Шамакаеңа алдау сабагы бирсен. Алдарга өйрәнәсе иде.
Лир. Алдашсаң, арт сабагыңны укытырмын.
Шамакай. Шайтан да аңламас сезне, үзеңне дә, кызларыңны да. Кызларың турысын әйткәнгә суктыра, ә син — ялганлаган өчен. Дәшми калуның да әллә ни файдасы юк. Шамакай булганчы, теләсә кем бул, тик, абзыкаем, син булырга гына Ходай язмасын. Синең акылыңны ике яклап печтеләр дә инде чарлагың шып-шыр калган. Әнә печүчеләрнең берсе үзе дә килә.

Гонерилья керә.

Лир. Исәнме, кызым. Нигә кашларың җыерылган? Чыраеңны бик еш сыта башладың әле.
Шамакай. Элек син гайрәтле идең — аның чырай сытуларына төкереп тә бирми идең. Ә хәзер син беркем түгел — таяксыз ноль. Хәтта мин дә синнән дәрәҗәлерәк. Мин әле Шамакай, ә син Шамакай бәясе дә тормыйсың. *(Гонерильяга.)* Бетте, дәшмим. Чыраеңа язылганны укып аңладым. Тш-ш, тш-ш! *(Лирга күрсәтә.)*
Мал-мөлкәтен өләште,
Тотып калды шымытыр.
Инде хәзер теләнә —
Тәтегәне кукиштыр.

Гонерилья

Бу йөгәнсез телегез һәм аннан битәр
Котырынган сезнең башка хезмәтчеләр,
Кем эләксә шуның белән бәйләнешеп,
Сәгать саен тавыш-гауга чыгаралар.
Мин баштарак бу турыда сезгә әйтсәм,
Сез аларны тыярсыз, һәм тулы тәртип
Урнашыр дип уйлый идем, инде хәзер
Мин шикләнәм, чөнки сезнең гамәлләргә,
Сезнең хуплап торуларга, сезнең сүзгә
Аркаланып алар шулай кыланалар.
Хәтта шулай булганда да гаеплеләр
Җәзаларын алачаклар. Кичерегез —
Без дәүләтнең иминлеге файдасына
Һич битараф калалмыйбыз, шуңа күрә
Кәефегез кырылса да, кичекмәстән
Бер-бер чара күрәчәкбез һәм зарурлык

Бу чараны тулысынча аклаячак.

Шамакай

Аңладыңмы, абзыкаем?
Кәккүк баласын бер чыпчык
Карап үстергән.
Үсеп җиткәч, ул чыпчыкны
Чукып үтергән.
Шәм сүнде, без караңгылыкта калдык.

Лир

Һәм сез — безнең кызыбызмы?

Гонерилья

Йә, булды, сэр,
Сезне артык ямьсезләүче бу коточкыч
Гадәтләрдән арынырга вакыт инде.
Үткәннәрне бераз искә төшерегез:
Акыллырак идегез бит элегрәк.
Шамакай. Күкәйләр тавыкны әйбәт өйрәтәләр, әтәчләренә үч итептер инде.
Менә ичмасам болар күкәй!

Лир

Йә, кайсыгыз әйтә миңа — минме соң бу,
Әллә инде мин түгелме? Бу кем тавышы?
Кем йөреше, әйтегезче, кем күзләре?
Лирмы соң мин, әллә инде Лир түгелме?
Тану, сизү сәләтләре бу бәндәдә
Һәммәсе дә йоклый, ахры? Алай дисәң,
Мин уяу бит, юк, йокламыйм! Әйтегезче,
Кем мин хәзер, йә, кем?

Шамакай

Лирның күләгәсе.

Лир

Беләсем килә: чөнки аңым һәм хәтерем,
Һәм корольлек дәрәҗәм дә — һәммәсе дә
Алдый мине, алар минем күңелемә
Ялган фикер сала, имеш, кызларым бар.
Шамакай. Әтиләрен телсез-тешсез, буйсынучан итеп күрергә хыялланучы кызлар.

Лир

Исемегез ничек сезнең, затлы бикә?

Гонерилья

Аптыраулы бу ясалма соравыгыз
Чираттагы кыланышка охшап тора.
Мине дөрес аңлагыз сез: карт кешегә
Бераз гына акыллырак булу кирәк.
Йөз хезмәтче тотасыз бит — йөз бушбугаз,
Дуңгыздан да битәррәк йөз гаугачы.

Безнең йортны танырлык та түгел хәзер:
Әллә йорт ул, әллә инде кәрвансарай,
Әллә кабак, әллә фәхешханә шунда,
Аңламассың. Безнең затлы сарайда да
Тик бирәнлек һәм азгынлык хөкем сөрә.
Туктатырга кирәк моны кичекмәстән.
Мин әлегә тик яхшылык белән сорыйм:
Хадимнәрнең санын бераз киметегез.
Яныгызда калсын бары тәртиплесе,
Карт кешегә ни кирәген аңлый торган
Һәм дә хөрмәт итә торган әдәплесе.

Лир

Шайтаныма олак! Атлар иярләгез!
Хадимнәрне җыегыз! Ah, син имгәк!
Төнлә туган нәрсә, чәнчелеп кит!
Әллә минем башка кызым юкмы?!

Гонерилья

Минем кешеләрне сез кыйныйсыз,
Һәм аларны буйсындырыр өчен
Форсат кына көтә сезнең өер.

Олбани керә.

Лир

Соңга калып тәүбә итүченең
Эше харап. Сез биредәмени?
Бу эшләргә сезнең катнаш бармы?
Ник дәшмисез? Атлар иярләгез!
Игелексезлек, таш йөрәкле шайтан,
Минем кызга кереп оялагач,
Җирәндергеч диңгез хәшәрәтен
Хәтерләтеп карап торасың син.
Хәтта аннан яман!

Олбани

Кызмагыз, сэр...

Лир
(Гонерильяга)

Син алдыйсың, козгын. Хадимнәрем —
Сайлап җыйган кебек әйбәт халык.
Хезмәтләрен белеп башкаралар.
Бик беләсең килсә, намус, бурыч
Алар өчен бар нәрсәдән өстен.
Ah, кечкенә, нәни генә гаеп,
Корделия күңелендә авыраеп,
Бар дөньяның астын өскә әйләндерде.
Йөрәгемнең сөю хисен суырып алып,
Аны зәһәр агу итте. Ah Лир, Лир, Лир!
(Башын төя.)

Кыйна, кыйна бу ишекне — ул гаепле,
Ул уздырып ахмаклыкны минем аңга,
Акылымны чыгаручы... Халкым юлга!

Кент, рыцарьлар китәләр.

Олбани

Һичбертөрле гаебем юк, ачуыгызның
Сәбәбен дә әйтә алмыйм.

Лир

Бәлки, бәлки.
Ишет мине, әй, Табигать-ана, ишет!
Яудыр аңа син илаһи каты җәза:
(Гонерильяга күрсәтеп.)
Гомерлеккә кысыр яса мәлгунәне,
Аналыгын корыт аның, бала бирмә.
Әгәр бирсәң, бир шундыен: явыз булсын,
Көне-төне газапласын үз анасын.
Ана назы, ана хакы дигән сүзне,
Әче көлү, мыскыллауга әйләндереп,
Анасының яшь чыраен җыерчыкка,
Ә күзләрен канлы яшькә батырсын ул.
Үз балаңның хыянәте еланнан да
Яманрак чагуын һәм бар хурлыгын
Үз өстендә татып белсен. Киттек! Киттек!
(Китә.)

Олбани

Мәрхәмәтле аллалар, йә, нәрсә соң бу?

Гонерилья

Сәбәпләрен эзләп бер дә газапланма,
Сабый акылы кергән аңа, тик шауласын.

Лир кире әйләнеп керә.

Лир

Ике атна да узмады бит, шул арада
Сакчыларның иллесе юк! Нәкъ ярты сы!

Олбани

Галиҗәнап, эш нәрсәдә?

Лир

Хәзер әйтәм...
(Гонерильяга.)
Яшәвем һәм үлемем белән антлар итәм:
Миңа оят. Шушы адәм актыгына
Минем ирлек ныклыгымны какшатырга —
Күз яшемне чыгартырга насыйп булды.
Баш-аягың белән минем каргышымның
Томанына кереп урал, тончык шунда!
Әй сез күзләр, картайган һәм ахмак күзләр,
Еламагыз, тыелыгыз, юкса хәзер

Йолкып атам үзегезне, кайнар суны
Балчык изәр өчен җиргә сибәчәксез.
Күрегезче, эш нәрсәгә килеп җитте!
Ярый, ярый, шулай булсын. Минем әле
Башка кызым бар лабаса. Һәм ышанам,
Ул, әлбәттә, колач җәеп каршы алачак.
Бу хәлләрне ишетүгә, синең бүре
Чыраеңны тырнаячак. Тукта, тукта,
Мин элекке халәтемә кайтам әле.
Һәм бу көнне күрерсең син, сабыр, сабыр.
(Китә.)

Гонерилья

Ишеттеңме, герцог?

Олбани

Сиңа булган бөек мәхәббәтем
Юк, томалый алмый...

Гонерилья

Үтенеп сорыйм, җитте. Освальд, кайда син, әй?
(Шамакайга.)
Ә син, күрәм, тиледән битәр алдакчысың.
Ычкын моннан, бар, бар, ычкын хуҗаң янына!
Шамакай. Лир абзыкай, мине көт. Шамакай да синең белән китә, Шамакай синең белән!

Мондый кызны син
Кызганма һич тә.
Алып кайт бер мичкә,
Һәм давыллы кичтә
Шул мичкәгә сал да
Тәгәрәт таудан түбән,
Шуның белән вәссәлам.
(Китә.)

Гонерилья

Йөз рыцарь тотмакчы икән! Акылы алтын!
Тик шул гына җитмәгән ди. Йөз рыцарь —
Баштанаяк коралланган йөз сугышчы.
Көйсезләнеп саташканда, ул карт җүләр,
Бер дә юктан безнең өскә яла ягып,
Сакчыларын безгә каршы котыртачак
Һәм ул чакта безне бик зур хәвеф көтә —
Кыл өстендә калачакбыз. Освальд кайда?

Олбани

Куркынычны син арттырып күрсәтәсең.

Гонерилья

Дер калтырап яшәгәнче, куркынычтан
Арынуың кулайрак. Мин әтине
Биш бармагым кебек беләм. Сеңелкәшкә
Аның миңа янауларын хәбәр итәм.
Әгәр хатны укыгач та ул әтине

Яраннары белән бергә кабул итсә...

Освальд керә.

Хат әзерме, Освальд?

Освальд

Әзер, әзер, ханым.

Гонерилья

Җан сакчылар ал да, Освальд, чап сеңелгә,
Минем җанны ни борчуын сөйлә аңа.
Һәм хаттагы дәлилләрне телең белән
Тагын бер кат раслап чык, йә, бар, ычкын.
Юлда озак тоткарланма.

Освальд китә.

Юк, юк, герцог,
Изерәгән камыр кебек йомшаклыкны
Начар димим, әмма ләкин ул зарарлы,
Аның өчен сине һич тә мактамаслар.

Олбани

Ялкынлы күз карашыңның ни күләмдә
Мин үтәли күралганың әйтә алмыйм.
Яхшылыкны яхшылыктан эзлә, диләр...

Гонерилья

Яхшылыкның монда нинди катнашы бар?

Олбани

Исән булсак, анысын да бер күрербез.

Китәләр

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Герцог Олбани сараеның ишегалды. Лир, Кент һәм Шамакай керәләр.

Лир *(Кентка).* Шушы хат белән Корнуоллга бездән алдарак барып җит. Кызым хатны укыганнан соң, ни дә булса сораса гына җавап бир, башка берни дә сөйләмә. Әгәр дә юлда артык акрын кыймылдасаң, мин анда синнән алдарак барып җитәчәкмен.
Кент. Хатны илтеп җиткерми торып, күземне дә йоммам, галиҗәнап.

Тиз-тиз чыгып китә. Шамакай аның артыннан карап кала.

Шамакай. Әгәр дә кешеләрнең мие табан астына урнашкан булса, акылларына сөял чыгып йөдәтер иде.
Лир. Бәлки.
Шамакай. Ә син бер дә курыкма, синең акылга башмак кию тәтемәячәк.
Лир. Ха-ха-ха!
Шамакай. Менә күрерсең, икенче кызың да сине бик яратып каршы алачак, чөнки алар бер-берсенә баллы бакча алмасы белән әче кыргый алма кебек охшаш, мин белгәнемне беләм инде.
Лир. Нәрсә беләсең инде син, балам?

Шамакай. Икесенең дә тешне бертигез камаштырганын. Бит уртасына ни өчен борын чәпәп куйганнар, әйтеп кара?
Лир. Ни өчен соң?
Шамакай. Борынның ике ягында ике күз булсын өчен, ул чагында кеше борыны белән сизә алмаганны күзе белән күрәчәк.
Лир. Мин кызымны кыерсыттым, ахры...
Шамакай. Әкәм-төкәм үзенә ничек кабырчык ясаганын беләсеңме?
Лир. Белмим.
Шамакай. Мин дә белмим. Аның каравы әкәм-төкәмгә ни өчен өй кирәклеген беләм.
Лир. Ни өчен?
Шамакай. Башын яшерер өчен. Аны кызларына биреп, шәрә мөгезләрен тырпайтып калыр өчен түгел.
Лир. Шәфкатьлелектән ваз кичәм. Шундый мәрхәмәтле атаны... Нишләп һаман атлар юк?
Шамакай. Атларны алып килергә ишәкләрең китте. Ә ни өчен Җидегәндә җиде йолдыз? Ah, шундый кызык бер сәбәп аркасында!
Лир. Сигез булмаганга күрәме?
Шамакай. Нәкъ шуңа күрә. Синнән бик акыллы җүләр чыгар иде.
Лир. Көч белән кайтарырмын! Игелексез иблис токымы!
Шамакай. Әй абзыкаем, әгәр дә син минем шамакаем булсаң: «Вакытыннан алда картайма, картайма!» — дип, арт ягыңа сыдырган саен кабатлар идем.
Лир. Ничек инде алай?
Шамакай. Шулай, акыл җыймас борын картайма.

Лир

Мәрхәмәтле күгем, ныклык бирче миңа!
Акылымнан мине, зинһар, син шаштырма!

Рыцарь керә.

Йә, ничек, атлар әзерме?
Рыцарь. Әзер, галиҗәнап.
Лир. Киттек, балам. *(Лир белән рыцарь китәләр.)*

Шамакай

Көләсең син дә, кызый, көләсең бездән?
Эштиеңне суытырлар егетләр тиздән.
Бу бәхеттән кемдер сине мәхрүм итмәсә,
Егетләрнең шөлдерләрен кисеп китмәсә.
(Китә.)

Икенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне. Төрле яклардан Эдмунд белән Куран керәләр.

Эдмунд. Сәлам, Куран.
Куран. Исәнмесез, сэр. Бүген кичкә үк Корнуэль герцогы белән Регана-герцогиня биредә булачаклар, хәзер генә мин бу турыда әтиегезгә җиткердем.
Эдмунд. Килүләренең сәбәбе нидә?
Куран. Белмим. Яңа хәбәрләр ишеттегезме әле, хәер, колакларны кытыклап йөрүче чыш-пыш дисәң, дөресрәк булыр.
Эдмунд. Юк, ишетмәдем. Нинди хәбәрләр?

Куран. Корнуэль һәм Олбания герцоглары арасында сугыш чыгарга тора, имеш.
Эдмунд. Мин бу хакта берни дә ишетмәдем.
Куран. Вакыты җиткәч, ишетерсез. Хәерле төн, сэр! *(Китә.)*

Эдмунд

Герцог үзе бирегә килә? Искиткеч шәп!
Монысы да миңа файда. Эдгарны
Кулга алырга каравыллар куйды әти.
Ә мин хәзер бер хәйләле эш башкарам.
Тырышлык һәм уңыш миңа юлдаш булыгыз!
Абый! Абый! Ишетәсеңме? Бирегә төшче!

Эдгар керә.

Әти сине бик нык эзли. Кач, туганым!
Синең миндә яшеренгәнне җиткергәннәр.
Караңгыдан файдаланып кал тизрәк.
Алай-болай Корнуоллга тел тидереп,
Аңа каршы син берәр сүз әйтмәдеңме?
Төнгә каршы бик ашыгыч бирегә килә,
Регана да аңа иярген. Олбаниның
Аның белән ызгышканын кемгә булса
Сөйләмәгән идеңме соң? Хәтерлә әле.

Эдгар

Юк, берни дә сөйләмәдем.

Эдмунд

Әти килә.
Кичер, туган, кылычымны чыгарамын.
Юри генә сугышкандай иткән булыйк.
Син дә чыгар. Йә, каушама. Катырак селтә!
(Кычкырып.)
Бирел, явыз! Һәм чык әти хөкеменә!
Ут бирегез! Ут бирегез! Кач, Эдгар.
Кач тизрәк! Озакламый күрешербез!

Эдгар китә.

Үз-үземне бераз гына яраласам,
Чын сугышкан кебек булыр. Сәрхушләр дә
Мәзәк ясап фахишәләр хөрмәтенә
Шәрабка кан кушып эчү ниятеннән
Үз каннарын шактый гына агызалар.
(Кулын җәрәхәтли.)
Әти, әти, ярдәмгә кил! Ут кертегез!
Тотыгыз аны!

Глостер һәм факеллар тоткан хезмәтчеләр керәләр.

Глостер

Эдмунд, кайда ул кабахәт?

Эдмунд

Әле генә, караңгыда кылыч тотып,
Менә шунда басып торды һәм ярдәмгә

Гекатаны чакырды ул әфсен укып.

Глостер

Кайда соң ул?

Эдмунд

Күрегезче, кан ага бит.

Глостер

Кайда явыз? Кайда?

Эдмунд

Качып котылды ул.
Шушы якка качты. Аңлап алгач минем...

Глостер

Артыннан бер адым калмый эзәрләгез.
Тиз булыгыз! Тизрәк!

Хезмәтчеләрнең бер өлеше китә.

Нәрсә аңлады ул?

Эдмунд

Аның ягына аумасымны. Һәм мин аңа:
Үз атасын үтерүчеләр аллаларның
Каһәренә юлыгалар, һәм андыйлар
Яшен сугып көлгә әйләнә, шуңа өстәп,
Ата белән улны бәйләп тора торган
Җепләрдән нык бу дөньяда бернәрсә юк,
Дигән идем, шул сүздән соң ул, ниһаять,
Үзенең шакшы ниятенә бик җирәнеп
Каравымны аңлады да, явызланып,
Кылычы белән кулны ярды, әмма ләкин
Миндә гайрәт кузгалганны күргәнгәдер,
Әллә шау-шу куптарганнан курыккангамы,
Кинәт кенә юкка чыкты.

Глостер

Әйдә, качсын.
Җәзадан һич качып кына котылалмас.
Тиздән герцог килеп җитә, ул бит минем
Мәрхәмәтле химаячым һәм яклаучым.
Аның исеме белән игълан итәчәкбез:
Җанкыярны кем яшерә — аңа үлем,
Кем тотарга ярдәм итә — аңа бүләк.

Эдмунд

Ниятеннән аны кире кайтарырга
Тырышсам да, ул карышты. Ачуымнан,
Фаш итәм, дип куркытып та карадым мин.
Тик курыкмады, сүзләремә җавап итеп:
«Син кем белән тартышасың, әтрәк-әләм?
Йөз мәртәбә син ышаныч казансаң да,
Дәлил итеп минем хатны күрсәтсәң дә,

Бу — мәкерле ялган, диеп игълан итеп
Һәммәсен дә кире кагам һәм шуннан соң
Йә, кем сиңа ышансын соң? Мин үлгәннән
Килгән файда сине ничек камчылыйсын
Мие түнгән кеше генә аңламас», — ди.

Глостер

Ah вөҗдансыз! Ул үз кулы белән язган
Үз хатыннан баш тартмакчы! Ah кабахәт!
Моннан ары мин аңарга ата түгел.

Сәхнә артында бырғы тавышлары.

Бырғы тавышы, димәк, герцог килеп җитте.
Ник килгәндер, анысын белмим, әмма хәзер
Бар портларны яптыруын үтенәчәкмен.
Башкисәрнең бар юллары киселәчәк.
Өстәвенә сурәтләрен тараттырам
Без яшәгән илнең һәммә почмагына.
Сине исә, тугры балам, бүгеннән үк
Мин законлы улым ясап варис итәм.

Корнуолл, Регана һәм хадимнәр керәләр.

Корнуолл

Йә, нихәлләр, зур хөрмәткә лаек дустым.
Килеп җитәр-җитмәс борын миңа биредә
Кеше ышанмас яңа хәбәр җиткерделәр.

Регана

Әгәр дә бу дөрес булса, ул явызны
Җәзалау аз. Хәлегезгә керәм, милорд.

Глостер

Сынды күңелем, яраланды карт йөрәгем.

Регана

Минем әткәй исем табып, исем кушкан
Шул Эдгар әллә сезне чынлап торып
Үтерергә җыенганмы?

Глостер

Ah, миледи,
Хәтта җавап бирергә дә оят миңа.

Регана

Безнең әти яраннары барысы да
Котырынган башкисәрләр, шулар белән
Ул дуслашып йөрмәдеме?

Глостер

Белмим, ханым.
Әмма шундый авыр миңа. Бәла, бәла.

Эдмунд

Йөреде, ханым. Алар белән әшнә иде.

Регана

Ул чагында ник аптырап маташырга?
Аны алар котыртканнар: сезне үтереп
Мирас малын бергәләшеп туздырырга.
Төнгә каршы апам миңа хат җибәргән
Һәм хатында ул аларның кыланышын
Тулысынча сурәтләгән, дөрес булса,
Өйдән чыгып качарсың ул кунаклардан.

Корнуолл

Әйе, әйе, башыңа төшсә качарсың да.
Ишетүемчә син, Эдмунд, әтиеңә
Бик зур хезмәт күрсәткәнсең.

Эдмунд

Мин бары тик
Бурычымны үтәдем, сэр.

Глостер
Ул явызның
Ниятенә каршы төшкән, шул чагында,
Аны тотам дигән чакта яраланган.

Корнуолл

Җинаятьчене эзлиләрме?

Глостер
Әйе, милорд.

Корнуолл

Әгәр тотсак, моннан ары башкаларга
Бер зарар да тидермәслек итәчәкбез.
Син хөкем ит аны минем исемемнән
Чикләнмәгән власть бирәм. Ә син, Эдмунд,
Мактаулардан югарырак. Батырлыгың,
Тугрылыгың белән безне сокландырдың.
Синдәйләрнең урыны бездә. Һәм хезмәткә
Иң беренче итеп сине алачакбыз.

Эдмунд

Булдыра алган хәтле җаным-тәнем белән
Сезгә хезмәт итәчәкмен.

Глостер
Галиҗәнап,
Улым өчен мең-мең рәхмәт укыйм сезгә.

Корнуолл

Тик мин әйтеп бетермәдем ни өчен без...

Регана

Ни өчен без сукыр төнне ашыгу атлы
Энә белән типчи-типчи сезгә килдек.
Килүебезнең, Глостер, мөһим сәбәбе бар.

Сезнең киңәш кирәк булды. Әтидән дә,
Ападан да хатлар алдык. Бик зур низаг
Килеп чыккан икән алар арасында.
Шул низагны бергәләшеп хәл итик тә,
Хатларына биредән генә җавап бирик.
Шулай итсәк безнең өчен кулайрак,
Чапкыннары җавап көтә. Йә, Глостер,
Иске дуслыгыбыз хөрмәтенә безгә,
Кичектереп булмый торган шушы эштә,
Төпле киңәш биреп, безне һәм шулай ук,
Дөрләп янган йөрәкләрне юатыгыз.

Глостер

Сезгә хезмәт итәргә мин һәрчак әзер,
Хуш килдегез, галиҗәнап һәм миледи.

Китәләр. Бырғы тавышлары яңгырый.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне алды. Капма-каршы яклардан Кент белән Освальд керәләр.

Освальд. Хәерле иртәләр белән, дускай. Син бу тирәдә яшисеңме?
Кент. Әйе, биредә.
Освальд. Атларны каярак куярга икән?
Кент. Әнә сазламыкка куй.
Освальд. Әйт инде, бер яхшылык эшлә.
Кент. Миннән яхшылык көтмә.
Освальд. Хөрмәт күрсәтергә теләмисең икән — кирәкми.
Кент. Кул астыма эләгеп кара әле — күрерсең хөрмәтне.
Освальд. Син нигә миңа бәйләнәсең? Мин сине белмим дә, күргәнем дә юк.
Кент. Аның каравы мин сине үтәли күрәм. Һәм кем икәнеңне дә беләм.
Освальд. Кем инде мин синеңчә?
Кент. Кабахәт, алдакчы, кеше өстәленнән калдык-постык җыючы, мактанчык, көяз хәерче, кибәкбаш, хуҗа хатынына яраргa тырышучы астыртын, шакшы йон оеклар кигән һәм бердәнбер байлыгы булган өч тиенлек сандыгында кершән белән көзге йөртүче тоткалы җиңги, әләкче капчыгы, тәлинкә ялаучы, ялагай, бикәсенең күңелен күрү өчен уйнашчылар арасында арадашлык итүче, затлы кеше булып күренергә тырышучы адәм актыгы, куркак ялганчы белән фәхешханә себеркесеннән яралып дөньяга килгән нәрсә, капка астыннан өреп ятучы кәнтәй этнең көчеге һәм мирасчысы. Әгәр дә бу сыйфатларның һәм титулларның берсеннән генә баш тартырга җөрьәт итсәң дә, мин сине эт кебек чинарга, бүре кебек уларга мәҗбүр итәчәкмен.
Освальд. Сиңа таныш булмаган, хәтта сине бөтенләй белмәгән ят кешене болай хурлар өчен никадәр кыргый булырга кирәк!
Кент. Ah оятсыз! Җирбит! Әле танымаган булып кылана! Өченче көн үзеңне король алдында кем сугып егып дөмбәсләде? Бас каршыма, хәзер тиреңне туныйм, эт баласы! Курыкма, караңгының зыяны юк, синнән ит бәлеше ясар өчен миңа ай яктысы да җитә. Чыгар кылычыңны, каршы тор! *(Освальдка кылычы белән кизәнә.)*
Освальд. Кит! Синең белән бәйләнешергә теләмим.
Кент. Чыгар коралыңны, ялганчы! Үз атасына этлек эшләүче шул таш курчакның сүзенә карап, король галиҗәнапларына яла яккан хатлар ташыйсың! Саклан, имгәк, югыйсә хәзер кылычымны балтырыңа батырам. Чыгар кылычыңны, үләксә, чыгар, диләр сиңа — итеңне иткә, сөягеңне сөяккә аерам хәзер.

Освальд. Коткарыгыз! Үтерәләр! Коткарыгыз! *(Качмакчы була.)*
Кент. Качма, ялганчы! Кузгалма, куркак! Якла үзеңне көяз саламторхан, саклан кол. *(Освальдка кылычы белән суга.)*
Освальд. Коткарыгыз! Үтерәләр! Каравыл!

Эдмунд, Корнуолл, Регана, Глостер һәм хезмәтчеләр керәләр.

Эдмунд. Бу ни бу? Ник син аның белән сугышасың?
Кент. Теләсәң, синең белән дә мөмкин. Кан татып карыйсың киләме, козгын баласы! Кил әйдә, очып кун, мәми авыз.
Глостер. Корал, кылычлар белән нишләмәкче буласыз? Эш нәрсәдә?

Корнуолл

Кылычларны кыннарына яшерегез,
Юкса үлем яный сезгә! Бу нинди эш?
Регана. Король белән Гонерилья чапкыннары.
Корнуолл. Ә ни өчен сугышасыз? Йә, сөйләгез!
Освальд. Милорд, минем сулуым капты, тын алалмыйм.
Кент. Капмыйча, ул кадәр тырышып сугышуга.
Син — куркак хәшәрәт. Сине табигать тудырмаган, сине чулак тегүче генә энә белән типчеп маташтырган.
Корнуолл. Бу нинди көфер сүз? Ничек инде тегүче?
Кент. Тегүче шул, сэр. Иң тәжрибәсез буяучы яки таш кисүче дә мондый корчаңгы әвәләп чыгармас иде.
Корнуолл *(Освальдка).* Йә, сөйлә, ни өчен сугыштыгыз?
Освальд. Сэр, мин аны чал сакалына хөрмәт йөзеннән генә исән калдырган бу карт дуамал...
Кент. Ah, кәтәнә, кирәксез хәреф. Милорд, рөхсәт итегез, шушы йомарланган нәҗес кисәгенең измәсен изеп әбрәкәй тактасына сылап куйыймчы. Чал сакалына хөрмәт йөзеннән генә кызганган, имеш, — әбрәкәй сандугачы!

Корнуолл

Йә, йә, хайван!
Артык канат җәймә.

Кент

Ә мин канат җәймим.
Ачуның да үзенә күрә хокукы бар.

Корнуолл

Хокукы бар. Ачуның да. Ник ачулы?
Чыгырыңнан чыгып болай ник шашасың?

Кент

Намусның ни икәнен дә белми торган
Шушы колның биленә кылыч тагуына.
Нәкъ шушындый елмаючы шат күселәр,
Сүтелмәслек изге нәсел төеннәрен
Урталайга чәйнәп өзә бик еш кына.
Ул алдакчы кыл койрыклар бик күпләрнең
Акылына буйсынмаган уй-хисләрен
Хуплап тора, ягъни утка май тамызып,
Зәмһәриргә кар яудырып, юмаланып,
«Әйегә» — «әйе», «юкка» — «юк» дип баш кагалар.
Хуҗалары ягыннан бер җил иссә дә,
Этләргә хас ялагайлык белән алар

Борыннарын нәкъ шул якка борып куя.
Ник ыржайдың, өянәкле кылтыравык?
Шамакайга саныйсыңмы? Ah, дуадак,
Ялан кырда очрамадың, юкса күптән
Йоның гына тузып калган булыр иде.

Корнуолл

Саташасыңмы әллә, картлач?

Глостер

Гаугагызның сәбәбе ни, аңлатып бир.

Кент

Шушы шакшы бәндә белән минем кебек
Берсен берсе күралмаган дөньяда юк.

Корнуолл

Ә ник аны шакшы дисең? Гаебе ни?

Кент

Кыяфәтен ошатмыймын.

Корнуолл

Алай икән.
Ә минекен, ә моныкын, ә аныкын?

Кент

Ялган сөйләү безнең шөгыль түгел, милорд.
Хәзер миңа карап торган чырайлардан
Әйбәтрәк чырайлар да күргәнем бар.

Корнуолл

Бу халыкны беләм. Аны кайчандыр бер
Турысын әйткән өчен кемдер мактагандыр.
Инде беткән баш беткән дип теләсә кемгә
Тупаслыгын чәчеп йөри һәм көчәнеп
Туры сүзле кеше булып кылана ул.
Барып чыкса, бик шатлана, ә юк икән,
Хаклык өчен интегүче булып кала.
Мин күп күрдем инде мондый әрсезләрне.
Андыйларның хәтта берсе, гомере буе
Түбәнчелек белән хезмәт күрсәтүче
Егермеләп ялагайдан үткенрәк.

Кент

Мин ант итәм һич ялгансыз һәм ихластан,
Феб нурыннан яктырак нур чәчеп торган,
Сез җәнабе галиләрнең каршысында...

Корнуолл

Тукта, тукта. Ник сафсата сатасың син?
Кент. Сезгә минем сөйләү алымым ошамый бит, шуны үзгәртәм. Миннән әйбәт ялагай чыкмасын белеп торам, сэр. Сезнең алда туры сүзле, гади булып кыланган бәндә гап-гади адәм актыгы булган ул. Мине алай кыланырга ялвару да, сезнең ачуыгызга дучар булу да мәҗбүр итә алмаячак.

Корнуолл

Ник ул сиңа һөҗүм итте?

Освальд
Тиктомалга.
Һич гаебем булмаса да, күптән түгел
Король миңа рәхим итеп суккан иде.
Ә бу бәндә хуҗасына яхшатланып
Арттан килеп сизмәгәндә сугып екты.
Һәм әшәке сүзләр белән коендырды.
Мин, әлбәттә, үз-үземне тыеп калдым,
Аңа исә гайрәте өчен мактау яуды.
Шуны исенә төшереп, ахры, ул биредә
Кабат миңа ябырылды.

Кент

Тыңлап торсаң,
Бу кабахәт Аякстан ялганчырак.

Корнуолл

Агач богау белән аны богауларга!
Йә, барыгыз, китерегез. Тиз булыгыз!
Син тупас һәм оятсыз бер карт ялганчы!
Болай булсаң өйрәтермен!

Кент

Өйрәнергә
Бераз гына картрак шул. Мин — илче, сэр.
Мине бирегә король үзе озатып калды.
Богауларга уйласагыз, бу — дорфалык.
Бу — корольне явызларча мәсхәрәләү.

Корнуолл

Йә, богаулар китерегез! Мин ант итәм,
Ул биредә төшкә кадәр утырачак.

Регана

Ул гына аз. Юк, юк, милорд, таңга кадәр.

Кент

Атагызның хәтта эте булсам да мин,
Мыскылларга хакыгыз юк.

Регана

Этенә юк.
Ә оятсыз ялчысына бу бик таман.

Корнуолл

Апаң әйткән шайкадан бу. Әй, богаулар!

Агач богаулар китерәләр.

Глостер

Үтенеп сорыйм, галиҗәнап, калдырыгыз
Һәм богаулар кидертмәгез. Гаебе зур,
Әмма ләкин сез шикаять бирә аласыз.

Шуннан король аңа үзе җәза бирер.
Ә богаулап куяр өчен сукбайлар бар,
Җыен кесә караклары һәм башкалар...
Илчесенә мондый «хөрмәт» күрсәтүне
Король үзен мыскыллау дип кабул итәр.

Корнуолл

Синең кайгы түгел анысы. Син борчылма.

Регана

Илчесенә һөҗүм иткән бу явызның
Бер җәза да алмаганын ишетсә әгәр,
Апам ныграк хурланачак. Богауларны
Әйбәтрәк беркетегез.
(Кентны богаулыйлар.)
Инде киттек.

Глостер белән Кенттан башкалар китәләр.

Глостер

Кызганычсың кызганычын, әмма, туган,
Боерганны үтәмичә мөмкин түгел.
Һәммәсенә мәгълүм, герцог каршы әйткәнне
Һич кенә дә күтәрә алмый. Тик шулай да
Синең өчен ялынырмын.

Кент

Юк, кирәкми.
Йокым килә, арыдым, сэр. Йоклап алыйм.
Йокым туйгач утырып бер сызгырырмын.
Бәхетемнең, туган, авызы чалышайды!
Нишлисең бит, була инде. Сау булыгыз!

Глостер

Герцог әйбәт эшләмәде. Бу хәлдән соң
Хөкемдарның кәефе тәмам кырылачак.
(Китә.)

Кент

Король, король, нәкъ мәкальдә әйтелгәнчә,
Уттан качып син ялкынга сикереп төштең.
Чыкчы кояш, җир йөзенә нурларың чәч,
Шушы хатны укырга син булыш миңа.
Могҗизалар килсә килә бәхетсезгә —
Корделия хаты бит бу! Минем хакта
Инде аңа җиткергәннәр, һәм ул яза:
(Укый.)
Бөтен көчен куеп миңа ярдәм итәчәген.
Соңгы чиккә җитеп арыдым, күзләр күрми.
Йомылыгыз һәм күрмәгез бу хурлыкны.
Бәхет, миңа борыл, зинһар, алдың белән,
Күрсәт йөзең һәм бер елмай элеккечә!
(Йокыга тала.)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Аулак дала. Эдгар пәйда була.

Эдгар

Мине үлемгә хөкем иткән карарларын
Ишеттем мин. Бәхетемнән очраган
Шушы агач куышында качып торып,
Шымчыларны юл яздырдым. Минем өчен
Барлык юллар һәм сукмаклар инде ябык.
Бөтен җирдә эзләү бара, ау коралар.
Котылу өчен хәйлә кирәк. Болай итәм:
Фәкыйрьлектән кеше нинди түбәнлеккә
Һәм хайвани бер сурәткә керә алса,
Үз-үземне кертәм шундый кыяфәткә.
Җирәндергеч нәҗес белән битем буяп,
Тупас киндер белән урап бил тирәсен,
Чәчләремне ямьсез итеп тузгытам да,
Ярым шәрә килеш китәм сукбай булып,
Салкын җилләр һәм давыллар каршысына.
Бер мин генә түгел илдә, бик күп алар
Бедламаның тилеләре — Том ишеләр.
Акрып елап ялваралар: «Мескен Томның
Тамагы ач, ни дә булса бирегез!» — дип.
Һәм суыктан бөрешеп каткан иңбашларын
Розмариннар белән тәмам җәрәхәтләп,
Энә кадап, кадак кагып, канга батырып,
Шуның белән караңгырак авылларда
Яшәп яткан фәкыйрьләрнең котын алып,
Алдап-йолдап, кызгандырып яки янап,
Йә булмаса каргау белән куркытып алар
Тамакларын туйдыралар. Бу дөньяда
Хәерче Том булып әле яши алам,
Әмма бүтән Эдгар булып яши алмыйм.
(Китә.)

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне алды. Кент элеккечә богауда. Лир, Шамакай һәм Сарай йомышчысы керәләр.

Лир

Чапкынымны миңа кире юлламыйча
Үзләре өйдән чыгып киткән — сәер, сәер.

Сарай йомышчысы

Ишетүемчә, әле алар кичә кич тә
Беркая да җыенмаган, өйдә булган.

Кент

Сәламәт бул, мәрхәмәтле хөкемдарым!

Лир

Бу ни тагын? Монда нишләп утырасың?

Мондый хурлык әллә сиңа бик кызыкмы?

Кент

Юк, хөкемдар.
Шамакай. Ха-ха, берәүләр керпе тиресеннән кәвеш тектереп җибәргәннәр. Атларны башыннан бәйләп куялар, этләр белән аюларны муеннарыннан, маймылларны билләреннән, ә кешеләрне аягыннан. Әгәр кеше бик кызып китеп артык сикеренә башласа, агач оек кидереп куялар.
Лир. Кем ул минем чапкынымны богауларга җөрьәт иткән?

Кент

Кызыгыз белән киявегез.
Икесе дә.

Лир

Булмас.

Кент

Булды.

Лир

Булмас, дим.

Кент

Булды, дим.

Лир

Юк, юк, алар мондый эшне эшләмәсләр.

Кент

Менә бит, күреп торасыз, эшләделәр.

Лир

Юпитер белән ант итәм, моның булуы мөмкин түгел.

Кент

Юнона белән ант итәм, булуы мөмкин һәм булды.

Лир

Юк, юк, җөрьәт итә алмаслар, булмас, булмас,
Андый эшкә базмас алар — бу мәсхәрә
Үлемнән дә яманрак, тиз җавап бир,
Нигә мондый хәлгә төштең? Ләкин кызма.

Кент

Сэр,
Өйләренә килеп кереп хатны бирдем
Һәм тезләнгән җирдән торып өлгермәдем,
Гонерилья чапкыны да килеп җитте.
Сулуы кабып, шыбыр тиргә баткан хәлдә,
Атылып кереп бикәсеннән хат тапшырды.
Алар аны шундук ачып укыды да,
Хезмәтчеләр, хадимнәрен җыеп алып,
Тиз-тиз юлга җыендылар, миңа исә,
Боздай салкын караш ташлап, җавап көт, дип,
Артларыннан иярергә боердылар.

Юлыма аркылы төшкән юньсез ул чапкынга
Биредә кабат юлыктым, ул, галиҗәнап,
Күптән түгел Гонерилья сараенда
Сез җәнабе галиләргә дорфа җавап
Кайтарырга базган адәм булып чыкты.
Мин — сугышчы, хөкемдарым, акыл сатмыйм,
Кылычымны кынысыннан тартып алдым.
Кылычымны чыгаруга теге куркак
Коты алынып бөтен йортка сөрән салды.
Киявегез белән кызыгыз шуның өчен
Миңа шушы хөрмәтләрен күрсәттеләр.

Шамакай

Эһе-һе, киек казлар ул якларга таба юл тоткач,
Кышның узасы юк икән әле.
Кесәң калын булганда,
Балаларың ярата.
Кесәң такыр булганда,
Артыңа тибеп озата.
Байны бәхете коча,
Ә ярлыдан ул кача.
Кайгырма, абзыкаем, син әле ул кызларыңнан ел буе да санап бетерә алмаслык күчтәнәчләр алачаксың.

Лир

Ah, йөрәкнең авыртуы басыл, басыл!
Әй син, хәсрәт, йөрәгемә үрмәләмә,
Урыныңа төш, түбәнгәрәк. Кайда бу кыз?

Кент

Әнә анда, Глостерның кирмәнендә.

Лир

Минем арттан иярмәгез, монда калыгыз.
(Китә.)

Сарай йомышчысы

Бар гаебең тик шул гына идеме соң?

Кент

Тик шул гына. Сакчылар да сирәгәйгән.
Ник корольне бик аз кеше озата килгән?
Шамакай. Әгәр сиңа шундый сорау биргән өчен богау кидерткән булсалар, эзләгәнеңне тапкансың.
Кент. Моны ничек аңларга инде, Шамакай?
Шамакай. Менә үзеңне кырмыскага сабакка йөртербез, ул сиңа эшлисе эшне кышка калдырырга ярамаганны аңлатыр. Син бит сукыр түгел, күзләрең бар, борын шәрифләрең дә үз урынында — кай тарафтан сасы ис килгәнен чамаларга тиеш идең. Дәү тәгәрмәч таудан түбән тәгәрәгәндә, аңа тотынма, муеныңны сындырырсың. Ә менә тауга таба тәгәрәгәндә, тизрәк асылынырга кара, үз артыннан сине дә өстерәп алып менсен. Әгәр дә акыл ияләреннән акыллырак киңәш ала алсаң, минекен үземә кире кайтарырсың. Тиле биргән киңәшне кабахәт бәндәләр тотса, әйбәтрәк була ул.
Тик акчаңа кызыгып кына
Кемдер сиңа хезмәт итсә,

Бәла-каза килү белән,
Ул адәмнән җилләр исә.
Ә мин калам. Мин — дивана!
Диванага намус кыйммәт.
Акыллылар качсын әнә.
Чөнки алар чын кабахәт.

Кент

Син моны каян өйрәндең, дивана?

Шамакай

Әлбәттә, богауда утырганда түгел, ахмак.

Лир белән Глостер керәләр.

Лир

Арыганнар?! Төн йокламый авырганнар?!
Минем белән сөйләшергә хәлләре юк?!
Бар да ялган. Буйсынмаска маташу бу.
Башка җавап кирәк миңа.

Глостер

Хөкемдарым,
Сез герцогның бик тә кызу һәм холыксыз,
Киребеткән кеше икәнен беләсез бит.

Лир

Каһәр генә суккан икән! Йә, нәрсәгә
Аның холкын сөйлисең син? Глостер, Глостер,
Герцог белән хатынын күрү кирәк миңа.

Глостер

Мин аларга нәкъ шулай дип җиткердем дә.

Лир

Аңлыйсыңмы соң син минем ни әйткәнне?
Аңлыйсыңмы?

Глостер

Аңлыйм да бит, хөкемдарым...

Лир

Герцог белән сөйләшергә тели король.
Галиҗәнап ата үзенең газиз кызын
Бик күрәсе килә. Шулай дидеңме соң?
Киребеткән дидеңме әле? Әйт үзенә.
Андыйларны авызлыклау берни түгел...
Юк, алай ук димә, бәлки, ул чыннан да
Авырыйдыр, хәле юктыр, авырганда
Кеше сүзен тыңлар хәлдә булмыйбыз бит.
Тәнебезнең сырхаулыгы җанга күчеп,
Акылыбыз томалана. Бераз гына
Мәрхәмәтле булу кирәк, авыруны
Сау-сәламәт кеше белән чагыштырмыйк.
Ашыкмаска кирәк. Сабыр. *(Кентны күреп.)* Ah иблисләр!

Ник богауда утыра илчем? Аңлашылды,
Димәк, ару, авырулары бар да ялган.
Герцог белән хатынына җиткер сүзем:
Алар белән сөйләшергә телим — хәзер үк,
Кичекмәстән. Килми генә карасыннар,
Йоклап яткан бүлмәләре турысында
Шундый итеп дәү барабан кактырырмын,
Мәрткә киткән булсалар да уянырлар.

Глостер

Тыныч кына хәл итәргә иде эшне.

Лир

Шым, йөрәгем! Бугазыма үрмәләмә,
Тын алырга болай да авыр. Һава җитми!
Шамакай. Менә шулай бер пешекче хатын балык бәлеше пешергәндә балыкларны тере килеш камырга сала да, ди, тегеләр сикерешә башлагач, тик ятыгыз, селкенмәгез, наяннар, дип, башларына уклау белән тондыра да тондыра икән. Ә аның абзасы, бик тә ат җанлы булганга күрә, атына печәнне май ягып кына ашата торган булган.

Корнуолл, Регана, Глостер һәм хезмәтчеләр керәләр.

Лир

Икегезгә дә хәерле иртә.

Корнуолл

Саулык телим,
Галиҗәнап.

Регана

Сезнең белән очрашуга
Мин бик шатмын, хөкемдарым.

Лир

Шаттыр, шаттыр!
Мин ышанам сиңа, кызым. Югыйсә бит
Бер уйнашчы азгын хатын кабере сыман
Әниеңнең изге каберен йөрәгемнән
Күптән инде йолкып аткан булыр идем.
(Кентка.)
Ә, син азат? Бу турыда бераз соңрак
Сөйләшербез, калып торсын. Регана,
Балакаем, апаң синең җинаятьче.
Менә шушы җиремә ул тилегән кебек
Чукый-чукый төзәлмәслек яра салды.
(Кулы белән йөрәк тирәсен күрсәтә.)
Бу турыда сөйләве дә авыр хәтта.
Сөйләсәм дә ышанмассың, ул иблиснең
Үзеннән дә яманрак... Ah Регана...
Балакаем...

Регана

Үтенеп сорыйм, борчылмагыз.
Гонерилья сез әйткәннән күпкә яхшы.

Ихтирамлы. Сезгә шулай күренгән генә.

Лир

Ничек инде күренгән генә? Ул нинди сүз?

Регана

Апабызның ата хакын хакламавын
Күз алдына китереп булмый. Әгәр дә ул
Сезнең хадим — сакчыларның кайберләрен
Бераз гына тезгенләргә булган икән,
Димәк, шулай кирәк булган. Ул бит моны
Сезгә яхшы булсын өчен эшләгән тик.

Лир

Kaһәр генә суксын аны!

Регана

Сез инде карт,
Гомерегез ахырына якынлаша,
Сезне карап, тәрбияләп тотар өчен,
Хәлегезне үзегездән яхшырак белгән
Кем дә булса булу кирәк. Шуңа күрә
Үзегезнең гаебегезне таныгыз да
Гонерилья янына тизрәк ашыгыгыз.

Лир

Гаебемне танып гафу үтенергә?
Безнең өчен килешә торган эшмени бу!
(Тезләнә.)
«Балакаем! Картлыгым хак, шуңа күрә
Кирәгем дә бетеп бара. Мин тезләнеп
Сорыйм синнән, икмәк, кием, торыр урын».

Регана

Булды, җитте, кыланмагыз, галиҗәнап,
Гонерилья янына кайтыгыз.

Лир

(тора)
Беркайчан да!
Хадимнәрнең нәкъ яртысын ул кудырткан.
Усал караш һәм агулы сүзләр белән
Йөрәгемне яралады. Моның өчен
Ул күкләрнең каһәренә дучар булсын!
Балаларын тумас борын, карынында ук
Гарип итеп күкләр аны җәзаласын!

Корноулл

Яхшы түгел, галиҗәнап.

Лир

Әй, яшеннәр,
Тәкәбберлек белән тулган ике күзен

Көйдерегез. Ә син исә, төпсез сазлык,
Әллә каян чыккан сасы тыныҥ белән
Йөзенә өр, матурлыгы череп аксын.

Регана

Йа, аллалар! Тора-бара нәкъ шушылай
Сез мине дә каргарсыз бит болай булгач.

Лир

Юк, һичкайчан, Регана. Син инсафлы,
Син беркайчан андый явыз булалмыйсыҥ.
Мәрхәмәтсез янып торган күзләр анда,
Синекеләр исә нурлы. Син бит минем
Гаскәремне киметмәссеҥ. Күҥел ачу,
Кәеф-сафа коруларга сүз әйтмәссеҥ,
Син юмартсыҥ. Карулашып телләшмәссеҥ,
Мине күргәч, миннән качып бикләнмәссеҥ.
Һәм ышанам, намус, бурыч, рәхимлелек,
Әдәплелек ни икәнне онытмассыҥ.
Мин бит атаҥ. Син, әлбәттә, хәтерлисеҥ —
Мин бит сиңа ярты дәүләтемне бирдем.

Регана

Үтенәм, сэр, мәсьәләдән читкә китмик.

Лир

Миннән килгән илчене кем богаулатты?

Сәхнә артында быргы тавышы.

Корнуолл

Кем быргысы?

Регана

Бу — апабыз быргычысы.
Ул хатында киләм диеп язган иде.

Освальд керә.

Синең белән герцогиня килдеме әллә?

Лир

Бикәсеннән чикмән алган эт масая,
Салдырмасын өчен тырышып койрык болгый.
Кит, ялагай!

Корнуолл

Сабыр, сабыр, галиҗәнап!

Лир

Богауларга кем боерды? Газиз кызым,
Син түгел бит?

Гонерилья керә.

Бу ни тагын? Йа, аллалар!
Әгәр хөрмәт яратсагыз, йә булмаса
Сезгә картлар кирәк булса, әгәр дә сез
Үзегез дә карт булсагыз, ул чагында
Мине яклап гаскәр булып басыгыз сез!
(Гонерильяга.)
Шушы ап-ак сакалымнан оялыр идең.
Регана, син аңарга кул бирәсең?

Гонерилья

Ник бирмәсен? Әллә минем гаебем бармы?
Картаюдан тәмам мие сыегайган
Тинтәк өчен гаеп булып күренгәннең
Һәммәсе дә гаеп түгел.

Лир

Ah, күкрәгем,
Бу хурлыкка түзеп торыр көчең булгач,
Нык икәнсең. Илчемне кем богаулатты?

Корнуолл

Мин, хөкемдар, ул җәнҗалчы әле катырак
Җәзага да лаек иде.

Лир

Ah, сезмени?!

Регана

Әткәй, сез бик бетерешкәнсез. Чамагызны
Белебрәк сөйләшегез. Ай узмаган.
Сезне карау әле апа нәүбәтендә.
Хадимнәрнең тик яртысын гына алып,
Ай беткәнче сез апада торып торыгыз.
Аннан минем нәүбәт җитәр, рәхим итегез.
Хәзер бит мин өйдә түгел, шулай булгач,
Сезне кабул итә алмыйм, мөмкинлек юк.

Лир

Илле кешем белән аңа кайтыргамы?
Юк, һичкайчан! Андый юлга басканчы, мин,
Төн пәрдәсен үземә сыеныр урын итеп,
Бүре белән ябалакка иптәш булам...
Мин мохтаҗлык тырнагына килеп каптым!
Аңа әйләнеп кайтыргамы? Юк, юк, булмас!
Аңа әйләнеп кайтканчы, мин төпчек кызны
Бирнә-мазар сорамыйча алып киткән
Кызу канлы французга барып егылам.
Аңа әйләнеп кайтканчы, мин әнә аның
Иң әшәке лакеена ялчы булам.
(Освальдка күрсәтә.)

Гонерилья

Анысы сезнең ихтыярда.

Лир

Ярый, кызым,
Мине үртәп шаштырма син. Моннан ары
Синсез генә көн күрермен. Ярый, сау бул.
Инде бүтән очрашырга туры килмәс.
Тик шулай да син бит, кызым, минем каным.
Ә дөресе канымдагы авырудан
Тәнгә чыккан эренле шеш, кутыр, чуан.
Әмма сине каргамыйм да, оялтмыйм да,
Оят үзе килер берчак. Һәм үч тотып
Дәшмим яшен алласын да синең өскә.
Теләгең туса, тәүбәгә кил. Мин көтәрмен.
Ә хәзергә йөз хадимем белән бергә
Реганада яшәп торам.

Регана

Юк, булмый, сэр.
Тиешенчә кабул итәр әмәлем юк.
Кире апага кайтыгыз сез. Ачулану —
Ул картаю һәм көчсезлек галәмәте.
Хәер, болар апага да мәгълүм нәрсә.

Лир

Чынлап шулай уйлыйсыңмы?

Регана

Чынлап булмый.
Илле хадим, ә артыгы нигә кирәк?
Иллесе дә артык әле. Һәм куркыныч.
Бер үк йортта ике хуҗа хадимнәре
Тату яшәү мөмкин түгел. Ә аннары
Ашатырга күпме кирәк.

Гонерилья

Югыйсә бит
Регана белән минем хезмәтчеләр әнә
Сезгә хезмәт күрсәтергә һәрчак әзер.

Регана

Шул-шул менә. Әгәр алар ялкауланса,
Без аларны өйрәтербез. Кыскасы шул:
Ызгыш чыгу ихтималы барга күрә,
Миңа күчеп килгән чакта ул хадимнәр
Егерме биш кешедән дә күп булмасын.

Лир

Мин бит сезгә барын бирдем... Бар дәүләтем...

Регана

Бик вакытлы һәм акыллы эшләдегез.

Лир

Үз янымда йөз кешене калдырдым тик.

Ә син исә, егерме биш кеше, дисең.
Сине дөрес аңладыммы?

Регана

Әйе, шулай, егерме биш. Артык түгел.

Лир

Әшәкелек күренә башлый яхшы булып,
Кабахәтлек белән әгәр чагыштырсаң.
(Гонерильяга.)
Сиңа барам. Ни дисәң дә илле бит ул
Ике тапкыр егерме биш, димәк, мине
Ике тапкыр артыграк сөясең син.

Гонерилья

Тыңлагызчы, егерме биш сезгә нигә?
Сезгә хезмәт итәр өчен ике йөзләп
Хезмәтчебез әзер тора. Шулай булгач,
Унысы да, бишесе дә кирәк түгел.

Регана

Ул гынамы? Берсенең дә хаҗәте юк.

Лир

Хаҗәт-мазар диеп бүтән сүз катмагыз!
Иң сәләмә хәерченең киемендә дә
Берәр артык ямау була. Син кешенең
Ихтыяҗын тик табигый хаҗәтенә
Тәңгәл итсәң, ул хайванга әверелә.
Син — хатын-кыз. Синең затлы киемнәрең
Табигатькә хаҗәтме соң? Ул ефәкләр
Сине хәтта җылытмый да, ә менә минем
Хаҗәтем ни? Ул — сабырлык. Йа, аллалар,
Сез сабырлык бирегез миңа, тик сабырлык.
Сезнең алда басып торам кайгы-хәсрәт,
Картлык әчесен күп татыган мескен хәлдә.
Кызларымның йөрәкләрен таш иттегез,
Инде үземне, зинһар, чүпрәк ясамагыз.
Күңелемдә ирләргә хас кырыс, гадел
Нәфрәт уты кабызыгыз. Яңагымны
Тик хатын-кыз коралы булган тозлы судан
Таплатмагыз. Юк, юк, явыз җен затлары,
Шатланмагыз. Сездән шундый үч алырмын!
Шундый эшләр майтарырмын... Шундый итеп...
Ни эшлисемне хәтта әлегә үзем белмим...
Әмма ләкин бөтен дөнья дер калтырар.
Елар бу дип уйлыйсызмы? Юк, еламыйм,
Елар өчен сәбәп булган сурәттә дә,

Күк күкрәгән тавыш ишетелә.

Йөрәгемне телем-телем телсәгез дә,
Күз яшемне күралмассыз, көтмәгез дә.
Аһ, диванам, мине акылдан яздыралар.

Лир, Глостер, Кент, Шамакай һәм сарай хезмәтчеләре чыгып китәләр.

Корнуолл

Без дә китик. Бик дәһшәтле давыл килә.
Йорт әллә ни зурдан түгел, картлач анда
Хадимнәре белән бергә сыеп бетмәс.

Гонерилья

Шул кирәк ул котырганга. Үзен үзе
Сыеныр почмак табудан ул мәхрүм итте.
Үзен генә рәхәтләнеп кабул итәм;
Башкаларын кертәсем юк.

Гонерилья

Мин дә шулай.
Глостер кайда?

Корнуолл

Картны озата. Ә, менә кайтты.

Глостер керә.

Глостер

Король шашар дәрәҗәдә. Бик ярсыган.

Корнуолл

Инде кая юл тотмакчы?

Глостер

Анысын белмим.
Һәммәсенә ат менәргә әмер бирде.

Корнуолл

Кая тели, шунда китсен. Бала түгел.

Гонерилья

Үгетләп тә маташмагыз. Китә бирсен.

Глостер

Төн куера. Дала буйлап җил котыра.
Бер ышык җир таба торган түгел кырда.
Ничә мильләр тирә-якта бер куак юк.

Регана

Киреләрне бары шулай дәвалыйлар.
Әйбәт дәва. Капкаларны бикләтегез.
Аңа ияргән халык бар да башкисәрләр.
Әллә нинди яман эшкә котыртырлар.
Ә ул күндәм. Сак булырга кирәк безгә.

Корнуолл

Ул хак әйтә. Капкаларны бикләтегез!
Төн бик хәтәр. Давыл килә. Ышыкланыйк.

Китәләр.

Өченче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Давыл. Төрле яклардан Кент белән Сарай йомышчысы керәләр.

Кент

Кем чайкала давыл кочагында?

Сарай йомышчысы

Кеше.
Күңелемдә җил-давылдан көчле хәвеф.

Кент

Ә, сез икән. Король кайда?

Сарай йомышчысы

Ул ярсыган давыл белән көрәшә һаман:
Котырынган җилдән сорый коры җирне
Диңгезләргә батыруын йә булмаса
Тау-тау дулкын өереп китереп диңгез суын
Кыяларның түбәсеннән аштыруын:
Йә үзгәрсен дөнья, әгәр үзгәрмәсә,
Тәмам бетсен, юкка чыксын, дия, дия,
Чал чәчләрен ярсып йолкый, һәм аларны
Көчле өермә шундук үзенә суырып алып
Чиксезлеккә алып китә. Лир үзенең
Рухи дөнья дигән нәни дөньясында
Җиһандагы гарасатны сүндермәкче.
Ач бүреләр өннәреннән чыкмый яткан
Шундый төндә дала буйлап йөри һаман.
Бәргәләнә. Җил тузгыткан яланбашын
Һәлакәтнең каршысына алып бара.

Кент

Янында кем?

Сарай йомышчысы

Шамакае. Мәзәк сөйләп,
Такмазалар көйли-көйли ул корольнең
Кайгыларын таратырга азаплана.
Кент

Сэр, мин сезне яхшы беләм һәм ышанып
Бик тә мөһим сер тапшырам. Олбани белән
Корнуоллның арасында татулык юк.
Озакламый ызгыш булыр. Язмышлары
Күккә чөйгән андыйларның барысының да
Ышанычлы хадимнәре арасында
Кайберләре шымчы була, менә шулар
Герцогларның дошманлыгын һәм аларның
Карт корольне ничек итеп җәберләвен,
Шул эшләрнең бөтен яшерен сәбәпләрен
Французга җиткергәннәр булса кирәк.
Инде хәзер әнә француз гаскәрләре

Безнең шушы бүленүдән, саксызлыктан
Файдаланып Дуврга да килеп төшкән.
Байракларын күтәрергә әзер алар.
Сез Дуврга чабыгыз хәзер. Хөкемдарның
Ата кеше түзалмаслык җәберләрдән
Инде шаша башлаганын җиткерегез.
Сезне биредә рәхмәт көтә. Ә мин үзем
Ихтирамлы дворянмын һәм сезнең дә
Нинди кеше икәнлекне белгәч кенә
Бу йомышны тапшырырга җөрьәт иттем.

Сарай йомышчысы

Тагын бер кат тәфсиллерәк сөйләгез.

Кент

Юк.
Менә янчык. Анда — йөзек. Шул йөзекне
Корделиягә күрсәтегез, һәм ул минем
Кемлегемне әйтер сезгә. Нинди давыл!
Хөкемдарны эзли китәм.

Сарай йомышчысы

Сау булыгыз.
Менә кулым! Ни кирәген һәммәсен дә
Әйттегезме?

Кент

Хәзер өстим. Иң кирәген.
Сез бу якка таба барыгыз, мин — бу якка.
Хөкемдарны кайсыбыз әүвәл күреп ала,
Шунда ук ул икенчебезгә аваз бирсен.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Давыл дәвам итә. Лир белән Шамакай керәләр.

Лир

Исәр җил, ис, өр син, әйдә, бүртенгәнче!
Өр! Явызлан! Котыр! Яңгыр, чиләкләп кой!
Ургылып ак! Туфан бассын бар дөньясын.
Манаралар очындагы кыңгыраулар
Су астында калып бар да тончыксыннар.
Әй, яшеннәр, имәннәрнең көл буласын
Алдан хәбәр итә торган утлы уклар,
Көйдерегез минем ап-ак чәчләремне!
Бар галәмне калтыраткан көчле күкрәү
Шул капкорсак Җир шарыннан коймак яса
Һәм җир асты байлыкларын он итеп тарт.
Яхшылыкның кадрен белмәс бәндәләрнең
Орлыкларын юкка чыгар, тумасыннар!

Шамакай. Их абзыкай, яңгыр астында коенуга караганда, сарайдагы ялагайлыктан коллыкка чумдырулары әйбәтрәк икән. Тизрәк түбә астына ашык, тәти абый, һәм кызларыңнан гафу сора. Мондый төн акыллыны да аямый, тилене дә кызганмый.

Күк күкри.

Лир

Күкрә син күк, көлгә түндер, кырып ташла!
Давыл белән яшенгә мин ата түгел.
Мин бит сезгә дәүләтемне өләшмәдем.
Балаларым дип дәшмәдем. Гаепләмим —
Көлегез миннән, мыскыллагыз, сезнең алда
Әлсерәгән, мәлҗерәгән бер карт тора.
Әмма ничек оялмыйсыз шул әшәке
Кызлар белән миңа каршы берләшергә?
Чал башымны юк итәргә җыенасызмы?
Ah, никадәр түбәнлек бу, әшәкелек!

Шамакай

Башын тыгар өе булган бәндә, башлы егет була.
Йорт-курасыз зимагурның
Төне була бик кыска.
Бетле тунын ябына өскә,
Хатынын сала аска.
Уйларга баш бирелгән.
Уйласаң аяк белән,
Төн йокысы күрмәссең —
Интегерсең сөялдән.
Чибәр кызлар интектерәләр алар, чөнки көзге каршында кыланып борын җыермаган хатын-кызның дөньяга туганы юк әле.

Лир

Юк, мин хәзер сабырлардан сабыр булам,
Инде бүтән бер сүз дәшмим.

Кент керә.

Кент

Кем бар монда?
Шамакай. Кем булсын? Галиҗәнап агылый белән аның койрыгы тагылый инде. Акыллы белән тиле.

Кент

Сез ник монда, галиҗәнап? Төне буе
Әрле-бирле чабып йөргән ерткычлар да,
Күкләрнең бу күкрәвеннән котсыз калып,
Инде күптән өннәренә постылар бит.
Мин гомеремдә ишетмәдем мондый күкрәү,
Сызгырулар, улау, шартлау, су шаулавын
Һәм күрмәдем моның кебек дөрләп янган
Иксез-чиксез ут пәрдәсен. Бу дәһшәткә
Юк, түзалмас адәм заты.

Лир

Йа, аллалар,

Күк гөмбәзен дер селкеткән, илаһәләр!
Явызлыгын караңгыда кылганнарга
Сезнең утны юнәлдерер вакыт җитте.
Үзенә тиеш камчы алмаган, әшәке җан,
Дер калтыра! Канлы куллы үтерүче,
Котың очсын! Калтыранығыз — ант бозучы,
Тәкъва булып кыланган кан катыштыручы,
Мәкер белән кеше гомерен өзүчеләр,
Икейөзле риячылар, тетрәнегез!
Яшерен гөнаһ, кара киемең салып ат та
Тәүбәгә кил. Гафу сора югарыдан...
Мин үзем дә бер гөнаһкәр, тик гөнаһым
Минем алда гөнаһлары булганнардан
Күпкә кимрәк.

Кент

Шундый давыл — сез яланбаш!
Галиҗәнап, ерак түгел бер куыш бар,
Анда ышык. Бераз гына ятып торыгыз.
Мин кирмәнгә барып киләм. Инде бер кат
Сезне сорап капкаларын каккан идем,
Ачмадылар. Таш бәгырьле халык анда.
Кабат барам, ачтырам һәм мин аларны
Мәҗбүр итеп сезгә хөрмәт күрсәттерәм.

Лир

Мием кайный. Әллә акылдан язам инде.
Әйдә киттек, юләркәем. Туңасыңмы?
Мин дә туңдым. Кайда куышың, күрсәт, туган.
Нужа бабаң тылсымчы ул, бер мизгелдә
Саламнан да мамык түшәк ясый ала.
Әйдә, балам, әйдә, минем шук наяным.
Йөрәгемнең иң түрендә сине жәлләп
Сызланучы бер ярам бар.

Шамакай
(җырлый)

Җилләр иссә, яңгыр яуса,
Кесәңдә дә җил уйнаса,
Бераз гына акылың булса,
Рәхим-шәфкать көтмә көздән.

Лир

Син хаклысың...
(Кентка.)
Йә, илт безне куышыңа.

Лир белән Кент китәләр.

Шамакай

Мондый төндә иң азгын урам хатынының да эштие суыныр.
Ярый, китәр алдыннан бераз күрәзәлек итим әле.
Руханилар акчадан ваз кичә калса,
Ә сырачы сырасына су кушмаса,

Затлы халык кием диеп уынмаса,
Фәкыйрь кеше өйдән тышка куылмаса,
Учакларда хөр фикерле бәндәләрне
Яндырмыйча, яндырсалар кәнтәйләрне,
Хөкем эше гаделлеккә нигезләнсә,
Яла ягып яшәүчеләр көн күрмәсә,
Акчаларын җилгә чәчсә рибачылар,
Фахишәләр чиркәү төзи башласалар,
Хәсрәткә чум, бәхетсез ил, ела, кайгыр,
Синең өчен ахырзаман шул буладыр.
Ул көнгәчә яшәгәннәр бар да күрер,
Ул заманда адәм аяк белән йөрер.
Бу — пәйгамбәрлек тылсымчы Мерлин эше,
Мин бит аннан элегрәк яшим.
(Китә.)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне. Глостер белән Эдмунд керәләр.

Глостер. Ah Эдмунд, Эдмунд, үз аталарын шулай мәсхәрәләгәнне күзләрем күрмәсен иде, ичмасам. Мин алардан корольгә кулымнан килгән ярдәмне күрсәтергә рөхсәт сорыйм, алар шуңа җавап итеп мине үз йортым белән идарә итүдән читләштерәләр; иң каты янаулар белән куркытып, миңа король исемен телгә дә алмаска, аның өчен берни сорамаска кушалар, хәтта кечкенә генә ярдәм күрсәтүдән дә тыялар.
Эдмунд. Нинди гайре табигый вәхшилек!
Глостер. Тсс, беркемгә дә сөйләмә. Герцогларның аралары бозылган, әле куркынычрак хәбәрләр дә йөри: бүген төнлә мин хат алдым, куркыныч хат; хөкемдарның чиккән газаплары өчен үч алыначак; гаскәрләрнең бер өлеше инде безнең җиргә төшерелгән; без король ягында булырга тиешбез. Хәзер мин аны эзләп табып шыпырт кына тынычландырам; ә син бар, герцогны сүз белән мавыктыр, алай-болай шикләнерлек булмасын. Әгәр мине сораса, урында ята, авырый, диген. Әйдә, үтерсәләр үтерерләр, миңа үлем җәзасы белән янадылар инде, шулай булуга карамастан, мин корольгә — үземнең хөкемдарыма ярдәм итәргә тиеш. Баш очында кара болытлар куера, Эдмунд. Үзеңне сакла.
(Китә.)

Эдмунд

Хат турында һәм корольгә яшерен ярдәм
Күрсәтергә җыенуын җиткеримче.
Герцог юмарт. Тырышлыгым бушка китмәс,
Бүләге дә мулдан булыр болай булгач.
Картлар ауса, шул урында яшьләр калка;
Урыныңа мин басармын, юл бир, картлач.
(Китә.)

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Куыш алды. Лир, Кент һәм Шамакай керәләр.

Кент

Менә биредә, галиҗәнап. Керегез, кер.
Яшеренегез шунда төннең дәһшәтеннән.

Бу афәткә адәм түзмәс.

Давыл дәвам итә.

Лир

Калдыр мине.

Кент

Хөкемдарым, үтенеп сорыйм, керегез инде.

Лир

Тимә миңа, йөрәгемне телгәләмә.

Кент

Галиҗәнап, үз йөрәгем телгәләнә.
Керегез, зинһар.

Лир

Сөякләргә кадәр үткән
Күкрәп яуган шул яңгырдан куркасыңмы?!
Күкрәгемдә йөрәк яргыч күкрәү барда
Бу зилзилә берни түгел минем өчен.
Чөнки арттан аю куып килгән чакта,
Әгәр алда котырынган диңгез ятса,
Син яңадан шул аюның авызына
Ирексездән кире барып керәчәксең.
Җаның тыныч булса гына тәнең сизгер.
Минем сизү тойгыларым эчемдәге
Гарасатта янып-көеп бетсәләр дә,
Тик бер нәрсә, тик бер нәрсә миемә бәрә —
Кызларымның хыянәте. Бу — авызның
Үзенә ризык сузган кулны тешләве күк.
Мин үчемне алачакмын. Юк, еламыйм!
Шундый төндә кертми куып чыгардылар.
Кой син, яңгыр! Сил булып ак, түзәчәкмен.
Регана! Гонерилья! Бар булганын
Чын йөрәктән сезгә биргән атагызны...
Юк, ярамый. Бу турыда уйлама син.
Оныт барын. Юкса акылдан язачаксың.

Кент

Галиҗәнап, керегез инде.

Лир

Үтенеп сорыйм,
Элек үзең ышыклан син. Бу давылда
Мин газаплы уйларымны онытып торам.
Өлгерермен. *(Шамакайга.)* Кер, кер, балам, йортсыз гидай...
Йә, кер инде. Ә мин башта дога кылам.
Аннан гына кереп ятам.

Шамакай куышка кереп китә.

Әй, сукбайлар,

Мәрхәмәтсез давыл белән көрәшүче
Йортсыз-җирсез, ач-ялангач мескен затлар!
Иске-москы киемегез тишекләрен
Бу дөньяга тәрәз иткән как тәнегез
Мондый хәтәр җил-яңгырга ничек түзә?
Элегрәк бу турыда уйламадым!
Гамьсез муллык, салкын җилгә сыртың ачып
Дәвалан син. Фәкыйрьлекнең бу давылда
Нинди газап кичергәнен үзең таты.
Һәм бүлешеп артыгыңны алар белән
Гаделлекнең күктән иңүен исбатлачы!

Эдгар
(куыш эчендә)

Су басты, су! Тирәнлеге колач ярым!
Бичара Том!

Шамакай куыштан атылып чыга.

Шамакай

Кермә, кермә, абзыкаем, ачәрвах бар анда!
Ай, куркам! Куркам!

Кент

Бир кулыңны. Кем бар анда?

Шамакай

Ачәрвах, ачәрвах; ул үзен, бичара Том, ди.

Кент

Кем ул анда куышта акырып ята? Чык.

Куыштан юләр булып кыланучы Эдгар чыга.

Эдгар

Якын килмә! Мине иблис эзәрлекли!
Чәнечкеле чытырманда җил сызгыра.
Брр... Чум да салкын түшәгеңә, җылын шунда.

Лир

Бар малыңны ике кызыңа бүлеп биреп
Шушы хәлгә төштеңме син?
Эдгар. Мескен Томга ни дә булса бирегезче.
Явыз иблис аны утка-суга куып кертте, упкыннар, баткаклыклар, сазлыклар аша сөйрәп йөртте; мендәр астына пычаклар салды, утырасы урындыгына элмәкле бау элде, ашыйсы ашына агу салды; котыртып, йөрәгендә горурлык хисе уятып, ул Томны акбүз атларда, кул яссуы киңлеге күперләр аша, хыянәтчене эзәрлекләгәндәй, үз күләгәсен куып йөрергә мәҗбүр итте. Аллалар сезне берүк акылыгыздан яздырмасыннар. Томга суык. Ah, ды-ды-ды-ды-ды-ды. *(Салкыннан калтырана.)* Җил-давылдан, йолдызларның һәлакәтле тәэсиреннән, сихерчеләрнең күзләре тиюдән сакласыннар. Бичара Томга аз гына булса да хәер бирегез. Аны җен бимазалый. Менә моннан тешли, менә моннан, менә, менә моннан да; хәзер мин аны!

Лир

Бичараны нинди хәлгә төшергәннәр
Үз кызлары. Син аларга бар малыңны

Иң ахыргы җебенәчә өләштеңме?

Шамакай

Юк инде, гаурәтен капларлык кына
Сәләмәләре калган.

Лир

Залимнәрнең баш очында эленеп торган
Бөтен каргыш кызларыңа төшсен синең!

Кент

Ул адәмнең кызлары юк, галиҗәнап.

Лир

Ялганлыйсың! Дәшмә! Дәшмә! Мондый эшне
Бары ерткыч кызлар гына эшли ала.
Инде хәзер бу дөньяда үз атаңны
Сукбай ясап чүп базына чыгарып ату
Гадел эшкә тиң микәнни? Шул кирәк тә.
Үз атасын чаккан андый еланнарны
Ник тудырган? Тудырмаска кирәк иде!

Эдгар

Зеңге, зеңге, зеңге елан,
Зеңге башлы кара елан,
Син тимәсәң, мин тимәм,
Кара елан, кит, елан.
Тфү, тфү!
Шамакай. Мондый салкын төндә без барыбыз да акылдан язачакбыз.
Эдгар. Аздыручы шайтаннан саклан, ата-анаңа хөрмәтле бул, әйткән сүзеңдә тор, яман сүзләр белән сүгенмә, кеше хатыны белән уйнаш кылма, байлык артыннан куып үз-үзеңне харап итмә. Томга салкын.
Лир. Син кем идең соң?
Эдгар. Затлы түрәләрнең хезмәтчесе идем, мактанчык һәм тәкәббер булдым; чәчләремне бөдрәләтеп йөрдем, эшләпәмне сөяркәләремнең перчаткалары белән бизи идем, зур тырышлык белән хуҗабикәбезнең җенси теләген канәгатьләндердем, шул эшкә башкаларны да димләдем, сүз саен ант итеп, адым саен шул антымны боздым, шәрабны мичкәсенә төшеп эчтем, отыш уеннарының алласы, ә хатын-кыз мәсьәләсендә төрек солтанының мулласы булырлык идем, эчем тулы ялган булды, кулларым канлы булды, дуңгыздан яман ялкау, төлкедәй карак, бүредән дә комсыз, эт кебек котырган, арыслан кебек ерткыч идем. Ефәк кыштырдавы белән башмак шыгырдавына алданып, бичара йөрәгеңә азынырга юл куймасаң, фәхешханәләр ягына әйләнеп тә карамасаң, итәк асларына кул тыкмасаң, рибачыдан бер тиен дә акча алмасаң, шайтанны җиңәрсең.
Җил эләккән койрыгыннан,
Ычкыналмый чытырманнан,
Сызгыра, шаулый, яный:
Ычкынырмын, куармын,
Куармын да тотармын,
Тотармын да йотармын!
Фию, фию, фию.

Давыл туктамый.

Лир. Сиңа ялангач тәнең белән күкләрнең ярсуына каршы торганчы, кабергә кереп ятсаң, әйбәтрәк булыр иде. Кеше дигәнең шушы була микәнни инде? Уйлап кына карагыз, ул беркем-

гә дә бурычлы түгел. Синең барысы да үзеңнеке. Үгездән салдырып тире дә ябынмагансың, корттан ефәк, сарыктан йон да алмагансың, ата мәче сиңа хушбуен да сиптереп китмәгән. Ха! Без өчебез дә ялган акча кебек ясалмалар. Ә син — чын. Шушы киенмәгән-ясанмаган, ач-ялангач ике аяклы җан иясе — чын кеше, аңарда ясалма, тышкы бизәкләр юк. Артык бизәкләр коелыгыз миннән, коелыгыз! Йә, шушыны чишеп җибәр әле! *(Өстеннән киемнәрен йолкый.)*
Шамакай. Абзыкаем, зинһар, сабыр ит, чишенә күрмә. Бик салкын бит, мондый төндә су кермиләр. *(Еракта ут күреп.)* Мондый төндә даладагы ут карт зиначы йөрәге күк пыскып кына яна. Аз-маз очкын чыгарса да, ялкыны юк. Карагыз әле, безгә таба ниндидер ут килә. Әллә убыр уты инде.
Эдгар. Убыр уты. Убыр ул. Төн убыры! Ул беренче әтәчләргә кадәр кешеләрне юлдан яздырып йөри, күзләренә ак салдыра, кылыйлата, китек иренле ясый, өлгереп килүче игеннәрне харап итә, бичара адәм балаларына зыян сала.
Тугыз убыр баласы
Һәм аларның анасы
Адәмгә зыян салганын
Изге Витольд күргән, ди,
Әфсен укып өргән, ди:
Убыр, убыр, кач, кач!
Балаларың буармын,
Ә үзеңне суярмын.
Убыр, убыр, кач, кач, кач! Тфү, тфү!

Кент

Кәефегез ничек, галиҗәнап?

Глостер керә.

Лир

Кем бу?
Кент *(Глостерга).* Кем йөри анда? Нәрсә югалттыгыз биредә?
Глостер. Сез үзегез кемнәр буласыз? Исемнәрегез ничек?
Эдгар. Бичара Том. Ул бакалар, чукмарбашлар, тычканнар, су һәм дала кәлтәләре белән туенып яши. Ә эчендә җеннәре котыра башласа, сыер тәбикмәген дә соса, кортлап беткән күсене дә кабып йота, үләт базыннан үләксә дә сыпырта, эчәсе килсә, чокырда җыелып яткан яшелләнеп беткән сасы суны чөмерә. Томны чыбыркылап төбәктән төбәккә куалап йөртәләр, богаулап төрмәгә утырталар. Ә бит заманында Томның өч чикмәне, алты күлмәге, иярле аты һәм билендә кылычы да бар иде. Инде менә...
Бичара Том җиде еллап
Ач-ялангач йөри елап.
Якын килмә! Миңа җеннәр оялаган.
Иблис мәлгунь, мине газаплаудан туктыйсыңмы син, юкмы?!

Глостер

Галиҗәнап, саташкан Том сезнең белән
Янәшә үк басып тора, бу нинди хәл?!

Эдгар

Ә иблис кара көчләр патшасы ул,
Исемнәре — Модо белән Mahy аның.
Кушаматы — котыртучы, аздыручы.

Глостер

Нәҗесләнде җаныбыз да, тәнебез дә,
Үз каныбыз дошман хәзер үзебезгә.

Эдгар

Бичара Том өши.

Глостер

Галиҗәнап,
Инде әйдәгез минем белән. Кызларыгыз
Әмеренә буйсынмыймын. Бурычым кушмый.
Чөнки алар, капкаларны бикләттереп,
Сезне шомлы төн куенында калдырдылар.
Мин шуңа да карамастан эзли чыктым,
Инде хәзер алып китәм кайнар ашы,
Учагында уты булган бер урынга.

Лир

Башта акыл иясеннән сорыйм әле.
(Эдгарга.)
Ни сәбәпле күк күкри, әйтче, зинһар!

Кент

Галиҗәнап хөкемдарым, милорд сезне
Ышык җиргә дәшә.

Лир

Тукта, сабыр итче,
Хаким кеше белән әүвәл сөйләшик без.
Фикереңне нинди эшкә җиктең, галим?
Эдгар. Җен-пәриләрдән саклануга, төрле хәшәрәтләрне юк итүгә.

Лир

Инде бик тә яшерен сорау бирәм сиңа.

Эдгарны читкәрәк алып китә.

Кент

Тагын бер кат чакырыгыз хөкемдарны.
Ул акылдан шаша бугай.

Глостер

Гаҗәп түгел.

Давыл тагын да котыра төшә.

Кызлары бит аны харап итмәкчеләр.
Бичара Кент бу турыда кисәтсә дә,
Тыңламады. Кентның үзен читкә сөрде.
Син корольне акылыннан шаша дисең,
Мин үзем дә нәкъ шундый ук хәлдә хәзер.
Күптән түгел бар иде бер улым минем,
Инде хәзер улым түгел. Һәм ул мине
Үтерергә ниятләде, үз әтисен.
Белсәң иде үзен ничек яратканым.
Шул кайгыдан мием кайный. Нинди төн бу...

Хөкемдарым!..

Лир

Ah, әйе, әйе. Кичерегез.
(Эдгарга.)
Фәйләсуф ир, рәхим ит минем белән.

Эдгар

Томга салкын.

Глостер

Бар, бар, куышка кер, анда җылынырсың.

Лир

Барыбыз да шунда керик.

Кент

Галиҗәнап,
Анда түгел безгә.

Лир

Ә мин аның белән.
Фәйләсуфтан башка бармыйм бер адым да.

Кент

Милорд, Том да безнең белән барсын, әйдә,
Хөкемдарны ярсытмаска кирәк хәзер.

Глостер

Әйтегез соң, бара бирсен.

Кент

Әйдә, туган, безнең белән.

Лир

Әйдә, акыллы афиналы.

Глостер

Тсс! Акрын, акрын.

Эдгар

Һәм кап-кара бер манара күрде алар
Килеп җитте шунда Роланд, ә дию: «Фу!
Сизәм, сизәм, адәм исе бу».

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне. Корнуолл белән Эдмунд керәләр.

Корнуолл. Мин биредән киткәнче үк аңардан үч алачакмын.
Эдмунд. Ә, юк, милорд! Ул чагында миңа Герцогка яраргатырышуы, атасына булган мәхәббәтен дә күмеп киткән дигән шелтәләрдән котылу булмаячак.
Корнуолл. Инде хәзер күрәм, синең агаң аны юкка гына үтерергә йөрмәгән икән — бу эшкә аны барыннан бигрәк атагызның түбән җанлы булуы этәргән.

Эдмунд. Сез галиҗәнапларына тугры булуым аркасында язмыш мине, мыскыл итеп, нинди вөҗдан газапларына сала! Менә ул хат, хат буенча аның француз шымчысы икәнлеге көн кебек ачык. Йа, аллалар! Әгәр дә бу хыянәт булмый калса яки аны фаш итү вазифасы миңа йөкләнмәсә, бу кадәр газапланмас идем!
Корнуолл. Әйдә минем белән, герцогиня янына барабыз.
Эдмунд. Әгәр хаттагы хәбәрләр дөрес булса, сезгә шактый көч куярга туры киләчәк.
Корнуолл. Дөрес булса да, булмаса да, син бүгеннән граф Глостер. Бар, әтиеңне эзләп тап, аны кичекмәстән кулга алырга кирәк.
Эдмунд *(читкә)*. Әгәр дә хәзер ул король көен көйләп йөрсә, герцогның шиген арттырачак кына. *(Кычкырып.)* Туганлык хисләре каршы төшүгә карамастан, мин үз бурычымны үтәргә әзер!
Корнуолл. Ышанычымны акладың, сиңа булган мәхәббәтем ул юньсез атаңны артыгы белән алыштырачак.

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Кирмән тирәсенә урнашкан игенче йорты. Кент белән Глостер керәләр.

Глостер. Тыштагыга караганда биредә ышыграк булыр. Монысы өчен дә рәхмәт. Инде ашау мәсьәләсен кайгыртырга кирәк. Мин хәзер киләм.
Кент. Аның акылы күңелендәге давылга каршы тора алмады. Изге гамәлегез өчен сезне күкләр бүләкләсен.

Глостер китә. Лир, Эдгар һәм Шамакай керәләр.

Эдгар. Фратеретто миңа «Нерон тәмуг күлендә балык тотып ята» дип яза. Гыйбадәт кыл, дивана, иблис ләгыйньнән саклан.
Шамакай. Абзый, абзый, әйт әле, морзамы акылдан шашкан, әллә игенчеме?
Лир. Король шашкан, король!
Шамакай. Юк, игенче. Ул малаена морзалык дәрәҗәсе сатып алып биргән. Балаларыңны үзеңнән өстен ясау өчен акылсыз булырга кирәк.

Лир

Кыздырылган гөрзиләрен болгый-болгый,
Өсләренә иблис явы ябырылсын!..
Эдгар. Аркамны җен тешләде.
Шамакай. Бүренең кулга ияләшүенә, малай-шалайның мәхәббәтенә ышанма, бер авырган аткa ышанма, фахишә биргән антка ышанма. Кем шуларга ышана, шул акылдан шашкан була.

Лир

Әйе, әйе, кичекмәстән судка аларны.
(Эдгарга.)
Галим судья, син бирегә утырырсың.
(Шамакайга.)
Син зирәк зат, менә бирегә. Йә, бүреләр!
Эдгар. Кара әле, иблис ничек күз карашы белән өтеп ала. Миледи, суд каршында күз уйнатма, карашыңны түбән төшер.
(Җырлый.)
Әйдә, Бесси, елга аша йөзеп кил, ярым.

Шамакай
(җырлый)

Ничек йөзсен, көймә тишек,

Су тула бит, булмый ишеп,
Оятыннан белдертмәде ник килә алмавын.
Эдгар. Шайтан ләгыйнь сандугач тавышы белән сайрап күңелемне иләсләндерә. Ә Томның корсагында Хопданс атлы бер җен: «Балык бир, балык бир,» — дип шыңшый. Шыңшыма да, кычкырма да, иблис токымы, берни бирмим.

Кент

Хәлегез ничек, галиҗәнап? Болай булмый.
Сез ятыгыз, ял итегез. Менә мендәр.

Лир

Юк, башта — суд. Шаһитларны кертегез, әй!
(Эдгарга.)
Ябынчалы гадел судья, утыр бирегә.
(Шамакайга.)
Иптәш хаким, аның белән янәшә бул.
(Кентка.)
Син дә хөкем итәсең бит, син дә утыр.

Эдгар

Хөкем гадел булачак.
Уян, уян, көтүче,
Сарыкларың син күрче,
Кергәннәр бит игенгә.
Кычкырт быргың, иренмә.
Мыр, мыр, мыр иткән
Соры песи шул икән.
Прес! Прес!..
Лир. Иң әүвәле менә монысыннан сорау алабыз — Гонерильдан.
Югары суд каршында ант итеп әйтәм — ул үз атасын, бичара корольне, типкәли-типкәли куып җибәрде.
Шамакай. Якынрак килегез, ханым. Сез — Гонерильямы?
Лир. Анысын инкарь итә алмый ул.
Шамакай. Гафу итегез, мин сезне урындык дип уйлаган идем.

Лир

Менә тагын икенчесе. Безгә таба
Кырын гына карап тора. Димәк ки, ул
Икейөзле... Тукта, качма! Тотыгыз, тот!
Ут бирегез! Кая корал? Суд сатылган!
Сатлык судья, ник син аны ычкындырдың?!

Эдгар
(читкә)

Мәрхәмәтле күгем, аның акылын сакла!

Кент

Башыбызга бәла килде! Галиҗәнап,
Элегрәк горурланып сөйли торган
Сабырыгыз ник төкәнде? Кая китте?

Эдгар
(читкә)

Кызганудан чишмә кебек яшем ага,

Уйнаганны сизмәсәләр ярар иде.

Лир

Өрәләр бит! Көтүләре белән өрә!
Олысы да, кечесе дә, хәтта әнә
Муйнак белән Актырнак та миңа өрә.

Эдгар

Ә Том алар артыннан үзенең башын алып тондырачак.
Ычкыныгыз, кәкре койрыклар!
Ак этме син, карамы,
Әллә ала-коламы,
Ау этеме, яу этеме,
Яхшымы син, яманмы,
Томга болар барыбер,
Ул сезгә сабак бирер.
Артыгыздан таш бәрер,
Таш тимәсә, үз башын
Йолкып алып җибәрер.
Чиный-чиный чабарсыз,
Том явыз ул чамасыз!
Ды-ды-ды-ды. Булды, бетте, вәссәлам!
Инде бар, Том, ил буйлап йөр, базарларга, ярминкәләргә сугыл, гыйбадәтханәләргә кер. Бичара Том эчәр иде дә, мөгезе коргаксыган.
Лир. Регананың мәетен ярсыннар да йөрәгенә нинди таш утырганын тикшерсеннәр. Бу кадәр каты бәгырьле булуның табигый сәбәпләре бар микәнни? *(Эдгарга.)* Мин сезне үз гаскәремнең йөзбашы итеп билгелим. Тик менә күлмәгегезнең тегелеше миңа бик ошап бетми. Сез, әлбәттә, аны фарсилар киеме диярсез, тик шулай да алыштырырга кирәк.
Кент. Ятып торыгыз, мәрхәмәтле хөкемдарым, ял итегез.
Лир. Шауламагыз, шауламагыз; әкрен генә пәрдәне төшер; менә шулай, менә шулай, менә булды. Иртәгә иртән кичке аш вакыты җитә, бергә утырып ашарбыз.
Шамакай. Ә мин төш вакыты җиткәч, төн уртасында йокларга ятам.

Глостер керә.

Глостер. Минем янга килче, туган. Король нихәл?
Кент. Әнә йоклый. Ул акылдан язды, милорд.

Глостер

Алып кит син аны моннан, зинһар, коткар.
Тыңлап тордым: Хөкемдарны сүз берләшеп
Үтерергә җыеналар. Атлар әзер,
Җайлап кына салыгыз да кичекмәстән,
Дувр ягына элдертегез, анда сезне
Сыеныр урын, яклау көтә. Әйдә, күтәр!
Җәһәтрәк, ярты гына сәгатькә дә
Соңлый күрмә. Соңладыңмы — ул да, мин дә,
Аңа ярдәм кулы сузган һәммәбез дә
Шундук харап булачакбыз. Йә, кузгалыйк.
Мин тиз генә юл кирәген хәстәрлимен.

Кент

Хәлдән тайган җаны, тәне йоклый аның.
Йокы берүк дәва гына була күрсен.

Юкса — бәла. *(Шамакайга.)* Алып чыгыйк, кил, күтәреш.
Монда кала күрмә тагын.

Глостер

Тизрәк, тизрәк.

Эдгардан башкалар китәләр.

Эдгар

Язмышымны мин авырдан саный идем,
Инде күрәм: корольгә дә җиңел түгел.
Ялгыз гына хәсрәт чигү җанны ашый,
Башкаларның хәсрәтен күз күрми башлый.
Үзең кебек хәсрәтлене күреп алсаң,
Кемдер сиңа ярдәм кулы сузган сыман.
Хөкемдарны күргәч сагыш диңгезендә,
Кайгыларым җиңеләйде шул мизгелдә.
Мин — әтидән, ә ул исә кызларыннан
Михнәт чигә. Дөнья шулай яратылган.
Яшерен син, аулак җирдә ят әлегә,
Ялалардан арынмыйча һич күренмә.
Ah, корольгә котылырга язсын берүк!
Кач, Эдгар, кабыгыңа биклән кереп.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне. Корнуолл, Регана, Гонерилья, Эдмунд һәм
хезмәтчеләр керәләр.

Корнуолл *(Гонерильяга)*. Ирегез янына ашыгыгыз һәм аңа шушы хатны күрсәтегез. Француз гаскәрләре безнең җиргә төшерелгән. Хыянәтче Глостерны табыгыз.

Берничә хезмәтче чыгып китәләр.

Регана. Кичекмәстән асып үтерергә кирәк аны.
Гонерилья. Күзләрен чокып чыгарырга!
Корнуолл. Анысын миңа калдырыгыз. Эдмунд, син безнең герцогиня апабыз белән китәрсең; сиңа хыянәтче атаңны ничек җәзалаганны карап тору кирәкмәс. Герцогны ашыгыч рәвештә әзерлек чаралары күрергә үгетлә, без дә шуңа керешәбез. Ике арада чапкыннар йөртеп, даими элемтә тотарбыз. Хәерле юл, кадерле апакай. Хәерле юл, граф Глостер.

Освальд керә.

Йә, корольнең кайдалыгын белдеңме?

Освальд

Граф Глостер ярдәмендә качты король.
Капка янында аңа килеп кушылдылар
Өч дистәдән артык булыр — хадимнәре.
Графның да кешеләре бар арада.
Менә шулар бергәләшеп Дувр ягына
Мактанышып юл тоттылар, имеш, анда
Коралланган дус-ишләре көтә аларны.

Корнуолл

Бикәнә атлар әзерләттер.

(Освальд китә.)

Гонерилья

Сау булыгыз, сөекле герцог һәм Регана.

Корнуолл

Хәерле юл сиңа, Эдмунд.

Гонерилья белән Эдмунд китәләр.

Кайда Глостер?
Тиз табыгыз! Хыянәтчене тотып алып
Карак кебек бәйләп бирегә китерегез.

Хезмәтчеләр китәләр.

Аны судсыз без җәзалый алмасак та,
Үчебезне кандырырга юл табарбыз.
Ризасызлык белдерүләр булса булыр,
Туктатырлык көч табылмас.

Ике-өч хезмәтче Глостерны алып керәләр.

Регана

Хыянәтче карт төлкене каптырганнар.

Корнуолл

Как сөякле кулларына бау салыгыз.
Катырак бәйлә. Кысыбрак!

Глостер

Нишләвегез?!
Сез бит минем кунакларым. Үз өемдә
Ник бу кадәр мыскыллыйсыз?

Корнуолл

Бәйләгез, дим.

Глостерның кулларын бәйлиләр.

Регана

Һәм катырак! У, намуссыз хыянәтче!

Глостер

Юк, миледи, хыянәтче түгел Глостер,
Ә сез менә мәрхәмәтсез.

Корнуолл

Ягез әле,
Урындыкка бәйләп куегыз. Син — кабахәт...

Регана Глостерның сакалын йолкый.

Глостер

Күкләр, күкләр, сакалымны йолкый бит ул,
Чал сакалны мыскыл итү — намуссызлык!

Регана

Чал кабахәт!

Глостер

Оятсыз син, явыз леди!
Сакалымның син йолкыган шул төкләре,
Мәхшәр көнне күк каршында телгә килеп,
Үзеңне үк гаепләрләр, исеңдә тот.
Хәзинәдә бары белән кунак иттем,
Ә син мине юлбасар күк йолыккалыйсың!
Инде тагын нишләтергә җыенасыз?

Корнуолл

Йә, әйт әле, Франциядән хат алдыңмы?

Регана

Турысын әйт. Һәммәсе дә мәгълүм безгә.

Корнуолл

Дувр ярына төшерелгән дошман белән
Нинди яшерен сөйләшүләр алып бардың?

Регана

Акылыннан язган Лирны кая куйдың?

Глостер

Ул хатта бит барысы да фараз гына.
Аны дошман җибәрмәгән, бу хәлләргә
Һичбертөрле катнашы юк кеше язган.

Корнуолл

Ah, хәйләкәр.

Регана

Һәм ялганчы.

Корнуолл

Йә, әйт әле,
Син корольне кая озаттың, ә?

Глостер

Дуврга.

Корнуолл

Ник Дуврга? Тыелганын белмәдеңме?..

Регана

Ник Дуврга озаттың син? Йә, җавап бир.

Глостер

Түз, түз, аю. Баганага бәйләп куеп
Бер көтү эт җибәрделәр синең өскә.

Регана

Ник Дуврга озаттың дип сорыйлар бит?!

Глостер

Ерткычныкы кебек үткен тырнакларың
Карт атаңның күзен чокып алмасын дип,

Усаллыгы тышына чыккан явыз апаң
Хөкемдарның галиҗәнап изге тәненә
Кабат тешен батыралмый калсын өчен.
Төне буе давыл белән көрәште ул...
Җил көченнән диңгезләрнең дулкыннары
Йолдызларны сүндерергә үрелделәр.
Шундый төндә ул адашып озак йөрде,
Күкләр белән бергә түкте күз яшьләрен.
Ул давылда синең капка төбеңә килеп
Кыргый бүре уласа да, «Каравылчы,
Керт мескенне» дияр идең күңелең тулып.
Атагыздан иңгән каргыш канатында
Сезгә тиеш җәза килер, һәм мин моны
Озакламый күрәчәкмен.

Корнуолл

Күрә алмассың.
Урындыкны тотыгыз әле. Күзләреңне,
Йолкып алып, аягаска салып таптыйм.

Глостер

Коткарыгыз! Үзегез дә минем кебек
Картаерсыз!.. Ah, явызлар...

Регана

Кәкрәйдеңме?
Кәкрене турайтырга кирәк инде,
Икенчесен төртеп чыгар.

Корнуолл

Шулаймыни?
Менә кара...

Беренче хезмәтче

Кулыгызны тыегыз, сэр.
Сезгә күптән хезмәт итәм, бала чактан,
Менә хәзер туктаткандай тугры хезмәт
Күрсәткәнем булмагандыр һичберкайчан.

Регана

Ничек җөрьәт итәсең, эт!

Беренче хезмәтче

Ah, миледи,
Сакалыгыз булган булса, менә хәзер
Рәхәтләнеп йолкыр идем. Нишлисез сез?

Корнуолл

Тыныңны да чыгарма, кол.
(Кылычы белән кизәнә.)

Беренче хезмәтче

(кылычын чыгарып)

Алай булгач,
Минем әйтер сүзне аңа син әйт, кылыч.

Сугышалар. Хезмәтче Корнуоллны яралый.

Регана

Кылыч бирегез! Фетнәче кол баш күтәрде!

Икенче бер хезмәтчедән тартып алынган кылыч белән беренче хезмәтченең аркасына кадый.

Беренче хезмәтче

Үтерделәр... Әмма ул да кан эчендә,
Үчегезне алдым, граф, күрәсезме?..
(Үлә.)

Корнуолл

Юк, ул аны күрмәячәк. Ah син, лайла,
Кабыгыңны төртеп тишәм. Күрәсеңме?

Глостер

Дөм караңгы... Кайда Эдмунд? Эдмунд, улым!
Мине сөюең нәфрәт булып кабынсын да,
Үч ал аннан.

Регана

Кемгә шулай ялварасың?
Бугазыңны ертма юкка, хыянәтче.
Сине безгә фаш итүче Эдмунд үзе.
Ул җирәнеп карый сиңа.

Глостер

Ah, мин юләр!
Димәк, Эдгар яла белән хур ителгән.
Кичерегез мине, күкләр, шул баламны
Мәрхәмәттән ташламагыз.

Регана

Алыгыз аны,
Һәм капканың аръягына куыгыз этне!
Борыны белән эзләп тапсын Дувр юлын.

Бер хезмәтче Глостерны алып чыгып китә.

Нәрсә булды сиңа, милорд?

Корнуолл

Яралы мин.
Ул сукырны куыгыз моннан. Кол мәетен
Чүп базына ыргытыгыз. Ә кан ага...
Бик вакытсыз яраландым... Кил таяныйм.

Регана белән китәләр.

Икенче хезмәтче

Әгәр дә аңа күкләр җәза иңдермәсә,
Мин гөнаһның диңгезенә чумачакмын.

Өченче хезмәтче

Бар хатын-кыз ерткычларга әйләнәчәк,
Үз үлеме белән үлсә шушы хатын.

Икенче хезмәтче

Әйдә тизрәк граф янына. Үзебез белән
Томны да алыйк.
Ул җитәкләп йөртер аны.
Юләр сукбай андый эшкә бик кулай зат.

Өченче хезмәтче

Киттек, туган! Тукта, күкәй агы белән
Бичараның җәрәхәтен бәйләр өчен
Берәр учма сүс тә алыйк. Бар, чыга тор.

Китәләр.

Дүртенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дала. Эдгар керә.

Эдгар

Бар да миннән җирәнәләр. Бу эшләрен
Яшермичә башкаралар. Анысы ярый.
Тыштан мактап, эчтән генә җирәнсәләр,
Хәтәррәк булыр иде. Ник куркырга?
Мин тормышның иң төбенә тәгәрәдем.
Моннан ары да начаррак булмаячак;
Ә яхшырак булу мөмкин, өмет — шайтан.
Нәни генә үзгәреш тә шатлык миңа.
Дала җиле, кер куеныма, кер, иркәлә,
Җаным ачык җилбәгәйгә, ә тәнемне
Инде шәрә калдырганчы җилләндердең,
Тукта, тукта, кемдер килә...

Җитәкләшеп, Глостер белән Карт керәләр.

Әти бит бу...
Күзләре ник канлы аның?.. Ah син язмыш!..
Дөнья, дөнья, әгәр дә син коточарлык
Хәсрәтләрең белән нәфрәт тудырмасаң,
Без картаймый яшәр идек мәңге-мәңге.

Карт

Мәрхәмәтле әфәндем, мин сиксән еллап
Башта сезнең атагыздан, хәзер сездән
Биләмәгә чәчүлек җир алып яшим.

Глостер

Кит син, туган, кит син моннан яхшы чакта.
Син барыбер миңа ярдәм итә алмыйсың.
Үзеңне үзең харап итмә.

Карт

Әй әфәндем,
Китәр идем, тик сез юлны күрмисез бит.

Глостер

Барыр юлым юк бит минем, шуңа күрә
Кирәкмисең. Күзләрнең дә кирәге юк.
Мин бит күзле чагымда да абына идем.
Бәхетебез ташыган чакта, без — сукырлар,
Бәла килсә — күз ачыла. Улым, Эдгар,
Минем сукыр нәфрәтемнең корбаны син!
Кулым белән маңгаеңнан сыйпасам да,
Күз алларым яктырыр иде өр-яңадан.

Карт

Кем бар монда?

Эдгар
(читкә)

Үз хәленне беркайчан да
Моннан да авыр булмас димә, менә хәзер
Элеккедән күпкә авыр минем хәлем.

Карт

Саташкан Том икән ич бу. Бичара Том.

Эдгар
(читкә)

Иң ахыргы сулышта да үз хәленне
Моннан да авыр булмас димә. Була икән.

Карт

Кая таба юл тотасың?

Глостер
Хәерчеме?

Карт

Хәерче шул, яп-ялангач, үзе — юләр.

Глостер

Хәер эстәп үз тамагын туйдыралгач,
Бөтенләй үк юләр булмас. Үткән төндә
Шуның төсле ялангач бер бәндә күргәч,
Кеше бары суалчан дип уйлап куйдым.

Ирексездән искә алдым үз улымны.
Әмма ләкин начар яктан. Чөнки аңа
Дошман итеп карый идем ул вакытта.
Инде хәзер күп нәрсәне аңладым мин.
Бала-чага чебен белән уйнаган күк
Безне сытып тәм табалар аллалар да.

Эдгар
(читкә)

Күрче, ничек үзгәргән ул! Инде нишлим?
Таудай кайгы каршысында ничек итеп
Шамакайлык кылыйм хәзер? Юк, килешми.
(Кычкырып.)
Күкләр сиңа ярдәм бирсен, хуҗа кеше.

Глостер

Бу шул теге хәерчеме?

Карт

Әйе, милорд.

Глостер

Ә син, бар, кайт. Әгәр инде теләгең булса,
Шушы юлдан безне куып җит бераздан.
Иске дуслык хөрмәтенә шул фәкыйрьгә,
Шыр ялангач тәнен бераз каплар өчен,
Ни булса да кием-салым китереп кит.

Карт

Ул акылдан шашкан бит, сэр.

Глостер

Вакыты шундый.
Kaһәр суккан бу заманда сукырларны
Акылсызлар җитәклиләр. Йә, бар, китер...
Хәер, анысын үзеңә кара. Ә хәзер кит.

Карт

Ни күрсәм дә күрермен, тик мин аңарга
Киememнең иң яхшысын китерермен.
(Китә.)

Глостер

Кил яныма, ялангач зат...

Эдгар

Том бик туңа.
(Читкә.)
Кыланырга көчем җитми.

Глостер

Кил, бичара.

Эдгар
(читкә)

Бармый булмый...
(Кычкырып.)
Күзкәйләрең канлы синең...

Глостер

Әйтче, олан, Дувр юлын беләсеңме?
Эдгар. Ат юлын да, сукмагын да, кайда койма, күпер барын — һәммәсен дә беләм. Бичара Томны куркыттылар, артыннан кудылар, куа торгач, акылыннан куып чыгардылар. Син берүк явыз көчләрдән саклана күр, мәрхәмәтле бәндә. Бичара Томга берьюлы биш җен оялаган: азгынлык җене Обидикут; телсезләр җене Хоббидиденс; караклык җене Маһу; үлеш-кырылыш җене Модо; Шамакайлык җене Флибертиджиббет, — анысы соңгы вакытта пешекче хатыннарга, асрау кызларга да ияләшкән. Изге көчләр саклый күрсен үзеңне, игелекле бәндә!

Глостер

Менә янчык. Ал син аны, язмыш колы,
Күкләр тере мәет иткән бичаракай.
Минем башка төшкән бәла син фәкыйрьне
Күктән төшкән бәхет булып куандырсын.
Һәм һәрвакыт шулай булсын, әй, аллалар!
Сез чыгарган кануннарны бозучылар —
Азган-тузган байбәтчәләр, бирән затлар,
Сезнең җәза бирер кулның көчен тоеп,
Байлыкларын бүлешсеннәр. Ул чагында
Һәммәсенә тигез өлеш тияр иде.
Син Дуврны беләсеңме?

Эдгар
Әйе, әфәндем.

Глостер

Анда биек һәм куркыныч, ә түбәсе
Океанга чыгып торган таш кыя бар.
Син җитәкләп илт тә мине шунда менгер.
Бүләгенә — бар булганым. Ә аннан соң
Җитәкләүче кирәк булмас, үзем генә.

Эдгар

Бичара Том илтер сине. Бир кулыңны.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Герцог Олбаниның сарай алды. Гонерилья белән Эдмунд керәләр.

Гонерилья

Хуш килдегез сараема. Гаҗәп, гаҗәп,
Җебек ирем никтер безне каршыламый.

Освальд керә.
Герцог кайда?

Освальд

Мондалыгын монда да ул,
Тик танырлык түгел аны. Безнең җиргә
Дошман гаскәр төшергән, дим, — ул елмая.

Сез кайтканны әйткән идем — кара коела.
Өлкән Глостер хыянәтен һәм улының
Тугырылыгын сөйләп торам, ә ул миңа:
«Ник киресен сөйлисең син, аңгыра!» — ди.
Аңа хәзер начар хәбәр — яхшы булып,
Яхшы хәбәр начар булып тоела бугай.

Гонерилья
(Эдмундка)

Алай булгач, саубуллашыйк. Ул җебекнең
Куркаклыгы кузгалгандыр йөрәгендә.
Һәм каршылык күрсәтүдән шүрләп шулай
Читтә посып калмакчыдыр. Безнең юлда
Сөйләшкән сүз инде чынга аша бугай.
Корнуоллга кире әйләнеп кайтыгыз да
Гаскәр туплау эшен, зинһар, тизләтегез.
Һәм, җизнинең гаскәренә баш булып, сез
Дошманнарга каршы аны күтәрегез.
Ә мин исә итәгемне иремә биреп
Коралланам. Ышанычлы шушы хадим
(Освальдка күрсәтә.)
Илче булып йөрер безнең ике арада.
Әмеремне аның аша җиткерүгә
Бәхетең өчен арыслан күк ташлан яуга.
(Аңа тасма бирә.)
Мә, так. Дәшмә. Иел әле. Бу үбүем
Әгәр сөйләү көченә ия булса,
Дәртең күккә ашар иде. Аңла һәм хуш.

Эдмунд

Соңгы сулышыма кадәр мин синеке.

Гонерилья

Ah, Глостер, кадерлем син!

Эдмунд китә.

Менә ул — ир!
Теләкләрнең — менә ул чын падишасы!
Түшәгемә бер селәгәй хуҗа минем.

Освальд

Ah, миледи, герцог килә!
(Китә.)

Олбани керә.

Гонерилья

Мин этмени?
Димәк ки, мин каршыларга лаек түгел?

Олбани

Гонерилья! Җил искәндә күзгә кергән
Чүп кадәр дә тормый синең бөтен бәһаң.

Мин холкыңнан куркам синең. Холкың яман.
Үз атасын санламаган синдәйләрдән
Әллә ниләр көтеп була. Әмма ботак
Үзенең туган кәүсәсеннән аерылса,
Сынып төшсә йә булмаса каерылса,
Корый, кибә һәм ахырда ялкын ялмый.

Гонерилья

Ахмак көе вәгазь укый башлады бит.

Олбани

Игелексезнең изгелеккә исе китми.
Үз пычрагы якын аңа бар нәрсәдән.
Үз тизәге исен генә хуш күрә ул.
Ah, сез ерткыч юлбарыслар! Нишләдегез?!
Нинди хәлгә төшердегез атагызны!
Ак сакалы, чал чәчләре каршысында
Чылбырдагы котырынган аю хәтта
Хөрмәт белән аның кулын ялар чакта,
Сез, вәхшиләр, төрле яктан талый-талый,
Акылыннан яздырдыгыз тәмам аны.
Игелеген күп күрсә дә хакимчән ир —
Корнуолл да якламады бичараны!
Бу кадәр дә чиктән ашкан явызлыкны
Әгәр күкләр тиз арада туктатмаса,
Кешелекнең хәле яман — озакламый,
Тирән диңгез төбендәге еланнардай,
Адәм заты берсен берсе ашый башлар.

Гонерилья

Селәгәй син! Күренеп тора, яңакларың
Бертуктаусыз чабакларга, ә муеның
Камыт өчен яратылган. Ач күзеңне,
Намус ни дә, хурлык нәрсә — аер бераз!
Фетнәчене кызганасың? Явызларны
Зыян салып өлгергәнче җәзалыйлар.
Как барабан, сөрән салдыр, җый гаскәреңне!
Каурыйлы очлым кигән французлар
Каплап алган йоклап яткан илебезне.
Ә син монда бик зур намус ияседәй
Ахмак көе: «Ник алай да, ник болай?» — дип,
Күзләреңнән яшь агызып такмаклыйсың.

Олбани

Син үзеңә күз сал бераз, шыксыз шайтан!
Иблискә килешсә дә шыксызлыгы,
Хатын-кызга килешми ул, аңла шуны.

Гонерилья

Ah, аңгыра!

Олбани

Әй син, тәмуг албастысы,
Иблисләнеп ник чыраең үзгәртәсең?

Шул кулларым белән сине кисәкләргә
Өзгәләргә иде дә бит, ләкин булмый.
Үзең — шайтан, кыяфәтең — хатын-кыз шул,
Шуңа күрә андый эшкә кулым бармый.

Гонерилья

Ир икәнең исеңә төште! Камыр батыр!

Чапкын керә.

Олбани

Нинди хәбәр белән килдең?

Чапкын

Герцог үлде.
Үтерделәр галиҗәнап Корнуоллны.
Глостерның күзен төртеп чыгарганда,
Хезмәтчесе тарафыннан үтерелде.

Олбани

Күзен төртеп чыгарганда?

Чапкын

Хезмәтчесе
Глостерны кызганудан үз кылычын
Хуҗасының күкрәгенә юнәлдерде.
Мондый хәлдән шашар чиккә җиткән герцог
Ярсуына түзалмыйча үтерде аны,
Тик үзенең ярасы да тирән булган,
Хезмәтчесе артыннан ук китеп барды.

Олбани

Әле җиңел котылган ул! Инде ышанам
Күктә гадел хөкем барга. Ah Глостер,
Бер күзеңне жуйдыңмыни, бичаракай?

Чапкын

Икесен дә.
(Гонерильяга.)
Сеңлегездән хат, миледи.
Бик ашыгыч җавап көтә.

Гонерилья
(читкә)

Хәбәре әйбәт.
Регананың тол калуы борчый мине.
Эдмунд белән аралары якынайса,
Бу күңелсез тормышымнан арындырыр.
Хыялларым чәлпәрәмә килүе бар...
Ә хәбәре үзе болай начар түгел.
(Кычкырып.)
Хатны укып чыгуга ук җавап язам.
(Китә.)

Олбани

Ә атасын җәзалаган ул мизгелдә
Яшь Глостер кайда булган?

Чапкын

Ул бирегә
Хатыныгызны озата килде.

Олбани

Кайда соң ул?

Чапкын

Әле генә очраштык без, кайтып китте.

Олбани

Атасына ни булганны белмимени?

Чапкын

Ah, әфәндем, ул әтисен үзе саткан
Һәм иркенләп аңа җәза бирсеннәр дип,
Өеннән үк чыгып киткән.

Олбани

Ah, Глостер!
Үз-үзеңне корбан итәр дәрәҗәдә
Хөкемдарга тугры булып калган өчен
Бүләкләрмен. Ә хәзергә нык бул, туган,
Синең өчен үч алыныр! Киттек әйдә,
Ни булганын сөйлә миңа бәйнә-бәйнә.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дувр тирәсенә урнашкан француз лагере. Кент һәм Сарай йомышчысы керәләр.

Кент. Сез француз короленең кинәт кенә Франциягә кайтып китү сәбәбен белмисезме?

Сарай йомышчысы. Ул ниндидер бик тә мөһим дәүләт эшләрен эшләп бетермичә киткән булган. Инде корольлеккә бик зур куркыныч янавы ачыклангач, аның анда булуы бик тә мөһим булганга күрә, кичекмәстән кайтып киткән.
Кент. Ә гаскәр башлыгы итеп кемне калдырган?
Сарай йомышчысы. Франция маршалы Ла-Фарны.
Кент. Сез тапшырган хатны королева ничек кабул итте? Бик кайгырдымы?

Сарай йомышчысы

Әйе, милорд. Минем алда хатны укыды.
Үзем күрдем, аның нәфис йөзе буйлап
Эре-эре күз яшьләре тәгәрәде.
Әмма аны җиңәргә дип килгән кайгы
Чигенергә мәҗбүр булды.

Кент
Ул борчылган...

Сарай йомышчысы

Әйе, ләкин шашар хәлгә җитеп түгел.

Аның күңелен яулар өчен шул мизгелдә
Кайгы белән сабырлыгы көрәштеләр.
Күргәнегез бармы икән, кайчакларда
Аяз күктән яңгыр ява, ул да шулай
Үзе елый, үзе шундук елмая да;
Иреннәре нәкъ салават күпередәй
Балкып-балкып китә аның, күрмәгәндәй,
Нурлар чәчеп торган якты күзләреннән
Бөртек-бөртек энҗе яшьләр тәгәрәвен.
Кайгы безне һәрчак шулай матурласа,
Кайгыдан да кыйммәт нәрсә булмас иде.

Кент

Хат укыган чакта сорау бирмәдеме?

Сарай йомышчысы

Йөрәге таш булып каткан кеше төсле
Бер-ике кат авыр сулап: «Әти!» — диде.
Ә аннары: «Апаларым! Апаларым!
Оялыгыз бераз гына! Кент! Әтием!
Ничек инде шундый төндә? Шул давылда?
Ah, мәрхәмәт хисе беткән хатыннарда!» —
Шулай диеп ул илаһи күзләреннән
Изге суга коендырды ah-зарларын.
Һәм шуннан соң чыгып китте, аулак җирдә
Үз кайгысын үзе генә йотар өчен.

Кент

Юк, йолдызлар тудыра безне, тик йолдызлар.
Юкса болай төрле-төрле булмас иде
Бер атадан, бер анадан туган затлар.
Ә шуннан соң сөйләшкәнең булдымы?

Сарай йомышчысы
Юк.

Кент

Король кайтып киткәнче үк булдымы бу?

Сарай йомышчысы

Король киткәч. Ул юк иде.

Кент

Инде әйтим:
Бичара Лир килеп җитте. Ул Дуврда.
Бераз гына аңына килгән чакларында,
Ник Дуврда икәнлеген аңлый кебек,
Әмма кызын һич күрергә теләми ул.

Сарай йомышчысы

Ә ни өчен?

Кент

Оятына көч килгәндер,
Рәхимсезлек күрсәтте бит төпчегенә:
Фатихадан мәхрүм итте, читкә сөрде,
Аңа дигән мирасны да тулысынча
Эт йөрәкле кызларына бүлеп бирде.
Менә шулар аны хәзер кызы белән
Күрешүдән тыеп тора.

Сарай йомышчысы

Бичара Лир!

Кент

Олбани һәм Корнуоллның гаскәрләре
Кайда хәзер, ишетелмиме?

Сарай йомышчысы

Алар юлда.
Бирегә таба киләләр, ди.

Кент

Алай икән.
Йә, әйдәгез, Лир янына барыйк хәзер.
Сезне шунда калдырырмын. Кемлегемне
Мин беразга ачмый торам. Сәбәбе бар.
Әмма ачкач сез, әлбәттә, үкенмәссез.
Ярдәмегез бәяләнер. Инде китик.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Французлар лагерендагы чатыр. Корделия, Табиб, барабаннар кагып, байраклар күтәреп, офицерлар һәм солдатлар керәләр.

Корделия

Бу, әлбәттә, әлбәттә ул. Бая гына
Аның җырлап йөрегәнен күргәннәр ич.
Тигәнәктән такыя ясап таҗ кигән, ди,
Ә таҗын ул әрекмәннәр, күкчәчәкләр,
Тукранбашлар һәм әремнәр белән бизәп;
Билдән үскән чүп үләне арасында
Йөри икән ул ташландык бер басуда.
(Офицерга.)
Хәзер үк гаскәр җибәрегез, эзләсеннәр,
Ул басуны төрле яклап иңләсеннәр,
Тикшерсеннәр һәрбер куак, һәр чокырны —
Табу белән аны бирегә китерсеннәр.

Офицер китә.

(Табибка эндәшеп.)
Әйтегезче, сезнең гыйлем ярдәмендә
Акылына кайтарырга мөмкинме аны?
Зинһар өчен, терелтегез, терелтегез,

Бар байлыгым сезгә булсын. Йә, ни дисез?

Табиб

Бер чара бар, ул да булса, ханым, йокы.
Ә йоклатыр өчен төрле үләннәр бар.
Шифалы үлән тәэсиреннән күзен йомып,
Хәсрәтеннән арыныр ул, тынычланыр.

Корделия

Җиде кат җир астындагы хәят суы,
Тау-таш ярып чишмә булып бәреп чык та
Терелт аны — җәфа чиккән җан иясен!
Хәзер исә барыгыз да аны эзләгез,
Зинһар өчен, соңармагыз, ашыгыгыз!
Котырынган ярсуы аны кинәт кенә
Харап итеп, үз-үзенә кул салмасын!

Чапкын керә.

Чапкын

Ah, миледи, Британия гаскәрләре
Ташкын булып монда килә!

Корделия

Анысын беләм.
Без аларны каршы алырбыз. Әти, бәгърем!
Үзем өчен борчылмыйм мин. Сине уйлыйм.
Мыскылланган картлыгыңны яклыйм шулай.
Шуңа күрә ил-дәүләтле хаким ирем
Гозеремне аяк аска таптамады.
Бу көрәшкә мине вәхши кансызлык һәм
Дан-дәрәҗә, шөһрәт сөю этәрмәде.
Тик ярату, үз әткәмне яратуым —
Минем аңда, минем җанда, минем канда.
Ah, тизрәк күрәсе иде газиземне!

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Глостер кирмәне. Регана белән Освальд керәләр.

Регана

Йә, җизнинең гаскәрләре юлдамы инде?

Освальд
Әйе, юлда.

Регана

Гаскәр башы ул үземе?

Освальд

Бик авырлык белән генә риза булды.
Яу эшендә хатыны аннан булдыклырак.

Регана

Лорд Эдмунд сезгә баргач герцог белән

Ни дә булса сөйләштеме?

Освальд
Юк, миледи.

Регана

Синдәге ул Эдмундка дигән хатта
Ниләр язды икән апа?

Освальд

Һич әйталмыйм.

Регана

Лорд Эдмунд бик мөһим эш белән китте.
Күзләреннән мәхрүм иткәч Глостерны
Үтермичә зур ахмаклык эшләгәнбез.
Кая барып чыкса да, ул, шул кызганыч
Кыяфәтен безгә каршы корал итеп,
Безгә каршы нәфрәт тудыра йөрәкләрдә.
Миңа калса, Эдмунд аны кызганудан,
Сукыр килеш михнәт чигеп йөрмәсен дип,
Бу дөньядан озатырга китте бугай.
Бер уңайдан ул дошманның куәтен дә
Үз күзләре белән күреп, белеп кайтыр.

Освальд

Милединың хатын аңа тапшырыр өчен
Мин артыннан китәм хәзер.

Регана

Юк, китмә, кал.
Иртәгә без яу чыгабыз. Юл бик хәтәр.
Безнең белән кузгалырсың сәфәреңә.

Освальд

Юк, ярамый, бикәм миңа һичберкайда
Тукталмаска әмер бирде озатканда.

Регана

Ә хат нигә? Ни кирәген телдән генә
Әйтә алмас идеңмени? Димәк, анда
Нәрсәдер бар... Рөхсәт ит, ачыйм әле.
Күңелемне күрсәң әгәр, яратырмын.

Освальд

Юк, миледи, андый эшкә барганчы мин...

Регана

Беләм, апам ирен сөйми. Анысы хак.
Әле үткән килүендә күз уйнатып,
Эдмундка шундый серле карады ул.
Син бикәңнең сердәше бит.

Освальд
Юк, миледи.
Регана

Синең нинди кош булуың миңа мәгълүм.
Киңәшем шул, мин әйткәнне исеңдә тот:
Герцог үлде. Эдмунд белән килештек без —
Минем ирем булачак ул. Уйлап кара.
Андый чакта апага ник кысылырга?
Эдмундны эзләп тапкач, рәхим итеп,
Тапшыр шуны. Ә бикәңә мин әйткәнне
Түкми-чәчми җиткер дә әйт, котырмасын.
Акылына килсен бераз. Йә, ярый, хуш!
Теге сукыр хыянәтче очрап куйса,
Шундук юк ит. Аның башы кыйммәт тора.

Освальд

Кулыма гына килеп капсын, мин үземнең
Кемгә тугры икәнемне күрсәтермен!

Регана

Хәерле юл.

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Дувр тирәсендәге бер урын.
Глостер һәм крестьян киеменә киенгән Эдгар керәләр.

Глостер

Бу кыяга менәбезме, юкмы соң без?

Эдгар

Менәбез бит. Менгәнебез сизелмиме?

Глостер

Миңа калса, тигез җирдән барабыз күк.

Эдгар

Булыр тигез! Текә ярдан үрмәлибез.
Диңгез шавын ишетәсезме?

Глостер

Юк, ишетмим.

Эдгар

Димәк, сезнең күзләрегез белән бергә
Барлык башка тойгылар да зарарланган.

Глостер

Димәк, шулай булып чыга. Әйе, әйе,
Хәтта синең тавышың да үзгәргән күк,
Сөйләвең дә элеккедән чиста, ыспай.

Эдгар

Ялгышасыз. Мин һаман шул, киемем генә
Чистарак һәм ыспайрак.

Глостер

Миңа калса,

Сөйләшүең бүтән синең.

Эдгар
Менеп җиттек.
Туктагыз, сэр. Бу кадәрле текә ярдан
Аска карау, ай, куркыныч, баш әйләнә.
Коточарлык төпсез бушлык, упкын анда.
Моннан чебен булып кына күренүче
Ач козгыннар бөтерелә, ә астарак,
Хәтта үзенең башыннан да кечерәк күренеп,
Текә ярга ябышып кемдер тамыр җыя.
Ә иң аста, яр буенда, балыкчылар
Тычканнар күк йөгерешеп мәш киләләр.
Җилкәннәре киерелгән дәү бер кораб
Көймә чаклы гына калган, ә көймәләр
Калкавычлар булып кына күренәләр.
Кайберләрен хәтта күз дә шәйли алмый.
Усалланып яр ташына капланучы
Дулкыннарның шау-шуын да ишетеп булмый.
Юк, бүтәнчә карый алмыйм, баш әйләнеп
Шул упкынга тәгәрәвең мөмкин моннан.

Глостер

Шул урынга илтеп бастыр әле мине.

Эдгар

Менә хәзер сез нәкъ упкын читендә үк.
Сак булыгыз. Мин сикермәс идем моннан,
Шул тау кадәр алтын вәгъдә итсәләр дә...

Глостер

Җибәр кулны. Менә сиңа тагын янчык.
Бу янчыкта бик кыйммәтле йөзек булыр.
Ал да шуны, рәхәтен күр. Инде, бар, кит.
Тик киткәнең ишетелсен. Ярый, сау бул.

Эдгар

Бәхет телим сезгә, милорд.

Глостер
Әйе, анда
Мондагыдан бәхетлерәк булачакмын.

Эдгар
(читкә)

Менә хәзер өметсезлек тырнагыннан
Мин әткәйне хәйлә белән йолып алам.

Глостер

Йа аллалар!
(Тезләнә.)
Бу дөньядан ваз кичтем мин.
Һәм илаһи карашыгыз каршысында
Тыныч кына газаплардан арынам менә.

Әгәр түзә торган булса ул газаплар,
Иркегезгә каршы бара алмас идем.
Гомер шәмем үзе янып беткәнгәчә,
Пыскып кына көйрәр иде. Әй, аллалар,
Әгәр исән була калса улым Эдгар,
Шәфәгатьле булып аны саклагыз сез!
Сау бул, туган, бәхилләшик.

Эдгар
Хушыгыз, сэр.
Мин китәмен. Инде киттем.
(Глостер алга таба сикерә һәм егыла.)
Ah, куркыныч.
Әгәр гомер өзелергә тора икән
Өзелгәнен күзаллау да өзә аны.
Әткәй инде хыялында егылып төште,
Упкындагы үлеменең кочагында.
Әгәр дә ул уянмаса? Сез исәнме?
Берәр тавыш бирегез, сэр! Ишетәсезме?
Соң, әлбәттә, ишетми ул. Юк, юк, терелә.
(Тавышын үзгәртеп.)
Сез кем, милорд? Нәрсә булды?

Глостер
Кит, үлимче.
Эдгар

Пәрәвезме, мамыкмы син йә һавамы?
Шуның кадәр югарыдан очып төшеп
Чәлпәрәмә килер чакта, таза-саусың.
Канау түгел, сыдырылган җирең дә юк.
Сулыйсың да, сөйлисең дә. Ә бит, туган,
Син егылган ул кыяның биеклеге
Унлап мачта биеклеге кадәр булыр.
Син могҗиза белән генә исән калдың.
Яле, тагын ни дә булса әйтеп кара.

Глостер

Мин егылып төштемме соң? Егылдыммы?

Эдгар

Әнә теге бурлы кыя түбәсеннән.
Анда сабан тургае да менеп җитмәс.
Күрәсеңме?
Глостер

Күрер өчен күз кирәк бит...
Миңа үлү насыйп түгел микәнни соң?
Хәсрәтемнең, ичмасам, шул юанычы
Бар иде бит. Мөмкин иде котылырга
Золымнардан, кереп үлем кочагына,
Залимнәрнең дәһшәтеннән көләр өчен.

Эдгар

Йә, тор әле. Бир кулыңны. Менә шулай.

Аягында басып торыр хәлең бармы?

Глостер

Кызганычка каршы, бар шул.

Эдгар
Гаҗәп, гаҗәп!
Югарыда синең янда басып торган
Һәм бераздан китеп барган ул кем иде?

Глостер

Ач-ялангач бер хәерче.

Эдгар
Миңа астан
Ике күзе ике ай күк күренде аның.
Әллә меңләп томшыгы бар. Мөгезләре
Диңгездәге дулкыннар күк сырлы-сырлы.
Ул, әлбәттә, иблис булган. Бәхетең инде,
Җиңел генә котылгансың син үлемнән.
Үзләренә шөһрәт өчен могҗизалар
Тудыручы аллаларга рәхмәт укы.

Глостер

Инде аңладым һәм бүгеннән мин кайгымны,
Шәрран ярып: «Булды, җитте!» — дигәнгәчә,
Үлгәнгәчә йөрәгемдә йөртәчәкмен.
Ә мин теге син сөйләгән мөгезлене
Кеше диеп уйладым бит. Ә ул — иблис.
Әйтәм аны телендә гел шайтан да җен.
Упкынга да ул җитәкләп алып менде.
Эдгар. Бернидән дә курыкма, берүк сабыр бул син.

Киеменә чәчәкләр аскан, чүп үләннәреннән үргән таҗ кигән сәер кыяфәтле Лир керә.

Кем килә ул? Акылы камил булган затның
Болай итеп киенергә акылы җитмәс.

Лир

Юк, юк, минем акча сугар хокукым бар —
Мин бит король.
Эдгар. Ah, коточкыч күренеш бу!
Лир. Бу мәсьәләдә табигать сәнгатьтән өстенрәк. Менә сезгә гаскәр яллар өчен акча. Ә бу егетнең җәя тотышы карга карачкысын хәтерләтә. Син җәяңнең керешен аршын буе тарт. Карагыз әле, карагыз, тычкан! Әкрен, әкрен, хәзер тотабыз. Бер кисәк ит бирегез әле, капкын куябыз. Күрәсезме бу тимер бияләйне?! Шуны киеп алам да Алып батырны алышка чакырам. Сөңгеләрне алга! Әйбәт, әйбәт очасың, кошчыгым. Фию-у! Тиде, тиде, нәкъ төбәгән җиргә тиде. Парольне әйт.
Эдгар. Күке төкереге.
Лир. Уз әйдә.
Глостер. Мин бу тавышны таныйм.
Лир. Ха! Гонерилья ак сакаллы?! Алар минем алда ялагай этләр кебек бөтереләләр иде. Әле миңа кара сакалым да чыкмас борын ук, зурлап, зирәк аксакал, дип дәшәләр иде.
Һәрвакыт мин «әйе» дисәм, «әйе», «юк» дисәм, «юк» дип җөпләп тордылар. Ә бит ул «әйе», «юк» дигән сүзләр аллалардан иңгән сүз түгел. Аллалар алай ялагайланырга кушмаганнар.

Бервакыт яңгыр астында чыланып, салкын җилдә тешләрем тешкә тими башлагач, шундый иттереп күк күкрәп җибәрде, әмма никадәр генә боерсам да, туктарга теләмәде. Менә шуннан соң мин аларның кем икәнлекләрен аңладым. Бушбугазлар алар. Алар миңа: «Бар нәрсәгә көчең җитә», — дип әйтәләр иде, ә менә бизгәккә каршы тора алмыйм икән, димәк, бизгәк миннән көчлерәк.

Глостер. Исемә төште, таныйм, таныйм, бу бит король.

Лир

Әйе, король, баштанаяк корольмен мин.
Яраннарым карашымнан дер калтырый.
Күрәсез бит. Ә мин сине гафу итәм.
Гөнаһың ни? Уйнаш кылып каптыңмыни?
Бар гаебең шул гынамы? Юк, үлмисең.
Уйнаш өчен үтермиләр. Аны хәтта
Әтәчләр дә күз алдында башкаралар.
Ә чебеннәр, башка шөгыль тапмагандай,
Көне-төне шул эш белән маташалар.
Азыныгыз-тузыныгыз, чөнки әнә
Глостерның теге уйнаштан туган улы
Минем хәләл хатыныма ясап биргән
Кызларымнан күп мәртәбә шәфкатьлерәк.
Азгынлыкны изге эш итеп ишәегез,
Бик күп солдат кирәк миңа. Әнә теге
Нәзакәтле ханымга бер күз сал әле.
Йөзенә баксаң, коеп куйган әүлия күк,
Тән ләззәтен белмәгәндәй кылана ул —
Әйтерсең лә бот арасын кырау суккан.
Ә чынында азгыннарның азгыны ул,
Азгынлыкта көзәннән дә азгынрак.
Симертелгән бия кебек артын борып,
Узган-барган һәр кешене ымсындыра.
Хатыннарның һәммәсе дә кентаврлар —
Билгә кадәр өлешләре аллалардан,
Билдән түбән һәммә төше — иблиснеке.
Анда җәһәннәм, тәмуг, караңгылык, әшәке исләр чыгарып дөрли-дөрли янган күкерт базы ул. Эссе, тынчу. Бар нәрсәне көйдерә, йота, харап итә. Тфү, тфү, тфү! Әй, аптекчы, берәр шешә җофар мае бирче, дустым, шушы бозык уйларымны бераз гына хушбуйлыймчы. Менә сиңа акча.

Глостер

Рөхсәт итче, үбим әле шушы кулны.

Лир

Башта сөртим, мәет исе килә аннан.

Глостер

Табигатьнең мие түнгән бер кисәге —
Җимерек гакыл! Киләчәктә нәкъ шулай ук
Безнең бөек дөньябыз да җимерелер,
Көлгә дүнәр... Ә син мине таныйсыңмы?

Лир. Таныш күзләр. Ә син нигә миңа күз кысасың? Юкка тырышасың, сукыр купидон, хәйлә белән генә миннән амур ясый алмассың. Минем өндәмәмне укы әле — син аның бигрәк тә язылышына игътибар ит.

Глостер

Һәр хәрефе кояш булып балкыса да,
Укый алмыйм, чөнки күрмим.

Эдгар

Әгәр миңа
Король шундый хәлдә диеп сөйләсәләр,
Мин ышанмас идем хәтта. Әмма бу хак.
Аңа карап ирексездән йөрәк сызлый.
Лир. Укы!
Глостер. Ничек? Күз чокырым беләнме әллә?
Лир. Ә, әнә эш нәрсәдә икән. Маңгаеңда күзең, янчыгыңда акчаң юкмыни? Янчыгыңа җиңеллек, күзләреңә авырлык килдеме? Алай да дөньяның кая таба барганын күрә торгансыңдыр әле?
Глостер. Күрмим, тоям.
Лир. Ничек инде күрмисең? Ычкындыңмы әллә? Андый эшләр күзсез дә күренә. Ә син колакларың белән кара: әнә бер судья ничек итеп гади кесә карагының кычкырып котын ала. Кил әле, колагыңа гына бер сүз әйтәм: әгәр дә урыннарын алыштырсаң — менә кара... Бер, ике, өч, күрәсеңме? Инде кемнең судья, кемнең карак икәнен төшендеңме? Ә син чылбырдагы этнең хәерчегә ничек итеп өргәнен күрдеңме соң?
Глостер. Күрдем, сэр.
Лир. Ә тегесе башын иеп качамы? Властька буйсынуның бөек мисалы шушы инде ул: урынына карап, эткә дә сәлам бирәсең.
Әй, син, җәллад, нигә урам фахишәсен
Кара канга батырганчы камчылыйсың?
Үзеңә сук. Син үзең дә, шыпырт кына,
Аңа кызыгып йөрисең бит, эттән туган.
Ата карак вагракларны бимазалый.
Гариплегең сәләмә аша бик тиз күренә,
Төлке толып, затлы туннар аны каплый.
Гөнаһларны төрсәң әгәр алтын белән,
Галиҗәнап законның да үткен угы
Аңа бәрелеп шартлап сынар зыян салмый.
Әгәр төрсәң аламага... әтрәк-әләм
Кәрлә дә аны төртеп тишәр салам белән.
Закон бозган җинаятьче юк дөньяда.
Юк, дидем бит. Барысын да мин йолучы.
Ал, ал, туган. Судьяларның тулмас авызын
Томаларлык бәяне мин үзем түлим.
Күзлек сатып ал да өреп кабартылган
Иң кабахәт сәясәтче булып кылан,
Имештер, син күрмәгәнне күрәсең, ди.
Алай, алай, итекләрне салдыр әле.
Йә, тарт инде. Катырак тарт. Менә шулай.

Эдгар

Мәгънәсенә мәгънәсезлек кушылган да
Акылына акылсызлык иңгән аның!

Лир

Мине җәлләп еламакчы булсаң әгәр,
Ал син минем күзләремне. Мин бит таныйм.
Син — Глостер. Түз, түз, туган. Беләсең бит,
Бу дөньяга елап килә һәммәбез дә.

Елый-елый туабыз да, тын алуга,
Өр-яңадан акырырга тотынабыз.
Яле, тыңла, мин бер үгет сөйлим сиңа.
(Чүп үләннәреннән үргән таҗын сала.)

Глостер

Ah, бу нинди каһәрләнгән көн булды соң?

Лир

Бик беләсең килсә, шулай елый-елый,
Без дөньяның бу юләрләр театры
Сәхнәсенә басуыбызга яшь түгәбез...
Эшләпәсе нинди әйбәт. Бу бит фикер!
Шул эшләпә киезенә без атларның
Тоякларын урыйбыз да, шыпырт кына
Кияүләрнең өсләренә барып чыгып,
Ас, кис, җимер, чәнче, тура, кырып ташла!

Берничә хезмәтче ияртеп, Сарай йомышчысы керә. Эдгар белән Глостер читкәрәк китәләр.

Сарай йомышчысы

Менә бит ул. Тотыгыз, зинһар, качырмагыз.
Галиҗәнап, сезнең өзелеп сөйгән кызыгыз...

Лир

Мин тоткында? Инде миңа котылу юкмы?
Язмыш мине көләр өчен яраткан тик.
Зинһар, миңа тимәгез сез — йолым бирәм.
Табиб кирәк миңа, табиб. Мин яралы.
Минем мием яраланган.

Сарай йомышчысы

Бар да булыр.

Лир

Һичбер төрле ярдәм юкмы? Мин ялгызым?
Бу хәсрәттән мөмкин тозга әйләнергә.
Күзләрең дә көзге юлның тузаннарын
Бастыручы сукоярга әйләнерләр.

Сарай йомышчысы

Галиҗәнап...

Лир

Юк, мин үлем каршысына
Кияү егете кебек барам, көязләнеп.
Кайгыларым, таралыгыз! Мин бит король.
Кем икәнне онытмагыз, әфәнделәр!

Сарай йомышчысы

Хөкемдарга буйсыну ул — безнең бурыч.

Лир

Ул чагында яшәп була. Түләү — шул ул.
Аласыгыз килә икән, башта бераз

Минем арттан йөгерегез. Мә, мә, мә, мә...

Йөгереп кача, хезмәтчеләр куа китәләр.

Сарай йомышчысы

Мондый хәлдә иң кабахәт сукбайны да
Кызганмыйча мөмкин түгел. Бу бит король!
Төпчек кызың... тик ул гына коткарачак
Табигатьне
Теге икәве дучар иткән
Аллаларның каһәреннән...

Эдгар
(якын килеп)

Сәлам сезгә!
Сарай йомышчысы. Сәлам, сәлам. Йомышыгыз бармы миндә?
Эдгар. Көткән сугыш була диме? Ишетелмиме?
Сарай йомышчысы. Ничек инде булмасын ди. Әлбәттә, була.
Эдгар. Британлылар ерак микән?

Сарай йомышчысы

Ерак түгел.
Инде тиздән төп көчләре күренә башлар.

Эдгар

Рәхмәт, сэр.

Сарай йомышчысы

Королева үзе биредә
Бер эш белән тоткарланды, әмма гаскәр
Яу кырына чыгып китте.

Эдгар

Рәхмәт, сэр.

Сарай йомышчысы китә.

Глостер

Йа аллалар, алыгызчы минем җанны,
Калдырмагыз мине иблис коткысына —
Үз-үземә кул салудан аралагыз.

Эдгар

Догаң әйбәт икән, картлач.

Глостер

Ә сез кем, сэр?

Эдгар

Язмыш колы. Күпне күргән бер фәкыйрьмен.
Чиккән кайгы-хәсрәтләрдән сабак алып
Өйрәндем мин адәмнәрне кызганырга.
Бир кулыңны, аулаграк берәр җиргә
Илтеп куйыйм.

Глостер

Рәхмәт, сэр. Күкләр сезгә
Бәхет, шатлык, зур уңышлар насыйп итсен.

Освальд керә.

Освальд

Бу күзсез баш минем өчен хәзинә бит.
Миңа бүләк алыр өчен яралган ул.
Син, сатлыкҗан! Догаңны укы һәм тизрәк.
Сине үтерер кылыч чыкты кынысыннан.

Глостер

Бер яхшылык эшлә, әйдә үтер тизрәк,
Мәрхәмәтле кулың, зинһар, калтырамасын.

Эдгар Глостерны үз гәүдәсе белән каплый.

Освальд

Ничек җөрьәт итәсең син, оятсыз кол!
Бу карт явыз җинаятьче, сатлыкҗан ул.
Бар, кит, аның язмышына дучар булма.
Башың исән калсын дисәң, кагылма аңа.

Эдгар

Ә, юк инде, сәбәп барда кагылабыз
Һәм әлегә китәргә дә уйламыйбыз.

Освальд

Йә китәсең, йә үләсең, әшәке кол!
Эдгар. Бар, бар, юлыңда бул, мәрхәмәтле әфәнде, ярлы халыкны бимазалама. Синең мактануларыңнан бик курыктым инде, котым ботыма төште, үләм дип торам. Картка якын киләсе булма, читтәрәк тор, диләр, югыйсә хәзер синең баш сөягеңме, әллә шушы күсәкме катырак икәнен белер өчен сынау үткәрә башлыйм. Мин синең белән ләкәтә сатып тормаячакмын.

Освальд

Югал күз алдымнан, тирес корты!

Эдгар

Менә хәзер ипи шүрлегеңә берне кундырырмын.
Төкерәм мин синең кылыч уеныңа.

Сугышалар. Освальд егыла.

Освальд

Син бит мине үтердең, кол. Ал янчыкны.
Һәм бәдбәхет булмас өчен җирлә мине.
Аннан шушы хатны тапшыр Эдмундка,
Ягъни граф Глостерга. Аны исә
Британия гаскәреннән эзләп тап син.
Ah, вакытсыз килдең, үлем!..
(Үлә.)

Эдгар

Мин бит сине яхшы беләм, кабахәт җан,
Үз бикәңнең азгынлыгын йомыш итеп

Бик күп чаптың.

Глостер

Ничек, әллә ул үлдеме?

Эдгар

Кил, хөрмәтлем, утыр бирегә, ял ит бераз.
Карыйк әле хәшәрәтнең кесәләрен.
Ниндидер хат диде бит ул. Һәм ул хатның
Безгә ярап куюы бар. Үлүе яхшы.
Тик нәҗескә кул ягучы мин булуга
Бераз гына эчем поша. Менә хаты.
Балавызга баскан мөһер, кичер мине,
Дошманнарның ниятләрен белер өчен,
Без хатларын гына түгел, кылыч белән
Күкрәкләрен ачарга да әзер бүген.
(Укый.)
«Үзара бирешкән вәгъдәләребезне исеңә төшер. Инде хәзер син минем иремне юк итә аласың, моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек, тик ихтыяр көчең генә нык булсын. Әгәр дә ул җиңүче булып кайтса, бөтен хыялларыбыз юкка чыгачак. Ул чагында мин гомерлек тоткын. Аның түшәге минем өчен төрмә. Аның җирәнгеч һәм тынчу кочагыннан коткар мине. Коткар да батырлыгың өчен бүләккә иремнең урынын ал. Сине өзелеп яратучы *(хәтта хатының дип әйтәсе килә)* Гонерилья».
Хатын-кызның азгынлыгы чик-чамасыз.
Син күр әле, ул үз ирен үтермәкче,
Ә алмашка минем энекәш кирәк аңа.
Ул башкисәр уйнашчылар арасында
Арадашчы булып йөргән син мөртәтне
Җеназа да укымыйча комга күмәм.
Ә бу хатны мин герцогның үз кулына
Вакытында тапшырырмын. Ул бәхетле,
Аны, әлбәттә, куандырыр синең үлем.
Явызлыкка чик куела чөнки бүген.

Глостер

Король шашкан. Минем акыл, юк, бирешми,
Чөнки әнә газабымны аңлыйм, тоям!
Миңа да бит шашу кирәк, әгәр шашсам,
Арыныр да иде акылым газаплардан,
Авыртулар онытылыр иде тәмам.

Барабан тавышлары ишетелә.

Эдгар

Мин барабан тавышлары ишетәм сыман,
Тизрәк сине дуслар янына илтеп куйыйм.
Киттек, картлач. Бир кулыңны. Әйдә кузгал.

Китәләр.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Француз гаскәрләре урнашкан лагерьдагы бер чатыр.
Корделия, Кент һәм Табиб керәләр.

Корделия

Кадерлем, Кент, синең кылган изгелеккә
Тиң бүләкне ничек эзләп табыйм икән?
Аның өчен җитмәс минем гомерем дә
Һәм шулай ук байлыгым да.

Кент

Бу сүзләрне
Ишетү дә иң зур бүләк минем өчен.
Ни булганын арттырмый да, киметми дә
Бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.

Корделия

Бу киемең
Хәтерләтә хәсрәт чиккән көннәреңне.
Син иң затлы киемнәргә лаек бүген.
Үтенеп сорыйм, алыштырчы өсләреңне.

Кент

Кемлегемне белдерергә әле иртә.
Зинһар, сез дә игълан итми торыгызчы.
Корделия. Яхшы, яхшы, шулай булсын. *(Табибка.)* Король нихәл?

Табиб

Әлегә йоклый.

Корделия

Йа аллалар! Әткәемне
Кайтарыгыз элеккеге халәтенә.
Һәм кызлары тарафыннан йолыккаланган
Акылының җепселләрен ялгагызчы.

Табиб

Рөхсәт булса, мин уятыр идем аны.
Ул бик озак йоклады инде.

Корделия

Ихтыярыгыз.
Фән кушканча эш итегез. Ә сез аны
Киендерә алдыгызмы?

Табиб

Әйе, әйе,
Йоклавыннан файдаланып, без аңарга
Өр-яңа һәм затлы кием киендердек.

Сарай йомышчысы керә. Хезмәтчеләр креслода йоклап утыручы Лирны күтәреп кертәләр. Сәхнә артыннан музыка тавышы ишетелә.

Юк, китмәгез. Хәзер аны уятабыз.
Уянганда, ул бик тыныч тотар үзен.

Корделия

Анысы яхшы.

Табиб

Якынрак килегез, зинһар.
Музыканы көчәйтегез, музыкантлар.

Корделия, тезләнеп, Лирның кулын үбә.

Корделия

Ah, әткәем, кадерлем син! Иреннәрем
Хөрмәт белән үбеп сине терелтсеннәр.
Шул үбүдән апаларның явызлыгы —
Әрнеп торган яраларың төзәлсеннәр.

Кент

Изгелегең чиксез икән, принцесса!

Корделия

Шушы ап-ак чәчләренә күз салу да
Йомшартырга тиеш иде күңелләрен.
Ышыкланыр түбә итеп чал чәчләрен,
Шуның кадәр нурлы йөзне ничек мөмкин
Бар дөньяны ялмап алган утлы телле
Яшеннәрнең күз камашкыч яктысында,
Йөрәк яргыч күк күкрәүләр, зәһәр җилләр,
Гарасатлар каршысына бастырырга?
Үз үлемен каршыларга бастырылган
Тузган түбә астындагы төнге сакчы!
Дошманымның этен дә мин кызганудан
Үз өемә дәшәр идем андый чакта.
Ә син исә, газиз әткәм, шул төнеңне
Шалаштагы черек салам өсләрендә,
Җыен сукбай арасында уздыргансың.
Хурлык! Хурлык! Әле ничек акылы белән
Гомере бергә сүнмәгәннәр... Ул кузгала.
Сөйләшегез үзе белән.

Табиб

Сез башлагыз.
Аның өчен хәзер сезнең сүз шифалы.

Корделия

Ничегрәк йокладыгыз, галиҗәнап?

Лир

Нигә инде каберемнән кузгатырга?
Син бит ожмах фәрештәсе. Мин — тәмугта:
Эчем-тышым ялкын минем. Күз яшьләрем
Эреп тамган кургашын күк пешерәләр.

Корделия

Хөкемдарым, әллә мине танымыйсыз?

Лир

Син — оҗмахтан. Үлүеңә күптәнме соң?

Корделия

Саташа ул.

Табиб

Әле уянып җитмәгәндер.
Көтик бераз.

Лир

Моңарчы мин кайда идем?
Хәзер кайда? Әллә инде көн яктысы?
Ник кешене бу кадәрле мыскылларга?
Ник сез мине кызганмыйсыз? Ә мин инде
Әллә кайчан жәлләп үлгән булыр идем.
Тукта, бу кул — минем кул бит. Минеке шул.
Энә белән төрткәнне дә сизә әнә,
Нәрсә булды икән миңа, беләсе иде.

Корделия

Зинһар, миңа карагызчы! Аталарча
Фатихалы кулыгызны сузыгыз, йә!
Юк, юк, нигә тезләнергә? Тезләнмәгез.

Лир

Йә, көлмәгез инде миннән. Мин — карт юләр,
Артык та һәм ким дә түгел... Мин сиксәндә...
Турысын әйтеп сөйләшкәндә, минем инде
Акылым да тулы түгел. Менә сезне
Мин таныйм да кебек үзем, тик шикләнәм.
Аңлый алмыйм чөнки кайда икәнемне.
Үтерсәң дә хәтерләмим бу киемне
Һәм шулай ук хәтерләмим бу төнемне
Кайда, ничек үткәргәнем. Сез көлмәгез,
Кылычым белән антлар иткән булыр идем:
Бу бит — минем Корделиям.

Корделия
(яшь аралаш)

Әйе, әйе.

Лир

Ник яшьләрең юеш синең? Чынлап әйтәм.
Юк, елама. Агу бирсәң, эчәр идем.
Мине нигә яратырга? Мин хәтерлим,
Апаларың бер сәбәпсез яратмыйлар,
Синең исә сәбәбең бар.

Корделия

Юк, сәбәп юк.

Лир

Кайда соң мин, Франциядә?

Кент

Галиҗәнап,
Бу җир сезнең үз илегез, үз җирегез.

Лир

Алдашырга ярамый бит.

Табиб
(Корделиягә)

Борчылмагыз.
Күрәсез бит, йокы аны дәвалаган,
Шашынулы өянәге узган сыман.
Әмма ләкин шунысы бар: үткәннәрен,
Зинһар, исенә төшермәгез. Бу — куркыныч.
Иң әүвәле бик һәйбәтләп ял итсен ул.

Корделия

Галиҗәнап, сезгә йокы бүлмәсенә
Узу авыр булмас микән?

Лир

Ачуланма.
Оныт, зинһар, кичер мине — карт тилене.

Кент һәм Сарай йомышчысыннан башкалар чыгып китәләр.

Сарай йомышчысы. Корнуолл герцогының үтерелүе турындагы хәбәр дөрес микән, сэр?
Кент. Дөрес.
Сарай йомышчысы. Аның гаскәрләрен хәзер кем җитәкли инде?
Кент. Глостерның уйнаштан туган улы дип әйтәләр.
Сарай йомышчысы. Әйтүләренә караганда, аның качкын улы Эдгар хәзер граф Кент белән Германиядә, ди, имеш.
Кент. Төрлечә сөйлиләр. Инде Британия гаскәрләре килеп тә җитә торганнардыр. Озакламый хәлиткеч сәгать сугачак.

Сарай йомышчысы

Бу сугышта бик күп кан коелыр төсле.
Ярый, хәзергә хушыгыз, сэр.
(Китә.)

Кент

Минем язмыш хәл ителер сәгать җитә,
Алда безне җиңү яки җиңелү көтә.
(Китә.)

Бишенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дувр тирәсенә урнашкан Британия гаскәрләре лагере. Байраклар, барабаннар белән Эдмунд, Регана, хадимнәр һәм солдатлар керәләр.

Эдмунд
(бер хадимгә)

Бар герцогка, җәһәт кенә белешеп кил,
Әллә тагын ниятеннән кайтканмы ул?
Һаман шулай икеләнсә, бер үкенер.
Әйт үзенә, төгәл генә җавап бирсен.

Хадим китә.

Регана

Апабызның чапкынына нидер булган.

Эдмунд

Шулай бугай.

Регана

Йә, сөекле Глостерым,
Инде минем ниятемне аңлыйсыңдыр.
Әйтегезче, әмма ләкин чын дөресен —
Сез апаны сөясезме?

Эдмунд

Әйе, сөям.
Үз апамны сөйгән кебек.

Регана

Ә менә теге
Үз иреннән бүтәннәргә хәрам булган
Җирләренә төшкәнегез булмадымы?

Эдмунд

Мондый фараз сезнең өчен һич төс түгел.

Регана

Арагызда нидер бар күк, шикләнәмен.
Эдмунд

Ни сөйлисез сез, миледи! Валлаһи, юк.

Регана

Көндәшлекне җенем сөйми. Ah, кадерлем,
Сез читтәрәк йөрегез аннан.

Эдмунд

Борчылмагыз.
Әнә үзе кереп килә ире белән.

Байраклар, барабаннар белән Олбани, Гонерилья һәм солдатлар керәләр.

Гонерилья
(читкә)

Эдмундны сеңлемә оттырудан
Бу сугышта отылуым хәерлерәк.

Олбани

Исәнмесез, балдызкаем. Ишеттем, сэр.

Король барып сыенган, ди, төпчегенә.
Безнең власть кысуына түзалмаган,
Башкалар да шул ук юлны сайлаганнар.
Хаклык өчен мин көрәшкә әзер анысы:
Басып кергән французны туктатырмын.
Әмма король юкка гына шашынмады,
Миңа калса, ул бик каты кимсетелде.

Эдмунд

Шәфәгатьле сөйлисез, сэр.

Регана

Ә ник кирәк?

Гонерилья

Дошманнарга каршы хәзер берләшик без;
Үткәндәге ызгышларны, талашларны
Искә төшереп тора торган вакыт түгел.

Олбани

Гаскәрдәге барлык өлкән яугирләрне
Җыярга да киңәшергә кирәк хәзер.

Эдмунд

Чатырыгызга килермен мин.

Регана
Гонерилья,
Ә син безнең белән әйдә. Киттекме?

Гонерилья
Юк.

Регана

Йә, нишләвең инде, апа? Алай булмый.

Гонерилья

Бавырыңны ни талавын чамаладым.
(Кычкырып.)
Барам, барам.

Ике якның да гаскәрләре һәм Эдмунд китәләр. Чыгып баручы Олбаниның каршысына Эдгар очрый.

Эдгар

Галиҗәнап, мин фәкыйрьдән җирәнмичә
Тыңласагыз бер-ике сүз әйтер идем.

Олбани

Ярый, сөйлә.
(Чыгып баручыларга.)
Артыгыздан хәзер җитәм.

Эдгар

Шушы хатны яу алдыннан укыгызчы.
Сез җиңсәгез, быргычыгыз хәбәр салсын.

Күрер күзгә мин фәкыйрьмен, әмма ләкин
Бер сугышчы җибәрермен, ул баһадир
Шушы хатта язылганның хак булуын
Кылычы белән исбат итәр. Җиңелсәгез —
Дошманнарның нияте дә, үзегез дә
Ахирәткә күчәчәксез. Җиңү телим!

Олбани

Тукта, укыйм.

Эдгар

Юк, көтә алмыйм, рөхсәт юк.
Вакыты җиткәч, сөрәнчегез хәбәр бирер —
Шулчак кабат каршыгызда булырмын мин.
(Китә.)

Олбани

Алайса, хуш. Мин хатыңны карап чыгыйм.

Эдмунд керә.

Эдмунд

Якынаеп килә дошман. Вакыт җитте.
Гаскәрләрне яу кырына чыгарыгыз.
Менә сезгә күзәтчеләр җыеп кайткан
Дошман көчен сурәтләүче мәгълүматлар.
Зинһар өчен, ашыгыгыз.

Олбани

Борчылмагыз,
Барысы да вакытында әзер булыр.
(Китә.)

Эдмунд

Апасын да, сеңлесен дә берәм-берәм
Яратам дип антлар итеп ышандырдым.
Инде хәзер еланнар күк йөри алар
Бер-берсеннән шикләнешеп, агу җыеп.
Тик кайсысын алырга соң? Икесен дә?
Йә берсен дә алмаскамы? Нишлим икән?
Икесе дә исән чакта миңа аларның
Берсенә дә хуҗа булу насыйп булмас.
Толын алсаң, Гонерилья шашыначак.
Анысына исәп тотсаң, ире исән.
Бу сугышта без герцогны файдаланыйк...
Ә калганын Гонерилья башкарачак.
Котылу җаен үзе табар. Күр әле син,
Корделия белән Лирга шәфкатьлелек
Күрсәтмәкче була герцог. Җиңик кенә,
Кулыма гына эләксеннәр, күрсәтермен.
Миннән хәзер ләчтит түгел, эш көтелә.
(Китә.)

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кыр. Сәхнә артында сугыш шау-шуы. Сәхнә буйлап барабаннар, байраклар белән Лир, Корделия һәм гаскәр уза. Эдгар белән Глостер керәләр.

Эдгар

Шушы агачның күләгәсе сиңа, картым,
Киң күңелле һәм кунакчыл хуҗа булсын.
Хаклык җиңеп чыксын өчен гыйбадәт кыл.
Синең янга исән кайту насыйп булса,
Юанычың булачакмын.

Глостер

Рәхмәт, сэр.
Күкләр сезне якласын да, сакласын да.

Эдгар китә.
Сугыш шау-шуы. Чигенергә боерып бырғы кычкырта. Эдгар керә.

Эдгар

Киттек, картлач, бир кулыңны. Лир җиңелде.
Ул үзе дә һәм кызы да әсирлектә.
Йә, бир инде, бир кулыңны. Киттек тизрәк.

Глостер

Кая? Нигә? Монда да бит череп була.

Эдгар

Ул нинди сүз? Өметеңне өздеңме әллә?
Без туганда сабыр итеп туабыз бит,
Үлгәндә дә сабыр булыйк. Өлгерүгә
Үлем үзе килеп җитә. Каршы бармыйк.
Тор, атакай.

Глостер.

Әйе, әйе, сез хаклы, сэр.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Дуврдан ерак түгел Британия гаскәрләре лагере. Офицер һәм солдатларын иярtеп, Эдмунд керә. Йөзләрендә җиңү шатлыгы. Алардан соң әсирләрне — Лир
белән Корделияне алып керәләр.

Эдмунд

Ышанычлы сак астында икесен дә
Хөкемгәчә таш зинданга озатыгыз.

Корделия

Кешеләргә игелек теләп корбан булган
Бичаралар бер без генә түгел җирдә.
Синең өчен әрним, әткәй, югыйсә мин
Язмышымның күзенә курыкмый карар идем.
(Эдмундка.)
Ә кызлары — апаларым нигә чыкмый?

Ник тамаша кылмый алар безгә карап?
Карасыннар.

Лир

Юк, кирәкми. Тизрәк, тизрәк,
Шул зинданга озатсыннар! Һәм без анда
Читлектәге кошлар кебек сайрашырбыз.
Хәер-дога сорарсың син, ә мин исә
Алларыңа тезләнермен гафу сорап.
Шулай итеп яңа тормыш башларбыз без —
Догалы һәм әкиятле, җырлы тормыш.
Канатларын алтын суы белән юган
Күбәләкләр белән уйнап юанырбыз.
Төрмәдәге сукбайлардан сораштырып
Әле сарай хәлләрен дә сөйләтербез:
Кем хөрмәттә, кем горбәттә,
Кемнәр баткан, кемнәр калыккан.
Һәм Алланың шымчылары сыман гына
Бу дөньяның агышына күз салырбыз.
Таш капчыкта тыныч кына яши-яши
Күзәтербез хакимнәрнең ызгышканын.
Өер-өер килә-китә торыр алар...
Ай тулганда эшләнәләр андый эшләр —
Күтәрелеш, чигенешләр.

Эдмунд

Озатыгыз.

Лир

Корделия, ә бит мондый корбаннарны
Аллалар да күккә чөеп мактыйлар, ди.
(Корделияне кочагына ала.)
Син бит хәзер минем кулда. Инде безне
Утка-суга салсалар да аера алмаслар.
Еламачы, күгәрченем. Сөрт күзеңне.
Үләт кырсын явызларны. Үлсәләр дә,
Елаталмас алар безне. Әйдә киттек.

Сакчылар Лир белән Корделияне алып чыгып китәләр.

Эдмунд

Әй, капитан! Син аларны зинданга озат.
Менә әмер. Соңрак укы, хәзер түгел.
Бел: дәрәҗәң бер баскычка күтәрелде.
Кулыңдагы әмерне дә үти алсаң,
Үсүеңнең чиге булмас. Шуны да бел:
Заманына күрә була кешесе дә,
Кылыч нечкә, әмма күңеле нечкә түгел.
Зур эшләрне икеләнеп эшләмиләр,
Йә, әйт хәзер: «Үтим», — диеп, йә булмаса,
Бар, үзеңчә яши бир син.

Офицер

Милорд, мин үтәрмен.

Эдмунд

Ярый, эшеңдә бул һәм онытма:
Язылганның һәммәсен дә үтәп чыксаң,
Бәхетлеләр рәтенә керт үзеңне.
Тик әмерне төгәл үтә. Соңлый күрмә.

Офицер

Җигелеп арба тартканым юк, солы ашамыйм,
Әмма адәм башкарганны башкарырмын.
(Китә.)

Бырғы тавышлары. Олбани, Гонерилья, Регана, офицерлар һәм солдатлар керәләр.

Олбани

Сэр, сез бүген зур батырлык күрсәттегез,
Сезне бүген бәхет үзе җитәкләде.
Король белән кызы сездә әсирлектә.
Инде аларны гадел хөкем ясар өчен
Безнең кулга тапшырыгыз.

Эдмунд

Ләкин мин, сэр,
Лирның урыны зиндан дигән фикер яклы.
Ак чәчләре, король дигән исеме белән
Солдатларның күңелләрен нечкәртеп ул,
Сөңгеләрен безгә каршы боруы бар.
Һәм кызын да шул ук сәбәп аркасында
Аның белән озаттырдым. Ә иртәгә
Йә булмаса бераз соңрак мин аларны
Хөкемезгә тапшырырмын. Хәзер исә,
Канга, тиргә баткан килеш ул эш белән
Шөгыльләнү мөмкин түгел, чөнки әнә
Югалтулар күз алдында, сугышчылар
Ятып калган иптәшләрен эзли кырда.
Һәммәсе дә ачулылар, шуңа күрә
Король белән Корделия мәсьәләсен
Кичектереп хәл итәрбез.

Олбани
Кичерегез,
Сез бит миңа буйсынулы, туган түгел,
Үзегезне минем белән тиң куймагыз!

Регана

Ул турыда әүвәл бездән сорарга иде.
Бу сугышта гаскәремә ул баш булды.
Мин вәкаләт бирдем аңа, шулай булгач,
Ничек инде тиң булмасын?

Гонерилья

Син тынычлан.
Ул үзенең батырлыгы аркасында
Синең биргән вәкаләттән күпкә өстен.

Регана

Мин сайлагач, корольләргә тиң, димәк, ул.

Олбани

Аны ирегез сыман итеп сөйләшәсез.

Регана

Кыек атып, җизни, туры тидердегез.
Суга карап күрәзәлек итәсезме?

Гонерилья

Синең суың бик пычрак һәм болганчык.

Регана

Кәефем юк, шуңа гына дәшми калам,
Бер сүз белән авызыңны каплар идем.
(Эдмундка.)
Гаскәрбашым, сиңа бирәм бар гаскәрем,
Сиңа булсын әсирләрем, җир-суларым,
Үземне дә өстәп бирәм, курыкмый билә,
Һәммәсен дә яулап алдың, ирем бул син.

Гонерилья

Булмый торсын!

Олбани

Анысы синнән торамыни?

Эдмунд

Һәм синнән дә тормый, герцог.

Олбани

Токымсыз зат,
Ялгышасың.

Регана
(Эдмундка.)

Кактыр, әйдә, барабаннар
Һәм көч белән — кылычың белән исбатла син
Мин күтәргән дәрәҗәгә хакың барын.

Олбани

Ашыкмагыз барабаннар кактырырга.
Мин Эдмундны һәм шулай ук сезгә таныш
(Гонерильяга күрсәтеп.)
Алтын белән йөгертелгән бу юханы
Кичекмәстән шушы урында кулга алдырам.
Гаепләре — хөкүмәткә хыянәт итү.
Ә менә сезнең иргә чыгу омтылышына
Каршы төшәм, балдызкаем, ник дисәгез —
Эдмунд белән минем хатын ярәшелгән.
Ул буш түгел. Мин исә буш. Мин — ирекле.
Менә мине яучылагыз.

Гонерилья

Шамакайлык.

Олбани

Син, Глостер, баштанаяк кораллангән.
Әгәр хәзер бырғы тавышы яңғырауга,
Синең сатлык хыянәтче булуыңны
Исбатларга җыенучы күренмәсә,
Менә сиңа минем чакыру.
(Перчаткасын ташлый.)
Һәм ант итәм:
Синең шакшы йөрәгеңне күкрәгеңнән
Кылычым белән әйләндереп чыгармыйча,
Икмәк йөзен күрү миңа хәрам булсын.

Регана

Хәлем китә. Миңа авыр.

Гонерилья
(читкә)

Шулай булмый.
Мин үземнең агуыма ышанамын.

Эдмунд

Чакыруыгызны кабул итәм.
(Перчаткасын ташлый.)
Менә җавап.
Мине биредә хыянәттә гаепләүче
Кем булса да, ул оятсыз һәм ялганчы,
Кычкырт бырғың! Сугышырга әзермен мин.
Йә, кем чыга, синме, улмы? Кем чыкса да,
Намусымны аяк терәп яклыйм хәзер.

Олбани

Әй, Сөрәнче!

Сөрәнче керә.

Эдмунд

Әй, Сөрәнчем, бирегә кил!

Олбани

Сөрәнчең дә, гаскәрең дә булганы юк.
Гаскәреңне мин җыйдым һәм мин тараттым.

Регана

Хәлем һаман авырая.

Олбани

Ул авырый.
Озатыгыз әнә минем чатырга аны.

Регананы алып китәләр.

Җиткерегез, бырлычылар кычкыртсыннар.
Әй, Сөрәнче, бирегә кил. Менә хәзер
Бырлы тавышы ишетүгә, шуны укы.

Бырлы тавышы.

Сөрәнче *(укый).* «Әгәр дә затлы нәселле яугирләрдән кем дә булса үзен граф Глостер дип йөргән Эдмундның хыянәтче һәм сатлыкҗан булуын исбатларга теләсә, өченче бырлы тавышына килеп җитсен. Эдмунд аны каршыларга әзер».

Эдмунд
Кычкырт!

Беренче бырлы тавышы.

Сөрәнче

Тагын!

Икенче бырлы тавышы.

Сөрәнче

Һәм соңгы кат!

Өченче тапкыр бырлы кычкыртыла. Сәхнә артыннан да җавап итеп бырлы тавышы ишетелә.
Баштанаяк коралланган Эдгар белән Бырлычысы керәләр.

Олбани

Сора, кем ул?

Сөрәнче

Әй, рыцарь, кем буласыз?
Исемегез, дәрәҗәгез, затыгыз кем?
Һәм ни өчен чакыруга килдегез сез?

Эдгар

Элеккеге исемемне югалттым мин,
Хаинлекнең кабан теше кимерде аны.
Нахак яла кайрагында кайралып ул
Тәмам бетте, юкка чыкты. Затым белән
Мин алышка чакыра торган дошманымнан
Бер мыскал да ким түгелмен.

Олбани
(Эдгарга)

Ә кем соң ул?

Эдгар

Үзен граф Глостер дип исәпләүче
Эдмунд кайда? Кайда аның Сөрәнчесе?

Эдмунд

Граф Эдмунд Глостер биредә. Ни әйтерсең?

Эдгар

Чыгар кылычың, гаепләүләр нахак булса,

Хаклыгыңны кылычың белән исбатларсың.

Кылычын чыгара.

Намусыма һәм антыма тугры калып,
Кылычымны чыгардым мин кынысыннан.
Син яшь, көчле, язмыш сине күккә чөйде,
Батырлык та күрсәттең син һәм җиңдең дә,
Тик шуңа да карамастан хыянәтче син.
Аллаларга, үз атаңа, туганыңа,
Инде килеп герцогка да хыянәт иттең.
Баш түбәңнән үкчәңәчә син хаинлек
Агуына манчылгансың, кара елан.
Инкарь генә итеп кара — шушы кылыч
Ялганыңны исбатларга әзер тора.

Эдмунд

Миңа алышның тәртипләрен саклау өчен
Исемеңне сорап белү тиеш иде.
Ярый, калсын. Кыяфәтең, сөйләшүең
Затлы кеше чалымнарын хәтерләтә.
Шуңа күрә бөтен саклык чарасына
Мин җирәнеп кул селтим дә, шул мизгелдүк,
Миңа аткан ул пычрак гаепләүне
Кире үзеңнең йөзеңә атам. Ялганыңны
Кылычым белән йөрәгеңә куып кертеп,
Мәңгелеккә шунда биклим. Кычкырт быргың!

Быргы тавышы. Сугышалар. Эдмунд егыла.

Олбани
(Эдгарга)

Юк! Үтермә!

Гонерилья

Син тозакка каптың, Глостер!
Чөнки, алыш тәртибенчә, син билгесез
Яугир белән сугышырга тиеш түгел,
Җиңелмәдең, сине бары алдадылар.

Олбани

Зинһар өчен, авызыгызны ябыгызчы.
Юкса шушы кәгазь белән томалыймын.
Үтерергә ашыкма аны. *(Гонерильяга.)* Син, хәшәрәт,
Мәле, укы үз хатыңны. Ә, юк инде,
Ерталмассың. Кем кулы бу, таныйсыңмы?

Гонерилья

Танысам ни? Шуннан нәрсә? Бу минем җир.
Монда синең хөкемең йөрми.

Олбани

Оятсыз син!

Бераз гына танарга да теләмисең.

Гонерилья

Минем нәрсә теләвемдә ни эшең бар?
(Китә.)

Олбани

Озатыгыз. Ул үз-үзен белештерми,
Бәлки, көч тә кулланырга туры килер.

Офицер китә.

Эдмунд

Мин нәрсәдә гаепләнсәм, барын кылдым.
Ул гына да түгел әле. Гамәлләрем
Еллар үткән саен һаман ачыла барыр.
Минем өчен дөнья бетте, мин дә сүнәм.
Мине җиңгән яугир, әйт, син кем буласың?
Затың асыл булса, сине гафу итәм.

Эдгар

Риясыз соравыңа ачык җавап:
Затым белән синнән һич тә түбән түгел,
Өстен икән, димәк, гаебең арта гына.
Эдгар — мин. Без бер ата балалары.
Үзебез кылган гөнаһларның җимеше белән
Үзебезне җәзалаучы күкләр хаклы —
Караңгыда кача-поса гөнаһ кылып
Сиңа гомер биргән әти сукырайды.

Эдмунд

Әйе, әйе, син хаклысың, мине дә бит
Язмышымның тәгәрмәче сытып китте.

Олбани
(Эдгарга)

Мин асыл зат икәнеңне шундук белдем,
Атлавыңнан күренеп тора. Кил, бер кочыйм.
Әгәр дә мин кайчан булса әтиеңә
Яки сиңа бер начарлык кылган булсам,
Бәхет миннән йөз чөерсен.

Эдгар

Беләм, герцог.

Олбани

Йә, кайларда качып йөрдең? Ниләр күрдең?
Әтиеңнең фаҗигасен каян белдең?

Эдгар

Уртаклашып. Аңа ярдәм итә-итә.
Минем эзгә баса-баса куып килгән
Канлы үлем карарыннан котылу өчен

Мин качарга мәҗбүр булдым. Ah, бу тормыш,
Шулкадәр дә татлы бит ул, юккамыни,
Кинәт кенә үлеп китү рәхәтеннән
Ваз кичәбез һәм сайлыйбыз үзебез теләп,
Озак итеп, газапланып үлүне без!
Кыскасы шул: ач үлемнән котылу өчен,
Иң әшәке йолкыш эт тә җирәнерлек,
Бер дивана хәерчегә әверелдем.
Һәм соранып йөри торгач, көтмәгәндә
Юлда әтигә тап булдым мин. Тик ни күрәм?..
Кайда аның энҗеләргә тиң күзләре?
Күз урынына кашы төшкән йөзекләр күк
Ике канлы чокыр гына утырып калган!
Шул көннән соң аның белән җитәкләшеп
Хәер эстәп йөрдек без. Һәм ничә кат
Өметсезлек тырнагыннан йолып калдым.
Инде менә ярты сәгать элек кенә
(Нигә сузып йөргәнмендер), мин, ниһаять,
Яу алдыннан кемлегемне ачтым аңа.
Бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем һәм ул шунда
Фатихасын бирде миңа. Тик йөрәге
Кайгы белән шатлык кинәт алышынудан
Бу хәбәрне күтәралмый туктап калды.
Һәм елмаеп җан бирде ул.

Эдмунд

Сүзләреңнән
Тәэсирләндем. Хәерлегә булсын берүк.
Син бит әле бетермәдең. Йә, дәвам ит.

Олбани

Алга таба кайгы һаман арта барса,
Сөйләмәвең хәерлерәк. Болай да авыр.

Эдгар

Моннан да авыр кайгы булмас тоелса да,
Әле кайгы бетми аның белән генә.
Хәсрәтемнән үксеп елап торган чакта,
Ниндидер бер кеше килде минем янга.
Элегрәк очрашсак та, ул һәрвакыт
Мин сукбайны күрмәмешкә салына иде.
Инде хәзер кемлегемне белеп алгач,
Кочагына алып кысты, ә аннары,
Күк күкрәгән тавыш белән акрып елап,
Ул әткәйнең гәүдәсенә капланды да
Лир турында һәм үзенең күргәннәрен
Бик кызганыч итеп миңа сөйләп бирде.
Сөйләгәндә күргәннәрен өр-яңадан
Йөрәгеннән кичергәндер, җан кыллары
Берәм-берәм үзелә башлап — аңын җуйды.
Мин, икенче быргы тавышын ишетүгә,
Аны калдырып китеп бардым.

Олбани

Ә кем соң ул?

Эдгар

Кент иде ул. Кыяфәтен үзгәрткән дә,
Һичбер төрле хезмәттән дә тайчанмыйча,
Үзен сөргән Лирга хезмәт итеп йөргән.

Канлы хәнҗәр тотып Сарай йомышчысы керә.

Сарай йомышчысы

Ярдәм! Ярдәм!

Эдгар

Нәрсә булды?

Олбани

Тизрәк сөйлә!

Эдгар

Ник хәнҗәрең канлы синең?

Сарай йомышчысы

Хәнҗәр яна.
Йөрәк каны ялкын булып капты аңа.
Йөрәгеннән тартып алдым. Ah, ул үлде.

Олбани

Әйт, кем үлде?

Сарай йомышчысы

Хатыныгыз, галиҗәнап.
Үзен-үзе чәнчегән ул. Шуннан алда
Сеңелесе үлгән иде, ул аны да
Агу биреп үтергәнен әйтеп үлде.

Эдмунд

Икесе дә алар миңа ярәшелгән,
Өчәүләшеп туй ясарбыз гүрдә бүген.

Эдгар

Әллә инде күземә күренә, Кент килә ич.

Олбани

Тереләрме кыз туганнар, үлеләрме,
Икесен дә хәзер бирегә китерегез.

Сарай йомышчысы чыгып китә.

Алар өчен иңдерелгән күкләр хөкеме
Күңелләргә курку сала, кызгандырмый.

Кент керә.

Граф, бу син? Ah, кызганыч, тиешенчә

Каршыларга мөмкинлек юк, вакыты шундый.

Кент

Хөкемдарым — галиҗәнап корольгә мин
Хәерле төн теләргә дип килгән идем.
Ул биредә түгелмени?

Олбани

Ничек соң без
Иң мөһимен онытканбыз! Эдмунд, тиз әйт:
Кайда король? Корделия?

Гонерилья белән Регананың мәетләрен кертәләр.

Кент
Мин ни күрәм?

Эдмунд

Эдмунд өчен һуштан язган кыз туганнар.
Башта апасы сеңлесенә агу биргән,
Ә аннары үз-үзенә кул салган ул.

Олбани

Әйе, дөрес. Мәетләрнең йөзләренә
Ни дә булса ябыгызчы.

Эдмунд

Тыным кысыла.
Үзем явыз булуга да карамастан,
Бер яхшылык эшләп калыйм кичекмәстән,
Таш кирмәнгә йөгерегез. Әле генә
Мин Лир белән аның кызын үтерергә
Әмер бирдем...

Олбани

Тиз булыгыз! Йөгерегез!

Эдгар

Ә кирмәндә кемгә барып сүз катарга?
Әмереңне үзгәртердәй билгең бармы?

Эдмунд

Син хаклысың. *(Офицерга.)* Кылычымны ал да әнә
Офицерга тапшыр шуны.

Эдгар

Тизрәк, тизрәк!

Офицер китә.

Эдмунд

Хатының белән сүз берләшеп капитанга
Корделияне асарга да, ә аннары,
Кайгысыннан үз-үзенә кул салган, дип,
Ялган хәбәр таратырга әмер бирдек...

Олбани

Коткарыгыз аны, күкләр!
(Хәлдән тайган Эдмундка күрсәтеп.)
Алыгыз моны!

Эдмундны алып китәләр. Корделияне күтәргән Лир, аның артыннан Офицер һәм башкалар керәләр.

Лир

Үкерегез! Үкерегез! Таш бәгырьләр!
Сездә булган кадәр бугаз миндә булса,
Күк гөмбәзе әллә кайчан безнең өскә
Җимерелеп төшәр иде... Ул суламый!
Ул мәңгегә китте бездән! Ашыкмагыз,
Үле белән терене мин аера беләм.
Яле, көзге китерегез, әгәр дә ул
Шул көзгене парландырса тыны белән,
Исән, димәк.

Кент

Әллә күкләр вәгъдә иткән
Ахырзаман җиттеме соң?..

Эдгар

Мәхшәрдер бу...

Олбани

Кырыш-кырылыш...

Лир

Каурый бераз селкенде күк!
Ah, ул исән! Ул терелә! Шулай булса,
Хәсрәтемне җуяр мизгел җитә, димәк...

Кент
Хөкемдарым!

Лир

Үтенеп сорыйм, читкәрәк кит.

Эдгар

Бу бит сезнең турылыклы дустыгыз Кент.

Лир

Барыгыз да хаиннәр сез, үтерүчеләр.
Коткарган да булыр идем, тик ул китте.
Корделия, тукта, китмә! Ни дидең син?
Ә тавышың ягымлы һәм йомшак синең —
Хатын-кызга килә торган сирәк бәхет...
Сине аскан хайванны мин үтердем бит.

Офицер

Ул чыннан да үтерде аны.

Лир

Хак сөйлим бит?

Яшьрәк чакта мин дәһшәтле кылычым белән
Андыйларны биетә идем... Картайдым шул.
Хәсрәт чигеп хәлсезләндем... Сез кем тагын?
Дөресен әйтим, минем күзләр шәптән түгел.

Кент

Язмыш ханым мәхәббәт һәм хәсрәт белән
Бүләкләгән ике адәм булса җирдә,
Шуның берсе сезнең алда.

Лир

Тукта, тукта,
Әллә күземә күренә инде. Сез Кентмы әллә?

Кент

Әйе, мин — Кент. Сезнең хадим. Ә Кай атлы
Хезмәтчегез кайда хәзер?

Лир
Ни дип әйтим,
Алышларда курку белмәс, җитез куллы
Бик тә гаярь яугир иде. Гүрдә чери.

Кент

Юк, хөкемдар, ул Кай дигән хезмәтче дә
Мин булам бит.

Лир

Анысын соңрак ачыкларбыз.

Кент

Бәхет сездән йөзен чөерә башлау белән,
Артыгыздан калмый йөрдем.

Лир
Мин бик шатмын.

Кент

Шатлык качты бу тирәдән, караңгылык,
Сагыш басты күңелләрне, җансыз тынлык.
Дошманлашып сезнең өлкән кызларыгыз
Икесе дә һәлак булды.

Лир
Булуы мөмкин.

Олбани

Ишетми ул. Сүз катуның файдасы юк.

Эдгар

Әйе, әйе, сез хаклысыз.

Чапкын керә.

Чапкын
Эдмунд үлде.
Олбани

Хәзер аның кайгысымы... Лордлар, дуслар!
Безнең карар шуннан гыйбарәт: бу үзара
Низагларга чик куелыр тиз арада.
Иксез-чиксез хәсрәт эчкән олуг затка
Кулдан килгән бар ярдәмне күрсәтеп, без
Ил һәм дәүләт эшләренең дилбегәсен
Кабат аңа тапшырырга ниятлибез.
(Эдгар белән Кентка.)
Сезгә исә элеккеге хокукыгыз
Өр-яңадан кайтарылыр, артыгы белән.
Дусларны мул бүләкләрбез, ә дошманнар
Безнең нәфрәт касәсеннән кайгы татыр...
Ah, карагыз, ни булды аңа? Күрәсезме?

Лир

Минем теге юләремне асканнар бит...
Үлгән. Үлгән. Ник этләргә, күселәргә
Яшәү рөхсәт ителә дә, аңарга — юк?
Сулышыңны өзделәрме? Инде хәзер
Һичберкайчан, һичберкайчан, һичберкайчан
Кайтмаска дип киттең бездән. Үтенәм сездән,
Изүемне чишегезче... Ай рәхмәт.
Иреннәрен карагыз сез, иреннәрен...
Зинһар өчен, күз салыгыз...
(Үлә.)

Эдгар

Галиҗәнап!
Һуштан язды!

Кент

Ah, йөрәгем, ярыл тизрәк!

Эдгар

Галиҗәнап, уяныгыз!

Кент

Юк, кирәкми.
Интектермә аны соңгы сулышында.
Бу дөньяның газабында янар өчен
Тоткарлама аның җанын.

Эдгар

Ул җан бирде.

Кент

Җан бирүе гаҗәп түгел, шул көнгәчә
Җан бирмәве гаҗәп аның. Бу — могҗиза.

Олбани

Мәрхүмнәрнең мәетләрен алыгыз моннан.
Матәм көне булыр бу көн — гомум матәм.

(Кент белән Эдгарга.)
Әй, дусларым, бар ышаныч сездә генә,
Ил хәсрәтен күтәрикче бергә-бергә.

Кент

Кичерегез, галиҗәнап, иске хуҗам —
Король мине үзенә дәшә. Юлга чыгам.

Эдгар

Язмыш безне салды бүген зур кайгыга,
Сүз сөйләрдән алда елый һәркайсыбыз.
Йөрәктәге әрнүләрне әйталсак та,
Әйтелергә тиеш сүзне әйталмыйбыз.

Матәм маршы астында әкрен генә чыгып китәләр.

Антоний

һәм

Клеопатра

Трагедия

Биш пәрдәдә

Илдус Әхмәтҗанов
тәрҗемәсе

КАТНАШАЛАР:

Марк Антоний
Октавий Цезарь
Марк Эмилий Лепид
Секст Помпей.
Домиций Энобарб
Вентидий
Эрос
Скар
Дерцет
Деметрий
Филон
Меценат
Агриппа
Долабелла
Прокулей
Тирей
Галл
Менас
Менекрат

Варрий
Тавр — Цезарьның гаскәр башлыгы.
Канидий — Антонийның гаскәр башлыгы.
Силий — Вентидий гаскәрендә хәрби начальник.
Евфроний — Антонийдан Цезарьга җибәрелгән илче.
Алексас
Мардиан
Селевк
Диомед
Багучы.
Авыл кешесе.
Клеопатра — Мисыр патшабикәсе.
Октавия — Цезарьның кыз туганы, Антонийның хатыны.
Хармиана
Ирада

Хәрби начальниклар, сугышчылар, чапкыннар, хезмәтчеләр һәм сарай хадимнәре.

Вакыйга Рим империясенең төрле өлкәләрендә бара.

Беренче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Клеопатра сараеның бер бүлмәсе. Деметрий белән Филон керәләр.

Филон

Юк, командан акылыннан язган тәмам.
Элегрәк ул, дәһшәтле Марс сыман,
Гаскәренә ташлый иде утлы караш,
Инде хәзер, күрче, ничек ул мөкиббән
Чегән арбасыннан төшкән шул чәчбигә,
Курку белмәс йөрәгенең тибешеннән
Сугышларда өзелә иде көбә бавы,
Шул йөрәк тә һич карусыз әйләнгән бит
Фахишәнең кызуын басар җилпәзәгә.

Бырғы тавышлары. Антоний, Клеопатра, сарай хадимнәре керәләр.
Хәрам агалары Клеопатраны җилпәзәләр белән җилләтеп баралар.

Әнә кара, үзләре дә монда килә,
Кара, кара, дөньяның өч терәге булса,
Шуның берсе синең алда: фахишәгә
Үзе теләп шамакайлык кыла әнә.
Карап соклан һәм гыйбрәт ал!

Клеопатра

Бу мәхәббәт икән әгәр, әйт хәзер үк,
Мәхәббәтнең зурысымы, әллә юкмы?

Антоний

Үлчәүләргә сыйса хисең, мәхәббәт — чүп.

Клеопатра

Мин үземнең әсир итү кодрәтемнең
Көчен генә сиңнән сорап белмәкче идем.

Антоний

Бик беләсең килсә әгәр, миннән түгел,
Чиксезлектән сора аны син, кадерлем.

Антонийның Хезмәтчесе керә.

Хезмәтче

Хөкемдарым, Римнан яңа хәбәрләр бар.

Антоний

Эчпошыргыч сүзләр... сөйлә, тик кыска тот.

Клеопатра

Юк, Антоний, син җентекләп сораш аннан.
Фульвиянең, бәлки, күңелен кыргансыңдыр?
Яшь Цезарьдан, бәлки, ашыгыч боерык бардыр:
«Тегесен башкар, монысын үтә, бу патшаны
Төшереп, тизрәк яңасын куй, үтәмәсәң,
Эшең начар». — һәм башкалар, һәм башкалар.

Антоний

Ни сөйлисең син, сөеклем?!

Клеопатра

Бәлки, сиңа
Бүгеннән соң монда калу тыеладыр.
Бәлки, инде властьтан да мәхрүмсеңдер.
Ә ник, бәлки? Йә, тизрәк сораш инде:
Хатының сиңа ни боера... Юк, юк, Цезарь...
Иң дөресе — икесе дә димәкче идем.
Чакырт тизрәк чапкыннарны! Ник кызардың?
Бу Цезарьдан шүрләвеңме, йә булмаса
Фульвиягә исәп-хисап тотар көнең
Исеңә төшеп куркуыңнан оялумы?
Чапкыннарны бирегә дәшегез!

Антоний

Империя тәмам җимерелсен.
Рим — Тибр дулкынында чересен.
Бүгеннән соң өем шушы минем.
Патшалык — чүп, пыран-заран килә,
Ә җир — шакшы тирес өеме;
Адәмне дә, ерткыч хайванны да
Икесен дә тигез сугара.
Яшәү бөеклеге — мәхәббәттә!

Клеопатраны кочагына ала.

Безнең мәхәббәткә тиңнәр юк.
Моны бүген бөтен дөньяга мин
Каным белән исбат итә алам.

Клеопатра

Ялган, ялган! Мәхәббәткә мәдхияләр
Яудырсаң да, ни өчендер, син, Антоний,
Фульвиягә өйләнгәнсең, яратмыйча...
Кемлегеңне аңларлык мин, ахмак түгел,

Үзең булып каласың син һәрвакытта.

Антоний

Һәм һәрвакыт Клеопатраның колы булып.
Инде үтенәм: татлы сөю минутларын
Бар нәрсәдән артык күреп сөйгән өчен,
Буш бәхәскә артык вакыт әрәм итмик —
Һәр мизгеле чиксез ләззәт бүләк итсен.
Бүген нинди хозурлыклар көтә безне?

Клеопатра

Чапкыннарны тыңлыйк әйдә.

Антоний
Ah, үзсүзле!
Көлүе дә, елавы да, нәфрәте дә,
Килешеп тора бит үзенә һәммәсе дә.
Капылт кына кабынып китсә — ни гүзәллек!
Чапкыннарны, синнән булса, кабул итәм,
Башкалары күземә дә күренмәсен.
Мин — синеке, тик синеке. Әйдә, иркәм,
Бүген кичен урамнарга чыгыйк икәү,
Халык нишли — күзәтербез, кичә генә
Үзең шуны теләдең ич, патшабикә!
Инде әйдә, рәхим ит! *(Хезмәтчегә.)* Ычкын! Дәшмә!

Антоний һәм Клеопатра сарай хадимнәрен иярtеп чыгып китәләр.

Деметрий

Күрәсеңме, Цезарьны да санга сукмый!

Филон

Вакыт-вакыт ул бөтенләй алмашына,
Танырлык та булмый башлый Антонийны.

Деметрий

Бик кызганыч! Римгача барып җиткән
Имеш-мимеш хак булуын үзе раслый.
Тик ышанам, иртәгә ул үзгәрәчәк.
Хәзергә хуш.
Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук икенче бүлмә. Хармиана, Ирада, Алексас һәм Багучы керәләр.

Хармиана. Затлылардан-затлы Алексас, татлылардан-татлы Алексас, иң, иң, иң, иң... Алексас, тагын әллә нинди, әллә нинди Алексас! Патшабикәгә мактаган теге Багучы кайда соң? Минем мәрхәмәтем аркасында куелачак мөгезен чәчәк такыя белән каплап йөрергә тиешле булачак ирем турында ни дә булса беләсем килә! Зинһар, тилмертмә!
Алексас. Әй, Багучы!
Багучы
Ни боерасың?
Әллә шушы?
Хармиана. Син барын да беләсең ди, шул дөресме?

Багучы

Табигатьнең бөек серләр китабыннан
Кайчагында аны-моны укый алам.

Алексас

Уч төбеңне күрсәт аңа, күз салсын бер.

Энобарб һәм хезмәтчеләр керәләр.

Энобарб

(хезмәтчеләргә)

Тиз булыгыз! Бокалларга шәраб коегыз.
Клеопатра хөрмәтенә эчәчәкбез.
Хармиана. Мәрхәмәтлем, сихерең белән бәхетле ит.
Багучы. Сихерләмим, мин бары тик багам гына.
Хармиана. Әйдә алайса, багып кара.

Багучы

Киләчәктә
Матурлыгың артыр синең чик-чамасыз.
Хармиана. Аркылыгамы?
Ирада. Юк, картайгач чамадан тыш бизәнерсең, ди ул.
Хармиана. Җыерчыклар гына берүк бизәмәсен.
Алексас. Багучы галиҗәнапларының ачуын китермәгез. Ихтирамлы булыгыз.
Хармиана. Тс-с!

Багучы

Сөелүгә караганда,
Күбрәк үзең сөярсең син.
Хармиана. Шул гына җитмәгән иде! Бавырымны мәхәббәт утында көйдергәнче, шәраб белән көйдерәм, ичмасам.
Алексас. Бүлдермә әле! Тыңлап бетер башта.
Хармиана. Искитмәле берәр нәрсә юра миңа. Әйдә, көннәрнең берендә берьюлы өч патшага кияүгә чыгыйм да шундук тол калыйм яки илле яшемдә Яһүди Иродының да котын алырлык ямьсез бала табыйм. Йә булмаса Октавий Цезарьга кияүгә чыгыйм! Ул чагында патшабикә белән дәрәҗәбез тигез булыр иде.
Багучы. Патшабикәңнән син гомерлерәк.

Хармиана

Искиткеч шәп! Озын гомерне мин
Инҗир җимешеннән дә артыграк күрәм.

Багучы

Өлешеңә тигән бәхетеңне
Сарыф итеп бетергәнсең инде күптән.
Хармиана. Ул чагында затлы токым калдыру миңа насыйп булмас. Бәхетсездән тик хәерче генә туа. Бер уңайдан әйтеп бирче: ничә улым, ничә кызым булыр икән?

Багучы

Теләгән саен күңелеңне күрүче булса,
Күптән инде миллион балаң булыр иде.
Хармиана. Югал күз алдымнан, тинтәк! Сихерче булганың өчен генә кичерәм, югыйсә...
Алексас. Ә син үзеңнең оятсыз теләкләреңне түшәк җәймәңнән башка берәү дә белми дип уйладыңмыни?
Хармиана. Тукта! Инде хәзер Ираданың язмышын әйт.

Алексас

Киләчәктә безне ни көткәнен

Һәммәбезнең беләсебез килә.
Энобарб. Киләчәген белмим, бүген ни көткәнен мин әйтә алам: күбенгәнче эчеп, ләх булганчы исерәчәкбез.
Ирада. Менә бу учның сызыкларына карап, аның иясе гыйффәтле, саф дип юрарга гына кала.
Хармиана. Әгәр дә Нил ярларыннан ташып чыкса... Корылык була дип юраган сыман.
Ирада. Яп авызыңны, азгын! Син багучы түгел ләбаса.
Хармиана. Әгәр дә дымлы уч төбе үрчемлелек билгесе түгел икән, ул чагында минем турыда: «Колак артын табаны белән кашый», — дип сөйләп йөри аласың. Кара әле, гади генә берәр нәрсә юра әле үзенә.
Багучы. Икегезне дә бер үк язмыш көтә.
Ирада. Нинди язмыш? Ачыграк сөйлә.
Багучы. Мин барын да әйттем.
Ирада. Ничек инде, чәч бөртеге хәтле генә булса да мин аннан бәхетлерәк түгелмени соң?
Хармиана. Әгәр чәч бөртеге хәтле генә бәхетлерәк булсаң, ул йонның кайда үсүен теләр идең?
Ирада. Теләсә кайда, тик иремнең борын тишегендә генә үсмәсен.
Хармиана. Күкләр безне гөнаһлы уйларыбыздан арындырсын. Ә хәзер Алексаска, — әйе, әйе, аның язмышын, аның язмышын әйт! Изге Изида! Мәрхәмәтең салып, зинһар, шуны сыңар аяклы хатынга өйләндер. Ул хатыны үлеп, тиз арада аннан да яманрагына килеп капсын. Гомере буе бер әшәке хатыннан икенчесенә калып изалансын. Иң ахырда иң хәшәрәте, илле тапкыр мөгезле иткәч, бии-бии кабергә озатсын иде үзен. Мәрхәмәтле Изида, ишет минем догаларымны! Башкаларын кабул итмәсәң итмәссең, зинһар, монысын гына кабул итә күр. Мәрхәмәтле Изида, үтенеп сорыйм синнән.
Ирада. Амин. Изге илаһия, безнең үтенечләребезгә колак сал. Намуслы, яхшы ирнең азгын хатынга өйләнүен күрү нинди аяныч хәл, ә әшәке намуссыз ирнең әлегәчә мөгезсез йөрүе тагын да аянычрак. Шуңа күрә, мәрхәмәтле Изида, гаделлек өчен генә булса да, тиз арада шуңа үзенә тиешле язмышын җибәрә күр.
Хармиана. Амин.
Алексас. Юк, сез тыңлап кына карагыз! Әгәр дә миңа мөгез кую болардан торса, моңа ирешү өчен, урамга чыгып үзләрен узган-барганга тәкъдим итеп торудан да тартынмаслар.
Энобарб. Тс-с! Әй, сез, акрын — Антоний.
Хармиана. Юк — патшабикә.

Клеопатра керә.

Клеопатра

Антонийны күрдеңме син?

Энобарб

Юк, күрмәдем, патшабикәм.

Клеопатра

Ул биредә булмадымы?

Хармиана

Юк, булмады, патшабикәм.

Клеопатра

Кәефе шундый әйбәт иде, кинәт кенә
Рим исенә төште никтер. Энобарб!

Энобарб

Тыңлыйм сине, патшабикәм.

Клеопатра

Эзләп тап та
Монда чакырып китер үзен.
Алексас кайда?

Алексас

Мин биредә, мәрхәмәтле патшабикә.
Антоний да килә әнә минем арттан.

Антоний, Чапкын һәм Сарай хадимнәре күренәләр.

Клеопатра

Әйләнеп тә карамыймын. Киттек моннан.

Клеопатра, Энобарб, Алексас, Ирада, Хармиана, Багучы һәм хезмәтчеләр чыгып китәләр.

Чапкын

Сугыш башлап җибәрүче хатының булды.

Антоний

Һәм абыем аңа каршы сугыштымы?

Чапкын

Әйе. Ләкин тиздән алар килештеләр,
Уртак дошман — Цезарь чыкты алларына
Һәм, беренче бәрелештә үк тар-мар килгәч,
Икесе дә Италиядән чыгып качты.

Антоний

Тагын нинди хәбәрең бар?

Чапкын

Чапкын өчен
Яман хәбәр — бәхетсезлек чыганагы.

Антоний

Хәбәреңне кабул иткән ахмак булса.
Үткән эшләр кире кайтмый, дөресен сөйлә.
Минем өчен хәтта үлем хәбәре дә,
Дөрес булса, мең ялганнан кадерлерәк.

Чапкын

Чынлап та зур күңелсезлек, яман хәбәр —
Бик зур гаскәр туплап Лабиен парфяннардан
Евфрат аша Азиягә бәреп кергән.
Аның җиңү байраклары җилфердиләр
Сүриядән Лидиягә кадәр.
Шундый чакта...

Антоний

Әйт, әйт, нәрсә телең йоттың?
Шундый чакта син, Антоний...

Чапкын

Хөкемдарым!

Антоний

Боргаланма, йөземә бәреп турысын әйт.

Клеопатраны Римда кем дип атасалар,
Шулай ата. Әрлә мине, һич тартынма.
Фульвиядән усалрак итеп әрлә.
Дөреслек һәм нәфрәт кебек кырыс бул син.
Дәшми калу — чүп үләне үстерү кырда,
Ә шелтәләү — кырны чүптән арындыру.
Ярый, бар, кит.

Чапкын

Теләгеңә буйсынамын.
(Китә.)

Антоний

Сикионнан килгән Чапкын ниләр сөйли?

Беренче хезмәтче

Әй, кайсыгыз Сикионнан? Кайда Чапкын?

Икенче хезмәтче

Ул биредә, боерык көтә.

Антоний
Чакырыгыз.
Әлегә мин акылымда һәм шуңа да
Соңга калмас борын тизрәк ычкынырга.
Ычкынырга кирәк мисыр богавыннан.

Икенче чапкын керә.

Нинди хәбәр белән килдең, әйдә сөйлә!

Икенче чапкын

Хөкемдарым, хатының Фульвия вафат булды.

Антоний

Фульвия вафат? Ничек? Кайда?

Икенче чапкын

Сикионда. Шушы хаттан авыруы хакында да,
Башка хәлләр турында да укырсың син.
(Хат тапшыра.)

Антоний
Бар, чык.

Икенче чапкын китә.

Җирдән тагын бөек бер җан китте.
Тормышка ашты теләк. Әйе, без күп вакыт
Нәфрәт белән читкә ташлаганны кабат
Кайтарырга телибез дә, тик соң була.
Бүген безгә чиксез ләззәт биргән затлар
Кинәт чиксез нәфрәт белән чолганыла.
О, кабергә тыккан куллар аны кабат
Каберннән кире тартып ала алса!..
Үлгәннән соң ул яңадан якын миңа...
Тизрәк шушы сихерчедән котылыйм, юкса
Гамьсезлегем монысыннан йөз кат куркыныч

Мең бәлагә юлыктырыр бу башымны.
Әй, Энобарб!

Энобарб керә.

Энобарб. Ни боерасың, хөкемдарым?
Антоний. Биредән тизрәк ычкынырга кирәк миңа.
Энобарб. Без моның белән биредәге хатыннарны үлемгә дучар итәчәкбез. Кырыслык алар өчен үлемгә бәрабәр. Әгәр дә без китсәк, берсе дә калмый үлеп бетәчәкләр.
Антоний. Мин китәргә тиеш.
Энобарб. Ул чагында башка эш. Китәргә кирәк булгач, әйдә, дөмексеннәр. Аларны сәбәпсез үтерү генә кызганыч, әгәр дә алда мөһим эшләр тора икән — потлары бер тиен. Клеопатра, китү хакында авыз ачуга ук, беренче булып егылып үләчәк. Ул минем күз алдымда бер егерме тапкыр үлгәндер инде. Сәбәбе дә моңа караганда ташка үлчим. Күрәсең, үлем рәхәт нәрсәдер, югыйсә ул аның кочагына керергә шулай атлыгып тормас иде.
Антоний. Хәйлә белән тулган аның эче-тышы.
Энобарб. Ә, юк, хөкемдарым. Аның эче дә, тышы да чат мәхәббәттән генә тора, башка берни кушылмаган аңа. Аның турында: «Елый, йә булмаса көрсенүдән авыр сулый», — дип әйтергә ярыймы соң?! Һич ярамый! Күз яшьләрен — яңгыр, көрсенүен давыл дию генә дә аз аның. Чөнки бер генә календарьда да әлегә кадәр мондый ташкын, җил-давыллар булуы хакында мәгълүмат юк. Аның өянәкләре хәйлә түгел. Хәйлә генә булса, Клеопатра җил-давыллар белән Юпитердан ким идарә итми.
Антоний. Нигә генә күрде икән шуны күзем!
Энобарб. Ничек инде шулай дияргә мөмкин? Әгәр дә син аны очратмаган булсаң, дөньяның бер могҗизасын күрми калыр идең. Ул чагында дөнья гизеп йөрүләрең мәгънәсез бер буш сәяхәт булыр иде.
Антоний. Фульвия үлгән.
Энобарб. Нәрсә?
Антоний. Фульвия үлгән.
Энобарб. Фульвия?
Антоний. Әйе. Үлгән.
Энобарб. Алай булса, моның өчен аллаларга рәхмәт әйтеп, корбан чалырга кирәк. Әгәр галиҗәнап аллалар ир хатынын үзләренә алырга карар кылалар икән, ул чагында ир кешегә иске сәләмәләр урынына өр-яңа кием тегеп кидерер тегүче табылыр әле дигән уй белән үз-үзен юатырга гына кала. Әгәр дөньяда Фульвиядән башка хатыннар булмаса, аның үлеме синең өчен коточкыч зур кайгы булыр иде. Ә бу очракта сиңа кайгырырга сәбәп юк. Иске күлмәк тузган икән, аннан яңа итәк чыга. Ышан миңа, хөкемдарым, мондый хәсрәт өчен бары суган тураганда гына елап була.
Антоний. Римдагы Фульвия чуалткан ул төенне мин чишәргә тиеш.
Энобарб. Ә мондагы төенең нишләр? Син Римда төен чишеп йөргәндә, Клеопатра аны тәмам чуалтмасмы?

Антоний

Туктат тизрәк мәзәкләрең, мине тыңла:
Барлык гаскәр башларына боерык тапшыр.
Патшабикә белән хәзер хушлашырга
Кирәк миңа кичекмәстән һәм берьюлы
Болай ашыгыч китүемнең сәбәбен дә
Аңлатырмын шунда аңа.
Фульвия үлеме
Өйгә дәшкән сәбәпләрнең берсе генә.
Римнан миңа ышанычлы дуслар яза:
Цезарьга каршы баш күтәргән Секст Помпей
Диңгездә бик дәһшәтле зур көчкә әйләнгән.

Безнең халык тере кешенең кадерен белми,
Үлгәч кенә исенә төшә, шуңа бүген
Әтисенә тиешле бурычын улына түли.
Батырлыгы белән түгел, затлы нәселе
Һәм гаскәре белән көчле Секст Помпей,
Бар халыкның тәмам башын әйләндереп,
Каһарманга әверелгән бүген анда.
Дәүләт өчен куркыныч бу, күз алдында
Ат кылыннан акрын гына елан ярала.
Кичекмәстән юлга. Гаскәр башларына,
Хадимнәргә хәзер үк җиткер бу турыда.

Энобарб
Җиткерермен.
Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук, тик башка бүлмә.
Клеопатра, Хармиана, Ирада һәм Алексас керәләр.

Клеопатра. Кайда Антоний?
Хармиана. Шуннан бирле күргәнем юк.

Клеопатра
(Алексаска)

Хәзер үк бел, кайда, нишли һәм кем белән.
Тик онытма — бу йомышны мин кушмадым.
Моңсу булса, мине җырлый, бии, диген.
Ә шат булса, авырый, диген, күз дә йомма.
Бер аягың анда булсын, берсе — монда.

Алексас китә.

Хармиана

Патшабикә, әгәр дә аны чынлап сөйсәң,
Ул да сине чын күңелдән сөйсен дисәң,
Йөрәгендә сөю уты кабызыр өчен,
Миңа калса, син дөрес юл сайламадың.

Клеопатра

Ә синеңчә мин нишләргә тиеш инде?

Хармиана

Иреген кысма, ни теләсә, шуны эшләсен.

Клеопатра

Ни сөйлисең, бу бит аны тәмам жую.
Ахмактыр син.

Хармиана

Түземе бетәр, котыртма аны.
Күңелебезгә курку салган кешене без
Чын күңелдән сөя алмыйбыз, шуны онытма.
Әнә Антоний үзе керә.

Антоний керә.

Клеопатра. Ah, мин үләм.
Антоний *(читкә)*. Җөрьәт итеп ничек кенә сүз башларга?

Клеопатра
(Хармианага)

Хармиана! Мин егылам.
Бир кулыңны.
Күпме түзеп торырга мөмкин бу газапка.
Һәрнәрсәнең чиге була.

Антоний
Клеопатра!..

Клеопатра

Үтенәм синнән, якын килмә!

Антоний

Нәрсә булды?

Клеопатра

Әйбәт хәбәр китергәнең күзләреңнән
Күренеп тора. Йә, хатының ниләр яза?
Юкка гына җибәргән ул сине монда.
Өеңә кайт, мин сине һич тоткарламыйм,
Теләсәм дә булдыралмыйм, син — аныкы.

Антоний
Күкләр шаһит...

Клеопатра

Җирдә патшабикәләрнең
Берәвен дә бу кадәрле оятсызларча
Алдаучылар булмагандыр. Хыянәтеңне
Алдан күреп, белеп тордым.

Антоний
Клеопатра...
Клеопатра

Юк, эзләмә юатырга матур сүзләр,
Хушлаш та кит һәм вәссәлам. Элегрәк,
Монда калыр өчен рөхсәт сораганда,
Матур сүзләр күп сөйләдең. Минем күзләр,
Иреннәрдә мәңгелекнең үзен күрдең.
Кашларымның кыйгачлыгы — җан рәхәте,
Баштанаяк мин илаһи бер зат идем.
Мин хәзер дә нәкъ шундый ук, ә менә син
Бу дөньяның иң бөек бер хөкемдары,
Иң бөек бер ялганчыга әйләнгәнсең.

Антоний
О, Клеопатра!

Клеопатра

Әгәр дә мин ир-ат булсам,
Күрер идең ул вакытта мисырлылар
Ничек итеп үз намусын яклаганын.

Антоний

Зинһар, тыңла, патшабикә, мине Римда
Кичектерми торган ашыгыч эшләр көтә.
Шуңа күрә вакытлыча китеп торам,
Ә йөрәгем тулысынча синдә кала.
Италиядә чуалышлар, тәртипсезлек.
Диңгезләрдә котырына Секст Помпей.
Илдә ике хуҗа хәзер. Халык кайный.
Элек читкә кагылучы — көн батыры.
Секст Помпей әтисенең даны белән
Бүген анда каһарманга әверелгән.
Ил авырый, торгынлыктан чыга алмый.
Хөкем сөргән тәртипләрдән ризасызлар
Кискен борылыш ясар өчен власть даулый.
Һәм, ниһаять, минем моннан китүемне
Синең алда аклар, бәлки, Фульвия үлеме.

Клеопатра

Чамадан тыш ышанучан булсам да мин,
Әкиятләргә ышанудан узган инде.
Фульвия үлгән?

Антоний

Әйе, әйе, патшабикәм.
Аның анда нинди шау-шу күтәргәнен
Шушы хатны уку белән төшенерсең.
Синең өчен иң мөһиме: мәрхүмәнең
Кайда, ничек үлгәнлеге ахырдарак.

Клеопатра

Әнә нинди икән синең мәхәббәтең!
Кайда елга булып аккан күз яшьләрең?
Фульвия үлеме күрсәтте инде, мин үлгәч тә
Синең ничек күз яшьләре түгәсеңне.

Антоний

Бәхәсләшмик, тыңла минем сүзләремне.
Син ни дисәң, шул булачак, тыңла, зинһар!
Кояш белән ант итәмен, мин биредән
Сиңа тугры солдат булып бүген китәм,
Илме, яумы, анысы синең карамакта,
Ни боерсаң, шуны үтим мин, хезмәтчең!

Клеопатра
(Хармианга)

Ач тизрәк тәрәзәне, шундый тынчу,
Хәлем начар, юк, кирәкми, узды инде.
Антонийның мәхәббәте сыман, чирем
Бер көчәеп ала да ул тагын сүрелә.

Антоний

Теләсә нинди сынауларны уза алырлык
Мәхәббәтнең көченә ышан, патшабикәм.

Клеопатра

Әйе, Фульвия раслар иде сүзләреңне.

Аның өчен борылып бераз елап ал да,
Минем белән хушлашырсың һәм әйтерсең:
Синең өчен түгәм, диеп, яшьләремне.
Яле, шуны уйнап бир син зур хис белән,
Ялганыңны нәкъ чын сыман итеп күрсәт.

Антоний

Сабырымны җуеп барам, дәшмә, тукта!

Клеопатра

Начар түгел! Ышандыра, тик шулай да
Камиллекнең чиге юк бит, тырышып кара.

Антоний

Шушы кылычым...

Клеопатра

Һәм калканым... Әйбәт, әйбәт.
Хармиана, күр, ничек ул рольгә керә,
Бик табигый, котыра Рим Гераклы.
Искиткеч бу! Нәкъ чын кебек.

Антоний
Хуш алайса!
Клеопатра

Ике генә сүз әйтимче, о, сөеклем.
Аерылырга язган безгә... Юк, юк, түгел!
Бер-беребезне шундый сөйдек... Бу да түгел!
Нәрсә әйтергә теләдем соң? Ah, оныттым.
Миңа хәтерем хыянәт итте Антоний күк.
Онытканга күрә мине, мин дә онытам.

Антоний

Юләрлекнең нинди генә төре булса,
Һәммәсе дә сиңа җыелган дияр идем.
Әгәр дә мин сөюемнән яна-көя
Синеке булу юләрлеген татымасам.

Клеопатра

Җиңел түгел андый юләрлекне йөртү
Клеопатра йөрткән күк йөрәгендә.
Кичерә күр берүк минем кыланышларны,
Мин алардан башлап үзем зыян күрәм.
Сине моннан намусың чакырып ала икән,
Зинһар, минем көйсезлеккә колак салма.
Бар аллалар сиңа гына ярдәм итсен,
Кылычың сиңа җиңү тажы яулап бирсен,
Ә уңышлар юлыңа ак җәймә булсын.

Антоний

Йә, хушлашыйк. Аерылсак та гел бергә без:
Йөрәгемә салып алып китәм сине.
Һәм үзем дә калам синең йөрәгеңдә.
Вакыт җитте. Йә, кузгалыйк. Хуш, сөеклем.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рим.
Цезарь йортының бер бүлмәсе.
Кулына хат тоткан Октавий Цезарь, Лепид һәм хезмәтчеләр керәләр.

Цезарь

Менә кара һәм онытма, Лепид, Цезарь
Үзенең бөек коралдашын кичерә белә.
Нәфрәт йөртмим күңелемдә, холкым шундый.
Искәндәриядән ни язалар, беләсеңме?
Антонийның бар шөгыле — таңга кадәр
Кәеф-сафа кору, эчү, типтерү, ди.
Ир димәсәң, хәтере калыр! Клеопатра
Ни хатын-кыз табигатьле, тик шулай да
Бу өлкәдә аннан күпкә артыграк.
Чапкыннарны көчкә генә кабул иткән,
Безнең хакта сорашып та тормаган ул.
Дөньяның бар бозыклыгын, фахишлеген
Эченә җыйган иң әшәке адәм икән.

Лепид

Ә шулай да кимчелекләре яхшылыгын
Күмеп китәр дәрәҗәдә түгел аның.
Хәтта яхшы сыйфатлары ныграк балкый,
Гөнаһлары караңгырак булган саен.
Кимчелекләрен үзе теләп алмаган ул,
Алар белән бергә туган һәм алардан
Котылырга чара гына табалмаган.

Цезарь

Артыграк шәфкатьле син. Птолемейның
Түшәгендә аунау яки мәзәк өчен
Кемнәргәдер таҗ һәм тәхет бүләк итү,
Коллар белән бер җамаяктан шәраб эчү,
Һәм таңгача җыен әтрәк-әләм белән
Кул сугышы оештырып күңел ачу —
Һич кенә дә гөнаһлы эш булмасын, ди.
Әмма алардан безгә зыян килгән чакта
Аклап булмый Антонийны берничек тә.
Шуклыкларын кичерер дә идең, әгәр,
Буш вакытта шөгыльләнеп алар белән,
Махмырыннан үзе генә газапланса,
Уртак эшкә китермәсә һичбер зыян.
Әмма ул бит илгә куркыныч янаганда,
Ярдәм сорап чакыру суккан барабанга тиң
Иң кадерле минутларны харап итә.
Уен белән мавыгып китеп бурычын оныткан
Малайдан да битәррәк, кичекмәстән
Туктатырга кирәк аны бу хыянәттән.

Чапкын керә.

Лепид

Яңа хәбәр китерделәр булса кирәк.

Чапкын

Әмерең төгәл башкарылды, шанлы Цезарь!
Илнең барлык чикләреннән синең катка
Сәгать саен яңа хәбәр килеп торыр.
Диңгезләрдә Помпей хаким. Синнән куркып
Качучылар хисабына арта көче.
Кимсетелгән Помпей дигән исеме белән
Үз ягына аудара ул бик күпләрне.

Цезарь

Башкасын мин көтмәдем дә. Күптән мәгълүм:
Югарыда утырганны беркем сөйми.
Күтәрелгәнче, халык мине ярата иде,
Бүген әнә сөя түбән мәтәлгәнне.
Диңгездәге су үләне сыман, халык
Агымнарга буйсынып тик яши бирә.
Әле анда, әле монда ага торгач,
Тора-бара мунчалага әверелә.

Чапкын

Янә, Цезарь, исемнәре күптән мәгълүм
Менекарт һәм Менас атлы ике пират,
Диңгезләрне аркылыга-буйга йөзеп,
Һәр тарафта юлбасарлык итә һаман.
Италиягә ничә тапкыр һөҗүм булган.
Яр буенда яшәүчеләр пиратларның
Исемнәрен ишетүгә аңын җуя.
Яшь-җилкенчәк нәфрәтләнә, корал сорый.
Кораб белән диңгезләргә чыгып булмый,
Чыксаң, шундук эләктерәләр. Ул явызлар
Үз көчләре белән түгел, Помпей исемен
Корал итеп күңелләргә шом салалар.

Цезарь

Ташла, Антоний, кәеф-сафа сөрүләрне,
Гирций белән Пансны үтереп син Моденнан
Чигенгәндә эзеңә басып ачлык куды.
Бишектән үк мул тормышка күнексәң дә,
Ул чагында кыенлыкларны кыргыйлар да
Көнләшерлек ныклык белән кичердең син.
Ерткычлар да эчми торган саз шулпасын,
Ат сидеген эчтең хәтта җирәнмичә.
Урмандагы җиләк-җимеш, гөмбәләрнең
Һәр күзеңә күренгәнен ашап бардың.
Ач боландай агачларның кайрыларын
Кимереп чыктың, ә Альпны кичкән чакта
Ашагансың үләксәнең син шундыен,
Күргән кеше шундук егылып үлгән, диләр.
Әнә шулай авырлыкны исән-имин
Кичердең син, җиңеп чыктың батырларча.
Бу сүзләрне әйтү авыр, шулай да әйтәм:

Элек син чын солдат идең.

Лепид
Ай, бичара.

Цезарь

Оятына көч килсен дә кайтсын иде.
Кулга корал алыр вакыт җитте безгә.
Шуңа тизрәк хәрби киңәшмәне җыйыйк,
Сузмыйк, юкса сузу — Помпей файдасына.

Лепид

Кул астымда күпме гаскәр, ничә кораб
Булачагын мин иртәгә ачыклармын.

Цезарь

Очрашканга кадәр мин дә нәкъ шундый ук
Эшләр белән мәшгуль булам, ярый, сау бул.

Лепид

Сау бул. Әгәр чик буеннан яңа хәбәр
Китерсәләр, миңа җиткер.

Цезарь

Шикләнмә дә,
Бу бит минем синең алда изге бурычым.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Клеопатра сараеның залы. Клеопатра, Хармиана, Ирада һәм
Мардиан керәләр.

Клеопатра

Хармиана!

Хармиана

Тыңлыйм сине, патшабикәм.

Клеопатра

О-о!
Мандрагор бир миңа тизрәк.

Хармиана

Нәрсәгә ул?

Клеопатра

Йоклар идем, ичмасам, бер уянмыйча,
Мәрткә китеп Антонием кайткангача.

Хармиана

Чамадан тыш күп уйлыйсың Антонийны.

Клеопатра

Ә уйламау — хыянәткә тиң.

Хармиана

Шулай микән?
Тик мин алай димәс идем, патшабикәм.

Клеопатра

Әй, Мардиан!

Мардиан

Нинди хезмәт күрсәтә алам?
Күңелеңне нәрсә белән күрим икән?

Клеопатра

Җырлый гына күрмә берүк, чәрелдәвек
Алаша миңа нинди хезмәт күрсәтә алсын.
Печтергәннәр, Мардиан, сине, син бәхетле,
Теләкләрең бар да йоклый, әйтче дөресен,
Дәртнең нәрсә икәнлеген беләсеңме?

Мардиан

Әйе, беләм, патшабикә.

Клеопатра

Чынлап тамы?

Мардиан

Бик үк чынлап түгел инде. Мин гамәлдә
Күп нәрсәне эшли алмыйм, әмма дәртнең
Ни икәнен яхшы аңлыйм. Шуңа күрә
Марс белән Венераның кылган эшен
Хыялымда күз алдына китерә алам.

Клеопатра

Хармиана, ничегрәк уйлыйсың син?
Кайда йөри микән хәзер Антонием?
Менә шушы минутта ул нишли икән?
Утыра микән, әллә басып тора микән?
Җәяү генә атлыймы ул, йә булмаса
Атта чабып бара микән? Бәхетле ат!
Үз өстеңдә Антонийның авырлыгын
Тоеп шундый ләззәт ала торгансыңдыр!
Син горурлан. Сиңа атланып Атлант бара.
Кешелекнең кылычы һәм калканы ул.
Җилкәсендә чиксез зур йөк — ярты дөнья.
«Кайда икән минем мисыр еланым», — дип,
Үз-үзенә пышылдыймы икән һаман?
Эссе кояш үбүеннән каралган һәм
Еллар сызган җыерчыклар тулы тәнне
Хәтерләргә мөмкинме соң? Юк, билгеле!
Ә бит мине киң маңгайлы Цезарь күреп:
«Татлы җимеш», — дип атады элегрәк.
Ә карт Помпей ничек итеп минем алда
Күз карашын алалмыйча күзләремнән
Сизми калды үзенә үлем килгәнен дә.

Алексас керә.

Алексас

Мисыр патшабикәсенә бездән сәлам!

Клеопатра

Антонийга син тамчы да охшамаган,
Әмма бергә булгансыз сез, күреп торам.
Чөнки аңа якын булуың сине гүя
Кургашыннан саф алтынга әйләндергән.
Ничек яши минем тиңсез Антонием?

Алексас

Миңа бирер алдыннан ул шушы энҗегә
Соңгы тапкыр иреннәрен тидерде дә
Сүзен әйтте. Ул сүзләрне күңелемдә
Саклап килдем сиңа төгәл җиткерергә.

Клеопатра

Ишетәсем килә, сөйлә, сузма, зинһар.

Алексас

Болай диде: «Мисыр патшабикәсенә
Тугры колы нәни энҗе бүләк итә.
Бүләге бик кечкенә дип аптырамасын,
Алда зуррак бүләкләр дә аны көтә.
Тиздән бик күп патшалыклар, шәфкать сорап,
Ул гүзәлнең аягына егылырлар».
«Син әйт, — диде, — киләчәктә бөтен шәрык
Аның кул астында булыр». — Һәм баш кагып
Кинәт кенә аргамакка сикереп менде,
Ә аргамак каты кешнәп алга ыргылды.
Минем җавап ишетелмәде, күмелеп калды.

Клеопатра

Кәефе нинди иде, шатмы, кайгылымы?

Алексас

Шат та түгел, кайгысын да күрсәтмәде,
Уртача гына, җәйге сүрән көн шикелле.

Клеопатра

Менә кеше! Ишетәсеңме, Хармиана,
Үзен ничек акыллы итеп тота белгән.
Кайгысын ул күрсәтмәгән, моның белән
Юлдашларын саклап калган боегудан.
Шатлыгын да күрсәтмәгән, моның белән
Мисырдагы шатлыгын ул куандырган.
Бер-беренә капма-каршы ике хисне —
Кайгы белән шатлыкны ул бергә кушкан.
Шатлана да, кайгыра да беләсең син,
Бу җәһәттән сиңа тиңнәр юк дөньяда!
Мин җибәргән чапкыннарны очраттыңмы?

Алексас

Әйе, әйе, егермедән артык булыр.
Нигә бик еш җибәрәсең син аларны?

Клеопатра

Аңа хәбәр җибәрмичә калган көнем,
Дөньяның иң каһәрләнгән көне булсын!
Хармиана, кәгазь, каләм китер миңа.
Мең рәхмәт сиңа, Алексас! Хармиана,
Цезарьны мин бу кадәрле сөйдеммени?!

Хармиана

О, гайрәтле, батыр Цезарь!

Клеопатра

Нәрсә дидең?
Соклануың бугазыңа тыгылгыры.
Иң гайрәтле, иң батыр ир ул — Антоний!

Хармиана

Бөек Цезарь!

Клеопатра

Тешләреңне коям хәзер,
Цезарь белән тиңдәше юк бөек ирне
Чагыштырып кына кара тагын бер кат.

Хармиана

Гаеплемен, кичерә күр, мин ялгышып
Синең иске көйгә җырлый башлаганмын.

Клеопатра

Ул чагында тәҗрибәсез, яшь булганмын,
Шуңа шулай җиңел генә алданганмын.
Кәгазь, каләм бир син миңа, киттек әйдә,
Мисыр тәмам бер кешесез калгангача,
Чапкын арты чапкын җибәреп торачакмын.

Китәләр.

Икенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мессина. Помпей йортының бер бүлмәсе. Помпей, Менекрат һәм Менас керәләр.

Помпей

Гадәләтле икән әгәр бу аллалар,

Йә, ни өчен ярдәм кулы сузмый алар?
Безнең эшнең гаделлеген беләләр ич.

Менекрат

Аллаларның ашыкмавын, мәшһүр Помпей,
Йөз чөерү дип уйларга һич ярамый.

Помпей

Без алардан шулай ярдәм көтә-көтә,
Күп вакытта ул ярдәмнең кирәге бетә.

Менекрат

Ахмаклыгыбыз аркасында бик еш кына
Аллалардан үзебезгә зыян сорыйбыз.
Ярый әле күкләр безне ишетмиләр,
Шул сәбәпле һәлакәттән котылабыз.

Помпей

Әйтте диярсез, мин, һичшиксез, җиңәчәкмен!
Халык сөя. Диңгезләр дә минем кулда.
Гаскәрем зур һәм көннән-көн арта бара,
Ә Антоний Мисырда туй ясап ята,
Алыштырмый ул, әлбәттә, туйны сугышка.
Октавий Цезарь, тирә-юньнән акча сыгып,
Берәм-берәм дусларыннан колак кага.
Лепид һаман икесен дә мактый бирә,
Үзенә дә шуның өчен мактау ява.
Тик аларны яратмый ул һәм алар да
Бер тиенгә дә санамыйлар ул мескенне.

Менас

Лепид белән Цезарь, бергә гаскәр туплап,
Зур яу белән киләләр, ди, безнең өскә.

Помпей

Дөрес түгел! Кемнән ишеттең бу хәбәрне?

Менас
Сильвий әйтте.
Помпей

Саташкандыр. Ул төш күргән!
Лепид белән Цезарь хәзер Римда алар,
Алар анда Антонийның кайтуын көтә.
О, Клеопатра, күңелләрне аздыручы
Бар әгъваңны бүген эшкә җик син, әйдә!
Сихерең белән матурлыгың кушылсыннар.
Һәм шуларга оятсызлык өстәп җибәр,
Кызганмыйча сөрхәнтәйнең башын бетер:
Шәраб дөньясында йөзсен, чыга алмасын,
Алдына тез барча Эпикур ашларын,
Кызыктырып ашат-эчерт, фахишлек ит,
Тик намусы гына, зинһар, уянмасын!

Варрий керә.

Нинди хәбәр белән килдең? Сөйлә, Варрий.

Варрий

Тикшерелгән дөрес хәбәр: бүген Антоний
Үз гаскәре белән Римга кайтып җитә.
Ул Мисырдан күптән чыгып киткән булган.

Помпей

Бу хәбәрне ишеткәнче, теләсә нинди
Күңелсезлек җанны биләп алсын иде.
Кем уйлаган исерек гашыйк шушы сугыш
Өчен генә кулына кылыч алыр диеп.
Ә бит сугыш сәнгатенә ул аларның
Икесеннән дә ике тапкыр mahиррак.
Горурланырга мөмкин безгә, баш күтәреп,
Юха елан Клеопатра итәгеннән
Аердык без мәңге туймас фахишне дә.

Менас

Цезарь белән килешә алыр микән соң ул?
Антонийның хатыны белән абзасы бит
Цезарьга каршы сугыштылар, әмма, дөрес,
Ул аларның бу эшләрен хупламады.

Помпей

Алларында хәвеф торган чакта,
Вак-төякне онытырлар. Әгәр дә без
Алар өчен уртак дошман булмаса идек,
Этләр кебек бер-беренә ташланырлар,
Чәйнәшерләр иде, моңа сәбәпләр күп.
Уртак куркыныч күреп ничек берләшерләр,
Алдан әйтеп булмый анысын һәм аларның
Үзара дошман икәненә исәп тотмыйк.
Безнең алда бер генә юл: бар көчебезне
Тик көрәшкә бирәчәкбез, ә аллалар
Язмышыбызны хәл итсеннәр. Киттек, Менас.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рим. Лепид йортының бер бүлмәсе.
Энобарб һәм Лепид керәләр.

Лепид

Әгәр дә син Антонийны бик кызмаска
Үгетли алсаң, бер изге эшең булыр иде.

Энобарб

Ничек телисең, шулай сөйлә, дип әйтермен.
Әгәр Цезарь аның ачуын чыгара икән,
Антоний да югарыдан карап кына
Күк күкрәтеп җавап бирсен, Марс кебек.
Юпитерның үзе белән ант итәмен,
Әгәр бүген мин Антоний урынында булсам,

Сакалымны да хәтта кырып тормас идем.

Лепид

Бер-береңнән үч алыр чак түгел хәзер.

Энобарб

Теләсә кайчан теләсә нинди эш эшләнә.

Лепид

Әмма алда зур-зур эшләр торган чакта,
Кечерәкләре онытылырга тиеш аның.

Энобарб

Кечерәк эш мөһимрәк була кайчак.

Лепид

Сабыррак. Узганнарны искә алма.
Әнә Антоний үзе дә килә.

Антоний белән Вентидий керәләр.

Энобарб
Һәм Цезарь да.

Цезарь, Меценат һәм Агриппа керәләр.

Антоний
(Вентидийга)

Римда эшне җайга салып бетерик тә
Парфяннарга каршы аннан кузгалырбыз.

Цезарь
(Меценатка)

Агриппадан сорап кара, мин әйталмыйм.

Лепид

Бөек максат берләштерә безне, дуслар.
Ул берлекне юк-бар ызгыш таркатмасын.
Бер-берегезгә бәйләнүдән тыелыгыз.
Юк-бар өчен артык кызып бәхәсләшү,
Җәрәхәтне дәвалау түгел — авырттыру.
Шуңа күрә сүзләрегез йомшак булсын,
Авырткан җиргә тоз сипмәгез.

Антоний

Бик дөрес сүз.
(Цезарьны сәламли.)
Дошман булсак та без хәтта, нәкъ шулай ук
Мин сәламләр идем сине яу алдыннан.

Цезарь

Рәхим ит. Төкле аягың белән.

Антоний

Рәхмәт.

Цезарь

Әйдә утыр.

Антоний

Юк, башлап син.

Цезарь

Яхшы, яхшы.

Утыралар.

Антоний

Минем кылган гамәлләрдән гаеп табып
Шелтәлисең икән мине, әмма аларда
Шелтәләрлек берни дә юк һәм булса да,
Алар сиңа кагылмыйлар, син борчылма.

Цезарь

Ничек инде юк-бар өчен ачуланыйм.
Өстәвенә тагын сине? Көлке бит бу.
Ә инде миңа катнашы юк гамәлләрне
Шелтәләсәм, икеләтә көлке булыр.

Антоний

Син Мисырда булуыма ничек карадың?

Цезарь

Минем Римда булуыма ничек карасаң,
Нәкъ шулай ук, һич кенә дә аерма юк.
Тик Мисырда мәкерле уйлар башыңа килгәч,
Гамәлләреңне безне читләп уза алмады.

Антоний

Мәкерле уйлар? Аңламадым.

Цезарь
Аңлатуы
Авыр түгел.
Хатының белән абзаң Люций
Миңа каршы сугыштылар. Сәбәпче — син.
Алар өчен байрак булды синең исем!

Антоний

Дөрес түгел. Ялгышасың. Абзам Люций
Минем исем артына качып эш итмәгән.
Синең кешеләр бу турыда миңа күптән
Бәйнә-бәйнә сөйләп бирде бар дөресен.
Сиңа каршы баш күтәреп, ул шул чакта
Миңа зыян китермәде дисеңме әллә?
Аның сиңа кизәнүе миңа төште.
Таркатмакчы булып безнең уртак эшне
Сиңа башлап, миңа да ул сугыш ачты.
Һәм бу хакта сиңа хатта язган идем.
Бәлки, ызгыш чыгарырга телисеңдер?
Ул ботканы мондый утта пешермә син.

Цезарь

Тугрылыксыз итеп мине сурәтлисең.
Ә үзеңне җиде кат күккә чөймәкчесең.
Бу бит бары акланырга сылтау эзләү.

Антоний

Ярый, булды! Синең шундый гади генә
Нәрсәне дә төшенмәвең ышандырмый.
Ничек инде бер максатка хезмәт иткән
Тугры дустың уртак эшкә кулын селтәп,
Үз абзасын хыянәткә димләсен ди.
Фульвия — башка. Сиңа да мин кайчан булса
Шундый хатын насыйп булуын теләр идем.
Үз кулыңда җиңел генә тотасың син
Кеше яши торган җирнең өчтән берен,
Менә минем хатынны син тотып кара,
Исән булса, күрсәтер иде күрмәгәнең.
Энобарб. Их, әгәр дә барыбызның да хатыннары шундый булса, ул чагында сугышка да хатыннарны җитәкләп кенә китәр идек.

Антоний

Күз алдына китерәм, Цезарь, Фульвиянең
Ызгыш, җәнҗал яратуы, холыксызлыгы
Сиңа күпме бәла-каза китергәнен.
Хәленә керәм, тик нишләмәк кирәк хәзер?
Нинди ярдәм күрсәтә ала идем соң мин?

Цезарь

Мин сиңа яздым, әмма ләкин ул чагында
Кәеф-сафа сөрү белән мәшгуль идең.
Минем хатны укымыйча читкә аткансың,
Ә чапкынны тыңларга да теләмичә,
Этә-төртә мәсхәрәләп озаткансың.

Антоний

Ул чапкының рөхсәтсез бәреп керде.
Аңа кадәр өч патшага мәҗлес ясап
Арыган идем. Күңелем эштә түгел иде.
Иртәгесен үзем чакырып алдым аны.
Гафу үтенү белән бер дип саныйм моны.
Бу турыда сөйләп вакыт әрәм итмик.
Ызгышасың килсә, эзлә башка сәбәп.

Цезарь

Вәгъдәңне дә боздың тагын өстәвенә,
Миңа андый гаеп ташлый алмыйсың син.

Лепид

Цезарь!

Антоний

Лепид, бүлдермә аны, дәвам итсен.
Нигезсез шик, чөнки намусым чиста минем.
Йә, әйт, Цезарь, ничек вәгъдә боздым соң мин?

Цезарь

Миннән хәбәр килү белән, син, ярдәмгә
Кешеләр һәм корал җибәрәм, дигән идең.
Мин сорадым, син, Антоний, кире кактың.

Антоний

Дөресрәге, игътибардан читтә калган.
Ул чагында ниндидер бер агулы сөрем
Зиһенемне миңгерәүләтте һәм үземне
Кая куяр урын тапмый тилмердем мин.
Гаебемне таныйм бүген, ләкин моны
Үз теләгем белән эшлим, мәҗбүри түгел.
Фульвиянең сиңа сугыш башлавы да
Мин Мисырдан кайтсын өчен булгандыр, шәт.
Бар бәланең сәбәпчесе тик мин генә,
Шуңа күрә гафу сорыйм, әмма ләкин
Горурлыгым күтәрерлек кадәр генә.

Лепид

Нинди күркәм, мәгърур сүзләр.

Меценат

Инде хәзер
Үткәндәге үпкәләрне калдырыгыз.
Үткәннәргә күмелеп алар онытылсын.
Вакыт җитте киләчәкне искә алырга,
Ә киләчәк куша сезгә дуслашырга.
Лепид. Бик вакытлы әйтелгән сүз һәм бик дөрес.
Энобарб. Йә булмаса, кире кайтару шарты белән, вакытлыча гына, бер-берегезгә бурычка мәхәббәт хисе биреп торыгыз. Ә Помпейның эшен бетергәч, кире кайтарырсыз. Ул чагында башка эшегез булмас, шуңа күрә иркенләп, теләсә күпме чәйнәшерсез.
Антоний. Син сугышчы, тел бистәсе түгел. Дәшмә.
Энобарб. Дөреслек бик якты булса, күз чагыла.
Антоний. Телеңә тилчә чыкты мәллә? Җитте, дәшмә!
Энобарб. Аңлашылды. Тораташтай телсез калам.

Цезар

Тупасрак әйтте әйтүен, әмма дөрес.
Чынлап та, без бердәм булып эш йөртмәсәк,
Ахыргача дуслар булып кала алмабыз.
Әгәр безне беректерер кыршау булса,
Дөнья буйлап шуны эзләп йөри-йөри,
Җир читенә кадәр барып җитәр идем.

Агриппа

Рөхсәт ит миңа, Цезарь.

Цезарь

Сөйлә, Агриппа.

Агриппа

Сеңлең синең Октавия өстен барлык
Мактаулардан, ә шөһрәтле Марк Антоний

Күптән тол ир.

Цезарь

Башка бер сүз дәшмә, Агриппа!
Бу сүзләрне Клеопатра ишетсә әгәр,
Кирәгеңне биргән булыр иде синең.

Антоний

Әйе, мин тол. Бүлдермә аны, Агриппага
Фикерен әйтеп бетерергә мөмкинлек бир.

Агриппа

Мәңге өзелмәс дуслык җебе белән сезне
Бер-берегезгә беректереп бәйләр өчен,
Туганлашу кирәк бүген, шуңа күрә,
Әйдә, Антоний Октавиягә «хатыным» дисен.
Аның чиксез матурлыгы, гүзәл холкы
Антонийның шөһрәтенә, данына тиң.
Бу туганлык арагызда ышаныч тудырыр.
Әлегә кадәр юктан куркып яшәсәгез,
Моннан ары куркуларга чик куелыр.
Һәм сез өчәү берләшерсез бер берлеккә.
Октавиянең сезгә булган мәхәббәте
Яратырга мәҗбүр итәр бер-берегезне.
Бу сүзләрем өчен мине кичерегез,
Буш сафсата түгел алар. Шушы фикер
Бик күптәннән күңелемне тырнап йөрде.

Антоний

Цезарь ни ди?

Цезарь

Цезарь әлегә берни дими.
Үз фикерен әйтсен башта Марк Антоний.

Антоний

Ярый, әгәр мин хәзер үк Агриппага
Ризамын дип җавап бирсәм, ул чагында
Эшне җайга салу өчен Агриппаның
Ниндиерәк вәкаләте бар кулында?

Цезарь

Цезарь нинди вәкаләткә ия булса,
Нәкъ шундый ук вәкаләте бар аның да.
Октавияне күндерергә үзем алынам.

Антоний

Бу тәкъдимнән баш тартырга өндә түгел,
Төшемдә дә батырчылык итмәс идем.
Бир кулыңны! Әйдә, Цезарь, бүгеннән соң
Туганлык һәм дуслык җебе икебезне
Зур максатка барган юлда берләштерсен.

Цезарь

Менә кулым. Бу дөньяда үз сеңлемне
Минем кебек сөйгән кеше юктыр бүтән.

Бүген сиңа тапшырам аны, сакла үзен.
Дәүләтләр һәм йөрәкләрне бергә бәйләп
Яшәсен ул. Әйдә, мәңге безнең өстән
Хөкем йөртсен туганлык һәм дуслык хисе.

Лепид

Амин. Берүк шулай гына була күрсен.

Антоний

Һич Помпейга каршы яуга чыгармын дип
Уйламаган идем, әле күптән түгел
Минем өчен зур яхшылык эшләде ул.
Шуңа күрә башта аңа рәхмәт әйтим,
Игелексез, дип атамасын һәм шуннан соң
Аңа сугыш игълан итәм.

Лепид

Күптән вакыт.
Тиз арада үзебез һөҗүм ясамасак,
Помпей безгә үзе һөҗүм ясаячак.

Антоний

Гаскәрләрен кай тирәдә туплаган ул?

Цезарь

Мизен тавы тирәсендә.

Антоний

Алай, алай...
Коры җирдә көче зурмы?

Цезарь

Әйе, бик зур.
Һәм көннән-көн аның көче арта бара.
Диңгездә дә ул хакимлек итә һаман.

Антоний

Әйе, ишеттем. Болар бар да имеш-мимеш.
Кичекмәстән кузгалырга кирәк безгә.
Әмма өскә сугыш киеме киенгәнче,
Тәмамлыйк без башлап куйган эшебезне.

Цезарь

Рәхәтләнеп. Һәм хәзер үк сеңлем белән
Таныштырыр өчен сине аңа илтәм.

Антоний

Лепид, безне ташлама син.

Лепид

Юк, Антоний,
Хәтта муеным сынса да, мин сездән калмыйм.

Бырғы тавышлары. Антоний, Цезарь һәм Лепид китәләр.

Меценат. Сине Мисырдан Римга кайтуың белән котлыйм! Төкле аягың белән, дустым Энобарб.
Энобарб. Цезарьның уң кулы, сөекле Меценат!
Агриппа. Киң күңелле, батыр Энобарб!
Меценат. Күрдегезме, барысы да ничек әйбәт җайланды, шатланырга мөмкин. Йә, ничек, Мисырда әйбәт яшәдегезме?
Энобарб. Сөйләп тә торасы юк инде. Көннәребезне мәрткә киткән кебек йоклап, ә төннәребезне туктаусыз эчүләр белән әрәм-шәрәм итеп бетердек.
Меценат. Чынлап сөйлиләрме, имеш, анда иртәнге ашка өстәлгә сигезәр кабан дуңгызы кыздырып куялар икән һәм нибарысы унике кеше өчен генә, ди?
Энобарб. Монысы диңгездән бер тамчы гына. Әле моннан болайраклары да, затлыраклары да яугалады. Күрсәң, исең-акылың китәр. Кыскасы, сөйләсәң, сөйләрлек нәрсәләр бар.
Меценат. Сөйләүләренә караганда, ышанырга мы, юкмы, белмим, имеш, Клеопатра чамадан тыш матур икән. Шулаймы?
Энобарб. Кидн елгасында беренче очрашуларында ук ул Марк Антонийның йөрәген тәмам әсир итте.
Агриппа. Әгәр дә инде ул хәлләрне үз күзләре белән күреп миңа сөйләүче кеше үзеннән уйлап чыгарып кына сөйләмәгән булса, чыннан да, Клеопатра ул вакытта искитәрлек булган, күрәсең.

Энобарб

Хәзер үзем сөйләп бирәм.
Ул утырган кораб алтын тәхет сыман
Нурлар чәчеп килә Кидн елгасыннан.
Кызгылт ялкын төсле җилкәннәре аның
Хуш ис сирпеп бара бөтен тирә-якка.
Көтмәгәндә кинәт, әллә шуны сизеп,
Килеп җитә, җилләр талгын гына исеп.
Күңелләрне хушлап сихри моңнар агыла
Һәм ишкәкләр ишә шуның салмагына.
Көмеш ишкәкләрдән көмеш тамчы тама,
Агым белән куышып кораб алга бара...
Ә патшабикәнең сез үзен күрсәгез,
Тел белән генә сурәтләп булмый.
Алтын чатырда килә ул ятып,
Венерадан да гүзәлрәктер.
Тирә-ягында чибәр малайлар,
Көлемсерәгән Амурлар кебек,
Алсу алмадай матур йөзенә
Җилпәзә белән торалар җилпеп.
Җилпегән саен, аның йөзенә
Тагын да ныграк алсулык иңә.

Агриппа

Менә тамаша! Бәхетле дә соң бу Антоний!

Энобарб

Шат нимфалар сыман сылу хезмәтчеләр
Күз карашын аулый аның ни әйтер дип.
Ә берсенең гүзәл чәчәк сабагыдай
Йөгерек матур кулларында ал тасмалар,
Ара-тирә ул шуларга кагылып ала,

Кораб тыңлый һәм тиешле юнәлеш ала.
Бая әйтеп киткән идем, ул корабтан
Тирә-юньгә искиткеч бер хуш ис агыла.
Һәм шул хуш ис, ярга кадәр барып җитеп,
Кешеләрнең тәмам һушын, акылын алган.
Ә Антоний олы базар мәйданында
Тәхетендә утыра икән бу вакытта...
Бер мизгелдә базар тәмам бушап калган,
Яр буена йөгергәннәр бөтен халык.
Һәм Антоний берьялгызы торып калган.
Хәтта теге хуш ис үзе, әйтерсең лә
Тизрәк барып күзләр өчен, Клеопатраны
Үзен-үзе урлап качкан бу тирәдән.

Агриппа

Юк, хатын-кыз түгелдер ул, могҗизадыр!

Энобарб

Клеопатра ярга килеп туктау белән,
Антоний аны кичке ашка дәштерттергән.
Ә Клеопатра аңа биргән җавабында:
«Башта үзең кунак бул син миндә», — дигән.
Һәм хатын-кыз сораганда кыстатырга
Күнекмәгән Марк Антоний риза булган.
Ким дигәндә бер ун тапкыр кырынган да
Мәҗлескә дип юлга чыккан. Һәм мәҗлестә
Күзе белән ни ашаса, шуның хакын
Йөрәге белән түләп кайткан.

Агриппа

Менә хатын!
Сихерчедер! Хәтта бөек Юлий Цезарь,
Ул да әнә Клеопатра түшәгендә
Үз кылычын сука белән алыштырган.
Сукалаган, сукалаган, үзе киткәч
Бар уңышын Клеопатра җыеп алган.

Энобарб

Берчак моның минем алда тыны кысылды,
Йөгерергә туры килде бер илле адым.
Туктады да шулчак сулышын йота-йота
Сүз башлады. Ишетсәгез иде аның
Буыла-буыла сөйләвенең матурлыгын...
Бүтән булса әйләнеп тә карамас идең,
Ә бу исә тончыкса да матур сөйли.

Меценат

Инде хәзер Антоний аны ташлаячак.

Энобарб

Антониймы? Клеопатраны? Беркайчан да!
Еллар аңа тәэсир итми. Аннан тую
Мөмкин түгел, чөнки ничек күңел ачу
Серләрен ул кирәгеннән артык белә.

Башкалардан гарык булып туйганда да,
Аны күрсәң, өр-яңадан теләк туа.
Ул башкарган иң йөгәнсез азгынлык та
Руханилар дога кылган сыман изге эш.

Меценат

Шулай да Антоний Октавиянең тыйнаклыгын,
Матурлыгын һәм акылын бәяли алса,
Аның өчен бик зур табыш булыр иде.

Агриппа

Йә, әйдәгез, киң күңелле Энобарб!
Монда чакта минем кунак сөюемнән
Файдаланып кал, югыйсә үкенерсең.
Рәхим ит, үтенәм синнән.

Энобарб

Рәхмәт, дустым.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Цезарь йортындагы бер бүлмә.
Цезарь, Антоний, Октавия һәм Сарай хадимнәре керәләр.

Антоний

Вакыт-вакыт вазифам һәм бурычларым
Бер-беребездән, бәлки, безне аерып торыр.

Октавия

Ул чакларда Октавия синең өчен
Аллаларга бертуктаусыз гыйбадәт кылыр.

Антоний

Тыныч йокы сиңа, Цезарь. Октавия,
Мине хурлый торган пычрак гайбәтләрне
Тыңлама син. Әйе, таныйм, гөнаһ кылдым.
Тик борчылма, төзәлермен. Тыныч йокы.
Тыныч йокы сиңа, Цезарь.

Цезарь
Тыныч йокы.

Цезарь һәм Октавия китәләр. Багучы керә.

Антоний

Ник күңелсез, әллә Мисыр сагындырамы?

Багучы

О, китмәгән булсам иде мин Мисырдан!
Йә килмәгән булсаң иде син Мисырга!

Антоний

Ә ни өчен?

Багучы

Мин сүз белән аңлата алмыйм,
Әмма тоям: кичекмәстән Мисырга кайт.

Антоний

Син шуны әйт, безнең кайсыбыз бәхетлерәк?
Киләчәктә Цезарь өскә чыгачакмы,
Әллә минме? Ник дәшмисең? Йә, кем?

Багучы

Цезарь.
Шуңа күрә моннан тизрәк кит, Антоний.
Сакчы фәрештәң көчле, бөек, даһи синең,
Цезарьныкы читтә булган чакта гына.
Ә Цезарьның газазиле алдында ул
Коелып кала. Син Цезарьдан читтәрәк тор.

Антоний

Бу турыда берәүгә дә ычкындырма!

Багучы

Авызымны да ачмам. Бары сиңа гына.
Цезарь белән нинди уен уйнасаң да,
Оттырачаксың. Синең йолдыз сүнеп бара.
Ә аныкы әле яңа кабына гына.
Кабат әйтәм: янәшәңдә Цезарь булса,
Рухың синең коелып төшә, көчен жуя.
Ә Цезарьдан читтә чакта алай түгел,
Киресенчә, гайрәт белән канат җәя.

Антоний

Ярый, бар, чык. Вентидийны чакыр монда.

Багучы китә.

Аңа күптән яуга китәр вакыт җитте.
Очраклы гына шулай дөрес әйттеме соң,
Әллә белепме? Ни булса да Багучы хаклы:
Сөяктәге күзләр дә бит аның яклы.
Нинди уен уйнасак та, аның бәхете
Өстен кала һәрчак минем осталыктан.
Шобага салсак — миңа түгел, аңа чыга.
Әгәр әтәч талаштырсак, әтәче дә
Минекен талый, ул җиңүче булып кала.
Бүдәнәләр сугышында да нәкъ шул ук хәл.
Юк, Мисырга китү кирәк кичекмәстән.
Тынычлыгым ныгысын өчен өйләнсәм дә,
Бәхетем минем көнчыгышта.

Вентидий керә.

Парфяннарга каршы кузгал син бүген үк.
Боерык әзер. Әйдә киттек, вәкаләт ал.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Урам. Лепид, Меценат һәм Агриппа керәләр.

Лепид

Җитте, бүтән озатмагыз, инде хәзер
Үзегезнекеләр янына тизрәк ашыгыгыз.

Агриппа

Октавия белән Антоний хушлашсын да
Аннан без дә кузгалабыз дип торабыз.

Лепид

Исән-сау һәм сезгә бик тә килешә торган
Шушы сугыш киемнәрен кигән көе
Тиз арада очрашырга язсын безгә.

Меценат

Без, мөгаен, синнән бераз алдарак та
Барып җитәрбез Мизен тавы тирәсенә.

Лепид

Әйе, әйе, мин әйләнеч юлдан барам.
Ә сез турыга.

Меценат, Агриппа
(икесе бергә)

Хәерле юл.
Лепид

Сау булыгыз.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Клеопатра сараеның залы. Клеопатра, Хармиана, Ирада һәм Алексас керәләр.

Клеопатра

Мәхәббәттән көйгән җанны сугарырдай
Берәр моңлы аһәң хәзер тыңлар идем.

Барысы бергә
Уенчылар!
Клеопатра

Юк, кирәкми. Хармиана,
Әйдә, икәү шар тәгәрәтеп уйныйк әле.

Хармиана

Кулым авырта. Мардиан белән уйна әнә.

Клеопатра

Дөрестән дә, синең белән уйнадың ни,
Мардиан белән уйнадың ни — барыбер ич.

Алашаның ни зыяны, ни файдасы.
Уйныйбызмы? Әй, Мардиан!

Мардиан

Тырышып карыйк.

Клеопатра

Файдасызга тырышып та, кайчагында
Мәрхәмәткә лаек була кайберәүләр.
Инде уйныйсым килми. Миңа кармак бирегез!
Елга буена төшик хәзер һәм мин анда
Кызылканатларның сайлап иң зурысын,
Кармак белән саңагыннан эләктереп,
Ярга тартып чыгарырмын һәм шуннан соң
Антонийга охшатып аны: «Эләктеңме,
Инде хәзер ычкына алмассың», — дип әйтермен.

Хармиана

Хәтерлисең микән хәзер, әллә юкмы,
Антоний белән бәхәсләштең бервакытны:
Әйдә, имеш, кем күбрәк балык тота!
Бер хезмәтчең су астыннан чумып барып
Кармагына үләксә элде Антонийның.
Әй Антоний тарта, тарта, ә чыгарса...
Көлә-көлә эчләр катты шул вакытта.

Клеопатра

О, ул көннәр! Онытылмаслык көннәр булды!
Ул көн ачуы чыкты аның мин көлгәнгә.
Шул ук төндә көлүем аны бәхетле итте.
Иртә белән шәраб эчтек, ул исергәч,
Аңа үземнең күлмәгемне кидердем мин.
Филипп сугышы истәлеге булган кылычын
Үз билемә тагып куйдым.

Чапкын керә.

Син Римнанмы?
Тиз бул, сөйлә, әйбәт хәбәр көткән
Колакларны артык тилмертмә.

Чапкын

Патшабикә!

Клеопатра

Нәрсә? Ул үлдеме?
«Әйе» дисәң, мин дә үләчәкмен.
Әгәр «Исән, иректә» дисәң,
Менә алтын сиңа, менә кулым,
Зәңгәр тамырларын ул кулның
Патшалар да калтырап үбә иде.

Чапкын

Исән, исән, патшабикә.

Клеопатра

Менә
Алтын сиңа тагын, тик саклан!
Үлгәнне дә кайчак тере дибез.
Шул мәгънәдә әйтсәң, алтынны
Эреттереп синең бугазыңа
Койдырачакмын, шуны белеп тор.

Чапкын

Патшабикә, тыңла.

Клеопатра

Йә, йә, сөйлә.
Әмма әйбәт хәбәр көтмим мин.
Әгәр Антоний исән-имин икән,
Нигә йөзең шундый караңгы?
Әгәр яман хәбәр китерсәң,
Кеше сыйфатында ник килдең?
Син килергә тиеш фурия булып,
Еланнардан үргән таҗ киеп.

Чапкын

Патшабикә, мине тыңларга син
Телисеңме?

Клеопатра

Телим. Тик кыйнарга.
Әмма Антоний исән һәм иректә,
Цезарь белән дуслар дип әйтсәң —
Алтын яудырам, энҗе белән күмәм.
Йә, ни дисең?

Чапкын

Исән ул, исән.

Клеопатра

Монысы әйбәт.

Чапкын

Цезарь белән дуслар.

Клеопатра

Син искиткеч яхшы күңелле.

Чапкын

Алар дуслар, хәтта артык дуслар.

Клеопатра

Бу хәбәрең өчен бик юмарт
Бүләкләрмен.

Чапкын

Ләкин, патшабикә...

Клеопатра

Нәрсә ләкин? Ул нинди сүз тагын?
Бар әйткәнне юкка чыгара,

Барлык башлангычның каберчесе.
Ләкин, имеш... Сузма, хәбәреңнең
Яхшысын да, хәтта яманын да
Чыгарып сал, әйдә, нибарын.
Цезарь белән дуслар, ул исән-сау
Һәм иректә, дидең.

Чапкын

Иректә?
Мин алай дип сиңа әйтмәдем, юк,
Ул иректә түгел, ул бәйле.
Октавия белән бәйләнгән ул.

Клеопатра

Октавия белән? Тукта әле,
Ә аларның уртак нәрсәсе бар?

Чапкын

Түшәкләре.

Клеопатра

Хәлем начарланды,
Хармиана.

Чапкын

Алар никахланды.

Клеопатра

Мур кыргыры! Тончык, бет, кадал!

Сугып Чапкынны аягыннан ега.

Чапкын

Акылыңа кил, зинһар!

Клеопатра

Нәрсә дидең?
Кыйный.

Ah, кабахәт! Ычкын моннан тизрәк,
Күзләреңне чукып чыгарам.

Өстерәп йөртә.

Берәм-берәм чәчләреңне йолкып,
Тимерчыбык белән ярдырам.
Ә аннары тозлы суга салып
Пешерәчәкмен.

Чапкын

Зинһар, сабыр ит.
Мин хәбәрче генә, димче түгел.
Никах укымадым аларга.

Клеопатра

Ялганладым, диген һәм шунда ук
Мал-мөлкәтле итәм үзеңне,
Данга күмәм. Ялганыңны кичерәм!

Ә кыйналган өчен син миннән
Теләсә нәрсә сора. Хәзинәдә
Ни ошаса, шуны бирермен.
Андый затлы маллар төшеңә дә
Кермәгәндер.

Чапкын

Кичер, ул өйләнде.

Клеопатра

Әшәке кол! Үләр вакытың җитте!

Хәнҗәр чыгара.

Чапкын
(читкә)
Юк,
Качарга кирәк! Ни өчен?
Синең алда ни гаебем бар соң?

Чапкын чыгып йөгерә.

Хармиана

Тукта, патшабикә, тынычлан.
Ул гаепсез.

Клеопатра

Яшен суккан чакта,
Карап торамыни гаепне?
Мисырны су бассын, Нил суында
Бөтен нәрсә череп таркалсын.
Күгәрченнәр шакшы еланнарга
Әверелсен. Кайда ул Чапкын?
Кайтарыгыз хәзер үк, котырсам да,
Мин тешләргә җыенмыйм аны.

Хармиана

Шүрләде ул.

Клеопатра

Кайтарыгыз, тимим.

Хармиана китә.

Аңа кагылып болай да инде
Кулларымны гына пычраттым.
Барысына да үзем гаепле.

Хармиана Чапкынны алып керә.

Кер, кер, әйдә. Яман хәбәр китерү
Игелексез, хәтәр хезмәт ул.
Шатлык булса мең авыздан чыга,
Ә кайгылар сүзсез сарыла.

Чапкын

Бурычымны гына үтәдем мин.

Клеопатра

Өйләнүе хакмы? Әгәр дә

«Әйе» дисәң, сиңа элеккедән
Мең кат күбрәк нәфрәт явачак.

Чапкын
Өйләнде ул.

Клеопатра

Кahәр суккан нәрсә,
Үзенекен туглый hаман да!

Чапкын

Мин алдарга тиешмени инде?

Клеопатра

О, алдасаң иде, ичмасам!
Нил төбендә калып ярты Мисыр,
Хәшәрәтләр оя ясасын!
Ычкын моннан. Хәтта Нарцисс сыман
Чибәр булсаң да син — җирәнгеч.
Өйләндеме?

Чапкын

Кызган, патшабикә.

Клеопатра

Өйләндеме? Кабат сорыйм мин.

Чапкын

Ялганласам, сине хурлау булыр,
Дөрес сүзем өчен кичерә күр
Мин колыңны, әмма никахланды
Октавия белән Антоний.

Клеопатра

О, бу кадәр хәтәр явызлыкны
Хәбәр итеп китергән кеше
Ничек үзе явыз булмасын ди?
Кит тизрәк! Югал күземнән!
Син күрсәткән Рим товарларын
Алыр өчен кесәм сай минем.
Үзеңә булсын, шулар белән бергә
Җәһәннәмгә олак тизрәк.

Чапкын китә.

Хармиана

Йә, тынычлан инде, патшабикә,
Зинhар өчен, бераз сабыр бул!

Клеопатра

Антонийны мактар өчен, хәтта
Бөек Цезарьны мин хурладым.

Хармиана

Бер генә дә түгел.

Клеопатра

Менә бүген
Җәзасын да күрдем шуларның.
Инде сабак булыр. Йә, әйдәгез...
Ah, егылам! Тизрәк тотыгыз!
Хәлем начар, Ира, Хармиана,
Юк, юк, узды. Син, Алексас, аны,
Чапкынны, дим, тизрәк куып җит.
Октавиянең холкын, яшен сора.
Йөзе нинди? Чәче турында да
Бик җентекләп белеш һәм шундук
Миңа йөгер.

Алексас китә.

Инде мәңгегә
Оныттым мин аны, Хармиана!
Шулай микән? Юк, юк, теләмим!
Аждаһамы, әллә Алламы ул,
Аера алмыйм шуны... Мардиан,
Бар, әйт Алексаска, ул Чапкыннан
Октавиянең буен сорасын.
Хармиана, дәшми-нитми генә
Кызган мине. Килче, таяныйм,
Инде хәзер йокы бүлмәсенә
Әкрен генә алып чык әйдә.

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мизен тавы тирәсе. Быргы, барабан тавышлары астында үзләренең гаскәрләре белән бер яктан Помпей һәм Менас, ә икенче яктан Цезарь, Антоний,
Лепид, Энобарб һәм Меценат керәләр.

Помпей
Ике якта да тотыклар бар, инде хәзер
Сугышырдан алда бераз сөйләшеп алыйк.

Цезарь

Безнең дә төп теләгебез — сөйләшүләр.
Шуңа күрә сиңа алдан хат җибәреп,
Үзебезнең тәкъдимнәрне ирештердек.
Бәлки, алар кылычыңны кынына тыгып,
Бу яшьләрне — Сицилиянең киләчәген
Өйләренә таратырга күндерер сине.
Югыйсә алар бер дә юкка кырылачак.

Помпей

Аллаларның җирдәге төп таянычы —
Бу дөньяның хакимнәре, әйтегезче,
Дуслары һәм улы исән булган чакта,
Әтием өчен үч алынмый калсынмыни?
Ә бит Юлий Цезарь тапкан кешеләрен,
Өрәген Филипп тирәсендә Брут күргәч,
Аның үчен алучылар сез булдыгыз.
Римлыларның намусы булган Брут белән

Ирек сөюче Кассийны һәм башкаларны
Капитолийда кеше каны түгәр өчен
Нәрсә мәҗбүр итте икән? Минемчә, алар
Бер кешенең меңәрләгән кеше өстеннән
Хакимлеген әнә шулай туктаттылар.
Мин дә шундый максат белән гаскәр туплап,
Котырынган диңгезләрне күбекләндереп
Йөзә торган корабларга төядем дә
Шул дәһшәтле зур көч белән яуга чыктым.
Яхшылыкның кадерен белмәс Римнан мин
Әтиемнең үчен алам!

Цезарь

Артык кызма.

Антоний

Корабларың белән безне куркытма син,
Синең белән диңгездә дә сөйләшә алабыз.
Коры җирдә безнең көчне син беләсең.

Помпей

Коры җирдә көчлерәксеңдер: чөнки бүген
Әтиемнең йортына да син хуҗа бит.
Күке үзенә оя кормый, шуңа күрә,
Әйдә, куып чыгарганчы, тик яши бир.

Лепид

Бу сүзләрнең эшкә һичбер катнашы юк.
Иң яхшысы: без җибәргән тәкъдимнәргә
Ничегрәк каравыңны аңлат әйдә.

Помпей

Нәкъ шул турыда сүз бара да.

Антоний

Исеңдә тот,
Хискә бирелеп кычкырудан файда булмас,
Һәммәсен дә аек акыл белән үлчә.

Цезарь

Алдау юлына бассаң, үзеңә начар булыр,
Күпне өмет итеп аздан колак какма!
Йә, әйт инде, шартларыңны ишетик әйдә.

Помпей

Сицилияне Сардиния белән икесен,
Димәк, минем карамакка тапшырасыз?
Ә мин моңа җавап итеп диңгезләрне
Пиратлардан чистартырга һәм Римны
Бодай белән тәэмин итеп торырга тиеш?
Әгәр дә мин шул шартларны кабул итсәм,
Кылычларын үтмәсләми-нитми генә,
Ике як та таралышамы?

Цезарь , Антоний, Лепид

(барысы бергә)

Шулай. Дөрес.
Безнең шартлар шундый иде.

Помпей

Инде белегез,
Мин риза булып килгән идем ул шартларга,
Әмма Антоний икеләнергә мәҗбүр итте.
Әйтмәскә дә дигән идем, шулай да әйтәм:
Абыең Люций белән Цезарь сугышканда,
Сицилиягә качып килде синең әнкәң.
Һәм ул анда кунакчыллык, хөрмәт күрде.

Антоний

Мин ул хакта беләм, Помпей, изгелегең
Тик изгелек булып кайтыр, рәхмәт сиңа.

Помпей

Димәк, тәртип? Ул чагында бир кулыңны!
Безнең монда, бу якларда очрашуны,
Дөресен әйтим, уема да китермәдем.

Антоний

Шәрык түшәкләре йомшак, шуны ташлап
Кайтырга мин мәҗбүр булдым, син уяткач,
Әмма күрәм: хәерлегә булган икән.

Цезарь

Соңгы тапкыр күрешкәннән бирле, Помпей,
Үзгәргәнсең, танырлык та түгел сине.

Помпей

Язмыш минем йөзне ничек сырлагандыр,
Анысын сезгә әйтә алмыйм, ә йөрәкне
Үзгәртергә теләсә дә, булдыра алмады.

Лепид

Без бүгенге очрашудан бик канәгать.

Помпей

Мин дә шулай. Ниһаять, бер сүзгә килдек.
Инде хәзер килешүне раслар өчен
Һәркайсыгыз кулын куеп, мөһер бассын.

Цезарь

Әйе, әлбәттә, иң беренче эш шул булсын.

Помпей

Хушлашканга кадәр, ләкин без чиратлап
Бер-беребезне хөрмәт итик мәҗлес ясап.
Кем башлыйсын шобага әйтер.

Антоний
Миннән башлыйк.

Помпей

Юк, Антоний, иң яхшысы — шобага салыйк.
Юкка курыкма, иң ахырга калсаң да, син
Затлы мисыр ашларының исе белән
Авыз суын корытачаксың әле безнең.
Ишетүемчә, Мисырдагы мәҗлесләрдә
Юлий Цезарь шактый гына симергән, ди.

Антоний

Кирәгеннән артыграк ишеткәнсең.

Помпей

Рәнҗерсең дип башыма да китермәдем.

Антоний

Рәнҗетерлек сүз дә әйтмәдем, диген инде.

Помпей

Ишеткәнне генә әйттем. Әле тагын
Аполлодор, имеш, аңа китергән, ди...

Энобарб

Җитте, дәшмә. Йә, китергән, шуннан нәрсә?

Помпей
Ни китергән?

Энобарб

Түшәкләре-ние белән.
Зур капчыкка салып төнлә Цезарьга ул
Бик чибәр бер патшабикә алып килгән.

Помпей

Хәзер генә таныдым сине, йә, туганкай,
Тормышларың ничегрәк?

Энобарб
Искиткеч шәп!
Киләчәктә дә начар булмас, чөнки әнә
Дүрт мәҗлес көтә алда.

Помпей
Бир кулыңны!
Мин дошманың түгел синең. Сугышларда
Син күрсәткән батырлыклар таң калырлык.

Энобарб

Син дустым да түгел минем, әмма ләкин
Күп тапкырлар мактап телгә алганым бар.
Тик шулай да син күрсәткән батырлыклар
Ун тапкырга артык минем мактаулардан.

Помпей

Ә мин сине туры сүзең өчен мактыйм.
Әфәнделәр! Корабыма чакырам сезне.

Цезарь, Антоний, Лепид
(барысы бергә)

Синең арттан барабыз без.

Помпей
Ярый, киттек.

Менас белән Энобарбтан башкалар барысы да китәләр.

Менас
(читкә)

Синең атаң Помпей беркайчан да
Мондый килешүгә бармас иде.
(Энобарбка.)
Безнең кайдадыр очрашканыбыз бар сыман.

Энобарб

Диңгездәдер.
Менас

Чынлап та, диңгездә бугай шул.

Энобарб

Син диңгездә бик тә гаярь сугышасың.

Менас

Ә син коры җирдә.
Энобарб. Мине мактау бик тә мактаулы эш. Хәер, ни генә әйтсәң дә, минем коры җир сугышларында күрсәткән батырлыкларны инкарь итеп булмый инде анысы.
Менас. Ә минем диңгездәге батырлыкларны.
Энобарб. Дөрес. Әмма син үзеңнең кайбер батырлыкларыңнан баш тартсаң да начар булмас иде. Чөнки син диңгездә юлбасарлык итәргә бик оста.
Менас. Ә син коры җирдә.
Энобарб. Моны инкарь итеп шуны гына әйтә алам. Минем коры җир гаскәрләрендәге эшчәнлегемнең бу өлкәсе телгә дә алып тормаслык дәрәҗәдә кечкенә. Бир кулыңны, Менас. Әгәр дә безнең күзләр судьялык хокукына ия булсалар, менә хәзер үбешеп торучы ике юлбасарны кулга алу бәхетенә ирешерләр иде.
Менас. Кешеләр куллары белән нинди генә явызлык эшләсәләр дә, гөнаһлары йөзләренә чыкмый.
Энобарб. Матур хатыннардан башкаларныкы, әлбәттә.
Менас. Менә монысы дөрес. Матур хатыннар, үзләренең матур йөзләре белән юлбасарлык итеп, йөрәкләрне урлыйлар.
Энобарб. Без монда сезнең белән корал тотып көч сынашырга дип килгән идек.
Менас. Кызганычка каршы, эчү өлкәсендә генә көч сынашырга туры киләчәк. Бүген Помпей үз бәхетен эчеп исерәчәк.
Энобарб. Ә соңыннан елап туя алмасмы?
Менас. Дөрес сүзгә җавап юк. Нәкъ шулай. Ә без Антонийны кайтыр дип уйламаган идек. Кара әле, аның Клеопатрага өйләнүе дөрес хәбәрме соң?

Энобарб

Цезарьның сеңлесе Октавия исемле.

Менас

Әйе. Ул Гай Марцелла хатыны иде.

Энобарб

Ә хәзер Марк Антонийның хатыны.

Менас

Син ни сөйлисең?

Энобарб

Ни ишетсәң, шуны.
Менас. Димәк, алар Цезарь белән хәзер мәңгелеккә берләшкәннәр.
Энобарб. Әгәр дә мин багучы булсам, алай дип әйтүдән тыелыр идем.
Менас. Ни генә әйтсәң дә, бу никахның нигезендә мәхәббәт түгел, сәясәт ята дип уйларга кирәк.
Энобарб. Мин дә шулай уйлыйм. Менә күрерсең, аларның дуслыкларын беректерергә тиешле җеп Октавия өчен элмәккә әйләнәчәк. Чөнки ул кирәгеннән артык изге күңелле, тыныч, сабыр холыклы хатын.
Менас. Кем генә үзенә шундый хатын теләмәс икән?
Энобарб. Үзе шундый булмаган кеше — Марк Антоний. Ул барыбер үзенең Мисырдагы кәнтәенә әйләнеп кайтачак. Ул чагында Октавиянең көрсенүләре Цезарь йөрәгендә Антонийга карата нәфрәт уты кабызып, аларның дуслыклары чәлпәрәмә киләчәк. Шулай итеп, Октавия аларның дуслашуларына сәбәпче булган кебек, дошманлашуларына да сәбәпче булачак. Антоний мәхәббәткә дәваны калдырып киткән җиреннән — диңгез аръягыннан эзләячәк. Аның биредәге никахы очраклы хәл генә.
Менас. Бәлки, бәлки. Безгә корабка юнәлергә вакыт җитмәдеме икән? Югыйсә синең исәнлек өчен үтереп эчәсе килә башлады.
Энобарб. Каршы килмим. Безнең бугазлар андый эшкә шактый гына күнеккән, Мисырдагы тәҗрибәмнән чыгып әйтәм.
Менас. Алайса киттек.

Китәләр.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мизен тавыннан ерак түгел генә туктаган Помпей корабы. Музыка. Шәраб, татлы ризыклар күтәргән хезмәтчеләр керәләр.

Беренче хезмәтче. Монда киләләр. Кайберәүләре тамыры черегән имән кебек чайкалалар, җил исеп китсә дә аварга торалар.
Икенче хезмәтче. Ә Лепид тәмам кысла кебек кызарган.
Беренче хезмәтче. Кызармыйча. Кем нәрсә тели — шуны эчертә. Бөтен калдык-постыкны аңа аударалар.
Икенче хезмәтче. Аз гына берсе икенчесенең авырткан җиренә баса башласа, Лепид шундук сикереп тора да: «Җитәр сезгә!» — дип кычкырып, менә-менә кабынып китәргә торган җәнҗалны тиз генә өреп сүндерә. Һәм үзе шунда ук: «Татулашу хөрмәтенә!» — дип шәраб чөмерә дә, битенә ут капкандай, бурлат кебек кызара башлый.
Беренче хезмәтче. Ул аларны татулаштыра, ә менә үзенең аяк-кулларын тыңлата алмый.
Икенче хезмәтче. Бөек ирләр арасына лаек булмаган көе тыкшынып йөрсәң, шулай була ул. Күтәрә алмаслык авыр сөңгегә ябышканчы, кулыңа камыш таяк алу хәерлерәк.
Беренче хезмәтче. Бөек кешеләр белән аралашып та, алар арасында тишекле бер тиен кебек селкенеп йөрү, бәбәге чыккан кешенең күз тишекләре аның йөзен ямьсезләгән сыман, кешене юкка чыгаручы бер сыйфат инде.

Бырғы тавышлары. Цезарь, Антоний, Помпей, Лепид, Агриппа,
Меценат, Энобарб, Менас һәм башка хәрби начальниклар керәләр.

Антоний
(Цезарьга)

Түбәләре күккә тигән таш төрбәләр
Бар Мисырда һәм аларга билге куелган.

Һәр ел саен язгы ташу вакытында
Шуңа карап үлчи алар Нилның суын.
Әгәр дә Нил бик югары күтәрелсә,
Иген уңа, күтәрелмәсә, су аз булса,
Корылык була. Шуңа карап игенчеләр
Нил сулары ярларына кайтуга ук,
Уңдырышлы ләм эченә орлык чәчә.
Ә шуннан соң хәтта сизми дә каласың,
Урып-җыю вакыты да килеп җитә.
Лепид. Сездә анда коточкыч зур хәшәрәтләр яши дип ишеттем мин.
Антоний. Бар, бар, Лепид.
Лепид. Сезнең ул Мисыр хәшәрәтләре Мисыр кояшының пычрак Мисыр сазлыкларына тәэсире нәтиҗәсендә яралалар.
Антоний. Дөрес.
Помпей *(Лепидка).* Утыр әйдә. Яле, Лепид саулыгына эчеп җибәр әле!
Лепид. Мин хәзер алай бик үк... Тик шулай да үзем өчен үзем тора алам әле.
Энобарб. Дүрт аяктамы?
Лепид. Юк, чыннан да, мин ул... ничек әле, аты коргыры... Птоломида пирамеяларын искиткеч дип ишеткән идем. Юк, юк, бәхәсләшмәгез дә, мин моны үз колакларым белән ишеттем.

Менас
(Помпейга, акрын гына)
Помпей!
Помпей
(Менаска, акрын гына)

Ни бар? Колакка гына әйт.
Менас. Читкәрәк китик әле. Сиңа бер-ике генә сүз әйтәсем бар.
Помпей

(акрын гына)
Сабыр ит. Хәзер.
(Кычкырып.)
Йә, әйдәгез, Лепид саулыгына эчик!
Лепид. Ә ниндирәк нәрсә ул крокодил?
Антоний. Кыяфәте белән ул үзенә охшаган. Буе үз озынлыгы кадәр, юанлыгы да үз юанлыгыннан артык түгел. Үз аяклары белән хәрәкәтләнә, ашаган әйбере белән туклана. Үлгәч чери, ә җаны кешеләргә күчә.
Лепид. Төсе нинди аның?
Антоний. Үз төсендә.
Лепид. Гаҗәеп хәшәрәт икән.
Антоний. Сөйлисе дә юк. Ә күз яшьләре аның юеш була.
Цезарь. Болай сурәтләү аны канәгатьләндерерме икән соң?
Антоний. Помпей аның бугазыннан койган касәләрдән соң канәгатьләнер дип уйлыйм. Әгәр дә канәгатьләнмәсә, ул чагында бирән дип уйларга гына кала.

Помпей
(Менаска, акрын гына)

Нәрсә кирәк? Бәйләнмә, дим, калдыр мине,
Әйткәнне эшлә.
(Кычкырып.)
Шәраб коегыз! Кайда касә?

Менас
(акрын гына)

Сиңа булган тугрылыгым хакына, тик
Тыңла мине, үтенеп сорыйм, зинһар, тыңла!

Помпей

Акылыңнан яздыңмы әллә? Сөйлә, ни бар?

Помпей белән Менас читкә китәләр.

Менас
(акрын гына)

Мин һәрвакыт сиңа тугры хезмәт иттем.

Помпей
(акрын гына)

Әйе, тугры хезмәт иттең. Йә, дәвам ит!
(Кычкырып.)
Нәрсә тынып калдыгыз анда? Уяныгыз!

Антоний

Комга утыра күрмә, Лепид, тора алмассың.

Менас
(акрын гына)

Әйт, хөкемдар буласың киләме бар дөньяга?

Помпей
(акрын гына)
Ә?
Менас
(акрын гына)

Хөкемдар буласың киләме бар дөньяга?

Помпей
(акрын гына)
Ничек итеп?
Менас
(акрын гына)

Риза гына булуың кирәк.
Үзем ярлы булсам да, мин хәзер сиңа
Бар дөньяны бүләк итәм.

Помпей
(акрын гына)

Син исерек.
Менас
(акрын гына)

Иренемне дә тидермәдем. Телә генә,
Сине җирнең Юпитеры ясыйм хәзер.
Иксез-чиксез биләмәләр бүләк итәм:
Күк астында ниләр булса, бар да сиңа.

Помпей
(акрын гына)

Моңа ничек ирешмәкче буласың соң?

Менас

(акрын гына)

Бар дөньяны үзара бүлешкән триумвирлар
Өчесе дә хәзер синең корабыңда.
Арканнарны шыпырт кына кисәм дә мин,
Диңгезгә юл тотачакбыз, ә инде анда
Өчесен дә бугазларбыз һәм шуннан соң
Син хөкемдар булачаксың бар дөньяга.

Помпей
(акрын гына)

Нигә аны миңа әйтеп торасың син,
Үзең генә башкармыйча шушы гомер?
Сиңа бит ул вазифаңны үтәү генә,
Минем өчен кабахәтлек андый шөгыль.
Мин файдадан өстен куям намусымны,
Телең белән нинди әйбәт эшне боздың.
Гамәлеңне мактаган да булыр идем,
Тәкъдимеңне кабул итмим. Бар, шәраб эч.
Бу турыда оныт.

Менас
(читкә)

Ярый, аңлашылды.
Сиңа хезмәт итүемнең соңы шушы.
Сүнгән йолдыз артыннан мин бара алмыйм.
Кулга кергән бәхетне дә ычкындыргач,
Форсат сине башка болай азындырмас.

Помпей

Тагын бер кат эчик Лепид саулыгына!

Антоний

Аны ярга алып чыгар вакыт җиткән,
Ә саулыгы өчен хәзер үзем эчәм.

Энобарб

Синең исәнлеккә эчәм, дустым Менас.

Менас

Ә мин, дустым, синең өчен.

Помпей

Тутырып сал.

Энобарб
(Лепидны алып чыгып баручы колга күрсәтеп)

Күрче, Менас, никадәр көч бу бәндәдә.

Менас

Ни өчен алай дип уйлыйсың?

Энобарб

Җирнең өчтән берен ничек сөйрәп бара.

Менас

Ул өчтән бер шактый исерек. Калганын да
Шулай эчертәсе иде, ул чагында
Чайкалып та карар иде.

Энобарб

Күбрәк эчсәң,
Ул болай да чайкалачак.

Менас

Эчик, дустым!

Помпей

Ничек кенә мактасаң да, безнең табын
Мисырныкы түгел инде.

Антоний

Шуңа якын.
Йә, чәкешик, дуслар, Цезарь саулыгына!

Цезарь

Ә мин бераз тыелыр идем. Начар эш бу.
Төне буе миебезне чайкый-чайкый
Юсак та без, чистарырга һич уйламый,
Киресенчә, юган саен ул пычрана.

Антоний

Вакыты шулай таләп итә. Буйсынасың.

Цезарь

Буйсындыру күңеллерәк. Ярый, эчәм,
Тик бер көндә шушы кадәр тыгынганчы,
Дүрт көн буе ач торуың әйбәтрәк.

Энобарб
(Антонийга)

Хөкемдарым, әгәр дә без бу мәҗлесне
Мисырдагы сыман шәраб алласына
Рәхмәт әйтеп, җырлап-биеп тәмамласак
Ничегрәк булыр икән?

Помпей
Бик шәп булыр!

Антоний

Йә, әйдәгез, тотынышып кулны кулга
Басыйк тизрәк әйләп-бәйләп уенына.
Җәһәтрәк, юкса хәзер шәраб батыр
Мәлҗерәтеп йоклатачак берәм-берәм.

Энобарб

Йә, әйдәгез, кулны кулга! Уенчылар!
Көйләрегез тилертерлек дәртле булсын.

Ә син, малай, җыр башларсың, кушымтасын
Барыбыз да күтәреп алыйк бертавыштан.

Музыка. Энобарб, кулларыннан җитәкләп, барысын да түгәрәккә бастыра.

Җыр

Юмарт шәраб алласы,
Без дә адәм баласы.
Эчерт безне, ләх яса,
Бик күңелсез ләбаса.
Касәгә шәраб аксын
Кайгылар шунда батсын.
Бернәрсәгә карама,
Әйдә, безнең арага!
Әйдә, Бахус, күңел ач,
Күңелсез син булмагач.

Цезарь

Ярый, булды. Тыныч йокы сиңа, Помпей.
Йә, каенагай, әйдә, киттек, озатып куям.
Артык шаулап күңел ачу килешеп бетмәс.
Дәрәҗәңне онытма син, болай да әнә
Эчкән шәраб кызуыннан битең яна.
Энобарб, хәтта ул да изрәп төшкән,
Мин дә телне көч-хәл белән әйләндерәм.
Шамакайга әверелгәнбез барыбыз да,
Һәрнәрсәдә чама кирәк. Тыныч йокы.
Әйдә, Антоний.

Помпей

Ярый, әмма ярга чыккач,
Очрашуны өр-яңадан кабатларбыз.

Антоний

Каршы түгел, мин риза. Бир кулыңны!

Помпей

Минем туган йортны тартып алсаң да син,
Без барыбер дуслар хәзер. Көймәгә төш.

Энобарб

Ипләбрәк, юкса суга капланасыз.
Ә мин калам.

Менас

Әйдә, минем каютага.
Әй, быргылар, барабаннар, йә, әйдәгез,
Аллаларга кадәр җитсен гөрелтегез!
Башлыкларны безнең ничек озатканны
Күрсен Нептун. Җәһәтрәк селкенегез!
Селкенегез инде бераз, ни торасыз?
Башлыйсызмы, юкмы, шайтан алгырлары?

Быргы, барабан тавышлары.

Энобарб

Ура! Әйдә, бүрекләрне күккә чөйик!

Менас

Э-he-he-heй! Киттек, иптәш. Әйдә киттек!

Китәләр.

Өченче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сүрия тигезлеге. Җиңү маршы астында Вентидий, Силий һәм башка Рим хәрби начальниклары, сугышчылар уза. Гаскәр алдыннан Парфия
патшасының улы Пакорның үле гәүдәсен алып баралар.

Вентидий

Тар-мар килдең, о, Парфия, уклар иле.
Красс өчен тулысынча үч алынды.
Китерегез үтерелгән шаһзадәне,
Үз күзләре белән күрсен һәркем аны.
Күрдеңме, Ород, Красс гомере нинди кыйммәт,
Корбан иттең аның өчен үз балаңны.

Силий

Кылычыңда дошман каны кипмәс борын,
Ку, Вентидий, син аларны, тын алдырма.
Себереп түк ике елга арасыннан,
Мидиягә эзләрен дә бастырттырма.
Һәм Антоний үз куллары белән сиңа
Җиңү тажы кидерәчәк шул чагында.

Вентидий

Ә, юк, Силий, җитеп торыр, шуны онытма:
Безнең кебек билбөгәргә башлыгыңнан
Арттырып дан казанырга һич ярамый.
Юлбашчыңның күләгәсе астындарак
Йөри белү безнең өчен файдалырак.
Антоний да, Цезаре да күпме җиңү
Яуладылар әнә кеше кулы белән
Һәм шуңа да карамастан миннән алда
Сүриядә баскак булып торган Соссий,
Данга хирыс булганлыгы өчен генә
Антонийның ачуына дучар булды.
Әгәр даның юлбашчыңның данын күмсә,
Юлбашчыңның юлбашчысы булачаксың.
Хуҗасыннан да уздырып дан казанса,
Шөһрәт сөйгән сугышчыга кайчагында
Җиңүеннән җиңелүе артыграк.
Антонийга бик күп файда эшләр идем,
Әмма куркам. Нигә, дисәң, хәтере калыр.
Һәм моңарчы яулап килгән җиңүләрем
Бер селтәүдә, булмагандай юкка чыгар.

Силий

Сугышчының кылычтан һич аермасы
Юк икәнен исбатладың син, Вентидий.
Инде хәзер Антонийга ни язарсың?

Вентидий

Шапырынмыйча, тыйнак кына итеп аңа,
«Синең бөек исемең белән канатланып,
Без көрәштә җиңеп чыктык, хөкемдарым,
Байракларың дошманнарның котын алып,
Безне алга дәште, шуңа парфяннарның
Сугышларда җиңелү белмәс җайдакларын
Тулысынча тар-мар иттек!» дип язармын.

Силий

Үзе кайда соң ул хәзер?

Вентидий

Афинага
Чыгып киткән ни өчендер. Безгә анда
Антонийдан элегрәк булу кирәк.
Шуңа күрә кичекмәстән юлга чыгыйк.
Йөк төягән олаулар бик йөдәтмәсә,
Өлгерербез дип уйлыймын. Йә, ашыгыйк!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рим. Цезарь йортының алгы бүлмәсе. Икесе ике яктан Агриппа белән Энобарб керәләр.

Агриппа

Йә, хушлашып туйдылармы ике туган?

Энобарб

Помпей китте. Тегеләр аннан котылуга,
Килешү төзеп, хәзер шуңа кул куялар.
Октавия аерылышу хәсрәтеннән
Үксеп-үксеп елый һаман. Цезарьның да
Чырае төксе, бик күңелсез. Лепид исә,
Моны миңа Менас әйтте, теге көнге —
Помпейдагы мәҗлестән соң айный алмый.

Агриппа

Зур мактауга лаек Лепид!

Энобарб
Искитәрлек!
Кеше генә түгелдер ул, могҗизадыр!
Цезарьны үзелеп яратуын күр син аның!

Агриппа

Антонийны ничек хөрмәт итә диген!

Энобарб

Цезарь кем ул? Цезарь җирнең Юпитеры!

Агриппа

Ә Антоний Юпитерлар Юпитеры!

Энобарб

О, Цезарьмы?! Аңа тиңнәр юк дөньяда!

Агриппа

О, Антоний! Коеп куйган Феникс кошы!

Энобарб

Ул — Цезарь дип әйтүдән дә зур мактау юк!

Агриппа

Мактауларга юмарт анысы, саран түгел,
Икесенә дә өлеш чыгара һәм шактый ук.

Энобарб

Ә Цезарьга аеруча. Антонийны
Җырчы, рәссам, чәчән, йолдыз санаучылар
Җырлап, ясап, сөйләп бирep һәм хисаплап
Күрсәтә алмас дәрәҗәдә яратса да,
Цезарьны ул Алла сыман итеп күрә,
«Цезарь!» дисәң, тезләнергә әзер хәтта.

Агриппа

Күренеп тора икесен дә яратканы.

Энобарб

Лепид — коңгыз, ә тегеләр — канатлары.

Бырғы тавышлары.

Чакыралар! Хуш, Агриппа, сау булып тор.

Агриппа

Хәерле юл сиңа, батыр Энобарб.

Читкәрәк китәләр.
Цезарь, Антоний, Лепид һәм Октавия керәләр.

Антоний

Ярый, җитәр, инде башка озатма безне.

Цезарь

Үз җанымның бер өлешен бирдем сиңа.
Күз караңдай сакла аны. Ә син, сеңлем,
Иреңә әйбәт хатын бул һәм сиңа булган
Өметемне тулысынча акла минем.
Кара, Антоний, безнең дуслык ныклыгына
Хезмәт иткән бу хәзинә тора-бара
Шул дуслыкны өзәр көчкә әверелмәсен.
Икебез дә яклаучысы булыйк аның.
Юкса аны ул сыйфатта файдалану,
Явызларча мәсхәрәләү генә булыр.

Антоний

Бу шикләрең белән мине рәнҗетәсең.

Цезарь

Әйтәсемне әйттем.

Антоний

Әмма аның өчен
Борчылырлык берәр сәбәп табу сиңа
Насыйп булмас, күпме генә тырышсаң да.
Ярый, сау бул. Аллалардан игелек яусын,
Рим халкы сиңа җанын фида кылсын.
Йә, кузгалыйк.

Цезарь

Хәерле юл сиңа, сеңлем!
Йомшак җилләр юлларыңда юлдаш булсын.
Ярый, сау бул, хәерле юл!

Октавия

Сау бул, абыем!..

Антоний

Безнең мәхәббәт языбыз, күз яшьләре —
Апрельдәге язгы ләйсән яңгыр аның.

Октавия
(Цезарьга)

Абыем, зинһар, Антонийның йорт-җиренә
Күз-колак бул. Аннан тагын...

Цезарь
Нәрсә тагын?
Октавия

Йә, кил әле, колагыңа әйтәм анысын.

Антоний

Буйсындыра алмый телен йөрәге аның,
Ә йөрәге — телсез, шуңа сөйли алмый.
Давылларда калган аккош баласыдай
Бәргәләнә, нишләргә дә белми хәзер.

Энобарб
(Агриппага, акрын гына)

Әллә Цезарь еларга ук җыена инде?

Агриппа
(Энобарбка, акрын гына)

Юк, маңгаен җыера шулай.

Энобарб
(Агриппага, акрын гына)

Мондый тамга
Кешенең түгел, хәтта атның ямен алыр.

Агриппа
(Энобарбка, акрын гына)

Юлий Цезарь үтерелгәч, Антоний да
Чак-чак кына үкереп елап җибәрмәде.
Брут мәетен күргәч, аның күзләреннән
Елга-елга булып хәтта яшьләр акты.

Энобарб
(Агриппага, акрын гына)

Ул елны ул томау белән изаланды.
Дошманнарын берәм-берәм харап итеп,
Күз яшендә юа барды ул аларны.
Мин еласам, миңа ышан, аңа ышанма.

Цезарь

Юк, сөеклем Октавия, борчылма син,
Хат язышып торачакбыз берөзлексез.
Вакыт кына мәҗбүр итә алмас мине,
Онытырга иң яраткан сеңлемне.

Антоний

Җитәр, Цезарь, кайсыбызның аны күбрәк
Яратуын исәпләргә әле иртәрәк.
Саубуллашыр алдыннан бер кочаклашыйк.
Менә хәзер аллаларга тапшырып сине,
Юлга чыгам.

Цезарь

Ярый, сау бул. Хәерле юл.

Лепид

Күк гөмбәзендә никадәр йолдыз булса,
Һәммәсе дә сезнең юлны яктыртсыннар.

Цезарь
(Октавияне үбеп)

Йә, хушлашыйк. Сау бул, сеңлем!

Антоний

Сау булыгыз!

Бырғы тавышлары. Барысы да китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Клеопатра сараеның бер бүлмәсе.
Клеопатра, Хармиана, Ирада һәм Алексас керәләр.

Клеопатра

Чапкын кайда?

Алексас

Ул керергә куркып тора.

Клеопатра

Менә ахмак!

Чапкын керә.

Кер, кер, курыкма.

Алексас

Патшабикә,
Син ачулы чакта, хәтта яһүди Ирод
Карый алмас иде сиңа, куркыр иде.

Клеопатра

Марк Антоний торса минем боерыкны үтәп,
Култыгына башын кыстырып китәр иде
Иродыгыз минем яннан.
(Чапкынга.)
Якынрак кил.

Чапкын

Мәрхәмәтле патшабикә!..

Клеопатра

Йә, күрдеңме?
Октавияне күрдеңме, дим?

Чапкын

Әйе, күрдем.

Клеопатра

Кайда?

Чапкын

Римда. Бик якыннан күрдем хәтта.
Цезарь белән Антонийның арасында
Минем алдан гына узды Октавия.

Клеопатра

Буйга ничек? Миннән озынмы?

Чапкын
Юк, тәбәнәк.
Клеопатра

Тавышы нинди? Көчлеме, әллә бик зәгыйфьме?

Чапкын

Чебен тавышы кебек кенә, ишетелми дә.

Клеопатра

Алай булса, яратуы күпкә бармас.

Хармиана

Яратуы? Аны ничек яратсын ул?

Клеопатра

Мин үзем дә шулай уйлыйм. Озакламый
Йөз чөерер ул тавышсыз кәтәнәдән.

Йөреше ничек? Кәттәлеге бармы бераз?

Чапкын

Аякларын көчкә сөйри. Аңлар хәл юк:
Әллә утырып тора шунда, әллә йөри.
Эчендә аның җаны юктыр, таш сын кебек.

Клеопатра

Ул кадәр үк булмас инде, алдыйсыңдыр?

Чапкын

Минем күзем үтәли күрә.
Хармиана. Монысы дөрес. Аның кебек үткен күзле Мисырда юк.
Клеопатра

Мин үзем дә күреп торам: үткен кеше.
Искитәрлек бернәрсәсе юк бит аның.
Чапкын аек фикер йөртә.

Хармиана
Бик тә аек.
Клеопатра

Яше аның ничәләрдә, шуны әйт әле?

Чапкын

Күпме диим? Тол калырга да өлгергәч...

Клеопатра

Тол калырга? Хармиана! Ишеттеңме?

Чапкын

Бер утызлар тирәсендә бардыр инде.

Клеопатра
Йөзе нинди? Озынчамы, түгәрәкме?

Чапкын

Туп шикелле түп-түгәрәк, бик шөкәтсез.

Клеопатра

Күп вакытта андыйларның акылы булмый.
Син чәчләрен күрдеңме аның? Нинди төстә?

Чапкын

Чәче коңгырт, ә маңгае шундый да тар.

Клеопатра

Менә алтын, ал да шуны, үпкәңне оныт.
Кырысрак булдым бугай сиңа бераз.
Үтә зирәк, булдыклы син, шуңа күрә
Килгән җиреңә кире озатам, җыен әйдә.
Тиздән хат та әзер булыр.

Хармиана
Әйбәт егет.
Клеопатра

Әйе, шулай. Тик, кызганыч, юкка гына

Әрләдем мин теге юлы ул мескенне.
Инде белдек: ул хатынның мин куркырлык
Бернәрсәсе юк икән ич.

Хармиана
Шикләнмә дә.

Клеопатра

Чапкынны әйтәм, чын матурлык, гүзәллекне
Ясалмадан аера белә.

Хармиана
Ничек инде,
Ул бит синдә бер генә ел хезмәт итми!

Клеопатра

Бер генә сүз сорыйсым калган... Ярый, соңыннан.
Хатлар әзер булгач, аны монда җибәр.
Шулай итеп, бәлки, эшләр рәтләнер.

Хармиана

Валлаһи, дип әйтәм сиңа — рәтләнә.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Афина. Антоний йортының бер бүлмәсе. Антоний белән Октавия керәләр.

Антоний

Юк, Октавия, сорама да, мөмкин түгел.
Андый гына хатасын мин кичерер идем.
Әле аннан зуррагын да, әмма монысын...
Ул Помпейга каршы тагын сугыш ачкан.
Өстәвенә васыять язып бар халыкка
Укыган шуны, әмма анда минем хакта
Бер кәлимә сүз юк икән юньле-башлы.
Мин күрсәткән хезмәтләрнең әйтми калу
Мөмкин түгелләрен генә әйтеп узган.
Аларын да саран гына мактаган ул,
Вакытын әрәм итеп озак тукталмаган.
Хәтта данлы җиңүләрем хакында да
Тешен кысып кына нидер мыгырдаган.

Октавия

Син ышанма, бәгърем, андый хәбәрләргә,
Ышансаң да, йөрәгеңә якын алма.
Шуны уйла: дошманлыкка юл куйсагыз,
Калачакмын мин ике ут арасында.
Ничек итеп ул чагында сезнең өчен
Ярдәм сорап ялварырмын аллаларга?
Алар миннән көләчәк бит, әгәр дә мин
Башта сиңа, аннан аңа җиңү сорап
Карашымны юнәлдерсәм күккә таба.
Бер-берсенә бәйләнми бит болар һич тә,
Капма-каршылык килешә алмый берничек тә.

Кем җиңсә дә минем өчен чиксез хәсрәт!

Антоний

Сөюеңнең кем күбрәк кадерен белсә,
Күңелеңне шуңа багла, Октавия.
Намусымны җуйсам, җуям үземне дә.
Ул хурлыкка төшеп синеке булганчы, мин
Бөтенләйгә синеке булмау юлын сайлыйм.
Әгәр безне килешсеннәр, дисең икән,
Ярый, тырыш, арадашлык итеп кара.
Ә мин сугыш хәстәрләрен күрә торам,
Тик хурлыгы абыеңа төшәр аның.
Ашык әйдә, юлга җыен, теләкләрең
Чынга ашсын, мин аларга киртә булмыйм.

Октавия

Рәхмәт сиңа. Инде хәзер мин зәгыйфькә
Бөек кодрәт ияләре көч бирсен дә,
Икегезне килештерү насыйп булсын.
Арагызда сугыш чыкса, җир ярылыр,
Аны бары тау-тау мәет кенә тутырыр.

Антоний

Бу гауганың сәбәпчесен тап та шуңа
Бөтенләе белән аудар ярсуыңны.
Сөюеңне кыл урталай бүлә алырлык
Тигез түгелдер, мөгаен, безнең гаеп.
Юлга җыен. Сайла хадимнәр үзеңә,
Юлыңа акча күп итеп ал, ал, жәлләмә.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Икенче бүлмә. Төрле яклардан Энобарб белән Эрос керәләр.

Энобарб

Йә, нинди яңалыклар бар, Эрос дус?

Эрос

Искитмәле яңалыклар.

Энобарб

Ә атап әйткәндә.
Эрос. Цезарь белән Лепид яңадан Помпейга каршы сугыш ачканнар.
Энобарб. Иске яңалык бу. Йә, кайсы як җиңгән соң?
Эрос. Цезарь Лепид булышлыгы белән Помпейны җиңгән, әмма хәзер ул аны үзенә тиң итми, ди, шуңа күрә җиңү тантанасына да катнаштырмаган, данны үзенә генә алмакчы икән. Өстәвенә Лепидның Помпейга язган әллә кайчангы хатларын сәбәп итеп, аны дошман белән бәйләнештә торган җинаятьче дип игълан иткән дә кулга алдырган. Менә хәзер бичара триумвир (дөньяның өчтән бере) йозак астында үлем килеп коткарганчыга кадәр тилмереп ятачак инде.

Энобарб

Хәзер дөнья ике башлы ерткыч сыман,
Күпме генә туйдырсаң да барыбер алар
Берсен-берсе чәйнәячәк. Кайда Антоний?

Эрос

Бакчада ул арлы-бирле йөренә һаман,
Коры-сары ботакларны тибеп очыра.
«Помпей өчен үч алам», — дип антлар итә.
Котыргандай: «Юләр Лепид!» — дип кычкыра.

Энобарб

Безнең флот әзер тора...

Эрос

Италиягә.
Һәм Цезарьга каршы сугыш башлар өчен.
Кара инде, телгә бетеп торам икән,
Мине Антоний синең арттан җибәрде бит.
Яңалыклар качмас иде соңыннан да.

Энобарб

Борчылма ла. Нәрсә булса, шул булыр дип,
Әйдә барыйк.

Эрос

Киттек әйдә. Минем арттан.

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Рим. Цезарь йортының бер бүлмәсе. Цезарь, Агриппа һәм Меценат керәләр.

Цезарь

Ул Римны күрәләтә мыскыл итә.
Искәндәриядә ни кыланган, беләсезме?
Көмеш белән йөгертелгән күперчектә
Икесенә ике алтын тәхет куйдырып,
Клеопатра белән янәшә утырганнар.
Алларына утыртканнар Цезарионны,
Ягъни миңа әти тиешле кешенең улын.
Аның янына утыртканнар янә тагын
Үзләренең теге уйнаштан туганнарын.
Һәм ул шунда чикләнмәгән власть биреп,
Кәнтәенә бүләк иткән Мисыр тәхетен.
Ул гынамы? Әле тагын өстәп биргән
Лидияне, Фаластинны, Сүрияне.

Меценат

Һәм ул моны ачыктан-ачык эшләгәнме?

Цезарь

Ат чабышы бара торган зур мәйданда,
Көпә-көндез бөтен шәһәр халкы алдында
Теге ике көчегенең икесен дә

Патшаларга патша итеп игълан иткән.
Искәндәре әрмәннәргә, Мидияга,
Парфияга хуҗа хәзер, Птолемейы
Финикия, Киликия һәм Кипрга.
Ә Клеопатра нәкъ шул көнне изге Изида
Киемендә күренергә җөрьәт иткән
Һәм беренче мәртәбә дә түгел икән.

Меценат

Рим халкын җыеп моны сөйләп бирик.

Агриппа

Инде күптән аның борын чөюенә
Эче пошып йөрегән халык йөз чөерсен.

Цезарь

Халык белә. Антонийның дәгъваларын
Тулысынча игълан иттек.

Агриппа

Нинди дәгъва?
Кемнән нәрсә дәгъвалый ул?

Цезарь

Инде миннән.
Сицилияне яулап алып, имеш тә, мин
Хәләл өлешен аның бирми калдырганмын.
Аннан бурычка алып торган корабларны
Кайтармауны сылтау итә һәм, ниһаять,
Мал-мөлкәте тартып алынып, вазифадан
Мәхрүм калган Лепид эшен — законсыз, ди.

Агриппа

Инде җавап бирергә кирәк моңа, Цезарь.

Цезарь

Җавап әзер һәм чапкын да күптән юлда.
Лепидны мин бик рәхимсез, кансыз, дидем.
Аңа ышанып тапшырылган властьтан да
Явызларча файдаланды, шуңа күрә
Уртак эшкә шактый гына зыян салгач,
Триумвират эшләреннән азат иттем.
Өстәп тагын шуны әйтәм: әгәр дә син
Үзең яулап алган барлык өлкәләрдән
Миңа өлеш чыгарырга риза булсаң,
Яулап алган җирләремне синең белән
Бүлешергә мин һәрвакыт әзер, дидем.

Меценат

Ул беркайчан андый эшкә бармаячак.

Цезарь

Ул чагында инде үзенә үпкәләсен.

Хадимнәрен ияртеп, Октавия керә.

Октавия

Сәлам сиңа, абыем һәм хөкемдарым!

Цезарь

Кемне күрәм? Әллә ирең ташладымы?

Октавия

Алай дияр өчен әлегә сәбәпләр юк.

Цезарь

Ни өчен син кача-поса килеп кердең?
Цезарь сеңле икәнеңне оныттыңмы?
Син Антоний хатыны бит, нигә сине
Меңәрләгән гаскәр юлда озата килми?
Килгәнеңне үзең түгел, ерактагы
Атлар кешнәп белдерергә тиеш иде.
Фәйтуныңнан күтәрелгән тузан болытын
Күрер өчен агачларга үрмәләгән
Ачыгавыз күзәтчеләр күплегеннән
Авырсынып агачларның ботаклары
Җиргә кадәр сыгылырга тиеш иде.
Ә син авыл хатыныдай килеп кердең.
Һәм халыкның сиңа булган мәхәббәте
Эчтән тышка чыга алмыйча пыскып калды.
Мәхәббәткә ирек кирәк, бикләп тотсаң,
Тора-бара ул да сула, сүнә башлый.
Һәр адымың мең сәламләү авазына
Әверелсен өчен, бүген сине монда
Юлларыңа каршы чыгып бөтен халык
Каршыларга тиеш иде җирдә, суда.

Октавия

Үз ирегем белән шулай кайтып кердем,
Мине мәҗбүр иткән кеше юк, абыем.
Сине сугыш хәстәренә керешкән, дип,
Авыр хәбәр ирештерде миңа ирем.
Һәм шунда ук Антонийдан кире Римга
Җибәрүен үтендем мин һәм ул күнде.

Цезарь

Синнән башка себерелергә җайлы булсын
Өчен генә җибәргән ул сине монда.

Октавия

Алай димә, зинһар, абыем.

Цезарь

Барын беләм.
Ни кылганын җилләр миңа китереп тора.
Йә, әйт әле, менә шушы минутта ул
Кайда хәзер?

Октавия

Ничек кайда? Афинада.

Цезарь

Ә, юк, сеңлем! Син бик каты алдангансың.
Клеопатра үз янына дәшкән аны.
Хакимлекне шул кәнтәйгә тапшырган ул.
Инде хәзер бөтен шәрык патшаларын
Җыйганнар да миңа каршы котырталар.
Каппадокия хөкемдары Архелай да,
Фракияле Адаллас һәм гарәп Малх,
Понта, Ирод, Митридат та килгән хәтта,
Пафлагония хөкемдары Филадельф,
Ликаония һәм Мидия патшалары
Аминта, Полемон һәм башкалар, һәм башкалар.
Барысы да, барысы да алар яклы.

Октавия

Кайгы килде! Нишлим хәзер? Ни хәл итим?
Йөрәгемне кыл урталай ярып салдым
Дошманлашкан ике җан дус арасына.

Цезарь

Онытып та торам икән, рәхим ит!
Чын күңелдән кайтуың белән котлыйм сине.
Миңа язган хатларыңда сораганча,
Әлегә кадәр мин араны өзми килдем.
Инде сине шушы хәлдә күрә торып,
Артык сузу мөмкин түгел. Бу — куркыныч.
Син алдандың, әмма, сеңлем, түземле бул.
Тормыш синең җилкәләргә котылгысыз
Сынауларын салган өчен бик көенмә.
Күз яшьләрең түкми генә, тулысынча
Язмышыңа тапшырыл син, өмет өзмә.
Бу дөньяда иң кадерле кешем тик син.
Хурлыкларың күтәргесез авыр, әмма
Хурлаучыга җәза бирер вакыт җитә.
Һәм аллалар бу изге эштә үзләренә
Корал итеп безне сайлар. Куан, сеңлем.
Рәхим ит! Синең кайту бәйрәм безгә.

Агриппа

Кайтуың белән котлыйм сине, Октавия.

Меценат

Рәхим ит. Рим халкы чын күңелдән
Чын ярату белән сине яраталар.
Марк Антоний гына сине читкә кагып,
Өстерәлчек бер кәнтәйгә алмаштырды.
Дилбегәне тапшырып шул кәнтәенә
Бар дөньяны болгаттыра хәзер әнә.

Октавия

Болар бар да дөресме соң, әйтче, абыем?

Цезарь

Кызганычка каршы, дөрес, сеңелкәем.
Тик сабыр бул, үтенәм синнән. Инде хәзер
Тагын бер кат кайтуың белән! Рәхим ит!

Китәләр.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Акциум борыны тирәсендә Антонийның гаскәре урнашкан урын. Клеопатра һәм Энобарб керәләр.

Клеопатра

Моның үчен алачакмын, онытыр димә.

Энобарб

Нинди үч ул? Ни өчен? Ни өчен?

Клеопатра

Мине гаскәр белән йөртү тиеш түгел.
Бу — мәсхәрә, дидең.

Энобарб

Нигә, тиешмени?

Клеопатра

Бу сугышта Мисыр сезгә төп теләктәш,
Ничек биредә булмасын ди минем урын?

Энобарб

Җавабым шул: айгырлардан тыш гаскәрдә
Бияләр дә асрала торган булса,
Айгырлардан мәгънә көтмә, һәммәсе дә,
Кызу сугыш барган чакта, бияләргә
Сикерәчәк җайдаклары-ние белән.

Клеопатра

Нәрсә һаман мыгырдыйсың?

Энобарб
Антонийның
Зиһене генә чуалачак син барында.
Аның хәзер акылын, көчен, игътибарын
Сиңа сарыф итә торган чагы түгел.
Болай да аны җилкуарга исәплиләр.
Әнә Римда бу сугышны үзе түгел,
Синең хәрам агаң белән асрауларың
Алып бара икән диеп сөйлиләр, ди.

Клеопатра

Телләренә тилчә генә чыксын тизрәк!
Минем халкым бу сугышта катнашканга,

Патшабикә буларак мин ирләр белән
Бер үк сафта көрәшергә карар кылдым.
Сүз кайтарма! Мин барыбер монда калам!

Энобарб

Бетте. Дәшмим. Хаким үзе килә монда.

Антоний һәм Канидий керәләр.

Антоний

Могҗизадыр бу, Канидий, син күр әле!
Брундизий белән Тарентны калдырып ул,
Ион диңгезе аша кичеп, шул арада
Торинаны алган, имеш. Мин шаккатам!
Бу турыда ишеттеңме син, сөеклем?

Клеопатра

Өлгерлеккә ялкау гына тел шартлата.

Антоний

Дөрес әйттең! Хатын-кызга хас булмаган
Дәрәҗәдә каты шелтә. Әй, Канидий,
Без диңгездә сугышачакбыз аның белән!

Клеопатра

Әлбәттә, шулай! Тик диңгездә!

Канидий
Ә ни өчен?
Антоний

Ул диңгездә сугышырга дәшә безне.

Энобарб

Харап икән! Син үзең дә кайчандыр бер
Аны шулай дәшкән идең түгелме соң?

Канидий

Юлий Цезарь Помпей белән алышканда,
Син дә аны дәшкән идең бит Ферсалда
Кара-каршы сугышырга — кире какты.
Үзенә җайлы булса гына сугыша ул,
Син дә шулай аның кебек хәйләкәр бул.

Энобарб

Корабларда безнең җыен әтрәк-әләм,
Диңгезче дип әйтерлеге юк аларның:
Кичә генә куып китереп утыртылган
Оешмаган сукачылар, көтүчеләр.
Ә Цезарьда Помпей белән сугышларда
Чыныгу алган тәҗрибәле диңгезчеләр.
Кораблары бар да җиңел, тизйөрешле,
Синекеләр шыксыз авыр, борыла алмыйлар.
Шуңа күрә, диңгез сугышын кире кагып,
Коры җирдә генә сугыш, ояты юк.

Антоний

Юк, диңгездә! Тик диңгездә!

Энобарб

Хөкемдарым!
Командалык сәләтеңне күбрәк җирдә
Күрсәттең син бер-бер артлы җиңү яулап.
Цезарь сүзенә карасаң әгәр, шул даныңа
Гаскәрләреңарасында шик туачак.
Күпне күргән сугышчылар нәрсә уйлар?
Гаскәреңнең бер өлешен корабларга
Төяп аның көчен генә таркатасың.
Һәм шулай ук командалык сәләтеңне
Бу сугышта файдаланмый калачаксың.
Ник уңышка илтә торган юлны ташлап,
Язмышыңны хәвеф кулына тапшырырга?

Антоний

Тик диңгездә сугышачакмын. Әйттем — бетте.

Клеопатра

Минем дә әнә алтмыш кораб әзер тора.
Цезарьныкы ише генә түгел алар.

Антоний

Корабларның артыкларын яндырып, без
Гаскәрләрен калганнарга бүлгәләрбез.
Һәм Цезарьны Акциум борыны тирәсендә
Бик әйбәтләп каршыларбыз. Инде әгәр дә
Суда җиңү насыйп түгел икән безгә,
Коры җирдә сынашырбыз.

Чапкын керә.

Йә, ниләр бар?

Чапкын

Син ишеткән хәбәр дөрес, хөкемдарым,
Торинага кергән Цезарь, ачыкладым.

Антоний

Ул үземе? Мөмкин түгел. Әле ничек
Гаскәрләре барып җиткән? Шуңа аптырыйм.
Әй, Канидий, унтугыз легион җәяүле һәм
Унике мең атлы гаскәр ярда кала.
Алар синең карамакта, син — җаваплы.
Без — корабка. Киттек әйдә, Илаһиям!

Өлкән яшьтәге сугышчы керә.

Әйтер сүзең бармы, картлач, кил, әйтеп кал.

Сугышчы

Хөкемдарым, эш түгел бу диңгез сугышы,
Язмышыңны салма черегән такталарга.
Менә кылычым, яраларым, шуларга ышан.
Авыр чакта таянып булмый дулкыннарга.

Суда әнә Финикия, Мисыр халкы
Үрдәк кебек быкырдасын. Римлылар
Җиргә басып, аяк терәп сугышырга
Һәм җиңәргә өйрәнгәнбез.

Антоний

Ярый, җитәр!
Барыгыз да корабларга, йә, кузгалдык!

Антоний, Клеопатра һәм Энобарб китәләр.

Сугышчы

Геракл белән ант итәмен, мин хаклы бит.

Канидий

Син хаклысың, әмма безнең юлбашчыбыз
Үз-үзенә хуҗа түгел, ул — тезгендә.
Шуңа күрә барыбыз да бүген монда
Бер хатынның ялчылары: ул да, без дә.

Сугышчы

Коры җирдәге гаскәрләргә син башлыкмы?

Канидий

Җәяүле һәм атлы гаскәр минем кулда,
Ә диңгездә командаллар дүртәү: Целий,
Марк Октавий, Публикола, Марк Юстий.
Син Цезарьны күрче, ай-һай, елгыр да соң!
Күз иярмәс тизлек белән хәрәкәт итә!

Сугышчы

Үзе Римнан чыкмас борын ук гаскәрләрен
Вак-вак төркемнәргә бүлеп алга озаткан.
Күзәтчеләр аны-моны уйламаган,
Гаскәр шулай шыпырт кына алга барган.

Канидий

Гаскәр башы кем аңарда?

Сугышчы

Тавр диме.

Канидий

Ah, менә кем? Беләм, беләм. Таныш кеше.

Чапкын керә.

Чапкын

Канидий, тиз, хөкемдарга кирәк булдың.

Канидий

Минут саен бер яңалык туып тора,
Нәрсә генә килеп чыкты икән тагын?

Китәләр.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Акциум борыны тирәсендәге тигезлек.
Хәрби җитәкчеләрен ияртеп, Цезарь һәм Тавр керәләр.

Цезарь

Тавр!

Тавр

Тыңлыйм.

Цезарь

Диңгездә яу басылмыйча,
Коры җирдә берүк сугыш башлый күрмә.
Менә төргәк: анда минем күрсәтмәләр,
Һәммәсен дә төгәл үтә, бүген безнең
Язмышыбыз хәл ителә бу сугышта.

Китәләр.

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шул ук тигезлекнең икенче өлеше. Антоний белән Энобарб керәләр.

Антоний

Атлы гаскәрне урнаштыр үр артына,
Капма-каршы торсын Цезарь гаскәренә.
Сугыш барышын күзәтергә мөмкин аннан,
Ул урыннан диңгез өсте әйбәт күренә.
Ә калганын хәл итәрсең сөйләшкәнчә.

Китәләр.

УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шул ук тигезлекнең башка урыны. Канидий үзенең гаскәре белән сәхнәнең бер ягына, Тавр үзенең гаскәре белән сәхнәнең икенче ягына узып китәләр. Алар
узып китүгә, диңгездә сугышкан тавышлар ишетелә башлый.
Энобарб керә.

Энобарб

Бетте! Бетте! Бар да бетте! Кәһәр сукты!
Клеопатраның корабы «Антониада»
Сугышның иң кызган чагын сайлап кына
Яу кырыннан койрык борып читкә шылды.
Барча Мисыр кораблары — алтмышы да
Моны күреп шундук аңа иярделәр.
Бу хурлыкка ничек түзим, йә аллалар,
Күзләремне чыгарсагыз иде минем.

Скар керә.

Скар

О, аллалар! Алиһәләр! Илаһи затлар!

Энобарб

Нигә шулай үкерәсең, ни булды, Скар?

Скар

Ярты дөнья китте кулдан! Үбешүләр,
Гыйшык-мыйшык уенына алдандык без!

Энобарб

Сугыш ничек бара анда?

Скар

Ничек барсын?!
Үләт чире кырган кебек кырылабыз!
Күтләк мисыр биясенә ләгънәт яусын!
Сугыш кызып уңыш белән уңышсызлык
Игезәкләр күк безнең алда торган чакта,
Инде җиңү менә-менә безнең якка
Авышам дигән иң җаваплы бер минутта,
Җилкәннәрен киерде дә кинәт кенә,
Кигәвеннән куркып качкан сыер сыман,
Койрыгын сыртка салып шылды җан-фәрманга!

Энобарб

Күрдем, әмма ул газаплы күренешкә мин
Озак карап тора алмадым.

Скар

Ул китүгә,
Аның сихере тәэсирендә Антоний да,
Төгәлләми-нитми хәтта сугышны да,
Чаты ачылган үрдәк күргән дуадактай,
Киереп җилкән канатларын алга очты.
Мондый хурлык күрмәдем мин гомеремдә дә,
Намусы да, исеме дә, җисеме дә
Пычракка тәгәрәде.

Энобарб

Бәла, бәла!

Канидий керә.

Канидий

Өметебез дулкыннарда тыпырчына,
Көч-хәл белән сулыш ала — батып бара.
Әгәр безнең юлбашчыбыз ахыргача
Үзе булып калган булса, җиңәр идек,
Куркакларча гаскәрләрен ташлап качкач,
Үзеннән үк үрнәк алыйк.

Энобарб

Алай, алай...
Әнә ниләр сайрыйсың син, димәк, беттек.
Ул чагында сау булыгыз һәм вәссәлам.

Канидий

Пелопоннес тарафына ычкынды алар.

Скар

Ерак түгел. Мин дә шунда юл тотармын.
Ахыры нәрсә белән бетәр, карап карыйк.

Канидий

Мин Цезарьга тапшырам бар гаскәремне,
Миннән алда алты патша тапшырган күк.

Энобарб

Акылым минем теләгемә каршы килә,
Тик шулай да Антонийның яраланган
Фаҗигале язмышына тартыла күңел.

Китәләр.

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Сарай залы. Сарай хадимнәрен иярткән, Антоний керә.

Антоний

Минем өчен оялудан, ишетәсезме,
Җир сыкрый, ыңгыраша, елый, ахры.
Аны таптап йөрүемнән хурланадыр,
Антонийны күтәрергә теләми ул.
Тирә-ягым дөм караңгы, инде, дуслар,
Юл табарлык кодрәтем юк бу дөньяда.
Яр буенда алтын төягән корабым бар,
Алыгыз шуны. Бүләк итәм. Бар да сезгә.
Казна малын бүлешегез һәм качыгыз.
Цезарь белән килешерсез, кабул итәр.

Барысы бергә.

Качаргамы? Анысы булмас!

Антоний

Ә мин качтым,
Куркакларга да өйрәттем качу җаен.
Йә, хушлашыйк. Мин үземә юл сайладым,
Сезнең ярдәм кирәк түгел миңа бүтән.
Ашыгыгыз. Йөк корабта. Ул сезнеке.
О, янам мин! Оятымнан утта янам,
Ихтыярсыз ясап мине яу кырыннан
Иярткән китүчегә әгәр күз ташласам.
Хәтта чәчләрем үзара ызгышалар,
Берсен-берсе гаеплиләр булган эштә.
Ак чәчләрем караларга «Сукыр» дисә,
Каралары акларына «Дуамал» ди.
Йә, хушлашыйк инде, дуслар. Танышларга
Сезнең аша хатлар язып җибәрермен.
Алар сезгә юл ярачак теләсә кая.
Өметсез җан тәкъдим иткән киңәшләрдән
Баш тартмагыз. Йә, барыгыз. Үзен-үзе

Онытканны онытырга вакыт җитте.
Моннан туры йөгерегез сез диңгезгә,
Мин хәзинә бүләк итәм бүген сезгә.
Калдырыгыз мине тизрәк, йә, үтенәм!
Боерырга базмыйм бүтән, ялынам гына,
Йә, барыгыз инде, зинһар, үтенеп сорыйм!
Мин дә хәзер шунда төшәм, озакламам.

Утыра.

Клеопатраны култыклап, Хармиана белән Ирада керәләр, алар артыннан ук Эрос та күренә.

Эрос

Патшабикә, янына кил, тынычландыр.

Ирада

Шулай, шулай, патшабикә!

Хармиана

Әйе, әйе.

Клеопатра

Мин утырам. О, Юнона!

Антоний
Юк, юк, юк, юк!
Эрос

Бер күз сирпе, хөкемдарым.

Антоний
Ият! Ият!

Хармиана
Патшабикә!
Ирада

Мәрхәмәтле патшабикәм!

Эрос

Хөкемдарым! Хөкемдарым!

Антоний
Әйе... Цезарь...
Филипп сугышы вакытында, биюче күк,
Файдасызга кылыч болгап йөргән иде.
Ә шул көнне чандыр Кассий белән Брут
Икесе дә минем кулдан һәлак булды...
Ул тик боерык кына бирә белә иде,
Сугыш эшен аңламады беркайчан да.
Ә бүген ни?.. Хәер, миңа хәзер барыбер.

Клеопатра

Зинһар, миңа ярдәм итегез!

Эрос
Хөкемдарым,
Патшабикә нинди хәлдә, күрәсеңме?

Ирада

Патшабикә, янына бар. Юат бераз.
Ул акылдан яза бугай хурлыгыннан.

Клеопатра

Ярый, яхшы... Хәзер торам... Булышыгыз.

Эрос

Бераз гына кузгал инде, хөкемдарым,
Патшабикә якынлаша синең янга.
Ул башын да күтәрә алмый, көчкә атлый,
Берәр сүз әйт. Җан өр аңа, юкса үлә.

Антоний

Куркакларча качып китеп, үз данымны
Үзем төкереп таптадым мин. Хурлык! Хурлык!..

Эрос

Галиҗәнап, патшабикә биредә бит!

Антоний

О, Мисырның мәликәсе, күр, син мине
Нинди хәлгә төшердең, йә, шатлан әйдә.
Оятымнан күзләремне яшерәм синнән,
Ә үткәннәр көлгә әйләнде.

Клеопатра

Хөкемдарым!
Кичер минем җилкәннәрнең куркаклыгын.
Син дә аларга иярерсең дип уйламадым.

Антоний

Юк, син әйбәт белә идең йөрәгемнең
Ычкынмаслык булып сиңа береккәнен.
Син кузгалсаң, ихтыярсыз синең арттан
Барачагым сиңа көн күк ачык иде.
Җаныма да хуҗа булуың, бер ымласаң
Аллалардан баш тартырга әзер торуым
Сиңа күптән мәгълүм иде.

Клеопатра

Кичер мине.

Антоний

Инде миңа язмышларның төеннәрен
Чишеп-бәйләп, бу дөньяның кыл яртысын
Үз кулында тоткан кешегә, ялагайланып,
Түбәнлеккә төшә-төшә шул малайга
Илче җибәреп ялынырга туры килә.
Мине әсир иткәнеңне белеп тордың.
Мәхәббәтең җәтмәсендә кылычым да
Ирексездән юашланды, көчен җуйды.

Клеопатра

Кичер мине!.. Кичер мине!..

Антоний

Юк, елама.
Энҗе кебек күз яшеңнең бөртеге дә
Мин югалткан бар нәрсәдән кыйммәтрәк.
Бер үбүең кайтарачак һәммәсен дә,
Шуннан да зур бүләк булу мөмкин түгел.
Мин Цезарьга балаларның мөгаллимен
Илче итеп җибәрдем, ул кайтмадымы?
Ah, сөеклем, бу борчулар хәсрәтеннән
Тәнгә кургаш койган кебек, көчкә йөрим.
Ашап-эчеп алсаң иде бер, ичмаса.
Язмышыбыз катлаулана барган саен,
Аның белән көрәшү дә авырлаша.

Китәләр.

УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мисырда Цезарь гаскәре урнашкан урын.
Цезарь, Долабелла, Тирей һәм башкалар керәләр.

Цезарь

Антонийдан килгән кеше керсен әйдә,
Илче итеп кемне юллый?

Долабелла
Мөгаллимен,
Болай булгач, ярыйсы ук йолкынган ул.
Канатында, димәк, затлы каурыйлар юк.
Әле күптән түгел генә Антонийың
Патшаларны юллый иде йомыш белән.

Евфроний керә.

Цезарь
Якынрак кил.
Евфроний

Нинди генә булсам да, мин
Антонийдан илче булып килдем сиңа.
Әлегә кадәр, диңгездән бер тамчы төсле,
Бик кечкенә кеше идем аның өчен.

Цезарь

Ярый, анысы шулай булсын. Йомышың ни?

Евфроний

Язмышының хөкемдары итеп сиңа
Сәлам белән бергә Антоний үтенеч юллый:
Ул Мисырда калдыруыңны сорый үзен,
Әгәр мөмкин түгел икән, ул чагында
Бер билгесез кеше булып тыныч кына
Афинада яшәргә дә риза була.
Инде хәзер Клеопатра мәсьәләсе:
Көч-шөһрәтең алдында ул башын ия.
Язмышлары синең кулда. Үтенеп сорый

Балаларын таждан мәхрүм итмәвеңне.

Цезарь

Антонийның үтенечен кабул итмим,
Ишетәсем дә килми хәтта. Патшабикә
Исәп тотсын мәрхәмәткә. Вәгъдә итәм,
Тик ул башта мәсхәрәгә калган дустын
Үз җиреннән кусын яки җәзалатсын.
Шулай итсә, мәрхәмәтем чиксез минем,
Ярдәм кулы суза алам. Шул җавабым.

Евфроний

Юлларыңда гел уңышлар юлдаш булсын.

Цезарь

Каравыллар аша аны озатыгыз.

Евфроний китә.

Булды, Тирей, синең телгә осталыкны
Файдалы эшкә җигәр көн дә килеп җитте.
Ычкын тизрәк, Клеопатраны ничек булса,
Безнең якка аударырга тырышып кара.
Алтын тавы вәгъдә ит син миннән аңа.
Башыңа нәрсә килсә, шуны тик лыгырда.
Хатыннарның тотрыклысы булмый аның.
Тормыш кысса, әүлияң да түзми — аза.
Бар хәйләңне эшкә җигеп, елгыр кылан,
Бүләгенә ни сорасаң — шуны бирәм.

Тирей

Ярый, Цезарь, мин риза.

Цезарь
Антонийның
Үзен ничек тотуына игътибар ит.
Җиңелүен ничек кичерә? Кыланышыннан
Башындагы уйларын бел.

Тирей
Тырышырмын.
Китәләр.

УНӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Сарай залы.
Клеопатра, Энобарб, Хармиана һәм Ирада керәләр.

Клеопатра

Инде безгә ни кылырга, Энобарб?

Энобарб

Уйлап-уйлап торырга да үз-үзеңә
Кул салырга.

Клеопатра

Бу эшләрдә кем гаепле, Антониймы,

Әллә минме?
Энобарб
Бер Антоний.
Ул акылын нәфесенә кол ясады.
Син курыксаң да, кичерергә мөмкин сине.
Ике гаскәр бер-берсенең котын алып
Кара-каршы сугышканда, ул ник качты?
Дөньяның бер яртысына икенчесе
Нәгърә орып ташланганда (аның өчен),
Ул мәхәббәт кымыржуын командалык
Бурычыннан өстен куйды оялмыйча.
Дошманнарның күз алдында, ерып-ертып,
Синең арттан элдертүе безнең өчен
Җиңелүдән дә хурлыклырак булды ул чак.

Клеопатра

Тс-с-с... Әкрен. Үзе килә. Дәшмә, зинһар.

Антоний белән Евфроний керәләр.

Антоний

Җавабы шулмы?

Евфроний

Нәкъ шулай ди, хөкемдарым.

Антоний

Патшабикә әгәр мине тотып бирсә,
Ташламалар ясарга да сүз бирәме?

Евфроний

Шулай диде, галиҗәнап.

Антоний

Ул чагында
Үзенә дә аңлат әнә, ни торасың?
Әгәр минем чал башымны кичекмәстән
Шул селәгәй малай кулына җибәрттерсәң,
Патшалыклар вәгъдә итә сиңа Цезарь.

Клеопатра

Шушы башың өченме ул?

Антоний

Бар яңадан.
Һәм әйт аңа: күкрәп торган яшь чагында
Батырлыгы белән безне сокландырсын.
Көч һәм байлык куркакта да була кайчак,
Аның гаскәр башлыклары җиңәр иде
Сабый бала кулы астында булсалар да.
Гаскәрләрен онытсын да ул бер мәлгә,
Япь-яшь кеше, минем кебек картлач белән
Сугышырга чыксын, әйдә, кылыч тотып,
Тик бергә-бер. Киттек, хәзер хат та бирәм.

Антоний һәм Евфроний китәләр.

Энобарб
(читкә)

Шулай булмый! Җиңеп чыккан Цезарь хәзер
Гаскәрләрен таратыр да, кылыч тотып,
Гладиатор сыман уңга-сулга селтәп
Синең белән чәкәләшер, көтеп утыр!
Бер киргә китсә эшләр китә икән,
Бәхетен жуйса, акылын да жуя кеше.
Уңны-сулны чамаласаң уйла бераз:
Ничек итеп син үзеңдәй бушкуыкны
Цезарь хәтле Цезарь белән тиңләмәкче?
Гаскәреңне генә түгел, акылыңны да
Тәмам тар-мар иткән, ахры, Цезарь синең.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче

Патшабикә, илче килде, Цезарьдан, ди.

Клеопатра

Әнә ничек? Әдәп-мазар сакламыйча,
Турыдан-туры эш йөртә? Күрегезче,
Чәчәк бөресе күреп шуңа капланганнар
Шаулап чәчәк аткан гөлдән йөз чөерә.
Бар әйт, керсен.

Энобарб
(читкә)

Намус белән безнең ара
Болай булгач ызгышуга табан бара.
Үз акылыңны жуймый гына акылсызга
Тугры хезмәт итә алмыйсың, ә шулай да
Җиңелүгә дучар булган хөкемдарга
Ахыргача ихлас хезмәт иткән кеше
Тугрылыгы белән жиңеп хәтта жиңүчене
Тарихларга яза ала үз исемен.

Тирей керә.

Клеопатра

Йә, Цезарьның теләге ни?

Тирей

Ул турыда
Үзеңә генә әйтер идем.

Клеопатра

Хафаланма.
Чит кеше юк арабызда, дуслар гына.

Тирей

Һәм шулай ук Антонийның дуслары да?

Энобарб

Антонийның чын дусларга мохтаҗлыгы
Цезарьныкы ише генә микән әле.
Сугышу да, килешү дә — алар эше.
Юлбашчылар ни боерса шуны үтәү —
Анысы менә безнең бурыч.

Тирей

Ярый, яхшы,
Мактауга һәм данга лаек патшабикә!
Кайгы-хәсрәт, гамьнәреңнән арын тизрәк.
Цезарь синнән аның Цезарь икәнлеген
Хәтереңнән чыгармауны үтенеп сорый.

Клеопатра

Патшаларча әйтелгән бу. Йә, дәвам ит.

Тирей

Антонийның кочагына сөю түгел,
Сине курку этәргәнен Цезарь белә.

Клеопатра

О!

Тирей

Намусың яраланган, җәрәхәтле,
Шуңа да ул исемеңә тап төшүдән
Күңеле сызлап, синең өчен бик борчыла.

Клеопатра

Ул — Алладыр. Бар хакыйкать аңа мәгълүм:
Намусымны ирексездән җуйдым, ләкин
Җиңел генә бирелмәдем, нык көрәштем,
Әмма каршы тора алмадым.

Энобарб

(читкә)

Шулаймыни?
Антонийдан белешербез. Ah, командан!
Көймәңә су кереп бара түгелме соң?
Синең белән бергә төпкә китмәс борын,
Сөйгәнеңнән үрнәк алып, кичекмәстән,
Котылырга чара эзләр вакыт җитте.

Китә.

Тирей

Мин Цезарьга нәрсә диим, ни боерасың?
Теләгеңне үтәячәк шикләнмә дә.
Юмартлыгын күрсәтергә мөмкинлек бир,
Үтенеп сорый диярлек ул моны синнән.
Шатланачак әгәр дә син аның көчен
Таяныч итеп кабул итсәң үзең өчен.
Бу дөньяның ул бердәнбер хөкемдары.
Антонийдан йөз чөереп, син Цезарьны
Яклаучың дип кабул итсәң, ул чагында

Тормышка ашар иде аның бар хыялы.

Клеопатра

Исемең ничек синең, илче?

Тирей

Тирей атлы.

Клеопатра

Менә нәрсә, сөйкемле илче. Цезарьга әйт:
Җиңүче итеп танып аның кулын үбәм
Һәм тезләнеп хөкемдарның алларына
Үз тажымны куям аның аягына.
Мисыр аның хөкемендә. Хөкем көтәм.

Тирей

Иң дөрес юл синең, өчен шушы булыр.
Уңышсызлык биләп алган чакта безне,
Күпне көтми азга риза булган кеше
Акыллырак була, чөнки ул чагында
Билгесезлек куркыталмый беркайчан да.
Инде хәзер мин фәкыйрьне бәхетле ит:
Бурычымны үтәвемнең билгесе итеп
Бир кулыңны, мөһер салыйм кулыңны үбеп.

Клеопатра

Цезарьга әти тиешле кеше элегрәк,
Яңа сугыш планнары кора-кора,
Минем шушы мескен кулны берөзлексез
Үбә-үбә уйный иде заманында.

Тирей Клеопатраның кулын үбә. Антоний һәм Энобарб керәләр.

Антоний

Мин ни күрәм? О, Юпитер, дәһшәтле Алла!
Каян килдең? Кем син? Танмый әйт хәзер үк!

Тирей

Хөкемдарлар арасында буйсынырга
Иң лаек зат әмере белән килүче мин.

Энобарб
(читкә)

Эләгәчәк сиңа хәзер.

Антоний

Хезмәтчеләр!
Ишетмиләр, кабахәтләр! Әй, бирегә!
Кайда минем элекке көчем? Бер кычкырсам,
Бала-чага төсле шундук узыша-узыша,
Бер көтү патша: «Ни боерасың, хөкемдар?» — дип
Килеп җитә торган иде. Ә хәзер ни?!
Нәрсә, анда чукракланып беттегезме?

Хезмәтчеләр керәләр.

Мин Антоний әлегә монда, аң булыгыз!
Алыгыз бу шамакайны һәм ярыгыз.

Энобарб
(читкә)

Үлеп барган арысланның мыегын тартсаң,
Бала арыслан ише генә котырынмас.

Антоний

Ай, йолдызлар! Ни карыйсыз, ярыгыз үзен!
Ник Цезарьга буйсынучы патшаларның
Егермесе килми шунда... Мин аларны...
Кулларына орынган өчен, шушы, шушы...
Кем дип атыйм аны хәзер, әгәр дә ул
Клеопатра түгел икән?.. Ни торасыз?
Еларга дип авызын бөреп ялварганчы,
Каезлагыз.

Тирей

Марк Антоний...

Антоний

Тиз булыгыз!
Алып китеп арт сабагын укытыгыз.
Эше беткәч кире монда китерерсез,
Хуҗасына хат тоттырып җибәрербез.

Хезмәтчеләр Тирейны алып чыгып китәләр.

Беренче кат очрашканда, инде синең
Кырау төшеп сулып барган чагың иде.
Кем очраса, шуның белән төчеләнеп,
Миннән көлгән юньсез хатын кыланышына
Тавыш-тынсыз түзеп яшәр өчен, шулай
Хәләл хатыным түшәгеннән йөз чөереп,
Хак никахлы бер бала да тудырмыйча
Китеп бардым микәнни соң мин Римнан?!

Клеопатра

Хөкемдарым!..

Антоний

Синдәйләргә ышаныч юк!
Бер гөнаһка кереп чумсаң — бетте башың!
Ул чагында безне аллалар сукырайта,
Акылыбызны тартып алып җәзалагач,
Ялгыш юлга этәрәләр һәм үзләре
Көлә-көлә безнең ничек эре генә
Һәлакәткә баруыбызны күзәтәләр.

Клеопатра

Юк, мин башка түзә алмыйм бу хурлыкка.

Антоний

Мәрхүм Цезарь калдыгы син, өстәвенә
Помпей авыз иткән сине, калганнарын,
Кеше белми торганнарын санамыйм да.
Чөнки синең туймас дәртне басар өчен
Күп кирәге мәгълүм миңа. Син бит хәтта
«Тыелу» дигән сүзнең нәрсә икәнлеген
Күз алдына китерә алмыйсың.

Клеопатра

Йә, ни өчен?..

Антоний

Хуҗасының сөяк-сөяк ташлавына
Риза булып яшәүче бер ялагай этнең
Синең шушы миңа ләззәт бирә торган
Патша мөһере, хөкемдарлар анты кебек
Изге кулыңа ач талпандай ябышуына
Ничек түзеп торырга мөмкин тыныч кына?
Ачуымнан бер кычкырсам хәзер, тавышым
Базан тавы итәгендә утлап йөргән
Үгез көтүе үкерүен дә күмеп китәр.
Мин шашынган ерткыч сыман бу минутта.
Сәбәпләре җитәрлек һәм җитди булды.
Моннан соң да нәзакәтле булып калу
Асылучы шома, җитез аскан өчен
Җәлладына рәхмәт әйткән белән бер ул.

Хезмәтчеләр Тирейны алып керәләр.

Ярдыгызмы?

Беренче хезмәтче

Ничек кенә, хөкемдарым.

Антоний

Кычкырамы? Гафу-мазар сорыймы соң?

Беренче хезмәтче

Рәхим-шәфкать сорый синнән, галиҗәнап.

Антоний

Әгәр атаң исән булса, сиңа карап
Еласын бер син кыз бала булмаганга.
Һәм үзең дә, Цезарь эте булуың өчен,
Үкен тизрәк. Чыбыкны син шуңа ашадың.
Киләчәктә хатын-кызның кулын күргәч,
Бизгәк тоткан кеше сыман калтырарсың.
Бар, Цезарьга кайтып сөйлә, сине ничек
Кабул иткәннәрен монда һәм әйт аңа:
Һаваланып алай артык масаймасын,
Юкса түзеп торуның да чиге була.
Бүген нинди авыр хәлдә калуымны
Мәсхәрәләп кабат-кабат искә ала,

Элегрәк кем булуым турында ул
Юри онытып чыгырымнан чыгармакчы.
Минем йолдыз күчәреннән ычкынырга,
Җәһәннәмгә атылырга торган чакта,
Бу, әлбәттә, бик җиңел эш аның өчен.
Әгәр хуҗаң сине ничек сыйлаганны
һәм мин әйткән бу сүзләрне ошатмаса,
Ул чагында бәйрәм ашы кара-каршы.
Кул астында бүген аңа хезмәт иткән
Мин иреккә чыгарган кол Гиппарх бар,
Минем белән исәп-хисап ясар өчен,
Әнә шуны теләгәнчә җәзаласын.
Бу сүзләрне түкми-чәчми җиткер аңа,
Хәзер тизрәк ычкын моннан.

Тирей китә.

Клеопатра

Йә, булдымы?

Антоний

Ah, җирдәге аем минем, син дә сүндең,
Антонийның бетүе бу.

Клеопатра

Йә, дәвам ит.
Әйтәсеңне әйтеп бетер, ә мин көтәм.

Антоний

Син Цезарьга ярар өчен аның колына
Күз уйнатып, борыла-сырыла күтләкләндең.

Клеопатра

Мине начар беләсең син.

Антоний

Әйт алайса,
Әллә миннән суындыңмы?

Клеопатра

О, сөеклем!
Әгәр дә мин суынган булсам, ул чагында
Күкләр минем бозга әйләнгән йөрәгемне
Агулы боз кисәкләре итеп ваклап
Бер кисәге белән миңа бәрсеннәр дә
Газиз җаным шул боз белән эреп аксын.
Икенчесе Цезарионны һәлак итсен.
Боз ташкыны җир йөзеннән токымымны,
Мисыр халкын пыран-заран китереп кырсын.
Мәетләре, чебеннәргә азык булып,
Күмелмичә тирә-юньдә череп ятсын.

Антоний

Ярый, җитте, ышандырдың. Инде тыңла:

Цезарь килә безнең өскә. Искәндәрия
Чолганышта калмас борын, кичекмәстән
Туктатырга кирәк аны юлына чыгып.
Аның белән алышырга мөмкин әле.
Коры җирдә без һәрвакыт көчле идек.
Безнең таркау флот, ниһаять, җыелып җитте.
Һәм сугышчан әзерлектә тора хәзер.
Әлегәчә кайда яттың, кыюлыгым?
Әгәр дә мин бу сугыштан исән чыксам,
Канга баткан булуыма карамастан,
Синең шушы иреннәрне үбәр өчен
Алларыңа киләчәкмен, патшабикәм.
Кылычым белән мин үземнең исememне
Мәңгелеккә уячакмын. Әле өмет бар.

Клеопатра

Менә кабат батыр итеп күрәм сине,
Элеккеге Антоний син бу минуттан!

Антоний

Мин берүзем өч кешегә торачакмын.
Рәхим-шәфкать көтмәсеннәр хәзер миннән.
Элегрәк сугышларда җиңгәннән соң,
Бер кызык сүз әйткән өчен генә дә мин
Әсирләрне азат итә торган идем.
Инде хәзер юлыма каршы төшкәннәрне
Тешне кысып җәһәннәмгә җибәрәчәкмен.
Әйдә бүген бу кичне без рәхәтләнеп
Күңел ачып үткәрик бер элеккечә.
Борыннары төшкән гаскәр башлыкларын
Чакырыгыз минем янга. Бокалларны
Шәраб белән тутырыгыз. Без яңадан,
Бердәм көлеп, төннең шомлы тынлыгына
Кызганмыйча һөҗүм итик шау-гөр килеп.

Клеопатра

Өстәвенә бүген минем туган көнем
Һәм мин аны бәйрәм итмәм дигән идем.
Өр-яңадан син — Антоний, мин — Клеопатра
Икән инде, ул чагында мөмкин, мөмкин.

Антоний

Әйтте диярсең, без җиңәбез бу сугышта,
Бәйрәм ясар көнебез безнең алда әле.

Клеопатра

Барлык гаскәр башларына бүген кичен
Үз янына җыелырга боера хаким.

Антоний

Әйе, әйе, шушы кичтә мин аларга
Карарымны игълан итәм. Ә аннары,

Яра җөйләренә кадәр кызарганчы,
Төне буе шәраб эчеп сыйлансыннар.
Күңелеңне төшермә син, патшабикәм,
Яшәү көче ташып тора әле бездә.
Мин сугышка ташланганны күреп, үлем
Сокланачак әле миңа, чөнки аның
Җан кыючы чалгысыннан күп мәртәбә
Үткенрәк, дәһшәтлерәк минем кылыч.

Энобарб кала. Башкалар чыгып китәләр.

Энобарб

Хәзер яшен каршында да күзен йоммас,
Курку хисен җуя кеше артык курыкса.
Соңгы чиктә күгәрчен дә гайрәтләнеп
Бөркетләргә ташланырга мәҗбүр була.
Хәзер безнең командованың батырлыгы
Акылын җую хисабына гына арта.
Ә акылдан мәхрүм калган батырлык ул
Тупасланган кылыч кебек, шуңа күрә
Аны ташлап китәр өчен җайлы форсат
Эзләр вакыт килеп җитте бугай миңа.

Китә.

Дүртенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия тирәсендә Цезарь гаскәре урнашкан лагерь. Кулына хат тоткан Цезарь, Агриппа, Меценат һәм башкалар керәләр.

Цезарь

Миңа маңка малай дигән, әйтерсең лә
Ул Мисырдан куып чыгара ала безне.
Илчемне дә чыбык белән суктырттырган
Һәм бергә-бер сугышырга чакыра мине.
Цезарь белән сугышырга, ишетәсезме?!
Кыланышы кырга сыймый, көлке хәтта.
Әгәр үлем эзләсәм, мин аннан башка
Юл табалмас дип уйлыйдыр, карт җәнҗалчы!

Меценат

Әгәр дә ки шундый ерткыч дулый икән,
Тәмам хәлдән тайдыргансың аны, димәк.
Тын алырга ирек бирмә. Бу форсаттан
Файдаланып кал тизрәк. Кызган чакта,
Ачудан кан баскан күзләр күрми башлый.
Саклануның ни икәнен оныта кеше.

Цезарь

Барлык гаскәр башлыкларын җыеп аңлат:
Иртәгә иң хәлиткеч зур соңгы сугыш.
Безнең гаскәр сафларында элегрәк
Антонийга хезмәт итүчеләр шактый,
Әнә шулар аны безнең тозакларга
Хәйлә белән алып керер. Күз-колак бул.
Гаскәрләрне бик һәйбәтләп хәзер сыйла,
Сый җитәрлек. Алар моңа күптән лаек.
Антонийны кызганам мин, ай, бичара!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Клеопатра сарае. Антоний, Клеопатра, Энобарб, Хармиана, Ирада, Алексас һәм башкалар керәләр.

Антоний
(Энобарбка)

Ул бергә-бер сугышудан баш тартамы?

Энобарб

Әйе.

Антоний

Нигә?

Энобарб

Ул ун тапкыр бәхетлерәк.
Һәм ун тапкыр көчлерәк дип саный үзен.
Бер кешегә каршы унау ярамый, ди.

Антоний

Коры җирдә дә, диңгездә дә сугыш ачып
Күрмәгәнен күрсәтермен иртәгә аның.
Йә мин исән калам анда, йә булмаса
Намусымны юып газиз каным белән
Мәңге үлемсез итәчәкмен. Ә син ничек?
Сугышырга теләк зурмы синдә, туган?

Энобарб

«Бер беткән баш бетсен!» — диеп бугаз ертып
Дошманнарга ташланырга әзер торам.

Антоний

Искиткеч шәп! Хезмәтчеләр керсен монда.

Хезмәтчеләр керәләр.

Безгә табын әзерләгез бүген кичкә,
Сый-хөрмәтне кызганмагыз, мулдан булсын.
Тугры хезмәт иттең миңа, бир кулыңны.
Һәм шулай ук син дә, дустым, син дә, син дә.
Миңа хезмәт иткән бик күп патшалардан
Намуслырак булдыгыз сез, рәхмәт сезгә.

Клеопатра
(Энобарбка)

Моны ничек аңларга соң? Бу ни тагын?

Энобарб
(Клеопатрага)

Бу кайгының ачылмаган бер сыйфаты.
Ул акылны мыскыл итеп, мәсхәрәләп
Әнә шулай шаярып ала вакыт-вакыт.

Антоний

Минем өчен армый-талмый йөгердегез,
Урыннарны алышасы иде хәзер:
Сез миңа, ә мин сезгә әверелсәм,
Тугры хезмәт итәр идем мин дә сезгә.

Хезмәтчеләр

Аллалар юл куймаячак андый эшкә!

Антоний

Миңа хезмәт итегезче, зинһар, бүген.
Бокалымны буш тотмагыз сез бу кичтә,
Мин яулаган халыкларның патшалары
Миңа хезмәт күрсәткән күк элегрәк
Йөгерә-йөгерә башкарыгыз мин кушканны.

Клеопатра
(Энобарбка)

Нишләмәкче була соң ул? Ни кылана?

Энобарб
(Клеопатрага)

Елатырга тырыша шулай якыннарын.

Антоний

Миңа хезмәт күрсәтегез сез бу кичтә,
Бәлки, соңгы хезмәтегез шушы булыр.
Башка мине күрә алмассыз, күрсәгез дә
Алдыгызда үзем түгел, мәетем торыр.
Бәлки, сезгә иртәгәдән яңа хаким
Боерык соңра боерык бирер, шуңа күрә
Яшь каплаган күзләремнең карашында
Сезнең белән саубуллашу ярылып ята.
Ышанычлы дусларым, мин сезне кумыйм.
Үлем генә аерыр безне бу дөньяда.
Үтенәм сездән, зинһар ике генә сәгать
Вакытыгызны кызганмагыз бүген миннән.
Мин артыгын сорамыйм да сезгә күкләр
Уны белән кайтарырлар моның өчен.

Энобарб

Сиңа аларны елатудан нинди файда?
Хатын-кызга әйләндердең безне тәмам.
Күрәсеңме, һәммәсе дә үкерәләр.

Мин ишәк тә, күзләремнән яшь агызып,
Шулар белән бергә үкерер хәлгә җиттем.

Антоний

Болай килеп чыгар диеп башыма да
Китермәгән идем хәтта, анттыр менә.
Ярый, ярый, сукранма. Күз яшегез
Изгелеккә әверелсен берүк, дуслар.
Тик сез мине никтер начар аңлагансыз.
Рухыгызны күтәрергә иде исәп.
Мәҗлес ясап шул мәҗлес яктысында
Төн карасын кудыртмакчы идем сездән.
Шикләнмәгез, мин ышанам килер көнгә
Алда безне үлем түгел, ә җиңүле
Якты тормыш көтә, дуслар. Йә, әйдәгез,
Бәйрәм итик, төн безнеке. Шик-шөбһәне
Шәраб белән юып төшерик күңелләрдән.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Сарай алды. Ике сакчы керәләр.

Беренче сакчы

Хәерлегә булсын, туган. Килер таңда
Безне нидер көтә сыман тоела миңа.

Икенче сакчы

Барысы да иртәгә хәл ителәчәк.
Бәхет телим. Син берни дә ишетмәдеңме?

Беренче сакчы

Юк, ә нәрсә?

Икенче сакчы

Гайбәт кенә булды, ахры.
Нәрсә генә лыгырдамый хәзер кеше.
Ярый, сау бул. Хәерле төн.

Беренче сакчы

Яхшы, туган.

Тагын ике сакчы керәләр.

Өченче сакчы

Үзеңә дә шуны телим. Сау булып тор.

Беренче һәм икенче сакчылар үзләренең күзәтү урыннарына китәләр.

Дүртенче сакчы

Безнең урын биредә булыр.

Өченче һәм дүртенче сакчылар сарайның икенче ягына сакка басалар.

Ah, иртәгә

Әгәр флот сынатмаса, коры җирдә
Без бирешмәс идек анысы.

Өченче сакчы

Шулай булмый.
Бик сугышчан халык бездә, гаскәр әйбәт.
Сайлап җыйган кебек бар да.

Сәхнә астыннан гобой тавышы ишетелә.

Дүртенче сакчы

Тс-с! Тукта әле!
Бу нәрсә бу?

Беренче сакчы

Ишетәсеңме?

Икенче сакчы

Нинди тавыш?

Беренче сакчы

Шомлы аһәң...

Өченче сакчы

Җир астыннан ишетелә.

Дүртенче сакчы

Нәрсә соң бу? Әйбәт фалмы?

Өченче сакчы

Юк, начар фал.

Беренче сакчы

Шаулама әле... Хикмәте ни икән моның?

Икенче сакчы

Антонийны яклаучы Алла Геракл бу,
Антонийны ташлап китеп бара шулай.

Беренче сакчы

Әйдә, барып белик әле, тегеләр дә
Ишеттеләр микән моны?

Икенче сакчы

Йә, ни хәлләр?
Ни дә булса ишетәсезме?

Барысы бергә

Әллә сез дә,
Әллә сез дә ишеттегез?

Беренче сакчы

Вәт могҗиза!

Өченче сакчы

Ишетәсезме? Ишетәсезме, туганкайлар?

Беренче сакчы

Хәрби хезмәт тәртипләре кушкан кадәр,
Әйдә, артыннан барыйк әле тыңлый-тыңлый.

Барысы бергә

Искиткеч хәл! Могҗиза бу! Чын могҗиза!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Клеопатра сараеның бер бүлмәсе. Антоний белән Клеопатра, Хармиана һәм башка Сарай хадимнәре керәләр.

Антоний

Эрос, минем коралларны китер тизрәк!

Клеопатра

Ят, йоклап ал!

Антоний

Юк, сөеклем. Эрос, тиз бул!

Хәрби киемнәр күтәреп, Эрос керә.

Көбә күлмәгемне кидер, сузма, дустым.
Уен-көлке белән ачуын китергәнгә,
Бәлки, бәхет бүген миннән йөз чөерер.
Җәһәтрәк!

Клеопатра

Йә, бир әле, үзем булышыйм.
Каптырмасы менә шулмы?

Антоний

Юк, кагылма!
Син бит минем йөрәгемнең хезмәтчесе,
Үз эшеңне генә кара, тимә, зинһар.

Клеопатра

Булышам гына. Менә шулаймы?

Антоний
Әйе, әйе.
(Эроска.)
Күрәсеңме, эшләр ничек әйбәт бара.
Бар үзең дә җыен, туган.

Эрос

Ярый, хәзер.

Клеопатра

Әллә начар каптырдыммы?

Антоний
Искиткеч шәп!

Ычкындырыр өчен аңа кем дә булса
Рөхсәтсез кагыла икән, ул кешегә
Башын саклап калу насыйп булмаячак.
Эрос, тиз бул! Нәрсә анда эреп актың?
Минем яңа хезмәтчемә күз сал әле.
Нинди җитез. Сиңа үрнәк булырлык ул!
Ах, сөеклем, минем ничек сугышканны
Карап тору насыйп булса иде сиңа
Һәм син анда ни дә булса аңлый алсаң,
Осталыкның ни икәнен күрер идең.

Кораллы сугышчы керә.

Йә, ни хәлләр? Утны-суны кичкәнлегең
Әллә каян күренеп тора синең, туган.
Без яраткан эшкә шулай иртүк торып
Сөенә-сөенә тотынабыз.

Сугышчы

Хөкемдарым,
Әле таң да беленмәгән, тик шулай да,
Баштанаяк коралланып инде күптән
Гаскәрләрең көтә сине яр буенда.

Шау-шу. Быргы тавышлары. Гаскәр башлыклары, сугышчылар керәләр.

Гаскәр башлыгы

Таң беленә. Мең яшәсен юлбашчыбыз!

Барысы да

Мең яшәсен юлбашчыбыз!

Антоний

Мин шат, дуслар.
Сезнең чакыру авазлары дәртле яңгырый.
Kaһарманга әвереләчәк сабый сыман,
Көн бик матур туды бүген иртә таңнан.
Шулай, шулай, менә рәхмәт, ярый, булды.
Инде хәзер хушлашырга вакыт безгә.
Дөнья хәлен белеп булмый, минем белән
Нәрсә генә булса да, син озак яшә.
Сугышчыга назлы сүзләр сөйләү хәрам.
Солдатларча бер үбим дә шушы корыч
Кушуы белән саубуллашыйк, патшабикә.
Кемнәр яуда катнашырга тиеш, шулар
Барыгыз да минем арттан. Ярый, сау бул.

Антоний, Эрос, гаскәр башлыклары һәм сугышчылар чыгып китәләр.

Хармиана

Үз бүлмәңә озатырга кушмыйсыңмы?

Клеопатра

Әйдә киттек. Күрдеңме, ул гаскәрләрен
Алып чыгып китте ничек гайрәтләнеп.
Ah, көрәшне тик бергә-бер сугышып кына

Хәл итсәләр икән әгәр Цезарь белән,
Ул чагында Антонийның... Ә бу көе...
Әйдә, киттек, Хармиана, озат мине.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәриядән ерак түгел Антоний гаскәрләре урнашкан лагерь. Быргы тавышлары. Антоний белән Эрос керәләр һәм өлкән яшьтәге сугышчы белән очрашалар.

Сугышчы

Күктән бәхет яусын бүген сиңа, Антоний.

Антоний

О, әгәр дә йөзеңдәге яра эзләре
Цезарь белән коры җирдә сугышырга
Мәҗбүр иткән булса мине теге чакта!

Сугышчы

Ул чагында хәзер синнән йөз чөергән
Патшаларның бик күбесе синең белән
Бер үк сафта булыр иде һәм шулай ук
Иң яраткан көрәштәшең, хөкемдарым,
Бүген таңда сиңа хыянәт итмәс иде.

Антоний

Ә кем миңа хыянәт итте?

Сугышчы

Иң якының.
«Энобарб!» дип кычкыр син менә хәзер,
Җавап булмас. Әгәр инде була калса,
Цезарь ягы тарафыннан киләчәк ул,
«Башка сиңа хезмәт итмим!» дигән аваз.

Антоний

Ни сөйлисең?

Сугышчы

Ул Цезарьга качты бүген.

Эрос

Хөкемдарым, аның барлык мал-мөлкәте
Биредә калган.

Антоний

Димәк, безне ташлап китте?

Сугышчы

Әйе, китте. Ант итә алам!

Антоний
Ул чагында

Тиененә кадәр санап мал-мөлкәтен
Кире үзенә җибәрт, Эрос, һәм яз аңа:
«Бәхет телим. Киләчәктә хөкемдарын
Ташлап китәр сәбәпләргә юлыкмасын».
Хатка үзем кул куярмын, китерерсез.
О, язмышым, син шулкадәр мәрхәмәтсез,
Иң намуслы юлдашымнан мәхрүм иттең.
Йә, бар, Эрос, кушканны үтә. — Энобарб!

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Искәндәриядән ерак түгел Цезарь гаскәрләре урнашкан лагерь. Быргы тавышлары. Цезарь, Агриппа, Энобарб һәм башкалар керәләр.

Цезарь

Вакыт җитте, әйдә, Агриппа, башла яуны.
Антонийны тере килеш алу кирәк.
Гаскәрләргә җиткер моны.

Агриппа

Тыңлыйм, Цезарь.

Цезарь

Күп калмады, көткән сәгать тиздән килер.
Бүген җиңсәк, бу дөньяның өч өлешен
Зәйтүн гөле күләгәсе каплаячак.

Чапкын керә.

Чапкын

Яу кырына чыкты Антоний.

Цезарь

Кичекмәстән
Агриппага тапшыр, Чапкын: качакларны
Алгы сафка урнаштырсын һәммәсен дә,
Ул чагында Антонийның һөҗүменә
Башлап алар эләгәчәк һәм Антоний
Үз-үзенә һөҗүм иткән кебек булыр.

Цезарь якыннарын иярtеп чыгып китә.

Энобарб

Алексас та хыянәт итте. Ул Антоний
Йомышы белән Яһүд җиренә киткән булган.
Әмма анда барып җиткәч, җайлап-майлап
Ул Иродны Цезарь ягына авыштырган.
Ә кайтуга Цезарь юмарт бүләкләгән:
Чатын-чатка каерып аяк-кулларыннан
Баганага кадакларга боерык биргән.
Канидийны иптәшләре белән бергә
Ул хезмәткә алган алуын, тик аларга
Ышанмый ул. Нинди этлек эшләдем мин!

Үз бәхетемә үзем төкереп, мәңгелеккә
Үз-үземне мәхрүм иттем мин бәхеттән.

Цезарьның бер сугышчысы керә.

Сугышчы

Энобарб, сиңа Антоний олау белән
Хәзинәңне җибәрттергән, хаты да бар.
Йөгер тизрәк, синең чатыр каршысында
Качырлардан шул малларны бушаталар.

Энобарб

Барысын да үзеңә ал, сиңа булсын.

Сугышчы

Ярый, көлмә, Энобарб, мин шаярмыйм.
Олаучыны кире озатып җибәр әнә.
Ә үземнең вакытым юк, сакта торам.
Хөкемдарың Юпитер күк юмарт икән.

Энобарб

Җир йөзендә иң әшәке кеше — мин ул.
О, Антоний, син юмартлык чишмәседер.
Хыянәтем өчен шулай бүләкләгәч,
Тугры калсам, син алтынга күмәр идең.
Изгелегең йөрәгемә пычак булды.
Шул ярадан үләчәкмен, әгәр дә мин
Башка чара таба алмасам алданрак.
Җитмәсә, бит сиңа каршы сугышырга
Тиеш бүген мин, Антоний. Юк, юк, булмас!
Соңга калмас борын тизрәк шакшы канау
Эзләп табыйм сузылып ятып тончыгырга.
Ул никадәр пычрак булса, үлемем дә
Хурлыклырак булыр минем шулкадәрле.

Китәләр.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капма-каршы ике гаскәр урнашкан сугыш кыры. Быргы, барабан тавышлары. Һөҗүм итүчеләрнең кычкырулары ишетелә. Гаскәр башлыкларын иярткән,
Агриппа керә.

Агриппа

Артык эчкә кергәнбез без. Чигенергә!
Чигенергә мәҗбүр булды Цезарь да әнә.
Мондый һөҗүм булыр диеп көтмәдек без,
Дошман көчле булып чыкты без көткәннән.

Китәләр. Сугыш шавы. Антоний белән яраланган Скар керәләр.

Скар

Менә, ичмасам, чын сугыш бу, хөкемдарым!
Әгәр башта ук шулай һөҗүм иткән булсак,
Авызларын, борыннарын канга батырып,
Күптән куган булыр идек без аларны.

Антоний

Тәмам канга баткансың син.

Скар
Ике ярам
«Т» хәрефе сыман иде, өченчесе
«ЭН» хәрефе ясады да куйды шуны.

Ераста бырғы тавышы.

Антоний

Бырғы тавышы. Чигенәләр булса кирәк.

Эрос керә.

Эрос

Алар кача. Инде безгә авыз тутырып
«Җиңдек!» диеп әйтергә дә мөмкин хәзер.

Скар

Куян куган сыман итеп ул этләрне
Эзләренә баса-баса эзәрлекләп
Тураклarга кирәк хәзер куып җитеп!
Куркакларны аулау үзе бер зур ләззәт.

Антоний

Ун бүләккә лаек иде батырлыгың,
Дәртле рухың өчен янә лаек булдың.
Йә, әйдәгез!

Скар

Бер аякта сикерә-сикерә
Барсам барам, сездән калмыйм. Киттек әйдә!

Китәләр.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия диварлары янында. Гаскәрләрен ияртеп, Антоний белән Скар керәләр.

Антоний

Без аларны өннәренә куып керттек.
Кем дә булса сөенечле хәбәр белән
Патшабикә хозурына чапсын хәзер.
Ә иртәгә, кояштан да алда торып,
Дошманнарның бүген исән калганнарын
Берәм-берәм җәһәннәмгә җибәрербез.
Һәрберегез Гекторга тиң каһарман сез!
Минем өчен түгел, гүя үзегез өчен
Сугышкандай сугыштыгыз, рәхмәт, дуслар.
Инде хәзер шәһәргә дә керергә мөмкин.
Хатын, бала-чагагыз һәм дусларыгыз
Ишетеп сезнең батырлыкны шатлансыннар.
Шатлык яше түгә-түгә өстегезгә,
Яу тузанын юсын алар йөзегездән.
Арагызда яралылар булса әгәр,

Ярларыгыз сезне үбеп дәваларлар.
(Скарга.)
Ә син, Скар, бир кулыңны, бир, тартынма.

Сарай хадимнәре белән Клеопатра керә.

Син күрсәткән батырлыкны бүген бөек
Алиһәгә сөйләп бирәм. Әйдә аннан
Рәхмәт ишетеп куан әле. Ah, күз нурым!
Минем тимер буып торган муеныма
Сарыл тизрәк, алчы мине кочагыңа.
Көбә күлмәк аша тизрәк күкрәгемә
Үтеп кереп йөгәнли күр йөрәгемне.

Клеопатра

О, син минем каһарманым! Шаһлар шаһы!
Батырлык һәм чиксез көчкә ия Аллам!
Усал язмыш тозагыннан ычкынуга,
Син елмаеп кайтып кердең.

Антоний
Сандугачым!
Бик күпләрне без мәңгелек йокыга дип
Җир куенына салдык бүген. Күр, сөеклем,
Чәчләремә чал төшүгә карамастан,
Безнең көчнең чыганагы — үткен зиһенем
Миңа хыянәт иткәне юк, шуңа күрә
Яшьләрне дә хур итәрлек көч бар бездә.
Рөхсәт ит, бүгенге яу каһарманын
Тәкъдим итәм: менә кем ул чын баһадир!
Иреннәре белән хәзер нәфис кулыңа
Кагылырга рөхсәт ит син, зинһар, аңа.
Йә, кил, батыр, кыюрак. Аның ничек
Сугышканын күрсәң иде — шаккатарлык:
Әйтерсең лә адәм токымын корытырга
Карар кылган Алла утыра аның эчендә.

Клеопатра

Батырлыгың өчен, дустым, бүген сине
Алтын көбә кием белән бүләкләрмен.

Антоний

Феб фәйтуны кебек хәтта кызыл якут
Ташлар белән бизәлсә дә ул киемнәр,
Бүләгеңә лаек аның батырлыгы.
Әйдә хәзер үзебез күк яу кырында
Яраланган калканнарны горур тотып,
Тантаналы адым белән Искәндәрия
Капкасыннан эчкә узыйк. Бир кулыңны.
Ah, кызганыч, сарай залы бар гаскәрне
Тулысынча сыйдыра алмый, югыйсә без
Бер гаиләдәй уртак табын корып, хәзер
Язмышларны хәл итәчәк иртәгәге
Булачак яу хөрмәтенә эчәр идек.
Быргычылар, быргыларның ачы тавышы

Барабаннар тавышы белән кушылсын да.
Шул гөрелте җирнең, күкнең алкышлавы
Булсын, әйдә, без шәһәргә кергән чакта.

Китәләр.

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Цезарь гаскәре урнашкан лагерь. Сакчылар каравылда торалар. Энобарб керә.

Беренче сакчы

Бер сәгатьтән алмаш килеп җитми икән,
Без каравыл өенә кайтып китәчәкбез.
Боерык шундый. Ай яктысы бигрәк якты.
Нәкъ иртәнге сәгать икедә тынып торган
Сугыш кабат яңарачак.

Икенче сакчы

Ә бит кичә
Безгә бәхет елмайса да, дөресен әйтим,
Бик авырга туры килде.

Энобарб

Караңгы төн!
Шаһит итеп дәшәм сине.

Өченче сакчы

Кем бар анда?

Икенче сакчы

Шаулама әле... Тыңларга бир.

Энобарб

О, тулган ай!
Син шаһит бул! Киләчәктә яшь буыннар
Бу хурлыклы хыянәтне искә алганда,
Мин мескеннең синең алда кылган эштән
Тәүбә итеп үкенүемне расларсың.

Беренче сакчы
Энобарб!
Икенче сакчы

Тс-с... Шаулама. Тыңлыйк әле.

Энобарб

Кайгы-хәсрәт алиһәсе, мәрхәмәт ит!
Төн сулышы белән тизрәк агула да
Яшәү дигән бу газаптан коткар мине.
Хәсрәтемнән корып кипкән йөрәгемне
Тораташка әверелгән гаебемә —
Хыянәткә бәреп ват та кичекмәстән
Көлен күккә очыр тизрәк. Ah, Антоний,
Әхлак тавы түбәсендә син биектә,
Ә мин түбән тәгәрәдем, кичер мине!
Син кичерсәң, бар дөньясы «Ант бозучы

Сатлыкҗан» дип атаса да курыкмас идем.
О, Антоний...
(Үлә.)

Икенче сакчы

Әллә үзен монда дәшеп
Моң-зарларын сөйләтикме?

Беренче сакчы

Юк, кирәкми!
Үзалдына сөйләнсен ул, тыңлап торыйк,
Бәлки, Цезарь файдасына ни дә булса
Ишетергә насыйп булыр.

Өченче сакчы

Ярый, тыңлыйк.
Тик йокыга талды бит ул, күрәсезме?

Беренче сакчы

Юк, йокламый, һуштан язды. Андый дога
Йокы алдыннан укылмый ул.

Икенче сакчы

Әйдә уятыйк.

Өченче сакчы

Әй, туганкай, уян әле, ишетәсеңме?

Икенче сакчы

Йә, тор инде. Ник дәшмисең? Чукрак мәллә?

Беренче сакчы

Әҗәл белән тартышкан ул.

Ерактан барабан тавышлары ишетелә.

Чү, барабан —
Бу йокыдан уянырга дигән хәбәр.
Димәк, яуга кузгалырга вакыт җитте.
Йә, әйдәгез, җыеныгыз, бу мәетне
Үзебез белән каравыл өенә алып китик,
Чөнки ул бик затлы кеше.

Өченче сакчы

Шулай, шулай.
Аның әле аңына да килүе мөмкин.

Сакчылар Энобарб гәүдәсен күтәреп чыгып китәләр.

УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ике лагерь арасындагы сугыш кыры. Гаскәрләрен ияртеп, Антоний белән Скар керәләр.

Антоний

Алар диңгез сугышына әзерләнә,

Димәк, җирдә без аларга ошамыйбыз.

Скар

Юк, җирдә дә сугышырга җыена алар.

Антоний

Хәтта күккә менеп әнә, йә булмаса
Ут эчендә сугышырга җыенсыннар,
Барыбер алар безнең күздән ычкынмаслар,
Тиешлесен алачаклар, син борчылма.
Инде эшкә. Син җәяүле гаскәрләрне
Хәзер шәһәр тирәсенә калкулыкка
Урнаштырып чык һәммәсен, мин флотка
Кузгалырга дигән әмер күптән бирдем.
Алар хәзер диңгездәләр. Кораблрның
Хәрәкәтен күзәтергә әнә теге
Тауга менсәк уңайлырак булыр безгә.

Китәләр. Гаскәре белән Цезарь керә.

Цезарь

Алар һөҗүм итми торып кузгалмаска!
Ә һөҗүмнең булмавы да бик ихтимал:
Иң яхшы дип санап йөргән гаскәрләрен
Кораблрга төяде ул бүген иртән.
Йә, әйдәгез, хәзер әнә шул тирәдән
Уңайлырак урын табып урнашыйк та
Сабыр гына көтеп торыйк. Онытмагыз,
Җиңү безнең якта була бу сугышта.

Китәләр. Антоний белән Скар керәләр.

Антоний

Ике якның да кораблары бер-беренә
Якынлаша, димәк, тиздән яу башлана.
Әнә теге нарат үскән калкулыктан
Карап кына килим әле, син торып тор.

Скар

Клеопатра корабының бауларына
Карлыгачлар оя корган. Багучылар
Дөреслекне яшерәләр булса кирәк,
Берни дәшми утыралар кара коелып.
Ә Антоний гайрәтләнеп куя кайчак,
Тик озакка түгел, шундук боегып кала.
Ярты-йорты бәхет аны йә иркәли,
Йә хурлыклы җиңелү белән котын ала.

Ераста барган диңгез сугышының шау-шуы ишетелә. Антоний керә.

Антоний

Бар да бетте! Шул кабахәт Мисыр хатыны
Башаягым белән сатты, юха елан!
Диңгездә мин тар-мар килдем, корабларым
Дошман ягына чыкты бар да, диңгезчеләр,
Бик күптәнге дуслар сыман, күрәсеңме,

Дошман белән бүрек чөеп бергә эчәләр.
Күтләк кәнтәй, мине корбан ясадың син,
Бәхете ташкан бер селәгәй малай өчен.
Бүгеннән соң йөрәгемнең кан дошманы
Бу дөньяда тик син генә, канмас үчем.
(Скарга.)
Гаскәрләрне тарат, Скар. Сихерчедән
Үчемне алсам — шуның белән эшем бетә.
Гаскәрләрне таратырга боер тизрәк.
Һәм үзең дә котылырга чара эзлә.

Скар китә.

Якты кояш! Синең балкып чыкканыңны
Күрү насыйп булмас инде миңа бүтән.
Антоний һәм язмыш чөнки бу мизгелдә
Куллар биреп хушлашалар мәңгелеккә.
Бар да бетте. Нәтиҗәдә этләр сыман
Табанымны ялап йөргән яраннарым
Койрык болгап Цезарь күңелен күрә хәзер.
Ә ул гөрләп чәчәк ата. Башкалардан
Югарырак күтәрелгән дәү имәнне
Яшен сукты, ул ялгызы көйрәп утыра,
Яфракларсыз, чәрдәкләнеп беткән көе.
Ah, алдандым. Шул ялганчы Мисыр хатыны
Сатты мине дошманыма. Ул — сихерче!
Күз карашы белән мине иректезләп
Һәлакәткә ташлаттырды гаскәремне.
Аның куены минем өчен бу дөньяда
Иң зур максат, төп теләккә әверелде.
Шуннан оста файдаланып, чегән кебек
Төп башына утыртты ул мин юләрне.
Эрос! Эрос! Минем янга! Ишетәсеңме?

Клеопатра керә.

Югал тизрәк күз алдымнан, җен карчыгы!

Клеопатра

Нигә болай сөйгәненә нәфрәт белән
Карый икән мәрхәмәтле хөкемдарым?

Антоний

Югал тизрәк күз алдымнан исән чакта,
Синең белән исәп-хисап ясап, юкса
Цезарьны да тантанадан мәхрүм итәм.
Әле синең аның җиңү бәйрәмендә
Фәйтунына тагылып бөтен Рим аша
Шау-гөр килгән кара халык күңелен ачып
Хатын-кызлар исеменә тап төшергән
Шакшы булып өстерәлеп барасың бар.
Ерткыч җанвар караган күк сине анда
Акча түләп карасыннар зур мәйданда.
Шуны гына көтеп торган Октавия
Тырнакларын батырачак чыраеңа.

Клеопатра чыгып китә.

Ярый китеп өлгердең син, бәхетең инде.
Яшәү бәхет булса әгәр синең өчен.
Ләкин хәзер минем кулдан киткән булсаң,
Моннан күпкә куркынычрак йөз үлемнән
Җиңел генә котыла идең син берьюлы.
Нидер булды миңа, Эрос, кил тизрәк!
Утта янам, минем тәндә Несс күлмәге.
О, гайрәтле бабам, Алкид, нәфрәтемә
Көч бир, зинһар, мин дә шулай синең кебек
Дошманымны айның үткен урагына
Бер селтәүдә атсам иде, йә булмаса
Үз чукмарым белән хәзер үз-үземне
Шул мизгелдә һәлак итим. Ah, сихерче!
Үлем аңа! Авызыннан сөт кипмәгән
Бер малайга сатты мине. Ул — фетнәче!
Фетнәчегә хөкем кыска, ул үләчәк!
Ул үләчәк. Үлем аңа! Эрос! Эрос!
(Китә.)

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Клеопатра сараеның бер бүлмәсе. Клеопатра, Хармиана, Ирада һәм Мардиан керәләр.

Клеопатра

Зинһар, ярдәм итегез, кызлар, ул котыра,
Фессалия кабаны күк тәмам шашкан.
Теламон да Ахиллесның калканы өчен
Бу кадәрле шашмагандыр. Инде нишлим?

Хармиана

Тизрәк кабер төрбәсенә кереп ят та
Антонийга сине үлде дияргә куш.
Шулай, шулай, хөкемдарга дан-шөһрәттән
Колак кагу җан бирүдән авырдыр шул.

Клеопатра

Дөрес, кабер төрбәсенә! Син, Мардиан,
Хәзер үк барып Антонийга: патшабикә
Үз-үзенә кул салды, дип хәбәр тапшыр.
Үлгәндә дә Антоний, дип үлде диген.
Булдыра алган кадәр мине кызгандырттыр.
Үлемемне ничек кабул итәр икән?
Кайткач миңа түкми-чәчми җиткерерсең.
Йә, бар, ычкын! Юкса соңга калуың бар.
Ә мин кабер төрбәсенә киттем хәзер.

Китәләр.

УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук, ләкин башка бүлмә. Антоний белән Эрос керәләр.

Антоний

Синең алда мин тора дип уйлыйсыңмы?

Эрос

Әйе, хаким.

Антоний

Карап торсаң, кайчагында
Болыт кинәт аждаһага әверелә.
Куе томан арыслан йә йонлач аю,
Манаралы таш кирмән, йә зәңгәр кыя,
Йә булмаса талгын җилдә тирбәлүче
Ерактагы урман булып күренә күзгә.
Ул гынамы? Озаграк карап торсаң,
Пәйда була әллә нинди могҗизалар.
Кичке эңгер әнә шулай алдый безне.
Күзәткәнең бармы, Эрос?

Эрос
Бар, хөкемдар.

Антоний

Синең алда муеннарын дугалатып
Ак аргамак басып торган сыман була,
Ләкин кинәт рәвешен җуя да ул
Ак томанда эреп тәмам юкка чыга.

Эрос

Андый хәлләр бик еш була, хөкемдарым.

Антоний

Күрче менә, хәзер синең командаңың
Нәкъ шундый ук тотрыксыз бер күләгә.
Дөрес, әлегә мин Антоний, әмма ләкин
Рәвешем торган саен көпшәкләнә.
Аның өчен сугышмадыммыни соң мин?
Ишетмәсәң ишет, Эрос, әлегә кадәр
Йөрәгенә мин хуҗа дип йөргән кешем
(Ә бит аңа минем йөрәк инде күптән
Мәңгелеккә тапшырылган һәм шулай ук
Бүген җуйган миллионнарның йөрәкләре
Һәммәсе дә аныкы иде), һәм шул кеше —
Мин алиһә санап йөргән патшабикә
Минем артта дошман белән шыпырт кына
Хыянәтчел алыш-биреш ясап яткан.
Ул, Цезарьның тантанасын бизәр өчен,
Шөһрәтемә төреп мине аңа саткан.
Юк, елама, әлегә мин исән әле
Гомеремә нокта куяр юл табармын.

Мардиан керә.

Югал тизрәк күз алдымнан! Хыянәтче
Патшабикәң янына ычкын, ник сузасың?
Кылычымны урлады ул, мин коралсыз...

Мардиан

Юк, Антоний, хаталанма, ялгышасың!
Патшабикә сине сөйде, өзелеп сөйде.
Сөюенә ахыргача тугры калып,
Үз язмышын синекенә кушып үрде.

Антоний

Дәшмә, алаша! Ычкын моннан, кысыр шайтан!
Икейөзле сатлык синең патшабикәң.
Хыянәте бик кыйммәткә төшәр аңа,
Гомере белән түләячәк ул явыз җан.

Мардиан

Бер гомерне ике тапкыр түләп булмый.
Ул бер кабат түләде инде үз бурычын.
Патшабикә дөнья белән саубуллашып
Мәңгелеккә күзен йомды, син тыныч бул.
Мәрхүмәнең иң ахыргы мизгелендә
Йөрәгеннән өзгәләнеп чыккан соңгы
«О, Антоний, бердәнберем!» дигән сүзе
Сулып барган иреннәргә җитә алмыйча,
Ярты юлда туктап калды һәм өзелде.
Алиһәгә тиң изге зат әнә шулай
Күкрәгенә бикләп синең исемеңне
Үзе белән алып китте мәңгелеккә.

Антоний

Ничек, әллә ул үлдеме?

Мардиан

Әйе, үлде.

Антоний
(Эроска)

Көндезге эшем тәмам, Эрос, инде йоклыйм.
Салдыр көбә күлмәгемне, йә, тизрәк.
(Мардианга.)
Исән-имин калганыңа рәхмәт укы,
Анысы да синең өчен бик зур бүләк.

Мардиан китә.

Җәһәтрәк! Аяксның җиде катлы
Калканы да бу бәладән саклый алмас.
Вакыт җитте. Әйдә, күкрәк, шартлап ярыл.
Әй, йөрәгем, эчтән бәреп ват төрмәңне!
Әсирлекнең богауларын өзеп ат та
Тоткынлыктан коткар тизрәк син үзеңне.
Нишләп, Эрос, болай озак маташасың?
Әйе, хәзер мин сугышчы түгел инде.
Сау бул, көбәм. Аерылмас дуслар идек.
Сугышларда теткәләнеп бетсәң дә син,

Әлегә кадәр зур горурлык белән кидем.
Йә, бар, Эрос, син чыгып тор.

Эрос китә.

Клеопатра!
Кичер мине, күз яшьләрем белән сорыйм.
Тиздән мин дә юлга чыгам синең янга,
Без яңадан күрешербез, көт, кадерлем.
Шунсыз булмый, ашыгырга кирәк миңа,
Тоткарланган һәр минутым авыр җәза,
Шәмдәлемдә утым сүнде, күзем йомам,
Мәгънәсезгә көрәшүдән юк бер файда.
Булган көчне үз-үземне юк итүдән
Башка эшкә куллана алмыйм. Бар да бетте.
Гомеремә нокта куйдым, инде хәзер
Мөһер генә басасы бар җөрьәт итеп.
Эрос, Эрос, кер тизрәк! Мәхәббәтем,
Синең арттан юлга чыгам. Әй, Эрос, дим!
Патшабикәм, без икәүләп синең белән
Изге рухлар бакчасына юнәлербез.
Хозурлыкның иге-чиге булмас анда,
Барча рухлар безгә генә карап торыр.
Эней белән Дидонаның хадимнәрен
Үзебезгә каратырбыз кызыктырып.
Әй, Эрос, дим!

Эрос керә.

Эрос

Хөкемдарым, ни телисең?

Антоний

Аннан калып яшәү миңа яшәүмени?!
Куркаклыгым хурлыгыннан утта янам.
Шундый оят, кая керер урын тапмыйм.
Аллалар да минем өчен ояладыр.
Мин үземнең кылычым белән бу дөньяны
Кисәкләргә телгәләдем кирәк кадәр
Һәм Нептунның дымлы яшел аркасына
Кораблардан корып куйдым зур шәһәрләр.
Ә менә бүген хатын-кызның гайрәтеннән
Көнләшергә калды миңа, күрәсеңме?!
Аның үлеме дошманына мин үземне
Үзем генә җиңдем дигән соңгы сүзе.
Хәтереңдәме, Эрос, миңа ант иттең син:
Әгәр кинәт түбәнлеккә төшсәм яки
Алларыма дәһшәт булып хурлык басса
(Килешүнең шарты шундый), мине шундук
Үтерергә тиешсең син мин кушуга.
Менә җитте көткән сәгать. Ник агардың?
Кыюрак бул, туганым. Әйдә башла.
Син бит мине үтермисең, ә Цезарьның
Тантанасын бозасың тик, йә, каушама.

Эрос

О, аллалар! Парфяннарның максатына
Төп-төз очкан уклары да читләп узган
Гомерне мин ничек өзим?!

Антоний

Ә бәлки син
Мине Римга кулларымнан каерып бәйләп,
Чыраема корым ягып, мәсхәрәләп,
Муеныма камыт кидереп, тантанадан
Авызын ерган яшь Цезарьның фәйтунына
Тагып алып баруларын тәрәзәдән
Күзәтергә телисеңдер?

Эрос

Юк, хөкемдар!

Антоний

Ул чагында, әйдә сузма, тәвәккәллә,
Бу хурлыктан котылыр чара синең кулда,
Ватан өчен күп көч куйган кылычыңны
Икеләнми чыгар тизрәк кынысыннан.

Эрос

Кичер мине, кичер, зинһар, хөкемдарым.

Антоний

Сине иреккә чыгарганда, мин кушуга
Шушы эшне башкарырга ант иттең син.
Инде үтә. Кылычың кая? Эшкә башла!
Югыйсә мин моңа кадәр син күрсәткән
Хезмәтләрне хәтеремнән сызып ташлыйм.

Эрос

Ул чагында мәңгелек дан нуры иңгән
Йөзеңне син яшер, зинһар, минем күздән.

Антоний

Анысы мөмкин.

Эрос

Менә кылычым чыкты кыннан.

Антоний

Ул гына аз. Ник сузасың? Әйдә кизән!

Эрос

Хөкемдарым һәм сөекле сәргаскәрем,
Кылычымны синең канга батырганчы,
«Кичер мине» дип әйтергә рөхсәт бир.

Антоний

Рөхсәт бирәм, тик син аны әйттең инде.

Эрос

Хуш, сөекле команданым! Кизәнимме?

Антоний

Сузма, Эрос!

Эрос

Ул чагында...
(Үз-үзен чәнчи.)
Менә булды.
Инде хәзер Антонийны үлгән көе
Күрү миңа насыйп булмас. Кичер, хаким!
(Үлә.)

Антоний

Бу акылга сыймаслык эш! Чын ирләрчә
Бөек адым ясадың син. Син — фидаи!
Сиңа кушып тормый гына, синнән алда
Мин ясарга тиеш идем бу адымны.
Патшабикә белән икегез батырлыкка
Иң туры юл күрсәттегез бүген миңа.
Тик мин дә бит үлем белән ярәшелгән
Кочагына ашыгам аның сезнең арттан.
Хөкемдарың синнән үрнәк алып үлә,
Син бу эштә аңа остаз булдың, Эрос.
(Үз кылычына чәнчелә.)
Бу ни тагын? Әллә соң мин үлмәдемме?
Ah, мин исән!.. Әй, сакчылар! Тиз булыгыз!

Дерцет һәм сакчылар керәләр.

Беренче сакчы

Кем кычкырды?

Антоний

Ярты юлда туктап калдым.
Мин башлаган эшне, зинһар, тәмамлагыз.

Икенче сакчы

Йолдыз сүнде.

Өченче сакчы

Ахырзаман җитте, димәк.

Барысы бергә

Кайгы килде безнең башка!

Антоний

Тиз булыгыз!
Әгәр мине сөйсәгез сез, күкрәгемә
Кылычымны батырыгыз һич кызганмый.
Йә, ни көтеп торасыз, ә? Ашыгыгыз!

Беренче сакчы

Булдыралмыйм.

Икенче сакчы

Мин дә шулай.

Өченче сакчы

Бездән булмый.
Сакчылар чыгып китәләр.

Дерцет

Син үлүгә, яраннарың төрле якка
Таралырга тиеш бар да.

Антонийның кылычын ала.

Ә бу кылыч
Үлемеңне раслар өчен әйбәт дәлил.
Мин Цезарьга илтәм аны.

Диомед керә.

Диомед

Кайда Антоний?

Дерцет
Ул биредә.

Диомед

Үлдеме әллә? Ник дәшмисең?

Дерцет чыгып китә.

Антоний

Әй, Диомед, кылычыңны чыгар да син,
Бу газаптан коткар тизрәк, үтенеп сорыйм.

Диомед

Синең янга патшабикәм Клеопатра
Кушуы белән килдем, хаким.

Антоний

Патшабикә?
Сине кайчан җибәрде ул?

Диомед
Хәзер генә.

Антоний
Үзе кайда?
Диомед

Ул патшалар төрбәсендә
Таш табутта яшеренеп качып тора.
Сизгер күңеле аңа биредә бәхетсезлек
Булганлыгын шыпырт кына пышылдаган.
Ул бит үзен Цезарь белән эш йөрткән дип,
Бер дә юкка хыянәттә гаепләгәч,
Синең чиксез нәфрәтеңне йомшартырлык
Һичбер чара таба алмыйча өметен өзеп,
Үзен үлде дип әйтергә кушып, сиңа
Ялган хәбәр җибәрергә мәҗбүр булды.
Ә соңыннан ул-бу килеп чыкмасын дип,
Чын дөресен сөйләр өчен кичекмәстән
Менә мине юллады ул синең янга.

Әмма куркам, артык соңга калдым бугай.

Антоний

Әйе, артык соңга калдың син, Диомед,
Зинһар, минем сакчыларны дәш бирегә.

Диомед

Кем бар анда? Әй, сакчылар! Тиз булыгыз!
Үз янына чакыра сезне галиҗәнап.

Антонийның җан сакчылары керәләр.

Антоний

Патшабикә янына тизрәк алып барыгыз.
Соңгы тапкыр миңа хезмәт итегез, дуслар.

Беренче сакчы

Бәла килде безнең башка! Синнән калып
Яшәү безгә нигә кирәк?! О, хөкемдар!

Антоний

Зинһар өчен, күңелегезне төшермәгез,
Усал язмыш шатлыгыннан мәхрүм калсын.
Аның сугуын сез елмаеп каршы алыгыз,
Әнә шулай җәзалагыз ул явызны.
Инде мине күтәрегез. Әлегә кадәр
Үзем сезне йөртә идем мин җитәкләп.
Ә менә бүген киресенчә килеп чыкты.
Сезнең кулда барам, дуслар, бик зур рәхмәт.

Антонийны күтәреп чыгып китәләр.

УНӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Патшаларны җирли торган таш төрбә. Югарыда Клеопатра,
Хармиана һәм Ирада пәйда булалар.

Клеопатра

Хармиана, мин биредән беркая да чыкмыйм бүтән.

Хармиана
Йә, тынычлан.

Клеопатра
Юк, теләмим.
Миңа хәзер тәкъдир язган коточарлык
Вакыйгалар кулайрак. Ә тынычлык...
Минем өчен юк ул хәзер. Бар теләгем:
Хәсрәтемнең авырлыгы сәбәбеннән
Бер тамчы да ким булмасын.

Аста Диомед күренә.

Йә, белдеңме?
Ул үлгәнме?
Диомед

Әлегә исән. Әмма хәле
Бик тә начар. Кыл өстендә генә тора.
Тәрәзәдән кара әнә, сакчылары
Аны бирегә китерәләр кулларында.

Аста Антонийны күтәргән сакчылар күренәләр.

Клеопатра

Кара күмер яса, кояш, бар нәрсәне!
Мәңгелек төн каплап алсын бу галәмне!
О, Антоний! О, Антоний! Бердәнберем!
Аны монда менгерегез, зинһар, бирегә!
Әй, Ирада, Хармиана, ни торасыз?
Булышыгыз! Җәһәтрәк!

Антоний
Өзгәләнмә!
Марк Антоний үзен-үзе җиңде бүген,
Цезарь эше түгел аның җиңелүе.

Клеопатра

Әлбәттә, шулай. Анысы мәгълүм. Антонийны
Тик Антоний үзе генә җиңүе мөмкин.
Әмма аннан ни җиңеллек? Башкаема
Дәрья кадәр кайгы килде. Ничек түзим?!

Антоний

Патшабикәм... Мине үлем, үлем көтә,
Ә мин сиңа моңа кадәр бүләк иткән
Бихисап күп үбүләргә өстәп тагын
Иң соңгысын бүләк итәр өчен генә
Тоткарланып аның һаман ачуын китерәм.

Клеопатра

Синең янга төшә алмыйм мин, кадерлем.
Кичер, зинһар, булдыралмыйм, юк, ярамый.
Анда төшсәм, мине тотып алачаклар,
Цезарь кулына эләгүдән куркам, җаным.
Бу дөньяда әлегә агу, үткен хәнҗәр,
Еланнарның зәһәр угы бар чагында,
Ул үзенең тантанасын минем белән
Бизи алмас. Һәм оялчан Октавия
Минем өскә җирәнүле караш ташлап
Ләззәтләнү бәхетен күрмәс... Ah, Антоний!
Синең янга төшә алмыйм, әмма үзең
Син биредә булачаксың. Ягез, дуслар,
Менгерегез аны бирегә, минем янга.
Сез дә, кызлар, булышыгыз. Менә шулай.

Антоний

Тик тизрәк. Юкса үләм. Күзләр йомыла.

Клеопатра

Менә сине дә күтәрергә язган икән,

Мондый хәлне әлегә кадәр белмәдек без.
Шундый авыр син, сөеклем, бар кодрәтең
Авырлыкка әверелгән, ахры, синең.
Мин Юнона булсам әгәр, кичекмәстән
Меркурийның армас-талмас канатында
Күккә алып менәр идем, бәгърем, сине,
Юпитерга иптәш булыр идең анда.
Бирегәрәк... әмма ләкин чынга ашмаслык
Хыял белән тик ахмаклар хыяллана.

Антонийны Клеопатра янына менгерәләр.

Тагын бераз, тагын бераз! Йә, мондарак...
Хәят тапкан җиреңдә үл, сыен миңа.
Күзләреңне йом, кадерлем. Әгәр дә мин
Сине үбеп терелтә алсам, инде күптән
Иреннәрем тузып беткән булыр иде.

Барысы бергә

Эшләр харап! Төсе качты!

Антоний

Үләм... үләм...
Тик бер генә йотым шәраб китер миңа...
Сиңа сүзем бар, кадерлем...

Клеопатра

Юк, сабыр ит.
Миңа ирек бир сөйләргә, мине тыңла.
Язмыш дигән җен карчыгын синең алда
Акылыннан яздырганчы каргыйм хәзер.

Антоний

Юк, юк, бәгърем... тыңлап бетер... киләчәктә
Син Цезарьдан мәрхәмәт һәм яклау эзлә.

Клеопатра

Мәрхәмәт һәм Цезарь, икесе ике нәрсә,
Берләштерү мөмкин түгел бу икәүне.

Антоний

Цезарь яклы кешеләрдән тик берәүгә —
Прокулейга ышан бары, патшабикә.

Клеопатра

Юк, Цезарьның колларына исәп тотмыйм.
Ышансам да, мин үземнең кулларыма
Һәм тәвәккәл йөрәгемә ышанам тик.

Антоний

Минем гомер аянычлы чикләнгәнгә
Хәсрәтләнмә ул кадәрле, кирәк түгел.
Үткәннәрне хәтерлә син, элегрәк
Хөкемдарлар арасында иң бөеге,
Шөһрәтлесе мин идем бит, инде менә

Шул бәхетле көннәремне искә алып,
Күңелеңне аз булса да юат, бәгърем.
Юк, хурлыклы үлем түгел минем үлем.
Куркакларча очлымымны салып баштан
Тезләнмәдем җиңелү белмәс якташымның
Алларына рәхим-шәфкать сорап аннан.
Мин үлемне чын римлы кулларыннан
Римлыларча кабул иттем, шуңа күрә...
Тыным кысыла... Башка булмый... Бар да бетте...
Җаным очып чыгып бара күкрәгемнән...

Клеопатра

Ничек? Әллә син үләргә җыенасыңмы?
Кызган! Кызган! Мине калдырып китмә, җаным!
Бу күңелсез дөнья миңа синнән башка
Салкын дуңгыз абзары күк!

Антоний үлә.
Хөкемдарым!
Күрәсезме, кызлар, ничек бу дөньяның
Асылташы күз алдында эреп акты.
Мәңге яшел дәфнә агачы төсен җуйды.
Утлар-сулар кичкән байрак җиргә ауды.
Һәм кешелек әле акыл да утырмаган
Ярымахмак яшүсмергә охшап калды.
Китте бездән галиҗәнап илаһи зат,
Инде айга күктән торып күзәтергә
Гадәттән тыш берни дә юк җир өстендә.
(Һуштан яза.)

Хармиана

Өзгәләнмә ул кадәрле, и тажия!

Ирада

Үлде, үлде шәфкатьчебез.

Хармиана

Патшабикә!

Ирада

Ач күзеңне, и мәликә!

Хармиана

Зинһар, уян!

Ирада

О, Мисырның йөзек кашы! Патшабикә!

Хармиана

Тс-с... Ирада! Тс-с... шаулама! Акрынрак!

Клеопатра

Патшабикә түгел, бары хатын гына,
Меңәрләгән башкалар күк газап чигәм.
Күз яшем дә мал караучы кол хатыннар

Күз яшеннән аерылмый берни белән.
Кодрәтемнән килсә хәзер аллаларга:
О, явызлар, көнләштегез, чөнки сездән
Мең мәртәбә бәхетлерәк идем, шуңа
Иң кыйммәтле алмазымны урладыгыз,
Ләгънәт яусын, ләгънәт сезгә, дия-дия,
Тажым белән йөзләренә бәрер идем.
Түзәр хәлем калмады һич, хәсрәт талый,
Котырган ач эттән яман талый, явыз...
Тукта, әгәр үлем яши торган йортка
Чакырылмаган кунак булып искәрмәстән
Үзең теләп барып керсәң гөнаһмыни?..
Кызлар, кызлар, бу нинди эш! Боекмагыз!
Хармиана, нәрсә булды?.. Ah, дусларым!
Утсыз калдык, янып бетте чырагыбыз!
Сугышчылар, җебемәгез, нык булыгыз!
Хөкемдарны тиешенчә җирлик тә без,
Ә аннары, римлыларча иркен сулап,
Үлем белән очрашырга әзерләник.
Элегрәк бөек рух яшәгән тән
Телсез, тынсыз салкын мәет булып калды.
Кызлар, кызлар, дустыбыздан мәхрүм калдык,
Әмма куып җитәчәкбез тиздән аны.

Антонийның гәүдәсен алып чыгып китәләр.

Бишенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Цезарь лагере. Цезарь, Агриппа, Долабелла, Меценат, Галл, Прокупей һәм башкалар керәләр.

Цезарь

Долабелла, әйт, бирелсен. Ул капчыкта.
Карышуның файдасы юк.

Долабелла

Тыңлыйм, Цезарь.
(Китә.)

Антонийның кылычын тоткан Дерцет керә.

Цезарь

Син кем тагын? Канлы кылыч кулларыңда,
Җөрьәт итеп ничек килеп кердең монда?

Дерцет

Исемем Дерцет. Мин Антоний гаскәреннән.
Тугры хезмәт иттем аңа намус белән,
Чөнки моңа башкаларга караганда,
Ул күбрәк лаек иде, нәкъ шуңа да

Үзе исән чагында ул галиҗәнап,
Олуг хаким булды миңа һәм мин аның
Дошманнары белән булган көрәшләрдә,
Үз-үземне беркайчан да аямадым.
Әгәр мөмкин булса, мине хезмәткә ал,
Тугры хезмәт итәчәкмен мин сиңа да.
Булмый икән, ихтыярың, теләсәң нишләт,
Минем гомер тулысынча синең кулда.

Цезарь

Бу сүзләрнең мәгънәсе ни?

Дерцет

Мәгънәсе шул:
Антоний үлде, шуны әйтергә телим, Цезарь.

Цезарь

Юк, юк, булмас. Андый зур тау ишелгәндә,
Күкләр күкрәп бар дөньяны золмәт каплый.
Шундый олы бәдән ауса, җир тетрәп,
Калтыранган күкрәгеннән чыккан утлы
Сулышы белән сахрадагы көтү-көтү
Арысланны шәһәрләргә, шәһәр халкын
Арысланнар яши торган сахраларга
Алып аткан булыр иде инде күптән.
Антонийның үлеме юк-бар үлем түгел,
Ярты дөнья дигән сүз ул — Марк Антоний.

Дерцет

Анысы дөрес, тик шулай да үлүе хак.
Аның гомерен хыянәтче хәнҗәре дә,
Гадел хөкем балтасы да өзмәде, юк!
Гамәлләрен данлы тарих битләренә
Кылыч белән язган кулы курку белмәс
Йөрәгеннән тәвәккәллек алып, үзенә
Шул йөрәкне җәрәхәтләде, менә кылычы,
Күкрәгеннән суырып алып килдем бирегә
Антонийның каны бизи кылыч йөзен,
Затлы канга буялган ул, күрәсезме?

Цезарь

Күрәм, дуслар, сезне хәсрәт биләп алды.
Әйе, әйе, елар өчен сәбәпләр бар.
Күкләр белән ант итәмен бу сүзләрең
Патшаларның күз яшенә лаек, туган.

Агриппа

Гажәп хәлләр бар дөньяда, без күп вакыт
Үзебез тар-мар китергәнне кызганабыз.

Меценат

Яхшы белән яманны ул аералмады.
Бичараның күңелендә шушы икәү
Алмаш-тилмәш җиңү яулап гомере буе

Бертуктамый гел үзара көрәштеләр.

Агриппа

Гаять сирәк очрый торган сыйфатларны
Берләштергән адәм иде. Кимчелекләр
Аллаларга әверелүдән саклар өчен,
Аллалардан җибәрелгән бүләк безгә.
Цезарь ничек дулкынлана!

Меценат

Миңа калса,
Каршысында бик зур көзге пәйда булып,
Шуннан үзен күрде бугай.

Цезарь

Ah, Антоний,
Шундый хәлгә сине китереп җиткердемме?
Тик нишләмәк кирәк, туган, үзебезнең
Тәнгә чыккан чуанны да сытабыз ич.
Ике тәкә башы сыймый бер казанга.
Бу дөньяда безнең беребез артык иде.
Тик шулай да мин канлы яшь түгәм менә,
О, туганым, якын дустым һәм киңәшчем,
Хакимият юлындагы безнең бөек
Башлангычның төп терәге, көрәштәшем,
Син җанымның ярты сы идең — мәхрүм калдым,
Күкрәгемнән чыгып очты ярты җаным.
Усал язмыш кинәт кенә бер-беребездән
Аерды да куйды безне. Ah, дусларым,
Хәзер сезгә бәйнә-бәйнә сөйләп бирәм!..

Чапкын керә.

Юк, соңыннан. Ник килгәнен күзләреннән
Аңласам да, бу Чапкынны тыңлыйк элек.
Кем син? Монда каян килдең?

Чапкын

Мин мисырлы.
Патшабикәм Клеопатра иң ахыргы
Биләмәсе булып калган каберлеккә
Бикләнде дә язмышына ни язганын
Белер өчен әмереңне көтә синең.

Цезарь

Зинһар өчен, борчылмасын, әйт аңарга:
Тиздән безнең хадимнәрдән кем дә булса
Хөкememне ирештерер һәм ул минем
Аңа ничек кадер-хөрмәт күрсәтергә
Җыенганны аңлар шулчак.

Чапкын

Рәхмәт, Цезарь.
(Китә.)

Цезарь

Син, Прокулей, патшабикә янына элдерт.
Һәм әйт аңа, кимсетүләр булмас, диген.
Вәгъдәләргә саранланма, юмарт кылан.
Үз-үзенә кул салудан сакла берүк.
Шуны онытма, әгәр аны исән-имин
Без Римга алып кайтсак, ул чагында
Тантанабыз тарихларга кереп калыр.
Йә, бар, ашык. Җавап көтәм, озаклама.

Прокулей

Тыңлыйм, Цезарь.
(Китә.)

Цезарь

Әй, Галл, син дә ияр аңа.
(Галл китә.)
Долабелла ник күренми? Кайда йөри?
Ул да барсын, ярдәм итәр.

Агриппа, Меценат
(икесе бергә)
Долабелла!
Цезарь

Юк, туктагыз! Чакырмагыз. Исемә төште,
Ул эш белән киткән иде, тиздән кайтыр.
Хәзер, әйдә, минем чатыр эченә узыйк.
Сезгә бер хат күрсәтергә телим, дуслар.
Анда минем түземлегем, сабырлыгым
Һәм тынычлык яклы булуым ярылып ята.
Бу сугышның миңа көчләп тагылуын да.
Хат аңлатыр. Йә, әйдәгез, минем арттан.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Искәндәрия. Патшалар төрбәсе. Клеопатра, Хармиана һәм Ирада керәләр.

Клеопатра

Бәхетсезлек әйбәт сабак бирә миңа,
Цезарь булу зур мәртәбә түгел әле.
Ул бары тик язмышының колы гына,
Һәм язмышы ни боерса, шуны үти.
Бөеклек ул — ихтыярны эшкә җигеп,
Бар нәрсәне тамырыннан йолкып ату.
Һәммә эшне, үзгәрешне, хәрәкәтне
Туктатырлык артык кискен адым ясап,
Патшаны да, ярлыны да бердәй күреп
Сугаручы тирес төмен онытыр өчен
Үз-үзеңне мәңгелеккә күз йомдыру.

Аскы катка Прокулей, Галл һәм сугышчылар керәләр.

Прокулей

Цезарь сәлам юллый Мисыр ханчасына
Һәм белергә тели синең теләгеңне.
Ни гозерең бар аңарга?

Клеопатра

Исемең ничек?

Прокулей

Мин Прокулей атлы булам.

Клеопатра
Исемеңне
Антонийдан ишеткән идем, хәтеремдә,
Һәм ул сиңа ышанырга мөмкин, диде.
Хәер, хәзер алдаулардан курыкмыйм икән,
Хак сүзгә дә исем китми, кул селтәдем.
Әгәр синең хөкемдарың каршысына
Патшабикә хәер сорап килсен, дисә,
Биргән хәере патшалыктан ким булмасын,
Шуннан да ким хәер алмый таҗ иясе.
Мисырны ул улыма бирсен, әйт Цезарьга.
Әгәр шуны эшли икән, ул чагында
Үземнекен үземә бүләк итте диеп
Рәхмәт әйтеп тез чүгәргә әзер аңа.

Прокулей

Синең язмыш ышанычлы кулда хәзер,
Ә Цезарьга таянырга мөмкин аңа.
Күңеле тулы рәхим-шәфкать һәм ул аны
Бертуктаусыз сибеп тора уңга-сулга.
Рөхсәт итсәң, патшабикә, мин хәзер үк
Сине сүзсез буйсына дип хәбәр итәм.
Ул чагында җиңелү белмәс данлы Цезарь
Ялынуыңны көтеп тормый, үзе килеп
Синең ярдәм соравыңны үтенәчәк.

Клеопатра

Әйт син аңа, бик зур кодрәт иясе ул,
Аның бәхете каршында мин баш иямен.
Һичбертөрле икеләнүсез көчен таныйм
Һәм буйсыну сәнгатенә өйрәнәмен.
Тиздән аның үзен күрү хыялым да
Тормышка ашып куяр, бәлки.

Прокулей
Һич борчылма,
Мин барын да җиткерермен. Тик шуны бел:
Син кичергән иксез-чиксез хәсрәтләрнең
Сәбәпчесе хәленә дә керә белер.

Галл

Җиңел генә кулга алырга мөмкин аны.

Прокулей белән ике сугышчы сөяп куелган баскычлардан төрбәнең югарыгы катына менәләр дә, Клеопатраны камап алалар. Башка сугышчылар, аркылы тыгылган

эшермәләрне алып, төрбәнең ишекләрен ачып җибәрәләр.

Тиздән Цезарь килеп җитәр, шуңа кадәр
Сак астында торып торсын.
(Китә.)

Ирада
Патшабикә!

Хармиана

Клеопатра! Дошманнарың кулында син!..

Клеопатра
(хәнҗәр чыгара)

Калтырама, зинһар, кулым, ашык ләкин!

Прокулей
(кулыннан хәнҗәрен каерып ала)

Үз-үзеңә зыян салма, мин сатмадым,
Тик сакладым гына сине, патшабикә.

Клеопатра

Үлемнәнме? Син юлыма каршы төштең.
Мондый чакта без яралы этләрне дә
Сызланудан коткарабыз, ә син мине
Шул иң соңгы өметтән дә мәхрүм иттең.

Прокулей

Үз-үзеңә кул салма син, Клеопатра.
Бу Цезарьның юмартлыгын сызып ташлау.
Әйдә, аның киң күңелле икәненә
Һәммәсе дә чын күңелдән ышансыннар.
Ә син үлсәң, аның күркәм бу сыйфатын
Дөнья белми калачак бит.

Клеопатра
Ни торасың?!
Кил син, үлем, кил син миңа! О, тизрәк!
Сабыйларны һәм ачларны, зинһар, калдыр.
Менә сиңа патшабикә — ал үзеңә,
Бу газаптан коткар мине!

Прокулей
Сабыр, сабыр.

Клеопатра

Ашау-эчү һәм йокыдан баш тартып, мин
Үз тәнемне җимерәчәкмен ахыргача.
Цезарегыз күпме генә тырышса да,
Һич кол булып басмам аның каршысына.
Юк, корышкан Октавия масаюлы
Караш белән чекерәя алмас минем өскә
Һәм котырган Рим әтрәк-әләменә
Күңел ачыр сәбәп бирмәм, көтмәсеннәр.
Баганага бәйләп мине зур мәйданда
Мәсхәрәләү насыйп булмас мәңге сезгә.

Андый хәлне күргәнче, әнә мәетемне
Шакшы түгә торган бозга ташласыннар.
Йә булмаса Нил сазына алып чыгып,
Чишендереп кигәвеннән талатсыннар.
Иң яхшысы аяк-кулга богау салып
Туган-үскән җиремдәге иң мәһабәт
Таш төрбәнең түбәсенә мине ассыннар!

Прокулей

Ник куркыныч уйлар били сине болай?
Куркыр сәбәп бирмәде бит Цезарь сиңа.

Долабелла керә.

Долабелла

Монда булган хәлләр белән Цезарь таныш.
Үз янына чакыра хаким, бар, Прокулей,
Ә ханчаны миңа калдыр, үзем саклыйм.

Прокулей

Яхшы, яхшы, Долабелла, әмма ләкин
Йомшаграк кылан, зинһар, аның белән.
(Клеопатрага.)
Клеопатра, Цезарьга мин нәрсә диим?
Теләгеңне тартынмый әйт.

Клеопатра

Үлем телим.

Прокулей һәм сугышчылар чыгып китәләр.

Долабелла

Патшабикә, әлегә кадәр минем хакта
Ишеткәнең бар идеме?

Клеопатра

Хәтерләмим.

Долабелла

Ничек алай? Син белергә тиеш мине.

Клеопатра

Минем белү-белмәвем бик мөһиммени?
Хатын-кыз йә бала-чага күргән төшен
Сезгә сөйли башлау белән, сез алардан
Мыскыл итеп көләсез ич.

Долабелла

Патшабикә,
Нәрсә әйтергә телисең син? Аңламыйм һич.

Клеопатра

Мин төшемдә кайчандыр бер Антоний атлы
Хөкемдарның яшәгәнен күргән идем...
Нәкъ шундый ук кешене кабат күрер өчен
Нәкъ шундый ук төш күрергә иде тагын!..

Долабелла
Рөхсәт итче...

Клеопатра

Аның йөзе нәни генә
«О» хәрефе сыман җирне яктыртучы
Ай һәм кояш әйлән-бәйләп уйнап йөргән
Күк гөмбәзе сыман матур, нурлы иде...

Долабелла

Гүзәлләрдән-гүзәлрәк таҗ иясе...

Клеопатра

Ул океанны атлап кына чыкты һәрчак,
Ә галәмне, очлым белән каплагандай,
Җиңел генә учы белән каплый иде.
Дуслар белән сөйләшкәндә, аның тавышы
Күктән иңгән моңлы аһәң иде гүя,
Ә кемнедер куркытырга теләгәндә,
Күк күкрәгән тавыш белән тулды дөнья.
Юмарт көздәй бүләкләде ул һәркемне,
Беркайчан да саран кышка әверелмәде.
Күңел ачу аны төпкә сөйрәү түгел,
Киресенчә дельфин сыман өскә чөйде.
Бу киң дөнья аның гына йорты иде.
Бар патшалар аңа гына хезмәт итте.
Патшалык һәм утрауларны ул үз куллап
Вак акчалар сипкән сыман гына сипте.

Долабелла
Клеопатра!..

Клеопатра

Син бу хакта ни уйлыйсың?
Йә, әйт әле, төштә күргән ул кешенең
Өндә булуы мөмкин эшме?

Долабелла

Юк, билгеле.

Клеопатра

Алдыйсың син, күкләр шаһит, ул тормышта
Төштәгедән күп мәртәбә артык иде.
Ул яшәде, аның гомере арабыздан
Татлы төштәй эзсез генә балкып үтте.
Табигатьнең хыял белән узышырга,
Тартышырга көче җитми беркайчан да.
Әмма ләкин Антонийны уйлап табып
Күп мәртәбә уздырган ул хыялны да.

Долабелла

Тыңла, зинһар, о, тиңдәшсез таҗ иясе!
Югалтуың чиксез олы, үзеңә тиң.
Хәсрәтең дә югалтудан һич ким түгел,
Үз-үзеңне хәсрәтеңчә тотасың син.

Ышан, зинһар, патшабикә, сүзләрем хак:
Шатланасым килми минем һич тә моңа.
Чөнки синең яраланган йөрәгеңнең
Һәр тибеше хәсрәт булып күчә миңа.

Клеопатра

Яхшылыгың өчен рәхмәт. Белмисеңме,
Цезарь мине нишләтергә җыена икән?

Долабелла

Әйтергә дә авыр миңа, әмма ләкин
Әйтмичә дә булдыралмыйм...

Клеопатра

Әйтеп бетер.

Долабелла

Нинди генә мәрхәмәтле булса да ул...

Клеопатра

Нигә туктап калдың инде, әйдә сөйлә!
Тантанасын бизәр өчен Цезарь мине
Фәйтунына тагарга дип җыенамы әллә?

Долабелла

Әйе, шулай карар кылды, патшабикә.

Быргы авазлары. Якынлашып килүче тавышлар ишетелә.

Тавышлар

Хөкемдарга юл бирегез! Цезарь килә!

Цезарь, Галл, Прокулей, Меценат, Селевк һәм башкалар керәләр.

Цезарь

Кем биредә Клеопатра?

Долабелла
(Клеопатрага)

Менә Цезарь!

Клеопатра тезләнә.

Цезарь

Мин ни күрәм? Патшабикә, торчы, торчы!
Үтенәм синнән, тор тизрәк, о асыл зат!
Ник йөзтүбән капландың син, Мисыр тажы?

Клеопатра

Күкләр шулай теләделәр. Синең алда
Бил бөгәргә тиешмен мин, хөкемдарым.

Цезарь

Җан өшеткеч мондый уйлар нигә кирәк,
Күкрәгемә хәнҗәреңне ник кададың?
Рәнҗетүең йөрәгемә уелып калды,

Бу турыда уйлавы да авыр миңа.
Тик мин синең бу эшеңне гади очрак
Дип санарга әле дә булса әзер торам.

Клеопатра

О, дөньяның бердәнбер хак хөкемдары!
Тәүбә итеп акланырга соң шул инде.
Хатын-кызны таплый торган кимчелекләр
Гомерем буе газаплады шулай мине.

Цезарь

Без аларга күз йомабыз, патшабикә,
Үткәннәрне искә алып тормыйк хәзер.
Мин чыгарган карарга син карышмасаң
(ә ул карар бары синең файдага тик),
Язмышыңа һәм Цезарьга гомерең буе
Рәхмәт укып яшәр идең. Әгәр инде
Антонийдан үрнәк алып, минем өскә
Син явызлык күләгәсе ташлар булсаң,
Ул чагында рәхим-шәфкать көтмә бездән,
Балаларың һәлакәткә дучар булыр.
Мин әйткәнчә эшләгәндә, бу куркыныч
Һәлакәттән котылырга мөмкин әле.
Бу турыда ныклап уйла. Ярый, киттем.
Хушлашырга вакыт безгә. Сау булып тор.

Клеопатра

Бар дөньяга җиһандар син шуңа күрә,
Кая гына барсаң да син үз җиреңдә.
Ә без башка. Без ганимәт маллары тик,
Дивар буйлап калкан тезеп чыккан кебек,
Теләсәң кая тезә аласың. Әйтик, менә...

Цезарь

Клеопатра мәсьәләсе каралганда,
Син киңәшчем булачаксың.

Клеопатра

Менә монда
Хәзинәмдә булган барлык мал-мөлкәтнең
Исемлеге: алтын-көмеш, савыт-саба.
Соңгы энәмә кадәр шунда теркәттердем.
Селевк кайда?

Селевк

Мин биредә.

Клеопатра

Бу — казначым.
Йә, Селевк, хөкемдарың каршысында
Башың белән ант итеп әйт, хак сөйлимме?

Селевк

Аңкавыма телем ябышып калса калыр,
Хак дип әйтеп алдый алмыйм, башым газиз.

Клеопатра

Нәрсә яшереп калдым соң мин?

Селевк

Саный китсәң,
Исемлеккә теркәлгәнне син берсүзсез
Кире сатып алаласың, патшабикә.

Цезарь

Ярый, булды, син кызарма, Клеопатра,
Сакчыллыгың акыллылык билгесе ул.
Кызарырлык бернинди дә сәбәп күрмим.
Бу эшеңне мактыйм гына, син тыныч бул.

Клеопатра

Күр, хакимлек ничек тәэсир итә, Цезарь!
Миңа тугры бәндәләр дә сиңа күчте.
Ә язмышлар кинәт кенә алмашынса,
Алар кабат синнән миңа күчәр иде.
Селевкның кыланышын күрче әнә,
Чыгырымнан чыгарды ул мине тәмам!
Оятсыз кол, тугрылыгың фахишәнең
Мәхәббәте сыман гына икән синең.
Кысла кебек чигенәсеңме? Чиген! Чиген!
Әмма оятсыз күзләреңне яшерә алмассың.
Канатланып җәһәннәмгә очсалар да,
Алар минем тырнакларның тәмен татыр.
О, кабахәт! О, сатлыкҗан! Әшәке эт!

Цезарь

Сабыр, сабыр, патшабикә, үтенеп сорыйм...

Клеопатра

Юк, юк, Цезарь, анысын көтмә, мөмкин түгел,
Бу хурлыкка берничек тә түзеп булмый!
Син илаһи бөеклегең тауларыннан
Иелеп мине шатландырган бу мизгелдә,
Аш атканга таш аткандай үз хезмәтчем
Синең алда мәсхәрәләп миннән көлә.
Әйтик, хәтта мин кайсыбер дусларыма
Ядкарь итеп бирергә дип ни дә булса
Яшереп тә калдырыйм, ди. Бәлки, миндә
Киләчәктә күрсәтәчәк мәрхәмәтен
Һәм яклавын истә тотып Октавиягә
Кыйммәтлерәк берәр бүләк ясар өчен,
Кайбер затлы нәрсәләр дә сакланадыр...
Тик тәлинкә ялаучы бу йолкыш колның
Минем йөзне кызартырга ни хакы бар?!

О, аллалар, упкынга очам, әмма упкын
Җәһәннәм күк төпсез, ахры...
(Селевкка.)
Югал тизрәк!
Юкса дөрләп кабына хәзер нәфрәтеннән
Кара күмер булып калган зәгыйфь йөрәк!..
Хатын-кызны аңлыймыни печтергән ир?!

Цезарь
Бар, Селевк.

Селевк китә.

Клеопатра

Үзе хөкем сөргән чорның
Гамәле өчен тик хөкемдар җавап бирә.
Шуңа күрә бу хокуктан ваз кичкәндә,
Башкаларның гаебе дә безгә өелә.
Шуны гына көтеп торган хаин җаннар
Елан кебек чага башлый тирә-юньнән.

Цезарь

Син борчылма, патшабикә, хәзинәңне
Тулысынча мин үзеңә бүләк итәм.
Исемлеккә кергәнен дә, башкасын да
Без ганимәт дәфтәренә теркәмәбез.
Синең белән сатулашып торыр өчен
Килмәдем мин, юк, сәүдәгәр түгел Цезарь.
Бу күңелсез уйларыңнан арын тизрәк,
Үз-үзеңне тоткын итмә бер сәбәпсез.
Без, сөекле патшабикә, синең белән,
Үзең ничек кушсаң, шулай эш итәрбез.
Язмышыңны минем кулга тапшыр да син,
Үзең рәхәт сафа кичер, аша да эч.
Син дусларың тәрбиясендә, язмышыңны
Үз кулыма алам, дустым, ә хәзер хуш.

Клеопатра

Олуг шаһым! Хөкемдарым! О, падишам!

Цезарь

Юк, кирәкми, түбәнләнмә. Тор тизрәк.
Мин падиша түгел сиңа, дустың бары.
Шуны онытма, патшабикә, ярый, сау бул.

Бырғы тавышлары. Цезарь хадимнәрен иярtеп чыгып китә.

Клеопатра

Матур сүзләр сөйли-сөйли мине үзенең
Җәтмәсенә төшермәкче була, төлке.
Йә, тыңла әле, Хармиана...
(Колагына нидер пышылдый.)

Ирада
Патшабикә,

Һәммәсенә нокта куяр вакыт җитте.
Кояшыбыз сүнде безнең, алда эңгер,
Караңгылык кочак җәеп көтеп тора.

Клеопатра

...Һәм шунда ук әйләнеп кайт. Аның белән
Барысы да килешенгән, тик ашыктыр.

Хармиана

Аңлашылды, патшабикә!

Долабелла керә.

Долабелла

Патшабикә!
Патшабикә кайда, диләр.

Хармиана

Менә ич ул.
Нәкъ каршыңда басып тора.
(Китә.)

Клеопатра

Долабелла?
Нигә болай бик ашыгыч, нәрсә булды?

Долабелла

Синең теләк минем өчен изге нәрсә,
Түкми-чәчми һәммәсен дә сөйлим хәзер.
Китү көне билгеләнгән, шуңа әзерлән.
Сүрия аша китә Цезарь һәм ул сине
Балаларың белән бергә шушы юлга
Өч көн алдан озатмакчы. Хәбәр шушы.
Ә калганын үзең кара, патшабикә.
Теләгеңне үтәдем мин.

Клеопатра

Долабелла,
Сиңа мәңге бурычлымын.

Долабелла

Мин хезмәтчең.
Хезмәтеңә һәрчак әзер. Ярый, сау бул.
Цезарь янына барыр вакыт җитә миңа.

Клеопатра

Хуш, исән бул, Долабелла. Рәхмәт сиңа.

Долабелла китә.

Йә, Ирада, күрәсеңме нинди хәлләр?
Усал язмыш безне тәмам кочакка алды.
Без бүгеннән римлыларның күңелен ачып,

Юатучы тәти Мисыр курчаклары.
Озакламый майга баткан һөнәрчеләр
Балта, пычкы, чүкеч алып кулларына,
Без күренеп торсын өчен зур мәйданга
Такталардан күпер корып куячаклар.
Безгә аларның кикерә-кикерә өстебезгә
Өргән сасы тыннарын һәм тир исләрен
Иреке здән сулап торырга туры килер.

Ирада

О, аллалар, коткарыгыз, зинһар, димен!

Клеопатра

Юк, Ирада, өметләнмә, һәммәсе дә
Нәкъ мин әйткән сыман булыр. Безне анда,
Урам хатынын бәйләгәндәй, тупас ликтор
Баганага бәйләп куяр аяк-кулдан.
Ә корчаңгы шамакайлар, такмакчылар
Маймылланып «мисыр туе» оештырыр.
Антонийны сәрхуш итеп мыскыллар лар,
Бөтен мәйдан корт өедәй гөжләп торыр.
Боргалана-сыргалана оятсызланып,
Авызыннан сөт кипмәгән яшүсмерләр
Патшабикә Клеопатра тормышыннан
Төрле әдәпсез уйдырмалар күрсәтерләр.

Ирада
О, аллалар!

Клеопатра

Менә ниләр көтә безне.

Ирада

Мин боларны күрмәм инде, чөнки минем
Тырнакларым күзләремә караганда,
Күп тапкырлар үткенрәк.

Клеопатра

Әйбәт чара.
Болай булса, без аларның ниятләрен
Пыран-заран китерәчәкбез.

Хармиана керә.

Йә, булдымы?
Кызлар, кызлар, минем затлы киемнәрне
Китерегез! Патшаларча булсын бар да!
Мин яңадан Кидн буйлап Антонийның
Каршысына йөзеп барам. Әй, Ирада,
Ишетәсеңме, йөгер тизрәк. Хармиана,
Иң ахыргы теләгемне үтә, зинһар!
Таҗым белән ябынчамны китерегез.
Һәм мин сезне мәңгелеккә азат итәм.
Җәһәтрәк, җәһәтрәк, йә, сузмагыз!

Ирада китә. Сәхнә артында шау-шу.

Бу нинди шау? Тагын нәрсә булды микән?

Сакчы керә.

Ниндидер бер авыл кешесе сорый сине:
«Инҗир җимеше китердем», — ди.

Клеопатра

Бар, әйт, керсен.

Сакчы чыгып китә.

Кайчагында артык гади корал белән
Баш җитмәслек бөек эшләр башкарыла!
Ул азатлык алып килде. Миндә хәзер
Хатын-кызлык сыйфатлары бетеп бара.
Мин бөтенләй мәрмәр кебек. Инде бүтән
Ышанычсыз айны үземә сердәш ясап,
Язмышымны аңа карап хөкем итмәм.

Кәрзин күтәргән Авыл кешесе белән Сакчы керәләр.

Сакчы

Сине сорап йөдәтүче — шушы кеше.

Клеопатра

Ярый, керсен, син чыгып тор.

Сакчы чыга.

Көттердемме?
Авырттырмый үлем бүләк итә торган
Теге иркә еланыңны китердеңме?
Авыл кешесе. Ничек инде китермим ди, китердем, бик китердем. Әмма аңа кагылырга киңәш итмим. Шундый каты чага — oho-ho-ho! Аның чагуыннан үлгән кешеләр бик сирәк терелә, ә күп вакыт хәлләрен аңлатырга иренеп бөтенләй терелеп тә тормыйлар.
Клеопатра. Ул чакканнан үлгәннәре булдымы соң?
Авыл кешесе. Ничек кенә әле. Мәетләрнең исәбенә чыга торган түгел. Ирләр дә бар, хатын-нар да. Әле күптән түгел генә, ялгышмасам, кичә бугай, берсе сөйләп торды. Гаҗәеп тә намуслы хатын инде, тик кайвакыт, хатын-кызларның һәммәсенә дә хас булганча, сөйләгәне бөтенләй дөреслеккә охшасын өчен сүзенә шактый гына ялган кыстырып сөйләргә ярата. Менә шул хатын елан чагып үлгәннән соң, үзен ничек хис итүе, ниләр кичерүе турында сөйләде. Галәмәт тә мактады инде. Елан турында бөтен дөреслекне ачты да салды. Хәер, җыен юк-барны күп тыңласаң, юләр булып калуың да ихтимал. Кыскасы шул, бу елан — еланнарның да еланы инде.
Клеопатра. Инде хәзер китәргә дә мөмкин сиңа.
Авыл кешесе. Елан сиңа иксез-чиксез шатлыклар бүләк итсен.
Клеопатра. Хуш.
Авыл кешесе *(кәрзинен идәнгә куеп).* Кара аны, сак бул! Елан ул карап торырга гына тыныч кебек, аның акылы үзе белән; тора-тора да чагып та куя.
Клеопатра. Ярый, истә тотармын мин, ә хәзер хуш.

Авыл кешесе. Еланга ышаныч бик аз аңа, шул рәтен белгән кешегә эләксә генә инде. Ә болай уйлап карасаң, бернинди яхшылыгы да юк инде еланның.
Клеопатра. Сакланырбыз, син борчылма.
Авыл кешесе. Син аңа ашарга бирә күрмә тагын. Ризык бәясе тормый ул.
Клеопатра. Ә ул үзе мине ашап куймасмы соң?
Авыл кешесе. Ул кадәр үк юләргә санама инде син мине. Хатын-кыздан елан гына түгел, дию пәрие дә качкан, ди. Ә дөресен генә әйткәндә, хатын-кыз аллалар ашы инде ул. Тик иблис котыртып кына харап итә үзләрен. Бу каһәр суккан шайтаннар белән изаланып та карыйлар инде, аллаларны әйтәм, дөньяга бер дистә хатын-кыз кәмәшен яратып өлгермиләр, тегеләре күз ачып йомганчы шуның яртысын аздыра да куя.
Клеопатра. Шулай, шулай. Бар, кайт инде. Ярый, сау бул.
Авыл кешесе. Чынлап та китәргә вакыт. Ярый, елан сиңа чамасыз күп шатлыклар китерсен. *(Китә.)*

Таҗ, кием-салым һәм тагын кайбер нәрсәләр күтәреп, Ирада керә.

Клеопатра

Ябынчамны яп тизрәк. Кидер таҗны.
Мәңгелек үз кочагына дәшә мине.
Моннан ары бу иреннәр йөзем сутын
Татый алмас. Йә, Ирада, ашык инде!
Җәһәтрәк, аңлыйсыңмы, сабырым бетте.
Антонийның тавышын ишетәм — мине чакыра.
Бу тәвәккәл адымымны мактар өчен,
Әнә күрәм, юлларыма каршы чыга.
Көлә-көлә килә Антоний. Ул Цезарьның
Бәхетеннән көлә шулай. Бәхет безгә
Бик масайсаң, тартып алып җәзаларга
Аллаларның үзләреннән җибәрелә.
Әй, хәләлем, сиңа барам, ирем, диеп
Дәшәр өчен мин үземне лаек саныйм.
Һава белән уттан гына торам фәкать.
Табигатьнең башка түбән күренешләрен
Мәетемә калдырып китәм. Син әзерме?
Ул чагында иреннәрем җылысын мин
Соңгы тапкыр бүләк итәм сезгә хәзер.
Хушлашырга вакыт җитте. Сау булыгыз!
Хуш, сөеклем Хармиана... Хуш, Ирада.

Икесен дә үбә. Ирада авып төшә һәм үлә.

Мин үпкәннән үлдеме соң? Бу ни тагын?
Әллә минем иреннәрдә елан агуы?
Дөнья белән хушлашмый да китеп бардың,
Әйтерсең лә үлем татлы газап инде.
Ике гашыйк кавышкандай кавыштыгыз.
Димәк, дөнья хушлашырга лаек түгел.

Хармиана

О, чал болыт, коеп яңгыр яудыр җиргә,
Күкләр елый, дип әйтерлек булсын, зинһар!

Клеопатра

Ah, кызганыч, аны Антоний миннән алда
Очратып сорашачак ни булганын.
Минем өчен бар дөньядан кадерлерәк
Үбүен дә аңа бүләк итәчәк ул.

Еланны күкрәгенә җибәрә.

Йә, кил әле, минем нәни юлбасарым,
Йә, кил инде, ник качасың? Тыңлаучан бул.
Үткен тешең белән, әйдә, чишелмәслек
Нык чуалган тормыш төенен кисеп җибәр.
Ни торасың? Усалланып эшкә тотын,
Йә, бер дулап ал, сөеклем, тешлә, тешлә.
Ah, әгәр дә менә хәзер кеше сыман
Сөйләшә дә белсәң иде, ул чагында
Син Цезарьны ишәк диеп атар идең,
Без хәйләдә күптән узып киттек аны.

Хармиана

О, шәрыкның таң йолдызы!

Клеопатра

Тс-с, шаулама,
Нәниемне куркытасың. Күрмисеңме,
Күкрәгемне суыра ич һәм ул тиздән
Мәңгелеккә йоклатачак үз әнкәсен.

Хармиана

О, йөрәгем, ярыл тизрәк, тизрәк ярыл!

Клеопатра

Ник бу кадәр татлы соң бу зәһәр агу?
Татлы бәлзәм сыман җанга рәхәт бирә,
Назлы җилдәй иркәли ул, шундый хозур!
Икенчегез кайда сезнең? Качма, качма,
Йә, кил әле, ялкауланма, эшкә башла.

Икенче еланны да алып күкрәгенә җибәрә.

Ник яшәргә...
(Үлә.)

Хармиана

...Эчпошыргыч бу дөньяда?
Хуш, бәхил бул, патшабикә! Шатлан, үлем,
Горурлана аласың син, чөнки бүген
Бу дөньяда тиңдәше юк бер гүзәлне
Җиңел генә үз кулыңа төшердең син.
Күзләреңне йомдырыймчы. Алтын кояш
Синекедәй күз карашын күрмәс бүтән.
Башыңдагы таҗ кыйшайган, патшабикә,
Шуны гына төзәтәм дә мин дә китәм.

Сакчылар йөгерешеп керәләр.

Беренче сакчы

Патшабикә кайда?

Хармиана

Дәшмә, уятасың.

Беренче сакчы

Ләкин Цезарь боерыгы бит...

Хармиана

Соңга калган.

Күкрәгенә елан җибәрә.

Ah, еланкай, ник бик озак маташасың?
Чакканыңны сизмим бер дә, тизрәк кылан.

Беренче сугышчы

Эшләр чиста түгел монда, әй, бирегә!
Ah, Цезарьны алдаганнар. Бу — хыянәт!
Инде хәзер ни кылабыз? Коточкыч хәл.

Икенче сакчы

Долабелла аста гына, чакырт тизрәк.

Беренче сакчы
(Хармианага)

Хармиана, әйт әле син, бу дөньяда
Шундый эшкә барырга да мөмкинмени?

Хармиана

Нәселендә шундый бөек падишалар
Булган затка ничек мөмкин булмасын ди.
Мөмкин, мөмкин, аңа шулай эшләү хәтта
Фарыз иде һәм ул шулай эшләде дә.
Ah, сугышчы...
(Үлә.)

Долабелла керә.

Долабелла

Нәрсә булды?

Икенче сакчы

Күрәсеңме,
Өчесе дә мәет алар, Долабелла.

Долабелла

Шикләнүең дөрес булган икән, Цезарь,
Менә тиздән үзең килеп күрәчәксең.
Син тоткарлап булдырмаска теләгән эш
Җан өшеткеч бер гамәлгә әверелгән.

Сәхнә артында тавышлар.

Цезарь килә! Цезарь килә! Юл бирегез!

Читкә тайпыл, кемгә әйтәләр, торма юлда!

Хадимнәре белән Цезарь керә.

Долабелла

Мең кат хаклы булып чыктың, даһи Цезарь!
Син шикләнгән коточкыч хәл күз алдында.

Цезарь

Бик тәвәккәл батыр адым ясаган ул.
Безнең теләк, күрәм, аңа барып җиткән.
Һәм үзенең тапкыр зиһене ярдәмендә,
Ул үз юлын патшаларча дәвам иткән.
Ә ник бер дә кан күренми? Үлеме нидән?

Долабелла

Аның янына кем дә булса кермәдеме?

Беренче сакчы

Ниндидер бер авыл кешесе менә шушы
Кәрзин белән инҗир җимеше кертеп китте.
Димәк, алар агуланган.

Долабелла

Без кергәндә,
Хезмәтчесе Хармиана исән иде.
Ул мәетнең тажын рәтләп кидерде дә
Шул мизгелдә егылып кинәт җан да бирде.

Цезарь

Бу хәсрәтнең авырлыгы чик-чамасыз!
Тик шунысы икеләндерә, әгәр дә ул
Агуны эчкә йоткан булса, ул чагында
Бөтен тәне шешенер иде, ә бит моның
Андый шикле билгеләре һич күренми.
Әйтерсең лә ул бары тик йоклап ята.
Матурлыгы яңадан бер Антонийны
Һуштан яздырып исертерлек балкый хәтта.

Долабелла

Карагызчы, күкрәгендә нәни яра,
Шеше дә бар, ә кулында — икенчесе.

Беренче сакчы

Елан чаккан.
(Кәрзинне карый.)
Күрәсезме, яфраклардан
Сузылып-сузылып лайла тама. Мондый елан
Нил ярларын биләп торган куышларда
Селәгәен агызып йөри әнә шулай.

Цезарь

Әйе, үлеме шуннан булган. Бу турыда

Аның сарай табибыннан сөйләттердем.
Патшабикә авырттырмый-нитми генә
Үтерә торган дару сорап йөдәтте, ди.
Ятагына илтеп салыгыз хәзер аны,
Кызларны да бу төрбәдән чыгарыгыз.
Һәммәсен дә хөрмәт белән җирләр өчен,
Мөмкин булган бар чараны кулланыгыз!
Антонийны патшабикә белән бергә
Без янәшә күмәчәкбез. Әлегә дөнья
Андый данлы каберләрне күрмәгәндер.
Ул дан күчәр кыйссалардан кыйссаларга.
Бик күпләрне тетрәндерде бу фажига,
Хәтта үзенең сәбәпчесен аямады.
Һәм киләчәк буыннарның күңелендә
Җиңүченең даны белән бердәй булып
Озак яшәр бу икәүнең язмышлары.
Гаскәрләргә боерык шушы: табутларны
Кабергәчә хөрмәт белән озатырга!
Долабелла, бу эшләрне сиңа йөклим,
Ә аннары сәфәр көтә — туры Римга.

Китәләр.

Ромео

һәм

Джульетта

Трагедия

Биш пәрдәдә

Илдус Әхмәтҗанов
тәрҗемәсе

КАТНАШАЛАР:

Эскал — Верона князе.
Граф Парис — яшь егет, князьнең кардәше.
Монтекки
Капулетти
Өлкән Капулетти.
Ромео — Монтеккиның улы.
Меркуцио — князьнең кардәше, Ромеоның дусты.
Бенволио — Монтеккиның туганнан туган энесе, Ромеоның дусты.
Тибальт — Капулетти ханымның туганнан туган энесе.
Лоренцо
Джованни

Балтазар — Ромеоның хезмәтчесе.
Самсон
Грегорио
Петр — Джульетта тәрбиячесенең хезмәтчесе.
Абрам — Монтекки хезмәтчесе.
Аптекчы.
Өч музыкант.
Парисның пажы.
Беренче шәһәр кешесе.
Монтекки ханым — Монтеккиның хатыны.
Капулетти ханым — Капулеттиның хатыны.
Джульетта — Капулеттиның кызы.
Тәрбияче — Джульеттаның сөт анасы.

Шәһәр кешеләре, һәр ике йортның ир һәм хатын-кыз кардәшләре, маскарадта катнашучылар, сакчылар, хезмәтчеләр. Хор.

Вакыйга Верона һәм Мантуяда бара.

Беренче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Верона. Шәһәр мәйданы. Кылыч, калканнар белән коралланган Капулеттиның хезмәтчеләре, Самсон һәм Грегорио керәләр.

Самсон. Грегорио, әйтеп куям: тегеләр алдында хур булмаска.
Грегорио. Син нәрсә? Киресенчә, мин аларның үзләрен очраган берен җир тишегенә керердәй итәчәкмен.
Самсон. Мунча кертәбез әле без аларны!
Грегорио. Тик үзебезгә судан коры чыгарга иде.
Самсон. Әгәр мин кызып китсәмме, шундук сугыша башлыйм.
Грегорио. Сине кыздыру җиңел эш түгел.
Самсон. Шул Монтекки көчекләрен күрүгә үк ачуым кайный башлый минем.
Грегорио. Кайнавын кайныйдыр анысы. Әмма кайнап чыгуга, сөт кебек ташыйсың да юкка чыгасың. Ә йөрәкле кеше алай итми, баскан урынында тораташ кебек тора, селкетә дә алмыйсың.
Самсон. Монтекки көчекләре килеп кенә карасыннар, ничек сугышканымны күрерсең. Измәләрен изәм мин аларның: ирләренең дә, хатыннарының да.
Грегорио. Харап икән, каян килгән йон батыр!
Самсон. Бөтенесен рәттән. Ирләрен як-якка болгап атам да хатыннарын берәм-берәм почмакка терим.
Грегорио. Ызгыш бит хуҗалар һәм ир-ат затыннан булган хезмәтчеләр арасында гына бара.
Самсон. Миңа барыбер. Ирләре белән эшне төгәлләгәч, хатыннарына керешермен. Мин аларга күрмәгәннәрен күрсәтермен.
Грегорио. Бичара кызларга дамы?
Самсон. Көчем барда аларына да өлеш чыгар. Син бит мине беләсең, йоннан төргән түгел, Аллага шөкер.
Грегорио. Әле дә ярый телең бар, юкса карга күтәреп алып киткән булыр иде үзеңне. Тиз бул, кылычыңны чыгар. Әнә Монтекки йортыннан икәү киләләр.
Самсон. Кылычым чыгарылган, мин әзер. Әйдә, бәйләп. Мин сине ташламам.
Грегорио. Ул ни дигән сүз тагын? Нәрсә? Әллә шүрләп табан ялтыратырга җыенасыңмы?

Самсон. Минем өчен борчылма.
Грегорио. Кем өчен борчылырга икәнен беләм мин.
Самсон. Аларны чыгырыннан чыгарырга кирәк. Әгәр сугышны беренче булып башласалар, закон безнең якта булачак.
Грегорио. Хәзер мин, алар янынннан узганда, чыраема усал кыяфәт чыгарам. Шуннан күрер-без, нишләрләр икән.
Самсон. Ә мин аларга кукиш күрсәтәм. Әгәр җавапсыз калсалар, хур булачаклар.

Абрам белән Балтазар керәләр.

Абрам. Сез безгә кукиш күрсәтәсезме, әфәндем?
Самсон. Мин бары тик кукиш кына күрсәтәм, әфәндем.
Абрам. Сез кукишны безгә күрсәтәсезме, әфәндем?
Самсон *(Грегориога пышылдап)*. Әгәр дә мин «әйе» дисәм, закон безнең якта буламы?
Грегорио *(пышылдап)*. Юк.
Самсон. Юк, кукишны мин сезгә күрсәтмим, әфәндем. Мин бары тик кукиш кына күрсәтәм, дидем, әфәндем.
Грегорио. Сез сугыш чыгуын телисезме, әфәндем?
Абрам. Минме? Юк, әфәндем.
Самсон. Әгәр дә сугышырга теләсәгез, мин әзер. Мин дә әйбәт хуҗага хезмәт итәм. Сезне-кеннән бер дә ким түгел.
Абрам. Артык та түгел.
Грегорио *(Тибальтның килгәнен күреп, Самсонга)*. «Сезнекеннән артыграк» диген. Әнә без-нең хуҗаның бер кардәше килә.
Самсон. Сезнекеннән артыграк, әфәндем.
Абрам. Ялганлыйсыз!

Бенволио керә.

Самсон. Ир булсагыз, сугышыгыз! Грегорио, күрсәт әле үзләренә теге яңа алымыңны.
Сугышалар.

Бенволио
Кылычларны ташлагыз, йә, тиз булыгыз!
Кемгә әйтәләр, сасы кәҗә тәкәләре.

Кулларыннан кылычларын сугып төшерә. Тибальт керә.

Тибальт
Шушы әтрәк-әләм белән сугышасыңмы?
Әҗәлеңне каршыла кил, Бенволио!

Бенволио
Килештерү иде аларны минем ният.
Кылычыңны тык кынына йә булмаса
Кил, бергәләп аерыйк бу ахмакларны.

Тибальт
Кылыч тотып килешү сүзен сөйлисеңме?
Үзеңнән дә, сүзеңнән дә җирәнәм мин,
Җирәнгән күк бар Монтекки нәселеннән.
Тукта, куркак!

Сугышалар. Ике йорттан да кешеләр җыелалар һәм сугышучыларга кушылып, кара-каршы сугыша башлыйлар. Бераздан күсәкләр, алебардалар күтәргән шәһәр
кешеләре дә аларга кушыла.

Беренче шәһәр кешесе
Әй, бирегә! Кулга күсәк, казык ал да

Монтеккиен, Капулетын бергә тукма!

Өстенә халат кигән Капулетти һәм аның хатыны Капулетти ханым килеп керәләр.

Капулетти

Нинди шау-шу монда? Кайда кылычым?

Капулетти ханым

Кылыч түгел, таянырга таяк сора.

Капулетти

Кылыч бирегез! Минем йортта Монтекки карт
Корал күтәреп килә әнә минем өскә.

Монтекки белән Монтекки ханым керәләр.

Монтекки

Кабахәт син, Капулетти! Җибәр, хатын!

Монтекки ханым

Юк, җибәрмим, бер адым да атлыйсың юк,
Дошман белән очрашуга юл куя алмыйм!

Хезмәтчеләре белән Князь керә.

Князь

Хыянәтчеләр, тынычлыкка дошман токым,
Үз кардәше каны белән корал таплап,
Үч ялкынын тамырлардан агып чыккан
Бер-берегезнең каны белән сүндерергә
Маташучы ерткыч затлар! Кемгә әйтәләр?
Каты җәза куркынычын искә алып,
Канлы кылычларны кулдан ташлагыз да
Хәзер үк князь хөкеменә колак салыгыз.
Капулетти һәм Монтекки, сез икегез
Җыен юк-бар аркасында өченче кат
Тынлык бозып юкка җәнҗал чыгарасыз.
Веронаның иң әүкатле ил картлары
Затлы киемнәрен өстән салып ташлап,
Күгәрүдән тупасланган кылычларын
Хәлсезләнгән кулларына кысып тотып,
Сезнең шушы бетмәс бәхәс аркасында
Өченче кат килә менә шушы урынга.
Әгәр бу хәл тагын бер кат кабатланса,
Хөкем итәм сезне үлем җәзасына.
Ә бу юлы таралыгыз. Капулетти,
Сез китмәгез, минем белән барачаксыз.
Ә менә сезне, Монтекки карт, бу эш буенча
Виллафранкта судта көтәм. Бер көн мөддәт.
Кемнең башы ике түгел — таралыгыз!

Монтекки, Монтекки ханым һәм Бенволиодан башкалар барысы да чыгып китәләр.

Монтекки

Бу җәнҗалны өр-яңадан кем кузгатты?

Әйт, энекәш, син бит биредә булгансыңдыр?

Бенволио

Мин килгәндә, ике йортның хадимнәре
Арасында каты сугыш бара иде.
Аерырга керешкән идем, шулчак кинәт
Кылыч тоткан ярсу Тибальт килеп керде.
Сугышырга чакырып мине, баш очында
Уңлы-суллы кылыч болгап җил турады.
Әмма һичбер зыян-зарар күрмәгән җил
Җавап итеп аны сызгырып мыскыллады.
Кылычка-кылыч килергә дә өлгермәдек,
Төрле яктан халык тулды, ә бераздан
Князь үзе килеп җитте һәм аерды
Күзләрен кан баскан сугыш чукмарларын.

Монтекки ханым

Ә Ромео кайда икән? Күрдеңме аны?
Ул биредә булмадымы? Исән-саумы?

Бенволио
Сеньора,
Алтын кояш көнчыгышның тәрәзәсен
Балкытудан нәкъ бер сәгать кала элек,
Эч пошканнан йөрергә дип чыккан идем.
Шәһәр капкасыннан бераз көнбатышта
Тут агачы куаклары үскән җирдә
Улыгызны очраттым, ни сәбәптер
Япа-ялгыз иртә таңнан шунда йөри.
Янына барыйм дигән идем, мине танып,
Куаклыкка кереп посты. Һәм мин аның
Ялгызлыкка омтылганын аңлап алып
Калдырып киттем һәм башкача борчымадым.

Монтекки

Аны анда иртән бик еш очраталар.
Энҗе кебек күз яшьләре, җиргә тамып,
Болындагы чыкка кушыла, ә аһлары
Зәңгәр күккә күтәрелә болыт булып.
Әмма кояш Аврора түшәгенең
Чыбылдыгын тартып ачып җибәрүгә,
Төксе чырай белән һәр көн минем улым
Өстерәлеп көч-хәл белән кайтып керә.
Бүлмәсенә бикләнә дә, пәрдә корып,
Көпә-көндез төн уртасы ясый үзенә.
Нинди китмәс караңгылык юлдаш аңа?
Аңлый алмый җавап эзлим шул сорауга.

Бенволио

Сәбәпләрен белмисезме?

Монтекки

Юк шул, белмим.
Күпме генә тырышсам да, белә алмадым.

Бенволио

Ә үзеннән сорашканыгыз булмадымы?

Монтекки

Ничек кенә! Мин үзем дә, дусларым да
Бик төпченеп сораштырдык, әмма аңа
Сорау белән үтеп керә торган түгел.
Яфрак ярмас, чәчәк атмас борын, эчтән
Корт кимергән бөре кебек һаман йомык.
Сәбәпләрен сорыйсың син. Ни дип әйтим?
Эчендәген тышына һич тә чыгармый ул.
Хәсрәтенең сәбәпләрен әгәр белсәм,
Дәвасына керешер идем кичекмәстән.

Ромео керә.

Бенволио

Әнә үзе дә. Сез китегез әкрен генә,
Әйтте диярсез, ачкыч табам йөрәгенә.

Монтекки

Иң яшерен эч серләрен тиз арада
Ишетергә язсын сиңа. Киттек, хатын.

Монтекки белән Монтекки ханым чыгып китәләр.

Бенволио

Хәерле иртә телим сиңа, Ромео!

Ромео

Хәерле иртә?! Әле шулай иртәмени?

Бенволио

Яңа гына тугыз тулды.

Ромео

Чынлап тамы?
Кайгылы чакта сәгате дә ел кебек шул!
Әле генә киткән кеше әткәйме ул?

Бенволио

Әйе, әтиең. Сәгатьләрне ел ясарлык
Нинди кайгы төште башыңа, Ромео?

Ромео

Бер елын бер сәгать итеп кыскартырлык
Юанычка мохтаҗлыгым кайгысы ул.

Бенволио

Син мәхәббәт көтәсеңдер?

Ромео

Юк, юк, көтмим.

Бенволио

Әллә гашыйк булдыңмы соң?

Ромео
Әйе, туган.
Әмма үзем мәхрүм сөелү шатлыгыннан.

Бенволио

Ah мәхәббәт! Бер карасаң, татлы да шул,
Тик, асылда, мәрхәмәтсез һәм явыз ул!

Ромео

Үзе сукыр, нечкә җирне бик тиз таба,
Җәрәхәткә учлап-учлап вак тоз сала!
Төшке ашны кайда ашыйбыз? Никадәр кан!
Юк, сөйләмә ни булганын. Мин ишеттем.
Мәхәббәт тә, нәфрәт тә бердәй газап.
Юктан туган җыен юк-бар тойгы алар,
Икесе дә сукыр хисләр ялкыны тик,
Буш авырлык, чамадан тыш авыр бушлык.
Бозлы ялкын, кургаш мамык, өндәге төш,
Үлем белән сугарылган сәламәтлек.
Әнә шундый мәхәббәткә дучармын мин.
Өзелеп сөям, ә шулай да сөелмимен.
Көлмисеңме?

Бенволио

Юк, юк, туган, хәтта елыйм.

Ромео
Ник елыйсың?

Бенволио

Хәсрәтеңне уртаклашып.

Ромео

Яхшылык итеп тик начарлык кылабыз без!
Үз хәсрәтем миңа баштан ашкан иде,
Синекен дә кушкач хәзер бигрәк авыр.
Минем хакта борчылуың белән, туган,
Хәсрәтемне икеләтә арттырдың син.
Мәхәббәт ни? Исереклек сөреме ул.
Нәни очкын белән уйнап янгын чыгару.
Дөрләп торган күз яшьләре диңгезе ул,
Агу белән шуның даруы катнашмасы,
Тирән уйга чумган юләр дуамаллык.
Йә, хуш, туган.

Бенволио

Тукта, ашыкма, бергә китик,
Бу башлаган әңгәмәне дәвам итик.

Ромео

Үз-үземне җуйдым туган, мин юк монда.
Ромео юк, Ромео әллә кайда.

Бенволио

Йә, шаярма, кемгә гашыйк булдың, сөйлә?

Ромео

Әлегә кадәр мин шаярдым гынамыни?

Бенволио

Юк ла инде, йә, чынлап та, әйт, кем соң ул?

Ромео

Үлем көтеп яткан мескен бер сырхауга
Син чынлап та үләсең дип әйтеп кара...
Мин шаяртмый-нитми әйтәм: ул — кыз бала.

Бенволио

Димәк, укны туры төбәп җибәргәнмен.

Ромео

Син шәп мәргән, әмма кыз да гүзәлләрдән.

Бенволио

Асылкошка төбәбрәк атасың шул.

Ромео

Бу сүзләрнең аңа һич тә катнашы юк,
Диана күк гөнаһсыз ул, ә Купидон,
Юк, куркыныч түгел аңа, хәтта көлке.
Алтын тавы вәгъдә иткән ялварулы
Карашлар да аулый алмый аның җанын.
Ул бик матур, һәм илаһи бу матурлык
Имин көе кабер йотар байлыгы аның.

Бенволио

Әллә иргә чыкмаска дип ант иткәнме?

Ромео

Әйе, иткән. Һәм сүзендә каты тора.
Аның тоткан уразасы ул гүзәлдән
Кысыр чәчәк ясаячак тора-бара.
Дөньядагы иң тәкъва бер әүлия ул.
Шуңа күрә өмет-мазар тотмыйм аңа.
Ул гөнаһсыз шулай яшәр, ә мин беттем:
Мин бу дөнья кешесе түгел, мин — мәетмен.

Бенволио

Киңәшем шул сиңа, туган: уйлама аны.

Ромео

Ничек итеп уйламаска, шунысын өйрәт.

Бенволио

Күзләреңә ирек бир син, өмет өзмә,
Чибәрләр күп тирә-юньдә, тот та күзлә.

Ромео

Алай итсәм, сөйгәнемнең гүзәллекнең
Тажы икәнен тагын бер кат кабатлармын.
Кара битлек аша һәрчак хатын-кызның
Ак чырае безгә аграк булып балкый.
Сукыр кеше элек күргән матурлыкны
Хәзинәдәй хәтерендә мәңге саклый.
Матур кызлар минем өчен бу дөньяда
Алардан да гүзәлрәк кыз барлыгын
Искәртергә килгән затлар. Тырышма да,
Мин барыбер онытырга өйрәнә алмам.

Бенволио

Ничек кенә карышсаң да, өйрәтермен.
Синең алда бу туганлык бурычым минем.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам. Капулетти, Парис һәм бер хезмәтче керәләр.

Капулетти

Монтеккига да һәм миңа да штраф салдылар.
Йә, нигә дип тату гына яшәмәскә?

Парис

Әйе, әйе, анысы сәер. Ике чал карт —
Гел пычакка-пычак килеп яшисез шул.
Соравыма никтер җавап бирмәдегез.

Капулетти

Нәрсә диим, шул әйткәнне кабатлыймын:
Кызым әле бала гына, ундүрт тә юк.
Тагын ике ел көтсәгез, без шуннан соң,
Кәләш итеп игълан итәр идек аны.

Парис

Анысы аннан яшьрәкләр дә кияүгә чыга.

Капулетти

Шулай, ләкин иртә өлгергән бик тиз сула.
Һәр баламны туган берен кабер алды,
Ходай саклап, шул бердәнбер кызым калды.
Үзе белән сөйләшегез, зинһар, Парис,
Ә үзара без кайчан да килешербез.
Башта аның ризалыгын сорагыз сез,
Фатихамны бирәм сезгә мин берсүзсез.
Бүген кичен безнең өйдә мәҗлес була,
Андый мәҗлес бездә һәр ел уздырыла.
Мәгълүм булсын: бик күп кунак чакырабыз,
Сез дә килегез, бик шатланып каршы алырбыз.
Кәләшләрнең төнге күктә балкып янган
Йолдызларга тиңнәренә тап булырсыз.

Язгы ташу кебек дәртле шат авазлар,
Күңел ачу, тантанага юлыгырсыз.
Әйләп-бәйләп уенына чакырып сезне
Гүзәл кызлар урап алыр төрле яктан.
Күңелегезне кайсы күбрәк әсир итәр,
Анысын инде хәл итәрсез сез азактан.
Артык мактауларга дәгъва итми генә
Минем кыз да шунда булыр бүген төнлә.
Киттек, граф.
(Хезмәтчегә кәгазь биреп.)
Әй син, хәшәп, кичекмәстән
Шушы исемлек буенча, бар, кунак чакыр.
Кемнең исеме теркәлгән, бу исемлеккә
Һәммәсе дә рәхим итсен бүген безгә.

Капулетти белән Парис китәләр.

Хезмәтче. «Шушы исемлек буенча, бар, кунак чакыр!» Ә кем белә монда нәрсә язылганын?! Бәлки, анда итекне — аршын белән, күлмәкне калып белән тегәләр дип язылгандыр. «Шушы исемлек буенча!» имеш. Ә бәлки, монда балыкны пумала белән тоталар, түбәне җәймә белән буйыйлар дип язылгандыр. «Кемнең исеме теркәлгән бу исемлеккә, һәммәсе дә рәхим итсен бүген безгә!» Ә син менә кемнең исеме теркәлгәнен әйтеп кара. Аның өчен бит укый белергә кирәк. Укымышлы кешеләрдән сорарга туры килер инде. Менә алар. Гомерләре озын булгырылар.

Бенволио белән Ромео керәләр.

Бенволио

Дәшмә, дустым. Чирне бары чир дәвалый,
Янгын чыкса, утка каршы ут ягалар.
Баш әйләнсә, кире якка әйләндерәләр.
Кайгы белән дә нәкъ шулай син бәхәскә кер.
Зәхмәт чире онытылсын дисең икән,
Өр-яңасын эләктер син кичекмәстән.

Ромео

Андый чакта бака үләне бик файдалы.

Бенволио

Кайчан, дустым?

Ромео

Шартлап аяк сынган чакта.

Бенволио

Әллә акылдан яздың инде?

Ромео

Юк, язмадым,
Әмма акылдан язганнар күк богаудамын.
Көне-төне газапланам, җәфа чигәм.

Хезмәтче

Сәлам, сеньор! Сез укырга маһирдыр бит?

Ромео

О, әлбәттә! Мин бит кара тәкъдиремнең
Хәсрәт тулы һәр иҗеген үзем укыйм.
Хезмәтче. Турысын әйтеп бирүегез өчен рәхмәт. Тик безгә кәгазьгә язганны укый белүче кирәк иде шул.
Ромео. Тукта, кая ашыгасың? Мин бит шаярдым гына.
Бир укып бирәм, «Хатыны һәм кызлары белән бергә синьор Мартиноны, граф Ансельмоны һәм аның берсеннән-берсе чибәррәк сеңелләрен, толлык газабында интегүче Витрувио ханымны, синьор Плаченцоны һәм аның сөйкемле сеңелләрен, туганы Валентин белән Меркуционы, хатыны һәм кызлары белән агам Капулеттины, сөекле сеңелкәшем Розалинаны, Ливияне, синьор Валенцио белән аның туганы Тибальтны, Лючио белән аның чая кызы Еленаны».
Менә ичмасам букет бу!
Боларны кая чакыралар?

Хезмәтче

Теге башка.

Ромео

Кая, кая?

Хезмәтче

Ягъни безгә кичке ашка.

Ромео

Кем өенә?

Хезмәтче

Хуҗам өенә.

Ромео

Бу хакта мин
Синнән башта ук сорашырга тиеш идем.

Хезмәтче

Анысын мин сорамасагыз да әйтәм.
Минем хуҗам — атаклы бай Капулетти әфәнде.
Бәлки, ишеткәнегез бардыр?
Әгәр Монтекки нәселеннән булмасагыз, сез дә рәхим итегез, берәр җамаяк шәраб эчеп чыгарсыз. *(Китә.)*

Бенволио

Капулеттида синең җанаш Розалина
Үзе генә булмый, туган. Ул зур балда
Веронаның барлык мәшһүр гүзәлләре
Һәммәсе дә катнашачак. Киттек шунда.
Валлаһи, дим, ул гүзәлләр арасында
Тутыеңның ала карга икәненә
Инанырсың чагыштырып карарсың да.

Ромео

О, күзләрем, әгәр дә сез юлдан язып
Хыянәткә бирелсәгез, ул чагында
Сездән тамган күз яшьләре ялкын булып
Кабынсыннар минем ике күз алмама!

Юк, кояшны күрми мөмкин түгел аны,
Әллә Ходай мине сукыр яратканмы?

Бенволио

Ләкин бит син кояшның ул матурлыгын
Үлчәүләргә салып үлчәп карамадың.
Әйләнәңә күз сал бераз, Алла колы,
Күркәмрәк затлар да бит дөнья тулы.
Бәлки, синең ул бердәнбер асылташың
Асылташ та түгелдер, ә гади таштыр?

Ромео

Барсам барам тик илаһи шул зат өчен,
Мәҗлес халкын күзләр өчен түгел ләкин.

Китәләр.

Өченче күренеш

Капулетти йортындагы бер бүлмә. Капулетти ханым белән Тәрбияче керәләр.

Капулетти ханым

Джульетта кайда? Тиз бул, чакыр.

Тәрбияче

Күптән җуйган кызлык намусым белән
Ант итәмен, бикә, чакырдым.
Джульетта, кайда йөрисең син?
Ah, тиктормас кәҗә бәтие!

Джульетта керә.

Джульетта. Тагын нәрсә инде?
Тәрбияче. Әнкәң чакыра.
Джульетта. Мин биредә, әнкәй, ни кирәк?
Капулетти ханым. Хәзер. *(Тәрбиячегә.)* Безне беразга калдырып тор әле, Джульеттага әйтер сүзем бар. Хәер, тукта, китмә, син дә тыңла. Үзеңә мәгълүм, кызым инде җитеп килә.
Тәрбияче. Шулай булмыйча, мин аның яшен көнен-көнгә, сәгатен-сәгатькә санап кына торам.
Капулетти ханым. Хәзер аның ундүрте тулып килә.
Тәрбияче. Дүрт кенә тешем булуына карамастан, ундүрт тешемне закладка салып бәхәсләшә алам, юк, дим. Питрауга ничә көн калды әле?
Капулетти ханым. Ике атнадан артыграк.
Тәрбияче. Артыгракмы, кимрәкме, сүз ул турыда түгел, әмма дә ләкин Питрау көнне аңа ундүрт тула, моны мин күземне йомып та әйтә алам. Ул да, Сусанна да — урыны оҗмахта булсын балакаемның! — бер яшьлекләр иде. Ходай Тәгалә аны миннән күпсенгәндер инде, юкса нарасый көенә үз катына алмас иде. Ә ундүрт яшь аңа нәкъ Питрау көнне тула, сез бу хакта шикләнмәгез дә, минем хәтерем бик әйбәт. Теге җир тетрәүгә быел унбер ел була бит инде. Әлегедәй хәтеремдә, нәкъ шул җир тетрәгән көннәрдә, имидән аердым мин аны. Имчәк башларыма әрем сөрттем дә күгәрчен читлегенә сөялеп кояш астында утырам шулай, ә сез ул вакытта җәмәгатегез белән Мантуяда идегез, йә, хәтер ничегрәк минем! Шуннан балакаем, имчәктәге әрем тәмен сизүгә, туп шикелле читкә атылды, артына да борылып карамый, бер Ходаем үзе генә кичерсен инде. Җитмәсә, нәкъ шул вакыт мин сөялгән күгәрчен читлеге авып китте дә, үзем дә котым алынып чаба башладым. Аягым җиргә тисә тия, тимәсә юк. Бу хәлләргә инде хәзер төгәл унбер ел. Ул чагында Джульетта тәпи баса, башлаган иде инде, тукта

әле, нәрсә сөйлим соң мин, тәпи баса, имеш! — йөри иде инде, йөгереп йөри иде, валлаһи менә, бер Ходаем алдарга ирек бирмәс. Җитмәсә, ул шул вакытта егылып маңгаен бәрде. Шунда ирем... авыр туфрагы җиңел булсын, бик тә шаян кеше иде инде, баланы күтәреп алды да: «Нишләп алай йөзтүбән егыласың? Йөзтүбән егылырга ярамый, кызым. Үсеп буйга җиткәч, син һәрвакыт чалкан егылырга гына кара, ярыймы», — ди. Шуннан ни булды дип уйлыйсыз? Бәләкәчем күз яшьләрен сөртте дә аңа: «Ярый», — дип җавап бирде. Юк, сез уйлап кына карагыз! Көлә-көлә эчләр катты шунда үзеннән. Мең елдан соң да онытмам. «Кызым, үсеп буйга җиткәч, син һәрвакыт чалкан егылырга гына кара, ярыймы», ди. Ә ул берни булмагандай «ярый» дип җавап бирә.
Капулетти ханым. Булды, җитте, юкны лыгырдама!
Тәрбияче. Ярый, ярый, туктыйм, синьора. Йә, көлке түгел диген инде шуны? Елавыннан туктап күз яшьләрен сөртте дә, ике дә уйлап тормый, «ярый» дип җавап бирә, ә бит маңгаендагы шеш күгәрчен күкәе чаклы бар иде. Кайнар күз яшьләрен агызып елады наныем. Тегесе дә: «Йөзтүбән егылырга ярамый, кызым. Үсеп буйга җиткәч, син һәрвакыт чалкан егылырга гына кара, ярыймы», ди бит. Шул орчык башы хәтле генә бала аның шул сүзенә «ярый» дип җавап бирсен әле, җитмәсә, елавыннан да шып туктады.
Джульетта. Җитте инде, зинһар, син дә тукта.
Тәрбияче. Ярый, ярый, бүтән авызымны да ачмыйм. Мин имезеп үстергән балалар арасында иң матуры син булдың. Гомерем булып туеңа кадәр яши алсам, шуннан да зур шатлыгым булмас иде!

Капулетти ханым

Туеңа кадәр? Менә мин дә нәкъ шул хакта
Сөйләшергә кергән идем. Джульетта,
Син кияүгә чыгу турында ни уйлыйсың?
Джульетта. Андый бәхет турында әле уйлаган юк.
Тәрбияче. Андый бәхет турында диме? Сез уйлап кына карагыз! Бәхет! Кызганыч, әгәр дә үзем имезеп үстермәгән булсам, акыл сиңа күкрәк сөте белән кергән дип әйтергә дә мөмкин булыр иде.

Капулетти ханым

Менә хәзер уйла инде. Веронада
Синнән соңрак туганнар да бала таба.
Үзем сине алардан да иртә таптым.
Озын сүзнең кыскасы шул, балакаем,
Парис сине үзенә хатынлыкка сорый.
Тәрбияче. Бу инде, туташкаем, ирләрнең асылы!
Мондый ирне көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Ир генәме соң, коеп куйган кәртинкә инде.
Капулетти ханым. Веронаның андый чәчәк күргәне юк.
Тәрбияче. Әйтерең бармы, чәчәк инде, чып-чын чәчәк.

Капулетти ханым

Йә, ни дисең? Күңеленә хуш киләме?
Бүген балда бик әйбәтләп күзәт әле.
Дикъкать белән йөзендәге һәр чалымын
Китап укыган сыман итеп укы аның.
Акылын, фигылен төрле яктан үлчәп кара,
Ул сыйфатлар ни микъдарда икән анда?
Ни дә булса аңлашылмый калды исә,
Аңлатмасын күзләреннән тизрәк эзлә.
Татлы гыйшык китабы ул синең алда,

Матур тышлык кына җитми хәзер аңа.
Балыклар да тирән сулар эзләп китә.
Затлы нәкыш матур кыса таләп итә.
Әгәр дә ки эчтәлеге алтын булса,
Ул китапка кирәк алтын каптырма да.
Син дә шулай. Ир турында уйлаганнан
Бер мыскал да кимемәссең, курыкма, балам.
Тәрбияче. Кимемисең, кимемисең! Артасың гына, туташкаем. Хатын-кыз ирләрдән юаная гына ул.
Капулетти ханым. Йә, ничек соң, мин әйткәнне эшләрсеңме?

Джульетта

Белмим әле. Карап карыйк, нәрсә чыгар.
Эшләсәм дә синең хакка гына эшлим.
Әмерегезгә буйсынырга тиеш бит мин.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче. Синьора, кунаклар җыелдылар, табынга аш утыртылды, бертуктаусыз сезне сорыйлар, туташны чакыралар, аш өендә тәрбиячене эттән алып эткә салалар, бөтен өйнең асты өске килә. Ярый, мин шунда чабам. Ялварып сорыйм: зинһар, сез дә озакламагыз.

Капулетти ханым

Киттек.
Хезмәтче чыгып китә.

Тизрәк, Джульетта! Граф көтә.

Тәрбияче

Бар, бар, балам, хәерле көн артыннан ук
Бәхетле төн насыйп булсын сиңа берүк.

Чыгып китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам. Ромео, Меркуцио, Бенволио битлекләр кигән биш-алты егет,
факеллар тоткан хезмәтчеләр һәм барабанчы малай керәләр.

Ромео

Тәбрик сүзен шигырь белән әйтәбезме,
Йә булмаса дәшми кереп китәбезме?

Бенволио

Ул искергән йола белән маташмыйбыз.
Һәм кирәкми күзләренә чүпрәк бәйләп,
Кулларына хатын-кызның котын алган
Карачкыдан күп мәртәбә хәтәррәк
Йонлач татар җәясе тоткан Купидон да.
Арттан суфлер әйтеп торган сүзне сөйләп
Мәҗлес халкын гарык итү нигә кирәк?
Без, әлбәттә, биемәбез алар көенә,
Үзебезнекенә биербез дә аннары өйгә.

Ромео

Алайса, миңа факелны бир. Кәефем юк,

Бии алмам. Факел тотып керәм бары.

Меркуцио

Юк, Ромео, син биергә тиеш бүген.

Ромео

Миннән булмас. Сез биегез, сез җиңелчә.
Күңелем минем кургаш кебек һәм ул һич тә
Талпынырга ирек бирми аска тарта.

Меркуцио

Син гашыйк бит, дустым, гыйшкың канатларын
Кыюрак җилпеп җибәр, күтәрерләр.

Ромео

Үткен угы беләм Амур очкан көйгә
Кадаклады мине. Инде менә
Ярам тирән, канатларым хәлсезләнде,
Сөюемнең газабыннан сыгылып төштем.

Меркуцио

Егыла калсаң өстенә ава күрмә берүк,
Күтәрә алмас, сөю бит ул бик нәзберек.

Ромео

Сөю нәзберек? Юк, тупас ул, явыз нәрсә,
Гөләп кебек кадый, чәнчә, әрнештерә.

Меркуцио

Алай икән, син дә аңа шәфкатьсез бул,
Үзе кебек када, чәнче һәм вәссәлам.
Иллә-мәгәр битлек кияр вакыт җитте.
Менә булды, бит өстенә чырай кунды.
Хәзер миңа нәрсә генә әйтсәләр дә,
Шушы битлек кызарудан саклап калыр.
Мин шамакай, минем өчен ул кызарсын.

Бенволио

Йә, әйдәгез, ишек шакыйк, керүгә үк —
Барыгыз да бии башлый тыпыр-тыпыр.

Ромео

Бир факелны миңа. Ә юләрләр биер.
Ул келәмнәр минем өчен җәелмәгән.
Мин, шәм тотып, борынгылар әйткән сыман,
Өч тиенгә ярамаган тамашаны
Өч тәңкәлек шәм яндырып читтән карыйм.

Меркуцио

Ah, маякчы, кайнар мәхәббәтең белән
Безне ыслап бетердең син баштанаяк!
Шакы ишекне, тереләй янып бетмәс борын,
Юкса бушка көпә-көндез шәм ягабыз.

Ромео

Бирегә кунак булып килү әйбәт фикер,
Тик яхшыга илтмәячәк.

Меркуцио

Ә ни өчен?

Ромео

Мин төш күрдем.

Меркуцио

Мин дә күрдем.

Ромео

Нәрсә күрдең?

Меркуцио

Төш күрүнең мәгънәсез эш икәнлеген.

Ромео

Ләкин минем күргән төшем гел юш килә.

Меркуцио

Һәммәсе дә королева Маб шуклыгы.
Ул феялар дөньясында кендек әби.
Гәүдәсе аның шундый нәни, мэр кулында
Җемелдәгән йөзек кашы кадәр генә.
Төннәрен ул иң вак тузан бөртекләрен
Җигеп ала мичәүләп тә, без йоклагач,
Безнең борын буйлап үзенең фәйтунында
Рәхәтләнеп әрле-бирле җилдерә башлый.
Тәгәрмәче аның песи борчагыннан,
Алъяпкычы вак саранча канатыннан,
Мичәү бавы шундый юка пәрәвездән,
Ә камыты — көмештәй саф чык тамчысы.
Уңган кызның тырнак астындагы кер күк,
Нәни генә черки тоткан дилбегәсен.
Кулындагы чыбыркысы шактый мулдан,
Шундый болгый, хәтта черки дә димәссең.
Фәйтунының көймәсе аның, беләсезме,
Буш чикләвек кабыгыннан, ул Фәйтунны
Сихерченең балта остасы тиен белән
Нәкышчысы коңгыз ясап биргән аңа.
Шул фәйтунда таң алдыннан гашыйкларның
Баш миенә томырылып чабып керә,
Һәм гашыйклар төшләрендә наз күрәләр.
Зур түрәнең бөкресенә менеп китсә,
Тегесе шундук зур дәрәҗә күрә төштә.
Иләмсез зур мыегына кагылуга,
Ришвәт күрә башлый шундук комсыз судья.
Яшь кызларның иреннәрен кытыкласа,
Тегеләр төштә үбешәләр, һәм шаян Маб
Тәмле тамак кызыйларның иреннәрен
Бетчә белән каплый да тиз алга чаба.
Көне-төне суд сукмагын таптаучының

Каш арасын кашып узса, теге мескен
Дәгъвалашу ләззәтенә чума тәмам.
Әгәр дә Маб дуңгыз кылы белән шунда
Йоклап яткан поп танавын кытыкласа,
Поп төшендә бай мәхәллә күрә башлый.
Ә кайчак ул йоклап яткан берәр солдат
Якасына чабып керә җан-фәрманга.
Теге шундук төштә сугыш күрә башлый.
Ура кычкыра, дошманнарын чәнчи, кадый,
Күз алдында испан кылычы, барабаннар,
Икешәр чиләк сыешлы шәп зур бокаллар.
Һәм ул кинәт коты алынып уяна да
Дер-дер калтырап чукына һәм кабат ава.
Болар бар да Маб ханымның шуклыклары.
Ул аранда ат ялларын үреп куя.
Чәчне-чәчкә бәйләп тәмам киез ясый,
Тарыйм дисәң, бәла-каза килеп чыга.
Чалкан йоклаучыны күрсә, өстенә ята,
Ә тегесе бастырыла, тәмам шаша.
Төшләрендә бала тапканнарын күреп
Аның астында япь-яшь кызлар ыңгыраша.
Менә шул Маб...

Ромео

Меркуцио, булды, җитте.
Телгә беткән лыгырдык син.

Меркуцио

Мин бит сезгә
Төш күрүнең хикмәтләрен генә сөйлим.
Төшләр алар — кешеләрнең мәрткә киткән
Акылында туа торган буш хыяллар.
Җиңеллекнең үзе кебек җиңел алар,
Өстәвенә ифрат та үзгәрүчән.
Бер төньякка, бер көньякка борыла торган
Юнәлеше үзгәрүчән җил шикелле.

Бенволио

Артык акрын кыймылдыйбыз. Синең җилең
Безгә дигән ашны суытып куймагае.

Ромео

Акрын түгел, чамадан тыш ашыгабыз.
Күңелем сизә — бу яхшыга илтмәячәк.
Бүген биредә, шушы балда минем өчен
Зур һәлакәт туып килә, ул әлегә
Билгесезлек томанында яшеренгән.
Тик бераздан гомеремне өзәчәк ул,
Ниндидер бер куркыныч сәбәп аркасында.
Корабымны алга әйдәүче күптән инде
Җилкәннәрне хасиятләп корып куйган.
Әйдә керик, әфәнделәр!

Бенволио

Бәр барабан!

Чыгып китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулетти йортындагы зал. Музыкантлар. Тастымаллар тоткан хезмәтчеләр.

Беренче хезмәтче. Кая теге капкорсак? Антонны әйтәм. Ник җыештырырга булышмый ул? Тагын калдык-постыкка ябышканнардыр инде! Кызган таба ялатасы нәрсә!
Икенче хезмәтче. Эшмени бу, бөтен мәшәкатьне бер-ике кеше өстенә йөкләделәр дә куйдылар, җитмәсә, аларының да куллары юылмаган.
Беренче хезмәтче. Бизәкле урындыкларны кертегез. Савыт-сабаны әнә стена буена куегыз. Берүк көмеш табакларны саклый күрегез. Әй, сөеклем, миңа бераз прәннек яшереп алып кал әле. Әгәр дә мине сөям дисәң, капка каравылчысын да кисәтеп куй, пычак кайраучы белән Неллины тоткарламый кертеп җибәрсен. Антон, дим, капкорсак!
Өченче хезмәтче. Мин биредә. Нигә бугаз ертасың?
Беренче хезмәтче. Зур залда дөнья бетереп эзлиләр бит сине, акыралар-бакыралар — сүз белән генә әйтеп аңлата торган түгел.
Өченче хезмәтче. Ничек барысына да өлгерим, урталай ярыла алмыйм бит инде. Җәһәтрәк, җәһәтрәк, егетләр! Кыймылдагыз! Кем эшләми, шул ашамый.

Капулетти, Капулетти ханым, Джульетта, Тибальт һәм Капулетти ыруының башка әгъзалары залга чыгып, битлек кигән кунакларны
каршылыйлар.

Капулетти

Әфәнделәр, рәхим итегез! Бүген бездә
Аягына сөял чыкмаган туташларның
Һәммәсенә эш җитәрлек таңга кадәр.
Йә, ни дисез, чибәркәйләр? Кайсыгызның
Кыюлыгы җитәр икән баш тартырга?
Аягына сөял чыккан аның диеп,
Шундук данын чыгарабыз, сак булыгыз.
Күрәсезме, язмышыгыз безнең кулда.
Рәхим итегез, әфәнделәр! Кайчан гына
Мин үзем дә туташларның колагына
Мәхәббәти сүзләре әйтеп шыпырт кына
Әсир итә торган идем. Ай, заманнар...
Үтте-китте ул заманнар...

Ромео, Меркуцио, Бенволио һәм башкалар керәләр.

Сәлам, дуслар!
Музыкантлар, уйнагыз! Әй, егетләр, кызлар,
Һәммәгез дә түгәрәккә, йә, биегез!

Музыка. Кунаклар бии башлыйлар.

Ник караңгы? Яктырак булсын, ут бирегез,
Урындыклар, өстәлләрне читкә этегез,
Мичнең утын сүндерегез, болай да эссе.
(Үзенең абзасына.)

Биегәннәрен карап торсаң, йөрәк түзми...
Юк, юк, абзый, утырыгыз, безгә кая!
Шуны әйтегез: кайчан әле сезнең белән
Соңгы тапкыр биедек без маскарадта?

Өлкән Капулетти

Минемчә, бер утыз еллап бардыр инде.

Капулетти

Юк, алай ук юктыр әле, әйдә саныйк!
Люченцоның өйләнүенә ничә ел бар?
Егерме биштән дә артык түгел. Исеңдәме?
Аның туенда биегән идек соңгы тапкыр.

Өлкән Капулетти

Ни сөйлисең? Люченцоның малаена
Күптән утыз тулды бугай.

Капулетти

Юк ла инде,
Әле балигъ булуына да бер ел гына.

Ромео
(үзенең хезмәтчесенә)

Әнә теге егет белән бии торган
Гүзәл туташ кем икән ул?

Хезмәтче

Белмим, синьор.
Ромео

Балкышыннан факел уты тоныкланды.
Кара гарәп кызы таккан алкадагы
Асылташтан да ул хәтта ныграк балкый.
Бу дөнья өчен, юк, ул артык кыйммәт бүләк.
Җыен чәүкә арасында ул гүзәлнең
Ак күгәрчен икәнлеген шундук күрдем.
Хәзер барып күзләренә багам аның,
Чын сөюнең нинди булуын мин аңладым.
Гүзәллекнең ни икәнен әлегә кадәр
Каплап торган миңа ялган алиһәләр.

Тибальт

Бу — Монтекки тавышы, тиз бул, кылыч китер.
Ул кабахәт битлек киеп монда кереп
Безнең гаилә тантанасын мыскылларга
Батырчылык итә, ярый, карап карыйк:
Тапкырлыкта без дә аннан ким түгелбез,
Ул гомере белән түләр моның өчен.

Капулетти

Әй, кадерлем, нигә тавыш куптарасың?

Тибальт

Өйдә дошман. Ул — Монтекки! Ничек узган!
Бернигә дә карамыйча бәреп кереп,

Безне мыскыл итмәкче ул маскарадта.

Капулетти

Ромеоны әйтәсеңме?

Тибальт

Шул, кабахәт.

Капулетти

Акылыңа кил. Нигә аңа бәйләнәсең?
Күрәсең бит, үзен ничек әйбәт тота.
Веронада затлылыкның үрнәге итеп
Халык аны кабул итә бертавыштан.
Дөньяның бар байлыгын тәкъдим итсәләр дә,
Мин үземнең өйдә аны кимсеттермәм.
Хәзер сиңа боерык шушы: калдыр аны.
Әгәр мине абзаң итеп санасаң, син,
Күтәр күңелең, башка болай каш җыерма.
Урынсызга өрелеп йөрү — ахмаклык ул.

Тибальт

Урынсызга түгел бер дә, бар да урынлы —
Чакырылмаган кунакны һич җенем сөйми...

Капулетти

Юк, сөярсең. Сөйдерермен. Әмер биреп.
Ишетәсезме? Нәрсә ди бит! Әйтерсең лә
Мин түгел, ә ул хуҗа бүген биредә.
Җене сөйми, имеш! Кара, нишләмәкче —
Минем өйдә кунакларны пыр туздырып
Ызгыш-талаш чыгарырга ниятләгән.
Хуҗа булган. Күр син аны. Ах, утаман!

Тибальт

Ләкин, абзый, бу бит оят.

Капулетти

Җитте, дәшмә!
Тиз тынычлан!
(Кунакларга.)
Шулай, шулай. Юк, булмас ла!
(Тибальтка.)
Абзасына акыл өйрәтмәкче була!
(Кунакларга.)
Юк, юк, булмас!
(Тибальтка.)
Җәнҗалчы син, тәрбиясез!
Үз-үзеңне тотарга өйрән.
(Хезмәтчеләргә.)
Ут бирегез!
(Тибальтка.)
Яхшылыкта өйрәнмәсәң, өйрәтермен.
(Кунакларга.)
Бердәмрәк булыгыз, дуслар, бердәмрәк!

Тибальт

Усаллыкның җиңүен танып китәргәме?
Ярый, китәм. Әмма ләкин аң булыгыз!
Үз каныгыз түгелүгә сәбәп булыр
Сезнең шушы чакырылмаган кунагыгыз.
(Китә.)

Ромео
(монах киеменнән, Джульеттага.)

Тупас кулым белән тоттым кулыгыздан.
Нәзер әйтәм арыныр өчен шул языктан:
Иреннәр ул изге урынга хаҗ кылсыннар,
Гөнаһ эзен үбеп юкка чыгарсыннар.

Джульетта

Изге ата, кул кысу һич гөнаһ түгел,
Бер-береңә сәлам бирү чарасы тик.
Хаҗ кылучы изге урынга табына гына,
Изге урынга кагылырга ярамый бит.

Ромео

Иреннәрне Ходай безгә ник биргән соң?

Джульетта

Дога кылыр өчен биргән, изге ата.

Ромео

Шулай булгач, сүзләремә колак салып,
Эш кушыгыз сез аларга йә бер дога.

Джульетта

Сүзегезгә колак салам, әмма иелмәм.

Ромео

Иелмәгез, изге ана, үзем үреләм.
(Джульеттаны үбә.)
Менә хәзер гөнаһлардан арындым мин,
Бер гөнаһ та калмагандыр иреннәрдә.

Джульетта

Аның каравы гомеремдә беренче кат
Гөнаһ ягылып калды минем иреннәргә.

Ромео

Соң, алайса, кире бирегез.

Джульетта

Юк, кирәкми.
Сезне болай үбешергә кем өйрәтте?

Тәрбияче

Әниең чакыра сине, туташ, сүзем бар, ди.

Ромео

Ә әнисе кем соң аның?

Тәрбияче
Белмисезме?
Шушы йортның хуҗасы ул — хуҗабикә.
Ә мин — биредә тәрбияче. Әле генә
Сез сөйләшеп торган кызның сөт анасы.
Әйтеп куям: бу туташка өйләнүче
Хәзинәгә тап булачак.

Ромео
Ничек, ничек?
Капулетти кызы булып чыктымы әллә?
Дошман кулына төштем, димәк, мин җәтмәдә!

Бенволио

Йә, саубуллаш. Күрәм, уен барып чыкты.

Ромео

Кирәгеннән артыграк булды хәтта.

Капулетти

Әфәнделәр, нишләп иртә кузгаласыз?
Хәзинәдә бары белән сыйланыгыз.
Булмый дисез? Ашыгасыз? Ни дип әйтим.
Рәхмәт сезгә. Хәерле юл. Сау булыгыз.
Кунакларга юлны әйбәт яктыртыгыз!
Ә мин авам бер кырыйга. Бик арыдым.
Вакыт та соң. Йокы килә. Булды, йоклыйм.

Капулетти һәм башкалар чыгып китәләр.

Джульетта
(тәрбиячесенә)

Әйтче, даям, кем ул теге егет?
Ишек янындагы почмакта?

Тәрбияче

Тиберьо карт улы.

Бенволио чыгып китә.

Джульетта

Ә тегесе —
Чыгып баручысы?

Тәрбияче

Анысы
Яшь Петручьо бугай, ялгышмасам.

Меркуцио чыгып китә.

Джульетта

Аңа ияргәне кем тагын?
Биюгә дә катнашмады бер дә...

Тәрбияче

Анысын белмим.

Джульетта

Барчы, белеп кер.
(Тәрбияче кайтырга җыенган кунаклар янына юнәлә.)
Ул өйләнгән булса, шундук миңа
Кәфен кистерсеннәр никахка.

Тәрбияче
(әйләнеп килә)

Исеме аның Ромео. Әтиеңнең
Кан дошманы — Монтекки улы.

Джульетта

Нәфрәтемдә дөрләр кешене
Мин белмичә сөйдем, йә, нигә?
Нәрсә көтим хәзер язмыштан
Дошман өчен җан аткан көйгә?

Тәрбияче

Нәрсә дисең?

Джульетта

Юк, юк, болай гына.
Юк-бар шигырь шунда. Бүген балда
Колагыма кереп калган иде.

Капулетти ханым

Джульетта!

Тәрбияче

Ишетәбез! Беләм, беләм!
Әйдә, кызым, кунаклар да таралышты.
Без дә керик, күгәрченем, әнкәң дәшә.

Китәләр.

Хор

Тәүге сөю үлем кочагында,
Нинди көчле иде ул кичә.
Джульеттаны күргәч, Ромео
Иске ярдан тәмам ваз кичә.
Ике гашыйк мәңге бергә булыр,
Аерып булмас кебек аларны.
Тик күптәнге ызгыш һаман да
Упкын булып бүлә араны.
Кызның гаиләсендә Ромеоны
Күралмыйлар, дошман итәләр.
Кайчан тагын күрешерләр алар,
Кайчан җимерелер киртәләр?
Мәхәббәт ул илаһи нәрсә,
Гашыйкларга кавышу юлын,
Кирәк икән, үзе күрсәтә.

Хор чыгып китә.

Икенче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулеттиларның бакча алды. Ромео керә.

Ромео

Кая китим, йөрәк биредә калгач?
Җир тирәли әйлән, бичара ай!

Койма аша төшеп бакчага кереп китә.

Бенволио

Ромео, тукта!

Меркуцио

Ул бит юләр түгел:
Күптән өендә йокы симертәдер.

Бенволио

Юк, бакчага төште, койма аша,
Катырак дәш аңа, Меркуцио.

Меркуцио

Дәшү генә түгел, изге рухлар
Чакыргандай чакырам, менә күр.
Ромео! Акылыннан язган гашыйк!
Өрәк сыман чыгып бас каршыма!
Бер аваз бир шунда йә булмаса
Шигырь-мазар сөйлә бераз гына.
Һәм син анда «сөю» белән «көю»,
«Кан» белән «җан» сүзен рифмала.
Венерага яки Купидонга
Әйт берәр сүз шунда саллы гына:
Күзең чыккан сукыр азгын, диген.
Йә сөйләп бир хәерче кыз белән
Кофетуа патша тарихын.
Тыны да чыкмый, хәтта селкенми дә.
Үлгән, ахры, ә мин юләр чакырам!
Соңгы тапкыр Розалина хакына,
Аның матур елтыр күзләре,
Ак маңгае, төп-төз аяклары,
Дерелдәп торган нечкә билләре,
Билдән түбән башка урыннары
Хөрмәтенә чакырам, чык, туган.

Бенволио

Ярый, булды, йә ачуы чыгар.

Меркуцио

Чыкмас, чыкмас. Әгәр дә мәгәр

Аның сөйгән яры янына
Аны түгел, башка берәүне мин
Чакырып китереп калдырсам шунда,
Ачуланыр сәбәп булыр иде,
Ләкин бит мин алай итмәдем,
Ромеоның үзен дәштем әнә.
Моның өчен үпкәләргә түгел,
Бәяләргә тиеш ул мине.

Бенволио

Киттек моннан. Сукыр гыйшкы аны
Куак арасына куып кертте.

Меркуцио

Сөю сукыр булса, аткан угы
Төгәл тимәс иде бу тикле.
Ул, мөгаен, куак арасында
Сөйгәненең алма шикелле
Уч төбенә өзелеп төшмәвенә
Утырадыр әле көенеп.
Беркатлы син ахмак, Ромео!
Йә, ярый, хуш, кайтып йоклыйм, туган.
Җилләр уйный синең бу түшәктә.
Киттек, Бенволио.

Бенволио

Әлбәттә,
Үзен табуларын теләмәгән
Кешене ник эзләп йөдәргә?

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулеттилар бакчасы. Ромео керә.

Ромео

Көлегез, көл, димәк, җәрәхәтнең
Нәрсә икәнлеген белмисез сез.
Чү! Тәрәзә нидән балкып китте?
Джульетта, ah, ул син икәнсең,
Кояштан да битәр нур сибәсең!
Тәрәзәдән карап үтер айны,
Болай да аның әнә төсе киткән,
Синең шулай балкуыңны күреп
Бәгъре көя тәмам көнчелектән.

Тәрәзәдән Джульетта күренә.

Табынма син сафлык алласына.
Салып ат тиз гыйффәт пәрдәсен.
Килешми ул сиңа, артык төссез,
Әнә Диана үзе бөркәнсен.
Ah, сөеклем, хәят, шатлыгым син!
Әнә бит ул, хәтта үзенең

Кем икәнен белми басып тора.
Нидер сөйли, сүзе ишетелми.
Ишетелмәсә, күзләр белән дә бит
Аңлашырга мөмкин үзара!
Ахмактыр мин! Аның белән әнә
Сөйләшәләр икән башкалар.
Ике йолдыз күктән күз кысалар —
Китмәкчеләр икән каядыр.
Шул арада күкне яктыртуны
Күзләреннән сорыйлар аның.
Ай, чынлап та аның күзкәйләре
Зәңгәр күктә торса җемелдәп,
Кошлар сайрап җибәрерләр иде
Кара төнне алсу таң диеп.
Басып тора. Тирән уйда үзе.
Нәфис кулын куйган ияккә.
Менә хәзер аның перчаткасы,
Перчаткасы булалсаң икән!

Джульетта

Ah, нинди зур хәсрәт!

Ромео

Нидер әйтте.
Исе китеп җирдән күзәтүче
Кешеләрнең баш түбәсендә,
Үрелеп буй җитмәс биеклектә
Очып йөргән фәрештә сыман,
Син дә менә минем баш өстендә
Караңгылык ертып салмак кына
Талпынасың, нурлы фәрештәм.

Джульетта

О, Ромео, нигә синең исем
Ромео булган? Ваз кич аннан.
Әтиеңнән ваз кич, булмый икән,
Хатының ит мине, ул чагында
Капулетти булмас минем исем.

Ромео

Тыңларгамы, җавап бирергәме?

Джульетта

Исемең генә бары дошман миңа.
Син бит ул син, юк, Монтекки түгел.
Монтекки ни? Нәрсә аңлата ул?
Аяк-кулны, кашны, йөзне-башны
Кем дә булса шулай атыймыни?
Башка исем беткәнме әллә сиңа?
Исем нәрсә? Роза гөлен әнә
Исеме белән ата, атама,
Ул барыбер исен җуймаячак.
Синең дә бит исем үзгәрткәннән

Камиллегең һичбер зыян күрмәс.
Үтенеп сорыйм: ваз кич бу исемнән,
Ә алмашка менә мине ал син,
Бөтенләем белән синеке мин!

Ромео

Бир кулыңны! Димәк, мин — синеке?!
Шулай дисәң исемем үзгәрәчәк,
Ромео булып калмас өчен.

Джульетта

Кем ул анда шушы караңгыда,
Үтеп керә татлы хыялыма?

Ромео

Исememне сиңа кем дип әйтим?
Юк, әйталмыйм, ул җирәнгеч хәзер.
Ул исемне хатта күрсәм дә мин
Мең кисәккә ертып ташлар идем.

Джульетта

Биш-алты сүз хәтта әйтмәс борын
Тавышыңнан сине танып алдым.
Син Ромео? Ягъни Монтекки бит?

Ромео

Ah, сөеклем, сиңа ошамагач
Икесе дә хәзер тыелган исем.

Джульетта

Үтә алмаслык биек койма аша
Ничек кердең? Нәрсә кирәк монда?
Туганнарым әгәр күреп алса,
Үтерәчәкләр сине шушы урында.

Ромео

Мәхәббәтем алып керде мине
Таш коймалар аша канатында.
Үз дигәнен итми калмый сөю,
Туганнарың алар нәрсә миңа!

Джульетта

Очратсалар әгәр, үтерәчәкләр.

Ромео

Үтерсеннәр, синең күз карашың
Мең хәнҗәрдән мең кат куркынычрак.
Бер ягымлы караш ташла, зинһар,
Сакланырга калкан булыр миңа!

Джульетта

Күзләренә берүк чалына күрмә!

Ромео

Төн пәрдәсе мине каплап торыр,
Тик син генә миннән йөз чөермә.
Булмый дисәң, үтерсеннәр әйдә.
Синең наздан мәхрүм яшәгәнче,
Мин үлемне артыграк күрәм.

Джульетта

Бирегә юлны сиңа кем күрсәтте?

Ромео

Мәхәббәтем аны үзе тапты.
Мин диңгезче түгел, әмма ләкин
Җир читендә булсаң әгәр дә син,
Бу хәзинә өчен диңгез ярып
Юлга чыгар идем мин хәзер үк.

Джульетта

Йөрәгемне ачтым синең алда,
Оятымнан хәзер кая керим?
Ярый әле төн пәрдәсе каплый
Дөрләп янган ике бит алмамны.
Әдәп саклап сүзләремне кире
Алмакчы да идем, тик соң инде.
Нигә кирәк икейөзлеләнү?
Син шуны әйт: мине сөясеңме?
«Әйе» диясеңне белеп сорыйм.
Тик ашыкма. Ялганлавың мөмкин.
Юпитер бит әнә гашыйкларның
Вәгъдә сүзләреннән тик көлә, ди.
Ялганлама. Бу бит уен түгел.
Бәлки, синең алда ышанучан
Һәм беркатлы булып күренәмдер?
Ул чагында синең бу фикерне
Үзгәртергә миңа туры килер.
Тәкъдимеңне кире кагачакмын.
Тик бу эшне үз ирегем белән
Эшли алмас идем беркайчан да.
Мине, әлбәттә, шашып сөйгән өчен
Бер җилбәзәк диеп уйлыйсыңдыр.
Ләкин бел син: тыштан гына тыйнак,
Саф кыз булып йөргән бик күпләрдән
Минем намус күпкә чистарак.
Хисләремне чәчеп салмас өчен
Сабыррак булу кирәк булган.
Караңгыда шулай кача-поса
Тыңлап йөрерләр дип кем уйлаган.
Кичер минем кайнар хисләремне,
Ә риясыз әйткән сүзләремне
Җиңел генә яуланырга тиеш
Йомшаклык дип кабул итмә берүк.

Ромео

Агачларны көмеш нурга күмгән
Айның үзе белән ант итәмен...

Джульетта

Ул ай саен йөзен үзгәртә бит,
Ай белән, юк, зинһар, ант итмә син.
Мәхәббәтең юкса тиз үзгәрер.

Ромео
Ни белән итим?

Джульетта

Берни белән итмә.
Ант итәсең килсә, ул чагында
Ант итәргә лаек иң бөек зат —
Үзең белән ант ит. Ышанырмын.

Ромео

Ант итәмен, йөрәгем типкән чакта...

Джульетта

Булды, булды, башка кирәк түгел.
Мин ышанам. Бик нык яратсам да,
Куркам никтер. Бар да бик тиз булды,
Ашык-пошык булды, кызган баштан.
«Яшен» диеп әйтеп өлгергәнче,
Яшьнәп сүнгән елгыр яшен сыман.
Хәерле төн! Яңа бөреләнгән
Бәхетебез тизрәк чәчәк атсын.
Күңелем тулы дөнья аклыклары,
Татлы төшләр булып керсен шулар.
Хәерле төн сиңа! Тыныч йокы!

Ромео

Ничек хәзер сине калдырып китим?

Джульетта

Йә, әйт, сиңа тагын нәрсә җитми?

Ромео

Мин ант иттем, инде җавап көтәм.

Джульетта

Мин беренче булып ант иттем һәм
Киләчәктә түгел, ә үткәндә
Калуына шуның хәзер үкенәм.

Ромео

Әллә антыңны кире алмакчымы?

Джульетта

Әйе, ләкин кабат бирер өчен.
Күңелемдә яткан саф хәзинәм
Минем карамакта түгел күптән.
Сөю хисем олы диңгез кебек

Иксез-чиксез үзе, үзе тирән.
Күпме бүләк итсәм, ул шулкадәр
Арта гына бара.

Арттан Тәрбияченең чакырган тавышы ишетелә.

Хуш. Дәшәләр.
Керәм, керәм. Йә, бар, тик онытма.
Тукта, бәлки, тагын чыгармын.
(Китә.)

Ромео

Илаһи төн, изге илаһи төн!
Ә бәлки, бу татлы төш кенәдер?
Иксез-чиксез зур икән ул шатлык.
Әкияттәге сыман могҗиза бу!

Джульетта кабат керә.

Джульетта

Ике генә сүз әйтимче тагын.
Аннан хушлашырбыз, сөеклем.
Чынлап торып миңа өйләнергә
Ниятең бар икән әгәр дә,
Кайда, кайчан никах булачагын
Хәбәр ит син миңа иртәгә.

Иртүк сиңа шуны белер өчен
Миннән кеше килер. Кирәксә,
Бөтен барлыгымны сиңа баглап,
Синең арттан китәм, син дәшсәң.

Тәрбияче
(сәхнә артыннан)

Күгәрченем!

Джульетта

Хәзер! Бер генә минут!
Алдау уе белән йөрсәң әгәр,
Ул чагында, зинһар...

Тәрбияче
(сәхнә артыннан)

Күгәрченем!
Килеп йөрмә бүтән, калдыр мине.
Ә иртәгә кеше җибәрермен.

Ромео

Мин ант итәм...

Джульетта

Хәзер саубуллашыйк.

Йөз мең кабат хәерле төн телим.
(Китә.)

Ромео

Карашыңнан синең мәхрүм калгач,
Сагышымнан йөз мең ah орырмын.
Сөйгән ярлар янына мәктәбеннән
Качкан бала сыман ашыгабыз.
Аерылгач исә, киресенчә,
Кыш мәктәпкә барган бала кебек
Салмаклана безнең адымыбыз.
(Китә башлый.)

Джульетта яңадан балконга чыга.

Джульетта

Ромео! Ah, кошлар алдый торган
Сыбызгы да юк бит кулларымда,
Лачынымны чакырып алыр идем.
Кычкыра алмыйм, чөнки мин тоткында.
Юкса хәзер мескен кайтавазны
Бертуктаусыз тавышы карлыкканчы,
«Ромео, бәгърем, син кая?» дип,
Кычкырырга мәҗбүр итәр идем.

Ромео

Кабат чакыра мине йөрәк парәм.
Көмеш моңнар булып яңгырый икән
Гашыйкларның тавышы төнлә белән.

Джульетта
Ромео!

Ромео
Бәгърем!

Джульетта

Әйт, иртәгә
Сәгать ничәләргә синең янга
Кеше җибәрергә?

Ромео

Тугызларга.

Джульетта

Аңа кадәр егерме ел әле!
Көтү газап... Нәрсә әйтмәкче идем?

Ромео

Син хәтерлә, ә мин көтеп торам.

Джульетта

Алларымда сине тотар өчен,
Мин бит аны тагын онытачакмын.

Ромео

Хәтерлә дә оныт, шул арада
Үз-үземне онтып басып торыйм.

Джульетта

Таң сызыла. Инде китсәң икән.
Тик әйт, синнән ничек аерылырга?
Ефәк җепкә тагып очыра торган
Асылкоштан безнең ни аерма?
Җепне бераз бушатуга, кошчык
Оча башлый. Ләкин аны шундук
Тартып ала үзенә җеп хуҗасы.
Без дә синең белән нәкъ шулай ук.

Ромео

Нәкъ шундый ук кошың булыр идем.

Джульетта

Мин үзем дә сиңа шуны телим.
Кочагымда сине үтергәнче
Назлар идем ул чак. Йә, ярый, хуш.
Хуш дип әйтәм, үзем китә алмыйм.
Синең янда шулай мең ел буе
Тыныч йокы теләп торыр идем.
(Китә.)

Ромео

Хуш, сөеклем! Татлы төшләр күр син,
Күкрәгеңә шуннан шатлык иңсен.
Тыныч йокы сиңа теләп калам.
Үзем исә хәзер киңәш сорап
Изге ата хөҗрәсенә чабам.
(Китә.)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лоренцо хөҗрәсе. Тырыс тоткан Лоренцо керә.

Лоренцо

Төн ачулы, ә көн әкрен генә
Болытларны алсу төскә мана.
Исерек сыман әлҗе-мөлҗе килеп,
Караңгылык һаман кача аннан.
Иртәнге чык кибеп җитмәс борын,
Күтәрелмәс борын төнге томан,
Үләннәрнең сайлап шифалысын
Һәм йоклата торган агулысын
Тырысыма хәзер җыеп салам.
Җир-ана ул бөтен табигатькә,
Табут та ул аңа һәм бишек тә.
Анасыдай күреп имә аны
Күкрәгендә яткан барча матдә.

Ул үзенең һәрбер баласына
Үзенә генә хас бер сыйфат биргән.
Һәрбер ташы, һәр чәчәге аның
Бинигая көч-куәткә ия!
Җиһандагы һәрбер җепсел белән
Горурлана ала чын күңелдән.
Тик бу әле җисем нигезендә
Гел яхшылык ята дию түгел.
Һәрнәрсәнең ике ягы була:
Берсе зыян булса, берсе — файда.
Менә мисал: шушы матур гөлдә
Бу сыйфатлар яши икесе бергә.
Чәчәгендә аның — татлы дару,
Тамырында исә — зәһәр агу.
Бүлгәләнгән шулай безнең җан да,
Ике дошман яши безнең канда.
Яхшылыкның явызлыкка каршы
Көрәшеннән тора тормыш агышы.
Явызлыгы җиңеп чыккан адәм
Агуланган була үлем белән.

Ромео
(сәхнә артыннан)

Изге ата!

Лоренцо

Мәрхәмәтле Аллам!
Кем булыр бу болай иртә таңнан?

Ромео керә.

Син икәнсең. Сөйлә, нәрсә булды?
Нишләп әтәчләрдән иртә тордың?
Мәшәкатькә чумган картлар гына
Күз йомудан мәхрүм таң алдыннан.
Синең кебек яшьләр бу вакытта
Үлгән кебек изрәп йоклап ята.
Юкка гына болай кара төннән
Мине эзләп килмәгәнсең, беләм.
Йә сырхавың сине йоклатмаган,
Йә бөтенләй бүген син ятмаган?

Ромео

Син хаклысың. Әйе, мин ятмаган.
Тик шулай да, ата, бүген төнем
Ләззәтлерәк узды йоклаганнан.

Лоренцо

Розалина белән булдыңмы әллә?
Раббым, кичер! Син гөнаһлы бәндә!

Ромео

Розалина белән? Юк, юк, ата!
Исемен дә хәзер оныттым хәтта.

Лоренцо

Хуплыйм, хуплыйм. Тик әйт, ник балкыйсың?

Ромео

Хәзер сиңа сөйләп бирәм барысын.
Кичә балга барып яра алдым,
Һәм үзем дә каты яраладым.
Бәйлә безне, зинһар, изге ата.
Шуны сорап килдем синең катка.
Минем өчен изге хөҗрәң юлы!
Үч сакламыйм, кичтем дошманымны.

Лоренцо

Ачыграк сөйлә. Бик болгатма.
Гөнаһың ни, улым? Әйт шул хакта.

Ромео

Капулетти кызын өзелеп сөям,
Ул да минем өчен яна-көя.
Бер-беребездән башка бер минут та
Тора алмыйбыз бүтән. Эш никахта.
Кайда, ничек гашыйк булганымны
Соңрак сөйләрмен мин, әйдә башта,
Бүген үк сезгә никах укыйм, диеп,
Вәгъдә бир син миңа изге ата.

Лоренцо

Изге Франциск, нинди алмашыну!
Розалина исемен алмый телгә.
Бу яшьләрнең мәхәббәте хәзер
Йөрәгендә түгел, күзләрендә.
Ah, җилбәзәк, әле кайчан гына
Башка исем иде хыялында.
Бертуктамый тоташ иртә-кичен
Күпме күз-яшь түктең аның өчен?
Буш чокырга бер дә файдасызга
Тозлы суны шактый мул агыздың.
Кайчан тынды әле сыкрауларың?
Кайчан сүнде соңгы ah оруың?
Күз төбеңдә һаман яшь таплары,
Юарга да өлгермәдең, ахры?
Кем хисләре болар, синекеме,
Аңлашылмый, аңлат, йә, кемнеке?
Розалина исемен күккә чөеп
Шашып йөргән әллә син түгелме?
Тотырыксыз булгач ир-ат сүзе,
Хатыннардан инде ни көтәсе?

Ромео

Розалина өчен әрлисең бит?
Аны сөйгән өчен, шулаймы, ата?

Лоренцо

Җилбәзәклек чире йоккан сиңа.

Ромео

Шуңа күрә аннан суындым да.

Лоренцо

Аннан суынып тизрәк яңаларга
Өр-яңадан гашыйк булыргамы?

Ромео

Иске ярны чутка кертмик, ата,
Иске яр — боз, бусы — ялкын аның.

Лоренцо

Боз булуы әйбәт. Ул бит синең
Аның өчен янып-көюеңнең
Аръягында салкын бушлык булуын
Алдан сизеп, белеп торган, улым.
Тик мин синең яклы, яшь җилкуар.
Ярдәм итәм кулдан килгән кадәр.
Болай эшләвемнең хикмәте бар:
Шушы никах, бәлки, озак еллар
Ике арада барган канлы ызгышка
Кабатланмас итеп нокта куяр.

Ромео

Киттек тизрәк!

Лоренцо

Сабыр, ашыктырма,
Ашыкканның ашка пешүе бар.

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урам. Бенволио белән Меркуцио керәләр.

Меркуцио

Ромеоны җир уптымы әллә?
Кайда йөри, шайтан алгыры?
Белмисеңме? Өйдә кунды микән?

Бенволио

Юк, сораштым, өйдә кунмаган.

Меркуцио

Болар бар да Розалина эше.
Ул үзенең шушы мәгънәсез,
Шакшы уены белән Ромеоны
Шыр дивана ясый, күрерсез.

Бенволио

Ишеттеңме? Капулетти картның

Кан кардәше Тибальт ниндидер
Хат җибәргән, имеш, Ромеога.

Меркуцио

Менә күрерсез, дуэльгә чакыра ул аны.

Бенволио

Чакырса, Ромео җавап бирер.
Меркуцио. Әлбәттә! Хатка каршы хат язуның нәрсәсе бар аның.
Бенволио. Юк, чакыруга чакыру белән җавап бирер, дим мин.
Меркуцио. Мескен Ромео! Теге ак чырайлы явыз кызның кара күзләре җәрәхәтләгәннән соң, ул болай да мәет бит инде. Колакларын мәхәббәт җырлары тишкәләп бетергән, ә йөрәгенә исә Амур угы кадалган. Шушы хәлендә аңамы соң Тибальт белән тартышырга!
Бенволио. Ә Тибальт үзе кем соң ул кадәр?
Меркуцио. Улмы? Арттырып әйтүем түгел, песиләр патшасы Тибальттан да болайрак. Дуэль мәсьәләсенә килгәндә — җен кебек. Шундый оста сугыша, нотага карап җыр башкара дияр-сең: бер, ике, ә өч дигәндә инде кылычы сабына кадәр корсагыңны тишеп кергән була. Шундый дуэльче, ул сугышканда, авыз ачып шаккатып карап торасың. Ә аның үлемсез passadolары, punto reversoлары, haiлары!
Бенволио. Нәрсәләре?
Меркуцио. Анысы тегеләр лыкылдавы инде, үләт кырып бетерсә иде шул килмешәкләрне. Бернәрсә булса, хәзер: «Алла белән ант итәм, менә бу, ичмасам, кылыч! Бәхәсләшә алам, менә бу ир дисәң дә ир! Чәнчелеп китим, искиткеч гүзәл фахишә!» Каян җыелып беткән диген син ул чит ил чебеннәрен pardonnes moi, bon, bonнары белән тәмам туйдырып бетерделәр. Шуларның чамасыз киң ыштаннары аркасында иске эскәмияләрдә утырыйм дисәң, бер артыңны терәрлек тә урын табалмыйсың!

Ромео керә.

Бенволио. Күр әле, Ромео түгелме соң бу?
Меркуцио. Бичара, коры сөяккә генә калган бит, нәкъ киптергән балык! Ай мескен адәм баласы, нинди генә кыяфәтләргә кертми сине язмыш, бу кадәр дә балыкка охшап калырсың икән! Менә кем ул шигырь дәрьясына чумып Петрарканы алыштырыр кеше! Әле бит, җитмәсә, Петрарканың Лаурасы моның сөйгәне янында шапшак бер асрау гына! Бонжур, Ромео әфәнде! Мин сезнең француз ыштаныгызга француз сәламе юллыйм! Кичә безне ярыйсы гына утырттыгыз, ә?
Ромео. Икегезгә дә сәлам. Утырттым? Ничек итеп?
Меркуцио. Ә менә шулай: бергә барырга дип вәгъдәләшкән идек, ә сез үзегез генә шылдыгыз.
Ромео. Зинһар, кичер, сөекле Меркуцио, минем эшләр хәзер баштан ашкан! Алда шундый эшләр торганда, вәгъдә кайгысымыни.
Меркуцио. Шулай булмыйча! Алда синекедәй эшләр торганда, тез башларына шактый авырлык килә торгандыр инде.
Ромео. О, нәзакәтле фикерләүнең гаять гүзәл үрнәге бу!
Меркуцио. Шулай булмыйча! Мин бит нәзакәт гөле.
Ромео. Розадыр, мөгаен.
Меркуцио. Нәкъ шулай. Өстенә бастың.
Ромео. Минем башмак каптырмасындагы роза кебегрәк инде алайса.
Меркуцио. Әйбәт әйттең. Искиткеч тапкырлык! Бу башмакчы тапкырлыгын берәрсе үкчәләрен сөртеп атканчы дәвам ит инде, әйдә. О, дуңгыз тиресе кебек, күпме тартсаң, шулкадәр сузыла һәм тузмый торган җир йөзендәге бердәнбер тапкырлык!
Ромео. Аның каравы синеке тузган. Тарта-суза торгач, өзелеп чыккан тапкырлыгыңны йөгән-сезлегең белән генә каплап тормакчы буласың түгелме соң?

Меркуцио. Менә бу шаяруың ярыйсы! Ни дисәң дә, мәхәббәт кайгысыннан ах-ух килеп елап йөрү түгел. Хәзер синең белән сөйләшергә дә була. Син хәзер элекке Ромео түгел. Үз асылыңа кайттың. Ничек бар — шулай, шулай булырга тиешсең дә. Югыйсә синең ул шайтан алгы-ры мәхәббәтең утын пүләнен чүпрәккә төреп шуны тирбәтә-тирбәтә бер почмактан икенче почмакка бәргәләнеп йөрүче, маңкалары аккан дивана хатын белән бер.
Бенволио. Ярый инде, булды, булды.
Меркуцио. Йонын тискәрегә сыпыра дип куркасыңмы әллә?
Бенволио. Бу тел чарлауның очы-кырые булмас дип куркам.
Меркуцио. Ялгышасың. Инде әйтәсемне әйтеп бетердем, менә хәзер туктыйм.
Ромео. Карагыз әле, кара, менә ичмасам тамаша!

Тәрбияче белән Петр керәләр.

Меркуцио. Игътибар, офыкта җилкән!
Бенволио. Берәү түгел, икәү: итәк белән ыштан.
Тәрбияче. Петр!
Петр. Ни боерасыз?
Тәрбияче. Җилпәзәмне бир, Петр.
Меркуцио. Җилпәзәсен бир аңа, йөзен капласын. Бераз гына кот кунар, ичмасам.
Тәрбияче. Хәерле иртә, мәрхәмәтле әфәнделәр!
Меркуцио. Хәерле кич, мәрхәмәтле ханым әфәнде!
Тәрбияче. Кич җитте дәмени инде?
Меркуцио. Шулайрак. Сезнең өчен, билгеле. Гомер кояшыгыз батып килә, диюем.
Тәрбияче. Бу нинди әдәпсезлек тагын? Нинди кеше сез?
Ромео. Бу кешене, ханым әфәнде, Ходай Тәгалә үзен үзе көлкегә калдырыр өчен яраткан.
Тәрбияче. Кызык! Үзен үзе көлкегә калдырыр өчен, дисезме? Ярый, шулай булсын. Әфәнде-ләр, кайсыгыз әйтә ала, яшь Ромеоны бу тирәдә очратып булырмы икән?
Ромео. Рәхим итегез, мин әйтә алам. Тик сез аны эзләп тапкан вакытта, яшь Ромео әлегедән бераз гына картая төшкән булыр. Ул исемне йөртүчеләр арасында иң яше мин булырмын — иң начары булмасам.
Тәрбияче. Әгәр Ромео булсагыз, минем сезнең үзегезгә генә әйтә торган сүзем бар.
Бенволио. Менә күрерсең, ул аны кая да булса кичке ашка чакырачак.
Меркуцио. Димче, димче, бозыклыкка өндәүче! Өсс! Өсс!
Ромео. Кемне өстерәсең?
Меркуцио. Куянны түгел, әлбәттә. Куян булган сурәттә дә моның ашарлык җире юк, картаеп, кибеп беткән. *(Җырлый.)*
Куян бәлеше
Ашаган кеше
Уразада да
Сагыныр шул эшен.
Әгәр дә, туган,
Карт булса куян,
Сындырыр тешең,
Күрерсең зыян.
Ромео, син кайтырга җыенасыңмы, юкмы? Төшке ашны сездә ашарга сөйләшкән идек бит.
Ромео. Бара торыгыз, хәзер куып җитәрмен.
Меркуцио. Сау булыгыз, карт синьора, сау булыгыз.

Тәрбияче

Сау булыгыз, юлыгызга ак җәймә.
Алдыгыздан артыгыз матуррак.

Меркуцио белән Бенволио китәләр.

Әйтегез әле, әфәндем, бу нинди оятсыз кеше? Бигрәк үзен әллә кемгә куя.
Ромео. Үзе сөйләгәнне тыңларга яратучы бер егет ул. Бер минут эчендә әллә ниләр сөйләп ташлый да аннары шул сүзләре өчен ай буе үкенеп йөри.
Тәрбияче. Әгәр дә ул бу сүзләрен миңа төрттереп әйткән булса, кыланышы үз башына төшәчәк. Мин аның кебек мактанчыкларның егермесен бер итек кунычына бөтереп тыгып куя алам. Миннән ничек көләргә икәнен күрсәтермен әле, Алла бирсә! Үзем күрсәтмәсәм, күрсәтүчеләр табылыр. Кешесен табармын! Кара син аны, нәрсә ди бит, оятсыз, җирбит! Син ул сүзләрне үзеңнең себеркеләреңә әйт йә булмаса сәрхуш дусларыңа. *(Петрга.)* Син дә әйбәт! Җыен адәм актыгы мине рәхәтләнеп мыскыл итә, ә ул күзле бүкән кебек авыз ачып карап тора.
Петр. Алай ук булмагандыр инде. Бер дә рәхәтләнгәннәрен сизмәдем. Эшләр алай тирәнгә китсә, түзеп торыр идеммени, шундук кылычымны тартып чыгарган булыр идем. Сугышыргa сылтау гына чыксын, әгәр закон минем якта була икән, башкалар кебек үк мин дә шундук кылычымны эшкә җигәм.
Тәрбияче. Йа Раббым, әле һаман аңыма килә алмыйм, бөтен тәнем дер-дер калтырый. Мактанчык! Адәм актыгы! Ah, әфәндем, мин бит бөтенләй башка эш белән килгән идем. Мине туташым җибәрде. Аның сезгә әйтергә кушкан сүзен әлегә әйтми торам. Әгәр дә сез аны алдарга ниятләсәгез, әфәндем, бу сезнең тарафтан бик зур әшәкелек булачак. Чөнки туташ әле бик яшь, сез дә алдасагыз, юк, яхшы кеше андый эшне эшләмәс. Сезгә килешми ул, валлаһи, килешми.
Ромео. Сабыр ит, анакай. Иң элек туташыңа миннән сәлам тапшыр. Ант итеп әйтәм...
Тәрбияче. Тапшырам, әлбәттә, тапшырам. Барысын да әйтермен. Сез шундый саф күңелле кеше. Әй шатланыр да инде балакаем!
Ромео. Соң син аңа нәрсә әйтмәкче буласың? Мин бит әле авыз ачып сүз әйтергә дә өлгермәдем.
Тәрбияче. Ант итүегезне әйтермен. Бу инде юк-бар гына түгел, затлы кеше буларак сезнең тәкъдим ясавыгыз дип уйлыйм.

Ромео

Син әйт аңа, бүген төш вакытында
Гыйбадәткә диеп чыгып китсен.
Лоренцо ата безгә никах укыр.
Онытмассыңмы? Монысы аяк ялы.

Тәрбияче

Юк, кирәкми сукыр бер тиен дә.

Ромео

Биргән чакта ал син, ялындырма!

Тәрбияче

Борчылмагыз, бар да әйбәт булыр.
Туташны мин үз кулларым белән
Тапшырырмын бүген сезнең кулга.

Ромео

Шуннан үзең чиркәү коймасының
Аръягына чык та күзәтеп тор.
Бер хезмәтчем сиңа шыпырт кына
Баудан үргән баскыч китереп бирер.
Шуның буйлап татлы ләззәт тулы
Бәхетем кыясына — сөйгәнемнең
Бүлмәсенә төнлә менәрмен мин.

Шуны эшләсәң, юмарт бүләкләрмен.
Ә хәзер бар, хәерле юл телим.
Туташыңа бик күп сәлам миннән.

Тәрбияче

Ходай гына саклый күрсен берүк!
Тик әфәндем...

Ромео

Әйт, әйт, ник туктадың?

Тәрбияче

Хезмәтчегез ышанычлымы соң?
Аңлый алмыйм. Монда мин булганда
Ул өченче кеше нигә тагын?

Ромео

Корыч кебек ышанычлы кеше,
Бер генә дә түгел, ун сынадым.
Тәрбияче. Алайса, ярый, әфәндем. Минем туташым... Ярабби бер Ходаем! Орчык башы хәтле генә сабый иде әле... Ә-ә, карагыз әле, бу шәһәрдә Парис атлы бер яшь егет бар, менә шул Парис бик тә үзенеке итәргә тели инде аны. Ләкин минем туташкаем аны бака белән бер күрә, валлаһи дип әйтәм, бака белән бер күрә. Кайчакларда Парис сезгә караганда кулайрак кияү дип юри тегенең ачуын китерәм. Нишләргә белми инде, балакаем, ачуыннан киндер кебек ап-ак булып агарып чыга. «Әфәндем, әйтегез әле, «розмарин» белән «Ромео» икесе дә бер хәрефтән башланамыни?

Ромео

Әйе, бер хәрефтән. Нигә алай дип сорыйсың?
Икесе дә «Р» га башлана.
Тәрбияче. Ай, шаян да инде үзегез! Р-Р-Р бит ул эт хәрефе. Сезнең исемегез дә, розмарин да ул хәрефтән башланырга тиеш түгел. Чөнки безнең туташ «Ромео» белән «розмарин» сүзләрен кушып шундый матур шигырьләр уйлап чыгара, ишетсәгез, шаккатар идегез.
Ромео. Туташың каршында минем өчен дә баш и.
Тәрбияче. Иярмен, мең кат иярмен.

Ромео китә.
Петр!
Петр. Ни боерасыз?
Тәрбияче. Минем җилпәзәне ал да, киттек. Әйдә, алдан бар. Йә, җәһәтрәк.
Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулеттилар бакчасы. Джульетта керә.

Джульетта

Тугызда ук киткән иде даям,
Бик тиз генә барып кайтам диеп.
Аймыл булды микән? Юк-юк, булмас.
Ялкау илче булып чыкты, димәк.
Гыйшык хәбәрчесе булыр өчен
Иң кулае йөгерек уй гына тик.
Күләгәне куып бара торган
Кояш нурыннан да ул җитез бит.

Хат ташучы күгәрченнәрне дә
Ашыктыра фикер үз артыннан.
Купидонга исә андый тизлек
Каян килә дисең? Ул да шуннан.
Төш вакыты җитте. Киткәненә
Нәкъ өч сәгать булды. Ул һаман юк.
Йөрәгендә әгәр җаны булса,
Сөйгән ярым белән ике арада
Туп шикелле очып йөрер иде.
Тере мәет кебек акрын гына
Кыймылдаудан картлар тәм табалар.

Тәрбияче белән Петр керәләр.

Кайтып килә. Даям! Ah, сөеклем!
Йә, нихәлләр? Аны күрдеңме син?
Әйт Петрга, чыксын.

Тәрбияче

Бар чык, Петр,
Ерак китмә, капка төбендә тор.

Петр китә.

Джульетта

Сөйлә, даям... Нигә борчулы син?
Төксе чырай белән шик арттырма.
Яхшы хәбәр алып кайткан булсаң,
Ник җуясың ямен каш җырып.

Тәрбияче

Тукта, тукта, бераз тын алыймчы.
Уф, арыдым! Сөякләрем сызлый,
Аякларым тәмам эштән чыкты.

Джульетта

Әйбәт хәбәр әйтсәң, мин үземнең
Сөякләрне сиңа бирер идем.

Тәрбияче

Кара, кара, ташы кызган моның!
Күрмисеңме, көчкә тын алам бит,
Синең өчен йөреп хәлдән тайдым.

Джульетта

Зарланырга үзең хәл табасың?
Кинаяләп сөйләшүең, даям,
Әйтер хәбәреңнән күпкә озын!
Эшләр ничек, бар да тәртиптәме?
Шуны әйтеп тынычландыр мине.
Әйе, дисәң, башка йөдәтмәмен.
Тәртиптәме, ничек? Йә, әйт инде.
Тәрбияче. Тәртибен инде аның менә син белергә тиеш. Үзең эзләп тапкан хәзинә. Сайлаганда минем белән киңәшмәдең, инде үзеңә үпкәлә! Ромео! Ярый инде, хәзер берни эшләп тә булмый... Болай ул үзе төскә-биткә ярыйсы гына, буе-сыны тагын да әйбәтрәк. Аяк-куллары турында сөйләп тә торасы юк. Алары мактап кына да бетерә торган түгел, һәртөрле чагышты-

рулардан өстен. Тагын нәрсә әйтим... Аллага рәхмәт әйтеп гыйбадәт кыл, балакаем. Төшке ашны ашадыгызмы әле?

Джульетта

Юк, юк. Мин бу хакта күптән беләм...
Никах турында ул нәрсә диде?

Тәрбияче

Алла, башым сызлый! Әллә инде
Егермегә чатнап ярыламы соң?
Алла, билем! Алла, Алла, билем!
Ходайдан курык бераз, карт даяңны
Үләр чиккә җиткереп чаптырасың!

Джульетта

Хәлеңне аңлыйм, син дә аңла мине!
Әйт, алтыным, зинһар, ул ни диде?
Тәрбияче. Саф күңелле, чибәр, ә иң мөһиме тәрбияле кеше буларак ул болай диде... Әниең кая синең?

Джульетта

Әнием кая? Кайда булсын, өйдә.
Нинди сәер җавап! Саф күңелле,
Тәрбияле кеше буларак ул
Болай диде: «Әниең кая синең?»
Мондый ахмак җавап буламыни?

Тәрбияче

Ай Ходаем, нинди кыбырсык җан!
Ник кызасың? Әллә карт даяңны
Мунча кертеп, авыру сөякләрен
Дәваларга шулай җыенасыңмы?
Шулай булса, тиздән йомышыңа
Үзең йөгерерсең.

Джульетта

Йә, йә, кызма.
Ромео сиңа нәрсә диде?

Тәрбияче

Гыйбадәткә барыр өчен бүген
Рөхсәт сорадыңмы?

Джульетта

Сорадым.

Тәрбияче

Ул чагында вакыт уздырмыйча
Лоренцо ата хөжрәсенә йөгер...
Шунда ирең сине хатын ясар.
Кара, кара, дәрте почмакланды,
Бармак күрсә, битенә кан йөгерә.
Бар хәзер үк гыйбадәткә ычкын,
Мин дә чабам. Әмма башка юлдан.

Баскыч кирәк булыр синең янга
Төнлә килә торган теге «аю»га.
Мин карчыкка төшә бөтен кыен.
Бүген төнлә, хәер, үзеңнең дә
Измәң изелер әле, туташкаем.
Ярый, хәзер бераз ашап алыйм,
Йә, бар инде, соңга калма, балам.

Джульетта

Киттем, киттем, хуш, сөекле даям!

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Лоренцо хөҗрәсе. Лоренцо белән Ромео керәләр.

Лоренцо

Бу никахны Тәңре кабул кылсын,
Берүк ахыры хәерлегә генә булсын.

Ромео

Амин, амин! Берүк шулай булсын.
Нинди генә хәсрәт көтсә дә алда,
Аның белән бергә булган мизгел
Пыран-заран китерер кайгыларны.
Изге догаң белән бәйлә безне.
Джульеттаны үземнеке дисәм,
Һич үкенмәс идем шул минутта
Шатлыгымнан әгәр егылып үлсәм.

Лоренцо

Бик ашкынма, андый көчле сөю,
Һәлакәткә илтә, ахырын уйла.
Дары белән очкын кавышканда,
Икесе дә шартлап юкка чыга.
Күп ашасаң, әнә бал да әче.
Сөюгә дә шулай, җиңдем дигәч,
Тантанада килә һәлакәте.
Хисләреңне берүк авызлыкла,
Чаманы бел, балам, хикмәт шунда.

Джульетта керә.

Әнә ул да. Балкый әллә каян.
Бу ташларга, бәлки, әлегә кадәр
Мондый җиңел аяк басмагандыр.
Гашыйк җаннар, мөгаен, җиңеллекнең
Үзе кебек җиңел булалардыр.

Джульетта

Сәлам сиңа, изге ата!

Лоренцо

Ромео,
Һәр икебез өчен рәхмәтне
Син әйт инде аңа.

Ромео

Джульетта,
Бу бәхеттән синең йөрәгең дә
Нәкъ минеке сыман тибә микән?
Әгәр шулай булса, бу мизгелдә
Кавышуны сизгән күңелләрдә
Кайный торган хиснең ни икәнен
Сүзләреңнән тамган аһәң белән
Аңлатып бир, үзем сүз табалмыйм.

Джульетта

Буш күңелдә туа күпсүзлелек,
Чын гашыйклар сүзгә саран була.
Мәхәббәтем ашты үлчәүләрдән,
Буйсынырга хәзер уйламый да.

Лоренцо

Алай булгач, инде эшкә керешик,
Гөнаһлардан сезне йолып алыйм.
Мондый дәртле, кайнар сүзләрдән соң,
Изге никах белән беркетмичә,
Икегезне бергә калдыралмыйм.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәйдан.
Меркуцио, Бенволио, паж һәм хезмәтчеләр керәләр.

Бенволио

Зинһар, китик моннан, Меркуцио,
Көн бик эссе. Өстәвенә әнә
Капулетти токымы мыжгып тора.
Сугыш чыкмагае, болай да бит
Эсселектән кайнап кан котыра.
Меркуцио. Син теге трактирга кергәндә, шпагасын өстәлгә ташлап: «Сине кулга алудан бүген Ходай үзе сакласын!» — дигән булып та, беренче бокалдан соң ук сәбәпсез-нисез яңадан шпагасына барып ябышкан кешегә охшыйсың.
Бенволио. Нәрсә, мин шундыймыни?
Меркуцио. Сөеклем, ышан, һәрбер Италия кешесе кебек үк син дә чамасыз кызу канлысың. Әз генә үртәсәләр — кызасың, кызсаң — котырасың.
Бенволио. Чынлап тамы?

Меркуцио. Әле ул икеләнеп тора! Соң бит син, башка берәүнең сакалындагы төкләре синекеннән бер генә бөртеккә артык яки ким булса да, ул кешене бугазлап ташларга әзерсең. Ә чикләвек ашаган кешене күрсәң, үз күзләреңчикләвек төсендә булган өчен генә дә, син аңа шундук йодрыкларың белән ташланасың. Исәбе-саны булмаган йодрык сугышларында чилепешле йомырка кебек изгәләнеп беткән башың әле дә булса сугышу уе белән шыплап тутырылган. Урамнан узып баручы бер гаепсез кешене кояшта йоклап яткан этеңне йөткереп уятканы өчен генә дә канга батырып тукмадың бит син. Яңа теккән киемнәрен бәйрәмнән алда киеп чыкканы өчен тегүчене нишләттең? Ә икенче берәүне яңа башмакларын иске тасма белән бәйләгәне өчен эт урынына кыйнап ташладың. Җитмәсә үзең миңа акыл өйрәтеп торган буласың тагын!
Бенволио. Әгәр дә мин синең кебек сугыш чукмары булсам, мирасымны вәгъдә итеп кемгә дә булса васыять язар идем һәм аңа, мин әйтте диярсең, ул мирасны алыр өчен сәгать ярым да көтәргә туры килмәячәк.
Меркуцио. Үзеңне бел, башсыз дуамал!

Тибальт һәм башкалар керәләр.
Тибальт

Дуслар, минем арттан! Боларга сүзем бар.
Сүз кыска булыр, бер-ике сүздән артмас, әфәнделәр.
Меркуцио. Бер-ике сүз? Нишләп алай гына? Мин тагын бер-ике селтәнү дә булыр дип уйлаган идем.
Тибальт. Сугышырга сылтау гына бирегез, сезнең чакыруны кабул итәргә мин һәрвакыт әзер.
Меркуцио. Сылтавын да бирергә кирәкмени әле?
Тибальт. Меркуцио, әллә син дә Ромео җырын җырлыйсыңмы?
Меркуцио. Ромео җырын? Ул нинди сүз тагын? Әллә син безне урам җырчылары дип уйлыйсыңмы? Әгәр шулай булса, үзеңә үпкәлә. Менә шушы скрипка таягы белән хәзер мин сине биергә мәҗбүр итәчәкмен. Кара син аны! Ромео җырын җырлыйм, имеш!

Бенволио

Урам уртасында шаулашабыз.
Икесенең берсе: яки читкә китик,
Йә булмаса хәзер тыныч кына
Аерылышыйк, юкса кеше карый.

Меркуцио

Карасыннар. Күзләр карар өчен.
Шушы урыннан китмим беркая да.

Ромео керә.

Тибальт

Китмәсәгез!.. Тукта, менә миңа
Кирәк кеше килә...

Меркуцио
Кирәк кеше?
Кем дип белик аны? Сезнең катта
Хезмәтчеме? Әгәр шулай булса,
Сез дуэльгә дәшегез: «Ә» дигәнче
Кылыч белән эчегезне айкап
Вазифасын үтәр ул хезмәтче.

Тибальт

Ромео, үчем канмас сиңа!
Йөрәгемдә булган нәфрәт хисе

Башка сүз табалмый: син — кабахәт!

Ромео

Йөрәгемдә булган сөю хисе
Кичерергә куша сине, Тибальт.
Мин кабахәт түгел. Ярый, сау бул.
Күрәм, мине начар беләсең син.

Тибальт

Мыскыллавың сызган җәрәхәтне
Бу сүзләрең генә басар димә.

Ромео

Дөрес түгел, сине мыскылларга
Уема да хәтта килгәне юк.
Тиздән, Тибальт, безне туган ясар
Яңа хәбәр сиңа җиткерерләр.
Аерылышыйк әйдә тату гына!
Капулетти исеме бүгеннән соң
Үземнеке кебек якын миңа.

Меркуцио

Түбәнлеккә төшеп буйсыну бу!
Бу җирәнгеч коллык хурлыгын мин
Кайнар каным белән юам хәзер!
Ата мәче Тибальт, син әзерме?

Кылычын чыгара.

Тибальт

Сиңа тагын миннән нәрсә кирәк?
Меркуцио. Хөрмәтле мәчеләр патшасы, миңа синең тугыз җаныңның берсе генә кирәк, ә калган сигезен, кирәк санасам, шуның артыннан ук берәм-берәм бәргәләп чыгарырмын. Кылычыңны колагыннан тартып чыгар, әйдә, югыйсә хәзер үз колакларыңны кисеп кулыңа тоттырам!
Тибальт
Рәхим ит.

Кылычын чыгара.

Ромео

Сабыр, Меркуцио!
Йә, әфәндем, күрсәт passadoңны!

Сугышалар.

Ромео

Бенволио, әйдә, кылычларын
Сугып төшерик тизрәк. Әфәнделәр,
Оялыгыз! Тибальт! Меркуцио!
Верона урамында сугышуны
Князь тыя. Тибальт, зинһар, тукта!
Меркуцио, дустым!

Тибальт Ромеоның кулы астыннан Меркуционы яралый да иптәшләрен иярtеп чыгып кача.

Меркуцио

Яралады!
Үләт кырсын сезнең ике йортны!
Исән килеш китте, ә мин — үләм!

Бенволио

Яраң зурмы?

Меркуцио

Тырнап кына узды.
Ләкин миңа хәзер шул да җиткән.
Пажым кая? Малай, табиб чакыр.

Паж чыгып китә.

Ромео

Хафаланма, яраң тирән түгел.
Меркуцио. Әлбәттә, әлбәттә, коедан да тирән түгел, киңлеге дә чиркәү ишеге кадәр үк булмас. Әмма шунысы да бик җиткән. Менә иртәгә мине чакырып карарсың: «Ул йөгерәсен йөгереп бетерде инде», — дип кенә җавап бирерләр. Үләт кенә кырсын шушы ике йортны! Ah, эттән туган, күсе, ата мәче! Кешене үләр чиккә җиткереп тырный бит! Оятсыз, кабахәт! Китап буенча сугышырга өйрәнгән, имеш! Ни шайтаныма дип безнең арага килеп кердегез? Сезнең кул арасыннан яралады ул мине!

Ромео

Мин бит сезне аерыйм дигән идем.

Меркуцио

Бенволио, һуштан язам бугай,
Алып кит син мине тизрәк моннан.
Үләт кырсын шушы ике йортны!
Нәселләре корысын, шулар өчен
Кабер кортларына ризык булдым.
Бар да бетте! Kaһәр генә суксын!

Бенволио Меркуционы алып чыгып китә.

Ромео

Князь токымы, дустым, Меркуцио
Минем өчен каты яра алды.
Мин гаепле моңа, мин гаепле!
Тибальт мыскыл иткәч... Әйе, әйе,
Нәкъ бер сәгать элек туганыма
Әверелгән Тибальт мыскыл иткәч,
Кылычымны эшкә җигәр җирдә,
Тешем кысып дәшми тыелып калдым.
Син сәбәпче моңа, Джульетта!
Намусымның корыч ныклыгын мин
Алыштырдым синең матурлыкка.

Бенволио керә.

Бенволио

Ромео, Меркуцио сүнде.

Нәфрәт белән җирдән йөз чөереп,
Аның батыр рухы күккә ашты.

Ромео

Хәерсез көн! Бу котычкыч үлем —
Киләчәктән килгән котсыз хәбәр.

Тибальт керә.

Бенволио

Канлы Тибальт әнә кире килә!

Ромео

Ул исән-сау? Ул тантана итә?
Меркуцио исә үтерелде!
Сабырлыгым, дәшмә! Бу минуттан
Ялкын күзле нәфрәт, мин — синеке!
Үз сүзеңне, Тибальт, кире ал син,
Үзеңә юллыйм аны: «Син — кабахәт!»
Меркуцио җаны җиде кат күккә
Җитәр-җитмәс туктап синекен көтә.
Икебезнең беребез: йә син, йә мин
Бу минутта хәзер шунда китә.

Тибальт

Син китәрсең. Син бит дусты идең,
Җәһәннәмгә олак, маңка малай!

Ромео

Кем китәсен шушы кылыч әйтер!

Сугышалар. Тибальт егыла.

Бенволио

Ромео, кач! Тиз бул! Тибальт үлде!
Халык купты, бар да монда йөгерә.
Йә, кач инде, нәрсә көтәсең син?
Юкса Князь үлем җәзасына
Хөкем итәр сине Тибальт өчен!

Ромео

Язмыш кулындагы шамакай мин!

Бенволио

Кач тизрәк! Сузма, сузма, дим бит!

Ромео китә. Шәһәр кешеләре килеп керәләр.

Беренче шәһәр кешесе

Меркуцио үлгән. Тибальт кайда?
Ah, башкисәр! Тотыгыз кабахәтне!

Бенволио

Ул биредә ята.

Беренче шәһәр кешесе

Алай, алай...
Сез, синьор, кулга алынасыз.
Закон исеме белән боерам сезгә:
Минем арттан барыгыз! Йә, атлагыз!

Үзенең хадимнәре белән Князь, Монтекки, Капулетти, аларның хатыннары һәм башкалар керәләр.

Князь

Бу сугышны әүвәл кем башлады?

Бенволио

Галиҗәнап, әгәр рөхсәт булса,
Үзем сөйлим сезгә барысын да.
Тибальт кулы белән Меркуцио
Үтерелде башта, ә аннары
Ромео белән бәрелештә
Үтерүче үзе һәлак булды.

Капулетти ханым

Тибальт! Тибальт! Газиз энекәем!
Картым! Князь! Нинди зур югалту!
Кардәшемнең канын түккәннәр бит!
Үтерүче әнә басып тора,
Хөкемгә тарт, зинһар, галиҗәнап,
Үз канын түк явыз Монтеккиның!

Князь

Бу сугышны кем башлады диеп
Сорыйм сездән?

Бенволио

Тибальт башлады.
Ямьсез сүзләр белән иң элек ул
Ромеоны бик нык мыскыллады.
Ә Ромео исә, хурланса да,
Тешен кысып түзде, сугышмады.
Киресенчә, төрле юллар белән
Тибальтны ул суытмакчы иде.
Әмма Тибальт, кая, тыңлыймы соң?!
Котырганнан котыра гына барды.
Меркуцио түзми арага кергәч,
Эләгештеләр, китте шуннан сугыш.
Көчләр тигез иде, шуңа күрә
Озак сугыштылар, ә Ромео,
Туктатырга теләп бу сугышны,
Ике арада шактый бөтерелде.
Шуның белән килер фаҗигане
Тизләтте ул, аның кул астыннан
Батыр Меркуцио күкрәгенә
Үлем җәрәхәте салды Тибальт.
Үзе качты, ләкин көтмәгәндә

Кире әйләнеп килде. Шул мизгелдә
Ромео чыкты чыгырыннан...
Мин аңыма килгән чакта инде
Тибальт җирдә тынсыз ята иде,
Ул үлгәнне күргәч, Ромео
Кинәт кенә чыгып качты моннан.
Ни булганын сөйләп бирдем сезгә,
Егылып үлим ялган кушсам сүзгә.

Капулетти ханым

Ул Монтекки токымы, үз туганын
Яклар өчен сөйли бу ялганын.
Тибальтны алар нәселләре белән
Җыелып килеп үтергәннәр, беләм.
Әгәр гадел икән закон көче,
Үтерелсен кеше үтерүче!
Җәзага тарт, Князь, Ромеоны,
Тибальт өчен кичерү юк аны.

Князь

Ромео җәза коралы тик.
Меркуцио өчен кемне хөкем итик?

Монтекки

Ромеоның монда гаебе юк.
Меркуцио белән дус иделәр.
Үтерүчедән бары үч алган ул.
Син үзең дә шулай эшләр идең.

Князь

Тиешлесен ул да алыр бүген,
Кылган эше өчен аңа сөрген.
Хөкем кыска булыр: ул башбаштак,
Кичекмәстән илдән куылачак.
Сезнең шушы ызгыш аркасында
Акты бүген монда үз каным да.
Аң булыгыз, бу югалту сезгә
Бик кыйммәткә төшәр һәммәгезгә.
Күпме генә күз-яшь түксәгез дә,
Колак салмам һичбер сүзегезгә.
Ромеоның башы газиз икән,
Бу шәһәрдә күренмәсен бүтән.
Алыгыз мәетне! Мин хаклыдыр шаять:
Үтерүчене аклау — зур җинаять.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулеттилар бакчасы. Джульетта керә.

Джульетта

Ут тояклы атлар, томырылыгыз
Көнбатышка таба — Феб йортына!
Ат башында Фаэтон үзе булса,

Күптән инде сез максатка җитеп,
Караңгылык җирне каплар иде.
Гыйшык булышчысы — караңгы төн!
Төшер тизрәк кара чыбылдыгың.
Минем янга килгән Ромеоны
Чит-ят күзләр күрми, сизми калсын.
Гашыйкларга исә сөю уты
Битләренә кабып юл яктырта.
Өстәвенә сөю сукыр да бит,
Караңгылык аңа күбрәк бата.
Кара бөркәнчекле мәгърур кортка,
Әй, кара төн, килче, өйрәт миңа:
Ничек итеп сөю уенында
Ота торган итеп оттырырга?
Оялудан янган йөзләремне,
Мәхәббәттә һәр эш изге икәнне,
Аңлаганга кадәр, әй, кара төн,
Каплап тор син кара пәрдәң белән.
Кил, кара төн! Килче, кил, Ромео,
Син кояшым минем, якты көнем.
Кара карга канатына яуган
Ак кар кебек балкып, йә, кил, күрен!
Кара күзле сөю алиһәсе,
Ягымлы төн, кил син, ялындырма.
Һәм алып кил миңа үзең белән
Бердәнберем булган Ромеоны!
Ә ул үлсә, вак-вак йолдызларга
Бүлгәлә дә аны күккә сип син —
Күк гөмбәзе шундый балкып торыр,
Кояш белән көннән йөз чөереп,
Бөтен дөнья төнгә гашыйк булыр.
Мин мәхәббәт йорты сатып алдым,
Керә алмый йөрим шуңа һаман
Һәм үзем дә күптән сатылсам да,
Хуҗам кулларына тапшырылмаган.
Нинди көн бу? Шундый әкрен үтә.
Гарык булдым тәмам көтә-көтә.
Бәйрәм таңын көтеп, күз йоммыйча
Уздырган төн кебек озын бу көн.
Ah, ниһаять, әнә даям кайтты.
Нинди хәбәр икән телләрендә?
«Ромео» дип исемен әйтсә дә, ул
Фәрештә күк күренер күзләремә.

Баулар күтәргән Тәрбияче керә.

Сузма, даям, сөйлә. Ә бу нәрсә?
Ромеога дигән баскычмы әллә?

Тәрбияче

Әйе, баскыч.
(Бауларны җиргә ташлый.)

Джульетта

Тукта, сабыр, даям!
Өзгәләнмә алай. Нәрсә булды?

Тәрбияче

Харап булдык! Ахырзаман килде!
Җан биргән ул, мескен, япь-яшь көе!
Үлгән, үлгән, үтергәннәр аны!

Джульетта

Күкләр шундый мәрхәмәтсезмени?

Тәрбияче

Күкләр түгел, әнә Ромеоң
Мәрхәмәтсез синең! Ah, мин юләр!
Кем уйлаган!..

Джульетта

Әллә Иблисме син?
Нигә болай газаплыйсың мине?
Бу җәзаңа хәтта җәһәннәмдә
Кычкырмыйча түзалмаслар иде!
Ромео әллә үз-үзенә
Кул салдымы? Йә, әйт, әйе, диген,
Һәм шул «әйең» явыз аждаһаның
Күз карашы кебек үтерер мине.
«Әйе» дисең икән, мин мин булмам.
Беркайчан да үзем була алмам.
Йә, җавап бир: әйе яки юк дип,
Һәм башка сүз әрәм итмә юкка.
Ике сүзнең берсе мине шундук
Йә кайгыга күмәр, йә шатлыкка.

Тәрбияче

Җәрәхәтең аның үзем күрдем.
Күкрәгендә, җаным, менә шунда.
Андагы кан! Ходай, үзең сакла!
Елга булып аккан тирә-якка!
Йөзе көл шикелле, карадым да
Һушым китте!

Джульетта

Йөрәк, шартлап ярыл!
Һәлакәтең җитте! Әй, күзләрем,
Йомылыгыз, зинһар, төрмәгезгә.
Көлгә әйлән, тәнем, сузма, тиз бул!
Ромео белән икебезне
Уртак кабер тизрәк йотсын, әйдә.

Тәрбияче

Тибальт, Тибальт! Якын дустым, Тибальт!
Нәзакәтле идең, тәмле телле!
Нигә синнән алда үлмәдем мин?!

Джульетта

Юнәлешен ник тиз үзгәртә җил?
Ромео үтерелгән? Инде Тибальт?
Ирсез калдым? Туганымны җуйдым?
Ник Исрафил өрми изге сурын?
Бу икәү дә үлгәч, дөньясында
Нинди тере кеше калсын тагын?

Тәрбияче

Ромео исән, Тибальт кына үлде.
Аны үтергән өчен Ромеога
Сөрген хәзер, Князь илдән сөрде.

Джульетта

Тибальт канын әллә түккәнме ул?
Ни сөйлисең? Раббым! Юк, ышанмыйм!

Тәрбияче

Ышан, балам, түккән, әйе, түккән!
Кызганмыйча түккән! Кансыз икән!

Джульетта

Гөл куенында яткан явыз елан!
Сокландыргыч матур ач аждаһа!
Бәрән кыяфәтле комсыз бүре!
Фәрештәгә охшаш котсыз шайтан!
Эчтән — козгын, тыштан — ак күгәрчен!
Алла, дисәм, тик түбәнлек икән!
Кабахәтлек катыш изгелек ул!
Эче-тышы тора каршылыктан!
Әй, табигать, нәрсә карадың син,
Җәһәннәмдә-остаханәңдә
Сокландыргыч төс-кыяфәт биреп
Чыгарганда Иблис-ләгыйньгә?
Эчтәлеге начар бу китапны —
Матур тышлык белән кем тышлаган?
Шундый гүзәл сарай, ә ни өчен
Ялган белән тулган аның эче?

Тәрбияче

Ирләр алар бар да ялганчылар.
Ият белән намус ни икәнне
Белә торган затлар түгел алар.
Һәммәсе дә бозык, хатын-кызны
Алдап-йолдап юлдан яздыралар.
Шәраб бирегез! Тизрәк! Бу кайгыдан
Вакытыннан алда гүргә керәм.
Хурлык, хурлык синең Ромеоңа!

Джульетта

Телеңә тилчә чыксын! Ромео
Хурлык өчен туган җан түгел ул.
Хурлык аның нәфис маңгаена
Кагылырга хәтта оялачак,

Ул бит тәхет, ул тәхеткә бары
Намус кына менеп утыра ала.
Түбәнлеккә төшеп аны әрләргә
Ничек җөрьәт иттем? Ah, явыз мин!

Тәрбияче

Кардәшеңне үтергәне өчен
Әллә аны мактар идеңме син?

Джульетта

Әрлиммени инде? Мескен ирем,
Өч сәгатьлек хәләл хатының да
Кызганмагач сине, кем кызгансын?
Ah, юлбасар, минем туганымны
Үтергәнсең бит син! Шул сугышта
Ул юлбасар әгәр сине үтерсә,
Әйбәтрәк булыр идемени?
Йә, акмагыз, ахмак күз яшьләре,
Чишмәгезгә кире борылыгыз!
Ялгышкансыз, сезнең бурыч башка:
Хәсрәт дәрьясына тамар чакта,
Шатлык диңгезенә агасыз бит.
Ирем исән минем, Тибальт аны
Үтермәкче иде, әмма Тибальт
Үзе үлде, юкса үтерер иде.
Бар да әйбәт. Нигә яшь түгәм мин?
Тибальт үлеменнән дә куркынычрак
Бер сүз миңа һаман тынгы бирми.
Оныта алмыйм шуны, хәтеремә
Кузгалмаслык булып береккән ул.
«Тибальт үлде, Ромеога сөрген».
Менә ул сүз. «Сөрген». Бу — хәтәр сүз.
Тибальт үлеменнән мең кат авыр.
Минем өчен аның үлеме дә
Баштан ашкан иде. Әгәр кайгы
Ялгызлыктан газап чигә икән,
Тибальт үлеменә өстәп тагын
Әткәң үлде, диген, яки әнкәң,
Йә булмаса икесе дә, диген.
Әмма ләкин Тибальт мәетенә
«Сөрген» сүзен, зинһар, өстәп салма.
Артыккарак китәр, ул чагында
Тибальт кына түгел, әткәй, әнкәй.
Ромео белән Джульетта
Барысы бергә һәлак булачаклар.
«Ромеога сөрген» — шушы сүздә
Үлем белән килешүгә кергән
Иксез-чиксез тирән өметсезлек.
Әткәй белән әнкәй кайда икән?

Тәрбияче

Тибальт мәете каршысында алар
Яшь түгәләр. Әйдә озатып куям.

Джульетта

Юк, кирәкми, даям, еласыннар,
Елар өчен сәбәп монда да бар.
Күз яшьләре түгеп кенә, ләкин
Ромеоны кайтара алмам шул мин.
Ә баскычны яшер. Мескен баулар,
Нәкъ минем күк алдандылар алар.
Аңлыйм, аңлыйм, сезнең күңел китек,
Ул сөргендә хәзер, нихәл итик?
Аның өчен сез бит бүген төнлә
Юл идегез минем түшәгемә.
Вазифагыз бетте. Инде менә
Мин тол булып калдым кыз көенә.
Җый бауларны, әйдә керик инде.
Никах түшәгендә бүген мине
Тугрылыкка антлар итә-итә,
Ирем түгел, салкын үлем көтә.

Тәрбияче

Ярый, бар, кер. Артык өзгәләнмә.
Ромеоның кайда икәнлеген
Мин беләмен, балам. Бүген төнлә
Синең янга китерәчәкмен аны.
Хәзер шунда чабам. Ул хөҗрәдә.

Джульетта

Шулаймыни? Ул чагында, даям,
Тапшыр аңа шушы балдакны син,
Таң алдыннан хушлашырга килсен.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лоренцо хөҗрәсе. Лоренцо керә.

Лоренцо

Ромео, чык. Йә, чык, бәхетсез җан!
Сиңа хәсрәт гашыйк булган, балам.
Бәхетсезлек белән ярәшелдең.

Ромео

Сөйлә, ата, нинди хәбәрләр бар?
Хөкем ни ди? Нинди бәла тагын
Минем белән танышырга тели?

Лоренцо

Син хаклысың, бөтен бәла-каза
Сиңа килеп дуслык кулын суза.
Инде хәзер Князь хөкемен тыңла.

Ромео

Ахырзаман ясыймы әллә миңа?

Лоренцо

Нишләп алай дисең? Аның хөкеме
Алай каты түгел. Ул бит сине
Үтерергә түгел, тик сөргенгә
Сөрергә дип кенә әмер бирде.

Ромео

Ә? Сөргенгә? Юк, үлемгә, диген,
Шәфкатьле бул, зинһар, син, ичмасам.
Сөрген бит ул үлемнән дә авыр,
Бу турыда бүтән авыз да ачма.

Лоренцо

Сине фәкать Веронадан гына
Сөрәләр ич, тукта, артык кызма,
Шуның белән дөнья бетмидер бит?

Ромео

Веронадан читтә дөнья юк ул,
Анда тәмуг, анда җәһәннәм тик!
Җәһәннәмгә сөрелү — шул ук үлем,
Исемнәре генә төрле-төрле.
Үлемне син сөрген дия-дия,
Алтын балта белән минем башны
Чапмакчысың миннән көлә-көлә.

Лоренцо

Игелексез! Сиңа бу эш өчен
Үлем тиеш, ә син исән-имин.
Сукырдыр син, юкса күрсәтелгән
Мәрхәмәтне бераз күрер идең.

Ромео

Бу мәрхәмәтмени? Үч алу бу!
Минем өчен яшәү, хәят әнә
Джульетта булган җирдә генә.
Шул оҗмахта яшәп эт, мәчеләр
Һәм һәртөрле шакшы хәшәрәтләр
Аны күреп ләззәтләнә ала,
Ромео — юк. Йә, әйт, хаклык кайда?
Хәзер инде тирес чебеннәре
Ромеодан күпкә дәрәҗәле.
Аларга бит әнә Джульеттаның
Сокландыргыч нәфис ак кулына
Кагылырга ярый, ул гынамы,
Чебеннәргә — ирек, алар хәтта
Оялудан алсу ут кабынган
Иреннәрдән татлы ләззәт тулы
Рәхәтлекне урлап кача ала.
Ромео — юк, алай эшли алмый,
Ул — сөргендә, бу тыелган аңа.
Ә син, сөрген үлем түгел, дисең?
Буш сафсата сөйләп йөдәткәнче,

Йә агула мине, йә булмаса
Пычак ал да әнә суеп ташла.
Сөрген, имеш! Бу сүз җәһәннәмдә
Газап чиккән гөнаһкярлар зары.
Һәм син миңа, рухи изге ата,
Остазым һәм дустым булган көе,
Телең барып ничек «сөргенче» дип
Әйтә алдың икән, аңлый алмыйм?

Лоренцо

Юләр Мәҗнүн, бераз мине тыңла.

Ромео

Синең сүзең һаман шул бер сөрген.

Лоренцо

Бу күңелсез уйларыңа каршы
Көрәшергә корал бирәм сиңа.
Ул — фәлсәфә. Хәтта сөргендә дә
Ташламас ул сине, юлдаш булыр.

Ромео

Тагын сөрген? Тукран булдыңмы әллә?
Шайтан алсын синең фәлсәфәңне!
Фәлсәфәңнән яңа Джульетта
Тумаячак синең беркайчан да.
Хөкем карары да шулай калыр.
Һәм шәһәр дә күчмәс үз урыныннан.
Буш сафсата юкка сатма, зинһар.

Лоренцо

Акылсызлар, димәк, чукрак була.

Ромео

Акыл ияләре сукыр булгач,
Аптырарлык түгел анысына.

Лоренцо

Ярый, булды, хәзер тыныч кына,
Кил, сөйләшик әйдә эш турында.

Ромео

Сиңа чит-ят булган хис турында
Ни сөйләшеп булсын, баш катырма!
Минем кебек әгәр яшь булсаң син,
Джульеттаны сөйсәң һәм өйләнсәң,
Шул сәгатьтә Тибальдоны суеп
Туган шәһәреңнән сөрелсәң,
Сөйләшергә хакың булыр иде.
Ул чакта син чәчләреңне йолкып,
Минем сыман үзеңә кабер үлчәп,
Идән буйлап тәгәрәп йөрер идең.

Ишек шакыйлар.

Лоренцо

Кемдер ишек шакый, бар, кач, улым,
Яман күзләр күрер, йә, тиз бул, тор!

Ромео

Юк, качмыймын, сагышларым мине
Сары томан булып каплап торыр.

Шакыйлар.

Лоренцо

Ишетәсеңме ничек дөбердәтә?
Кач тизрәк.

Шакыйлар.

Кем бар? Йә, тор инде!
Күрсәләр бит әгәр, башың бетә.
Бар, гыйбадәт бүлмәсенә йөгер.
Киребеткән! Кем бар? Хәзер, хәзер!

Шакыйлар.

Хәзер дим бит! Әллә ут чыктымы?
Кемне эзлисез. Сезне кем җибәрде?

Тәрбияче
(сәхнә артыннан)

Ачыгыз башта, кергәч аңлатырмын,
Ачыгыз инде тизрәк, мин бирегә
Джульетта кушуы белән килдем.

Лоренцо

Хәерлегә булсын, керегез әйдә.

Тәрбияче

Изге ата, Ромео кайда?
Туташымның ире?

Лоренцо

Ул идәндә
Күз яшенә исереп ята әнә.

Тәрбияче

Минем туташым да нәкъ шул хәлдә.

Лоренцо

Гашыйкларда гына була торган
Охшашлык бу.

Тәрбияче

Әйе, теге дә шулай,
Капланган да елый, кузгалмый да.
Сезгә, әфәндем, бер дә килешми бит,
Йә, торыгыз әле, ир булыгыз!

Ah-bah килеп яту эшмени ул?
Джульетта күрсә шушы хәлдә...

Ромео

Ah, шәфкатьле дая!

Тәрбияче

Тагын «ah» ди!
Нинди бетмәс ah-bah булды соң бу?
Үләр өчен туа һәммәбез дә!

Ромео

Джульетта дидең түгелме син?
Йә, ничек соң? Мине үтерүчегә
Саныймы ул һаман? Саныйдыр шул.
Чөнки яңа чәчәк атып килгән
Бәхетебезне Тибальт каны белән
Тапладым мин. Йә, әйт, Джульетта
Кайда хәзер? Хәле ничек аның?
Яшерен сөюебез турысында
Ниләр сөйли минем яшерен ярым?

Тәрбияче

Ни сөйләсен? Елый-елый да ул
Түшәгенә ава, тагын тора...
Йә Тибальтны сорый, йә булмаса
Түшәгенә кабат каплана да,
Ромео, Ромео, диеп,
Шаша башлый тәмам.

Ромео

Ромео!
Шушы исем аны һәлак итә,
Һәлак иткән кебек кан кардәшен.
Изге ата, әйтче, безнең тәннең
Кай җирендә яши бу исемнәр?
Шул ояны хәзер җимереп ташлыйм.

Кылычын чыгара башлый.

Лоренцо

Тый кулыңны, ахмак! Ирме соң син?
Ни кыланган була? Ah, дуамал!
Елаклыгың белән син — хатын-кыз,
Кыланышың белән ерткыч җанвар!
Ир сыйфаты сүнгән хатынша син!
Кеше сурәтендә йөргән ерткыч!
Шаккатырдың мине! Мин бит сине,
Изге Франциск белән ант итәм,
Сабыррак диеп уйлый идем.
Синең кулдан Тибальт һәлак булды,
Үз-үзеңне үтереп инде хәзер
Синең өчен җанын фида кылган

Хатыңны да гүргә тыгасыңмы?
Йә, әйт әле, җирне, күкне, җанны
Нигә каһәрләргә, ник хурларга?
Бик беләсең килсә бу өч нәрсә
Синең тәндә таркалырга түгел,
Бергә яшәр өчен кушылганнар.
Оял, оял, бу гамәлең белән,
Матурлыгың, акылың, сөюеңне,
Үз-үзеңне таптап хурлыйсың бит.
Шул байлыкны әллә карун кебек
Файдаланмый үлеп китәрсеңме?
Батырлыгың белән җан өрмәгәч,
Матурлыгың синең таш курчак күк.
Ә сөюең, биргән вәгъдәләрең
Сине сөйгән бер гөнаһсыз җанны
Үтерергә туган хаинлек тик.
Акылың исә әкрен кыймылдаган
Солдат кулындагы дары кебек.
Кинәт кенә дөрләп кабына да
Шартлап һәлак итә үзеңне үк.
Йә, тор әле, сөйгән ярың өчен,
Хәсрәт чигеп үлә язган бәндә!
Джульеттаң исән! Бу — зур бәхет!
Тибальт сине үтермәкче булган,
Әмма үзе үлгән. Бу да бәхет!
Күрәсеңме ничек, бәхет сине
Кочагына ала, ә син исә
Көйсез бала кебек турсаясың.
Кара аны, ахыры начар булыр!
Йә, бар, ычкын! Хатының көтә сине.
Бүген төнлә бүлмәсенә менеп
Тынычландыр үзен, ләкин кара,
Озак юанмагыз, таңга калып,
Тоткавыллар әгәр тотып алса,
Мантуяга җитү насыйп булмас.
Мантуяда миннән хәбәр көт син.
Сезнең бу никахны игълан итеп,
Ике йортны тәмам килештергәч,
Һәм Князь дә сине гафу иткәч,
Веронага үзем чакыртырмын.
Бик кайгырма, бер кайтырсың, улым.
Күрешү көне шушы хушлашудан
Мең мәртәбә шатлыклырак булыр.
Йә, бар, кортка, туташыңа тапшыр:
Үзенекеләрен иртә йоклатсын ул.
Хәер, алар йончыганнар инде,
Үзләре дә изрәп йоклап китәр.
Әйт: туташың көтсен. Ромео да
Синең арттан тиздән килеп җитәр.

Тәрбияче

Раббым, Аллам! Иртә таңга кадәр

Тыңласаң да тыңлап туеп булмас.
Ни дисәң дә гыйлем дәрьясында
Йөзгән кеше инде. Мин туташка
Сез килә дип хәзер кайтып әйтәм.

Ромео

Туташыңа тагын шуны да әйт:
Шелтәләргә мине әзерләнсен.

Тәрбияче

Ул, әфәндем, сезгә менә шушы
Балдакны да тапшырырга кушты.
Ярый, китим инде, тик карагыз,
Вакыт бара, зинһар, соңламагыз.

Ромео

Рухым күтәрелде, терелеп киттем!
Ә бу бүләк үзе бер хәзинә!

Лоренцо

Йә, бар, улым. Хәерле төн телим.
Тоткавыллар кулына эләгә күрмә.
Шуңа күрә таң атканга кадәр,
Шәһәр капкасыннан чыгып өлгер.
Мантуяда яшә. Ходай кушып,
Биредә эшләр уңайланып китсә,
Хезмәтчеңне табып, аның аша
Хәбәр җибәрермен. Йә, бар, ашык,
Вакыт җитте, улым, бир кулыңны,
Шатлык белән күрешергә язсын.

Ромео

Изге ата, әгәр сөйгәнемә
Илтмәсәләр иде аякларым.
Синең белән хушлашырга кыймый
Басып торыр идем мең ел тагын.
Кичер мине!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулетти өендәге бер бүлмә.
Капулетти, Капулетти ханым һәм Парис керәләр.

Капулетти

Бик зур хәсрәт төште безнең башка,
Шуңа күрә, граф, кызыбыз белән
Сөйләшә алмый калдык без бу хакта.
Ул абзасын бик тә сөя иде.
Тик нишләмәк кирәк? Үлем белән

Бәхәсләшеп булмый, ул көчлерәк.
Хәзер бик соң. Кызым чыга алмас.
Дөресен әйтим, мин үзем дә, граф,
Сезнең хакка гына утырам монда,
Юкса күптән изрәп йоклар идем.

Парис

Әйе, әйе, мондый кайгылы чакта
Туй турында сөйләп торып булмас.
Синьора, тыныч йокы телим,
Кызыгызга сәлам тапшырыгыз.

Капулетти ханым

Мин иртәгә иртән аның белән
Сөйләшермен, граф, борчылмагыз.
Ә хәзер ул Тибальт кайгысыннан
Баштанаяк хәсрәтенә чумган.

Капулетти

Әйтте диярсез, Парис, кызым сезне
Яратачак. Бер дә шикләнмәгез.
Минем сүздән чыкканы юк аның.
Син бар, хатын, йоклап китмәс борын
Джульеттага сөйләп бир Парисның
Ничек итеп аны яратканын.
Һәм әйт аңа — кисәтеп куй үзен —
Чәршәмбе көн... Тукта! Бүген ни көн?

Парис

Дүшәмбе көн, синьор.

Капулетти

Ә, дүшәмбе?
Юк, чәршәмбе иртә — өлгермәбез.
Атна кичкә. Син әйт: атна кичкә
Парис белән икесен никахлыйбыз.
Сез әзерме? Каршы килмисезме?
Туйны артык зурга җибәрмәбез,
Бер-ике дус килсә, шул бик җиткән.
Юкса әйтерләр: Тибальт үлүгә үк
Туй ясыйлар, күңел ачалар, дип,
Шуңа күрә ике-өч гаилә генә.
Атна кич көн сезгә уңайлымы?

Парис

Ул атна кич ник иртәгә түгел?
Мин иртәгә булуын теләр идем.

Капулетти

Ярый, булды. Атна кичкә, димәк.
Инде хәзер кайтсагыз да була.
Ә син, хатын, Джульеттаны кара,

Туйга әзерләнсен, яхшылап әйт!
Сау булыгыз, граф. Хезмәтчеләр!
Ут кертегез йокы бүлмәсенә!
Вакыт бик соң, иртә диярга дә
Күп калмаган инде. Тыныч йокы.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Джульеттаның йокы бүлмәсе.
Ромео белән Джульетта.

Джульетта

Китәсеңдәмени? Таң атмый бит.
Синең сак колакны сискәндергән
Тургай түгел, ә сандугач бары,
Ул һәр төнне анар агачында
Сайрап чыга шулай, җанкисәгем.

Ромео

Юк, сандугач түгел, таң хәбәрен
Тургай хәбәр итте, күр, сөеклем,
Алсу таң нурлары ничек итеп
Болытларны алсу төскә мана.
Төн сүндерде үзенең бар шәмнәрен.
Томанлы тау итәгенә басып,
Яңа туган көләч көн елмая.
Калсам — үләм, китсәм — исән калам.

Джульетта

Ул таң нуры түгел, яшен ташы,
Факел булып синең Мантуяга
Бара торган юлны яктыртмакчы.
Бераз гына тагын китмичә тор,
Йә, кал инде, кая ашыгасың?

Ромео

Тотсыннар да үтерсеннәр әйдә.
Син риза икән, ул чагында
Мин бик теләп калам синең янда.
Таң нурлары түгел, ай нуры бу.
Күк гөмбәзен сихри моңга төргән.
Тургай түгел, бәгърем, сандугач ул.
Калу җиңел миңа, китү авыр.
Ни язса, шул! Әйдә, үлсәм үләм,
Сөйгән ярым шулай тели икән,
Кил, сөйләшик, әле төн үтмәгән.

Джульетта

Юк, ярамый, ашык, таң беленә.
Тургай әнә күктә бугаз ертып
Ни гомерләр инде чыр-чыр килә.

Таң җырчысы, имеш. Шулмы җырчы?
Җырчы түгел, мескен гашыйкларның
Күңеленә курку, шом салучы.
Үз күзләрен бака күзләренә
Алмаштырган бит ул, әгәр шунда
Тавышын да алмаштырган булса,
Нинди әйбәт булган булыр иде.
Тургай тавышы сине кочагымнан
Тартып алып куа ят тарафка.
Йә, бар, йөгер, юкса кояш чыгар,
Күрәсең бит әнә көн яктыра.

Ромео

Көн яктыра, безнең хәсрәт кенә
Ул яктырган саен кара көя.

Бүлмәгә Тәрбияче керә.

Тәрбияче

Джульетта!

Джульетта

Даям? Нәрсә булды?

Тәрбияче

Яктыра бит, балам, әниең торды,
Тиздән монда килә, сак булыгыз!
(Китә.)

Джульетта

Әй, тәрәзә, керт син кояш нурын,
Сөйгәнемне чыгар, бүлмә юлын!

Ромео

Кер кочакка. Соңгы тапкыр үбим!
Менә булды. Йә, хуш! Инде китим.

Джульетта

Киттеңмени, дустым, ирем, бәгърем?
Сәгать саен, зинһар, хәбәр җибәр.
Сине көткән һәр минутым минем
Ничә елга торыр, шуңа күрә
Йөз елларга, бәлки, картаермын,
Синең белән күрешкәнгә кадәр.

Ромео

Хуш, сөеклем, үзем исән мәлдә,
Тилмертмәмен сине хат-хәбәргә.

Джульетта

Кабат күрешербез дип уйлыйсыңмы?

Ромео

Шикләнмә дә! Безнең бу күргәннәр
Татлы хатирәгә әйләнер бер.

Джульетта

Әй Ходаем, күзем алмашамы?
Кабер төбендәге мәет булып
Күренәсең миңа югарыдан.
Ялгышмаса күзем, киндер кебек
Агаргансың, төсең киткән тәмам.

Ромео

Синең йөз дә миңа шулай күренә.
Сагыш кимерә безне, комсызланып
Каныбызны эчә. Йә, хуш, җаным!
(Китә.)

Джульетта

Язмыш, сине үзгәрүчән, диләр,
Әгәр шулай икән, исбат ит син.
Сөйгәнемне озак тоткарлама,
Кайтарып бир аны кабат миңа.

Капулетти ханым
(сәхнә артыннан)

Кызым, тордыңмы инде?

Джульетта

Кем дәшә ул?
Әнкәй, сезме? Ник ятмыйсыз һаман?
Әллә ятып иртә тордыгызмы?
Ник кердегез болай иртә таңнан?

Капулетти ханым

Хәлең ничек?

Джульетта

Начар.

Капулетти ханым

Һаман да шул
Абыең хәсрәтеннән елыйсыңмы?
Күз яшьләрең генә кабереннән
Чыгара алмас аны, ә чыгарса,
Юар гына бары, тергезә алмас.
Җитәр, балам, түкмә күз яшеңне.
Якын кешең өчен хәсрәт чигү
Әйбәт сыйфат, әмма чама кирәк.
Күз яшьләрең күмсә чама чиген,
Бу — ахмаклык, кызым, ишетәсеңме?!

Джульетта

Ә югалту артык авыр булса?

Капулетти ханым

Күз яшеңне барыбер күрми бит ул.

Джульетта

Юк, ул күрсен өчен еламыйм мин,
Чын күңелдән елыйм, хәсрәтем зур.

Капулетти ханым

Тибальт кайгысыннан битәррәк,
Үтерүче борчый сине, беләм.
Ул кабахәт һаман исән йөри.
Шул бетерә сине.

Джульетта

Кем кабахәт?

Капулетти ханым

Кем булсын ди, әнә Ромео.

Джульетта
(читкә)

Ромео белән кабахәтлек
Икесе ике нәрсә!
(Кычкырып.)
Ходай шаһит,
Минем йөрәгемне аның кадәр
Телгәләгән кеше юк дөньяда!

Капулетти ханым

Болар бар да ул исәнгә күрә.

Джульетта

Әйе, исән һәм кул җитмәс җирдә.
Тибальт өчен үзем үч алырмын.

Капулетти ханым

Үч алырбыз анысы, син борчылма.
Мантуяга кеше җибәрәм мин.
Шунда ята, диләр ул башкисәр.
Агу бирәп аны Тибальт янына
Озатырга кирәк, шул чагында
Тынычланыр идең син дә, балам.

Джульетта

Ромео кулга төшми торып
Тынычлана алмам беркайчан да.
Илтер кеше булса, агуны мин
Үзем әзерләрмен, борчылмагыз.

Шундый әзерләрмен, эчү белән
Ромео изрәп йоклап китәр.
Ah, кызганыч, янына бара алмыйм!
Мин Тибальтка булган сөю көчен
Юнәлдереп аңа, үтерүчене
Кочагымда буып үтерер идем.

Капулетти ханым

Агуын эзлә, кешесен үзем табам.
Йә, борчылма, яңа хәбәр әйтеп
Шатландырам хәзер сине, балам.

Джульетта

Мондый чакта шатлык тансык була,
Әйтегез, әнкәй, нинди хәбәр соң ул?

Капулетти ханым

Атаң, кызым, шундый кайгыртучан.
Хәсрәтеңнән арындырыр өчен,
Синең белән минем төшебезгә дә
Керми торган олы бәйрәм ясый.

Джульетта

Нинди бәйрәм соң ул? Кайчан була?

Капулетти ханым

Атна кич көн, балам, атна кич көн.
Затлы, чибәр граф Парис сине
Шат, бәхетле хатыны итәр өчен
Изге Петр чиркәвенә дәшә.
Никах, кызым, никах, сизәсеңме?

Джульетта

Изге Петр үзе һәм чиркәве
Икесе дә шаһит, ант итәмен:
Мин Париска бармыйм. Беркайчан да
Шат, бәхетле хатын булмам аңа!
Әле кияү күз дә сирпемәгән,
Ә сез никах дисез ашык-пошык.
Рәхмәт инде: әйтегез әткәйгә дә,
Мин кияүгә чыкмыйм, иртә әле.
Чыгам икән, тик Париска түгел!
Аңа чыкканчы, мин кан дошманым
Ромеога чыгам. Белдегезме?

Капулетти ханым

Әнә атаң керә. Әйт үзенә.
Карап карыйк, нәрсә дияр икән.

Капулетти белән Тәрбияче керәләр.

Капулетти

Кояш баеса, җиргә чыклар төшә.
Ә Тибальтның гомер кояшы
Баеганнан бирле яңгыр коя.
Нихәл, кызым? Елап туймадыңмы?
Күзләреңнән һаман яшь коела.
Күрер күзгә йодрык кадәр генә,
Көрәшүе үзенә күрә түгел.
Көрсенүдән туган зилзиләдә
Күз яшьләре чоңгылына төшеп,
Батмый калган нәни кораб кебек,
Давыл тынып тынлык урнашканчы
Көрәшәчәк. Хатын, йә, ничек соң,
Безнең карар игълан ителдеме?

Капулетти ханым

Иттем дә бит, ләкин кире кага,
Ишетәсе дә килми ул турыда.

Капулетти

Ничек, ничек, ялгыш ишетәмме соң?!
Йә, кабатла әле. Кире кага?
Горурланмый дамы? Ah, дивана!
Үзеннән дә затлы кияү таптык,
Берәү булса рәхмәт әйтер иде,
Ә бу кире кага, юньсез бала.

Джульетта

Рәхмәт әйтәм, ләкин горурланмыйм.
Туры сүзем өчен кичерегез!
Мине җирәндергән нәрсә белән,
Йә, нигә дип әле горурланыйм?
Бу бүләкне тапкан өчен түгел,
Ә эзләгән өчен рәхмәт сезгә.

Капулетти

Бу ни тагын? Нинди мәгънәсезлек?!
Әйткән сүзләреңнең җебе кайда?
Бер «рәхмәт» ди шунда, бер «горур» ди,
Артыннан ук шуның киресен туглый.
Җитте, кызый, туктат бу уенны!
Горурлыгың белән рәхмәтеңә
Төкерәм мин синең лачт иттереп!
Кара аны, никах көнең җитә.
Парис белән Петр чиркәвенә
Барасыңны уйла һәм карышма.
Юкса әнә бозау илткән кебек,
Муенчаклап алып барачакмын.
Йә, бар, олак, юлдан язган нәрсә!
Ачәрвахтай торма күз алдымда.
Ah үләксә, үләт екса иде!
Бик зур кеше булган!

Капулетти ханым

Акылыңа кил!

Джульетта

Мин тезләнеп сорыйм, зинһар, әткәй,
Бер генә сүз әйтим, тыңлагызчы!

Капулетти

Яп авызыңны! Ни әйтәсең мәгълүм!
Мин сиңа әйттем: дәшми-тынмый гына
Чиркәүгә бар, дидем, атна кич көн.
Тыңламасаң әгәр, өйдән куам,
Күз алдымда тотмыйм бер минут та.
Җитте! Дәшмә! Без бит ике ахмак,
Ходай безгә бер генә бала бирде,
Дия-дия күпме елап йөрдек.
Шул берсе дә хәзер утка салды!
У, кабахәт!

Тәрбияче

Ходаем, үзең сакла!
Үз балагыз бит ул, ник хурлыйсыз?
Кыз баланы хурлау гөнаһ, синьор.

Капулетти

Дәшмә, ахмак! Үз ишләрең белән
Тел чарла син, телең бик кычытса!

Тәрбияче

Мин начарга әйтмим.

Капулетти

Йә, бар, ычкын!

Тәрбияче

Авыз ачып сүз дә әйттермиләр.

Капулетти

Ычкын, диләр сиңа! Ah, карт юләр!
Син үзеңнең хәшәп авызыңны
Үзең кебек җыен ахмак белән
Шәраб чөмергәндә ач күбрәк!
Монда кабак түгел, акыл сатма!

Капулетти ханым

Чамадан тыш кызма.

Капулетти

Кызу түгел,
Акылыңнан яздырырлар болар!
Йә, күр инде! Мин бит көне-төне,

Кая гына барып, ни кылсам да,
Урамда да, өйдә, кунакта да,
Кеше арасында йә булмаса
Ялгыз гына калган чакларда да,
Әйбәт кияү табу уе белән
Янып-көеп йөрдем һәм таптым да.
Менә дигән егет: дәүләте зур,
Нәселе затлы, чибәр, тәрбияле.
Яхшы сыйфатларын саный китсәң,
Очына чыгалмассың. Син күр әле,
Шундый егетне дә кире кага.
Дуңгыз кебек чинап елый-елый
Нәрсә ди бит, башсыз, ah, дивана!
«Юк, теләмим!», «Булмый», «Миңа иртә!»,
«Кичерегез!» Ярый, кичермен.
Әмма әйтеп куям: моннан ары
Тамагыңны теләсәң кайда туйдыр.
Мин телемне юкка әрәм итмим,
Уйлар өчен ике көнең калды:
Йә кияүгә чыгып каласың сиң,
Йә булмаса, ачка койрык чәнчеп,
Сукбайлыкта йөре, йә асылын!
Тик ул чакта миңа әти диеп
Эндәшәсе булма. Өстәвенә
Мирастан да колак кагачаксың.
Икенең берсе: уйла, мин шаярмыйм!
(Китә.)

Джульетта

Хәсрәтемнең бөтен тирәнлеген
Күреп торган күкләр ник якламый?
Зинһар, әнкәй, куып чыгармагыз!
Кичектереп торыгыз бу никахны.
Тик бер генә айга, бер атнага...
Булмый икән, кабер төрбәсенә
Озатырсыз тиздән Тибальт янына!

Капулетти ханым

Без хәл иттек. Инде теләсә нишлә.
Әйтер сүзем бетте. Башка дәшмә.
(Китә.)

Джульетта

Әй Ходаем! Даям! Әйтче, нишлим?
Антым күктә, ирем җирдә минем.
Хәләлемнең җаны күккә ашмый,
Ул антымны ничек кире алыйм?
Нигә язмыш шундый авыр богау
Сала икән миндәй зәгыйфь җанга?
Йә, ни дисең, даям, юатырлык
Бер сүзең дә юкмы?

Тәрбияче

Бар, бар, балам.
Ромеоң читтә каңгырып йөри,
Кайта да алмас бүтән, ул сөргендә.
Шуңа күрә син графны сайла.
Ни дисәң дә граф граф инде,
Бөркет карашы бар карашында.
Ә Ромео — чүпрәк, мәми авыз,
Менә шуннан үзең уйлап кара.
Яңа никах байлык, муллык белән
Оныттырыр, җаным, элеккесен.
Ромеодан сиңа нинди файда?
Синең өчен тере мәет бит ул.
Ә мәеттән аннан ни көтәсең.

Джульетта

Чынлап әйтәсеңме?

Тәрбияче

Чынлап әйтәм.

Джульетта

Амин!

Тәрбияче

Нәрсә?

Джульетта

Әйбәт юаттың.
Бар, әнкәйгә төшеп әйтче, дая:
Әткәй сүзенә каршы килеп бая
Зур гөнаһлы булдым. Шуңа күрә
Тәүбә итәр өчен Лоренцо ата
Хөжрәсенә барам, борчылмасын.

Тәрбияче

Хәзер төшәм. Бу — акыллы адым!
Бу эшеңә, балам, кул куямын.
(Китә.)

Джульетта

Менә кем ул гөнаһ чыганагы!
Күңел аздыручы җен карчыгы!
Ромеоны күккә чөя-чөя
Мактады да башта, инде хәзер
Шул ук теле белән хурлап аны,
Хыянәткә димли мине, ләгыйнь.
Бетте, бетте! Бар да бетте, дая!
Ике арада безнең упкын хәзер.
Атлап чыгармын дип уйлама да!
Изге атада хәзер бөтен өмет,
Ул коткарыр, бәлки, киңәш биреп.
Булмый икән, җаным күккә ашсын,

Ак тәнемне кара кабер алсын!
(Китә.)

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лоренцо хөҗрәсе.
Парис белән Лоренцо керәләр.

Лоренцо

Атна кичкә? Бик ашыгыч икән!

Парис

Каенатай ич әнә шулай тели.
Ашыктыра. Ничек каршы килим?

Лоренцо

Сез бит әле, кызның ризалыгын
Сорамадым, дисез. Белмим, белмим,
Күңелемә ятмый никтер бу эш.

Парис

Аның белән сөйләшеп тә булмый,
Тибальт өчен һаман күз-яшь түгә.
Ә мәхәббәт алиһәсе исә
Күз-яшь түккән өйдә сирәк көлә.
Атасы да көн-төн елавына
Бик борчыла: «Ул-бу булмасын», — ди.
Никах көнен ашыктырып, шулай
Елга булып ташыган күз яшьләрен
Ярларына кайтарырга тели.
Ялгыз кеше хәсрәтенә чума,
Иргә чыкса, тизрәк кибәр яше.
Ашыгуның сәбәпләрен хәзер
Аңлыйсыздыр?

Лоренцо
(читкә)

Кызганычка каршы!
(Кычкырып.)
Әнә туташ үзе кереп килә.

Джульетта керә.

Парис

Очрашуга мин шат, бикәчкәем.
Джульетта

Әлегә сезгә бикәч булганым юк!

Парис

Булырсыз дип уйлыйм атна кичкә.

Джульетта

Алла бирсә, диегез!

Лоренцо

Анысы дөрес.

Парис

Изге атага тәүбә итәр өчен
Килгәнсездер инде сез, мөгаен?

Джульетта

Әгәр җавап бирсәм, сезнең алда
Тәүбә итү була түгелме соң?

Парис

Күп елаудан йөзегез сулып калган.

Джульетта

Мин элек тә йөзгә ямьсез идем.

Парис

Ялган сүзләр белән үзегезнең
Йөзегезне алай ник хурлыйсыз?

Джульетта

Дөресен әйтү нигә хурлык булсын?
Хурласам да, үз йөземне хурлыйм.

Парис

Юк, минекен. Хәзер ул минеке.
Хурламагыз аны.

Джульетта

Бәлки әле,
Шулай булган өчен хурлыймдыр да.
Изге ата, вакытыгыз ничек?
Әллә миңа соңрак килергәме?

Лоренцо

Юк, юк, кызым, бик вакытлы килдең.
Кичерегез, граф, аның белән
Безгә икәү генә калу кирәк.

Парис

О, әлбәттә, андый изге эшкә
Комачаулап тору мөмкинме соң!
Джульетта, сезне атна кич көн
Иртән-иртүк килеп уятырмын.
Ә хәзергә ихлас үбүемне
Кабул итсәгезче. Сау булыгыз.
(Китә.)

Джульетта

Ишегеңне яп та минем белән
Кушылып ела син дә, изге ата.
Өмет тә юк хәзер, котылу да!

Лоренцо

Хәсрәтеңне беләм, Джульетта,
Ярдәм итәр чара таба алмыйча,
Уйлый-уйлый тәмам башым катты.
Атна кичкә никах, ишетүемчә,
Кичектереп булмый берничек тә!

Джульетта

Коткарырлык чара таба алмагач,
Ул турыда сөйләп тел талдырма.
Ниятемне генә акла, шушы хәнҗәр
Арындырыр мине кайгылардан.
Мин Ромео никахында хәзер,
Бөтенләем беләнаныкы мин,
Йөрәкләрне безнең күктә — Алла,
Ә кулларны җирдә син бәйләдең.
Ромеога тиеш шушы кулны
Башкаларга сузсам, йә булмаса
Тугры йөрәк үзенең антын бозып
Көтмәгәндә ятка тапшырылса,
Йөрәгемне мин үз кулым белән
Шул минуттук һәлак итәчәкмен.
Озак еллар җыйган тәҗрибәңне
Эшкә җигеп, тизрәк бер киңәш бир.
Юкса күрәсеңме, шушы хәнҗәр
Кайгы белән минем арадагы
Бу көрәштә миңа ярдәм итәр.
Сөйлә, сузма! Йә киңәш бир миңа,
Булмый икән, үлим, тоткарлама.

Лоренцо

Тукта, кызым. Бер өметле фикер
Туып килә бугай минем башта.
Тик куркыныч фикер. Безнең өскә
Килгән бәладән ул һич ким түгел.
Парис кочагыннан син үлемне
Артыграк күрәм, дидеңме әле?
Ул чагында сине бу хурлыктан
Коткарырга мөмкин. Минем кулда
Үлем сымаграк бер чара бар.
Тик ул бик зур тәвәккәллек сорый,
Риза булсаң, бирәм, әйдә уйла.

Джульетта

Мин, Париска хатын булмас өчен,
Манарадан сикерәм, тик куш кына.
Юлбасарлар белән бергә яшим,
Елан оясына барып керәм.

Йә котырган аю белән бергә
Бер чылбырга үземне беркеттерәм.
Аның кочагына кергәнче, мин
Мәет кочагына кереп ятам.
Яки әнә кәфен бөркәнәм дә
Буш кабергә төшеп төн уздырам.
Бөтенесен эшлим, Ромеога
Биргән антым гына бозылмасын.

Лоренцо

Бар, алайса, хәзер өеңә кайт.
Шат булган бул өйдә, боек йөрмә
Һәм Парисның хатыны булырга да
Ризалык бир, зинһар, каршы килмә.
Ә иртәгә — чәршәмбе көн исә —
Даяң белән бергә йоклама син.
Ничек булса аны үз бүлмәңнән
Озатырга тырыш, ә ятуга
Шул шешәне ач та бар даруны
Тамчысына кадәр эчеп җибәр.
Эчеп бетерүгә, кинәт кенә
Тамырларың буйлап салкын йөгерер,
Каның оер, каты йокы басар,
Тәнең суыныр, хәтта сулышың да
Туктагандай булыр, һичбер төрле
Хәят билгеләре калмас синдә.
Йөзеңдәге алсулыгың сүнеп,
Иреннәрең керер көл төсенә.
Ә күзләрең синең кич ябылган
Тәрәзәләр сыман йомылырлар.
Гәүдәң исә, җансыз мәет кебек,
Хәрәкәтсез-нисез катып калыр.
Шул халәттә кырык ике сәгать
Ятканнан соң кабат уянырсың.
Кыскасы шул: уятырга килгән
Парис сине үлгән диеп белер.
Шуннан инде борынгыдан килгән
Йола буенча, никах киеменнән,
Табутыңның өстен капламыйча,
Капулетти нәселе куела торган
Кабер төрбәсенә китererләр.
Ә мин исә тизрәк Ромеога
Хәбәр җибәрермен. Ул кайтуга,
Кабер төрбәсенә килеп икәү
Көтеп торачакбыз син торганны.
Уянуга, ирең Мантуяга
Алып китәр шундук, аңладыңмы?
Менә сиңа котылыр чара, кызым.
Куркып калып эшне чуалтмасаң,
Бу хурлыктан, шиксез, котылырсың.

Джульетта

Бир шешәңне! Әйтмә курку сүзен.

Лоренцо

Мә, ал, кызым, тәвәккәллек белән
Башкар эшне, курыкма, көчле бул син.
Ә мин исә хәзер үк Ромеога
Хат язам да юллыйм Мантуяга.

Джульетта

Тәвәккәллек белән көчне миңа
Мәхәббәтем бирер. Сау бул, ата.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулетти өенең залы. Капулетти, Капулетти ханым, Тәрбияче һәм
ике хезмәтче керәләр.

Капулетти

Исемлеккә кергән кешеләрнең
Һәммәсен дә чакыр!

Беренче хезмәтче чыгып китә.

Син, кадерлем,
Хәзер үк барып пешекчеләр ялла.
Егермеләп кеше кирәк булыр,
Тик онытма, әйбәтләре булсын.
Икенче хезмәтче. Ул турыда борчылмагыз, әфәндем. Тикшереп яллыйм мин аларны. Башта карармын: бармакларын ялыйлармы, юкмы.
Капулетти. Анысы нигә тагын?
Икенче хезмәтче. Бармагын яламаган пешекче пешекче була димени?
Андыйларның поты бер тиен.

Капулетти

Йә, ярый, бар.

Икенче хезмәтче чыгып китә.

Бу мәшәкать берәр бетәр микән?
Ерып чыгып булса ярар иде.
Лоренцога киттемени теге?

Тәрбияче

Хәерлегә булсын, шунда китте.

Капулетти

Туры юлга ул күндерсә генә,
Киребеткән кызый, тәмам шашты.

Джульетта керә.

Тәрбияче

Әнә кайта, тәүбә иткәч, ничек
Ачылып киткән, йөзе балкып тора.

Капулетти

Киребеткән, кая югалдың син?

Джульетта

Юк, үзеңне каян таптың, диегез!
Кирелегем өчен үкенәм хәзер.
Лоренцо ата сезнең алдыгызда
Тезләнергә кушты гафу сорап.
Кичерегез, зинһар, моннан ары
Сүзегездән чыкмам беркайчан да.

Капулетти

Бу сүзләрне тизрәк графка да
Җиткерергә кирәк. Ник сузарга?
Иртәгә үк кавыштырам сезне.

Джульетта

Лоренцо ата хөжрәсендә бүген
Граф белән без күрештек инде.
Әдәп белән генә мин үземнең
Теләгемне аңа ирештердем.

Капулетти

Бик шәп булган. Мин шат. Йә, булды, тор.
Күптән, кызым, шулай кирәк иде.
Графны да күрсәм, эш җайлана.
Әй, графка кеше җибәрегез!
Нинди әйбәт монах, юкка гына
Бөтен шәһәр хөрмәт итми икән.

Джульетта

Әйдә, даям, өскә меник тә без.
Иртәгесе көнгә кием сайлыйк.

Капулетти ханым

Ашыкмагыз, вакыт бар бит әле.
Туй иртәгә түгел, атна кичкә.

Капулетти

Бар, бар, дая. Булыш. Ике яшьне
Иртәгә үк кушам, Алла бирсә.

Джульетта белән Тәрбияче чыгып китәләр.

Капулетти ханым

Өлгереп булмас, вакыт бик аз калды.
Кич җитә бит.

Капулетти

Җитсен, курыкма, хатын.
Булышырмын, эшләр гөрләп торыр.
Бар, өскә мен, кызга кием сайлаш.
Синең эшне үзем башкарырмын.
Хезмәтчеләр! Шайтан алгырлары,
Берсе дә юк! Ярый, болай булгач,

Иртәгә туй, диеп, мин Париска
Үзем барып әйтеп килим инде.
Кызны йөгәнләгәч, бөтен эшләр
Майлаган күк бара, шундый җиңел.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Джульетта бүлмәсе. Джульетта белән Тәрбияче керәләр.

Джульетта

Иң әйбәте менә бу күлмәгем.
Инде, даям, мине ялгыз калдыр.
Төне буе бүген дога кылып
Туй алдыннан бераз аруланыйм.
Күңелемдә күпме яшерен гөнаһ
Ятканлыгын үзең беләсең бит.

Капулетти ханым керә.

Капулетти ханым

Мәш киләләр. Мин дә булышыйммы?

Джульетта

Юк, юк, әнкәй, туйга ни кирәген
Сайлап алдык инде: мөмкин булса,
Ялгызымны гына калдырыгыз.
Даяны да алыгыз үзегез белән.
Ул булышыр сезгә, юкса бүген
Мәшәкать зур. Бик авырга килер.

Капулетти ханым

Ярый, ярый, кызым, ят та йокла.
Ял итәргә кирәк хәзер сиңа.

Капуллетти ханым белән Тәрбияче чыгып китәләр.

Джульетта

Сау булыгыз. Кайчан очрашасын
Тик бер Алла белә... Тәнем буйлап
Курку катыш салкын йөгереп узды.
Тамырларда каным бозга әйләнә.
Миңа аларсыз бик ямансу икән.
Кире чакырам. Даям! Юк, юк, тукта!
Нәрсә калган аңа минем янда?
Бу сәхнәне мин ялгызым гына
Башкарырга тиеш. Шешә кайда?
Әгәр дару тәэсир итми калса?
Мин иртәгә, димәк, кияүгә чыгам?
Юк, юк, булмас, мине ул хурлыктан
Шушы хәнҗәр саклар. Янәшә бул.
(Хәнҗәрне мендәр астына яшерә.)

Изге ата әгәр дару түгел,
Агу биргән булса үтерер өчен?
Нигә, мөмкин, чөнки шушы никах
Фаш итәчәк аның кыңгыр эшен.
Әгәр үлсәм, мине Ромеога
Никахлавын кеше белмәячәк.
Ул чагында аның дәрәҗәсе
Тапланмыйча кала, чиста көе.
Шуңа күрә, бәлки, үтерергә
Телидер ул? Тукта, нәрсә сөйлим?
Булмас, булмас, ул бит изге кеше.
Әлегә кадәр изгелектән генә
Торды аның бөтен кылган эше...
Әгәр дә мин кинәт Ромео
Килеп җитмәс борын уянып китсәм?
Ah, коточкыч! Мәет исе сеңгән
Ул караңгы, сасы таш төрбәгә
Саф һаваның керми әсәре дә,
Шуңа күрә тончыгырга мөмкин!
Коткарырга килгән иремне дә
Күрә алмыйча үлеп китмәм микән?
Үлмәсәң дә андый караңгыда —
Дәһшәт тулы үлем сараенда
Акылыңнан язмау мөмкин түгел.
Ул төрбәдә безнең ата-баба
Ничә йөз ел инде күмелеп килә.
Канга баткан Тибальт мәете анда
Череп ята җирдә әкрен генә.
Вакыт-вакыт хәтта үлгәннәрнең
Өрәкләре чыгып йөри, диләр.
Раббым Алла, әгәр шунда кинәт
Вакытыннан алда уянылса?
Как сөякләр, черегән мәет исе,
Коточыргыч төрле ят авазлар,
Мандрагора ыңгырашуы кебек,
Акылымнан мине яздырсалар?
Шашып китеп Тибальт мәетеннән
Кәфенен тартып алсам йә булмаса
Бабамнарның балтыр сөякләрен
Күсәк итеп уйнап үз башымны
Урталайга ярсам, мием акса?
Тукта! Тукта! Минем күзгә әнә
Тибальт күренә. Үзен үтерүчене,
Ромеоны эзли. Тукта, Тибальт!
Ромео, бәгърем, сиңа барам.
Синең өчен эчәм бу даруны!
(Түшәгенә ава.)

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капулеттилар өенең залы. Капулетти ханым белән Тәрбияче керәләр.

Капулетти ханым

Инде хәзер тәм-том кирәк булыр,
Ачкыч ал да бар, алып кер, дая.

Тәрбияче

Аш өендә тагын айва белән
Хөрмә кирәк, диләр.

Капулетти керә.

Капулетти

Җәһәтрәк!
Икенче әтәч инде кычкырды бит.
Гыйбадәткә чакырып чаң суктылар.
Бәлешләрне кара, аш-суларың
Мулдан булсын берүк, саранланма.

Капулетти ханым

Кирәкмәгән эшкә хатынша күк
Тыгылып йөрмә. Йокла. Йә чирләрсең.

Капулетти

Үз гомеремдә төннең төн буенча
Йокламаган чагым шактый булды.
Чирләмәдем.

Капулетти ханым

Әйе, анысы дөрес,
Асрауларның ишеген күп шакыдың.
Моннан ары ауга чыгалмассың,
Мин өстеңдә торып йоклатырмын.

Капулетти ханым белән Тәрбияче чыгып китәләр.

Капулетти

Кара, кара көнче күбәләкне!
Нәрсә ди бит?!

Утын, ит кыздыра торган таяклар, тырыслар күтәргән хезмәтчеләр керәләр.

Тукта! Бу нәрсә бу?

Беренче хезмәтче

Пешекчегә илтәм. Ни икәнен
Мин үзем дә белмим.

Капулетти

Йә, бар, ычкын!

Беренче хезмәтче китә.

Ник утының юеш? Бар Петрдан
Корырагын сора. Ул күрсәтер.

Икенче хезмәтче

Ник Петрдан, синьор? Анлык кына
Үз башым да эшли, бүкән түгел.

Капулетти

Бүкән түгел, анысын хак әйтәсең,
Бүкән булса, эшкә ярар иде.

Икенче хезмәтче китә.

Әллә таң да атты? Озакламый
Музыкантлар белән Парис килер.

Сәхнә артында музыка тавышы.

Ни ишетәм, тукта, музыкантлар!
Әйе, әйе, алар, дая, хатын!
Берсе дә юк, каһәр генә суксын!
Дая, димен, дая!

Тәрбияче керә.

Бар, тизрәк.
Джульеттаны уят һәм киендер,
Йә, кыймылда инде, кияү килде!
Кияү килде, дим бит, җәһәтрәк!
(Китә.)

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Джульетта бүлмәсе. Тәрбияче керә.

Тәрбияче

Туташкаем! Туташ! Уян әйдә!
Уянырга вакыт! Йә, тор инде!
Йокы базарына киттеңме әллә?
Торасыңмы, юкмы? Юкса хәзер
Кирәгеңне бирәм! Менә! Менә!
Кымшанмый да. Ярый, йокла, йокла.
Бүген төнлә Парис йокы бирмәс,
Бар куәтен салыр йоклатмаска.
Ничек каты йоклый. Юк, хәзер үк
Уятырга кирәк. Джульетта!
Йә, тор инде, тиздән граф керә.
Түшәгеңдә яткан көе генә
Каршыларга җыенасыңмы?
Аңа нәрсә? Ул шатланыр гына.
(Пәрдәсен ачып җибәрә.)
Йә, күр инде, туй күлмәген киеп
Түшәгенә чумган. Бу нинди эш?
Туташ, димен, туташ, йә, тор әле!
Юк, юк, булмас... Бирегә! Туташ үлгән!
Әй Ходаем! Тизрәк, тизрәк! Ярдәм!
Шәраб бирегез! Тик бер генә йотым!
Бу хәсрәттән юкса мин дә үләм!

Капулетти ханым керә.

Капулетти ханым

Ник шаулыйсың болай?

Тәрбияче

Коточкыч көн!
Бәла килде безгә!

Капулетти ханым

Нинди бәла?

Тәрбияче

Юк, әйтә алмыйм, телем бармый минем.
Әнә карагыз!

Капулетти ханым

Балам! Бәгырькәем!
Ярдәм итегез, ярдәм!

Капулетти керә.

Капулетти

Бу нинди эш?
Кияү көтә анда, ул һаман юк!

Тәрбияче

Джульетта юк, үлде!

Капулетти

Ни сөйлисең?
Булмас, булмас, булуы мөмкин түгел!
Кая, карыйм әле, җибәрегез!
Кан әсәре күрмим. Боз күк салкын.
Йа Ходаем, ул бит күптән үлгән!
Бар да бетте! Үлем, кырау булып,
Бакчамдагы гөлне харап итте!

Тәрбияче

Коточкыч көн!

Капулетти ханым

Бәла, бәла килде!

Капулетти

Мәрхәмәтсез үлем аны алып
Телсез итте мине, сүз табалмыйм!

Лоренцо, Парис һәм музыкантлар керәләр.

Лоренцо

Йә, нихәлләр, кәләш әзерме соң?
Чиркәүгә дә барыр вакыт җитте.

Капулетти

Баруын барыр, әмма кире кайтмас.

Балакаем, синең кәләшеңне
Әҗәл явыз кочкан бүген төнлә.
Инде хәзер сынган чәчәк кебек,
Аның кочагында ята әнә.
Әҗәл — кияү миңа, әҗәл — варис,
Аның никахында хәзер кызым.
Мин дә үләм, әйдә, малыма да,
Җаныма да әҗәл хуҗа булсын.

Парис

Мин бик озак көттем шушы таңны,
Ә ул мине ничек каршылады?!

Капулетти ханым

Кahәр суккан көн бу, куркыныч көн!
Бәхетсезлек белән күмде безне!
Әлегә кадәр җиһан күргән-белгән
Көннәрнең бу иң-иң әшәкесе!
Бердәнберем, юанычым иде.
Күз нурым күк газиз шул баламны
Аямады язмыш, харап итте!

Тәрбияче

Нинди көн бу, нинди кahәрле көн!
Ah, күзләрем шуны күрмәсә иде!
Кahәр суккан көн бу, кahәр суккан!
Раббым Аллам, зинhар, сукырайт мине!

Парис

Мин тол калдым, явызларча мине
Алдадың син, үлем, мыскылладың!
Синең кулдан минем бар барлыгым:
Мәхәббәтем, җаным hәлак булды!

Капулетти

Беттем, беттем, ихтыярсыз калдым,
Хәсрәт мине тәмам изеп китте.
Бәхетсезлек, нигә килдең безгә?
Ник бәйрәмнән безне мәхрүм иттең?
Ул бит минем балам гына түгел,
Газиз җаным иде, йөрәк парәм.
Аны жуйгач, хәзер бу дөньяның
Шатлыклары миңа нигә кирәк?

Лоренцо

Булды инде, җитәр, оялыгыз!
Елап кына хәсрәт китмәячәк!
Бу бала бит сезнең Ходай белән
Уртак җимеш иде, инде менә
Бөтенләе белән үз катына
Алган аны бүген Хак Тәгалә.
Джульеттага күктә җирдәгедән
Әйбәтрәк, чөнки аны әнә

Сез үлемнән саклый алмадыгыз,
Ходай исә бакый гомер бирә.
Кызыгызны һаман югарыга
Күтәрергә иде исәбегез.
Ул күкләргә ашкач, нигә болай
Үләр чиккә җитеп яшь түгәсез?
Джульетта хәзер ожмах кошы.
Шуны белә торып сөенмисез,
Димәк, аны ихлас сөймәгәнсез?
Сез аңарга бәхет теләдегез.
Бәхетләләр шулай иртә үлә,
Кабул булды сезнең теләгегез!
Инде, әйдәгез, күз яшьләрен сөртеп,
Йола буенча розмариннар сибеп,
Туй киеме киендереп аңа,
Без чиркәүгә хәзер озатыйк аны.
Табигате белән кеше йомшак,
Елау, сыктау аңа шуннан килә.
Акылыбыз исә яшькә каты,
Көлеп кенә карый күз яшенә.

Капулетти

Туйга дигән һәммә нәрсә бүген
Сарыф ителәчәк җеназага
Һәм биредә шат аһәңнәр түгел,
Матәм көен уйнар уенчылар.
Изге җырлар җырлап, чаң кагарлар,
Туй өстәле матәм мәҗлесенә
Әверелеп китәр тора-бара.
Никахына дигән матур гөлләр
Табутына аның түшәлерләр.
Бар нәрсәнең асты өскә килде!

Лоренцо

Йә, кузгалыйк. Синьор, сез дә ханым,
Граф сез дә, барыгыз, җыеныгыз.
Мәрхүмәкәй гүзәл Джульеттаны
Каберлеккә илтер вакыт җитте.
Күкләр, мөгаен, сезгә ачулыдыр.
Күз яшегез белән Тәңребезне
Борчымагыз бүтән, сак булыгыз!

Капулетти, Капулетти ханым, Парис һәм Лоренцо чыгып китәләр.

Беренче музыкант. Димәк, безгә сыбызгы-сорнайларыбызны җыеп өйләребезгә таралырга?

Тәрбияче

Таралыгыз, тарал, күз нурларым,
Күрәсез бит, кайгы баштан ашкан.
(Китә.)
Беренче хезмәтче. Анысы шулайдыр, әмма чакырып китергәч — түләргә дә кирәк.

Петр керә.

Петр. Музыкантлар, әй, музыкантлар, бию көе уйнагыз! Әгәр дә минем исән калуымны теләсәгез, хәзер үк бию көе уйнагыз!
Беренче музыкант. Ә ни өчен бию көе?
Петр. Чөнки минем кайгыдан йөрәгем телгәләнә. Зинһар, бию көе уйнагыз. Дәртлерәген, күңеллерәген. Ачыгыз күңелемне. Коткарыгыз мине бу бәладән!
Беренче музыкант. Бию көе уйный торган чакмыни хәзер?!
Юк, ярамый. Уйнарга кушмадылар.
Петр. Димәк, уйнамыйсыз?
Беренче музыкант.Юк.
Петр. Алайса, хәзер мин сезгә күрсәтәм!
Беренче музыкант. Гафу итегез, нәрсә күрсәтмәкче буласыз?
Петр. Үз урыныгызны, йолкыш сыбызгылар!
Беренче музыкант. Күренеп тора: аш өенә юлны сез үзегез дә күптән оныткансыз бугай.
Петр. Аш өенә? Менә хәзер шушы пычак очы белән сыртыгызга шундый юл сызармын, аш өенә илткән юл ише генә дә булмас. Сезнең ул ре-ми-фа-ларыгыз аның янында чүп кенә булып калыр.
Икенче музыкант. Хәнҗәрегезне кынына тыгыгыз! Тәрбияле кешеләр бер-беренә хәнҗәр белән түгел, үткен сүз белән кадыйлар.
Петр. Ah, шулаймыни? Ул чагында сакланыгыз! Мин сезне үткен сүзләр белән берәм-берәм чәнчеп үтерәчәкмен. Хәлегездән килсә, әйдә, минем сорауга җавап бирегез:
Хәсрәтемнән янып көйгән чакта,
Көннәр нигә болай озак үтә
Музыканың көмеш тавышында?
Ни өчен көмеш? Ни өчен, музыканың көмеш тавышы, диләр?
Йә, Симон Ярык Барабан, әйтеп кара?
Беренче музыкант. Билгеле инде, көмеш тавышы җанга рәхәтлек бирә.
Петр. Әйбәт әйттең! Ә синеңчә ничек, Гью Тутык Быргы?
Икенче музыкант. Ни өчен көмешме? Чөнки музыка уйнаган өчен көмеш белән түлиләр.
Петр. Син дә ярыйсы әйттең! Ә син ни дисең, Яшка Сыбызгы?
Өченче музыкант. Валлаһи, дип әйтәм, белмим.
Петр. Ah, кичерә күр, зинһар, мин бит синең җырчы икәнеңне бөтенләй онытып җибәргәнмен. Кыскасы шул: берегез дә җавап бирә алмады, инде үзем әйтәм. Музыканың тавышы шуның өчен көмеш, чөнки сезнең ише хәсрәт музыкантларга беркайчан да алтын белән түләмиләр. Белдегезме?
Музыканың көмеш тавышында
Әллә килә сагыш, әллә китә?
(Китә.)
Беренче музыкант. Ah, Иблис, теленә тилчә чыкса иде, нәрсә ди бит!
Икенче музыкант. Төкер син аңа, Джек! Әйдәгез, аш өе тирәсендәрәк чуалыйк әле. Җеназаны озаткач, бәлки, ашатып чыгарырлар.

Китәләр.

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мантуя. Урам. Ромео керә.

Ромео

Юраганым тик юш кына килсен,
Күргән төшем шатлык вәгъдә итә.
Ниндидер көч бүген иртә таңнан
Җилкендерә мине, түбәм күктә.
Хыялларым — канат, очып йөрим,
Җиргә басканымны сизмим хәтта.
Бүген төштә хатынымны күрдем:
Эзләп килгән, ә мин үлгән, имеш.
Тик ни гаҗәп, үзем үлсәм дә, мин
Күреп ятам икән һәммәсен дә.
Көтмәгәндә аның үбүеннән
Терелеп киттем кинәт һәм ни күрәм:
Бар җиһанга мине патша итеп
Сайлаганнар, имеш. Әй мәхәббәт,
Син искиткеч татлы! Синең хакта
Уйлавы да әнә нинди рәхәт.

Шпорлы итекләр кигән Балтазар керә.

Веронадан хәбәр! Йә, Балтазар,
Хат китердең мәллә изге атадан?
Хатыным нихәл? Өйдәгеләр ничек?
Джульеттам, бәгърем, исән-саумы?
Тиз бул, сөйлә, әгәр аның хәле
Әйбәт икән, димәк, бар да яхшы.

Балтазар

Джульеттага әйбәт, инде хәзер
Беркайчан да начар булмаячак.
Ак тәненә аның кабер хуҗа,
Җаны исә фәрештәләр белән
Гарше көрсиләрдә күктә оча.
Җеназасын күргәч, шуны сезгә
Җиткерим дип тизрәк монда чаптым.
Бу хәбәрем өчен кичерегез,
Аны сездән яшереп калалмадым.

Ромео

Нәрсә дидең? Алай! Ләгънәт, ләгънәт!
Ләгънәт юллыйм күккә, йолдызларга!..
Минем торган өйне беләсең бит?
Бар, тиз генә кәгазь-каләм китер!
Атлар ялла. Төнлә юлга чыгам.

Балтазар

Күңелегезне, синьор, төшермәгез.
Күзләрегез яна, төсегез киткән...
Бу яхшыга түгел.

Ромео

Күп сөйләнмә.
Калдыр мине, бар, әйткәнне эшлә!
Изге атадан, димәк, хат-хәбәр юк?

Балтазар

Юк, әфәндем!

Ромео

Ярый, инде барыбер.
Йә, бар, сузма, тизрәк атлар ялла.
Синең арттан хәзер мин дә барам.

Балтазар китә.

Джульетта, бәгърем, бүген төнлә
Синең белән бергә ятачакбыз.
Ничек итеп хәзер бу нияткә
Ирешергә икән? Уйлап карыйк.
Бәхетсезгә шундук яман фикер
Көттермичә суза ярдәм кулын.
Теге аптекчы кинәт искә төште.
Ул биредә тора түгелме соң?
Әйе, әйе, күптән түгел генә
Күрдем үзен: җыйган үләннәрен
Ул тәртипкә китереп утыра иде.
Мохтаҗлыктан корып кибеп беткән
Как сөяккә калган сәләмә карт.
Аптегында аның ташбака бар,
Крокодилга хәтле эленеп тора,
Киптереп элгән төрле хәшәрәтләр,
Диңгез балыклары. Киштәләрдә
Чүлмәк ватыклары, буш әрҗәләр,
Кипкән үлән, орлык, киндерәләр,
Күгәреп беткән икмәк кисәкләре,
Иске-москы, тагын әллә ниләр.
Һәммәсенә товар кыяфәте
Кертеп бераз күрсәтергә куйган.
Шул чакта ук фәкыйрьлеген күреп:
Кемгә булса агу кирәк икән,
Агу саткан өчен Мантуяда
Үлем җәзасына тартсалар да,
Бу мескенкәй барыбер сатар, дидем.
Күңелем әллә агу кирәгәсен
Алдан сизгән шулай! Бу карт миңа
Ярдәм итми калмас. Ялгышмасам,
Алачыгы аның шушы бугай.
Бүген бәйрәм. Аптегында йозак.
Әй, аптекчы!

Аптекарь керә.

Аптекчы

Кем бар? Нәрсә кирәк?

Ромео

Чык әле, чык. Күрәм, син бик фәкыйрь,
Менә монда менә илле алтын,

Шул акчага миңа агу бир син.
Тик агуың шундый зәһәр булсын,
Аны эчүгә кеше шундук үлсен.
Туп авызыннан атылып чыга торган
Ядрә кебек, яшен тизлегендә
Чыгып очсын җаны ул кешенең.

Аптекчы

Андый нәрсә миндә бар барын да,
Сатып кына булмый, закон тыя.
Агу сатсаң, үлем җәзасына
Тарттыралар безнең Мантуяда.

Ромео

Ничек? Әллә ач-ялангач көе
Син үлемнән куркып торасыңмы?
Яңакларың тәмам эчкә баткан.
Күзләреңдә сагыш, кимсетелү,
Тормыш сине дуга итеп бөккән,
Фәкыйрьлектән тәмам алҗыгансың.
Бу дөньяның законнары сиңа
Байлык бирмәс, төкер дөньясына.
Ал акчаны, бае, боз законны.

Аптекчы

Ихтыярым түгел, мохтаҗлыгым
Ал дип боера, шуңа гына алам.

Ромео

Мин дә акчаны ихтыярга түгел,
Мохтаҗлыкка түлим, син борчылма.

Аптекчы

Менә шуны берәр эчемлеккә
Салыгыз да эчеп җибәрегез.
Нигә шунда егермеләп кеше
Көче булмый сездә, бер йотымы
Бер мизгелдә сезне егып салыр.

Ромео

Менә алтын, адәм җаны өчен
Аннан көчле агу булмас җирдә.
Бөтен явызлыкның башы шунда,
Син түгел, мин сиңа агу бирәм.
Ал алтынны, ал да ашап симер.
Ә без исә коткаручы, дустым
(Юк, син агу түгел — татлы дару),
Джульетта яткан таш төрбәгә —
Каберлеккә тизрәк чабыйк әйдә!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лоренцо хөжрәсе. Джованни керә.

Джованни

Әй, кайда син, газиз мәзһәптәшем?

Лоренцо

Джованни, туган, кайттыңмыни?
Нихәлләр соң анда — Мантуяда?
Ромео сиңа нәрсә диде?
Әйтер сүзен әллә хатка язып
Җибәрдеме? Йә, әйт, сузма инде.

Джованни

Өйдән өйгә йөреп авыруларга
Шәфкать күрсәтүче монах бар бит?
Шул монахны үземә юлдаш итеп
Чакырырга эзләп барган идем,
Көтмәгәндә шәһәр сакчылары
Ишегебезне тыштан бикләделәр.
Имештер, без үләт чире булган
Өйгә кереп авыру йоктырганбыз.
Чыгалмадык. Күпме ялынсак та,
Сүзебезгә колак салмадылар.
Шуңа күрә, туган, Мантуяга
Баралмадым.

Лоренцо

Тукта, минем хатны
Кем илтте соң ул чак Ромеога?

Джованни

Хат илтергә кеше тапмадым шул.
Бар да курка: имеш, үләт йога.
Менә хатың. Мә, ал. Кире бирәм.

Лоренцо

Харап булдык! Бу уен эш түгел.
Изге Франциск белән ант итәм:
Бу хатта бик мөһим хәбәр иде,
Вакытында аның тапшырылмавы
Бәхетсезлек булып кайтуы бар.
Бар, Джованни, син тимер лом эзлә,
Табу белән шундук монда китер.

Джованни

Китермен, туган.
(Китә.)

Лоренцо

Димәк, миңа
Кабер төрбәсенә ялгыз гына
Бару насыйп икән. Инде тиздән
Джульетта уяныр вакыт җитә.
Ул иренә хәбәр итмәвемне

Гафу итмәс. Шуңа Ромеога
Хат җибәрим кабат. Ул кайтканчы
Каберлекнең тере әсирен мин
Үз хөжрәмдә яшереп саклап торыйм.
(Китә.)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Каберлек. Капулеттилар төрбәсе. Парис һәм факел, чәчәкләр тоткан Паж керәләр.

Парис

Бир факелны. Үзең,бар, читкә кит.
Юк, юк, тукта! Сүндер! Юкса мине
Күрүләре мөмкин. Ә син әнә
Карт карама төбенә барып ят та
Колак салып тыңла тирә-якны.
Каберлектә күптән җирнең асты
Куышланып беткән. Аяк тавышы
Әллә каян яңгырап ишетелә.
Ул-бу булса, шундук сызгыр миңа,
Бир гөлләрне. Бар, әйткәнне эшлә.

Паж

(читкә)
Каберлектә төнлә ялгыз калу
Куркыныч та, нишлим, әмер шундый.
(Китә.)

Парис

Гөлкәемә гөлләр китердем мин.
Көл һәм таштан, бәгърем, синең чатыр.
Гөлләр сибәм никах түшәгеңә,
Күз яшьләрем юар кабер ташың.
Һәр төн саен шулай киләчәкмен,
Бәгърем, сине гөлгә күмәчәкмен.

Паж сызгыра.

Паж сызгырды, димәк, кемдер килә,
Нинди ләгыйнь йөри бу сәгатьтә?
(Яшеренә.)

Ромео белән Балтазар керәләр. Балтазарның кулында кәйлә, лом һәм факел.

Ромео

Кәйләне бир, ломны, ә бу хатны
Син әткәйгә тапшыр иртән-иртүк.
Ярый, булды. Инде ычкын моннан.
Әмма кара, кабат килеп минем
Нишләгәнне карап йөрмә тагын.
Әгәр күрсәм, шундук ботарлармын.
Мәетеңне, мең кисәккә турап,

Каберлеккә сибәм, аңладыңмы?
Шушы төн күк, мин куркыныч хәзер.
Котыртма син, алдан әйтеп куям:
Ач юлбарыс кебек ачулы мин,
Диңгез кебек ярсу, сак бул, туган.

Балтазар

Борчылмагыз, синьор, хәзер китәм,
Комачаулап тормыйм сезгә бүтән.

Ромео

Шулай итсәң, мине сөюеңне
Исбатларсың. Мә, ал. Син шәп егет.
Бәхетле бул. Йә, хуш. Озак яшә.

Балтазар читкәрәк китә.

Ромео

Комсыз әҗәл — мәңге туймас нәрсә,
Син йоткансың иң-иң гүзәл җанны.
Теш казнаңны хәзер каерып ачып,
Яңа ризык салам корсагыңа.
(Төрбә ишеген ача.)

Парис

Кемне күрәм? Кардәшемне суйган
Монтекки бит! Минем кәләшемне
Яшь түктереп гүргә керткән кеше.
Өстәвенә тагын мәетләрне
Мыскылларга килгән, ah, бәдбәхет!
(Яшеренгән җиреннән чыгып.)
Әй, Монтекки, тукта! Бу кабахәт
Ниятеңнән ваз кич! Изге урынга
Кагыласы булма! Үлгәннәрдән
Ничек мөмкин шулай үч алырга?
Җинаятьче качкын, хәзер үк бирел!
Кулга алындың. Әйдә минем арттан!
Син үләргә тиеш!

Ромео

Әйе, тиеш.
Шуның өчен монда килдем дә мин.
Котырганны, зинhар, ярсытма син.
Бу икәүне уйлап гыйбрәт ал да
Юлыңда бул, егет, калдыр мине.
Җан кыючы итмә мине кабат.
Үземнән дә артык сөям сине.
Сиңа түгел, тик үземә каршы
Коралланып килдем бирегә бүген.
Йөгер, дустым, йөгер исән чакта.
Шашкан кеше мәрхәмәте белән
Исән калдым, диген, сорасалар.

Парис

Бу җирәнгеч сүзләр! Җинаятьче,
Закон буенча сине кулга алам.

Ромео

Бик таләпчән булгач, әйдә саклан!

Сугышалар.

Паж

Сакчыларны дәшим! Сугышалар!
(Китә.)

Ромео

Кем икән бу? Йөзен карыйм әле.
Тукта, тукта, бу бит Меркуционың
Кан кардәше — мескен граф Парис!
Хезмәтчемнең юлда килгән чакта
Сөйләгәнен юньләп тыңламадым...
Ул бу хакта нидер әйтте бугай?
Ялгышмасам, Парис Джульеттага
Өйләнергә йөри диде кебек.
Әллә миңа шулай тоелдымы?
Әллә төштә күрдем? Бир кулыңны.
Язмыш безне кара китабына
Икебезне бергә теркәп куйган.
Син мәһабәт кабер кочагына
Ятачаксың. Юк, юк, кабер түгел —
Купшы сарай! Аның уртасында
Джульетта, бәгърем, балкып ята,
Таш төрбәне сихри нурга күмеп.
Ят син шунда, мәет, каберчең дә
Мәет инде күптән синең кебек.

Парисны төрбәгә кертеп сала.

Үләренә бераз вакыт кала.
Көлә башлый кеше, бу халәтне
Үлем алдындагы балкыш диләр.
Минем балкыш әллә шушы микән?
Әй, сөеклем, газиз хатыным минем,
Синең балдан татлы сулышыңны
Комсыз әҗәл эчкән, тик шулай да
Матурлыгың калган шул көенчә —
Үлем сине барыбер җиңалмаган.
Әле иреннәрең, яңакларың
Янып тора һаман, алсу төстә.
Һәм үлемнең төссез байрагы да
Җилфердәми, бәгърем, синең өстә.
Кәфене канлы, Тибальт, син дә монда?
Озакламый шатландырам, туган,
Сине үтергән куллар менә хәзер
Үтерүчеңне кара гүргә тыгар.
Кичер мине, Тибальт! Джульетта,

Нишләп һаман шулай гүзәлсең син?
Әллә инде үлем фәрештәсе
Тере көе сине караңгыда
Сөяркәсе итеп тотамы соң?
Әгәр шулай булса, мин бу баздан
Мәңге чыкмыйм. Синең хезмәтчеләр —
Кортлар белән бергә монда калам.
Мәңге тынлык монда, мәңгелек ял.
Бәхетсезлек теләп чекерәйгән
Йолдызларның җәбер-золымыннан
Коткарачак мине монда калу.
Әй, күзләрем, соң мәртәбә карап
Сокланыгыз аңа, ә сез, куллар,
Кочаклагыз аны соңгы тапкыр!
Сез, иреннәр — хәят капкалары,
Бик озаклап үбеп, үлем белән
Минем арадагы бу мәңгелек
Килешүне тизрәк беркетегез.
Кил тизрәк, кил син, кырыс юлдаш!
Теткәләнеп беткән корабымны
Бәреп ват син әйдә таш кыяга!
Ник сузасың, йә, кил, кил, койрыкчы,
Күчер тизрәк мине башка ярга.
Мәхәббәтем, синең хакка эчәм.
(Агу эчә.)
Ah, аптекчы! Сүзең дөрес булган,
Агуың көчле. Менә үбеп үләм.
(Үлә.)

Каберлекнең икенче ягыннан фонарь, лом, көрәк тоткан Лоренцо керә.

Лоренцо

Ярдәмчем бул, изге Франциск!
Юкса һаман кабер ташларына
Абынам да егылам. Кем бар анда?

Балтазар

Борчылмагыз, зинһар, изге ата,
Үз кеше мин, сезне яхшы беләм.

Лоренцо

Ходай сиңа бәхет, тәүфыйк бирсен!
Әйтче, дустым, кем факелы анда
Кабер кортларына, мәетләргә
Файдасызга үзенең нурын сибә?
Ялгышмасам, ул бит Капулетти
Төрбәсендә яна?

Балтазар

Әйе, шунда.
Изге ата, анда минем хуҗам.
Ул дустыгыз сезнең.

Лоренцо

Ә кем соң ул?

Балтазар
Ромео.

Лоренцо

Алай, ул бирегә
Кайчан килде?

Балтазар

Аның килүенә
Ярты сәгать булыр.

Лоренцо

Әйдә алайса
Төрбә эченә керик.

Балтазар

Юк, керә алмыйм.
Мин хуҗама монда булуымны
Белдермәскә тиеш. Чөнки бит ул:
«Кабат килеп минем нишләгәнне
Карап торсаң, шундук үтерәм», — диде.

Лоренцо

Йә, ярый, кал. Үзем генә керәм.
Күңелем сизә: нидер булыр кебек,
Бәла-каза чыгып куймагае.

Төрбә ишеге янына килә.

Ромео!
Раббым Аллам! Бу кем каны тагын?
Таш баскычны тәмам күл ясаган.
Йә, күр инде, канлы кылычларын
Бусагада ташлап калдырганнар.

Төрбә эченә керә.

Ромео!
Төсе качкан. Тукта, монда тагын
Кемдер бар бит? Әллә Парис инде?
Әйе, Парис! Кан эчендә ята?
Чишелмәслек нинди табышмак бу?
Кыз уяна бугай.

Джульетта уяна.

Джульетта

Изге ата!
Ирем кайда? Курыкма. Мин аңымда.
Мин үземнең кабер кочагында
Уянырга тиеш икәнемне
Онытмадым, әйе, мин нәкъ шунда.
Ромео кайда?

Сәхнә артында шау-шу.

Лоренцо

Ишетәсеңме?
Шау-шу купты. Тизрәк качыйк моннан —
Каһәр суккан үлем сараеннан.
Илаһи көч безнең ниятләрне
Пыран-заран кылды, китик, кызым.
Кочагыңда үлгән ирең ята.
Янәшәңдә Парис. Ашык. Әйдә.
Хәзер сине монастырьга илтеп
Урнаштырам, киттек, сузма инде!
Сорашма да, юкса соң булачак.
Аһ, сакчылар килә, харап булдык!
Джульетта, кузгал, тиз бул, балам!

Джульетта

Изге ата, син бар, ә мин калам.

Лоренцо чыгып китә.

Ул кулына нәрсә йомарлаган?
Шешә бит бу? Димәк, агуланган.
Аһ, комагай, тамчысына кадәр
Эчкән бит ул. Миңа калдырмаган!
Ул чагында иреннәрен үбәм.
Әгәр анда агу калган булса,
Ул үтерер мине.
(Ромеоны үбә.)
Иреннәрең
Шундый җылы синең!

Беренче сакчы
(сәхнә артында)

Ник туктадың?
Кайда ул җир? Тизрәк күрсәт, малай!

Джульетта

Шау-шу купты. Ашыгырга кирәк.
Бәхетемә каршы, менә хәнҗәр.
(Ромеоның хәнҗәрен ала.)
Аһ, керәләр. Ярый, кыныңда ят.
(Хәнҗәр белән күкрәгенә чәнчә.)
Кының шушы синең, ә мин үләм.
(Ромео өстенә ава һәм үлә.)

Парисның Пажы белән сакчылар керәләр.

Паж

Нәкъ шушында — факел янган төштә
Сугыштылар.

Беренче сакчы

Җирдә кан таплары!
Әй, барыгыз! Каберлекне тентеп,
Кем очраса, шуны кулга алыгыз.

Берничә сакчы китәләр.

Коточкыч хәл! Бу бит граф мәете...
Джульетта ята кан эчендә,
Тик нигәдер һаман тәне җылы,
Ике көн бит инде үлгәненә.
Князьгә тизрәк кеше җибәрегез!
Халык җыелсын! Хәзер үк чаң сугыгыз!
Уянсыннар Монтекки һәм Капулетти!

Тагын берничә сакчы чыгып китә.

Зур фажига булган җирне таптык,
Сәбәпләрен әмма фаҗиганең
Тикшермичә белү мөмкин түгел.

Берничә сакчы Балтазарны алып керәләр.

Икенче сакчы

Без биредә менә Ромеоның
Хезмәтчесен таптык.

Беренче сакчы

Бик яхшы.
Сак астында торсын ул хәзергә.

Тагын берничә сакчы Лоренцоны алып керәләр.

Өченче сакчы

Менә монах — елый, бәргәләнә.
Каберлекнең аргы ягы буйлап
Килгән чакта эләктердек үзен,
Кәйлә белән лом да аныкы.

Беренче сакчы

Бу зур дәлил. Кулга алыгыз үзен!

Хадимнәре белән Князь һәм сакчылар керәләр.

Князь

Тагын нинди көтелмәгән бәла
Татлы йокыбыздан безне бүлә?

Капулетти

Ник шаулыйлар? Ниткән ыгы-зыгы?

Капулетти ханым

Урамнарда халык чыр-чу килә:
«Ромео» диләр, «Парис», «Джульетта»!
Һәммәсе дә янгын чыккан кебек
Йөгерәләр безнең каберлеккә.

Князь

Нәрсә булган монда?

Беренче сакчы

Галиҗәнап,
Биредә менә граф Парис ята,
Үтергәннәр аны. Ә биредә
Ромео ята, ул да үлгән.
Джульеттаның исә, мәрхүмәнең,
Тәне җылы, димәк, терелгән дә
Күптән түгел кабат үтерелгән.

Князь

Бу вәхшәтнең сәбәпчесен миңа
Китерегез табып, тиз булыгыз!

Беренче сакчы

Менә монах, ә бу Ромеоның
Хезмәтчесе. Кәйлә белән лом да
Аларныкы, галиҗәнап, мәрхүмнәрнең
Каберләрен каерып ачар өчен.

Капулетти

Ай Ходаем, бу ни, безнең кызыбыз
Кан эчендә ята, күрче, хатын.
Ялгышкан бит хәнҗәр! Үз кынысы
Монтеккиның билбавында көе
Күкрәгендә ята кызыбызның.

Капулетти ханым

Ah, бу үлем, матәм көе булып
Салкын гүргә дәшә мин карчыкны.

Монтекки һәм башкалар керәләр.

Князь

Әй, Монтекки, иртә торгансың син,
Әмма улың синнән иртәләгән:
Таң яктырмас борын сүнгән әнә.

Монтекки

Сөргендәге улым кайгысыннан
Бүген төнлә минем хатыным үлде.
Нинди хәсрәт тагын көтә мине?

Князь

Әнә кара.

Монтекки

Әй, әдәпсез бала!
Атаңнан да алда гүргә кердең.

Князь

Бу хәлләрнең серенә төшенгәнче,
Сызлау, сыкранудан тыелыгыз.
Сәбәпләрен тәмам ачыклагач,

Юлбашчыгыз булып мин үзем дә
Сезнең белән хәсрәт чигәчәкмен.
Ул гынамы? Хәтта үлемнән дә
Тыеп калмам сезне. Ә хәзергә
Кайгыларның барын сабырлыкка
Кол итегез, дәшми-тынмый гына.
Шикле адәмнәр кая, китерегез!

Лоренцо

Гаепсездән мин гаепле сыман.
Бар дәлилләр миңа каршы сөйли.
Сезнең алда менә икейөзле
Кеше кебек басып торам хәзер:
Мин үземә гаеп ташлаучы да
Һәм үземне үзем яклаучы да.

Князь

Белгәнеңне сөйлә әйдә, сузма.

Лоренцо

Сүзем кыска булыр. Озын-озак
Сөйләр өчен минем хәлем җитмәс.
Биредә яткан мәрхүм Ромео —
Джульеттаның ире, ә мәрхүмә
Ромеога хәләл хатын иде.
Мин аларны үзем яшерен генә
Никахлаган идем. Нәкъ шул көнне
Тибальт үтерелде. Аның үлеме
Яңа никахланган Ромеоны,
Кәләшеннән аерып, илдән сөрде.
Тибальт өчен түгел, ул вакытта
Ире өчен шулай яшь түкте ул.
Юатырлык чара тапмаганга,
Күз яшьләре тиздән кибәр диеп,
Ирексезләп, мәҗбүр итә-итә,
Сез Париска аны ярәштегез.
Ике иргә хатын булудан ул
Коты алынып йөгереп миңа килде.
Ярдәм сорый, әгәр булышмасам,
Үз-үзенә кул салачак иде.
Белгәнемне эшкә җигеп шунда,
Йокы даруы бирдем мин аңарга.
Нәтиҗәсе мин көткәнчә булган —
Үлгән кебек, тирән йокыга чумган.
Үзем исә шундук Ромеога
Бәйнә-бәйнә язып хат җибәрдем.
Бүген төнлә килеп Джульеттаны
Дару тәэсиреннән айнуга ук,
Үзе белән бергә Мантуяга
Алып китәргә ул тиеш иде.
Кызганычка каршы, минем илчем —

Джованнины юлда тоткарлыйлар.
Веронадан чыгып китә алмагач,
Кичә хатны кире үземә бирде.
Шуннан инде мескен мәхбүсәне
Коткарырга берьялгызым киттем.
Ромеога хәбәр җибәргәнче,
Үз хөжрәмдә яшереп тотмакчы идем.
Уянырга ике-өч минут кала
Кабер төрбәсенә килеп керсәм,
Граф Парис белән Ромеоның
Мәетләре ята минем алда.
Джульетта торды. Ул торуга,
Үзем белән алып китәр өчен,
Тәкъдиренә буйсынырга кушып,
Бар көчемне куеп үгетләдем.
Әмма шулчак тышта шау-шу купты.
Шуннан куркып, кабер төрбәсеннән
Чыгып китәргә мин мәҗбүр булдым.
Ә ул калды, димәк, мин китүгә,
Үз гомерен, мескен, үзе өзгән.
Бар белгәнем шушы, яшерен никах
Даяга да мәгълүм, ул да раслар.
Бу эшләрдә әгәр азмы-күпме
Мин гаепле икән, ул чагында
Гомеремнең соңгы сәгатен дә
Кыскартыгыз хөкем файдасына.

Князь

Әлегә кадәр сине изгеләргә
Санап йөрдек. Тукта, ә Ромеоның
Хезмәтчесе кайда? Ул ни әйтер?

Балтазар

Джульеттаның үлгән хәбәрен мин
Ромеога илтеп җиткерүгә,
Ат мендек тә тизрәк Мантуядан
Бирегә чаптык — кабер төрбәсенә.
Килеп җиткәч, әтисенә диеп
Хат тоттырды миңа. Менә ул хат.
Ә аннары, үтерү белән янап,
Каберлектә аның үзен генә
Калдырырга кушты.

Князь

Китер хатны!
Эчтәлеге нидән гыйбарәт икән?
Карап карыйк. Ә графның пажы —
Сакчыларны дәшкән малай кайда?
Йә, әйт әле, хуҗаң синең монда
Нәрсә эшләде?

Паж

Хатыны табутына
Чәчәк куяр өчен килгән иде.
Миңа исә бераз читкә китеп
Көтеп торырга дип әмер бирде.
Нәкъ шул вакыт кабер төрбәсенә,
Факел тотып, кемдер килеп керде.
Хуҗам кинәт кылычын чыгаруга,
Мин йөгердем кешеләр чакырырга.

Князь

Хат раслый картның сөйләгәнен.
Ромео хәлне бәйнә-бәйнә
Әйтеп биргән хатта. Хатыныңның
Үлгәнлеген белгәч, ул шунда ук
Джульетта белән бер төрбәдә
Үләр өчен фәкыйрь Аптекчыдан
Агу алып тизрәк монда чапкан.
Әй, кайда сез, мәгърур кан дошманнар —
Капулетти белән Монтекки?
Ходай сезне кинә тоткан өчен
Җәзалады бүген, аң булыгыз!
Гыйбрәт өчен әнә бәхетегезне
Мәхәббәте белән җимереп атты.
Вакытында сезне бу ызгыштан
Туктатмавым өчен мин берьюлы
Ике кардәшемнән мәхрүм калдым.
Тиешлесен, әйе, һәркем алды.

Капулетти

Әй, Монтекки туган, бир кулыңны.
Шул мәһәрең булыр кызым өчен.

Монтекки

Алай гына түгел, күбрәк бирәм.
Мин алтыннан һәйкәл койдырам аңа.
Һәм Верона исән-имин чакта
Һәйкәлләрнең иң гүзәле булып
Джульеттаның тугры мәхәббәтен
Хәтерләтеп басып торачак ул.

Капулетти

Джульетта белән янәшә үк
Ромеоның алтын сыны торыр.
Бу хөрмәтне үзем күрсәтермен.
Әй, балалар! Безнең дошманлыкның
Кәсәфәте сезнең башка төште.

Князь

Караңгылык кочагында килештегез.
Хәсрәтеннән хәтта кояш яшерә йөзен.
Йә, әйдәгез бергә-бергә хәл итик без

Кем гаепле, кемне акларга икәнлеген.
Һәр көн шулай яңа кайгы туа җирдә,
Ике гашыйк бер-беренә сыена да...
Тик Ромео һәм Джульетта кыйссасыннан
Аянычлы кыйсса булмас бу дөньяда.

Китәләр.

Тискәрегә –

авызлык

Комедия

Биш пәрдәдә

Зөлфәт

Тәрҗемәсе
КАТНАШАЛАР:

Баптиста — Падуядагы бай морза.
Винченцио — Пизадагы карт морза.
Люченцио — Винченционың улы; Бьянкага гашыйк.
Петруччо — Верона морзасы, Катарина кияве.
Гремио
Гортензио
Транио
Бьонделло
Грумио
Кертис
Укытучы.
Катарина
Бьянка
Тол хатын.

Тегүче, галантерейчы, Баптиста һәм Петруччо хезмәтчеләре.

Вакыйгалар Падуяда һәм Петруччоның шәһәр читендәге йортында бара.

Беренче пәрдә

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Мәйдан.
Люченцио белән Транио керә.

Люченцио

Падуяны — гыйлем оясын да

Күрү бәхетенә ирештем бит!
Италиянең Ломбардиясенә —
Сихри бакчасына аяк бастым.
Табынсак та изге фәненә без,
Мәҗбүриме суфи, бүкән булу?
Үтик Аристотель тыйганнарны,
Овидийдан да йөз чөермик без.
Шәпләп өйрәнегез логиканы,
Әңгәмәдә риторика серен
Онытмагыз... Шигърият һәм көй
Кинәндерсен сезне... һәм дә тагын
Математика һәм метафизика
Дигәннәрен бары корсакка
Сыйган кадәр генә каплагыз.
Кабып йоткалагыз — боларын
Сыйган чаклы гына корсакка.
Тәме юкның яме юк, диләр бит.
Фәнмени ул — җанга хуш килмәсә!
Рәхмәт, Транио дус! Киңәшең шәп,
Тик монда Бьонделло булса әгәр,
Дус-ишләрне кабул итәрлек бер
Йорт юнәткән булыр идек хәзер.
Тукта әле! Кем ул монда килә?

Транио

Безне каршы алалардыр да зурлап.

Баптиста, Катарина, Бьянка, Гремио һәм Гортензио керәләр. Люченцио белән Транио бер читкәрәк китәләр.

Баптиста

Юкка интектермәгез, синьорлар.
Әйткән сүзем — каккан казык минем.
Өлкән кызыма ир табылмыйча,
Беркемгә дә бирмим кече кызны.
Әгәр дәхи инде икегезнең
Берегез минем Катаринаны
Җан-җанашы итсә... Ул чагында
Каршы килмәс идем һич кенә дә,
Килешер идек туганнарча.

Гремио
(бер читкә)

Җенеңне дә тыңламас ул явыз —
Гортензио, сез риза түгелме
Хатын итеп аны алырга, ә?

Катарина

Нигә, әткәй, мине көлке хәлгә
Куясыз бер пар ахмак каршында?

Гортензио

Пар, дидеме? Сезгә пар булырга
Ашыкмыйбыз һич тә, холкыгызны

Аз булса да үзгәртмичә торып...

Катарина

Кемгә кемгә, сезгә менә, синьор,
Һич тә куркасы юк, хатын-кызны
Болай каратуы мөмкин түгел.
Таймасагыз минем тирәдән сез,
Бу урындык белән башыгызны
Тарап алырга да күп сорамам,
Буйыйм мәллә нурлы йөзегезне
Бер кәмитче чырае иттереп?

Гортензио

Мондый җеннән, Ходай, үзең сакла!

Гремио

Һәм мине дә коткар, Тәңрем!

Транио

Синьор!
Күрегезче! Җенләндеме әллә?
Гел шулай җен кебекме ул әллә?

Люченцио

Кыяфәте генә шундый моның.
Ә тегесе асыл фәрештә бит.
Чынлыкта исә, күреп торам:
Сабыр, тыйнак, юаш кызыкай бу.
Су кап, Транио!

Транио

Каптым, синьор,
Тик үзегез берүк аң булыгыз.

Баптиста

Кылган карарымны раслау өчен,
Бьянка, сиңа мин китәргә кушам.
Һәм борчылма, кызым, газиз әткәң
Яратудан сине һич туктамас.

Катарина

Әткәсенең кызы! Күзкәйләре
Елар өчен көйләп куелган шул.

Бьянка

Хәсрәтемә куандыңмы, апам? —
Әткәй, күнәм әйткән сүзегезгә.
Китап уку һәм музыка тыңлау
Юатырлар мине ялгызлыкта —
Алар алмаштырыр дусларымны.

Люченцио

Тыйнаклык алиһәсенең
Сүзләре бу, синьор Транио!

Гортензио

Шулай кискен булырсызмы, синьор?
Янып сөюебез белән, Бьянкага
Нинди авыр хәсрәт ясадык без —
Бик кызганыч.

Гремио

Синьор Баптиста, сез
Бу җен кызы аркасында бары
Йозакка биклисезме Бьянканы?
Синьор Баптиста? Һәм сеңлесе
Апасының әче теле өчен
Нигә интегергә тиеш соң ул?

Баптиста

Синьорлар, сүз бетте. Бүтән сүз юк. —
Бьянка, бар.

Бьянка китә.

Аның шигърияткә һәм
Музыкага һәвәслеген беләм,
Укытучы ялларга дип торам —
Яшь күңелгә хак юл күрсәтсеннәр.
Әгәр сезгә, могтәбәр синьорлар,
Очрый калса шундый голәмәләр —
Минем йортка җибәрсәгез иде.
Мин алардан акча кызганмамын.
Сау булыгыз. — Син кал, Катарина,
Бер-ике сүз бар минем Бьянкага.
(Китә.)

Катарина

Миңа моннан китү ярамыймы?
Өйрәтәләр! Нәрсә яраганын,
Ярамаганын мин белмим, имеш.
(Китә.)

Гремио. Китә генә күр, шайтанның үз янына олаксаң да ярый. Мондый күркәм кызны беркем дә тоткарламас. Олы кызы белән әткәсенең борчаклары пешми бугай, Гортензио. Безгә бәлеш өсте кызарып чыкканга кадәр юкка авыз суы корытырга туры килмәгәе. Хушыгыз. Юньле укытучы очрата калсам, үземнең мәхәббәтем хакына мин аны синьор Баптистага тәкъдим итәчәкмен. Бьянканың күңеленә хуш килердәй нәрсәләргә өйрәтсен ул аны.

Гортензио. Мин дә нәкъ шулай итәрмен, синьор Гремио. Шулай да үзегезгә бер сүз әйтергә рөхсәт итегез. Чәкәләшүебез аркасында ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкин булмады. Шулай да белеп торыгыз: хәзер мин әйтәсе сүзләр икебезгә дә кагыла. Гүзәл Бьянка янына якын килергә һәм тагын бәхетле көндәшләр булырга мөмкинлекләребез бар әле безнең. Моның өчен шактый көч түгәргә һәм бер эшне ипле генә башкарып чыгарга кирәк.

Гремио. Ниндирәк эш икәнен ачыграк әйтмәссезме?

Гортензио. Мәсьәлә бик гади, әфәндем: аның апасына ир юнәтергә тиешбез.

Гремио. Ир дисезме? Ир түгел, шайтан кирәк аңа!

Гортензио. Ә мин әйтәм — ир кирәк!
Гремио. Ә мин әйтәм — шайтан кирәк! Сез нәрсә, Гортензио, әтисенең байлыгына кызыгып кына ул тәмугтан чыккан җен кызына кем дә булса өйләнергә риза булыр дип уйлыйсызмы әллә?
Гортензио. Булды, Гремио, җитте! Дөрес, аның чинауларына безнең чыдамлык җитмәс. Лә-кин аңа шул килеш тә өйләнергә әзер егетләр табылачак. Бирнәсе генә мулдан булсын!
Гремио. Ул бирнә өчен аңа өйләнгәнче, хурлык баганасы төбендә камчы белән тукмалуың хәерлерәк.
Гортензио. Әйе, алма өеме белән черегән икән, сайланып торуның мәгънәсе юк. Шулай да, бу әкәмәт хәл аркасында без дуслашып алганбыз икән, Баптистаның олы кызын кияүгә би-реп, кечесен азат иткәнгә кадәр безгә дус булып калырга кирәк булыр. Шуннан соң яңадан көндәшкә әверелсәк тә ярар. И, гүзәлләр гүзәле Бьянка! Кем бәхетенә генә насыйп булыр икән ул!
Гремио. Сүз дә юк, килешәм. Катарина артыннан йөрергә, аңа яучы җибәрергә, өйләнергә, бер түшәктә йокларга һәм әткәсен шундый җен кызыннан коткарырга риза булган кешегә мин Падуядагы иң шәп чабышкымны бүләк итәр идем. Киттек!

Гремио һәм Гортензио китәләр.

Транио

Ышанасым килми, синьор, шулай
Тиз гашыйк булып куюыгызга!

Люченцио

Мин үзем дә һич ышанмас идем,
Әле генә, тик тамаша кылып
Карап торган мәлдә, Транио,
Сөю уты капты йөрәгемә.
Күңелдәген яшермичә әйтәм:
Янам, әрним, һәм мин үләчәкмен,
Әгәр дә шул тыйнак гүзәлкәйне
Мин үземә яр итә алмасам.
Киңәш бир, Транио, мин беләм:
Кулыңнан бит килә барысы да.
Коткар. Транио! Белеп торам,
Әзер бит син миңа ярдәмгә!

Транио

Сүгәр идем, вакыты ул түгел,
Коткармый бит сүгү мәхәббәттән,
Гашыйк булсаң, бер генә юл кала:
Ягъни, сиңа әгәр әсирлектән
Түләп котылырга кирәк икән —
Азрак түләп котылырга тырыш.

Люченцио

Рәхмәт, дустым. Сөйлә. Син хаклысың.
Юат мине, акыл иясе син.

Транио

Кызны күргәч дәрт кабынды сездә,
Һәм шул томалады зиһенегезне —

Төп хикмәтне белми калдыгыз сез.

Люченцио

Ah, күрдем мин аның гүзәллеген
Крит ярларында Юпитер үзе
Тезләнеп кулкаен үпкән чакта,
Шундый матур булып балкыгандыр
Бары Агенорның кызы гына!

Транио

Шул гынамы? Димәк, күрмәгәнсез
Апасының ничек дулаганын!

Люченцио

Иреннәре мисле мәрҗән иде,
Хуш ис иде һәрбер сулышында,
Гүзәл, изге аның һәрбер төше.

Транио

Юк, һушына китермичә булмас! —
Айныгызчы, синьор! Гашыйк булгач
Һәм ашкынгач сылу кочагына,
Азрак башны эшләтү дә кирәк.
Хикмәт шунда: аның анасы бит
Җен-пәри сыман бер тискәре.
Олы кызын әгәр әткәсе бер
Кияү табып аңа чәпәмәсә,
Сазаячак сезнең сөйгәнегез.
Шуңа күрә, кияү егетләре
Борчылмасын диеп, әткәләре
Йозак астына аны утыртты.

Люченцио

Ah, дускаем! Нинди шәфкатьсезлек!
Ә син ишеттеңме: кызына ул
Укытучылар ялламак була?

Транио

Ишетмичә! Хәйләсен дә таптым.

Люченцио

Мин дә таптым.

Транио

Ярар, яхшы, хуҗам,
Планнарыбыз бер үк булыр, шөкер.

Люченцио

Үзеңнекен башта әйтеп кара.

Транио

Укытучы булып, Баптистаның

Өенә сез үтеп кермәкчесез.
Һәм шуннан соң аның кызына
Фәннәр укытырга ниятлисез.
Сезнең план шундый!

Люченцио

Дөрес! Ул планны
Үтәрбез дә!

Транио

Акылсызлык! Ә кем
Винченцио улы булыр монда?
Кем укыр да, кем хуҗалык итәр?
Кем типтерер җан дусларын җыеп?

Люченцио

Ташла әле! Барысын чамаладым:
Беркем белми безне Падуяда,
Кем хуҗа да, кем хезмәтче — безне
Йөзгә карап һичкем таный алмый.
Бәс, син бүгеннән алып — әфәнде!
Йортны кара, һәрбер хезмәтчегә
Эшләрне куш, ә мин бүгеннән үк
Неаполь сәфәрчесе йә булмаса
Пиза шәһәреннән гидай-ярлы.
Карар кылдык! Чишен, Транио,
Киенеп ал минем киемнәрне;
Бьонделло килсә — кисәтермен,
Ул беркемгә безнең серне чишмәс,
Тугры хезмәт итәчәк ул сиңа.

Транио

Әйе, кисәтүдән зыян булмас.

Киемнәрен алмашып киенәләр.

Нишлисең бит, синьор, әгәр сезгә
Ошый икән болай — буйсынамын.
Киткән чакта әткәгез бит әйтте:
«Үтәгез, — дип, — улым ни кушса да».
Хәер, ул башканы күздә тотты.
Шулай да мин бүген, рәхәтләнеп,
Люченционы яратканга күрә
Әвереләмен Люченциога.

Люченцио

Люченцио яратканга, диген!
Ah, килбәте белән күзләремнең
Явын алган шушы гүзәлкәйнең
Мәхәббәтен яулау өчен бары
Колга әверелдер, Хак Тәгаләм! —
Әһә, хәйлә капчыгы да килде!

Бьонделло керә.

Кая гына китеп олактың син?
Бьонделло. Мин олактыммы? Менә сиңа мә! Сез үзегез кайда югалдыгыз? Хуҗам, дустым Транио сезнең киемнәрегезне урладымы? Әллә сез аныкыларны урладыгызмы? Әллә бергә-ләшеп бер-берегезне таладыгызмы? Ходай хакына әйтә күрегез, ни булды?

Люченцио

Кил, эшлексез, монда. Шаяртырга
Вакыты түгел. Колагыңа киртлә:
Мине йолу өчен Транио
Бүген минем киемнәрне киде,
Аныкын мин кидем.
Хикмәт шунда:
Имеш, ярга төшү белән үк мин
Тукмашырга тотынганмын һәм дә
Кеше үтергәнмен. Менә хәзер
Танымасыннар дип качып йөрим.
Син — Транионың хезмәтчесе хәзер.
Мине карагандай кара аны.
Ә мин хәзер, исән калу өчен,
Качып кына яшим. Аңладыңмы?

Бьонделло

Юк, ант әгәр, берни аңламадым.

Люченцио

Транио исемен оныт бүгеннән.
Транио юк! Люченцио ул хәзер.

Бьонделло

Бәхете бар. Андый бәхет миңа
Тәтесен иде дә бит!

Транио

Аңла син,
Үзем өчен тырышуым түгел.
Баптистаның кече кызын хуҗам
Үзенеке итсен өчен генә
Тырышам мин. Тыңла киңәшемне:
Телеңне йот, минем хакка түгел,
Синьор хакына, икәү генә чакта
Синең өчен һәрчак мин — Транио,
Бүтән чакта — хуҗаң Люченцио.

Люченцио

Киттек, Транио. Хәзер инде
Тик бер эшне башкарасы калды:
Туры килер сиңа мәгъшук булу.
Нигә дисәң, җавап бирә алам:
Җитди сәбәпләр бар моның өчен.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Гортензио йорты каршында.
Петруччо белән Грумио керәләр.

Петруччо

Падуядагы дусларым белән
Бер күрешер өчен генә бары
Веронадан кузгаласы иттем.
Бигрәк Гортензионы сагындым.
Аның йорты бит бу! Әй, Грумио,
Ныклап торып бер дөмбәслә әле.
Грумио. Дөмбәсләргәме, синьор? Кемне дөмбәсләргә? Сез ки галиҗәнапларны берәрсе рәнҗетте мәллә?
Петруччо. Әйткәннәрме сиңа, хәйлә капчыгы, минем башым исән чакта, ныклап кундыр бернe!
Грумио. Ныграк кундырыргамы, синьор? Сез нәрсә, синьор, сезгә ныклап торып кундырырга кем мин?

Петруччо

Капкасын шакы, эт ашагыры,
Юкса хәзер муеныңны борам.

Грумио
(бер читкә)

Бәйләнде бит!
(Ишеттереп.)
Әгәр башлап суксам,
Көн күрсәтмәссез гомер буена.

Петруччо

Капка шакыйсыңмы, юкмы? Менә хәзер
Иманыңны кыям бит, алдар таз!
Ни сайрарсың икән менә хәзер.

Грумионың колакларын бора.

Грумио. Коткарыгыз! Коткарыгыз! Хуҗам акылыннан ычкынды!
Петруччо. Кушканнар икән, шакы, хәрам корсак!

Гортензио керә.

Гортензио. Нәрсә булды монда? Бәй, Грумио картлач! Дускай Петруччо! Веронада ниләр җимертәсез?

Петруччо

Араларга килдегезме, дускай?
Бик вакытлы.

Гортензио

Йортыма рәхим итегез, синьор Петруччо.
Тор, Грумио! Хәзер аңлашырбыз.
Грумио. Юк, синьор! Латинчалап кына да әйтеп бетерә торган түгел бу. Хезмәтчелектән баш тарту өчен бу да законлы сәбәп түгел мәллә? Үзегез уйлап карагыз, синьор, ул миңа үзен

дөмбәсләргә кушты, шәбрәк итеп кундыр, диде. Хезмәтченең үз әфәндесен шулай мәсхәрә кылганын кайда күргәнегез бар? Яше утыз икедән дә тулып ашты бит инде аның югыйсә!
Әгәр суккан булсаммы мин башлап —
Кемнең башы чатнар иде микән?

Петруччо

Ах, тел бәйле! Гортензио дускай,
Капка шакырга мин куштым аңа —
Тукмасаң да, сүз тыңламый бит ул!
Грумио. Капка шакырга? Башым исән чакта ныграк кундыр, дөмбәслә, дип капка шакыйлармыни? Сезнең башыгыз капка түгелдер бит?
Петруччо

Ычкын, юньсез, яки телеңне тый!

Гортензио

Ярар, Грумиога һич сүзем юк.
Турылыклы, әйбәт ялчы бит ул.
Сүзләр генә ялгыш буталгандыр.
Йә, дус, нинди җилләр ташлады соң?

Петруччо

Нинди җил кусын соң яшь йөрәкне? —
Өйдән читтә бәхет эзләү җиле!
Кыскасы, шул, дустым Гортензио,
Минем эшләр шушы тирәдәрәк:
Әткәм Антонио үлеп китте.
Янчыгымда — акча, өйдә — байлык,
Ат казаныйм һәм дә бай кәләшкә
Өйләним дип сәфәр чыктым менә.

Гортензио

Нәрсә, Петруччо, әгәр дә мин
Бик тиз генә яраштерсәм сине
Усал һәм тискәре бер кәләшкә?
Моның өчен рәхмәт әйтмәссең син;
Тик белеп тор: кәләш — гаҗәеп бай,
Хәер, син — дус кеше, ышандырып
Маташуның һич тә кирәге юк.

Петруччо

Безнең сыман ике ахиригә
Артык сүзнең һичбер кирәге юк.
Белсәң әгәр миңа пар булырдай
Бай кәләшне булса да ул хәтта!
Флорентий хатыныннан котсызрак,
Картрак Сивилладан һәм хәтта ки,
Сократ хатыны Кантипиадан да
Тискәрерәк — барыбер! Бай булса,
Шунсы җиткән миңа — тели икән,
Котырынсын диңгез давылыдай —
Исем китми — шушы Падуяда
Өйләнмәкчемен мин һәм, һичсүзсез,
Мөлкәтле һәм бай кәләшкә генә.

Грумио. О! Күрдегезме, синьор, эчендәгесен әйтте дә салды. Акча килердәй булса, ул таш курчакка да, агач түмәренә дә, авызында сыңар теше калмаган җитмеш җиде сырхау ябышкан корчаңгы ат шикелле карчыкка да өйләнергә әзер. Акча булса, калганына төкерә генә ул.

Гортензио
(Петруччога)

Шактый тирән кердек... Болай булгач,
Уйнап башлаганны чынлап әйтим:
Бер кыз тәкъдим итә алам сиңа.
Байлыгы бар, үзе яшь һәм чибәр,
Тәрбияле, бик затлы нәселдән.
Ләкин... бар аның бер кимчелеге —
Ырлап кына тора ызгышырга,
Шаккатырлык тискәре ул, тупас!
Тәмам бөлеп эштән чыккан чакта,
Тау-тау алтын бирсәләр дә миңа,
Юк, өйләнмәс идем мин андыйга!

Петруччо

Дәшмә! Алтын көчен белмисең син!
Әйт син әткәсенең кем икәнен —
Башка берни кирәк түгел —
Күкләр булып күкрәп торса да ул,
Үземнеке итәчәкмен аны!

Гортензио

Әтисеме? Баптиста Минола,
Бик юмарт һәм итагатьле синьор;
Кызы — Катарина Миноланың
Әрем телен белмәгән кеше юк.

Петруччо

Кызын белмим, әмма әткәсен мин
Ишетә беләм... Мәрхүм әткәм белән
Таныш булган алар... Йокы алмас
Мине, күрми торып ул кызкайны, —
Илтмәсәң син әгәр анда мине,
Кичер, менә шушы минутта ук
Ташлап китәргә мин мәҗбүр сине.

Грумио. Үтенәм, синьор, теләге бар чагында бара бирсен. Әйткәннәрем исегезгә төшәр әле: әгәр дә ул сылу моны минем кадәр белсә, андыйны сүгенеп кенә игә китереп булмаганын бик тиз аңлар иде. Ул кыз аңа хет егерме кат «адәм актыгы» дип кычкырсын — моның сыңар керфеге дә селкенмәячәк... Инде дә килеп үзе сүгенергә тотынса, теленә төер чыкмыйча торып туктый торган түгел. Сезгә шуны киңәш итәм, синьор: кызыкай аңа берәр кырын сүз әйтә калса, бу җавапны шундый иттереп коеп куячак ки, кызыкаең басып торган җиреннән онталкан булып коелып төшәчәк. Якты дөньяга сукыр песи баласы кебек карый башлаячак ул чибәркәегез. Сез аны белмисез әле, синьор.

Гортензио

Тукта, әй, Петруччо! Мин дә барам.
Гүзәл Бьянканы — кече кызын —
Баптиста зинданда бикләп тота —
Җанымнан кадерлерәк ул миңа.

Яшерде ул аны миннән һәм минем күк
Мәхәббәттән янган көндәшләрдән,
Катаринаның кыланмышлары
Аркасында Бьянка бичарага
Кияү чыкмас диеп шикләнә ул.
Җенле Катаринаны аткарганчы,
Биктә тотачак ул Бьянканы.

Грумио

Җенле Катарина! Күп ишеттем
Усал сүзләрне мин гомеремдә.
Әмма кыз кешегә кушаматның
Моннан әчерәген табып булмас!

Гортензио

Петруччо, җаным, зинһар, дип әйтәм:
Тәкъдим ит син мине Баптистага
Укытучы итеп! Бүген кием
Киярмен мин... Һәм әйт Баптистага:
Җыр-музыканы шәп белә, диген.
Һәм мөмкинлек бирер шушы хәйлә
Һичбер кемне шикләндерми генә
Миңа Бьянка белән ялгыз калып
Гел аулакта гына очрашырга.
Грумио. Ай-яй, хәйләкәр! Картларны карама көленә утырту өчен яшьләрнең ничек сүз берләшүен күр әле син!

Гремио белән Люченцио керәләр. Люченцио бүтән киемдә, ул култык астына китаплар кыстырган.

Гортензио

Шыпырт, Грумио! Минем көндәш бу. —
Бер читкәрәк китик, Петруччо.

Грумио

Күрәм! Тәмам гыйшык былбылы бу.

Читкәрәк китәләр.

Гремио

Укып чыктым китап исемлеген,
Менә дигән! Ләкин тышлыкларын
Алмаштырырга мин боерырмын.
Булсын алар тик сөю хакында —
Бүтәннәрен укымагыз аңа.
Һәм аннары хезмәт хакы түләр
Синьор Баптиста үзе, һәм
Миннән дә мул әҗер тамар сезгә.
Һәм кушыгыз китап-дәфтәрләргә
Затлы хушбуй исен сеңдерергә.
Аларны кулына тотачак зат
Үзе дә бит хушбуй гөле сыман.
Ни укырга уйлыйсыз сез аңа?

Люченцио

Һәр хәрефе сезгә файда булыр —
Ышаныгыз миңа, боеручым!
Йөрәк хисегезне ул гүзәлгә
Сез үзегез сөйләгән күк булыр.
Хәтта үтемлерәк булыр сүзләр.
Укымышлылар язган бит аны!

Гремио

Укымышлылык! О, бөек нәрсә!

Грумио
(бер читкә)

Мисез тавык! О, бөек ишәк!
И, саңгырау көртлек!

Петруччо

Авызыңны яп, хөрәсән!

Гортензио

Шыпырт, Грумио!

(Алга чыга.)

Сәлам сезгә, синьор.

Гремио

Синьор Гортензио! Сезне күрү
Минем өчен гаҗәп зур куаныч!
Кая барганымны әйтергәме?
Баптистаның йортына мин барам,
Вәгъдә иткән идем мин аңарга
Гүзәл Бьянка өчен укытучы
Табармын дип. Табу бәхетенә
Ирештем мин: галим дә ул, яшь тә,
Әдәпле дә үзе, шигъриятта
Һичбер белмәгәне юктыр аның.
Мин ышаныч белән әйтә алам —
Хуш килер ул гүзәл Бьянкага.

Гортензио

Бик шәп. Менә миңа да бер синьор
Бикәбезгә музыкант табарга
Вәгъдә итте. Димәк, мин дә сездән
Һич калышмаганмын сөеклемә —
Бьянкага хезмәт күрсәтүдә.

Гремио

Юк, ул минем сөеклем! Һәм моны
Эштә раслап күрсәтермен сезгә.

Грумио
(бер читкә)

Раслар аны акча капчыгы.

Гортензио

Гыйшык турында сафсата сатып

Сүз куерта торган вакыт түгел.
Бәлки, мине тыңларсыз, синьорлар?
Һәммәгезгә мөһим яңалык бар.
Менә бу дворянин — аның белән
Очраклы гына таныштык без —
Әзер сезнең хакка яучыларга
Киребеткән шул Катаринаны,
Һәм дә бирнә хакын килешүгә
Әзер тора хәтта өйләнергә.

Гремио

Бик шәп бу! Әйткән сүз — каккан казык!
Беләме ул аның өянәген?

Петруччо

Тузынырга бик тә һәвәс, диләр.
Алай гына булса, исем китми.

Гремио

Кызык, дускай! Ә син кай яклардан?

Петруччо

Туган җирем — Верон, мәрхүм булды
Әткәм Антонио. Байлык миңа
Мирас булып калды. Бер йөз еллап
Балда-майда йөзәр ниятем бар.

Гремио

Шундый хатын белән?! Балда-майда?
Ышануы кыен! Тик шулай да
Көчегездән килә икән — миннән
Мең фатиха! Мин ярдәмгә әзер!
Әйтегезче ләкин, сез, чынлап та,
Алмакчымы шул кыргый мәчене?

Петруччо

Әйткән — бетте. Ике сөйләмим мин.

Грумио

Алмыймы соң! Ничек кенә әле!

Петруччо

Сәфәр чыкмадыммы шуның өчен?
Ишеткәнем юкмы шау-шуларны?
Ишеткәнем юкмы үкерүен
Ярсу арысланның? Йә диңгезнең
Котырганын кабан дуңгызыдай?
Яу кырында туплар гөрселдәвен,
Күк күкрәүне ишетмәгәнме мин?
Яу барганда атлар кешнәшүен,
Бырлы тавышларын белмим мәллә?
Хатын-кызның теле белән мине
Куркытырга маташалар, имеш.
Күпме гыжласа да, коймак кызган

Таба кадәр чыжлый алмас ул тел!
Моның белән бала-чагаларны
Куркытыгыз!

Грумио

Кем кем. Бу шүрләмәс!

Гремио

Карагыз әле сез, Гортензио!
Безнең бәхеткә табылды бу синьор —
Һәм үз бәхетенә.

Гортензио

Вәгъдә бирдем
Яучылыкка кирәк чыгымнарны
Күтәрербез, диеп, бергәләшеп.

Гремио

Каршы сүз юк, тик өйләнсен генә!

Грумио
(бер читкә)
Әбәт ашау мәсьәләләре дә
Шулай ышанычлы хәл ителсә!

Байларча киенгән Транио белән Бьонделло керәләр.

Транио

Ходай ярлыкасын, әфәнделәр!
Рөхсәт булса, сорар идем сездән —
Могтәбәр Баптиста Миноланың
Йорты кайсы тирәдәрәк икән?

Бьонделло

Ике сылу кыз үстергән Миноланы әйтәсезме?

Транио
Әйе, нәкъ үзе.

Гремио
Кызның үзен
Күрергә чамалыйсызмы анда?

Транио

Кызнымы яисә башкасынмы —
Сезнең ни эшегез бар соң анда?

Петруччо

Тискәрегә күз төштеме әллә?

Транио

Җенем сөйми киребеткәннәрне! —
Киттек, Бьонделло!

Люченцио
(бер читкә)
Транио,

Мең яшә!

Гортензио

Синьор, тик бер мәлгә
Туктагызчы. Аны яучыларга
Чынлап торып карар кылдыгызмы?

Транио

Шулай булса, кем рәнҗер миңа?

Гремио

Һичкем рәнҗемәс, әгәр сез моннан
Ычкынсагыз, шушы минутта ук!

Транио

Әмма, синьор, сезнең өчен урам
Иркен булган кебек, миңа да ул
Ирекле бит.

Гремио

Әмма хәзер түгел!

Транио

Ә сәбәбе нидә, аңлатыгыз!

Гремио

Сәбәбе бик гади: Бьянканы
Синьор Гремио ярәшәчәк.
Гортензио. Һәм дә синьор Гортензио үзе
Аны хәләл җефет итмәкче.

Транио

Әфәнделәр. Чү! Сез бит — дворяннар;
Сезгә бер сүз әйтү шәрәфенә
Ирешсәмче: Баптиста әфәндә —
Бик могтәбәр синьор, әткәемнең
Әшнәсе ул, менә шуңа күрә
Әгәр дә кыз тагын да сылурак
Булса да һәм кияү егетләре
Икеләтә күбрәк булсалар да,
Кияүләрнең берсе мин булырмын!
Леда кызын меңнәр якын сөйгән —
Ә Бьянкага гашыйкларның саны
Бергә артык булса булыр, әмма
Шунсы мин булырмын. Исем китми,
Миңа Парис көндәш булса да!

Гремио

Барыбызны узар бу чаптырып!

Люченцио

Борчылмагыз, бер корчаңгы атка
Әвереләчәк ул хәзер!

Петруччо
Гортензио,

Ник тел әрәм итәсең син юкка?

Гремио

Рөхсәт булса, сорыйм сездән, синьор:
Күргәнегез бармы соң ул кызны?

Транио

Юк, әфәндем. Аның ике кызы
Барлыгын мин беләм. Бер кызының
Усал телле булып даны чыкты,
Ифрат күндәм, юаш икенчесе.

Петруччо

Стоп! Тимә, беренчесе — минеке!

Гремио

Һичкем эшли алмас батырлык бу —
Калдырыгыз аны Геркулеска.

Петруччо

Синьор, сезне юату йөзеннән
Тик бер генә фикер әйтә алам:
Сез ашкынган кече сылукайны
Яшереп бикләп куйды әтисе.
Өлкән кызы ирле булгач кына,
Ирле була кече тәтисе.

Транио

Һәммәбезгә, шул исәптән миңа,
Ярдәм итәр кеше — сез икән бит!
Вата алсагыз сез калын бозны
Һәм күрсәтеп бик зур каһарманлык
Йөгәнли алсагыз өлкән кызны,
Һәм кечесе чыкса азатлыкка —
Бьянканы үзенеке итеп
Үз бәхетенә ирешкән синьор
Һич бурычлы калмас алдыгызда.

Гортензио

Шәп фикерләр әйттегез сез, синьор,
Тик шунсы бар: сез, гашыйк буларак,
Катнашырга тиеш бүләкләүгә
Синьорны игелекле эш өчен.

Транио

Һич сүзем юк! Һәм мин сорыйм сездән
Кичен кунакка килүегезне.
Сөйгән ярыгызның шәрәфенә
Без тустаган күтәрергә тиеш!
Адвокатлар сыман эш йөртик без:
Әрепләшсәк, эштә әрепләшик.

Грумио, Бьонделло

(икесе бергә)

Шәп тәкъдим бу! Йә, кузгалыйк, дуслар!

Гортензио

Белмим моннан шәбрәк тәкъдимне мин.
Әйдүк, рәхим итә күр, Петруччо!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Баптиста йортындагы бүлмә. Катарина һәм Бьянка керәләр.

Бьянка

Син мәсхәрә итмә мине, апам:
Мине кол итәм дип, үзеңне бит
Кимсетәсең. Бик тә рәнҗим сиңа.
Барлык затлы киемнәрне мин
Бирер идем сиңа... Кулларымны
Чиш кенә син — хәтта юбкамны да
Салып бирәм сиңа — ни кушсаң да,
Мин үтәргә әзер, минем өчен
Өлкәннәрне тыңлау — изге бурыч.

Катарина

Әйт хәзер үк, кыланмыйча гына,
Кайсын ошатасың кияүләрнең?

Бьянка

Ышан, апам: мин моңарчы белгән
Ир-ат арасыннан беркемне дә
Якын итә алмыйм күңелемә.

Катарина

Алдашасың, җанкай! Гортензиомы?

Бьянка

Ошый мәллә сиңа? Алай икән,
Аны сиңа насыйп итү өчен
Барысын да эшләрмен мин, апам.

Катарина

Әһә! Сиңа акча кадерлерәк? —
Гремиога чыгаргамы уең?

Бьянка

Нәрсә? Гремиодан көнлисеңме?
Шаяртасың. Хәзер аңлыйм инде:
Миннән һаман көлеп яшәдең син,

Апакаем, чишче кулларымны.

Катарина

Мин — шаярттым? Бу да шаяртумы?

Бьянкага суга. Баптиста керә.

Баптиста

Бу нәрсә бу? Нинди оятсызлык? —
Бьянка, кызым елый, мескенкәем.
Чигүеңә утыр. Һәм апаңа
Эндәшмә дә, янына да килмә.
(Катаринага.)
Оялыр идең! Җен холкыдыр синдә!
Туган сеңлеңне бит җәберлисең!
Сиңа каршы, ичмасам, бер сүз дә
Әйткәне юк бит бичаракайның.

Катарина

Дәшмичә мине җенләндерә ул!
Чыдый алмыйм андый тешләклеккә!

Бьянкага ташлана.

Баптиста

Нәрсә кыланасыз минем алда?
Йә, бар әле, Бьянка.

Бьянка китә.

Катарина

Белеп торам, мине яратмыйсыз.
Һәммәсе дә аның өчен генә.
Ул ирле дә булыр. Ә мин һаман
Сазаган кыз булып калырмынмы?
Һәм, ниһаять, сезнең аркада мин
Маймыл тирбәтимме җәһәннәмдә?
Дәшмәгез! Утырам да мин менә,
Рәхәтләнеп елыйм. Һәм елаудан
Тукталмамын үч алмыйча торып.
(Китә.)

Баптиста

Миннән бәхетсезрәк кем бар икән!
Кемнәрдер килә...

Гремио, ярлылар киеме кигән Люченцио, Петруччо, музыкант рәвешенә кергән Гортензио, лютня һәм китаплар күтәргән Транио белән Бьонделло
керәләр.

Гремио. Хәерле көн, күршем Баптиста.
Баптиста. Исән-сау гынамы, күршем Гремио. Ходай үзенең мәрхәмәтеннән ташламасын сезне, синьорлар.

Петруччо

Һәм сезне дә, синьор. Әйтегезче,
Сезме соклангыч Катаринаның
Әткәсе?

Баптиста

Катарина исемле
Кызым бар, әйе.

Гремио

Сез бик турыдан
Ярып сөйләшәсез. Ипләп кирәк.

Петруччо

Комачауламагызчы миңа, синьор!
(Баптистага.)
Мин — дворянмын. Веронадан килдем.
Катарина атлы кызыгызның
Ипле, күркәм, тыйнак, ачык йөзле,
Искитмәле сылу икәнлеген
Ишеттем дә, ишеткәннәремнең
Хаклыгына күреп ышаныйм дип,
Җөрьәт иттем сезгә килергә мин.
Танышуның башы шуннан булсын,
Бу — хезмәтчем инде минем, синьор.

Гортензио белән таныштыра.

Оста музыкант һәм математик,
Кызыгызга ошый торган фәннәр,
Һәм хезмәтчем минем ул туташка
Төшендерер бу фәннәрнең серен.
Әгәр аны кабул итмәсәгез,
Рәнҗетерсез мине... Мантуяда
Туып үскән ул. Исеме — Лючио.

Баптиста

Танышуга шатмын. Аны эшкә
Кабул итәрмен мин. Әмма ләкин
Шунсы бик кызганыч: Катарина
Сезгә һич тә пар булырлык түгел.

Петруччо

Ансыз калудан сез куркасызмы?
Әллә сөйкемсезме минем сөяк?

Баптиста

Юк, уйлаганымны гына әйттем.
Ә сез, синьор, кайдан килдегез соң?

Петруччо

Петруччо мин, Антонио улы,
Аны илдә белмәгән кеше юк.

Баптиста

Мин дә белә идем әткәгезне,
Һәм бик шатмын улын күрүемә.

Гремио

Туктагызчы беразга, Петруччо,
Хет берәр сүз без дә әйтеп карыйк.
Бик ашыгасың, шайтан алгыры!

Петруччо

Бу эшне тизрәк очлыйсым килә.

Гремио

Ник өйләндем диеп, соңыннан сез,
Валлаһи, үкенәчәксез әле!
Күршем, мондый бүләк, әлбәттә, күңелегезгә хуш килгәндер дип ышанам. Сезнең каршыгызда минем дә башкалардан ким буласым килми. Чөнки мин сезгә боларның һәммәсенә караганда күбрәк бурычлымын. Шуңа күрә Реймста озак еллар укыган яшь галимне игътибарыгызга тәкъдим итәргә җөрьәт кылам.

Люченцио белән таныштыра.

Әлеге мөгаллим музыканы һәм математиканы яхшы белгән шикелле үк, бу да грек, латин һәм башка телләрне бик яхшы белә. Исеме — Камбио. Аның хезмәтләрен хуп күрерсез дип ышанам.
Баптиста. Мең рәхмәтләр яусын сезгә, синьор Гремио. Рәхим итә күрегез, кадерле Камбио. *(Транио га.)* Шулай да сез, синьор, безнең якларда яшәгән кеше түгел бугай. Безнең якка нинди рәк максат белән сәфәр чыкканыгызны сорарга мөмкин булмасмы?

Транио

Болай батырчылык итүемне
Кичерсә генә иде берүк, синьор.
Бу шәһәргә килеп төшкәчтен үк
Яучыларга булдым кызыгызны —
Күркәм, ачык йөзле Бьянканы.
Минем исемем — Люченцио, синьор!
Аңа кадәр өлкән кызыгызга
Ир юнәтү мәслихәтлеген дә
Ишеттем мин. Тик үтенәм сездән:
Кызга кияү сайлар вакыт җиткәч,
Берүк истән чыгармасагызчы
Минем асыл заттан икәнемне,
Исәпләгез мине кияү итеп,
Мәрхәмәттән мәхрүм итмәгезче.
Кызларыгызга мин алып килдем
Гади генә уен коралын һәм
Шулай ук латин, грек китапларын.
Хуплап сезнең кабул итүегез
Шанлы, шәрәфле итәр аларны.

Баптиста

Сез Люченциомы? Кай яклардан?

Транио

Пиза шәһәреннән Винченцио
Улы Люченцио буламын мин.

Баптиста

Пизаның зур кешесе ул, ишетеп
Беләм аны. Күрешүгә шатмын.
(Гортензиога.)
Алыгыз лютняны.
(Люченциога.)
Сез алыгыз
Китапларны. Һәм укучы кызлар
Янына тиз үк рәхим итегез.
Һәй! Килегез әле!

Хезмәтче керә.

Синьорларны
Хәзер үк илт минем кызларыма.
Әйтте, диген: ипле генә итеп
Кабул итсеннәр мөгаллимнәрне.
Сезне күрүемә шатмын, әфәнделәр.
Бакчада саф һава сулап керик,
Аннан төшке ашка җитешербез.
Сезне күрү миңа җан рәхәте,
Ышаныгыз миңа, чынлап әйтәм.

Петруччо

Синьор Баптиста, вакыт тыгыз минем.
Һәр көн саен кыз ярәшеп булмас.
Әткәемне белгәч, сез минем дә
Кем икәнне чамаларга тиеш.
Бай утарлар һәм дә мул мираслар
Минем кулда калды. Һәм мин аны
Җилгә очырмадым. Җаен табып
Гел үрчетеп тордым ул байлыкны.
Ризалыгын алсам кызыгызның,
Миңа күпме бирнә бирәчәксез?

Баптиста

Үлгәч, барлык биләмәләремнең
Нәкъ яртысы — мирас. Ә туй өчен
Нәкъ егерме мең алтын акча салам.

Петруччо

Ә мин исә, әгәр ул тол калса,
Биләмәләремне һәм дә барлык
Арендаларымны тулысынча
Берүзенә мирас итәчәкмен.
Без хәзер үк килешенү төзик,
Һәм ул контракт булсын арабызда.

Баптиста

Бусы — соңнан. Иң мөһиме — аның
Йөрәгенә ачкыч табыгыз сез.

Петруччо

Шуңа гына эш терәлеп калса...

Әйтсәм әйтим инде, әти кеше! —
Ул — тискәре, ә мин — киребеткән!
Ялкын белән ялкын кушылдымы —
Утка азык булган һәрнәрсәне
Ялмамыйча туктый алмый алар.
Назлы җилләр очкынны ут итсә —
Давыл җиле сүндерә ул утны.
Мин дә шундый. Борын төбенә дә
Төк шытмаган малай-шалай түгел.
Буйсыначак ул миңа! Мин бит — ир!

Баптиста

Яучылап карагыз соң... Тик Ходай
Үзе генә ярдәм бирсен сезгә,
Андый ызгышларга чыдар өчен.

Петруччо

Куркасым юк. Аумыйлар ла таулар,
Җилләр күпме генә котырса да.

Башы җимерелгән Гортензио керә.

Баптиста

Нәрсә булды, дускай? Агаргансыз...

Гортензио

Ышаныгыз, котым ботка төште!

Баптиста

Кыздан музыкант чыгарлыкмы соң?

Гортензио

Чыкса, солдат кына чыгар аннан!
Лютня түгел, мылтык кирәк аңа.

Баптиста

Лютняга карата нәфрәт хисен
Җимерергә хәлдән килмәдеме?

Гортензио

Ул лютняны түгел, минем башны
Бер селтәнү белән үк җимерде.
Бармакларын кылга дөрес куйыйм
Дип үрелгән идем, әйттем генә:
«Аһәңнәрдә ялгышасыз!» — диеп...
«Ah! Аһәңме?!» — дип сикереп торды,
Шашкан җеннәрдән дә хәтәр булып —
Һәм башыма орды лютня белән:
«Аһәңнән ah итеп карагыз!» — ди.
Кидерде дә куйды моң тактасын
Камыт сыман итеп, йа Ходаем!
Үзе кыйный, үзе шул арада
Җитешә бит мине мыскылларга:

«Кыл колы, — ди, — инде кол кыла, — ди, —
Бүкәннәрнең иң зур бүкәне», — ди.
Мине шулай рәнҗетер өчен
Алдан өйрәткәннәр диярсең.

Петруччо

Йә, иманым камил, кәеф кыз бу! —
Артты гына аңа ашкынуым! —
Ah, бер сөйләшеп карыйсы иде!

Баптиста
(Гортензиога)

Киттек минем белән. Ачынмагыз,
Илтифатыгызны сез юнәлтегез
Кече кызкаема, ялгышмассыз:
Күндәм дә ул, ифрат рәхимле дә.
Синьор Петруччо, сез безнең белән
Бергә барасызмы? Әллә инде
Җибәримме сезнең яныгызга —
Бирегә — Катаринаның үзен?

Петруччо

Монда җибәрсәгез шәбрәк булыр,
Нәкъ шушында көтәрмен мин аны.

Баптиста, Гремио, Транио һәм Гортензио китәләр.

Килсен генә — көен күрермен мин.
Әгәр инде җене котырынса:
«Әйткән сүзең — былбыл чутылдавы!» —
Дип мактармын; инде йөзен болыт
Каплап китә икән: «Таңгы күктәй
Йөзкәйләрең ягымлы!» — диярмен.
Сөйләшмичә тешләкләнсә әгәр,
Җор теленә мактау җырлармын мин.
Ә яныннан инде куа калса,
Бик тә яраткан бер кунагын ул
Тик беразга гына булса да
Калырга дип кыстагандай итеп
Кыланырмын... Инде тора-бара
Миннән ул баш тарта кала икән —
Әйтермен мин аңа төгәл итеп
Безнең никахлашыр көнебезне.
Килә бит! Эшкә тотын, Петруччо!

Катарина керә.

Нихәл, Кет, пескәй! Иштүемчә,
Сезгә шулай эндәшәләр бугай.

Катарина

Колагыгыз тонган бугай сезнең.
Миңа Катарина диләр иде.

Петруччо

Алдашасыз. Сезгә барысы да
«Кет!» — дип кенә эндәшә бит, беләм,
«Пескәем Кет!», «Тискәре Кет!» — диләр...
Әмма Кетка җиткән кем бар җирдә?! —
Назлыдан да назлым! Бер кашык су
Беләң генә кабып йотар идем!
Тик шунысы бар, назлы песикәем,
Юанычым, җаным, җан сөйгәнем —
Синең юашлыкны, күндәмлекне,
Күркәмлекне мактап сөйләүләрне
Бик күп ишеттем мин... Андый гына
Мактау сүзе җитәмени сиңа?!
Мин җилкенеп киттем шул сүзләрдән —
Һәм җилдерттем сине яучыларга.

Катарина

Җилдерткән, ди, берәү! Җилә-җилә
Сизмәгән, ди, кире очканын да!
Карыйм-карыйм да мин, сез дә миңа
Очып китәр сыман тоеласыз.

Петруччо

Ничек инде?

Катарина

Шушы урындык күк,
Типтең исә — очты да китте!

Петруччо

Урындыкка түгел, миңа атлан.

Катарина

Йөк басамы синдәй ишәк сыртын?

Петруччо

Хатын-кыз курка мәллә басудан?

Катарина

Минме? — Сиңа килешәрәк төшәр
Бетәшкән берәр корчаңгы бия.

Петруччо

Юк, авырлык булмам сиңа мин, Кет! —
Яшь тә бит син һәм шундый җиңел дә.

Катарина

Әйе, җиңелмен мин! Шуңа күрә
Мине эләктерү түт-түт сиңа.
Авырлыгым исә дәрәҗәмә
Төгәл генә туры килеп тора.

Петруччо

Бызылдыйсың, шөпшә!

Катарина

Син — ябалак.

Петруччо

Күгәрчен шул ябалакка тәтер.

Катарина

Миңа калса, мондый ябалакны
Күгәрченкәй чукып ташлар кебек.

Петруччо

Булды, булды, җитте, шөпшәкәем.
Ул кадәр үк усал булма инде.

Катарина

Мин — шөпшә? Саклан минем уктан!

Петруччо

Өздем аттым булыр ул угыңны.

Катарина

Башта аны табып кара, ахмак.

Петруччо

Кая яшерсен соң угын шөпшә?
Койрык төбендәдер.

Катарина

Юк, телендә.

Петруччо

Әйт, кем телендә?

Катарина

Койрыкта дип
Син бит лыгырдыйсың. Димәк, ул ук
Бары синең телдә. Хуш, егеткәй.

Петруччо

Тукта, ничек болай була инде? —
Минем телем — синең койрыгыңда?
Юк! Мин дворянмын!

Катарина

Хәзер ачыкларбыз.

Петруччога суга.

Петруччо

Тагын бер сук. Мин җавапсыз калмам.

Катарина

Ул чагында мәңгелеккә хушлаш
Син үзеңнең дворянлык гербы
Белән — мине кыйнасаң син әгәр,
Дворян түгел, димәк, шулай булгач,

Дворянлык гербың да юк синең.

Петруччо

Син герблар белгечемени әле?
Тасвирламасын ал минем гербның!

Катарина

Ә нәрсә соң синең башлыгыңда? —
Әтәч кикриге түгелме соң ул?

Петруччо

Мин әтәч булсам, син тавыгым бул!

Катарина

Әтәч, имеш! Шәлперәйгән әтәч!

Петруччо

Йә, җитте, Кет! Төкселәнмә алай.

Катарина

Төкселектән һәрчак төкселәнәм.

Петруччо

Монда төкселәнер берни дә юк,
Нигә юкка авыз кыйшайтасың?

Катарина

Бар шул, бар шул төкселәнер әйбер!

Петруччо
Кайда?
Катарина

Бик күрсәтер идем дә бит —
Көзгем алмаганмын үзем белән.

Петруччо

Димәк, ул — мин булам?

Катарина

Яшь булсаң да,
Башың бераз эшли икән әле.

Петруччо

Әйе, яшьрәк шул мин. Синең өчен...

Катарина

Тәмам җыерчыкка батып беткән.

Петруччо

Мәшәкатьләр күп шул.

Катарина

Минем моңа
Һичбер исем китми!

Петруччо
Җаным, аңла,

Болай гына җибәрмим мин сине.

Катарина

Китим, ачуыгыз гына чыгар.
Җибәрегез мине.

Петруччо

Тукта, тыңла:
Баштанаяк сихерләдең мине.
Мыжык, усал диеп сине, юкка
Кимергәннәр минем колак итен.
Барысы да ялган сүзләр булган —
Шундый ягымлы син, ачык йөзле,
Тымызык гөл сыман татлы да син,
Син тешләк тә түгел, аларынып
Кумыйсың син кияү егетләрен,
Якты йөз күрсәтәсең аларга.
Кем соң әйтте миңа, Кет аксак, дип?
Телләренә төер чыккырлары!
Сиңа яла якканнар бит алар!
Үзең чикләвектәй каратутлы,
Тик чикләвек төшеннән дә мәгәр
Күп мәртәбәгә тәмлерәк бит син!
Яле, карыйм, тәпи йөреп кара,
Күрим әле, чынлап аксыйсыңмы?

Катарина

Ычкын, ахмак, хезмәтчеләреңә
Боер әнә шундый сүзләр әйтеп.

Петруччо

Диана үзе әрәмәгә чыгып
Йөри алмас иде Кет шикелле.
Син Диана булсаң, Диана Кет булса,
Тыйнакланыр иде Кет беразга.

Катарина

Кайда өйрәндегез көяз сүзгә?

Петруччо

Бу — табигый акыл нәтиҗәсе.

Катарина

Бик акыллы табигать әнкәбез
Ник тапкандыр шундый ахмак бала?

Петруччо

Мин ахмакмы?

Катарина

Сезнең өчен хәзер
Йоклап алу хәерлерәк булыр.

Петруччо

Синең түшәгеңдә! Тел чарламыйк.

Кыскасы, шул: әткәң сине миңа
Хатынлыкка бирә. Бирнә хакын
Килешенеп кул сугыштык инде.
Шуңа күрә, телисеңме-юкмы —
Өйләнешәчәкбез синең белән.
Нурлы йөзләреңне иркәләгән
Якты кояш белән ант итәмен:
Хатын булачаксың син тик миңа!
Әткәң килә! Миннән баш тартырга
Уйлыйсы да булма, ишеттеңме?
Син миңа хатын булырга тиеш.
Һәм дә булачаксың!

Баптиста, Гремио һәм Транио керәләр.

Баптиста

Ничек, синьор,
Килештегезме сез кызым белән?

Петруччо

Килешмичә, тагын ничек булсын?
Килешмичә мөмкин түгел безгә.

Баптиста

Ә ник, кызым, бер дә кәефең юк?

Катарина

«Кызым» дигән буласыз сез миңа!
Йә, шушымы ата кайгыртуы? —
Ярәшәсез мине бер тилегә,
Җирбит, оятсыз бер юлбасарга —
Ул! Оятсызлык белән җиңмәкче!

Петруччо

Болай, әти кеше, юкка гына
Сез дә, башкалар да гел буш сүзләр
Лыгырдагансыз аның хакында.
Юри генә ул тискәре икән.
Ә чынлыкта назлы күгәрчен ул.
Ярсымый да, фәрештәдәй күркәм.
Түземлерәк хәтта Гризельдадан,
Ә сафлыгы Лукрециягә тәңгәл.
Кыскасы, без килешендек инде,
Туйны билгелибез якшәмбегә.

Катарина

Күрсәм иде мин ул якшәмбене,
Сине асканнарын күргәннән соң!

Гремио

Тиздән асачаклар, ә, Петруччо?!

Транио

Килешкәннәр, имеш. Хәлләр мөшкел!

Петруччо

Үземә дип аны мин сайладым.
Без канәгать икән — сезнең ни эш?
Килешендек: ул һаман да шулай
Гел тискәре булыр ятлар барда.
Әйтсәм әйтим, ышанасым килми:
Миңа аны шулкадәр дә үлеп
Гашыйк булыр диеп кем уйлаган?!
И, җаным Кет! Асылынды килеп
Муеныма минем, шашып үпте,
Антлар итте, гомерлеккә диеп,
Миндә дә дәрт уянганга тиклем
Назлады ул шулай... Йомран башлар!
Белмәгәнсез, димәк, ялгыз калгач
Юаш кына егет җен кызын да
Ияләштергәнен! Бир кулыңны,
Кет сөеклем. Мин Венециягә
Сәфәр киттем. Туйга күчтәнәчләр,
Бүләкләр дә юнәтергә кирәк.
Әти кеше, шаулы, затлы пирга
Кунак дәшегез сез! Җаныем Кет
Тиңсез гүзәллеге, назы белән
Һушын алсын әле һәммәсенең!

Баптиста

Нәрсә әйтим? Йә, кул бирешегез,
Гел бәхеттән торсын тормышыгыз.
Петруччо! Сезнең өчен шатмын.

Гремио, Транио
(икесе бергә)

Амин. Без монда — тере шаһитлар.

Петруччо

Әткәй! Хатыным һәм дә синьорлар!
Саубуллашыйк. Мине юллар көтә.
Якшәмбе дә борын төбендә үк.
Кием-салым, бизәк-балдак кирәк.
Үп мине, Кет, шүрләмичә генә,
Гөрләп туй итәрбез якшәмбедә!

Петруччо һәм Катарина икесе ике якка китәләр.

Гремио

Тиз хәл кылынды туй мәсьәләсе!

Баптиста

Кая ни сатканын белми саткан
Сәүдәгәрдәй булдым мин, синьорлар.

Транио

Товарыгыз, синьор, сатылмыйча
Калган булыр иде, бәлки. Менә хәзер
Йә әҗерле итәр, булмый икән,
Суга салган кебек булыр инде.

Баптиста

Аларның бәхете — әҗер миңа.

Гремио

О, бусына һич тә шикләнмәгез.
Хәзер инде без сөйләшеп алыйк
Сезнең кече кызыгыз хакында.
Көткән көнем килде; мин — күршегез.
Һәм, онытмыйк, сылу Бьянканы
Иң беренче булып яучыладым.

Транио

Бьянкага булган хисләремне
Аңлатырга әгәр теләсәм мин —
Хыяллар да, сүз дә җитмәс иде.

Гремио

Миндәй сөя алмыйсың син, чебеш!

Транио

Туңачак ул синең мәхәббәттән.

Гремио

Ә син көйдереп көл итәчәксең!
Тай биредән, бозау! Хатын өчен
Бабайдан да ышанычлысы юк.

Транио

Яшьләргә күз теки шул хатын-кыз.

Баптиста

Сабыр, синьорлар. Бәхәсегезне
Мин хәл итим әле. Җиңгән кеше
Үз бүләген алыр! Кыз тол калса,
Кемнән аңа күбрәк мирас калыр —
Шул хуҗасы булыр Бьянканың.
Ни вәгъдә итәсез соң, Гремио?

Гремио

Көмеш тулы шәһәрдәге йортым.
Юар өчен назлы кулкайларны
Әзер тора ләгән, савыт-саба —
Һәммәсе дә шау алтыннан гына.
Йорт төрелгән Тир келәме белән,
Фил сөягеннән уеп ясалган
Сандыкларым тулы тәңкә белән.
Ә кипарис сандыкларда исә —
Затлы тукымадан кием-салым,
Ука чиккән төрек мендәрләре,
Җиз җиһазлар... Хуҗалыкта кирәк
Нәрсәләрнең һәммәсе дә камил.
Ә фермамда нәкъ йөз савым сыер —
Берәр чиләк көнгә һәммәсеннән.

Йөздән артык таза үгезем бар,
Бүтән мал-туарым да җитәрлек.
Яшермим мин, бик яшьләрдән түгел —
Иртәгәсен мин җан тәслим кылсам!
Аңа калдырамын һәммәсен дә,
Чыксын гына миңа! Тик шул шартым!

Транио

Шартлар куелмый шул юкка гына.
Синьор, мин бердәнбер варис
Әткәемә. Әгәр кызыгызны
Бирсәгез сез миңа, аңа булыр
Бай Пизада күпме йортларыбыз!
Ул йортларның сыңары да хәтта
Уздырачак Гремио йортын.
Өстәвенә һәрбер биләмәдән
Ел саен ике мең алтын акча
Килеп торыр аңа туктамастан.
Җитәрлекме тол өлеше өчен?
Ачу килмиме, синьор Гремио?

Гремио

Ел саенмы ул ике мең керем?
Барлык биләмәләремнең хәтта
Хакы аның кадәр чыкмаячак.
Ярый, инде Марсель гаваненда
Торган корабымны өстәп карыйм.
Йә, ничек соң, синьор, минем кораб
Утырмадымы тамак төбенә?

Транио

Һәркемгә дә мәгълүм, әткәемнең
Ике галерасы һәм дистәләп
Ишкәк суднолары ннан да башка
Янә өч корабы бар икәне.
Барсына да хуҗа булыр кәләш —
Сез ни генә тәкъдим итсәгез дә,
Икеләтә арттырачакмын мин.

Гремио

Мин әйтәсен әйттем! Әйтерем юк!
Бүтән берни тәкъдим итә алмыйм.
Хуш күрсәгез әгәр, алыгыз сез
Барлык малымны да, үземне дә.

Транио

Болай булгач, кыз минеке инде!
(Баптистага.)
Сүз бирдегез. Мин Гремионы җиңдем.

Баптиста

Хакын әйтим, сезнең тәкъдимегез
Ошый миңа, инде әткәегез
Раслый икән сезнең мал-мөлкәтне,

Алыгыз Бьянканы. Әгәр раслау
Булмый икән инде, юк, бигайбә! —
Әгәр әткәгездән алдарак сез
Үзегез җан тәслим кылсагыз, йә,
Кая барыр минем кызым Бьянка?

Транио

Таптыгыз сүз! Мин яшь, ә ул карт бит.

Гремио

Нәрсә, яшьләр бер дә үлми мәллә?

Баптиста

Тыңлагызчы мине, синьорлар, мин
Карар кылдым: якшәмбедә кызым
Катаринаны кияүгә бирәм.
(Траниога.)
Шул ук якшәмбедә, әгәр дә ки
Фатихасын бирсә әткәегез,
Бьянка сезнең кәләшегез булыр.
Фатиха юк икән, һичбер сүзсез
Гремиога бирәчәкмен аны.
Рәхмәт икегезгә дә. Хушыгыз.

Гремио

Хуш булыгыз, әткәй.

Баптиста китә.

Юк, курыкмыйм
Синнән, көчек! Ахмак түгел әткәң! —
Карт көнендә бар мөлкәтен сиңа
Бирсен дәме, артык кашык булып
Ялмансынмы синең тәлинкәңнән?
Тәмгың сузма, бәгырь! Карт төлкене
Алдап кара әле син башта.
(Китә.)

Транио

Ah, карт иблис, үчен алмый калмам!
Бер козырь бар әле запаста;
Үз хуҗама ярдәм тапмаммы мин?
Әйтик, юри-морый Люченцио
Таба алмасмыни үзе өчен
Юри-морый гына бер әткәне —
Юри-морый Винченционы?!
Моннан да зур сихер булмас җирдә —
Гадәттә бит җиргә балаларны
Әтиләр бар итә, ә мин менә —
Мәхәббәтнең тугры хезмәтчесе —
Кирәк икән, якты бу дөньяга
Әткәемне үзем бар итәрмен!
(Китә.)

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Баптиста йорты. Люченцио, Гортензио һәм Бьянка керәләр.

Люченцио

Һәй, музыкант! Җитте! Әрсезләнмә!
Синьораның сине ничегрәк
Кабул итүен оныттың мәллә?

Гортензио

Һи, буш бугаз, педант! Камиллекнең
Алиһәсе ләса синең алда.
Юл бир миңа бәхәсләшми генә.
Мин бер сәгать аны музыкадан
Укытыйм да, аннан сиңа калыр
Уку дәресенә берәр сәгать.

Люченцио

И аңгыра ишәк! Музыканың
Нигә кирәген дә белмисең бит!
Шөгыльләрдән зиһен арыганда,
Ял итәргә генә ярый бит ул.
Менә хәзер мин фәлсәфә белән,
Уку белән шөгыльләнеп алыйм —
Бераз күңел ачып алу өчен.

Гортензио

Ыржаймагыз! Талкан коры минем!

Бьянка

Бары үзем генә хәл итәрдәй
Эш турында болай бәхәсләшеп
Рәнҗетмәгез мине сез, синьорлар.
Мин сезгә мәктәп баласы түгел.
Суктырырлар диеп куркып тормыйм.
Сәгатьләргә мине бүлмәгез сез.
Кайчан телим — шунда гына укыйм.
Бәхәсләшмик, утырышыйк әйдә.
(Гортензиога.)
Лютнягызны көйли торыгыз сез.
Шуңа кадәрле без уку белән
Шөгыльләнә торырбыз дип уйлыйм.

Гортензио

Мин лютняны көйләп бетерүгә,
Уку дәресен ташлыйсыз, димәк?

Люченцио

Юк, тәтемәс! Лютня көйләгез сез.

Бьянка

Нидә тукталдык без узган юлы?

Люченцио. Бу тирәдә, синьора. «Бу тирәдә Симоис елгасы аккан; монда Сигей җирләре; монда әүлия Приамның ташпулаты балкып торган». Бу җөмләнең мәгънәсе болай: «Бу төбәктә Симоис елгасы аккан» — минем чын исемем Люченцио; «монда әүлия Приамның» — мин Пиза шәһәреннән Винченционың улы, сезнең мәхәббәтегезне яулау өчен бүтән киемнәр киендем; «ташпулаты балкып торган» — ә сезне яучылаган Люченцио — минем ялчым Транио ул, карт әткәгезнең күзен буу өчен минем киемнәрне киде!

Гортензио

Минем лютня әзер, синьора.

Бьянка

Тыңлыйк! Фи, югары кыллар
Әллә нинди ялган тавыш бирә!

Люченцио

Юньләбрәк көйләгез сез аны.

Бьянка

Йә, тәрҗемә итә алырмынмы,
Карап карыйк әле, ничек чыгар.
«Бу тирәдә» — мин сезне белмим; «Симойс елгасы аккан» — мин сезгә ышанмыйм; «монда Приамик» — сак булыгыз, теге безне ишетеп тормагае; «ташпулаты» — үз-үзегезгә чамасыз ышанмагыз; «балкып торган» — өметегезне өзмәгез, сабыр итегез.

Гортензио

Инде булды бугай.

Люченцио
Ә бу юлы
Түбән кыллар ялган тавыш бирә.

Гортензио

Кыллар түгел, күзе тездән түбән
Бер ялганчы алдалаша монда.
(Бер читкә.)
Кырга сыймый моның кыланышы!
Укытучы аламасы, күрәм,
Тагылмакчы моның итәгенә.
Ah син, өтек! Эзеңә төшәрмен мин!

Бьянка

Бәлки, берчак ышанырмын сезгә.
Әле куркам.

Люченцио

Юкка курыкмагыз.
Закидның бабасы ягыннан
Исеме Аякс булган әле әнә.

Бьянка

Шикләремә ирек бирер идем,
Тыңламыйча булмый остаз сүзен.
Калдырып торыйк боларны, Личио. —
Кичерегез, укытучыларым,
Сезнең белән шаяртканым өчен.

Гортензио
(Люченциога)

Калдырыгыз безне. Бераз йөреп
Килегез, югыйсә өч тавышка
Җырларга һич җыенмыйм мин монда.

Люченцио

Ай-һай, кырыс! Юк, мин көтеп торам.
(Бер читкә.)
Күздән җуймыйм әле. Бу музыкант,
Күрәм, чынлап торып гашыйк булган!

Гортензио

Синьора, кылларга орынганчы
Һәм бармаклар кылга күнеккәнче,
Әлифтән без башлап җибәрербез —
Өйрәнербез гамма төзелешен.
Мин аңлаткан сыман гади итеп
Һәм үтемле итеп бүтән һичбер кем дә
Төшендерә алмас аны сезгә.
Менә гамма. Мин күчереп яздым.

Бьянка

Гамманы мин болай да шәп беләм.

Гортензио

Шулай да сез танышырга тиеш
Гортензионың гаммасы белән.

Бьянка
(укый)

«Һәр аккордның нигезе мин — гамма.
А, ре — Гортензио сиңа гашыйк,
В, ми — кире какма берүк сөюемне.
С, фа — сөйгән хатыным бул минем!
До, соль — ачкыч, анда ике нота.
Е, ля, си — кире каксаң — үләм».
Сезнең гамма шушымыни? Булмый,
Искесе дә миңа ярап торыр.
Алмаштырмыйм сез уйлап чыгарган
Әллә нинди әкәмәтләргә.

Хезмәтче керә.

Хезмәтче

Әткәгез куша сезгә, синьора,
Ташлап торып барлык дәресләрне
Апагызга ярдәм итәргә.
Ул никахка бара бит иртәгә.

Бьянка

Хушыгыз, сөекле остазларым!

Бьянка һәм хезмәтче китәләр.

Люченцио

Димәк, хаҗәт түгел монда калу
(Китә.)

Гортензио

Күздән ычкындырмау хаҗәт миңа.
Гашыйк булганга бик охшаган бу.
Әгәр, Бьянка, син һәр майлы күзгә
Күз атасың икән, ул — синеке!
Әмма синең андый мәкереңне
Үз күзләре белән күрә икән —
Үч алмыйча калмас Гортензио!
(Китә.)

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Баптиста йорты алдында.
Баптиста, Гремио, Транио, Катарина, Бьянка, Люченцио һәм хезмәтчеләр керәләр.

Баптиста
(Траниога)

Катарина белән Петруччоның
Никах көне, синьор Люченцио.
Ә кияүнең эзе дә юк әле.
Бөтенесе бездән көләчәкләр!
Кияү юкка чыкты — ә чиркәүдә
Изге ата безне көтеп тора,
Никах өчен һәммә нәрсә әзер.
Ни әйтерсез мондый мәсхәрәгә?

Катарина

Моның бар хурлыгы миңа гына.
Шул оятсыз, әрсез бер юньсезгә,
Кәмитчегә риза булырга
Мәҗбүр иттеләр мине, ул исә
Яучылаган чакта ни ашыкты —
Өйләнергә дигәч, ашыкмый ул.
Әйткән идем ахмак икәнлеген.
Эчендәге барлык җаһиллеген
Оятсызлык белән каплаган ул.
Чая егет данын алыр өчен
Мең кәләшкә яучы җибәрер ул,
Һәм, мең туйның көннәрен билгеләп,
Дус-ишләрен дәшәр типтерергә,
Ә өйләнү уена да килмәс.
Хәзер һәркем миңа бармак төртер:
Әнә, имеш, өйләнмәде генә,
Безнең Петруччо, юкса Катарина
Аңа хатын булган булыр иде.

Транио

Баптиста, Катарина, сабырлык!

Алдамаячак сезне Петруччо.
Очраклы бер хәлгә юлыккандыр.
Дорфарак ул бераз, тик акыллы,
Шук күңелле, әмма намусы саф.

Катарина

Белмәү хәерлерәк булган аны!

Елап чыгып китә. Аңа Бьянка һәм башкалар иярә.

Баптиста

Бар, сабыем! Елаганың өчен
Үпкәләмим сиңа. Мондый хәлдә
Синдәй тискәреләр генә түгел,
Изге җаннар хәтта рәнҗер иде.

Бьонделло керә.

Бьонделло. Хуҗам, әфәндем! Таң калырлык иске яңалыкларны ишеттегезме әле?
Баптиста. Ниткән иске яңалыклар тагын? Ничек алай булсын инде?
Бьонделло. Петруччоның килүе яңалык түгелмени?
Баптиста. Килде мәллә?
Бьонделло. Юк, синьор.
Баптиста. Алай булгач, эш нәрсәдә?
Бьонделло. Килеп ята ул.
Баптиста. Ә ул кайчан монда булачак?
Бьонделло. Менә мин басып торган урынга килеп басып, сезгә күз тутырып карагач ук, аны монда дип исәпли аласыз.

Транио

Шулай да безгә үзеңнең
Иске яңалыкларыңны сөйләп күрсәт!
Бьонделло. Сөйләмимме соң! Күз алдыгызга китерегез: Петруччо — ат өстендә; башында — өр-яңа эшләпә, өстендә — иске куртка һәм кырык мәртәбә эчен тышка әйләндереп теккән чалбар; итекләре шәм әрҗәсе сыман: берсе — каптырмалы, икенчесен шнур белән үреп кигән; шәһәрнең хәрби корал амбарларыннан алган кылычның сабы сынык, йөзе яньчек, кынысы бөтенләй юк. Җитмәсә ат сыртындагы иярне көя ашап бетергән; өзәнгеләрнең берсе — мәгърибтә, берсе — мәшрикъта. Өстәвенә аты маңкалаган, ялы киезләнеп беткән, тешләре төшәм-төшәм дип тора, талагы бертуктаусыз гоңкылдый, тиресен укра сарган; буыннары шешкән; малкайга сары чире һәм дә баш әйләнү өянәге йоккан; эч суалчаны җанын суырган ул мәхлук атның. Сырты да әллә ничек, калак сөякләре тырпаеп тора; алгы аякларына сөртенә, мескенкәй, авызлыгы сынык, ә нуктасы сарык күненнән. Егылган атын күтәрә-күтәрә, тәмам тартып-йолкып бетергәннәр бугай аны, инде ул нукта әллә ничә төштән өзелеп чыккан, аны төйнәштереп кенә куйганнар. Ияр ызмасын да ялгыштырып кына әмәлләгәннәр. Ә койрык астындагы бәрхет каеш — хатын-кыз ияренеке. Мунчала бау белән генә бәйләп куелган бу каешка асыл затлы нәсел исеменең баш хәрефләре беркетелгән. Һәм бу хәрефләр бик матур итеп канәфер чәчәкләре белән бизәлгән.
Баптиста. Ә янында кем бар?
Бьонделло. Ah, синьор, хезмәтчесенең кыяфәте атныкыннан да әкәмәтрәк. Бер аягына кәгазь оекбаш киеп алган, икенче аягында — йоннан эрләгән кунычлы итек. Ул аларны зәңгәр һәм яшел шнур белән аяк тезенә бәйләп куйган. Эшләпәсенең элә-танагы юк, каурый урынына кырыклап чуар тасма таккан. Кыяфәтенә караганда, тәмам җен кавеме: иманы булган лакей яки берәр кеше затының хезмәтчесе дип уйламассың да.

Транио

Безгә шундый кыргый кыяфәттә
Килә икән — юкка гына түгел...
Тиешенчә ул киенә иде.
Баптиста. Нинди кыяфәттә булса да, аның килүенә шатмын.

Бьонделло

Юк, синьор, ул килмәде.

Баптиста

Әле генә килде дидең түгелме соң?

Бьонделло

Кем? Петруччо килдеме?

Баптиста

Әйе, Петруччо килде, дидең.

Бьонделло

Юк, синьор, аның аты гына килде, дидем мин.
Ә ул үзе атның сыртында бит.

Баптиста

Барыбер түгелмени!

Бьонделло

Гаҗәп нәрсә бу,
Уйласаң бер кат:
Бердән артык күк
Ат белән җайдак.
Әмма дә ләкин
Уйласаң чынлап:
Бердән артык та,
Тик икәү түгел
Ат белән җайдак.

Петруччо һәм Грумио керәләр.

Петруччо

Кая олактыгыз? Өйдә кем бар?

Баптиста

Исән-саумы?

Петруччо

Нинди саулык ди ул!

Баптиста

Алгы аяклар аксамый кебек...

Транио

Хәер, кием тиешенчә түгел.

Петруччо

Кәттә кием кигән килеш тә мин
Нәкъ шулай ук шашып чабар идем.
Кайда минем назлы кәләшем Кет?

Әткәм кайда? Дуслар, нигә шулай
Бүртендегез әле? Күз алартып
Нигә миңа шулай текәлдегез?
Күз күрмәгән сихри сын мәллә мин?
Гыйфритме? Койрыклы йолдыз мәллә?

Баптиста

Синьор, сезнең туегыз бит бүген.
Сез юк та юк — шуңа бик борчылдык;
Инде хәзер килеш-килбәтегез
Икеләтә борчый һәммәбезне.
Кияү кеше шулай киенәме?
Хурлык бит бу, салып ыргытыгыз!

Транио

Әйтегезче, нинди ашыгыч эшләр
Аерды соң сезне яшь кәләштән?
Сез нишләп соң мондый кыяфәттә?

Петруччо

Сөйли китсәң, тыңлап күз күгәрер.
Сүздә торгач, шул җитмәгәнмени?
Соңаруын шактый соңарсам да,
Җае чыккач үчен кайтарырбыз —
Рәхәт чигәр көннәрегез алда.
Кет кайда соң? Сагындым мин аны,
Таң да атып килә — вакыт җитте
Чиркәү тарафына юл тотарга.

Транио

Бу килбәттә ничек бармак кирәк
Андый изге җиргә? Иң яхшысы —
Киенегез минем киемнәрне,
Миңа кереп чыгыйк!

Петруччо

Юк, кәләшем
Янына мин шушы килеш барам.

Баптиста

Никахка да болай бармассыз бит?

Петруччо

Шушы килеш барам! Җитте! Ул бит,
Әйтсәм әйтим, кием белән түгел,
Минем белән бүген никахлаша.
Ул тетәсе җанымны мин әгәр
Кием алмаштырган сыман гына
Алмаштырып кия алсам әгәр,
Ул сөенер иде, мин үзем дә
Иң бәхетле кеше булыр идем.
Нәрсә соң мин, тинтәк, ләчтит сатам,
Кәләшемә очып барып кына,
Хуҗа булуыма — мәһәр итеп,
Җанкисәкне суырып үбәр чакта?

Петруччо һәм Грумио китәләр.

Транио

Юри шулай сәер киенгән бу.
Үгетләргә кирәк, кешечәрәк
Кыяфәттә барсын ул никахка.

Баптиста

Барыйм әле алар артыннан мин,
Бераз колак салыйм: ниләр булыр?

Баптиста, Гремио һәм хезмәтчеләр китәләр.

Транио
(Люченциога)

Синьорның мәхәббәте генә
Җитми монда — аңа өстәп тагын
Әткәгезнең фатихасы кирәк.
Әйткәнемчә, моның өчен безгә
Кулайрак бәндә табу мәгъкуль.
Кем булуы мөһим түгел — аны
Үзебезчә өйрәтербез һәм аңа
Винченцио дип исем бирербез,
Янәсе ул Пиза шәһәреннән.
Шушы бәндә сезнең исемегездән
Мин әйткәннән күпкә күбрәк акча
Вәгъдә итсен — менә шул чагында
Татырсыз сез хыял алмагызны —
Сезнеке булыр Баптиста кызы.

Люченцио

Әгәренки өтек бу музыкант
Шымчыламый торса һәр адымын
Бьянканың, инде күптән бит мин
Яшерен генә никахлашыр идем
Бьянка белән, ә аннары исә —
Ник бар дөнья миңа ябырылмый —
Үземнекен якларга мин әзер!

Транио

Әкрен генә көйләү-чөйләү кирәк.
Без дигәнчә булыр һәммәсе дә.
Төп башына утырыр да калыр
Картлач Гремионы һәм дә кызның
Шома койрыклы әткәсен,
Мәгъшук музыкант Личионы да —
Сезгә шулай кирәк икән, хуҗам.

Гремио кире керә.

Чиркәүдән кайтышыгызмы, Гремио?

Гремио

Мәктәптән мин шулай тая идем.

Транио

Яшь ир белән аның хәләле дә
Чиркәүдә булып чыктылармы?

Гремио

Юк, ир түгел, кыргый бер гыйбат ул;
Күрәселәр кызның алда икән.

Транио

Катаринадан да кыргыйракмы?
Нигә кирәк сөйләү булмаганны!

Гремио

Иблисеңнең үзеннән дә хәтәр!

Транио

Катарина да бит җеннең җене.

Гремио

Аның янында ул бәти генә
Ничек диген… изге ата килгән,
Сорау бирә моңа: «Сез ризамы, — ди, —
Катаринаны, — ди, — хатынлыкка
Алырга?» — ди. Ә ул исә шулчак
Үкереп салмасынмы: «Риза! — ди, —
Риза! Риза, шайтан алгырысы!»
Һәм тотынды шуннан санарга ул —
Аллаларның кабер такталарын,
Кот калмады — хәтта изге ата
Төшереп үк җибәрде китап.
Алыйм диеп ул иелгән иде —
Кияү исә аның арт санына
Шундый итеп берне типте! —
Тәгәрәп үк китте изге атакай.
Күкри генә кияү егетебез:
«Кемгә кирәк, алып китегез, — ди, —
Аунап яткан шушы нәрсәләрне!»

Транио

Ә кәләш соң, сүз дә дәшмәдеме?

Гремио

Калтырана мескен, ә ул исә
Аяк тибә-тибә попны сүгә —
Янәсе, ул алдамакчы булган;
Никах беткәч, шәраб таләп итте,
Исән-саулык теләгән сүзләрен
Шулкадәр дә ямьсез үкерде ки —
Давылдан котылган бер корабта
Матрослар белән типтергәндәй
Кыланды ул, барлык мускатны
Чөмерде дә касә төбендәген
Пономарьның сипте чыраена.
Янәсе, ник хәер теләнгәндәй

Кәҗә сакалыңны суздың миңа?
Аннан кочып алды да кәләшне
Шундый итеп чытырдатып үпте —
Шаулап китте чиркәү гөмбәзләре!
Оятымнан чыгып йөгердем мин,
Калганнар да миңа иярделәр.
Булганы юк мондый кыргый туйның!
Ишетәсезме?

Музыка.

Музыка да уйный.

Петруччо, Катарина, Бьянка, Баптиста, Гортензио, Грумио һәм кунаклар керәләр.

Петруччо

Мәшәкатьләндегез, рәхмәт, дуслар.
Минем белән бергә утырырга
Мәҗлес әзерләгәнсез мул итеп.
Тик эшләрем минем муеннан шул,
Сезне калдырырга туры килә.

Баптиста

Төнгә каршы юлга чыгасызмы?

Петруччо

Төн кергәнче юлга чыгам. Ләкин
Шаккатмагыз. Минем эшләремнең
Кичектермәслеген белсәгез сез,
Үзегез киңәш итәр идегез
Юлга чыгарга дип. Рәхмәт яусын
Күркәмнән дә күркәм бу мәҗлескә.
Ләкин, күрәсез бит, хатыныма
Бирелгән мин җаным-тәнем белән.
Әткәм белән бәйрәм итегез сез.
Күтәрегез минем саулык өчен.
Мин китәргә тиеш. Сау булыгыз.

Транио

Ашка калуыгызны сорыйбыз.

Петруччо

Юк, булмый.

Гремио

Үтенеп сорыйм сездән.

Петруччо

Юк, һич мөмкин түгел.

Катарина

Мин үтенәм.

Петруччо

Шатмын.

Катарина

Калыргамы?

Петруччо

Юк, мин шатмын
Калырга дип сезнең кыстауларга.
Ләкин кыстамагыз, кала алмыйм.

Катарина

Сөю хакына да калмыйсызмы?

Петруччо

Атлар кайда?! Тизрәк китерегез!
Грумио. Булды, синьор; солы атларның булган кадәресен ашап бетерде.
Катарина

Алайгарак киткән икән эшләр —
Нишләтсәң дә риза, әмма ләкин
Кузгалмыйм мин бүген, иртәгә дә!
Бик теләсәм генә кузгалырмын.
Ишек — ачык, юлыңа — ак җәймә,
Сыпырт, итекләрең сау чагында.
Ә мин монда калам! Әйтәсе юк,
Шәп ир икән! Сез баштан ук
Үзегезне бик шәп күрсәттегез.

Петруччо

Сабыр, песикәем, ачуланма.

Катарина

Ачуланмам! Катышмагыз миңа.
Әткәй, ышаныгыз, ул калачак,
Мин әйтмичә, адым атламас ул.

Гремио

Була икән монда кыямәтләр!..

Катарина

Синьорлар! Мәҗлескә дәшәм сезне.
Каршы җавап бирә белми икән —
Хатын-кызны тинтәк итү җиңел.

Петруччо

Килер алар синең табыныңа —
Ни боерсаң, барсы үтәләчәк.
Сорыйм сездән сүзсез буйсынуны
Яшь кәләшкә, типтерегез юньләп!
Аның саф кыз булу хөрмәтенә
Туеп кикергәнче чөмерегез,
Теләмисез икән, һич үпкәм юк,
Шайтаныма китеп олагыгыз!
Ә хатыным минем белән китә;
Тыпырчынма, пескәй, мырылдама —
Мин — бердәнбер хуҗа үз малыма.
Хәзер инде минем мөлкәтем ул:
Йорт-амбарым, кирәк-ярагым ул,
Атым да ул минем, ишәгем дә —
Менә — каршыгызда. Тиеп кенә

Карагыз сез — башыгызны өзеп
Култык астыгызга кыстырырмын!
Падуяда мине тоткарларга
Теләүченең калҗасы да калмас.
Грумио! Коралга! Талыйлар!
Коткар хуҗабикәңне, ир булсаң!
Курыкма, Кет, беркем тимәс сиңа,
Яу килсә дә, турап атачакмын.

Петруччо, Катарина, Грумио китәләр.

Баптиста

Китсеннәр... Абау, пар килгәннәр!

Гремио

Шартлый идем көләсем килүдән!

Транио

Булды мондый шашкын никах?

Люченцио

Апагыз турында инде хәзер
Ни әйтерсез икән сез, синьора?

Бьянка

Шашкын кызның никахы да шашкын.

Гремио

Киявен ул катариналаган.

Баптиста

Дуслар, кияү-кәләш урыны буш,
Әмма сый-нигъмәтнең һәммәсе бар.
Җитешегез, күңел ачыйк шәпләп.
Кияү урынын алсын Люченцио;
Бьянка, кызым, барып утыр әле
Син Катаринаның урынына.

Транио

Дөрес, ярәшкәнче сабак кирәк!

Баптиста

Хак сүз сөйлисең бит, Люченцио!
Авызкайларыңа бал да май!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Петруччоның шәһәр читендәге йорты. Грумио керә.

Грумио. Тфү, корчаңгы алашаларны, акылдан ычкынган хуҗаларны, әшәке юлларны яшен суксын! Кешенең шушы кадәр дә эштән чыкканы булды микән? Булды микән кешенең шушы кадәр дә муеныннан пычракка батканы? Булды микән кешенең шулай йончыганы? Мич-

кә ут тергезергә дип мине алдап җибәрделәр, ә үзләре өй җылынуга гына кайтып керәчәкләр. Буем бәләкәй булып та, каным кайнар булмаса, иреннәрем тешкә ябышып катар иде, йөрәгем ашказанына берегер иде. Шулай булып куймасын өчен, бераз эреп куяр өчен, ут үрләтергә кирәк бит, ә? Мондый зәмһәрирдә миннән кәттәрәкләрнең дә суык тидерәсен көт тә тор. Әй, әй, Кертис!
Кертис керә.

Кертис. Кабердән чыккан тавыш белән кем чакыра мине анда?
Грумио. Туңып каткан боз күсәгәсе чакыра сине. Ышанмасаң, менеп утыр да минем җилкәдән үкчәгә кадәр шуып төшеп кара. Җилдертеп шуып китим дисәң, баш чүмечемнән муеныма кадәр йөгереп шусаң да җитә. Мичкә ут үрләт. Кертис, мәшһүрем!
Кертис. Хуҗам белән аның хәләл җефете кайталармы соң, Грумио?
Грумио. Кайталар, Кертис, кайталар, шуңа күрә тизрәк ут үрләт! Ут тегермәненә су коеп маташма!
Кертис. Төрле сүзләр йөри: аның кәләше, чынлап та, шулкадәр кызу канлы, шундый тискәреме әллә?
Грумио. Мондый суыклар бәргәнче, чынлап та шундый иде, Кертис ягымлым. Әмма, үзең беләсең, суык дигәнең ир-атны да, хатын-кызны да, хайванны да юашландыра бит. Шул суык минем карт хуҗамны да, яңа хуҗабикәмне дә, минем үземне дә бик нык бөкте бит, Кертис дускаем.
Кертис. Кит моннан, өч карыш буйлы түмәр. Мин хайван түгел сиңа.
Грумио. Минем буем шулай өч карышлы гына микәнни соң? Югыйсә синең мөгезләреңнән дә бәләкәйрәкмени инде мин? Мичне кабызырга уйлыйсыңмы син, юкмы? Әллә бу сөрхәнтәйлегең турында хуҗабикәгә җиткеримме? Исеңдә тот, аның үзенең дә кайнар йодрыкка йомарланган чагы. Шуңа күрә җылылык мәсьәләсен хәстәрләгәндә җәһәтрәк кылануың мәслихәт булыр. Боз итеп шакырайтмагайлары үзеңне.
Кертис. Ялварып сорыйм, сөеклебез Грумио, сөйләп җибәрсәнә: ниләр бар соң бу якты дөнья йөзендә?
Грумио. Якты дөнья йөзендә адәм чыдамаслык зәмһәрир салкыннары, Кертис. Синең җылы эш урыныңны исәпкә алмаганда, әлбәттә. Шуңа күрә тизрәк учак тергез. Үз эшеңне кара. Шунда гына өлешеңә тиеш көмешне тамызырлар сиңа. Хуҗа белән хуҗабикә тәмам туң күчәнгә әйләнделәр.
Кертис. Менә инде ут та дөрләп китте. Яңалыклар капчыгын чишеп җибәр инде, ягымлыбыз Грумио.
Грумио *(көйли).* «Их, Джек, ah, Джек!» Яңалыклар сиңа гына җитәрлек.
Кертис. Ай-яй, хәйлә капчыгы син!
Грумио. Дөрләт, дим, утны! Коточкыч күшектем. Аш остасы кайда? Кичке аш әзерме? Йорт-җир җыештырылганмы? Идәннәр чистамы? Үрмәкүч оялары себереп алынганмы? Хезмәтчеләр яңа күлмәкләрен, ак оекбашларын киделәрме? Туй бизәкләрен тактылармы? Стаканнар — эчтән, чынаяклар тыштан юылганмы? Келәм җәелгәнме? Кыскасы, барысы да тәртиптәме?
Кертис. Барысы да әзер; шуңа күрә үтенмә, сөйлә инде яңалыкларны.
Грумио. Болай булды: беренчедән, минем атым йончыды, ә хуҗам белән хуҗабикәм чупырдадылар.
Кертис. Ничек?
Грумио. Иярдән очып, туп-туры пычракка чупырдап чумдылар, әй, әкәмәт. Менә шуннан башлана инде сөйләрдәй галәмәтләр.
Кертис. Сөйлә шул вакыйгаларны, Грумио туганкай.
Грумио. Китер әле колагыңны.
Кертис. Менә бит ул.
Грумио *(Кертиска берне кундыра)*. Аласын ал!
Кертис. Вакыйга тыңлау булмады бит инде бу. Истән китәрә яздың бит!

Грумио. Менә шуңа күрә кешеләр, искиткеч вакыйга, дип әйтәләр дә инде. Ә колак төбеңә менеп төшүем юкка түгел. Баш шәрифеңә шакып карап, игътибар беләнрәк тыңлавыңны үтендем мин. Йә, башлыйм: яңгырдан изрәп ләпеккә баткан тау битеннән төшеп барабыз. Хуҗам исә хуҗабикәм артыннан килә.
Кертис. Икесе бер атта мәллә?
Грумио. Ә син нигә шуңа кайгырасың?
Кертис. Юк ла, үземне түгел, атны жәлләп әйтүем...
Грумио. Алай булгач, калганын үзең сөйлә. Әгәр дә син мине бүлдермәгән булсаң, ничек итеп хуҗабикәмнең аты өркегәнен, аның ат тояклары астына мәтәлеп төшкәне турында ишетер идең; хуҗабикәнең ничек итеп ләпеккә батканын, ә хуҗаның, аны ат астында килеш калдырып, өреккән ат өчен мине дөмбәсләргә тотынуын, хуҗабикәнең пычрак ера-ера мине араларга килүен, хуҗаның нинди хәшәп сүзләр белән сүгенүен, беркайчан да кешегә ялынмаган хуҗабикәнең аның каршысында ничекләр ялваруын, минем ничек акыруларымны, атларның качып китүләрен, хуҗабикә атының йөгән бавы өзелүен, минем ияр каешын югалтуымны һәм башка шундый кызык нәрсәләрне белгән булыр идең, ахмак. Хәзер инде син боларның берсен дә белмәгән, ишетмәгән килеш гүргә керәчәксең.
Кертис. Миңа калса, хуҗабикә яшь хуҗабикәдән дә тискәрерәк булып чыга түгелме соң?
Грумио. Шулай шул менә. Һәм син дә, сезнең арагыздагы иң тәкәббер бәндә дә, ул кайтып керү белән үк, моны үз сыртында татыячак. Нәрсә телемә салыныйм соң әле мин? Барысын да чакыр монда: Натаниэльне, Джозефны, Никласны, Филиппны, Уолтерны, Татлыкайны — тагын кем бар — һәммәсен дә чакыр. Чәчләрен шомартып тарасыннар, үзләренең зәңгәр курткаларын әйбәтләп чистартсыннар, тасмаларын килешле иттереп тиешенчә бәйләп куйсыннар. Сул тезләренә тезләнсеннәр һәм, хуҗабикәнең кулын үпмичә торып, хуҗаның ат койрыгындагы сыңар гына кылга да кагылырга кыймасыннар. Йә, нәрсә анда, барысы да әзерме?
Кертис. Әзер.
Грумио. Монда чакыр әле аларны.
Кертис. Һәй, ишеттегезме? Хуҗаны каршылаганда берегез дә хуҗабикә каршында чыраен сазга тыккан бәндәдәй мескен күренәсе булмагыз, ишетсен колагыгыз!
Грумио. Алай дисәң, хуҗабикә үзе үк йөзен сазга тыкты бит.
Кертис. Кем генә моны белми икән соң?
Грумио. Син белмисең. Аның каршында саз бакасы булып күренмәс өчен, кешеләр җыясың икән, мондый галәмәтне син генә белмисең дигән сүз!
Кертис. Хуҗабикәм каршында бурычлы бит алар. Шул бурычларын үтәр өчен чакырам мин аларны.
Грумио. Ә хуҗабикәбез бурычка керергә уйлап та карамый.

Берничә ялчы керәләр.

Натаниэль. Әйбәт кенә йөреп кайттыңмы, Грумио?
Филипп. Хәлләр ничек, Грумио?
Джозеф. Әй, Грумио!
Никлас. Грумио, саумы, дускай!
Натаниэль. Ничекләр яшисең, картлач?
Грумио. Әйбәт кайттыңмы?.. Хәлләр ничек?.. Саумы, дускай?.. Очрашу хакына болары да җитеп торыр. Ә хәзер, көяз дускайларым, әйтегез: барысы да әзерме? Барысы да тәртиптәме?
Натаниэль. Барысы да әзер. Нәрсә, хуҗабыз кайтып җитә мәллә?
Грумио. Килеп җитәр-җитмәс кенә, инде аттан төшеп, тәпи-тәпи киләдер, нигә дисәң... Шауламагыз, нәләт оргылары! Ул кычкыра түгелме соң?!

Петруччо белән Катарина керәләр.

Петруччо

Кайда соң бу җыен ачыгавыз?
Йөгән алыр кеше калмадымы?
Кайда Грегори, Филипп, Наниэль?

Хезмәтчеләр

Синьор, без монда, синьор, без монда!

Петруччо

«Синьор, без монда, синьор, без монда!»
Җыен хәйләкәр, чапкан да таккан!
Кайгырту юк, һичбер тырышлык юк!
Мин алдан җибәргән бүкән кайда?

Грумио

Монда, синьор, һәм дә элеккечә
Иң зур ахмакларның ахмагы мин.

Петруччо

Их. Их син, көчек, абау, кабахәт җан!
Мин сиңа бит безне паркта ук
Каршыларга боерык биргән идем,
Кушкан идем шушы хәшәпләрне
Шул паркка алып килергә.

Грумио

Натаниэльнең куртка әзер түгел,
Габриэльнең башмаклары умрык,
Питер өлгермәде эшләпәсен
Яңа, матур төскә буятырга;
Калганнары мисле йолкыш чебеш —
Шул килеш тә килде әле алар.

Петруччо

Ычкыныгыз, диваналар, моннан!
Кичке ашны тизрәк китерегез!

Хезмәтчеләр китәләр.

(Җырлый.)
Кайтсам буйдак чакларыма,
Җил булып исәр идем,
Шәраб тулы бокалларны...

Катарина керә.

Кет, түрдән уз, утыр, җанкисәгем. Их-ма-а-а!

Хезмәтчеләр кичке аш кертәләр.

Кәефлерәк булчы, җан-песием! —
Салдырыгыз аяктан, мәлгуньнәр!
(Җырлый.)
Яшәгән, ди, бер суфи,
Догалар укый-укый
Юлга чыккан, ди, имеш...

Кит, аңгыра! Өздең аягымны!

Мә сиңа!
Хезмәтчегә суга.

Тартып өзмәс өчен шәбрәк булыр.
Күңел ач, Кет! Әй, су китерегез!
Этем Троил кайда? Йөгер, бүкән,
Тудыкамны — Фердинандны чакыр,
Син үбәргә тиеш аны, Кетым!
Кайда минем әйбәт туфлиләрем?
Суны кайчан китерерсез икән?

Хезмәтче кувшин белән ләгән күтәреп керә.

Йә, юынып җибәр, мырмырыем.

Хезмәтче кулыннан кувшинны төшереп җибәрә.

Ах син, көчек, кулың чередеме?

Хезмәтчегә суга.

Катарина

Тынычланыгыз сез, зинһар өчен,
Ул бит ялгыш кына...

Петруччо

Миңгерәү эт! —
Йә, утыр, Кет. Ачыккансыңдыр бит.
Бисмиллаңны үзең әйтәсеңме,
Үзем әйтим мәллә? Бу нәрсә соң?
Сарык ботымы бу?

Хезмәтче
Әйе.

Петруччо
Моны
Кем китерде?

Хезмәтче
Мин.

Петруччо

Көйгән бит бу ит.
Көя-көя күмер булган бит бу.
Җыен эттән туган! Кайда угры
Аш пешерүче? Бу җирәнгечне
Ничек оялмыйча китердегез
Минем табыныма? Пычакларны,
Тәлинкәләрне дә — һәммәсен дә
Күрәсе булмыйм! Алып китегез!

Итле тәлинкәләрне һәм савыт-сабаны идәнгә сыпырып төшерә.

Җыен ялкау! Җыен миңгерәү кол!
Мыгырданма! Күрсәтермен сезгә!

Катарина

Борчылмагыз берүк, газиз ирем.
Сезгә шулай тоелгандыр гына,

Ит ярыйсы.

Петруччо

Әйттем түгелме соң —
Көйдергәннәр итне! Мондый аштан
Үтең сытылачак. Сытылган үт
Зәһәр бәндәләргә генә ярый.
Хәерлерәк булыр бүген безгә
Көйгән ит ашаганчы, ураза
Тоту. Нигә дисәң, синең белән
Миндә үт зәһәре җитеп ашкан.
Түземле бул! Иртән барысын да
Көйләрбез без. Ә бу төнне исә
Уразалы булыйк икәү бергә.
Әйдә киттек, йокы бүлмәсенә
Мин озатып куйыйм әле сине.

Петруччо һәм Катарина китәләр. Берничә хезмәтче кире керәләр.

Натаниэль. Йә, Питер, мондый әкәмәтне күргәнең бар идеме?
Питер. Хуҗабикәне үз коралы белән кыйный бит ул.

Кертис керә.

Грумио. Кайда ул?
Кертис. Йокы бүлмәсендә. Яшь хуҗабикәгә рәхәтләрдән нәфесне тыя белү турында вәгазь уку белән мәшгуль.
Акыра, дулый, хуҗабикә исә
Нишләргә дә белми, аңгы-миңге
Тик утыра. Киттек! Монда килә.

Китәләр. Петруччо керә.

Петруччо

Шәп башладым әле хакимлекне.
Әйбәт тәмамлармын, Ходай кушса.
Минем ау бөркетем ач, ачулы.
Буйсынмыйча торып ашатмамын.
Тук бөркетләр киек ауламый шул.
Тагын бер юлы бар бу кыргыйны
Кулга ияләштерүнең — йоклатмаска!
Тыңлаусыз төн ябалагын да бит
Әнә шулай ияләштерәләр.
Бер төн йокламады. Бу төне дә
Керфек йоммый узар. Иткә юри
Бәйләнгән күк, түшәк-ястыкка да
Бәйләнермен: мендәр-юрганнарны
Алып томырырмын караваттан.
Һәм гауганы бары аның өчен
Куптаргандай итеп кыланырмын.
Таңга кадәр аңа йокы кермәс,
Керфек йома калса, сүгенермен,
Һәм кычкырып, дулап, шаулап шулай
Ирек бирмәм йоклап китәргә.

Бу йөрәккә ачкыч тик бер генә:
Тискәренең холкын сындыруның
Бүтән ысулы юк. Кем дә булса
Моның шәбрәк җаен белә икән,
Курыкмыйча әйтеп бирсен иде —
Һәркем өчен изге эш булыр ул!
(Китә.)

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя.Баптистаның йорт алды.
Транио белән Гортензио керәләр.

Транио

Нәрсә, Личио дускай, Бьянканың
Күңелендә, чынлап, бүтәнмени?
Люченцио түгелмени? Ә бит
Өстен күрде мине һәммәсеннән!

Гортензио

Беләсегез килсә, менә монда
Басыгыз да, укытучысының
Аңа нинди сабак укытканын
Тикшерегез, шуннан төшенерсез.

Бьянка белән Люченцио керәләр.

Люченцио

Йә, сабаклар ничегрәк бара?

Бьянка

Сезнең сабак нәрсә турында соң?

Люченцио

Сөю сәнгатедер минем сабак.

Бьянка

Ул сәнгатьне сез камил беләсезме?

Люченцио

Сезне сөюемдәй камил хис ул.

Сәхнә түренә үтәләр.

Гортензио

Уңышларга ирешкән бу! Хәзер
Синьора Бьянка тик Люченциога
Тугры дип ант итә аласызмы?

Транио

Ah, хатын-кыз мәкере! Мәртәтлеге!
Ah, Личио, исем китә моңа.

Гортензио

Синьор, ялгышмагыз, мин Личио да,
Музыкант та түгел, инде миннән —
Дворяннан шундый бер гыйбатны
Өстен күреп барлык йөрәк хисен
Бер сукбайга багышлаган затны
Якын күрә алмыйм йөрәгемә.
Салам битлегемне. Таныш булыйк:
Чын исемем Гортензио минем.

Транио

Синьор Гортензио, Бьянканы
Янып сөюегез турысында
Ишетергә туры килгәнем бар,
Ләкин хәзер, үз күзләрем белән
Күргәч аның бу җилбәзәклеген,
Тәкъдим итәм: икәү бергәләшеп
Онытыйк без аны яратуны.

Гортензио

Күрәсезме, ничек үбешәләр?
Люченцио, менә минем кулым.
Ант итәмен; Бьянка лаек түгел
Минем тугры, кайнар мәхәббәткә.

Транио

Мин дә корычтай нык ант бирәмен
Беркайчан да аңа өйләнмәскә,
Хәтта үзе сорап ялварса да!
Адәм хуры! Сарыла бит тәмам!

Гортензио

Баш тартабыз! Аңа чыксын әнә!
Ә мин исә, антка тугры калып,
Өйләнәчәкмен өч көн эчендә
Гаҗәеп тә бай бер хатынга.
Мин бу кыланчыкны сөйгәннән дә
Дәртлерәк итеп сөя ул мине.
Сау булыгыз, синьор Люченцио.
Моннан соң мин хөрмәт итәчәкмен
Хатын-кызның чибәрләрен түгел,
Ә йөрәге тугры булганнарын.
Хуш булыгыз. Антка тугры калам.
(Китә.)

Транио
(Бьянка янына килә)

Тик гашыйклар хыяллана торган
Олы бәхеткә сез ирешкәнсез.
Сезнең гыйшык-мыйшык уйнаганны
Туры килде миңа күрергә.
Гортензио белән икәүләп без
Гомерлеккә сездән баш тарттык.

Бьянка

Икегез дә? Шаяртма, Транио!

Транио

Шаяртырга уйлаганым да юк.

Люченцио

Болай булгач, безгә Личиодан
Курку-өркү кирәк булмый, димәк!

Транио

Гаҗәп ачык күңелле һәм чибәр
Бер тол хатынга ул өйләнәчәк,
Көнендә үк туен уздырачак.

Бьянка

Ходай бәхет бирсен аңа!

Транио

Буйсындырачак ул тол хатынны.

Бьянка

Кем белә бит әле!

Транио

Беләсе юк —
Ул бит хәзер һәр көн сабак укый
Буйсындыручылар мәктәбендә.

Бьянка

Андый мәктәп бармыни, Транио?

Транио

Ник булмасын! Анда укыта бит
Петруччо үзе! Ә ул исә
Тискәре хатыннарны бер учка
Йомарлауның һәм аларның озын
Телләрен бик шәпләп кыскартуның
Нәкъ егерме җаен яттан белә.

Бьонделло керә.

Бьонделло

Синьор, синьор! Мин сагалый торгач,
Эттән яман ардым. Ә шулай да
Таптым могтәбәр бер картны. Ул таудан
Төшеп килә иде. Безнең өчен
Кулай килә сыман, минемчә.

Транио
Ә кем соң ул?

Бьонделло

Берәр укытучы
Кисәгеме шунда, сәүдәгәрме —

Әйтә алмыйм, ләкин бар килбәте
Нәкъ әткәгез инде, коеп куйган.

Люченцио

Йә, Транио, ни әйтерсең моңа?

Транио

Нәрсә әйтим? Минем шыттырганга
Ул ышана калса, кыланачак,
Һәм әткәгез исеменнән бирер
Баптистага ышаныч язуын
Раслап сезнең чынлап Винченцио
Улы булуыгыз хакында һәм
Аталарча фатихасын бирер.
Хәзер исә, синьор, сез китегез
Сөйгәнегез белән икәүләшеп.

Люченцио һәм Бьянка китәләр. Укытучы керә.

Укытучы

Ходай саулык бирсен, синьор.

Транио
Сезгә
Шул ук теләк бездән. Юлыгызны
Дәвам итәсезме, әллә бездә
Туктаргамы сезнең ниятегез?

Укытучы

Монда булам мин бер-ике атна.
Аннан кузгалырмын. Башта — Римга,
Шуннан инде, Ходай куәт бирсә,
Траполига барып элгәшермен.

Транио

Ә сез кайсы яктан?

Укытучы

Мантуядан.

Транио

Мантуядан, синьор! Ходай үзе
Саклый күрсен безне! Падуяга
Үлем эзләп килдегезме әллә?

Укытучы

Нишләп үлем эзләп? Нинди сүз бу?

Транио

Мантуядан килгән һәркемне дә
Үлем көтә монда. Сезнең флот
Венециядә туктатылды, синьор.
Безнең герцог сезнең герцог белән
Сүзгә килде, һәм ул бу турыда
Үзе хәбәр итте бар халыкка.
Иртәрәк килсәгез, бу хәлләрне

Үзегез үк ишетер идегез.

Укытучы

Әҗәлкәем монда икән, синьор!
Инде дә җитмәсә үз башыма
Флоренциядә мин вексельләр алдым,
Имеш, монда гамәл кылам диеп.

Транио

Ярдәм итә алыр идем сезгә...
Болай итик: әйтсәгезче миңа, —
Булганыгыз бармы соң Пизада?

Укытучы

Булганым бар, синьор. Ул шәһәрнең
Дәрәҗәле кешеләрен беләм.

Транио

Ә Винченционы беләсезме?

Укытучы

Күреп белмим, әмма
Ишетеп беләм иң зур бай икәнен.

Транио

Ул — әтием минем, синьор. Тагын
Шуны әйтим: сез бик охшаш икән.

Бьонделло
(бер читкә)

Тәртәгә гөл охшаш булган кебек.

Транио

Әткәм хөрмәтенә, бу бәладән
Мин әзермен сезне коткарырга.
Винченциога шулкадәр дә охшаш
Булуыгыз — сезнең өчен бәхет.
Исемен дә аның, кредитын да
Үзегезгә алыгыз һәм әткәм булып
Урнашыгыз миңа, әмма ләкин
Рольгә ныклап керә белегез сез.
Аңлашылдымы соң? Эшегезне
Бетергәнче, миндә яшәрсез сез.
Йә, разыймы минем ярдәмемә?

Укытучы

Разыймын, синьор, исән калсам,
Кара гүрләремә кергәнгәчә
Дога кылып яшәрмен мин сезгә.

Транио

Юлда булыйк, барысын көйләрбез без.
Шунысын да әйтим: минем әткәй
Килеп төшәр тиздән, халык көтә.
Сәүдәгәр Баптистаның кызына

Өйләнүдә минем төп ниятем.
Алдан үлеп куйсам, калыр малны
Раслап кул куярга тиеш әткәм.
Киттек, ни эшләргә кирәклеген
Аңлатырмын әле. Хәзер исә
Бүтән кием кидерербез сезгә.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Петруччо йортындагы бүлмә. Катарина белән Грумио керәләр.

Грумио

Юк, юк, антлар итәм, һич хакым юк.

Катарина

Мин интеккән саен котырына.
Мине ачка үтерим дип кенә
Миңа өйләнгәнме соң ул әллә?
Безнең йортка хәтта теләнчеләр
Ишек какса, ризык таба идек.
Беркемнән берни теләнгәнем юк,
Ә бүген мин — ач, үлеп йокым килә,
Ә баш төртсәң — дулый, сүгенә ул,
Сыйлый мине җикеренү белән.
Ачуың да килмәс иде, юньсез,
Мине сөйгән сыман кылана бит!
Янәсе, бер черем итүең дә,
Ризык кабуың да бит зарарлы,
Грумио, зинһар, тамак ялгардай
Берәр нәрсә юнәт, ни булса да
Ярый миңа, тик кабарлык булсын.

Грумио

Ничек булыр, әйтик, бозау боты?

Катарина

Искитмәле! Тизрәк китер генә!

Грумио

Юк, бавырга бәрә андый ризык.
Ярамасмы симез эчәк-бавыр?

Катарина

Тел йотарлык! Китер Грумиокай!

Грумио

Хәер, бу да сезгә зарарлыдыр.
Тәмләткечле сыер ите ничек?

Катарина

Чәйнәмичә йотар идем хәтта!

Грумио

Юк, тәмләткеч канны кыздыра бит...

Катарина

Тәмләткечсез ит тә ярый миңа.

Грумио

Юк, алай да булмый. Иң яхшысы
Борыч китерүем шәбрәк булыр.
Шунсыз тәтемәс бит сыер ите.

Катарина

Борычлымы әллә борычсызмы —
Булган кадәресен китерә күр.

Грумио

Борыч кына китерергә, димәк?

Катарина

Югал моннан, ялганчы кол, тинтәк!
Ризык исемлеге белән мине
Сыйлап маташуы! Кahәр суксын
Минем хәсрәтемне көлке иткән
Мәкерле һәм хәсис шайкагызны!
Югал күз алдымнан!

Тәлинкә белән ризык күтәреп Петруччо һәм Гортензио керәләр.

Петруччо

Ни хәлләр, Кет? Нигә уйга баттың?

Гортензио

Тормышлар ничек соң?

Катарина

Мәсхәрә бу!

Петруччо

Күңелеңне төшермә син алай.
Күз сал әле, бәгърем, синең хакта
Ничек кайгыртам мин: синең өчен
Үз кулларым белән пешерендем.
Мондый игътибарның кадерләрен
Белерсең дип уйлыйм.

Ризыкны өстәлгә куя.

Ник дәшмисең?
Ошамыймы әллә? Юкка гына
Тырышканмын инде алай булгач.
Алып китегез, әй!

Катарина

Калдырыгыз,
Калдыр монда, үтенәмен.

Петруччо

Ә хезмәткә хөрмәт дигән нәрсә
Ник күренми әле? Ашаганчы
Рәхмәт әйтү тиеш бит, минемчә.

Катарина

Рәхмәт сезгә, синьор.

Гортензио

Синьор Петруччо! Ничек оят түгел?
Рәхим итегез, синьора! Бергә
Утырышыйк.

Петруччо

(Гортензиога, шыпырт кына)
Гортензио, дус бул —
Ашап бетер үзең барысын да.
(Ишеттереп.)
Ашлар тәмле булсын, җанкисәгем,
Тизрәк аша, аннан әткәбезгә
Кайтырбыз да сыйланырбыз шәпләп,
Күңел ачарбыз бер рәхәтләнеп.
Яңа киемнәрдән көязләнеп
Йөрербез бер, күреп калсын барысы:
Эшләпәләр, энҗе-мәрҗәннәрне,
Челтәр якаларны, җиң тасмасын,
Җилпәзәне, муен яулыкларын
Һәм шундый җыен чүпрәк-чапракны.
Бәй, ашап та бетердеңме әллә?
Анда тегүче тир түгә әнә,
Син төренсен өчен ефәкләргә.

Тегүче керә.

Йә, син ни китердең?

Тегүче

Яңа башлык
Тектерергә биргән идегез сез.

Петруччо

Нәрсә? Бу башлыкны син чүлмәккә
Кидереп үтүкләдең мәллә, ә?
Карар җире дә юк! Чүпрәк миски!
Фи! Фи! Тәмам адәм көлкесе бу!
Кабырчык, буш чикләвек кабыгы,
Бәп-бәләкәч курчак башлыгы!
Ал да олак моннан! Зуррак иттер...

Катарина

Зуры кирәк түгел, хәзер шундый
Модада бит, шушындыйны кия
Әйбәт дамаларның һәммәсе дә.

Петруччо

Әйбәтләнсәң, сиңа да булыр.
Тик, кабатлыйм, әйбәтләнсәң генә!

Гортензио

(бер читкә)
Көтә-көтә көтек булачак бу.

Катарина

Әйтергә минем дә хакым бар.
Һәм әйтәм: мин бала-чага түгел!
Дәрәҗәлерәкләр хәтта минем
Әйткәнемне тыңлап тора иде.
Тыңлыйсыгыз килми икән инде,
Томалагыз колакларыгызны,
Төен булып җанга төйнәлгәнне
Әйтеп бирим әле чытырдатып.

Петруччо

Син хаклысың, җаным! Эшләпәнең
Элә-танагы юк: ефәкләрдән
Әвәләнгән гади пәрәмәч бу,
Бәлешне дә хәтерләтә сыман! —
Ошатмавың өчен бу мыскылны
Мин тагын да ныграк сөям сине!

Катарина

Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә, ләкин
Миңа ошый — башкасы кирәкми!

Петруччо

Күлмәк ничегрәк? Йә, тегүче,
Күрсәт әле безгә. Йа Ходаем!
Кәмит кичәсенә тектең мәллә?
Нәрсә соң бу? Җиңме? Зур пушкага
Көпшә итеп куярлык булган бу!
Ямаштырган алма бөккәне бит!
Бөтен җире ярык-йорык кына!
Нәрсә соң бу, шайтан алгырысы!

Гортензио
(бер читкә)

Мәрхүм кала икән мескен кәләш
Баш киеменнән дә, күлмәгеннән дә.

Тегүче

Соңгы модага туры килсен дип,
Матур булсын дип кушкан идегез.

Петруччо

Әйе, куштым. Әмма дә ләкин мин
Соңгы модага туры китереп
Кием бозарга дип кушмадым бит.
Ычкын моннан: чатыр-чотыр гына

Сикереп үт чокыр-чакырларны.
Өйрәнә тор: минем заказлардан
Мәхрүм калгач, син һич туктамастан
Үрле-кырлы сикерерсең әле.
Ал күлмәкне! Үзең теләгәнчә
Файдалан син мондый аламаны.

Катарина

Ә, юк, минем мондый күлмәктән дә
Күркәмрәген күргәнем булмады.
Тегелеше нәфис, алтын куллы
Кеше теккән моны, ә сез мине
Карачкы күк киендермәкчеме?

Петруччо

Шулай шул, җанкисәк, ул бит сине
Бер карачкы иттермәкче була.

Тегүче

Юк, мин түгел... Сезнең ният шундый,
Синьор нәкъ шул турыда әйтте.

Петруччо

Ах син, яман авыз! Алдашасың,
Уймак белән җепнең үги улы!
Карыш! Чирек! Аршын, җәй, чүпрәк корты!
Борча, кандала син! Чикерткә син!
Әле мине мыскыл итмәкчеме,
Чүпрәк-чапрак, корама! Кит моннан! —
Юкса тотып шундый үтүкләрмен —
Тел кайтарып сүз әйтүнең хәтта
Нәрсә икәнлеген онытырсың.
Әйттем бит, күлмәкне бозгансың, дип!

Тегүче

Юк, әфәндем, ялгышасыз, минем
Хуҗама ничек кушылган булса —
Нәкъ шундый итеп тегелде күлмәк,
Ничек тегәргә икәнен әйтеп,
Грумио боерык бирде безгә.

Грумио

Боерык түгел, күлмәклек бирдем.

Тегүче

Ә ничек тегәргә куштыгыз соң?

Грумио

Энә белән, дидем, чәнчелгере!

Тегүче

Нинди өлге белән тегәсен

Әйтүче сез түгел иде мәллә?
Грумио. Күпме күлмәкне син ука белән уйганың бар?
Тегүче. Җитәрлек.
Грумио. Ә менә син уйганны мин күптән уеп чөйгә элеп куйган. Күпме кием тегеп, күпме җәй очын яшердең? Ә менә миннән яшерә алмассың. Ишетсен колагың: мин хуҗаңа өлгеләрне ничегрәк кисәргә икәнен әйттем, әмма корама итеп тураргa кушмадым. Күрдеңме инде, син — ялганчы.
Тегүче. Менә бит күлмәкнең килбәтен сурәтләп язылган язу. Монда һәр сүз мин әйткәнне раслый.
Петруччо. Укы.
Грумио. Мин әйтмәгәнчә булса, бу язу — шыр ялган язу.
Тегүче *(укый)*. «Беренчедән, күлмәк иркен булсын».
Грумио. Хуҗам, әгәр дә мин кайчан да булса «күлмәк иркен булсын» дип әйткән булсам, мине күлмәк итәгенә дыңгычлап төреп тегегез дә камыт җебе белән үтергәнче ярыгыз.
Петруччо. Дәвам ит.
Тегүче *(укый)*. «Очлары түгәрәк бәләкәй генә яка булсын».
Грумио. Яка мәсьәләсендә каршы сүзем юк.
Тегүче *(укый)*. «Җиңе көяз булсын».
Грумио. Ике җиң дисә дә каршы түгелмен...
Тегүче *(укый)*. «Җиң көяз итеп, зур итеп уелсын».
Петруччо. Менә бусы хәшәплек инде.
Грумио. Язуда хата киткән, синьор, әйе, хата киткән. Мин бит җиңне әүвәл кисәргә, аннары яңадан тегеп куярга куштым. Уймак белән коралланган булсаң да, мин сиңа моны исбатлап күрсәтермен!
Тегүче. Әйткәнемнең һәммәсе хак. Аулаграк урында туры килгән булсаң, күрмәгәнеңне күрсәтер идем мин сиңа.
Грумио. Мин хәзер үк әзер, күрсәт әйдә! Язуыңны кесәңә тык та колга буеңны миңа биреп тор. Аннары һөҗүм ит, кызганып торма.
Гортензио. Алла сакласын, Грумио! Көчләр бер дә тигез булмас бит.

Петруччо

Кыскасы, шул: син китергән күлмәк
Миңа ярый торган түгел.

Грумио

Әйе,
Бикәгә ярый торган күлмәк бу.

Петруччо

Иел, күтәр аны, хуҗаң үзе
Рәхәтләнеп файдалана бирсен.
Грумио. Юньсез, исән калыйм дисәң, минем хуҗабикәмнең күлмәген үзеңнең хуҗаң өчен күтәреп кенә кара!
Петруччо. Моның белән ни әйтмәкче буласың?
Грумио. И, синьор, хәлләр сез уйлаганга караганда катлаулырак бит монда. Минем бикәмнең күлмәген моның хуҗасы өчен күтәреп торсыннар, имеш! Хурлык бит, хурлык!

Петруччо

(Гортензиога, шыпырт кына)
Әйт тегүчегә, хакы түләнер.
(Тегүчегә.)

Ал күлмәкне. Сайрап торма, ычкын!

Гортензио

(Тегүчегә, шыпырт кына)
Иртәгә түләрмен күлмәк хакын;
Үпкәләмә ләкин сүккән өчен
Һәм хуҗаңа сәламнәр ирештер.

Тегүче китә.

Петруччо

Бернишләп тә булмый. Кузгалыйк, Кет.
Туры килә әткәң тарафына
Шундый гади генә күлмәк киеп
Барырга… Тик киемдәме хикмәт! —
Кием гади, әмма кесә калын!
Күлмәк бизәми шул чын кешене.
Болыт аша кояш балкыгандай,
Намус балкый ярлы кием аша.
Каурыйлары тәти булган өчен
Күкшә-кош шәбрәкмени тургайдан?
Тик кабыгы матур булган өчен
Кара елан күркәмрәкмени
Еланбалыклардан? Ышан, җаным,
Шушы гади күлмәк белән дә син
Башкалардан бер дә ким булмассың.
Оят булып куйса — миңа сылта.
Рәхәтләнә, күңел ач! Хәзер үк без
Кузгалабыз синең әткәеңә —
Мәҗлестә кәеф-сафа кылырга.
Чакыр барлык хезмәтчеләрне дә.
Ашыгырга кирәк булыр безгә.
Олы аллеяга китерсеннәр
Атларны, без шуннан күралырбыз.
Сәгать җиде тирәседер инде,
Без нәкъ төшке ашка өлгерербез.

Катарина

Җиде түгел, сәгать төгәл ике —
Кичке ашка да без җитешмибез.

Петруччо

Җиде дигән икән, димәк, җиде,
Гел кирегә генә сукалыйсың.
Әй, атларны тугарыгыз! Бүген
Беркая да бармыйм. Мин барырга
Уйлаганга кадәр, әйткәнемчә,
Нәкъ җиде дә тулып куяр әле.

Гортензио

Тиздән газиз кояшны да хәтта
Үзенчә бу йөртә башлаячак!

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Юл өсте. Петруччо, Катарина, Гортензио һәм хезмәтчеләр керәләр.

Петруччо

Тизрәк, тизрәк — әткәй тарафына!
Йа Хода, ай бүген нинди якты!

Катарина

Ай, имеш! Бу — кояш бит! — Төнгәчә
Озак әле!

Петруччо

Ә мин әйттем — ай бик якты, дидем!

Катарина

Ә мин әйтәм — кояш шулай балкый.

Петруччо

Мин ант итәм газиз әнкәем улы
Исме белән, ягъни үзем белән,
Мин ни әйтсәм, күктә тик шул балкыр.
Аймы, кояш-йолдызмы — барыбер!
Югыйсә мин беркая да бармыйм.
Әй, борыгыз кире! Моңарга
Бертуктамый бәхәс кенә булсын!

Гортензио
(Катаринага)

Бәхәсләшмәгез сез аның белән,
Барып җитеп булмас бит югыйсә.

Катарина

Зинһар өчен, чыккач барыйк инде,
Ай-кояшмы — сез әйткәнчә булсын.
Шәм дисәгез, антлар итеп әйтәм,
Минем өчен дә ул шәм булачак.

Петруччо

Мин әйтәм — ай.

Катарина

Соң, ай, ай, әлбәттә!

Петруччо

Юк, кояш бу. Нигә ялганлыйсың?

Катарина

Кояш, кояш, Ходаның рәхмәте!
Кояш түгел, дисез икән — түгел.
Сез ай сыман үзгәрүчән икән.
Тик сез ничек кенә дисәгез дә,
Һәрчак минем өчен шулай булыр.

Гортензио

Зур чирүне җиңдең син, Петруччо.

Петруччо

Алга, алга! Шар дигәнең һаман
Таудан түбән тәгәрәргә тиеш,
Киресенчә — тау башына түгел!
Шым булыгыз! Кемдер килә монда.

Винченцио керә.

Петруччо

Хәерле көн, туташ! Кайсы якка
Юл тотасыз? Кет, йә, әйт, яшермә —
Чибәр кызыкай бит, искитмәле! —
Бит алсуы актан һич ким түгел!
Моның карашыдай пакь йолдызлар
Юктыр хәтта биек күкләрдә дә…
Нинди сылу аның яшь гәүдәсе.
Хәерле көн сезгә, чибәр туташ!
Кет, бер үп әле шул чибәр кызны.

Гортензио

Бу шуклыктан бабай ычкыначак.

Катарина

Чибәр, назлы, яшь кызкайга сәлам!
Кая юл тотышың? Йортың кайда?
Бәхетледер шундый кызыкайның
Әткә-әнкәләре! Язмыш кушып,
Хатынлыкка алса кемдер берәү —
Чумачак бит оҗмах багларына.

Петруччо

Акылыңа кил, Кет! Шаштың мәллә?
Ир дә түгел, чибәр кыз да түгел —
Бетәшкән бер бабай икән бит ул.

Катарина

И, могтәбәр ата, кичер берүк.
Кояш чагылдырды күзләремне,
Яшь тә яшел миңа бөтен нәрсә.
Баксаң, син могтәбәр карт икәнсең,
Тинтәклегем өчен кичер инде.

Петруччо

Кичер аны, синьор, һәм әйт безгә —
Кая юл тотышың? Бәлки, бергә
Үтәрбез без калган юлыбызны.

Винченцио

Синьор! Һәм үз чаялыгы белән
Мине һушсыз иткән синьорина!
Пизадан мин. Исемем — Винченцио.
Падуяга улым янына мин
Барам әле. Күптән күрешкән юк.

Петруччо

Исеме кем?

Винченцио

Люченцио, синьор.

Петруччо

Бик тә әйбәт — безнең өчен дә һәм
Аның өчен дә; мин сезгә хәзер
Әткәй диеп хәтта дәшә алам,
Яшькә карап түгел, минем моңа
Хокукым бар: минем хатынымның —
Бу синьораның — сеңлесе белән
Нәкъ менә без сөйләшкән бу мәлдә
Никахлашып өлгергәндер инде
Синең улың! Ләкин гажәпләнмә,
Ачуланма мине, киленкәйнең
Тыйнаклыгы тәмам искитмәле!
Ул байлыгы! Ул дәрәҗә димсең!
Нинди асыл аның тәрбиясе!
Затлы синьор җәмәгате өчен
Гыйлеме дә аның җитеп ашкан.
Кил, кочаклыйм, синьор Винченцио,
Люченцио янына без бергә
Барып ирешербез, Ходай кушса.

Винченцио

Ләкин хакмы соң бу? Әллә инде
Маташтырасызмы? Сәфәрчеләр
Сәфәрчене бик еш шаярта бит!

Гортензио

Юк, юк, и, аксакал, һәммәсе хак.

Петруччо

Киттек. Безгә, үз күзләрең белән
Күргәч тәмам ышанырсың әле,
Алдамавына һәр узгынчының
Ышанмыйсың, ахры, безнең сине
Бераз гына шаяртканга күрә…

Гортензиодан кала барысы да китәләр.

Гортензио

Шәп, Петруччо дускай! Син бит миңа
Куәт бирдең әле… Тол җанашым
Башын бер генә чөеп карасын! —
Нәкъ синеңчә итәрмен мин аны.
(Китә.)

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Баптиста йорты алдында. Транио белән Винченцио булып киенгән Укытучы керәләр.

Транио

Шушы йорт ул. Шакып карыйммы соң?

Укытучы

Әйбәт булыр. Бәлки, синьор Баптиста
Мине хәтерлидер. Ялгышмасам,
Егерме ел элек Генуяда
«Пегас» кунакханәсендә бергә
Без яшәгән идек.

Транио

Бигрәк яхшы.
Ләкин берүк минем әткәемә
Лаек тотыгыз сез үзегезне.
Борчылмагыз.

Бьонделло керә.

Укытучы

Хезмәтчегез килде,
Зыян итмәс аны искәрткәндә.

Транио

Аның өчен һичбер борчылмагыз.
Аң бул, Бьонделло, синең алда
Синьор Винченцио шәхсән үзе!

Бьонделло

Юкка борчылмагыз.

Транио

Мин әйткәнне
Илтеп җиткердеңме Баптистага?

Бьонделло

Венециядә дидем әткәгезне,
Әйттем сезнең аның Падуяга
Бүген килүен көткәнегезне.

Транио

Булдыргансың. Мәле, эчеп җибәр, —
Баптиста килә! Кыюрак, синьор!

Баптиста белән Люченцио керәләр.

Синьор Баптиста, чын күңелемнән
Шатмын сезне күрүемә, менә
Сезгә мин әйткән синьор шушы ул.
Хәзер инде мин үтенәм сездән:
Әткәм булыгыз һәм кызыгызны
Мирас итеп миңа бирегез сез.

Укытучы

Чү, сабыр, улым. Синьор Баптиста,

Аласымнарымны җыярга дип
Килүем иде минем Падуяга.
Көтмәгәндә, улым Люченцио
Әйтә куйды: сезнең кызыгыз һәм
Минем улым сөешәләр икән,
Сезнең хакта һаман яхшы сүзләр
Ишетә килдем, безнең балалар
Бер-берсенә гашыйк булганнар бит.
Шуңа күрә газиз улкаемны
Озак интектермәскә мин булдым
Һәм никахка фатихамны бирдем.
Сез дә риза булгач, һич шикләнмим,
Уртак сүзгә килербез дип уйлыйм.
Һәм күрерсез, гүзәл кызыгызны
Йөздерермен балда-майда гына,
Кирәк түгел миңа хәйлә-мәйлә,
Сез — хөрмәткә лаек кеше, синьор.

Баптиста

Әйткәнем кичерерсез, синьор.
Ошый миңа ихлас сүзләрегез.
Әгәр уен-муен түгел икән —
Минемчә дә, сезнең улыгыз һәм
Минем кызым берсен-берсе сөя.
Шуңа күрә, әгәр дә сез әзер
Икәнсез, ата кеше буларак,
Мирасның җитәрлек толлык өлешен
Беркетергә Бьянка хисабына —
Туй булачак! Һәм сезнең улыгыз
Хатынлыкка алыр кызкаемны.

Транио

Рәхмәт, синьор. Инде кайда гына
Безгә уңайлырак булыр икән
Контракт төзүе һәм, ике яктан
Өскә алган бурычларны теркәп,
Рәсми язуларны алмашуы?

Баптиста

Миндә түгел ләкин. Люченцио,
Сезгә мәгълүм: минем йортта хәтта
Стенаның да колаклары бар бит.
Өй тулы хезмәтчеләр. Җитмәсә
Гремио иснәнеп йөри һаман —
Эшне бозып куюлары мөмкин.

Транио

Миңа рәхим итегез алайса;
Әткәм миндә яши, һәм без бүген
Эшне ипләп кенә тәмамларбыз.
Тизрәк җибәрегез Камбионы,
Кызыгызны дәшсен. Ә мин исә
Җәһәт чакыртам нотариусны.

Тик шунсы бар: юньле сый-хөрмәтне
Әзерләргә вакыт җитмәс инде.

Баптиста

Бик шәп! Камбио, хәзер өйгә җилдерт;
Әзерләнеп торсын кызыкаем.
Сөйләсәң дә ярый бу хәлләрне,
Әткәсе, диң, килде Люченционың,
Никах ягы хәл ителде, диген.

Бьонделло

Ходай кушып, шулай була күрсен.

Транио

Ходай кайгысымы монда?! Йөгер!

Бьонделло китә.

Рәхим итегез, синьор Баптиста.
Шунысы үкенечле: мин сезгә тик
Бер генә аш тәкъдим итә алам.
Пизада без үчен кайтарырбыз!

Баптиста

Мин сезнең белән.

Транио, Укытучы һәм Баптиста китәләр. Бьонделло кире керә.

Йә, Камбио?

Люченцио

Ни әйтерсең, Бьонделло?

Бьонделло

Транио күз кысты, күрдегезме?

Люченцио

Мәгънәсе соң нидә, Бьонделло?
Бьонделло. Берни дә юк, әмма үзенең баш кагуларының, күз кысуларының мәгънәсен аңлату өчен мине монда калдырды ул.
Люченцио. Аңлатып бир, үтенәм.
Бьонделло. Хәлләр болайрак. Безгә Баптиста куркыныч түгел, ул хәзер ялган улының ялган әткәсе белән сөйләшә.
Люченцио. Булса соң?
Бьонделло. Сез аның кызын кичке ашка алып килергә тиеш.
Люченцио. Ә соңыннан?
Бьонделло. Изге Лука чиркәвеннән бер карт поп теләсә кайчан сезгә хезмәт күрсәтергә әзер.
Люченцио. Ә шуннан соң нәрсә инде?
Бьонделло. Белмим. Шулай да, алар алган кызның мул тормышын тәэмин итү хакында уйдырма әңгәмәләр белән мәш килгән арада, үзегезгә хокукын, ягъни әсәрне басуга аерым өстенлек хокукын тәэмин итәргә ашыгыгыз. Попны, никах йолаларын үтәүчене, берничә шаһитны эләктерегез дә тизрәк чиркәүгә юл тотыгыз.
Риза булмасагыз сез моңар,
Бер сүзем юк, әмма ләкин
Бьянкадан сез колак кагачаксыз.
Люченцио. Чү, туктале, Бьонделло...

Бьонделло. Кыл сыярлык түгел. Мин бер кызны белә идем: куян итен тәмләргә петрушка йолкып керергә генә дип бакчага чыккан иде ул. Сез дә шуны ук эшли аласыз, синьор. Шуның белән шул, хуш булыгыз. Хуҗам миңа изге Лука чиркәвенә бара торырга кушты. Һәм сез үзегезгә таккан өстәмә йөкне алып килеп җиткергәнчегә кадәр попка әзер булып торырга икәнлекне әйтергә боерды. *(Китә.)*

Люченцио

Риза гына булсын, мин әзермен!
Юк, юк, ул риза булырга тиеш!
Ни булса, шул булыр, йөгердем мин,
Ансыз кире кайтсам, яшен суксын!

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Люченцио йорты алдында. Әүвәл Гремио керә һәм сәхнә түренә барып туктала, аннары Бьонделло, Люченцио һәм Бьянка, Транио, Баптиста
керәләр.

Бьонделло. Шыпыртрак һәм җәһәтрәк булыгыз, синьорлар, поп көтә.
Люченцио. Очам гына, Бьонделло. Ләкин синең аларга өйдә кирәк булуың бар бит, китсәң дә ярар.
Бьонделло. Юк, башта мин сезнең чиркәүгә кереп киткәнегезне караштырып торырмын, аннары исә хуҗамның өенә таба җан көчемә элдертермен.

Люченцио, Бьянка һәм Бьонделло китәләр.

Гремио. Сәер, нишләп юк соң бу Камбио?

Петруччо, Катарина, Винченцио, Грумио һәм хезмәтчеләр керәләр.

Петруччо

Люченцио йорты шушы, синьор.
Әнә ишекләре. Минем исә
Каенатам базар янындарак.
Аның тарафына ашыгам мин.
Мин китәргә мәҗбүр.

Винченцио

Юк, юк, синьор,
Бергә касә күтәрик без башта;
Сезне монда кабул итәрмен дип
Өметләнәм, сый булырга тиеш!
(Шакый.)

Гремио

Алар мәшгуль. Шакыгыз катырак.

Укытучы тәрәзәдән урамга карый.

Укытучы. Ишек җимерердәй булып кем дөмберди анда?

Винченцио. Синьор Люченцио өйдәме?
Укытучы. Ул өйдә, синьор, ләкин әлегә сезнең белән сөйләшергә һичбер мөмкинчелеге юк.
Винченцио. Әгәр мин аңа кызык өчен ике йөзләп фунт акча төртсәм дәме?
Укытучы. Акча чыгарырга уйламагыз да! Мин исән чакта, Люченцио сукыр тиенгә дә мохтаҗ булмаячак!
Петруччо. Йә, сезнең улыгызны Падуяда бик нык күккә чөйделәр дип әйтмәдемме мин сезгә? Карагыз әле, синьор, мәзәк сүзләрне ташлап торыйк, синьор Люченциога әйтегезче: Пизадан аның әтисе килеп төште һәм аның әтисенең үзенең яраткан улы белән бер генә мәртәбә булса да сөйләшеп аласы килә.
Укытучы. Алдашасың, аның әтисе чыннан да Пиза шәһәреннән килеп төште һәм ул хәзерге минутта менә тәрәзәдән карап тора!
Винченцио. Синме аның әтисе?
Укытучы. Әйе, синьор, һәрхәлдә, әнкәсе шулай дигән була, әгәр аңа ышанырга яраса.
Петруччо *(Винченциога)*. Хәзер ни әйтерсез, синьор? Бигрәк инде, кеше исемен үзләштерүдән дә әшәкерәк алдауның булуы да мөмкин түгел.
Укытучы. Тотыгыз бу җирбитне, минем исемне файдаланып берәрсен карама төбенә утыртырга йөри бу, нәгаләт!

Бьонделло кире керә.

Бьонделло. Мин аларны икесен бергә чиркәүдә калдырдым. Ходай Тәгалә хәерле сәфәрләр насыйп итсен! Ә бу кем соң? Минем карт хуҗам Винченцио! Эләктек, бетте башкайлар!
Винченцио *(Бьонделлоны күреп алып)*. Кил әле монда, кабахәт җан!
Бьонделло. Минем киләсем киләме, килмиме, хикмәт шунда бит әле, синьор.
Винченцио. Кил, әшәке җан! Син нәрсә, минем кем икәнлегемне дә оныттыңмы әллә?
Бьонделло. Сезне оныттыммы? Юк, синьор. Ничек оныта алыйм инде, сезне үз гомеремдә бер генә мәртәбә дә күргәнем юк лабаса, белмәгән кешене ничек онытмак кирәк!
Винченцио. Нәрсә, эт җан, кабахәт, үз хуҗаңның улы Винченционы күргәнем дә юк дип әйтмәкче буласыңмы әллә, нәгаләт?!
Бьонделло. Минем карт һәм дәрәҗәле хуҗам турында сүз барамы? Сез нәрсә, синьор, күргәнем бар, әлбәттә: әнә тәрәзәдән карап тора ул.
Винченцио *(сугып җибәрә)*. Чынлап тамы?
Бьонделло. Коткарыгыз! Коткарыгыз! Коткарыгыз! Әллә нинди бер шашкан бәндә мине үтерергә маташа!

Йөгереп чыгып кача.

Укытучы. Ярдәмгә, улыкаем! Ярдәмгә, синьор Баптиста! *(Тәрәзә яныннан китә.)*
Петруччо. Бер читкәрәк китик әле. Көт, бу пәри туеның ни белән беткәнен күрик әле. *(Бер читкә китә.)*

Укытучы, Транио, Баптиста һәм хезмәтчеләр урамга чыгалар.

Транио. Минем хезмәтчемне кыйнарга батырчылык итәр өчен кем соң әле сез шулкадәрле, әфәндем?
Винченцио. Мин кемме, синьор? Юк, сез менә минем өчен кем? Йа Ходаем, мадәт бир! Алама ялган капчыгы! Ефәк колет! Бәрхет чалбар! Бөркәнчек! Очлы эшләпә! Йа Хода, белдем, белдем! Хуҗалыгымда көне-төне казганам, ә улым белән аның хезмәтчесе мөлкәтемнең көлен университетта күккә очыралар!
Транио. Нинди хәл бу? Нәрсә булды тагын?
Баптиста. Ычкынганмы әллә бу?
Транио. Синьор, килеш-килбәтегезгә караганда, сез өлкән яшьтәге могтәбәр генә кешегә охшагансыз, ләкин сөйләшүләрегез тилергән бәндәне хәтерләтә. Минем алтын-җәүһәргә төренеп йөрүемдә сезнең ни эшегез бар? Әткәм исән чакта мин моны үзем өчен мөмкин эш дип саныйм.

Винченцио. Әткәм, дисеңме? Ах, угры! Синең әткәй Баргаямода җилкән тегә.
Баптиста. Ялгышасыз, синьор, ялгышасыз. Әйтеп карагыз әле, сезнеңчә, исем-шәрифләре ничегрәк соң аның?
Винченцио. Аның исеме? Аның исемен мин дә белмәсәм! Өч яшеннән бирле тәрбияләп үстереп киләм. Транио аның исеме!
Укытучы. Ычкын моннан, ахмак ишәк! Аның исеме — Люченцио; ул минем бердәнбер улым һәм минем — синьор Винченционың — барлык биләмәләре аңа мирас кылынды!
Винченцио. Люченцио! Димәк, ул үзенең хуҗасын үтергән! Тотыгыз аны! Герцог исеменнән боерам, тотыгыз! И улкаем, улкаем! Әйт, дөмеккере, кайда минем улым Люченцио?
Транио. Сакчыларны монда чакырыгыз.

Сакчылар керәләр.

Транио. Бу дивана бәндәне төрмәгә илтегез. Баптиста, әткәм, зинһар өчен, күз-колак була күрегез: аны шунда илтә күрсеннәр.
Винченцио. Мине төрмәгә?!
Гремио. Сакчылар, туктагыз! Ул төрмәгә кермәячәк!
Баптиста. Дәшмәгез, синьор Грумио; әйткән сүзем — аткан ук: төрмәгә керәчәк ул.
Гремио. Сак булыгыз, синьор Баптиста, сезне бу шикле эшкә бутап куймагайлары. Аның чынлап та синьор Винченцио икәнлегенә мин ант итәргә әзер.
Укытучы. Иманың булса, ант ит!
Гремио. Юк, ант итәргә куркам.
Транио. Сез, бәлки, мине Люченцио түгел дип тә әйтерсез?
Гремио. Сезнең синьор Люченцио икәнне мин беләм.
Баптиста. Алып китегез ялганчыны! Төрмәгә!
Винченцио. Читтән килгән кешеләрне менә ничек мәсхәрәлисез икән сез, адәм тәганәсе!

Бьонделло, Люченцио һәм Бьянка керәләр.

Бьонделло. Беттек! Менә ул. Аңардан баш тартыгыз, югыйсә харап безнең эшләр.
Люченцио. Кичер, әткәй.
Винченцио. Улым! Исән-сау бит!

Бьонделло, Транио һәм Укытучы, ашыга-ашыга, йөгереп чыгып качалар.

Бьянка

Кичер, әткәй.

Баптиста

Синең ни гаеп бар?
Кайда Люченцио?

Люченцио

Мин ул — Люченцио,
Менә әткәм — чып-чын Винченцио.
Юри-морый әткәм белән безгә
Сез икәүләп бәхәсләшкән чакта
Никахлашып куйдык тиешенчә
Сөекле кызыгыз Бьянка белән.

Гремио

Болар сүз берләшкән, безне болар
Ныклап төп башына утыртмакчы!..

Винченцио

Хәйлә капчыгы һәм шамакай

Оятсыз Транио кайда йөри?

Баптиста

Ашыкмагыз! Ул Камбиом бит минем.

Бьянка

Камбиогыз Люченцио булды.

Люченцио

Могҗизалар ясый чын мәхәббәт.
Бары Бьянка өчен генә бары
Транио белән урын алмаштык без.
Ул мин булып йөрде шәһәр буйлап,
Ә мин исә нәкъ шул минутларда
Бәхет гаваненда ләззәт чиктем.
Үтәде ул мин кушканны гына,
Зинһар, әткәм, кичерә күр аны.
Винченцио. Мине монда төрмәгә тыгарга чамалаган ул юньсезнең танавын кара кан итмәсәмме!
Баптиста *(Люченциога)*. Тыңлагыз әле, синьор, сез минем кызыма миннән фатиха алмыйча гына өйләнгәнсез бит!
Винченцио. Юкка борчылмагыз, Баптиста, без сезнең белән ничек тә килешенербез. Ә мин шулай да мондый оятсызлык өчен исәп-хисапны үзеп килим әле. *(Китә.)*
Баптиста. Ә мин аларның бу коточкыч алдакчылыкларының төбенә төшим әле. *(Китә.)*
Люченцио *(Бьянкага)*. Курыкма ла, әткәң безгә әллә ни озак ачу тотмас.
Гремио

Пешеп чыкмаса да ашкайларым,
Типтереп ял итсен башкайларым.
(Китә.)

Петруччо һәм Катарина алга чыга.

Катарина. Җефеткәем, боларга ияреп барыйк әле, бу әкәмәтләрнең ни белән беткәнен күрик әле.

Петруччо

Башта үп, Кет, аннан чамаларбыз.

Катарина

Китче, урам уртасында мәллә?

Петруччо

Ә булса соң? Нәрсә, минем белән
Үбешергә оят мәллә сиңа?

Катарина

Ah, без нәрсә, синьор! Үбешергә
Оялам мин.

Петруччо

Шулаймыни әле?
Алай булгач, тизрәк киттек өйгә!
Җайлы булыр анда өйрәнүе.

Катарина

Кирәк түгел, хәзер үбәм, бәгърем.

Петруччо

Шәп булды бу! Шәп, ие бит, җаным.
Соң булса да уң була күрсен, диеп
Юкка гына әйтмиләр шул аны.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Падуя. Люченцио йортындагы бүлмә. Баптиста, Винченцио, Гремио, Укытучы, Люченцио, Бьянка, Петруччо, Катарина, Гортензио һәм Тол хатын, Транио, Бьонделло һәм Грумио керәләр. Грумио һәм хезмәтчеләр
сый-нигъмәт алып керәләр.

Люченцио

Инде килеп, низаг-гауга бетте,
Килешендек күңел теләгәнчә.
Тынды сугыш. Элеккегә курку,
Өркүләрдән көләр чаклар килде. —
Чакыр, Бьянка, әткәемне, ә мин
Чакырырмын синең әткәеңне.
Кадер-хөрмәт булсын тиешенчә.
Катарина сеңлем, Петруччо туган,
Гортензио! Синең назлы җефетең! —
Бәйрәм итегез бер! Мин бик шатмын
Күрүемә сезне үз өемдә.
Хәзер шәраб, тәм-том китерерләр,
Утырышыйк. Сүзне дәвам итик,
Дәвам итсен гөрләп бәйрәмебез!

Табынга утыралар.

Петруччо

Утыр да аша, аша да утыр.

Баптиста

Шундый йола безнең Падуяда,
Кунакка сый мулдан гына булсын!

Петруччо

Сыйның шәбен таптык без биредә.

Гортензио

Безгә дә шул насыйп булсын иде.

Петруччо

Ант итәмен, бу Тол хатын өчен
Коты оча Гортензионың, әй!

Тол хатын

Сездән генә котым очмас минем!

Петруччо

Аңламадыгыз сез, мин бит әйттем,
Гортензионың сезнең янда чакта
Куркуыннан коты оча диеп.

Тол хатын

Исереккә дөнья әйләнчек шул.

Петруччо

Йомры җавап.

Катарина
(Тол хатынга)

Бусы нәрсә тагын?

Тол хатын

Тоттым мин моны!

Петруччо

Мине тотты бит! —
Сезнең Гортензио?

Гортензио

Синең сүз сөрешен тоткан бит ул!

Петруччо

Төзәтте бит!
(Тол хатынга.)
Үбегез иректезне.

Катарина

Исереккә дөнья әйләнчек шул...
Нәрсә әйтмәкче сез моның белән?

Тол хатын

Киребеткән хатыннан туйгач,
Сезнең җефетегез минем иргә
Нәкъ шундый ук әче язмыш юрый.
Аңладыгызмы соң инде хәзер?

Катарина

Чүп фикер бу.

Тол хатын

Сезне күздә тоттым.

Катарина

Әйе, сезнең белән якын булу —
Чүпнең чүбе булу белән бер ул.

Петруччо

Күрмәгәнен күрсәт, Кет!

Гортензио

Бирешмә, Тол!

Петруччо

Бәхәсләшә алам: минем песи
Хәзер аны сузып яткырачак.

Гортензио

Юк! Яткыру — анысы минем бурыч.

Петруччо

Шәп әйтелде! Синең саулыгыңа!

Гортензио белән чәкәшә.

Баптиста
(Гремиога)

Бу тел чарлаучыларга карата
Фикерегез ничек?

Гремио

Әйтсәм әйтим,
Читтә торсын сөзгәк үгезләрең.

Бьянка

Сезгә, имеш. Монда тел чарламый
Булмый инде, маңгаегыздагы
Мөгез үсәр урын кычытмыймы?

Винченцио

Яшь килен дә уянасы итте!

Бьянка

Борчылмагыз, тагын йоклармын мин.

Петруччо

Ә, юк инде! Сүздә чәкәләшү
Сездән башланды бит — инде без дә
Сезгә атып карыйк сүз укларын.

Бьянка

Киек кош мәллә мин? Очтым-киттем!
Хәлдән килсә, тотып карагыз сез.
Сүзләрегез берексен, синьорлар.

Бьянка, Катарина һәм Тол хатын китәләр.

Петруччо

Бушка җәя тартты ла, Транио.
Сез төбәгән идегез бу кошка.
Тик тидерә генә алмадыгыз,
Эчик әле әйдә, бергәләшеп,
Аткан угы кыек киткәннәрнең
Саулыгына!

Транио

Бәйдән ычкындырган
Ау эте урынында мин, синьор.
Куып тота алган кадәресен
Мин хуҗама илтеп тапшыручы.

Петруччо

Ярыйсы, тик синең чагыштыру
Бераз этләрский булып чыкты.

Транио

Яшь боланга мине өстердегез.
Ә ул сезне хәтта янына да
Якын җибәрми бит әнә, күрдек...

Баптиста

Әй-яй! Петруччо! Ямадымы сиңа!

Люченцио

Шәп төрттердең, рәхмәт, Транио.

Гортензио

Чынлап та, бик төз тидерде бит!

Петруччо

Көлке угы миңа тиеп китте,
Ә аннары читкә сикерде дә
Нәкъ менә сезгә барып кадалды.

Баптиста

Ни дисәң дә, улым Петруччо,
Синең хатының — иң тискәресе.

Петруччо

Юк, димен мин! Һәм мин раслармын
Хаклы икәнемне менә хәзер:
Без бәхәстән акча салыйк хәзер.
Чакыртып карасын һәркайсыгыз
Үз хатынын монда — шул чагында
Безгә мәгълүм булыр кем җиңгәне.

Гортензио

Мин ризамын. Күпмешәрдән киттек.

Люченцио

Егермешәр алтын.

Петруччо

Ник алай гына?
Ат белән эт өчен генә дә мин
Аннан күбрәк салып бәхәсләшәм.
Хәләл җефет өчен егерме кат
Кыйммәтлерәк булсын бәхәс хакы.

Люченцио

Ярый, йөздән киттек.

Гортензио

Хуш. Килештек.

Петруччо
Бата.

Гортензио

Ягез, кем башлый соң?

Люченцио

Мин башлыймын. Чакыр, Бьонделло,

Бикәң монда килсен!

Бьонделло

Киттем, хуҗам.
(Китә.)

Баптиста
(Люченциога)

Бьянка өчен ярты хакны, улым,
Үзем саныйм.

Люченцио

Нишләп? Үзем генә!

Бьонделло кире керә.

Йә, ни анда?

Бьонделло

Синьор, хуҗабикәм
Эшем күп, ди, килә алмый монда.

Петруччо

Эш күпме? Килә алмый, имеш.
Ай-яй җавап!

Гремио

Нишләп, миңа калса,
Ярыйсы ук ягымлы җавап бу.
Менә сезгә җавапның саллысын
Ишетергә туры килмәгәе.

Петруччо

Шәбрәгенә өмет тотам әле.

Гортензио

Һәй, Бьонделло, бар, әйт хатыныма,
Килә алмас микән минем янга?

Бьонделло китә.

Петруччо

Тыңламаса болай ялынганны!

Гортензио

Куркам, синьор, ялынып та хәтта
Сезнең янга килмәс сезнең хатын.

Бьонделло кире керә.

Ә хатыным кайда?

Бьонделло

Әйтте сезгә, вакыты бар икән,
Рәхәтләнеп тел чарласын, диде.
Килмим, диде. Сезнең үзегезне
Үз янына килергә ул кушты.

Петруччо

Харап хәлләр! Килми! Күрдегезме?
Моңа ничек чыдап тормак кирәк?! —
Һәй, Грумио! Әйт хуҗабикәңә
Монда килергә мин кушам аңа.

Грумио китә.

Гортензио

Җавап гади булыр.

Петруччо

Ә ничек соң?

Гортензио

Килә алмыйм.

Петруччо

Алай булса — бетте!

Баптиста

Йа Ходаем, Катарина килә!

Катарина керә.

Катарина

Дәштегезме, синьор? Нәрсә кирәк?

Петруччо

Әйтеп бирче, нишлиләр соң анда
Гортензио хатыны һәм Бьянка?

Катарина

Камин янында ләчтит саталар.

Петруччо

Сөйрәп китер аларны син монда!
Килмәсәләр — тип арт саннарына!
Әйтәм бит, бар, алар монда булсын!

Катарина китә.

Люченцио

Могҗиза юк, диләр... Бу — могҗиза!

Гортензио

Могҗиза да... Тик ни белән бетәр?

Петруччо

Мәгънә шунда: бу могҗиза безгә
Вәгъдә итә тынлык, куанычны,
Бер кулдагы ныклы хакимлекне
Һәм дә ипле генә буйсынуны.
Һәм, кыскасы, андый могҗизаны
Акыллылар бәхет диеп әйтә.

Баптиста

Инде бәхет яусын аңа, Петруччо.

Тәки оттың! Инде тегеләрнең
Оттырганы хисабына сиңа
Өстим янә егерме мең алтын.
Бөтенләй бүтән булган бит кызым —
Бирнәсе дә бүтәнчәрәк булсын!

Петруччо

Моннан күбрәк булыр минем отыш.
Сез күрерсез аның никадәрле
Тыңлаучанлыгын һәм күндәмлеген.
Әнә сезнең тискәреләрне ул
Хатын-кызга хас ихтыяр белән
Авызлыклап монда алып килә.

Катарина, Бьянка һәм Тол хатын керәләр.

Петруччо

Бу башлык сиңа килешми бит, Кет!
Ыргыт идәнгә бу аламаны.

Катарина башлыгын салып идәнгә ыргыта.

Тол хатын

Дучар булсам булыйм хәсрәтләргә,
Тик язмасын мондый ахмак булу!

Бьянка

Юләр генә шулай кыланадыр.

Люченцио

Сез дә шулай юләр булсагызчы!
Юкса сезнең әдәп аркасында
Йөз алтыннан колак какмый бүген.

Бьянка

Минем буйсынуга ышанып син
Бәхәсләшеп акча куйган булсаң —
Икеләтә ахмак икәнсең бит!

Петруччо

Кет, аңлатчы бу тискәреләргә
Иргә буйсынуның ни икәнен.

Тол хатын

Шаяртмагыз. Нигә безгә вәгазь?

Петруччо

Кыюрак, Кет! Нәкъ вәгазьдән башла!

Тол хатын

Булмаячак!

Петруччо

Ә мин булачак дим! Һәм ул сездән
Башлап җибәрәчәк!

Катарина

Абау, оят!

Ашыкма син кашың җырырга
Һәм иреңне явыз караш белән
Көйдерергә. Ирең синең өчен
Боеручы да ул, әфәнде дә.
Болыннарны кырау суккан сыман,
Хөсетлектән кибә чибәрлекләр.
Кем хуш күрер икән явызлыкны?
Чәчәк тажы җилгә сибелгәндәй,
Юкка чыгар бөтен күркәмлегең.
Усал хатын ул — болганчык чишмә.
Тәмам тамак кипкән чакларда да
Су эчүче булмас ул чишмәдән.
Ирең — хөкемдар ул һәм яклаучың,
Тормышың ул, уең, аңың, зиһенең.
Синең өчен ул һаман тир түгә
Ерак җирдә, диңгез эчләрендә,
Кичеп үтә давыл-тайфуннарны,
Син түшәктә изрәп яткан чакта.
Тик бер нәрсә кирәк аңа — сөю,
Синең мәхәббәтең! Күпме газап
Кичергәне өчен синең хакка
Тик рәхмәтең кирәк! Аның хезмәтенә
Арзан гына түләү бит бу юкса!
Язмышына ир ничек буйсынса —
Хатын аңа шулай тезен чүксен.
Әгәр хатын, тискәре һәм кире
Булып, баш бирмәсә иргә — димәк,
Юлбашчысын саткан түбән зат ул!
Хатын-кызның ахмаклыгы өчен
Оят миңа! Сугыш кирәк чакта,
Тез чүгәсез сез тынычлык сорап.
Инде юаш кына булыр чакта,
Баш буласы килә сез тинтәкнең!
Хатын-кыз нәфесе эшкә ашса,
Кереп чумар идек афәтләргә.
Табигатьтә камиллек соң нидә?
Ирләр көчле, без яклауга мохтаж.
Камиллек бит шунда! И мескеннәр!
Хәлсез суалчаннар! Мин дә менә
Сезнең сыман баш чөерер идем —
Мин дә тискәренең тискәресе —
Бер сүзенә мең сүз таба идем,
Гел талашыр идем туктамыйча.
Әмма ләкин шуны күреп торам,
Сөңге түгел — салам сыныгын без
Корал иткәнбез дә сугышабыз.
Ә бит, уйлап баксаң, хатын-кызлар
Көчсез булу белән көчлеләр бит.
Менә хәзер әгәр ирем кушса,
Әзермен мин ике уйламастан
Чәчем белән идән себерергә.

Петруччо

Менә хатын бу ичмасам! Килче,
Үп бер мине, җаным! Менә шулай!

Люченцио

Әйе, картлач, бәхетең бар икән.

Винченцио

Балаларның ата-ана сүзен
Сүз итүе — безнең өчен бәхет.

Люченцио

Әмма ләкин иң зур бәхетсезлек
Хатыннарның тискәрелегендә.

Петруччо

Җаныем Кет, ятар вакыт җитте.
Йә, дускайлар, икегез дә миңа
Оттырдыгыз бүген. Бәхетемә
Берегез дә ышанмаган иде.
Барыбер мин хаклы булып чыктым!
Тыныч йокы сезнең һәммәгезгә!

Петруччо белән Катарина китәләр.

Гортензио

Тез чүкте бит шундый тискәре дә —
Җиңү белән котлыйм сезне, синьор!

Люченцио

Әмма нигә ул җиңелде икән —
Шунсын гына менә аңлый алмыйм!

Китәләр.

РИЧАРД III

Тарихи драма

Биш пәрдәдә
Шәрәф Мөдәррис
ТӘРҖЕМӘСЕ

КАТНАШАЛАР:

Король Эдвард IV.
Эдвард — Уэльс принцы
Ричард — Йорк герцогы
Георг — герцог Кларенс
Ричард — герцог Глостер,
соңыннан король Ричард III
Генрих — граф Ричмонд, соңыннан король Генрих VII.
Кардинал Борчер — Кентербери архиепископы.
Томас Росергэм — Йорк архиепископы.

Джон Мортон — Элий епископы.
Герцог Букингэм.
Герцог Норфольк.
Граф Сэррей — аның улы.
Граф Риверс — Королева Елизаветаның туганы.
Маркиз Дорсет
Лорд Грэй
Граф Оксфорд.
Лорд Гэстингс — лорд-камергер.
Лорд Стэнли.
Лорд Ловел.
Сэр Томас Воган.
Сэр Ричард Рэтклифф.
Сэр Вильям Кэтсби.
Сэр Джемс Тиррель.
Сэр Джемс Блант.
Сэр Вальтер Герберт.
Сэр Роберт Брэкенбери — Товер коменданты.
Сэр Вильям Брэндон.
Сэр Кристофор Юрсвик — рухани.
Икенче рухани.
Лондон лорд-мэры.
Вильтшир шэрифы.
Королева Елизавета — Эдвард IV нең хатыны.
Маргарита — король Генрих VI ның тол хатыны.
Герцогиня Йорк — король Эдвард IV нең, Кларенсның һәм Глостерның әнисе.
Леди Анна — Генрих VI ның улы һәм Уэльс принцы Эдвардның хатыны, соңыннан герцог Глостерга иргә чыга.
Леди Маргарита Плантагенет — Кларенсның бәләкәй кызы.
Кларенсның бәләкәй улы.

Лордлар, сарай хезмәтчеләре, ике джентльмен, Йомышчы һәм Язгын, гражданнар, сарай палачлары, хәбәр ташучылар, өрәкләр, солдатлар һәм башкалар.
Вакыйга XV йөз ахырында Англиядә бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Урам.
Глостер керә.

Глостер

Хәзер безнең ызгышларның суык кышын
Шат күңелле бер җәй итте Йорк кояшы.
Токымыбыз өстендәге дөм болытлар
Төшеп батты тирән океан төпләренә.
Җиңү тажы хәзер безнең башыбызда, —
Янчелешкән коралларны чөйгә элдек.
Безнең шомлы, хәтәр үткән көннәребез
Әйләнделәр шат шау-шулы мәҗлесләргә;
Без үткән зур, куркынычлы авыр юллар
Әверелделәр баш әйләнгеч биюләргә.
Тигезләтте җыерчыклы йөзен сугыш, —

Ул да хәзер, дошманнарның йөрәгенә
Курку салып, иярләнгән атка менми, —
Җүләр сата чибәр леди бүлмәсендә,
Канны бутап чыңлаганда лира кылы.
Тик мин менә тумаганмын наянлыклар,
Шаянлыклар өчен диеп. Тик мин менә,
Көзге тотсам, карый алмыйм үзем сөеп.
Яралганмын дорфа булып һәм юк минем
Тәти кызлар каршысыннан көяз атлап
Үтәр өчен мәхәббәткә лаек ягым...
Гүзәл сынлы булыр җирдән кәрлә калып,
Табигатьнең мәкереннән кимсетелеп,
Тәмамланмый, вакыт җитми, гарип килеш
Фани дөнья күкрәгенә туганмын мин.
Яралганмын ашык-пошык, ярым-йорты, —
Шуңар менә бер гарип мин, бер хәчтерүш,
Мине күргәч, этләр хәтта улап кала!
Шулай булгач, тыныч көннәр ләззәтендә
Вакытымны ничек рәхәт үткәрим соң?
Әллә кояш яктысында җиргә төшкән
Хөрти шәүләм карый-карый уйланыймммы
Гариплегем, кәрләлегем турында гел?
Гашыйк булып танылмагач, бу шаулы һәм
Шат көннәрдә сизгәч үзем артык итеп, —
Карар бирдем ерткычлыгым күрсәтергә,
Бу рәхәт һәм шат көннәрне күралмаска!
Исрек баштан күрәзәлек иткән булып,
Күргән төшне юрау белән, нахак белән,
Шомлы ялган, кинаяләр сөйли-сөйли, —
Король белән туган абыем Кларенсны
Бер-берсенә кан дошманы итәр өчен
Көнен-төнен яшрен фетнә корып йөрдем.
Мин мәкерле һәм ялганчы булган төсле,
Әгәр тиз һәм төгәл булса Эдвард король, —
Кларенс бүген ташкапчыкка утырачак!
Чөнки сүз бар: имеш, тиздән «Г» хәрефе
Эдвард король варисларын юк итәчәк...
Зирәк уйлар, җыйналыгыз минем башка!
Тукта, менә монда таба Кларенс килә...

Брэкенбери, сакчылары белән Кларенс керә.

Саумы, туган. Корал тоткан бу сакчылар
Нигә синең гали затны саклап бара?

Кларенс

Галиҗәнап король мине саклау өчен,
Атам кебек нык кайгыртып, менә шушы
Юлдашларны бирде миңа Товергача...

Глостер

Соң, ни өчен?

Кларенс

Исмем Георг булган өчен.

Глостер

Китче, абый! Монда синең ни гаеп бар?
Утыртсыннар, кирәк икән, сиңа менә
Георг диеп исем кушкан кешеләрне!
Ах, бәлки, ул, галиҗәнап, шул Товерда
Яңабаштан миңа исем кушмакчыдыр?
Әйтче, Кларенс, хикмәт нидә? Мин дә белим!

Кларенс

Анысы була аның, Ричард, әгәр белсәм...
Тик үзем дә аңламыйм ич. Хикмәт шунда!
Беләм фәкать шуны гына: королебез,
Ишетеп төрле күрәзәлек, юрауларны,
Әлифбадан сызып аткан «Г» хәрефен.
Аңар килеп бер сихерче әйткән, имеш.
Шул «Г» белән тамырыгыз корыр, диеп.
Минем исмем Георг — «Г» дан башланганга
Газраилен мин дип уйлап йөри бугай.
Менә шундый сәер эшләр күтәргәндер
Миңа каршы король галиҗәнапларын.

Глостер

Әйе, шул, шул! Эшләр менә шуңар китә,
Ирләр шулай хатыннарга буйсынганда!
Товерга бит сине безнең король түгел,
Аның хатыны леди Грэй җибәрттерә!
Бел, Кларенс, хөкемдарны бу соң чиккә
Котыртучы — бары тик шул леди Грэй!
Ул да түгел, аның якын кан кардәше —
Ихтирамга лаек егет Антон Вудвилль! —
Гэстингсны тоткын итеп шул җибәртте.
Беләсеңдер, Товер дигән шул төрмәдән
Бүген генә чыгарылды лорд Гэстингс!
Хәтәр безгә монда, Георг, хәтәр безгә!

Кларенс

Валлаһи, хак! Кемгә монда хәтәр түгел?
Королева кардәшләре өчен фәкать!
Шор ханым һәм безнең король арасында
Көн-төн чапкан илчеләргә әйбәт монда!
Ишеткәнсең, түбәнчелек белән ничек
Гэстингсның Шордан ярдәм сораганын?

Глостер

Аңар баглап, итагатьле дога кылды, —
Шунда гына лорд-камергер азат булды!
Әйтим сиңа, мин шулай дип уйлап торам:
Калыйк дисәк әгәр король шәфкатендә, —
Тик бер юл бар: керик Шорга ялчы булып,
Киеп алыйк аның лакей киемнәрен.
Безгә хәзер кемнәр хуҗа? Шор ханым һәм

Ләпшердәгән көнче бер тол королева! —
Безнең абый шундыйларга башын игәч,
Хөкем йөртә илдә шушы гайбәтчеләр...

Брэкенбери

Гали затлар, гафу сорыйм, сөйләшмәгез.
Дәрәҗәсе кем булса да, тоткын белән
Һичбер нинди яшрен киңәш кормасын дип,
Бик нык итеп кушты миңа галиҗәнап.

Глостер

Ярый, бик хуп! Әйдә сез дә, Брэкенбери,
Катнашыгыз безнең уртак сүзебезгә.
Хыянәттән без бик ерак. Без сөйлибез,
Королебез саф күңелле һәм зирәк, дип.
Безнең данлы королева карт булса да,
Гүзәл, дибез, һәм, көнче дә түгел, дибез.
Миссис Шорның аяклары бигрәк нәфис,
Ирене — алсу, күзе — нурлы, сөйләгәндә
Шат күңелле, тәмле телле ханым, дибез.
Без сөйлибез, королева кардәшләре
Бар да хәзер аксөякләр булды, дибез.
Ни дисез, сэр? Моны кире кагарсызмы?

Брэкенбери

Анда минем бер генә дә эшем юк ич!

Глостер

Шор ханым да, эшем юк, ди! Алай дисәң,
Бер сер итеп, әйтим инде сиңа, егет:
Ул чакны бит аның белән тик бер кеше
Маташырга тиеш була ялгыз гына...

Брэкенбери

Кем ул, милорд?

Глостер

Аның ире. Белеп кал, эт!
Хәзер йөгер, минем өстән җиткер инде!

Брэкенбери

Сездән, герцог, мин тагын да гафу сорыйм,
Туктатыгыз тоткын белән сөйләшүне.

Кларенс

Боерык икән — буйсынабыз, Брэкенбери.

Глостер

Королева каршысында үги шул без, —
Буйсынырга мәҗбүр инде, нихәл итик?
Сау бул, туган. Мин корольгә барам хәзер.
Хәтта Эдвард хатынына җиңги диеп
Дәшү кебек кыен нәрсә кушсаң да син,
Сине азат итәр өчен барын эшлим!
Син, туганым, мәсхәрәгә төшкән өчен

Йөрәгемдә нинди тирән эз калганын
Күз алдыңа китермисең булыр хәтта!

Кларенс

Беләм, бу хәл сиңа да бик әйбәт түгел.

Глостер

Тоткын булып артык озак ятмассың син!
Коткарырмын сине, туган. Даным фида!
Тик сабыр ит, чыда азрак!

Кларенс

Нишлисең бит,
Ирексездән сабыр итәм. Сау бул, туган!

Кларенс, Брэкенбери һәм сакчылар чыгып китәләр.

Глостер

Бар, бар, атла. Кире кайту булмас инде!
Их, Кларенс! Беркатлы син, сабый бала!
Бу хәлеңдә миңа шундый сөйкемле син!
Әгәр миннән алса Ходай бүләк итеп, —
Синең җаның китәр тиздән җәһәннәмгә!
Чү, кем килә? Азат булган Гэстингсмы?

Гэстингс керә.

Гэстингс

Сәлам сезгә, хәерле көн сезгә, герцог!

Глостер

Исәнмесез, хәерле көн, лорд-камергер!
Бик шәп булды: хәзер инде сез иректә.
Тоткынлыкны ничек итеп кичердегез?

Гэстингс

Тоткыннарча түземлелек белән, милорд.
Яшим хәзер шәпләп рәхмәт әйтер өчен
Шушы хәлгә сәбәп булган адәмнәргә.

Глостер

Шик юк, шик юк. Шулай итәр Кларенс та!
Сиңа кемнәр — аңар да бит шулар дошман.
Сине алар мыскыллаган шикелле үк,
Ул да калды хәзер шундый мәсхәрәгә.

Гэстингс

Шунсы тагын: бөркет өчен кысан читлек,
Ә шул чакны тилгән йөри чебеш күзләп!

Глостер

Ни хәлләр бар җир йөзендә?

Гэстингс

Җир йөзендә
Хәлләр алай начар түгел. Өйдә — хөрти.

Король авырый, хәле начар, гел борчулы.
Табиблары аның өчен гел кайгыра...

Глостер

Изге Павел исеме белән ант итәм мин:
Яңалыклар чыннан да бик хөрти икән!
Беләм, ул кем король тәнен хәлсезләтә,
Тотып һаман усал рухлар тозагында!
Юк, бу хакта уйлау да шул бигрәк авыр!
Нәрсә, король түшәктәме?

Гэстингс

Түшәктә шул.

Глостер

Әйдә анда. Синең арттан мин дә барам.

Гэстингс китә.

Көне беткән, һич шөбһә юк! Тик үлмәс ул,
Кларенсны чаптар атта, бер йөк итеп,
Җибәрмичә теге дөнья тарафына.
Яхшы корган ялган белән, ышанырлык
Юк-бар белән тагын аның ярсуларын,
Кларенска нәфрәтләрен көчәйтермен.
Үзем казыган базга үзем төшмим икән,
Георг инде ярты көн дә тора алмас!
Ә аннан соң Эдвард галиҗәнапларын
Ходай Тәгалә алыр үзенең рәхмәтенә.
Минем өчен дөнья тагын иркен калыр!
Ә аннан соң алачакмын Варвик кызын!
Аның ирен мин үтердем. Аннан ни соң?
Карт атасын мин үтердем. Ни булган ди?
Ризалату өчен кызны — иң җайлы юл:
Аңар ир һәм әткә булып калу гына!
Шулай итәм. Сөяр өчен түгел ләкин!
Әлегә чаклы яшерен торган максатыма
Ирешә алам фәкать аңа өйләнгәчтен.
Тик төтенем уттан азрак алда чыга:
Кларенс әле һаман исән, Эдвард тере,
Тәхетендә утыра һаман король булып.
Шатланырмын хыял чынга ашкач кына,
Көндәшләрне юлдан алып аткач кына!
(Китә.)

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Икенче урам. Өсте ачык табутта король Генрих VI мәетен алып керәләр. Затлы кешеләрдән торган һәм айбалталар белән коралланган сакчылар табутны
саклап баралар. Леди Анна траур киемендә күмү мәрасимен озатып килә.

Леди Анна

Куегыз, куегыз, Ходай өчен, җиргә азрак
Саф намуслы шул табутны, әгәр намус,

Кәфенләнеп, тар табутка сыяр булса!
Төшерегез! Мин борынгы коллар төсле
Үкси-үкси яшем түгим — вакыт җитми
Һәлак булган Ланкастерлар йорты өчен!
Әй син, минем изге җанлы королемнең
Тимер төсле салкын булган мескен тәне!
Әй соры көл, җимерелеп җиргә ауган
Ланкастерлар токымының салкын көле!
Патшабызның каны беткән, җаны очкан
Иң соңгы бер истәлеге, рөхсәт бирче:
Газиз Аннаң тилмерүен тыңлар өчен
Чакырырга синең изге күләгәңне!
Сиңа менә шушы тирән җәрәхәтне
Калдыручы шул ук явыз кулдан үлгән
Улың Эдвард хатынының зарын ишет!
Яраң тора җаның очкан тәрәзәдәй, —
Түгәм шунда күзләремнән энҗе яшем,
Терелтергә соңга калган тере суын!
Нәләт, сине һәлак иткән кулга нәләт!
Нәләт, нәләт, синең изге йөрәгеңне
Тибүеннән туктатучы таш йөрәккә!
Синең канны кызганмаган канга нәләт!
Синең үлемең аркасында безгә килгән
Кайгылардан йөз-мең кабат авыр кайгы
Тап булсын ла каһәр төшкән бәдбәхеткә!
Күрсәтмәсен моны ләкин, җирдә яшәп,
Һәлак иткеч пычрак агу чәчеп йөргән
Чаяннарга, үрмәкүч һәм еланнарга!
Әгәр булса бер баласы — бала түгел,
Җитлекмичә коточкыч бер гарип тусын!
Аның шомлы, табигатькә ят бер төсе
Бер карауда әнкәсенең котын алсын, —
Бәхетсезлек өчен туган бала булсын!
Әгәр дә ул хатын алса, ул яшь хатын
Күрсен аның үлеменнән шундый газап:
Сөйгән ирем һәм син үлгәч, мин кичергән
Газаплардан йөз-мең кабат артык булсын!
Күтәрегез фәрештәләр исеме белән,
Изге Павел чиркәвеннән алып чыккан
Изге йөкне илтик әйдә Чертсигача, —
Иң лаек бер хөрмәт белән җирләр өчен!
Талчыксагыз, юлда тагын тукталырсыз, —
Ә мин тагын шул вакытны үксеп-үксеп
Яшь коярмын король Генрих табутына...

Алып баручылар табутны күтәреп китә башлыйлар. Глостер керә.

Глостер

Табутчылар! Бер адым да кузгалмагыз!
Төшерегез җиргә шуны!

Леди Анна
Чү, бу нинди
Бер кара көч килеп чыкты сихер белән

Туктатырга безне шулай изге юлдан?

Глостер

Сәләмәләр! Куегыз җиргә шул мәетне!
Изге Павел исеме белән ант итәм мин:
Кем тыңламый — шуның үзен мәет ясыйм!

Берәү

Әйдә, милорд, табут үтсен! Юл бир безгә!

Глостер

Өрмә, көчек! Боерам сиңа: тик кенә тор!
Ант итәм мин изге Павел исеме белән:
Менә минем күкрәгемнән биек итеп,
Күтәрәсең икән хәзер айбалтаңны,
Сугып егып, җиргә салып, басып изәм
Базынганың өчен шулай, ертык сукбай!

Алып баручылар табутны җиргә куялар.

Леди Анна

Чү, нәрсә сез? Калтырыйсыз? Курыктыгыз?
Ah, юк, хәер, үпкәләмим. Чөнки бит сез
Тере җаннар. Тере җанның күзе hич тә
Мондый дәҗҗәл карашына чыдый алмый.
Шомлы тәмуг карачкысы, югал моннан!
Хаким булдың менә шушы үлек тәнгә,
Ләкин аның җаны инде сиңа булмас!
Югал моннан!

Глостер

Әй хур кызы, зинhар, болай
Каргамачы!

Леди Анна

Кит алдымнан! Кит, аждаhа!
Ходай өчен, зинhар, безне борчыма син!
Якты җирне елау-каргыш тавышлары
Яңгыраган тәмуг итеп торасың син!
Сокланасың килсә, явыз, кылганыңа, —
Кара менә ерткычлыгың корбанына!
Гали затлар, карагызчы, карагызчы, —
Ачыла менә мәрхүм Генрих ярасының
Күгәренеп, катып калган чит-читләре!
Күрегезче, ничек аннан кан саркыла!
Кил, күр, кызар, явыз җанлы бөкре күсәк,
Син килгәч тә ташып чыкты аның каны
Суынып беткән, бушап калган тамырыннан!
Кешелексез, коточкыч бу явызлыгың
Үзең килгәч, сәбәп булды канның шулай
Җәрәхәттән могҗизалы саркуына...
Әй бер Аллам, шушы канны яраткан син —
Мәрхәмәтсез үч ал аның үлеме өчен!
Әй кара җир, аның канын суырган син —

Кызганусыз үч ал аның үлеме өчен!
Әй кара җир, йот син шушы кабахәтне,
Королемнең затлы канын йотканың күк!
Әй күк йөзе, яшен суксын шул мөртәтне,
Хөкемдарга канлы кулын сузган өчен!

Глостер

Белмисең син изгелекнең кануннарын!
Ә соң, леди, яманлыкка яхшы белән,
Нәләтләүгә гафу белән җавап бирсәң?

Леди Анна

Сиңа, явыз, Алла да юк, бәндә дә юк, —
Ерткыч — усал, ул да белә мәрхәмәтне.

Глостер

Ә мин белмим. Чөнки исемем ерткыч түгел.

Леди Анна

Менә гажәп! Шул дәҗҗәл да дөрес әйтә.

Глостер

Гажәбрәге — фәрештәләр нинди усал!
Рөхсәт ит син, әй хур кызы, минем өскә
Син белмичә аткан барлык гаепләрдән
Күз алдында вөҗдан белән акланырга!

Леди Анна

Рөхсәт ит син, череп беткән йогышлы җан,
Миңа кылган явызлыкның барсы өчен
Син нәләтне тагын бер кат нәләтләргә!

Глостер

Мактар өчен тел җитмәслек гүзәл леди!
Гафу итәр дигән өмет калдыр миндә!

Леди Анна

Каргар өчен сүз җитмәслек гарип өтек!
Гафу көтмә, бар, үз үзең буып үтер!

Глостер

Алай булгач, үземә үзем гаеп тагыйм?

Леди Анна

Шулай булгач, үзеңә үзең җәза да бир!
Башкаларны кешелексез үтерә белдең.

Глостер

Шуны әйт син: мин аларны үтермәдем.

Леди Анна

Син шуны әйт: ничек, алар үлмәгәнме?
Алар вафат. Синең эш бу, кабахәт җан!

Глостер

Юк, мин сезнең ирегезне үтермәдем.

Леди Анна

Менә ничек! Алай булгач, исән инде!

Глостер

Юк, ул үлде. Әмма бу эш — Эдвард кулы.

Леди Анна

Ялганлыйсың шуны пычрак авызыңнан!
Синең үткен, хыянәтчән хәнҗәреңнең
Йөзе буйлап аның каны саркып аккан;
Королева Маргарита күреп торган.
Син аңа да чәнчәм диеп кизәнгәчтен,
Туганнарың, синең кулга ябышып кына,
Хәнҗәр очын читкә таба этәргәннәр.

Глостер

Мин ул чакта аның нахак сүзләреннән
Үз-үзем дә белмәс булдым. Үзләренең
Гаепләрен миңа такты Маргарита.

Леди Анна

Ул чак сине фәкать канлы ниятләрең
Чыгырыңнан чыгаргандыр. Андый ният
Палачларда бер минут та сүнеп тормый.
Ә соң король синең кулдан кичмәдеме?

Глостер
Ярый, риза.
Леди Анна

Ризамыни син дә, керпе?
Бер Хода да минем белән риза булсын:
Нәләт төшсен сиңа канлы эшең өчен!
Нинди юмарт, яхшы җанлы, шат иде ул!

Глостер

Ожмах өчен шундый кеше кирәк тә шул!

Леди Анна

Урыны — җәннәт. Сиңа анда мәңге юл юк!

Глостер

Рәхмәт әйтсен үзен анда җибәргәнгә.
Җирдә аның бер эше юк. Андый тәкъва
Ожмах өчен кирәклерәк!

Леди Анна

Ә син, явыз,
Җәһәннәмнән бүтән җиргә ярамыйсың!

Глостер

Бер урын бар. Тик кайда дип сорагыз сез.

Леди Анна

Төрмәдәме?

Глостер

Сезнең йокы бүлмәгездә.

Леди Анна

Нәләт төшсен синең торган почмагыңа!

Глостер

Синең белән икәү анда йоклаганчы
Төшә торсын.

Леди Анна

Бирсен Ходай.

Глостер

Шулай булсын.
Ләкин әйдә, гүзәл җанлы леди Анна,
Үткен телле бәхәсләрне ташлап торып,
Тыныч кына берәр нәрсә хәл итик без.
Ни уйлыйсыз, Плантагенет, Генрих белән
Эдвардыңны берәү, әйтик, канга сусап,
Ерткычларча үтерә икән — моның өчен
Юк микән соң ни булса да берәр сәбәп?

Леди Анна

Сәбәп — син һәм синең кара ниятләрең.

Глостер

Сәбәп булды моңар синең гүзәллегең,
Төшемә кереп газаплаган чибәрлегең.
Җир йөзендә мин һәммәсен кырыр идем,
Күкрәгеңә бер тын гына баш куйыйм дип.

Леди Анна

Уема гына килсә дә, — әйтим сиңа, —
Йөземдәге матурлыкны менә шушы
Тырнакларым белән кырып ташлар идем!

Глостер

Синең шушы гүзәллегең хур булганын
Күреп торып, минем күзем чыдый алмас, —
Мин бар чакта мәңге булмас андый нәрсә!
Күктә кояш нурлый ничек бар дөньяны —
Нурлый мине шулай синең матурлыгың!
Якты көнем, тереклегем — гел шул гына!

Леди Анна

Караңгы төн каплап китсен синең көнне,
Үлем алсын синең харәм тереклекне!

Глостер

Син үз-үзең нәләтлисең, чибәр кызый,
Минем көнем, тереклегем — син үзең ич!

Леди Анна

Шулай булса, үчем тизрәк алыр идем.

Глостер

Сине сөйгән гашыйк җаннан үч алам дип
Янап тору бер сәер эш түгел микән?

Леди Анна

Үтерелгән ирем өчен үч алам дип
Янап тору бик мәслихәт, гадел эш ул!

Глостер

Сине ирдән мәхрүм иткән шушы кеше
Табып бирер сиңа аннан яхшырагын.

Леди Анна

Аннан яхшы мәңге тумас, туса — тормас.

Глостер

Андый кеше дөньяда бар. Һәм ул сине
Аннан ныграк сөеп йөри.

Леди Анна

Исеме ничек?

Глостер

Плантагенет.

Леди Анна

Ничек инде? Эдвард ич ул!

Глостер

Бу да шул ук Плантагенет. Тик шәбрәге.

Леди Анна

Кайда соң ул?

Глостер

Менә монда. Синең алда.

Леди Анна аның өстенә төкерә.

Чү, чү, леди, нигә миңа төкерәсең?

Леди Анна

Агу булып төшсен икән синең өскә!

Глостер

Мондый нәфис иреннәрдән агу чыкмый.

Леди Анна

Мондый явыз еланнарны агу алмый.
Югал моннан, күз алдымнан! Синең төсең
Минем күзгә үләт йога.

Глостер

Чибәр леди!
Синең күздән миңа инде гыйшык йокты.

Леди Анна

Кара елан булса икән минем күзем —
Баскан җирдә сине чагып үтерерлек!

Глостер

Булсын гына! Мин дә бик тиз үләр идем.
Синең күзләр, сихер белән әсир итеп,
Тере килеш үтерә мине! Күпме алар
Агыздылар ачы яшьне минем күздән!
Булды ул яшь — оялтучан һәм бертоташ
Тамчы-тамчы тамып торган сабый яше!
Кайгы чигеп, тәүбә итеп, күзләремнән
Тамчы яшь тә агызмаган кеше идем...
Шашкан Клиффорд кылычыннан җан биргәндә,
Безнең Рутлэнд үзәк өзгеч кычкыргачтын,
Эдвард белән әтием Йорк үксеп-үксеп
Яшь түктеләр. Мин шунда да еламадым.
Синең әтиең, батыр бер ир, сөйли иде
Минем әткәм кайда, ничек үлгәнлеген;
Шул кайгылы хикәясен һәр сүз саен
Бүлә-бүлә сабыйларча елый иде.
Яфраклардан җиргә яңгыр тамчылары
Коелгандай, шунда торган кешеләрнең
Битләреннән энҗе яшьләр агыла иде.
Мин шунда да еламадым. Чөнки миңа
Тамчы яшь тә хурлык кына булыр иде.
Минем шундый кайгылардан яшь коймаган
Күзем хәзер күреп синең күркәмлекне, —
Томанланып калды кайнар яшьләр белән.
Мин дуска да, дошманга да тез чүкмәдем,
Һичбер вакыт назлы сүзләр сөйләмәдем.
Ләкин хәзер сусыйм синең гүзәллеккә.
Синнән минем горур йөрәк җавап көтә,
Телем ашыга сүзен тизрәк әйтер өчен.

Леди Анна аңа нәфрәт белән карый.

Нәфрәт белән кысма шулай иреннәрең,
Чөнки алар үбешү өчен яратылган!
Җитәр инде, йөзең чытма шулкадәрле!
Чибәр леди, әгәр синең мәрхәмәтсез
Таш йөрәгең кичерүне белми икән, —
Менә, кара, минем кулда үткен кылыч:
Сорыйм синнән, ал да шуны, када минем
Сиңа мәңге тугры булган йөрәгемә, —
Мә, ал минем сине сөйгән саф җанымны!
Чәнеч әйдә, ачам менә күкрәгемне, —
Тез өстендә сиңа ялынып үлем сорыйм!

Глостер күкрәген ача, леди Анна аңа чәнчергә омтылыш ясый.

Туктап торма, мин Генрихны һәлак иттем,

Сәбәп булды моңа синең матурлыгың!
Куркып торма, Эдвардыңны мин чәнечтем.

Леди Анна аңа яңадан чәнчемәкче була.

Моңар сәбәп — мин яраткан син — фәрештә!

Леди Анна кылычны җиргә ташлый.

Ал кылычны яки кил дә мине ал син!

Леди Анна

Тор, ялганчы! Үлемеңне бик телим дә,
Ләкин үзем үтерәсем килми сине...

Глостер

Бер генә әйт — үз-үземне юк итәм мин!

Леди Анна

Әйттем инде.

Глостер

Анысы аның ярсу белән.
Тагын бер әйт! Миңа җитә бер сүзең дә!
Сиңа булган мәхәббәтем өчен синең
Мәхәббәтне һәлак иткән шушы кулым
Сиңа булган мәхәббәтем өчен хәзер
Аннан зуррак мәхәббәтне һәлак итәр!
Болар өчен син сәбәпче булачаксың!

Леди Анна

Йөрәгеңдә нәрсә барын белсәмче...

Глостер

Телем әйтте анда нәрсә булганын.

Леди Анна

Ялганлыйдыр йөрәгең дә, телең дә.

Глостер

Минем кебек туры кеше бар микән?

Леди Анна

Ярый, ярый, кылычыңны кынга тык.

Глостер

Син әйт инде, кичердеңме, беттеме?

Леди Анна

Моны инде бераз соңрак белерсең.

Глостер

Күңелемнән өметләнеп торыймммы?

Леди Анна

Беләсеңдер, шайтан гына өметсез.

Глостер

Бүләк итсәм әгәр шушы йөзекне?

Леди Анна

Алсам алыйм, әмма көтмә үземнән.

Йөзекне бармагына кидерә.

Глостер

Кара, ничек минем йөзек, әйбәт итеп,
Бармагыңны кочып алды! Шулай беркөн
Минем йөрәк калыр синең кочагыңда!
Кабул итеп алчы миннән син аларны, —
Йөзегем дә, йөрәгем дә тик синеке!
Итагатьле колың булып, синнән тагын
Тик бер нәрсә үтенергә рөхсәт итче, —
Мәңге-мәңге мин бәхетле булыр идем...

Леди Анна

Нәрсә тагын?

Глостер

Синнән шуны сорар идем:
Король җирләү кебек авыр вазифаны
Миңа калдыр. Аның өчен һәр кешедән
Күбрәк итеп яшь түгәргә тиешмен мин.
Ә син үзең юнәл хәзер Кросби-плацка.
Зур тантана, хөрмәт белән Чертсидагы
Монастырьга күмгәч бөек королемне, —
Чын күңелдән тәүбә итеп, яшем белән
Аның салкын кабер ташын юармын мин.
Аннан бик тиз синең янга йөгерермен!
Моның әлегә яшерен булган сәбәбе бар.
Мин ялварып сорыйм, леди, риза булчы!

Леди Анна

Риза, риза, чын күңелдән. Сине шулай
Тәүбә иткән килеш күреп шатланам мин!
Трессель, син, Беркли, син дә минем белән!

Глостер

Миңа «Сау бул» диген инде.

Леди Анна

Синең өчен
Күбрәк хөрмәт булмас микән? Әгәр инде
Мине шулай җиңде икән төче телең, —
Хушлаштык дип фараз итик.

Леди Анна, Трессель һәм Беркли чыгып китәләр.

Глостер

Әй, кешеләр!
Күтәрегез мәетне әйдә!

Берәү

Чертсигамы?

Кая, милорд?

Глостер

Анда түгел, Вейт-Фрайрска!
Мин килгәнче, шунда көтеп торырсыз сез.

Алып баручылар табутны күтәреп чыгып китәләр.

Кайсы хатын шулай уйнап яучыланган?
Нинди хатын шулай уйнап кулга төшкән?
Ул — минеке! Тик мин аны озак тотмам!
Гаҗәп! Ирен һәм әткәсен мин үтердем
Һәм бирегә килеп чыктым шундый чакта:
Йөрәгендә каты нәфрәт кайный иде, —
Күзе — яшьле, телендә гел каргыш иде.
Шунда гына канын сыгып мәет тора!
Бер Ходай да, леди Анна вөжданы да,
Бар да, бар да минем алда киртә иде,
Кулай булган дусларым да юк иде бит!
Карашымда булды фәкать хәйлә, мәкер,
Күңелемдә булды Иблис ниятләре...
Яулап алдым хәзер үзен! Бу дөньяда
Һичкем миңа һичнәрсә дә эшли алмас!
Һа!
Шулай ук соң хәтеремнән чыкты микән
Аның батыр һәм яшь ире? Өч ай элек
Тьюксбери төпләрендә ярсуымнан
Хәнҗәр кадап мин үтергән Эдвард принц?
Фәрештәләр «амин» дигән чакта туган,
Шундый матур, мәхәббәтле, затлы булган
Яшь, нык, батыр, иң лаек бер чын корольне
Бу киң дөнья инде бик тиз бирә алмас!
Ә бу хатын күзен хәзер миңа төби, —
Миңа төби — бәхетенең яшь чәчәген
Чабып өзгән, үзен яшьли тол калдырып,
Түшәгеннән ирен алган бер кешегә!
Миңа төби — затлылыкта Эдвард белән
Һич тә, һич тә тиң килмәгән бер адәмгә!
Миңа төби — гарип туган бер чатанга!
Бәхәс өчен куям бөтен биләмәмне, —
Куегыз әйдә моңа каршы сукыр тиен:
Үз-үзем мин белми генә йөрим икән!
Чәчрәп китим, үзем белмим, ә ул күргән:
Искиткеч бер чибәр егет икәнмен мин!
Булды хәзер, карыйм көзге табу ягын!
Тегүчеләр кирәк булыр егермеләп, —
Шәп фасонга бизәсеннәр буй-сынымны!
Әгәр шулай матур булып киттең икән,
Кызганмаска кирәк булыр кием өчен.
Ләкин алдан каберенә салыйм шуны;
Аннан соң мин, күзләремнән яшем коеп,
Сөйгән ярым, синең янга юнәлермен!
Көзгем юкта, балкы, кояш, нурың тарат!
Күләгәмне күрим мин гел җиргә карап!

(Китә.)

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Король сараендагы бер бүлмә. Королева Елизавета, Риверс һәм Грэй керәләр.

Риверс

Сабыр итик, королевам. Әүвәлгедәй
Сау-сәламәт булыр тиздән галиҗәнап.

Грэй

Сезнең кайгы аңар фәкать зарар гына.
Ходай өчен, савыгыр дип өмет итик, —
Юатыйк үзен кызык-кызык сүзләр белән.

Елизавета

Ах, ул үлсә, газиз башым ниләр күрер!

Грэй

Ирегезне югалтырсыз, тик шул булыр.

Елизавета

Бөтен-бөтен югалтулар шуңа керә!

Грэй

Тәңре сезгә бүләк итте шәп бер улны,
Король үлсә, калыр сезгә терәк булып.

Елизавета

Ах, ул яшь шул! Аның чәчәк яшьлегенә
Ричард Глостер сакчы итеп билгеләнде,
Ул мине дә һәм сезне дә күрә алмый...

Риверс

Глостер безнең хаким булып калдымыни?

Елизавета

Әлегә юк та... Ләкин инде хәл ителгән.
Әгәр король терелмәсә, шулай булыр.

Букингэм белән Стэнли керәләр.

Грэй

Лорд Букингэм, лорд Стэнли килә менә.

Букингэм

Хәерле көн сезгә, затлы королевам!

Стэнли

Кайтса иде сезгә тагын шат чагыгыз!

Елизавета

Лорд Стэнли, тик графиня Ричмонд, әнә
Яхшы сүзең хуплап, «амин!» дияр микән?
Шулай, Стэнли. Синең хатын булса да, ул
Мине сөйми. Әмма, милорд, ышан миңа:
Сине һич тә дошман итмим. Хатының гел

Кәперенеп, борын чөеп йөри бирсен!

Стэнли

Сорыйм сездән, җыен көнче-гайбәтчеләр
Аңар аткан гаепләргә ышанмагыз!
Алар сүзе, әйтик, бераз хак булса да,
Кичерегез аның йомшак якларын сез.
Тик бу гадәт усаллыктан түгел һич тә,
Үзенә күрә тискәрелек чиредер, дим.

Елизавета

Бүген, Стэнли, сез корольне күрдегезме?

Стэнли

Без Букингэм белән икәү хәзер генә
Король галиҗәнапларын күреп чыктык.

Елизавета

Ничек, лордлар, терелүенә өмет бармы?

Букингэм

Бар, бар, ханым. Галиҗәнап бик шат иде.

Елизавета

Ходай аңар саулык бирсен! Аның белән
Сөйләшеп тә чыктыгызмы?

Букингэм

Бик шәп итеп!
Герцог Глостер белән сезнең туганнарның,
Лорд Гэстингс белән сезнең туганнарның
Татулыгын теләп тора галиҗәнап, —
Һәммәсен дә хәзер үзенә дәшеп калды.

Елизавета

Килешсәләр, бик шәп тә бит! Юк ла, булмас!
Куркам. Упкын кырыенда — безнең бәхет...

Глостер, Гэстингс һәм Дорсет керәләр.

Глостер

Алар миңа гадел түгел! Чыдый алмыйм!
Күр син, алар хөкемдарга ни дигән бит:
Мин бер тупас, кеше сөймәс кеше, имеш!
Ант итәм мин изге Павел исеме белән:
Ташып торып җыен ялган, юк-бар гайбәт,
Алар бик аз хөрмәтлиләр корольне дә!
Табан ялау, назлы сүзләр, ялган хисләр,
Француз чалап көяз, төче кыйланулар,
Маймылларча якланулар юк шул миндә!
Шуңар мине дошман итеп саныйлар да!
Гадел кеше хәвеф-хәтәр уйламыйча
Һич кенә соң тыныч тора алмыймыни?
Нигә аның сабыйларча саф күңелен
Рияланган узгынчылар мыскыллыйлар?

Грэй

Сезнең бу сүз кем хакында, затлы милорд?

Глостер

Синең хакта! Синдә зат та, намус та юк!
Әйт син миңа: кайчан сиңа зарар иттем?
Сиңа кайчан? Сиңа кайда? Яки сезнең
Әшнәләргә кайчан иттем бер начарлык?
Берәм-берәм үләт кырсын һәммәгезне!
Галиҗәнап азрак иркен тын алса да, —
Йөгерәсез чүп-чар белән борчыр өчен.
Күпме генә сез начарлык теләмәгез —
Раббым Алла иминлектә саклар аны!

Елизавета

Туганкаем Глостер! Синең сүзең ялгыш.
Король һич тә читләр зары белән түгел,
Үзенең гали ирке белән хөкем йөртә.
Аңар, бәлки, синең миңа, балаларга,
Туганнарга каршы бөтен эчке керең,
Барлык тышкы кыйланышың күренәдер.
Шуңар да ул, сезне җыеп, алдыгызда
Ызгышларның сәбәпләрен ачмакчы да,
Андый юк-бар нәрсәләрне юк итмәкче.

Глостер

Телем бармый! Ай-һай, дөнья хөрти хәзер!
Каракошлар куна алмый торган җирдә
Черик-черик чыпчык йөри хуҗа булып.
Очраган бер шакшы олтан солтан булды,
Солтаннарың калды хәзер олтан булып...

Елизавета

Туганкаем Глостер, сине бик аңлыйбыз:
Күрәм, миннән, дусларымнан көнләшәсең.
Шөкер, әле дә сиңа мохтаҗ түгелбез без!

Глостер

Ә без менә, Ходай кушып, сезгә мохтаҗ!
Сез әйткәч тә безнең Георг утыртылды.
Минем исемем мыскылланды. Асыл затлар
Мәсхәрәгә дучар булды. Башкаларны
Баш әйләнгеч биеклеккә күтәрәсез.
Берәр көннән инде алар асыл затлы
Аксөякләр булып китә, түрә була...

Елизавета

Җаным тыныч, күңелем шат бер вакытта
Королева итеп, мине утка салган
Тәңре шаһит! Король галиҗәнапларын
Кларенска каршы һич тә котыртмадым, —
Киресенчә, аны гел мин яклап килдем.
Ә син, милорд, шушы пычрак шикләреңне

Миңа ташлап, гөнаһсыздан мыскылладың.

Глостер

Ә син, бәлки, күптән түгел Гэстингсны
Утыртканың танырга да булдырырсың?

Риверс

Булдыра ул, милорд. Чөнки...

Глостер
Булдыра шул!
Кем соң аны шулай дими, лорд Риверс?
Моны гына инкарь итү түгел, хәтта
Аннан зуррак нәрсәне дә булдыра ул.
Ул булдыра сезгә гел-гел булышуны,
Торган саен биегрәккә үрләр өчен.
Һәм, үзенең ярдәм кулын инкарь итеп,
Үзе биргән титулларга, имеш, сезнең
Хезмәтегез лаек диеп күрсәтә ул.
Ул ни генә эшли алмый? Ул булдыра...
Ул булдыра яшь кияүгә чыгарга да...

Риверс

Нәрсә дисез? Нинди кияү?

Глостер

Нинди кияү?
Чибәр генә, яшь кенә бер буйдак король!
Синең әбиең ирдән әмма уңмый калды.

Елизавета

Милорд Глостер, җитәр инде, миңа булган
Синең тупас каһкаһаңа күп чыдадым, —
Мине һәр көн зәһәр итеп хурлавыңа
Озак түздем! Сәгать саен өскә яуган
Шундый дорфа гайбәтләрне ник күтәрим?
Биллəһи, дим, әйтәчәкмен королемә!
Кичергәнче оят, хурлык, мәсхәрәне,
Җанга үткән ызгыш-талаш давылларын;
Күтәргәнче бөек королева исемен, —
Булса идем авылда бер асрау хатын!
Англиядә король хатыны булуыңның
Шатлыклары бик аз икән...

Королева Маргарита керә.

Маргарита

(үзалдына)
Раббым Аллам
Шул азны да кимсетсәче, теләк телим!
Дәрәҗәң дә, дәүләтең дә, тәхетең дә
Сиңа түгел, алар барсы миңа тиеш!

Глостер

Менә нәрсә! Король белән куркытасың!
Сөйлә әйдә, түкми-чәчми барын җиткер!
Яхшы тыңла: монда ниләр әйткән булсам,
Дөресләрмен шуны король алдында да!
Бәлки, барып, Товерга да эләгермен...
Ни дисең соң, онытылгач хезмәтләрең!

Маргарита
(үзалдына)

Беләм, дәҗҗәл, хезмәтләрең хәтеремдә!
Син Товерда һәлак иттең Генрихымны,
Тьюксберида — газиз улым Эдвардымны!

Глостер

Ирең — король, үзең — бөек королева
Булганчыга хәтле барсы исеңдәдер:
Йөк атыдай йөрдем аның хезмәтендә!
Аның күпме борын чөйгән дошманнарын
Тамырыннан йолкып аттым, дусларына
Юмарт итеп күпме бүләк өләштем мин!
Аның канын патша каны итәр өчен
Үз каным да аз түкмәдем мин ул вакыт!

Маргарита
(үзалдына)

Аныкыннан, синекеннән мең мәртәбә
Изге булган канны да син аз түкмәдең!

Глостер

Ә шул вакыт син һәм синең ирең Грэй
Ланкастерлар йорты өчен фетнә корып
Маташтыгыз. Лорд Риверс, сез дә шунда!
Әйтче миңа, Сент-Альбанс кырындагы
Маргарита башлаган бер бәрелештә
Синең ирең нәрсә өчен үтерелде?
Онытмагыз, мин төшерим исегезгә!
Кем идегез, инде хәзер кем булдыгыз?
Мин кем идем, бүген калдым нәрсә булып?

Маргарита
(үзалдына)

Канечкеч бер палач идең, хәзер дә шул!

Глостер

Әнә Кларенс, мескенкәем, каенатасы
Варвикны да тотып сатты, антын бозды.
Пәйгамбәре Гайсә үзен гафу итсен!

Маргарита
(үзалдына)

Аллаһ аңар җәза бирсен!

Глостер

Әйе, Кларенс
Синең Эдвард кул астында күп сугышты,
Аңар тажны алып бирде. Әҗере нәрсә?
Бичара лорд, әҗере хәзер төрмә аңар!
Бер Ходайдан шуны сорыйм: минем йөрәк
Эдвардныкы төсле корыч булса икән!
Һич булмаса, аның салкын таш йөрәге
Минекедәй нечкә, йомшак булсын иде!
Юк, дөньяда сабыйларча җүләр шул мин!

Маргарита
(үзалдына)

Бу дөньяны калдыр да син, хур булырга
Олак тизрәк җәһәннәмгә, явыз шайтан! —
Шунда урыныңда, шунда синең патшалыгың!

Риверс

Милорд Глостер, монда безне дошман диеп
Исбат итеп маташсаң да барып чыкмас!
Дау-гаугалы ул көннәрдә безне алга
Чын хуҗабыз, таҗ-тәхетле король илтте.
Әгәр король сез булсагыз, без шулай ук
Сезнең арттан бара идек.

Глостер

Һем, мин дисең!
Мин, ичмасам, булам шунда бер асламчы,
Корольлегең күңелемнән ерак йөрсен!

Елизавета

Шулай, Глостер, сизәсездер, король булу
Сезгә дә шул бик кечкенә шатлык икән!
Инде хәзер күз алдына китерегез:
Королева булу миңа зур бәхетме?

Маргарита
(үзалдына)

Бик кечкенә! Чөнки мин ул королева!
Әмма үзем тәхетсез дә, бәхетсез дә!
Юк, мин болай артык һич тә чыдый алмам!
(Алга чыга.)
Тыңлагыз сез, әй ызгышкан юлбасарлар!
Минем кулдан талап алган нәрсәләрне
Бүлешә алмый якалашкан килмешәкләр!
Кайсыгыз соң мине күреп калтыранмый?
Мин тәхеттә чагымда сез, яран булып,
Бил бөктегез. Мине бәреп төшергәч, сез
Фетнәчеләр төсле хәзер дерелдисез!
Йөзең борма, әй син, ерткыч галиҗәнап!

Глостер

Чү, ни дисең син, убырлы явыз карчык?

Маргарита

Хәтерләтәм синең кылган гөнаһларың,
Шунсыз сине күз алдымнан җибәрмәм мин!

Глостер

Монда кайту үлем сиңа. Син сөрелгән!

Маргарита

Сөрелсәм соң! Үз йортымда килә торган
Үлемнән дә зур җәза юк ул сөргендә!
Минем улым, ирем өчен син җаваплы,
Патшалыгым өчен минем син бурычлы!
Шулай итеп, кол сез миңа һәммәгез дә!
Хаклы сез тик мин кичергән кайгыларга,
Алдыгыз сез талап минем шатлыкларны!

Глостер

Сиңа минем газиз әткәм нәләт әйтте:
Аның горур, ут-су үткән карт башына
Мыскыл итеп кәгазь тажы кидердең син.
Синең бөтен мәсхәрәңә чыдый алмый
Күзләреннән елга-елга яшь акканда,
Кайнар яшен сөртәр өчен герцогка син
Сабый җанлы Рутлэндыбыз каны белән
Сугарылган сәләмә бер яулык аттың!
Аның шунда йөрәгеннән әрнеп чыккан
Каргышлары синең өскә төшеп калды.
Синең бөтен канлы эшең, гаебең өчен
Җәза бирү бездән түгел, бер Ходадан!

Елизавета

Тәңре гадел, гаепсезне тик ул яклар!

Гэстингс

Шул сабыйны үтерү кебек рәхимсез һәм
Пычрак эшне кем күргән дә, кем ишеткән?

Риверс

Шушы хәлне ишеткәчтен, ул вакытны
Канечкечләр үзләре дә еладылар!

Дорсет

Һәркем шунда тик үч кенә теләп торды.

Маргарита

Һа, сез ничек! Кара, кара! Мин килгәндә,
Бугазыгыз чәйнәшергә әзер торып,
Тарткалаша идегез ич! Ә соң хәзер
Чагагызны миңа таба бордыгызмы?
Әллә соң сез Йоркның шомлы каргышлары
Хак язганнан өстен диеп уйлыйсызмы?
Генрихымның һәлакәте, сөйгән улым
Эдвардымның һәләкәте һәм аларның
Тәхетеннән коры калып, минем хәзер

Тол хәлемдә сөргенлектә йөрүләрем
Азгын малай Рутлэнд өчен җәзамыни?
Әгәр каргыш, болытларны ярып кереп,
Җитә алса ерак-ерак күккә чаклы, —
Кара болыт, юл бир минем каргышыма!
Безнең король үлде палач хәнҗәреннән,
Сезнең король сугыш мәйданында түгел,
Шартлап үлсен бирән булып тыгынудан!
Сезнең хәзер Уэльс принцы булган Эдвард
Уэльс принцы булган безнең Эдвард өчен
Яшьли үлсен шул ук хәтәр үлем белән!
Син — хәзерге королева, мин — элекке, —
Сине минем кайгым өчен җәза тотсын!
Мин — бәхетсез, син — бәдбәхет. Сиңа телим
Тәхетеңнән, дәрәҗәңнән озын гомер!
Күп яшә син, балаларың үлгәнче тор,
Алар өчен яшь түккәнче гомер ит син!
Минем күзем сине күреп торган кебек,
Алдыңда күр син дә бүтән королева!
Урынымны син бүген абзар иткән кебек,
Алсын тартып ул да синең тәхетеңне!
Син үләрдән алда бетсен рәхәт көнең,
Күп кайгылы озак көннәр кичергәчтен
Баласыз һәм тол булып үл, һич тә ләкин
Англиягә королева булып түгел!
Риверс, Дорсет, сез дә менә күргәнсез бит,
Лорд Гэстингс, сез дә анда булгансыз бит:
Сез ни генә уйладыгыз, минем Эдвард
Канлы дошман хәнҗәреннән җан биргәндә?
Ялварам мин бер Ходайга: тигән яшен
Һичберең дә яшәмәсен! Көнегезне
Киссен икән көтелмәгән бер вакыйга!

Глостер

Ташла, диләр, юк-бар әфсен-төфсеннәрең,
Ләпшердәгән тол сихерче, нәләт карчык!

Маргарита

Ташларгамы? Сине болай буш калдырып?
Тик тор син, эт! Син тыңларга тиеш мине!
Әгәр тәкъдир язган булса дәфтәрендә
Минем сиңа теләп торган, юрап торган
Җан әрнеткеч бәлаләрнең яманрагын, —
Раббым Аллам, төшсен аның нәфрәт ташы,
Гөнаһларың күбәйгәнче, менә сиңа,
Якты дөнья бәрәкәтен бозучыга!
Җаның катсын, вәжданыңны корт ашасын!
Дусларыңнан шикләнеп тор хыянәттә,
Якын дустың авыр чакта сатсын сине!
Куркытмаса сине тәмуг кисәүләре,
Өркетмәсә газап катыш саташулар,
Йомылмасын нәләт төшкән керфекләрең!

Сихер белән яралган бер ташландык син,
Борыны белән җир казыган бер дуңгыз син,
Туар-тумас каргалган бер шайтан колы,
Җәһәннәмнең янып торган кисәве син!
Син — атаңның көчәнгән бер хәрам каны,
Син — анаңның карыны өчен тик бер оят!
Йөзе кара, нәләт төшкән синме, кем ул?

Глостер
Маргарита.

Маргарита
Ричард!

Глостер
Нәрсә?

Маргарита
Сиңа әйтмим.

Глостер

Гафу итәм. Шушы зәһәр сүзләреңне
Миңа төбәп әйттең диеп уйладым мин.

Маргарита

Шулай иттем. Тик мин моңа җавап бирмим.
Ярый, инде каргышымны тәмам итим.

Глостер

Сиңа атап, әйдә, мин дә тәмам итим.

Елизавета

Маргарита, каргышларың үзеңә төшәр!

Маргарита

О син, буяп, ясап куйган королева!
Юкка минем бәхетемә кул сузучы!
Син үзеңне шомлы итеп чолгап алган
Шул астыртын үрмәкүчкә бал коясың.
Җүләр, җүләр, үзеңә үзең пычак кайра!
Килер бер көн, үзең мине чакырырсың
Каргашырга шушы бөкре бер еланны!

Гэстингс

Әй тузган баш! Бетер шашкан каргышыңны!
Чыдап тормам. Үзеңә-үзең үпкәләрсең!

Маргарита

Сез үзегез кузгаттыгыз. Оят сезгә!

Риверс

Сез торасыз шулай итеп: гүя хәзер
Әйтү кирәк тагын сезнең кем икәнне!

Маргарита

Әйтегез соң! Әйтегез! Мин — королева!
Ә сез минем буйсынучы яраннарым, —

Онытмагыз, моны яхшы хәтерләгез!

Дорсет

Бәхәсләшмик аның белән. Ул котырган.

Маргарита

Телеңне тый, өтек маркиз, оятсыз бит!
Синең затлы дәрәҗәң дә бик чамалы.
Тәүгә төшкә керер өчен җитлекмәгән
Күптән түгел пешеп чыккан асыл затлар,
Белмисез сез дәрәҗәне югалтуның
Һәм шул хакта кайгыруның авырлыгын!
Кем югары — шуны күбрәк давыл чайкый,
Егыла икән — җыя алмый сөякләрен...

Глостер

Әйбәт киңәш. Моны, маркиз, абайлап кал!

Дорсет

Миңа түгел, күбрәк сезгә кагыла бит!

Глостер

Ярый, миңа! Тудым чөнки мин биектә!
Биек кедр башларында бөркет оям!
Әкият сата ярсып искән җилләр белән,
Горур тора көндәш булып кояш белән!

Маргарита

Ай-һай! Хәтта кояшны да каплап тора!
Ah, ah! Хәтта минем улым өстен инде
Ябып китте синең кара үлем шәүләң!
Нурлы йөзен басып синең кара болыт,
Дучар итте мәңге тыныч кара гүргә.
Бөркет ояң — безнең агач түбәсендә!
Тәңрем моны күреп торып чыдый алмас:
Сез кан белән ирешкәнне кан кайтарыр!

Букингэм

Җитәр инде, авызың яп! Әгәр бер дә
Оялмасаң, тукта, зинһар, әдәп өчен!

Маргарита

Әдәп тә юк монда миңа, оят та юк.
Сез — әдәпсез, чөнки мине хур иттегез!
Сез — оятсыз, өметләрем җимердегез!
Әдәп — мыскыл, тормыш оят минем өчен,
Яшим фәкать нәфрәт катыш кайгы белән.

Букингэм

Җитәр инде, җитәр инде!

Маргарита

Әй, Букингэм!
Хәзер сине бер дус итеп, сердәш итеп

Менә шунда кулларыңнан үбәр идем:
Бәхетле бул, туган йортың имин торсын,
Киемнәрең тапланмады безнең канга,
Сиңа төшмәс һич тә минем шушы каргыш!

Букингэм

Һичкемгә дә төшмәсен ул. Чөнки каргыш
Хуҗасыннан артык бер дә ерак китми.

Маргарита

Бу каргышым, күккә менеп, бер Ходайның
Тыныч гаршен уятмас дип уйламыйм да!
Койрык селкеп сыена дисәң — сине тешләр,
Тешли икән — агуы белән һәлак итәр...
Гөнаһ белән үлем аның чын тамгасы,
Аңар эшли тәмугтагы зобанилар!

Глостер

Лорд Букингэм, тукта, тукта, нәрсә ди ул?

Букингэм

Монда, милорд, әһәмият бирер сүз юк.

Маргарита

Нәрсә, әллә син дә мине хурлыйсыңмы?
Минем шушы саф күңелле киңәш өчен?
Мин бит сиңа ерак тор, дим, шул диюдән!
Ә син аңар ялагайлык күрсәтәсең...
Әх, хәтерлә, исеңдә тот! Бер көн килер:
Шундый итеп кайгы белән җаның турар, —
Әйтерсең син: «Маргарита — әүлия», — дип!
Нәфрәт итеп тотсын ул гел һәммәгезне,
Сез дә аны мәңге-мәңге нәфрәтләгез, —
Ул да, сез дә каргалыгыз бер Ходайдан!
(Чыгып китә.)

Гэстингс

Каргышыннан минем чәчләр үрә торды!

Риверс

Минеке дә! Ник ул һаман иректә соң?

Глостер

Юк, мин аны гаепләмим, валлаһи, ант!
Кимсетүне, явызлыкны ул күп күрде, —
Көенәм шуңа: минем дә бар гаепләрем.

Елизавета

Минем аңа һичбер зарар иткәнем юк!
Ләкин бит син гүя тартып, талап алдың
Маргарита мәхрүм булган һәрнәрсәне!
Аңар каршы сүз әйткәндә кайнарландым,

Хәзер менә шуны уйлап туңып китәм.
Кларенс та бик шәп кенә утыртылды,
Хәзер инде җәза өчен симертәләр...
Кемдә гаеп — шуны Ходай ярлыкасын!

Риверс

Яманлыкка яхшы белән җавап бирү —
Бер изгелек, христианча гадилек ул!

Глостер
(читкә карап)

Ниятләрем анык чакта мин гел шулай:
Каргыш алам һәм үземне каргап куям.

Кэтсби керә.

Кэтсби

Королевам, сезне анда король дәшә,
Сезне, герцог, һәм сезне дә, гали затлар!

Елизавета

Керәм, Кэтсби. Барасызмы сез дә, лордлар?

Риверс

Әйе, без дә сезнең арттан, королевам!

Глостердан кала бар да чыгып китәләр.

Глостер

Этлек эшлим, үзем башлап ызгыш ачам,
Мескеннәрнең җилкәсенә гаеп ташлыйм.
Кларенсны үзем тыктым ташкапчыкка,
Үзем елыйм шул тилеләр каршысында.
Әйткән булам Гэстингска, Букингэмга,
Стэнлиларга, имеш, диеп, королева
Һәм аның бар туганнары король белән
Кларенсны бозыштырды, дигән булам.
Алар миңа ышаналар һәм телиләр
Риверслардан, Воган, Грэй кебекләрдән
Мин — Глостер кулы белән үч алырга.
Тик мин күрәм. Үбәм дә мин Зәбүр битен,
Һәммәсенә шулай әйтәм: «Алла куша, —
Син таш белән атканга да аш белән ат!»
Шул китаптан ертып алып сыңар бер бит,
Аның белән каплыйм иң зур этлекләрем.
Изге булып күренәмдер мин — аждаһа!..

Ике палач керә.

Чү, чү, акрын! Палачларым килә менә!
Әһә, бу сез! Минем өлгер, кыю дуслар!
Теге эшне бетерергә хәзерме сез?

I палач

Әйе, милорд. Әмма безгә аның янына
Тоткарлыксыз керү өчен кәгазь кирәк.

Глостер

Аны белдем. Менә кәгазь. Монда гына.
(Кәгазь бирә.)
Тәмам иткәч, ычкыныгыз Кросби-плацка.
Ләкин, сэрлар, эшне бик тиз башкарырга!
Мәрхәмәтсез кыйланыгыз. Һич тә аның
Рәхим-шәфкать сорауларын тыңламагыз!
Кларенс ул сүзгә оста! Һәм, ихтимал,
Аңар колак салсагыз сез, җаныгызга
Рәхимлелек тойгысы да салып куяр.

I палач

Һи-һи, милорд, лыгырдауга колак салсаң!
Тел бистәсе кайчан булган эш остасы?
Борчылмагыз, башкарырбыз без бу эшне,
Телләр белән түгел инде, куллар белән!

Глостер

Ахмакларның күзләреннән яшь акканда,
Сезнең күздән мәрхәмәтсез таш тәгәрәр.
Ошыйсыз сез миңа, дуслар. Сүздән — эшкә!
Әйдә, әйдә, тиз тотыгыз!

I палач

Була, милорд!
Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Товердагы бер бүлмә. Кларенс һәм Брэкенбери керәләр.

Брэкенбери

Галиҗәнап, сез нигәдер моңсу бүген.

Кларенс

Ah, шулкадәр төнем бүген авыр үтте!
Күрдем шундый шомлы төшләр, хәтәр эшләр!
Саф христиан булып әйтәм сиңа шуны:
Хәтта бик күп шат, бәхетле елларны мин
Бу төн белән алыштырып алмас идем!
Шундый шомлы һәм коточкыч булды ул төн!

Брэкенбери

Ничегрәк соң булды сезнең ул төшегез?
Сорыйм сездән, сөйләгезче шуны, милорд.

Кларенс

Товердан мин качып чыккан икәнмен дә
Корабльдә Бургундиягә барам, имеш.
Күрәм, имеш, шунда икән Глостер да.
Икәү бергә палубада йөрик, диеп,
Ул килде дә алып чыкты каютамнан.
Без, күз тегеп, ерак ярга, Англиягә,

Искә алдык, имеш, шунда Йорк-Ланкастер
Сугышының мең-мең хәтәр вакыйгасын.
Кораб буйлап люк капкачы өсләреннән
Акрын гына атлый идек. Шунда Глостер,
Баш әйләнеп, имеш, кинәт таеп китте.
Аңар килеп ярдәм кулым сузыйм дисәм,
Ул егылды... һәм мине дә сөйрәп төште
Киң океанның ишелеп аккан дулкынына.
Йә бер Хода! Нинди авыр газап белән
Суга һаман бата бардым! Колагыма
Никадәрле шом китерде суның шавы!
Үлек булган, йөрәк яргыч манзаралар
Күзләремә никадәрле шом китерде!
Күрәм, имеш, күптән инде суга баткан
Йөз-меңнәрчә корабларның ватыкларын
Кимерәләр, имеш, шунда ач балыклар
Йөз-меңнәрчә кешеләрнең мәетләрен!
Сандык-сандык алтын шунда, тау-тау энҗе,
Очсыз-чиксез асыл ташлар; күз күрмәгән,
Тел белмәгән алмаз, җәүһәр, мәрҗән, якут!
Зур якорьлар белән бар да аралашып,
Тирән диңгез төпләрендә ауный, имеш.
Шунда, имеш, кайбер энҗе кисәкләре
Мәетләрнең күз чокырын биләп тора;
Кайчандыр бер күз булган бу тишекләрдән,
Чын күзләрне мыскыллаган төсле итеп,
Асылташның уйнак нуры балкып тора.
Ком-дуенлы шушы диңгез төпләрендә
Анда-санда тузгып яткан сөякләрдән
Үчекләгән төсле һаман балкый алар
Сихерләгеч тирән гыйшык дәрте белән...

Брэкенбери

Диңгез төбе байлыкларын күзәтергә
Ничек шулай өлгердегез үлгән чакта?

Кларенс

Барын-барын күзәттем күк. Бик еш кына
Җан бирергә әзер идем! Ләкин һаман
Явыз упкын кысып торды минем җанны
Һәм тәнемнән җибәрмәде һич тә аны
Буш киңлеккә, хөр асманга очар өчен.
Диңгездәге тирән упкын ярсу белән
Ярыла язган күкрәгемне кысты һаман.

Брэкенбери

Шундый каты газапта да уянмадың?

Кларенс

Юк шул! Бу төш мин үлгәч тә дәвам итте.
Ух, җанымда шундый көчле давыл купты!
Гүя шунда мин шагыйрьләр күп җырлаган
Явыз җанлы карт каекчы көймәсендә

Мәңгелек төн патшалыгын күрер өчен
Кара упкын арасыннан барам, имеш...
Иң беренче булып шунда минем җанга
Сәлам бирде каенатам, Шанлы Варвик.
Әйтте шунда ул кычкырып: «Нинди җәза
Бирер икән бу кара төн патшалыгы
Антын бозган кара эчле Кларенска?»
Ул шунда ук юкка чыкты. Аннан кинәт
Ефәк чәче ал кан белән катып беткән
Фәрештәдәй бер күләгә очып килде.
Килү белән кычкырды ул каты итеп:
«Менә Кларенс, хыянәтче Кларенс килә!
Тьюксберида мине суйган явыз Кларенс!
Җәзалагыз тотып үзен, зобанилар!»
Шуннан, имеш, мине кинәт көтү-көтү
Зобанилар чолгап алды. Имеш, алар
Шулкадәрле ямьсез итеп акыралар,
Куркынычлы итеп шундый үкерәләр —
Котым очып уяндым мин шул тавыштан.
Күзем ачкач, уянгач та мин бик озак
Җәһәннәмнән чыкканыма ышанмадым...
Шундый шомлы хис калдырды минем бу төш!

Брэкенбери

Куркуыгыз бер дә, милорд, гажәп түгел,
Бу төштән соң мин дә менә тетрәп торам!

Кларенс

Брэкенбери, ah, күп минем гөнаһларым!
Эшләнделәр алар бар да Эдвард өчен, —
Күр син, хәзер ничек түли миңа шуны!
Йә бер Алла, минем ихлас тәүбә сүзем
Ризалатмый икән сине, әгәр дә син
Явыз эшем өчен җәза бирсәң, —
Үч ал, зинһар, бары тик син миннән генә,
Имин калдыр бер гаепсез хатынымны,
Бер гаепсез балаларым-җаннарымны!
Сакчым минем Брэкенбери, сорыйм синнән:
Торчы шунда, минем янда. Җанга авыр,
Бик йоклыйсым килеп китте әллә нигә...

Брэкенбери

Торам, милорд. Бирсен Ходай тыныч йокы!

Кларенс йоклап китә.

Кайгы боза холыкны һәм ял сәгатен,
Төнне — иртә, төш вакытын төн итә ул.
Шаһзадәләр дан ала да титул яулый,
Эчке газап белән килә тышкы бизәк.
Хиссез булган буш хыяллар өчен алар
Кичерәләр дөнья кадәр кайгы-гамьне.
Өлкән — кече арасында инде, димәк, —
Аерым як та тик бер генә: тышкы бизәк!

Ике палач керә.

I палач. Әй, кем бар биредә?
Брэкенбери. Нәрсә кирәк сиңа, йолкыш? Ничек монда кердең?
I палач. Мин Кларенс белән сөйләшергә телим. Монда исә үз аягым белән кердем.
Брэкенбери. Нәрсә, сүзең шул гынамы?
II палач. Шул да җитә, сэр, сөйләп эчне пошырганчы. Әйдә, бир шуңа рөхсәт кәгазен. Артык ләм-мим!

Кәгазь бирәләр. Брэкенбери укый.

Брэкенбери

Миңа монда боерылган бу гали зат
Кларенсны сезнең кулга тапшырырга.
Нигә алай? Тикшерергә бер хакым юк,
Мин бу эшнең гөнаһына керә алмыйм.
Әнә герцог — йоклап утыра. Менә — ачкыч.
Ә мин китәм король янына, Кларенсны
Сезнең кулга тапшырганым белдерергә.

I палач

Барыгыз, сэр. Бик акыллы эшлисез сез.
Сау булыгыз.

Брэкенбери чыгып китә.

II палач. Нәрсә, без аны шулай йоклаган вакытында үтерәбезме?
I палач. Юк, уянып китәр дә безне куркаклар дип уйлар тагын.
II палач. Уяныр, пычагым! Тинтәк тә инде син! Кыямәт көненә кадәр беркайчан да уяна алмас инде ул.
I палач. Алайса, без аны йоклаган килеш үтергәнне кыямәт көнендә әйтер.
II палач. «Кыямәт көне» дигән сүзне искә алуың минем күңелемдә изге тойгы уятты бит әле!
I палач. Нәрсә, син әллә куркып та калдыңмы?
II палач. Юк, куркуым аны үтерүдән түгел, — моның өчен безгә әмер бар. Ләкин мин аны үтерүем өчен ләгънәт алырмын дип куркам. Ләгънәттән бернинди әмер дә саклый алмый.
I палач. Мин сине әле тәвәккәл кеше дип уйлый идем.
II палач. Әйе, тәвәккәл. Әмма аны дөньяда калдыру өчен.
I палач. Алайса, герцог Глостер янына барам да шулай дип әйтеп киләм.
II палач. Юк, юк, үтенәм синнән, сабыр ит аз гына. Минем бу изге тойгым тиз үзгәрер дип өмет итәм. Ул тойгы гадәттә мине «Ә!» дип әйткәнче генә тотып тора.
I палач. Ярый, менә хәзер синдә нинди тойгы?
II палач. Валлаһи менә, миндә вөҗданның бик аз өлеше генә булса да калган икән шул әле.
I палач. Эшне бетергәч, безгә дигән әҗерен исеңә төшер!
II палач. Шайтан алгырысы! Бетте, үтерәбез! Әҗерен бөтенләй онытып торам икән әле мин!
I палач. Йә, хәзер синең вөҗданың кайда?
II палач. Герцог Глостер янчыгында.
I палач. Алай булгач, безгә акча бирү өчен герцог үзенең янчыгын чишүгә үк синең вөҗданың очып китә ич!
II палач. Миңа димәгәе шунда, оча бирсен! Анда минем эшем бик аз яки бер дә юк.
I палач. Әгәр дә ул сиңа яңадан очып килсә?
II палач. Юк, мин вөҗдан дигән нәрсә белән булашмыйм. Ул бик куркынычлы нәрсә. Аның аркасында кеше куркакка әверелә. Урлар иде — урлый алмый, вөҗданы гаепли; Алла исеме белән ант итәр иде — итә алмый, вөҗданы каршы төшә; күршесенең хатыны белән йоклар иде — йоклый алмый, шунда ук аны вөҗдан фаш итә. Вөҗдан ул — оятыннан йөзе кызарып торган бер шайтан. Ул кешеләрнең йөрәкләрен фетнә белән ярсыта, анда кирле-кирәкмәгән

каршылыклар тудыра тора. Аның аркасында мин бервакыт юлдан тапкан бер янчык алтынны да иясенә кайтарып бирдем. Кемдә вөҗдан бар — аның хәерче булып калуын көт тә тор. Зарарлы булганы өчен вөҗдан дигән нәрсәне хәзер барлык шәһәрләрдән, бистәләрдән куып чыгардылар. Әгәр кеше яхшы яшәргә тели икән, үз-үзенә генә ышансын да вөҗдансыз гына көн итсен.

I палач. Шайтан алгырысы! Менә хәзер ул минем терсәк янымда гына. «Үтермә герцогны!» дип гел үгетләп торган була.

II палач. Чыгар уеңнан ул шайтанны, ышанма син аңа! Син аңа юл гына бир, сиздерми генә җаныңа керер дә утырыр!

I палач. Минем җилкәләрем калын, тиз генә җиңә алмас!

II палач. Әһә, үз дәрәҗәсен белә торган тәкәббер егет төсле итеп әйттең. Ярый, әйдә, эшне башлыйбызмы?

I палач. Кылычыңның сабы белән түбәсенә тондыр берне. Аннан соң без аны, чәнчеп, теге бүлмәдәге аракы мичкәсенә тыгып куярбыз.

II палач. Менә әйбәт акыл да соң! Аңардан куәтле аракы килеп чыгачак!

I палач

Тсс! Әнә үзе дә уянды.

II палач

Када әйдә!

I палач

Юк әле, үзе белән аз гына гәпләшеп алыйк.

Кларенс уянып китә.

Кларенс

Сакчым, син кайда? Берәр чәркә шәраб бирче!

I палач

Сез туйганчы эчәчәксез хәзер, милорд.

Кларенс

Ходай өчен әйтегез миңа, сез кем?

I палач

Сезнең кебек бер бәндәмен мин дә, милорд.

Кларенс

Минем кебек? Мин бит патша нәселеннән!

I палач

Безнең эш тик изге синең кәсебеңнән!

Кларенс

Тавышың зур, күз карашың тыйнак ләкин.

I палач

Минем тавыш чөнки, милорд, король тавышы,
Күз карашым — ансы инде үземнеке!

Кларенс

Нинди шомлы, куркынычлы синең сүзең,
Дәһшәт белән янап тора синең күзең!
Нигә болай йөзең ап-ак? Әйтегезче:
Сезне монда кем җибәрде, ник килдегез?

Ике палач

Без... без сезне...

Кларенс

Үтерергә?

Ике палач

Әйе, әйе, әйе!

Кларенс

Күреп торам, сезнең моны әйтер өчен
Батырчылык итми хәтта йөрәгегез!
Моны эшләү өчен инде бөтенләй дә
Намусыгыз җитмәс сезнең! Әйтсәгез лә:
Кайчан сезгә начарлыгым тиде, дуслар?

I палач

Безгә түгел. Галиҗәнап хөкемдарга.

Кларенс

Король белән килешергә әзермен мин.

II палач

Тик үлемгә әзерлән син. Вакыт көтми.

Кларенс

Гөнаһсызны үтерергә бар дөньядан
Сезне генә эзләп табып алдылармы?
Нәрсәдә соң минем гаеп? Кайда минем
Гаепләрне исбат иткән мәгълүматлар?
Нинди хөкем миңа рәсми гаеп ташлый?
Нинди судья йөз чытып та, каш җимереп,
Миңа каршы каты карар игълан иткән?
Кайда, кем ул мине, мескен Кларенсны,
Хөкем биргән, тартып үлем җәзасына?
Хөкем белән гадел хөкем ителгәнче
Үлем белән миңа янау — гаделсезлек!
Мин ялварам сезгә бүген безнең авыр
Зур гөнаһлар аркасында җиргә аккан
Изге Гайсә каны белән: тик ул сезнең
Җаныгызны җәзалардан йолып алыр, —
Китегез сез, зинһар, миңа кул салмагыз,
Ниятегез — йөрәк яргыч һәм чирканыч!

I палач

Безгә нәрсә? Әмер булды — эшне кара!

II палач

Әмер дисәң, ансын инде король бирде.

Кларенс

Ялганчы кол! Корольләргә король булган
Хак бер Алла, төбәп синең кебекләргә,
«Кеше үтерү — язык» дигән әмер биргән.

Ә син хәзер, шул хөкемне кире кагып,
Үтәрсеңме бер бәндәнең ниятләрен?
Сакланыгыз, җәза бирү һәм үч алу —
Бер Ходайның тик үз эше. Аның сүзен
Бозганнарның баш очында яшен яшьнәр!

II палач

Ул синең дә баш очында яшьни менә
Иман бозган, кеше һәлак иткән өчен!
Тәңре белән ант иттең син бервакытны
Ланкастерлар йортын яклап сугышырга.

I палач

Ә аннан соң, Тәңре исемен җиргә таптап,
Иң явыз бер мөртәт булып антың боздың.
Хыянәтчән хәнҗәр белән кадап соңра,
Патша улының эчәкләрен актардың син.

II палач

Синең антың аны бик нык саклау иде...

I палач

Ничек хәзер Ходай язган хөкем сүзен
Безнең алда әйтәсең син? Ә соң үзең
Аның сүзен шулай хөрмәт иттеңмени?

Кларенс

Кем өчен соң мин ул эшне кылдым, Раббым?!
Эдвард өчен, абыем өчен түгелмени?
Юк, кушмас ул, кушмас мине үтерергә!
Бу гөнаһта ул да, мин дә бертигез ич.
Әгәр Ходай моның өчен җәза бирсә,
Бирер ул тик бар дөньяга гыйбрәт итеп.
Төшенегез, бу бары тик аның ирке, —
Аерылмагыз аның хөкем кодрәтеннән!
Бик зур гөнаһ кылсам да мин, әмма Ходай
Юлсыз эшкә, яшерен үчкә мохтаҗ түгел!

I палач

Кем җибәрде сине анда, канлы палач,
Суяр өчен Плантагенет-баһадирны,
Көчле, гүзәл, көләч егет-шаһзадәне?

Кларенс

Туганыма булган тирән мәхәббәтем,
Явыз шайтан вәсвәсәсе, тиле ярсу —
Мине анда менә кемнәр җибәрделәр.

I палач

Туганыңның сиңа булган мәхәббәте,
Безнең бурыч, синең авыр гаепләрең
Безгә хәзер куша сине үтерергә.

Кларенс

Туганымны яратсагыз, сез миңа да
Каныкмагыз. Сөям мин үз туганымны.
Яллангансыз икән аңар акча өчен,
Барыгыз сез, мин җибәрәм сезне хәзер
Сөйгән энем герцог Глостер каршысына.
Мин үлгәнне ишеткәчтен Эдвард биргән
Шул акчадан күбрәк итеп Ричард түләр,
Мин дөньяда икәнлеккә хәбәр алгач.

II палач

Ялгышасың. Глостер дошман синең өчен.

Кларенс

Ой, юк, дус ул! Аның өчен кадерле мин!
Барыгыз сез аңар!

Ике палач

Әй-йе, барачакбыз.

Кларенс

Сөйләгез сез: көчле хаким атабыз Йорк
Кочып алды бер көн безне, өч баласын,
Үзенең ныклы һәм сугышчан кулы белән.
Һәм ул шунда үгет бирде чын күңелдән:
Балалар, дип, бер-береңне яратыгыз!
Уйлаганмы ул шул чакта мондый хәлне?
Хәтерләсен Глостер шуны һәм ул елар!

I палач

Күзләреннән яшь агылмас, таш тәгәрәр;
Сез дә шулай елагыз, дип, ул өйрәтте.

Кларенс

Юк, нахак сүз! Минем энем яхшы җанлы!

I палач

Шулай, дөрес. Җәен яуган кар шикелле.
Әйдә, милорд, алданма син юкка болай:
Синең башны бетерергә ул җибәрде.

Кларенс

Мәңге булмас! Минем шушы язмыш өчен
Әрнеп-әрнеп елап калды. Каты итеп
Кочаклады. Яшькә тулып вәгъдә бирде:
Тиз көндә ул мине моннан азат итәр.

I палач

Нигә? Шулай эшли дә ул! Ошбу җирнең
Җәфасыннан азат итеп, сине күккә,
Теге дөнья рәхәтенә очыра инде...

II палач

Иманың әйт. Үтерәбез хәзер, милорд.

Кларенс

Җаныгызда изге хисләр шулмы сезнең?
Иманың әйт, диеп киңәш бирәсез сез...
Аңсызлыктан мине бүген һәләк итеп,
Иманнан да, Алладан да бизәрсезме?
Ah, сез, сэрлар, уйлагызчы, сезне монда
Кем җибәргән — шул ук сезне нәләт итәр!

II палач

Нишлибез соң?

Кларенс

Алла сезне ярлыкар, дус,
Кызганыгыз!

I палач

Кызганырга? Куркак җаннар,
Хатын-кызлар өчен генә хас нәрсә бу!

Кларенс

Рәхимсезлек, вафасызлык хас нәрсә ул
Ерткычларга, вәхшиләргә, иблисләргә.
Әгәр хәзер булсагыз сез менә шунда
Минем кебек азатлыктан мәхрүм принц, —
Әгәр шунда килеп керсә сезнең кебек
Мәрхәмәтсез ике палач, — әйт, кайсыгыз,
Мәдәт сорап, минем төсле ялвармас соң?
Әй син, дустым! Әх, әгәр дә чын булса ул —
Рәхимлелек сизәм синең карашыңнан!
Кил, бас менә минем янга, үзең өчен
Ялынгандай, минем өчен шәфкать сора,
Минем кебек бәладә дип хис ит үзең!
Зур бәлага дучар булган шаһзадәгә
Каза күргән нинди адәм шәфкать итми?

II палач

Әйләнегез әле, милорд, артыгызга!

I палач
(Кларенска хәнҗәр белән кадый)

Менә шулай! Менә шулай! Җитми дисәң,
Илтеп шәраб мичкәсенә салам хәзер!

Мәетне алып чыгып китә.

II палач

Кан түгеш бу. Баш китәрлек хәтәр бер эш.
Пилат, Гайсә пәйгамбәрне үтергәчтен,
Башын ничек белмәмешкә салган булса,
Мин дә шулай итәр идем. Чөнки бүген
Зур гөнаһлы бер җинаять эшләдек без.

I палач әйләнеп керә.

I палач

Нигә болай катып калдың? Булышмыйсың?
Ничек акрын мыштырдавың герцог белсә?
Валлаһи, дим, белер моны! Син ни дисең?

II палач

Хәзер менә аңар барып, «туганыңны
Мин коткардым» дип әйтергә теләр идем.
Акчаларны үзеңә ал да син, әйт аңар:
Үкенәм мин Кларенсны үтергәнгә!
(Чыгып китә.)

I палач

Мин үкенмим. Бар, куркак җан, югал моннан!
Күмәргә дип герцог боерык биргәнгәчә
Шул мәетне яшереп куыйм. Китим мин дә!
Акчаларын алгач сызам. Җилдән сора!
Бу фаш булса — минем эшем мөшкел тора.
(Чыгып китә.)

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Король сараендагы бер бүлмә.
Авыру хәлендә король Эдвард, королева Елизавета, Дорсет, Риверс,
Гэстингс, Букингэм, Грэй һәм башкалар керәләр.

Король Эдвард

Шулай итеп, бүген зур эш эшләдем мин;
Ә сез, парлар, ныгытыгыз бердәмлекне!
Мин һәр көнне көтәм Ходай Тәгаләдән
Бу дөньядан китү өчен фәрман гына...
Җир өстендә дусларымны килештердем, —
Күк көзендә җаным тыныч булыр минем.
Риверс белән сез, Гэстингс, бетерегез
Бөтен яшерен дошманлыкны. Кул кысышып,
Сүз бирегез мәңге-мәңге дус булырга.

Риверс

Хода шаһит! Җаным азат явызлыктан, —
Тугрылыклы йөрәгемнең мәхәббәтен
Раслап менә кулым белән мөһер сугам.

Гэстингс

Мин дә сөенеп бирәм шул ук тугры антны.

Король Эдвард

Сак булыгыз патшагызга ялганлаудан! —
Корольләргә король булган бөек Тәңре
Нык җәзалар сезне ялган вәгъдә өчен.
Тәкъдирегез шулай булыр: һәркайсыгыз
Дошманлыкта бер-берсенең башын ашар!

Гэстингс

Мин бик шатмын. Бирәм чөнки камил антым!

Риверс

Мин дә шулай: Гэстингсны чын дус күрәм.

Король Эдвард

Королева! Син дә моннан читтә калма, —
Улың Дорсет Букингэмга кулын бирсен.
Чөнки син дә һәм алар да — икәү, өчәү
Бер-берегез белән һаман чәйнәштегез.
Әйдә, хатын, якын дус ит Гэстингсны,
Суз син аңар — кулың үпсен. Әмма барсы
Эчкерсез һәм чын күңелдән булсын инде.

Елизавета

Кил, Гэстингс, үткәндәге дошманлыкны
Һич тә искә төшермәм мин. Нинди рәхәт!

Король Эдвард

Дорсет, әйдә кочакла син Гэстингсны!
Син, Гэстингс, ярат безнең лорд-маркизны!

Дорсет

Вәгъдә бирәм: безнең шушы тату дуслык
Минем яктан мәңге-мәңге какшатылмас!

Гэстингс

Мин дә шуңа вәгъдә бирәм!

Король Эдвард

Әйдә хәзер
Патшаларның нәселдәше Букингэм, мин
Хатынымның кардәшләрен кочакла да,
Менә шушы татулыкны нык беркетеп,
Дуслыгыгыз белән мине бәхетле ит!

Букингэм

Галиҗәнап королева! Әгәр тагын
Букингэмың сине бүтән дошман итсә,
Ул сиңа һәм синең бөтен туганнарга
Тугрылыклы мәхәббәтен күрсәтмәсә, —
Ходай аңар татулыкка сүз куешкан
Дусларының нәфрәтләрен, үчен язсын!
(Гэстингска, Дорсетка һәм башкаларга.)
Миңа шундый тугры бер дус кирәк чакта,
Ул ант эчсен, мин иң яхшы, иң чын дус, дип, —
Һәм соңыннан ул бер буш һәм кара эчле
Череп чыккан хыянәтче булып калсын, —
Шуны сорыйм бер Ходайдан, әгәр сезгә
Ихтирамым зәррә мыскал кимеп куйса!

Король Эдвард

Шәп, Букингэм. Синең антың күңелгә хуш,

Шифа булды минем сырхау йөрәгемә.
Тик туганым Глостер гына никтер килми,
Дусланунең изге эшен төгәлләргә.

Букингэм

Менә! Гомере озын булыр: герцог килә.

Глостер керә.

Глостер

Хәерле көн, королем һәм королевам!
Хәерле көн, гали затлы пэрларыбыз!

Король Эдвард

Әйе, Глостер, көн чыннан да бик хәерле.
Бүген шундый изге эшләр эшләдек без:
Юкка гына әтәчләнеп, бер-берсенә
Ярсуланган шушы пэрлар арасында
Дошманлыкны алмаштырдык солых белән,
Нәфрәтләрне тугрылыклы дуслык белән.

Глостер

Бик мәслихәт, минем бөек хөкемдарым!
Әгәр шушы гали затлар арасында
Гайбәт белән, ялган белән, хата белән
Кем булса да миңа үпкә тота икән, —
Әгәр минем кайнарланган чакларымда
Монда булган кешеләрнең кайберсенә
Ирексездән чыккан икән катырак сүз, —
Чын күңелдән телим шуны: татулашыйк,
Гафу сорыйм, дуслык хисен өмет итәм.
Дошманлыкта булу миңа үлем бит ул!
Күрә алмыйм чәйнәшүне. Һәм мин телим
Бөтен яхшы кешеләргә чын дуслыкны!
Әүвәл сездән, королева, гафу сорыйм,
Аклармын мин моны тугры хезмәт белән.
Сорыйм синнән, минем якын кан кардәшем
Букингэмнан. Әйдә, герцог, барын оныт,
Күңелләрдә сакланмасын явыз уйлар.
Сорыйм синнән, Риверс туган, синнән, Дорсет,
Юкка миңа каш җимереп карадыгыз, —
Бетерик без кирәкмәгән дошманлыкны.
Сорыйм сездән, Вудвилль, сездән, лорд Скайльз,
Герцог, лордлар, графлар һәм асыл затлар,
Барыгыздан сорыйм бүген фәкать шуны!
Минем җаным аз булса да чит-ят күргән
Бүтән хәзер беркем дә юк Англиядә.
Бүген төнлә тусын икән нәни бала, —
Шөкер, Ходам! — мин аңар да башым орам!

Елизавета

Бу көн зур бер бәйрәм булып истә калыр!
Дога кылам мин Ходайга: килештерде,

Бездә булган ызгышларга чик куйды ул!
Падишаһым, сорыйм синең мәрхәмәтне:
Туганыбыз Кларенсны гафу ит син!

Глостер

Ничек инде, королева? Мин соң бүген
Король бар да көлке булыр өчен генә
Сөйләдемме тирән дуслык хисләремне?
Кларенсның үлгәнлеген кем соң белми?

Бар да торып баса.

Ә сез аның тыныч гүрен мыскыллыйсыз.

Риверс

Үлгәнлеген кем белми, ди. Кем белә соң?

Елизавета

Әй бер Ходам, нинди генә дөнья соң бу?!

Букингэм

Кара, Дорсет, мин дә шулай башкалар күк
Ап-акмы соң?

Дорсет

Әйе шул, лорд. Монда хәзер
Чыраеннан кан качмаган беркем дә юк.

Король Эдвард

Кларенсны үлгән дисең? Мин бит үзем
Күптән түгел фәрманымны кире алдым!

Глостер

Ләкин инде һәлак булды бичарабыз
Башта биргән әмер белән. Чөнки бит ул
Сезнең кулдан аткан уктай чыгып китте.
Инде сезнең гафу иткән фәрманыгыз
Эләккәндер бер чатанга, килде чөнки
Кларенсны гүргә салган чакта гына...
Алла шаһит! Затлылыкта, тугрылыкта
Кларенстан бик күп өлеш кимнәр дә бар.
Уйларында канлы ният күп булса да,
Имин алар канлы үч һәм җәзалардан, —
Алар бер дә җавап бирми герцог төсле.
Шикләнәм мин, монда һаман нәрсәдер бар.

Стэнли керә.

Стэнли

Падишаһым, мәрхәмәт кыл хезмәтчемә!

Король Эдвард

Калдыр, зинһар, җаным тулы кайгы белән!

Стэнли

Тез өстемнән тормам мәңге, галиҗәнап,
Сез минем бу гарзы хәлем тыңламыйча!

Король Эдвард

Тизрәк сөйлә, сиңа миннән нәрсә кирәк?

Стэнли

Коткарыгыз хезмәтчемне, падишаһым!
Ул, бик ярсып, бүген герцог Норфолькның
Азгын куллы бер вассалын дөмектергән.

Король Эдвард

Туганымны үтертергә тел ачтым мин,
Шул ук телдән юк-бар колны кичеримме?
Минем энем бер кеше дә үтермәде, —
Күңелендә булды начар уйлар гына:
Тик аңар да җәза булды зәһәр үлем.
Кем, кем миңа аның өчен ялынды соң?
Кем, кем миңа ярсуланган вакытымда,
Минем алда тезен чүгеп, аның өчен
Тагын бер кат уйла, диеп үтенде соң?
Кем китерде күңелемә туганлыкны?
Кем төшерде хәтеремә мәхәббәтне?
Кем әйтте соң миңа шушы бичараның,
Багланышны өзеп горур Варвик белән,
Минем өчен батырларча сугышканын?
Кем әйтте соң Тьюксбери кырларында
Оксфорт мине җиргә еккач, туганымның
Мине аннан йолып алып, «Тор, кадерлем,
Мең яшә син һәм патша бул!» дигән чагын?
Кем әйтте соң, без икәүләп, суык кырда
Сөякләргә чаклы туңгач, шунда аның
Киемнәрен салып, миңа япкан чагын?
Кем әйтте соң шул вакытта туганымның
Күм-күк булып, ярым шәрә калган килеш,
Карлы-бозлы суык җирдә дерелдәвен?
Ерткычларча ярсу белән мин боларның
Барын-барын хәтеремнән чыгарганмын.
Нинди гөнаһ! Әмма кем дә, рәхим итеп,
Моны шунда минем искә төшермәгән!
Хәзер инде сезнең ялчы, олаучылар
Төтен кебек эчеп-исереп, кеше суеп,
Бер Ходаның кануннарын мыскыллагач,
Сез шунда ук тез өстенә егыласыз,
«Шәфкать ит» тә «гафу ит» дип ялынасыз.
Мин дә шунда бер хаксызга шәфкать итәм.
Туганымны яклап кем дә сүз әйтмәде,
Мин дә, мөртәт, бичараны аклау өчен
Күңелемдә яхшы тойгы тапмаганмын.
Арагыздан иң горур да тормышы һәм
Җаны белән бурычлы бит Кларенска!
Берегез бер сүз әйтмәде шунда аның
Тормышы һәм җаны өчен. Әй бер Аллам!
Сизеп торам, аның гадел, хак җәзасы
Төшәр миңа, төшәр сезнең һәммәгезгә, —

Мин эшләгән һәм сез кылган бу эш өчен!
Кил, Гэстингс, булыш. Керим бүлмәмә мин.
Ай бичарам, Кларенсым!

Король, Эдвард, Елизавета, Гэстингс, Риверс, Дорсет һәм Грэй чыгып китәләр.

Глостер

Менә сиңа
Ашыгып ашка пешкәнлекнең бер җимеше!
Сиздегезме, мин, Кларенс үлгән, диеп
Хәбәр иткәч, ничек бар да ап-ак булды,
Явыз җанлы королева туганнары!
О, мин беләм, корольне тик алар гына,
Алар гына шундый эшкә котырттылар.
Алла үзе моның өчен җәза бирер!
Әйдә, лордлар, барабызмы бергәләшеп,
Эдвард галиҗәнапларын юатырга?

Букингэм

Әйе, герцог. Барабыз без сезнең арттан.

Чыгып китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Король сараендагы бер бүлмә. Кларенсның Улы һәм Кызы белән герцогиня Йорк керә.

Малай

Әйтче, әбием, безнең әткәй үлдемени?

Герцогиня

Юк, юк, улым.

Кыз

Нигә соң син алай булгач гел елыйсың,
Күкрәгеңә суга-суга кычкырасың:
«Әй Кларенс, әй бәхетсез балам!» — диеп?

Малай

Әгәр әткәй исән икән, нигә соң син
Безгә карап башың чайкап торасың да:
«Үксез, ятим мескенннәрем минем!» — дисең?

Герцогиня

Оныкларым, ялгышасыз. Мин яшь түгәм
Сезнең король абыегыз авырганга, —
Ул үләр дип куркуымнан елыйм шулай.
Әтиегез үлгән өчен түгел ләкин, —
Юк кайгы ул югалтканны жәлләп елау!

Малай

Менә, әбием, үзең әйттең: үлгән шул ул!
Моның өчен гаепле тик король абый, —
Ходай аңар җәза бирер. Мин аңардан
Көн-төн моны каты итеп ялварырмын!

Кыз

Мин дә шулай.

Герцогиня

Тыныч кына, тыныч кына, балакайлар!
Король сезне чын күңелдән сөя бит ул!
Сез, гөнаһсыз бичаралар, сай йөзәсез,
Сезнең газиз әткәгезнең үлеме өчен
Аңламыйсыз кем сәбәпле икәнлеген!

Малай

Әбием, моны без беләбез. Глостер абый
Ачык итеп әйтте миңа: безнең җиңги
Уйдырмалар, шикләр белән котырткачтын,
Король абый тоткын иткән әткәбезне.
Абый миңа моны әйткәч елап алды,
Бик жәлләде, сөеп үпте маңгаемнан;
Әтиең итеп миңа гына таян, диде,
Улым итеп яратырмын сине, диде.

Герцогиня

Ай-һай, кара: нурлы йөздә — хәйлә-мәкер!
Изге битлек, аның асты — тирән этлек!
Оят миңа аның өчен — улым бит ул!
Биргән аңар мондый бозык гадәтләрне
Ана сөте түгел, ләкин тана сөте!

Малай

Әбием, син ул хәйләкәр дип уйлыйсыңмы?

Герцогиня

Шулай, балам.

Малай

Ышанмыйм шул. Тукта, анда нинди тавыш?

Кайгысыннан акылын җуйган төсле булып королева Елизавета керә. Аның артыннан Риверс белән Дорсет.

Елизавета

Ah, кем миңа елар өчен, үксер өчен,
Язмышымны каргар өчен, үземә үзем
Тирән әрнү салыр өчен ирек бирми?
Үземә үзем дошман булыйм, үземә каршы
Бөтен кара хәсрәтләрне бергә җыйыйм!

Герцогиня

Синең мондый ярсуларың нәрсә өчен?
Нигә кинәт мондый кәмит күрсәтәсең?

Елизавета

Фажиганең бер пәрдәсен уйнар өчен!
Эдвард үлде. Минем ирем, синең улың,
Һәммәбезнең хөкемдары Эдвард үлде!
Тамыр беткәч, ботаклары ничек үссен?

Дымы кипкәч, яфраклары ничек торсын?
Сез яшисез икән әгәр — яшь коегыз,
Сез үләсез икән әгәр — тиз үлегез, —
Канатланып очкан газиз җаннарыбыз
Куып җитсен өчен тизрәк король җанын!
Итагатьле коллар булып барыйк аның
Киң, яңа һәм мәңге тыныч дәүләтенә!

Герцогиня

Ah, бу кайгы минем дә бит тирән кайгым!
Чөнки синең затлы ирең — минем улым!
Мин яшь түктем бөек җанлы ирем өчен,
Гомер иттем күреп аның шәүләләрен,
Күзем тегеп аның газиз улларына...
Хәзер миңа аның гали, саф сурәтен
Чагылдырган ике көзге чәлпәрәмә
Ватылды да китте явыз үлем белән.
Юаныч булып калды янә чалыш көзге,
Кайгырам тик күреп аннан хурлыгымны.
Син — тол хәзер, тик шулай да ана бит син;
Балаларда калды синең бар шатлыгың!
Тартып алды үлем минем кулларымнан
Ирем Йоркны. Инде хәлсез култыгымнан
Суырып алды минем култык таякларым —
Балаларым Эдвард белән Кларенсны...
Ah бу күрмеш, нинди авыр минем язмыш!
Мин бер елыйм, синең елау ярты гына,
Минем күз яшь диңгеземдә үксүләрең
Өстән йөзә, сулкылдавың батып кала!

Малай
(королевага)

Бер дә, җиңги, әткәй үлгәч еламадың,
Ничек синең хәлгә керик, без дә елап?

Кыз

Без ятимнәр кайгысына яшь жәлләдең,
Син тол өчен инде без дә еламыйбыз!

Елизавета

Булышмагыз минем елау-сыкравыма, —
Агып торсын бар чишмәләр минем күзгә,
Мин түккән бу яшь диңгезен Су патшасы —
Ай күтәреп ярларыннан чыгарсын да,
Бар дөньяны басып алсын минем туфан!
Елыйм ирем, гадел хуҗам Эдвард өчен!

Балалар

Ай, елыйбыз әткәй өчен, Кларенс өчен!

Герцогиня

Ah, мин елыйм Эдвард өчен, Кларенс өчен!

Елизавета

Инде кемгә таянырмын, Эдвард үлде!

Балалар

Инде кемгә таянырбыз, Кларенс үлде!

Герцогиня

Инде кемгә таянырмын, икесе дә юк!

Елизавета

Бер хатын да миндәй мәхрүм калмас инде!

Балалар

Бер бала да бездәй ятим калмас инде!

Герцогиня

Бер ана да миндәй ялгыз калмас инде!
Ah, мин, бөтен кайгыларның карт анасы!
Алар зары өлеш булса, минем — бөтен.
Килен елый Эдвард өчен, мин дә елыйм, —
Кларенс дип мин еласам — килен читтә.
Балакайлар елый менә, мин дә елыйм, —
Эдвард диеп мин еласам — алар читтә.
Ah, сез өчәү, һәммәгездә хәсрәт тулы.
Миндә ләкин өчегезнең кайгы-зары!
Яшь түгегез барыгыз да, ә мин сезне
Яныгызга хәсрәт куйган хәдимәдәй
Илереп-илереп елау белән иркәләрмен.

Дорсет
(королевага)

Сабыр ит син, әнкәй җаным. Алла каргый
Кылган эшен хупламаган бәндәләрне.
Дөньялыкта намуссызлык була инде —
Чырай сытып, теләмичә бурыч түләү;
Юмарт кулдан, якты йөздән вакытлыча
Бирелгәнне кайтармаска ниятләнү,
Шулай булгач, Тәңре белән сүзгә килмә —
Әҗәт итеп патша бирде — бүген алды.

Риверс

Королева! Кайгыртучан ана бул да
Уйла хәзер улың — принц хакында син.
Син туп-туры хәзер аңа кеше җибәр:
Таҗны кисен. Таянычың шунда синең!
Үлгән Эдвард белән хәсрәт гүргә керсен,
Исән Эдвард тәхетеннән шатлык килсен!

Глостер, Букингэм, Стэнли, Гэстингс, Рэтклифф һәм башкалар
керәләр.

Глостер

Ярар, килен. Тынычлан син. Һәммәбезгә
Сүнеп калган шушы якты йолдыз өчен
Яшь түгәргә язган инде. Ләкин һич тә

Кайгыларны басып булмый елау белән.
Ах, әни, сез... Чын күңелдән гафу сорыйм:
Башта сезне күрмәгәнмен. Сезнең алда
Тезем чүгеп, көтәм сезнең фатиханы!

Герцогиня

Ходай сине ярлыкасын. Бирсен сиңа
Миһербанлык, итагатьлек, игелекләр.

Глостер

Амин! Шулай йөз яшәп, бер бабай булыйм!
(Читкә карап.)
Әнкәй гел-гел фатихасын шулай очлый.
Гаҗәп! Бүген нигә моны әйтмәде соң?

Букингэм

Кайгы чиккән принцлар, җаннарына
Тирән хәсрәт үтеп кергән гали затлар!
Сагышларның авыр йөге уртак булды,
Сөенешик хәзер уртак дуслык белән.
Шиңде шатлык чәчәгебез король белән,
Принц белән шатлык тагын чәчәк атсын!
Үчлек бетте сезнең горур йөрәкләрдә,
Без кушылдык бергә-бергә, дуслар булып,
Яхшы саклыйк һәм кадерлик бердәмлекне!
Минем фикер менә болай: без, Ладлоуга
Бик аз санда кеше туплап, вәкил итик.
Алар бүген яшь принцны алып кайтсын, —
Лондонда без аңар тажны тапшырырбыз.

Риверс

Нигә алай, бик аз кеше, дисез, милорд?

Букингэм

Шулай, милорд. Әгәр кеше бик күп булса,
Күптән түгел тынган фетнә тагын чыгар,
Андый нәрсә безнең өчен бик куркыныч.
Әлегә безнең дәүләтебез яшь һәм яшел,
Ныклы хуҗа кулы да юк. Һәркем хәзер
Тезгеннән ычкынган бер атка охшый:
Әйдәүчесен кайда тели, шунда сөйри.
Фетнә чыгар. Куркыныч бар һәм ул шиксез.
Минем фикер: андый хәлне булдырмаска.

Глостер

Король безне инде тәмам килештерде, —
Тату дуслык миндә ник һәм тугрылыклы.

Риверс

Мин дә шулай. Һәркайсыбыз шулай хәзер.
Ләкин әлегә татулыкның башы гына...
Аңар һич тә шөбһә табын төшермәскә
Тиешбез без. Чөнки, дуслар, андый нәрсә
Халык күптә бик тиз калкып чыгучан бит.

Мин кушылам Букингэмга. Яшь принцны
Барып алсын фәкать бик аз кеше генә.

Гэстингс

Мин дә риза.

Глостер

Шулай булсын. Ярый, әйдә, хәл итик без, —
Кем Ладлоуга вәкил булып барыр икән?
Королева, сез дә безгә, әнкәй, сез дә
Бу зур эштә киңәш-уңаш бирерсез бит?

Герцогиня, Елизавета
(икесе бергә)

Чын күңелдән ризабыз без андый эшкә!

Букингэм белән Глостердан кала бар да чыгып китәләр.

Букингэм

Принц янына кемне генә җибәрмик без, —
Ходай өчен без икәүләп монда калмыйк!
Безнең корган ниятләрне үтәү өчен,
Шаһзадәдән королебез хатынының
Кәперәйгән туганнарын аеру өчен
Юлда чакны уйлармын мин берәр хикмәт.

Глостер

Уң кулым син, үз-үзем син, киңәшчем син,
Пәйгамбәрем, әүлиям син, туганкаем!
Сабый төсле, мин иярәм сиңа һаман, —
Артта торып калмыйк дисәң, алда — Ладлоу!

Чыгып китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Урам. Ике яктан ике кеше килеп керәләр.

I кеше

Саумы, күрше. Кайда болай ашыгасың?

II кеше

Чынын әйтим: үз-үзем дә белми барам.
Ишеттеңме яңалыкны?

I кеше
Король үлгән.

II кеше

Начар хәбәр. Хәерлесе бик сирәк шул.
Хәтәр! Хәтәр! Дөнья ничек болгана бит!

Өченче кеше керә.

III кеше

Алла сезгә ярдәм бирсен, күрше-колан!

I кеше

Хәерле көн сезгә дә, сэр!

III кеше
Ишеткәнсез,
Король Эдвард үлгән дигән хәбәр йөри.

II кеше

Әйе шул, сэр. Нәрсә дисең, дөрес хәбәр.
Инде Ходай ярлыкасын. Нинди заман!

III кеше

Күр син, ничек дөнья килә асты өскә!

I кеше

Алай димә, Ходай сузар ярдәм кулын, —
Король үлсә, тәхетендә принц калыр.

III кеше

Илдә бала патша булса — бәла инде!

II кеше

Шикләнмәгез, тәхет булса, король булыр.
Ул яшь чакта киңәшчеләр ярдәм итәр.
Принц үсәр, буйга җитәр, аннан соң ул
Берүзе дә эшне бик шәп алып барыр.

I кеше

Хәл шундый ук иде берчак: Генрих VI
Король тажын кигәч Париж шәһәрендә, —
Аңар хәтта тугыз ай да юк иде бит.

III кеше

Шундый дисең? Юк, юк, дуслар, Алла шаһит!
Ул чак бу ил зирәк, үткен акылларга,
Күренекле кешеләргә бай иде шул!
Сабый бала — король галиҗәнапларын
Менә дигән абзалары карап торды.

I кеше

Бу король дә шулай булыр. Моның да бар
Сарай тулы һәр ике як абзалары.

III кеше

Булсын икән бар да ата ягыннан тик!
Яки бер дә кирәк түгел. Чөнки барсы
Падишага ныграк якын булу өчен
Бер-берсеннән көнләшәләр. Сакла, Ходай,
Безнең өскә төшәр моның авыр башы!
Oh, ничаклы коточкыч ул, герцог Глостер!
Королева малайлары, кардәшләре
Никадәрле вәкарьле һәм тәкәбберләр!
Дилбегәне явызларга бирмәс өчен
Йөгәнләргә кирәк барын. Шунда гына
Иркен сулар безнең сырхау, газиз ватан.

I кеше

Курыкмагыз. Яманрагын хак язмасын.
Кем белә бит, бәлки, барсы яхшы үтәр.

III кеше

Болыт күрсә, зирәк кеше плащын кия, —
Җиргә яфрак коела икән — кыш киләсе.
Кояш батса, кем дә сизә: төн җитәчәк,
Коры давыл исеп торса — ачлыкны көт.
Язган булса, бәлки, бар да яхшы үтәр,
Тик ышанмыйм. Без шул моңа лаек түгел.

II кеше

Кешеләрнең җаны тулы шаукым белән.
Йөзен чытып карамаган һәм күзендә
Курку хисе чагылмаган беркем дә юк.

III кеше

Үзгәрешкә бара эшләр. Шуңа бу хәл.
Илаһи бер сизем белән кеше белә
Янап торган бәлаләрне. Диңгез дә бит
Кайный башлый давыл алды тынлыгында.
Ярый инде, болар бар да Ходай эше...
Сез кай якка?

II кеше

Безме, без... ни... судья көтә,
Белмим, никтер хөкемгә дип җибәрделәр.

III кеше

Мин дә шунда. Әйдә, сезгә юлдаш булыйм.

Чыгып китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Король сараендагы бер бүлмә. Йорк архиепископы, кече яшьтәге герцог Йорк, королева Елизавета һәм герцогиня Йорк керәләр.

Архиепископ

Кичә төнлә алар булса Нортемптонда,
Бүген алар җитәр Стони-Стрэтфордка.
Берәр көннән Эдвард инде монда булыр.

Герцогиня

Бар йөрәктән сагынам мин яшь принцны,
Хәзер инде үскәндер ул бик зур булып.

Елизавета

Мин ишеттем, ул әллә ни үсмәгән, дип, —
Минем Йоркым буйга аннан зуррак, диләр.

Герцог Йорк

Юк, юк, әни, һич үсәргә теләмим мин.

Герцогиня

Нигә балам? Үсү бит ул яхшы нәрсә.

Герцог Йорк

Беркөн, әни, кичке аш-су вакытында,
Риверс абый мине өлкән туганымнан
Буйга зуррак үскән, диеп мактап куйды.
Шунда аңар Глосстер абый болай диде:
«Нәни гөлләр затлы була, матур була,
Әрем генә шулай бик тиз буйга үсә».
Нигә миңа андый үсү? Чөнки гөлләр
Акрын гына, тыныч кына чәчәк ата, —
Чүп-үләннәр исә бик тиз буйга калка.

Герцогиня

Менә ничек! Сиңа әйткән шушы мәкаль
Аның үзенә бер дә инде туры килми.
Ул бит гарип, кәрлә булып озак үсте!
Әгәр аның шушы сүзе раска чыкса —
Җирдә инде аннан яхшы беркем дә юк.

Архиепископ

Һич шөбһә юк, шундый яхшы кеше дә ул.

Герцогиня

Яхшы. Ләкин миндә шик бар. Ана ич мин.

Герцог Йорк

Валлаһи, дим, әгәр исемә төшкән булса,
Абый миннән көлгән чакта мин аңар да
Үзе күк үк әйтер идем шундый нәрсә...

Герцогиня

Сорыйм синнән, әйт әле, Йорк, нәрсә соң ул?

Герцог Йорк

Ул менә шул: минем абый бик тиз үскән, —
Туганына ике сәгать үткәч тә ул
Чәйни алган таштай каты икмәк тышын.
Миңа фәкать тешләр чыккан ике яшьтән!
Әйтче, әбием, үзен яхшы тешләдемме?

Герцогиня

Әйт әле, Йорк, моны сиңа кем сөйләде?

Герцог Йорк

Тәрбияче хатын әйтте.

Герцогиня
Тәрбияче?
Ничек инде? Син туганчы үлде ич ул.

Герцог Йорк

Алай булса әйтә алмыйм, кем сүзедер.

Елизавета

Шаян малай, җитәр, артык кыйланасың.

Архиепископ

Нәни бит ул, ачуланмыйк аңар, мадам.

Елизавета

Стеналар тыңлый монда.

Хәбәр ташучы керә.

Архиепископ
Менә кайтты.
Сөйлә, нинди яңалыклар! Нинди хәбәр?

Хәбәр ташучы

Яңалыклар бик үк, милорд, яхшы түгел.
Сөйләве дә авыр инде...

Елизавета

Принц саумы?

Хәбәр ташучы

Әйе, ул сау.

Герцогиня

Сөйлә, нинди хәбәрләр бар?

Хәбәр ташучы

Лорд Риверсны, лорд Грэйны, кулга алып,
Помфретка җибәрделәр. Алар белән
Воган да бар. Озаттылар тоткын итеп.

Герцогиня

Кем аларны кулга алды?

Хәбәр ташучы

Көчле, бөек
Ике герцог — Ричард Глостер һәм Букингэм.

Архиепископ

Сөйлә, нинди гаеп белән?

Хәбәр ташучы

Миңа нәрсә?
Белгәнемне барын әйттем. Ничек итеп,
Нәрсә өчен алар кулга алынганнар —
Миңа инде болар, милорд, дөм караңгы.

Елизавета

Ah, мин сизәм, йортыбызга афәт килде!
Зифа болан килеп капты юлбарыска.
Безнең шушы изге, газиз таҗ-тәхеткә

Килеп җитте шул залимнең ерткычлыгы!
Әйдә, әйдә, килегез сез, һәлакәтләр,
Килегез, кил, канлы сугыш, үтерешләр!
Мондый эшнең ахыры ничек булачагын
Учымдагы төсле итеп күрәм хәзер!

Герцогиня

Нәләт төшкән явыз көннәр, фетнә тулы,
Гауга тулы канлы көннәр! Ah, ничаклы
Күреп үтте сезне минем бу күзләрем!
Минем ирем тәхет өчен башын куйды,
Тәхет өчен көрәш минем балаларны, —
Миңа кайчак шатлык биреп, кайчак кайгы, —
Бер упкынга тәгәрәтте, бер күтәрде,
Бер җиңдерде, бер калдырды харап итеп.
Сугыш азрак тынса да, тик тынгылык юк!
Йортта тагын көчле тавыш, гауга куба:
Җиңүчеләр, бер-берсенә сугыш ачып,
Бер-берсенә ташланалар. Кан өчен кан
Җиргә ага. Кардәшенә каршы кардәш,
Үзенә каршы үзе тагын ярсып чыга...
Ой, коточкыч тиле ярсу, үчле гауга!
Йә бетер син нәләт төшкән явызлыгың,
Йә үлим мин күрмәс өчен үтерешләр!

Елизавета

Җыен, улым, китик әйдә монастырьга.
Сау булыгыз.

Герцогиня

Сезнең белән мин дә барам.

Елизавета

Сезгә анда бару өчен бер сәбәп юк.

Архиепископ

Королева! Әйдә тизрәк, ашыгыгыз.
Калдырмагыз барлык алтын әйберләрне.
Байлыгыгыз имин булыр. Ә мин сезгә
Бирәм минем кулда булган зур мөһерне.
Ходай миңа ярдәм итсә, җил тидертмәм
Сезгә дә һәм йортыгыздан беркемгә дә.
Әйдә киттек. Монастырьга илтим сезне.

Чыгып китәләр.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Урам. Торба тавышы. Принц Уэльс, Глостер, Букингэм, Кэтсби,

кардинал Борчер һәм яраннар керәләр.

Букингэм

Кил, рәхим ит, бөек принц. Синең алда
Пайтәхетең Лондон тора.

Глостер

Сәлам сиңа,
Сөйгән энем, минем бөек падишаһым!
Бу авыр юл сине шактый алҗыткандыр...

Принц Уэльс

Һич юк, абый. Безнең бу юл бик күңелсез,
Мәшәкатьле юл булса да, армадым мин.
Абыйларның барсы мине каршыларга
Чыгар диеп көткән идем... Ник алар юк?

Глостер

Сөекле принц, синең керсез саф яшьлегең
Дөньялыкның төрле ялган-мәкерләрен
Хәзергәчә очратканы юк шул әле...
Шуңа күрә таныйсың син кешеләрнең
Фәкать тышкы шәүләләрен. Ходай белә!
Тышкы шәүлә андыйларның җаны белән
Бик еш кына бер тамчы да туры килми.
Принц, синең хөрмәт иткән абыйларың
Синең өчен хәтәр алар. Син аларның
Тыңлагансың бал-шикәрле төче сүзен,
Сизмәгәнсең җаннарында агу барын...
Саклый күрсен Ходай сине андыйлардан,
Имин кылсын җыен ялган дус-ишләрдән!

Принц Уэльс

Имин кылсын җыен ялган дус-ишләрдән!
Ләкин алар бер дә андый түгел иде...

Глостер

Лондон мэры килә сезне сәламләргә.

Лондон мэры һәм аның яраннары керәләр.

Лорд-мэр

Принц галиҗәнаплары, Алла сезгә
Саулык бирсен, бәхет бирсен!

Принц Уэльс

Затлы милорд,
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, дуслар, һәммәгезгә!

Лондон мэры һәм аның яраннары китәләр.

Әнием белән туганым Йорк безне бүген
Юлга чыгып каршы алыр дигән идем...
Фу, ничаклы ялкау икән бу Гэстингс,
Киләләрме, килмиләрме безнекеләр, —

Чыкмады бит шуны хәбәр итәр өчен!

Гэстингс керә.

Букингэм

Менә гомере озын икән. Лорд үзе дә!
Тиргә батып ашыгып килә...

Принц Уэльс

Әйдә, милорд.
Нәрсә анда, минем әнием киләчәкме?

Гэстингс

Ходай белсен, белмим, нинди сәбәптәндер
Королева әнкәгез һәм Йорк энегез
Монастырьга китеп барган. Яшь шаһзадә
Сезне каршы алыр өчен минем белән
Килмәкче дә булган иде, ирексездән
Әнкәсенең сүзе белән тыелып калды.

Букингэм

Фу, ничаклы эчкерле һәм кыяфәтсез
Бүген аның менә мондый кыйланышы!
Лорд кардинал! Бармассызмы сез хәзер үк
Королева белән ныклап сөйләшергә?
Сүзгә күнеп, җибәрмәсме герцог Йоркны
Кардәше һәм хөкемдары каршысына.
Әгәр дә ул буйсынмаса, сез, Гэстингс,
Яшь принцны, аның көнче кулларыннан
Йолкып алып, тизрәк монда китерегез.

Кардинал

Лорд Букингэм, минем көчсез үгетләрем
Герцог Йоркны әнкәсеннән аера алса, —
Шул ук минут яшь шаһзадә монда булыр.
Әгәр инде минем үгет-вәгазьләргә
Риза булмый, королева каршы торса, —
Яшь принцны бик тә ала алмыйбыз без.
Бер Ходадан һич рөхсәт юк бозар өчен
Монастырьның изге, ныклы кануннарын.
Җирдә мине һичнәрсә дә ымсындырмас,
Андый авыр, зур гөнаһны эшләмәм мин!

Букингэм

Сез дә шул ук тискәре һәм хиссез икән,
Ырымнарга баш игән бер дәрвиш икән!
Әх сез, милорд! Уйлагызчы, шул сабыйны
Монастырьдан чыгарсагыз — нинди гөнаһ?
Ул — изге йорт. Аның изге мәрхәмәте
Берәр төрле гаебе булган кешеләргә
Хак җәзадан качар өчен билгеләнгән, —
Кеше анда керә фәкать теләп кенә.
Ә яшь принц монастырьда яшеренергә
Мәҗбүрмени яки бик нык телимени?

Аңар анда торыр өчен һич сәбәп юк.
Чыгарсагыз тизрәк аннан яшь принцны,
Изге дини кануннарны бозу булмас.
Күргәнем бар өлкән яшьтәге монахларны,
Балалардан монахларны күргәнем юк!

Кардинал

Хәзер, милорд, сезнең сүзгә инандым мин.
Сез, Гэстингс, барасызмы минем белән?

Гэстингс

Барам, милорд, әйдә киттек.

Принц Уэльс

Ә сез, лордлар,
Зинһар, тизрәк булыгызчы. Вакыт бик аз.

Кардинал белән Гэстингс чыгып китәләр.

Глостер абый, әйтче миңа: энем килсә,
Таҗны киеп мин тәхеткә утырганчы,
Аның белән кайда торып торырбыз без?

Глостер

Монысы инде үзегезнең иркегездә.
Ләкин сезгә киңәш бирәм, галиҗәнап:
Бер-ике көн тын алыгыз Товерда сез,
Ә аннан соң карар идегез теләгәнчә
Сәламәтлек һәм ял өчен шәбрәк урын.

Принц Уэльс

Мин Товерны ни өчендер яратмыйм шул.
Аны монда Юлий Цезарь салган бугай?

Букингэм

Юк, ул аны башлап кына калган, диләр,
Аннан соңгы күп буыннар тәмам иткән.

Принц Уэльс

Юлий Цезарь тезгән дигән шушы хәбәр
Буыннардан буыннарга килгән сүзме,
Әллә берәр елъязмада калган сүзме?

Букингэм

Елъязмада калган сүз бу, галиҗәнап.

Принц Уэльс

Ярый, милорд. Андый нәрсә елъязмада
Язылмаган булса да бит, чын дөреслек
Буыннардан буыннарга барыр иде, —
Кыяматкәчә, мәңге күчеп телдән телгә,
Онтылмаслык тарих булып калыр иде!

Глостер
(читкә карап)

Каян килгән аңар мондый үткен акыл?

Бала тинтәк булса гына озак яши...

Принц Уэльс

Сез ни дисез анда, абый?

Глостер

Юк, мин әйтәм,
Шөһрәт ул, дим, язмасаң да озак яши.
(Читкә карап.)
Мин гел шулай, Иблис төсле, бер үк сүзгә
Капма-каршы ике төрле мәгънә бирәм...

Принц Уэльс

Юлий Цезарь данлы бер ир булган икән!
Зур батырлык баета барган зур гакылын,
Һәм бу гакыл данга күмгән батырлыгын.
Җиңүчене үлем һич тә җиңә алмый!
Бу дөньяда бүген тере булмаса да,
Ул яши гел шан-шәрәфтә. Сезгә, абый,
Бер сүзем бар...

Букингэм

Нинди сүз ул, галиҗәнап?

Принц Уэльс

Әгәр дә мин сезнең кебек үсеп җитсәм,
Үзебезнең элек алган хокукларны
Яулар өчен китәр идем Франциягә.
Тыныч чакта король булып яшәгәндәй,
Канлы яуда солдат булып үләр идем.

Глостер

(читкә карап)
Иртә чыккан чәчәкләрне салкын куыра.

Герцог Йорк, Гэстингс һәм кардинал керәләр.

Букингэм

Менә әйбәт! Герцог Йорк та килеп җитте.

Принц Уэльс

Әйдә, Ричард. Саумы, туган, хәлләр ничек?

Герцог Йорк

Әйбәт кенә, минем зирәк хөкемдарым! —
Хәзер сезне шулай диеп атыйм инде.

Принц Уэльс

Анысы шулай. Көенечкә каршы, ләкин
Бу зур сүзгә лаек кеше исән түгел, —
Ул үлгәчтен бу исем дә тоныкланды...

Глостер

Ни хәл синдә, Йорк туганым, кәеф ничек?

Герцог Йорк

Рәхмәт сезгә, Глостер абый. Беләсезме,
«Начар үлән буйга бик тиз үсә ул», — дип,
Беркөн миңа сез әйттегез. Король менә
Буйга миннән шактый гына зуррак икән!

Глостер

Шулайрак шул.

Герцог Йорк

Димәк, ул да начар үлән?

Глостер

Ой, Йорк туган, һич тә алай димәс идем.

Герцог Йорк

Димәк, безне тигез итеп яратмыйсыз?

Глостер

Ул хөкемдар, димәк, аңар баш иям мин;
Син — кардәшем, димәк, сине яратам мин.

Герцог Йорк

Абый, миңа бүләк итче шул хәнҗәрне!

Глостер

Менә моны димсең, энем? Чын күңелдән.

Принц Уэльс

Нәрсә, хәер сорыйсыңмы?

Герцог Йорк

Сорыйм икән —
Абыемнан. Чөнки беләм, андый гына
Уенчыкны уфтанмыйча бирәчәген.

Глостер

Аннан зурын бирә алам сиңа, энем.

Герцог Йорк

Аннан зурын? Алай булса, кылычын бир!

Глостер

Бирәм, энем. Ләкин сиңа авыр бит ул.

Герцог Йорк

Ah, мин күрәм, син шул җиңел аерыласың
Фәкать җиңел нәрсәләрдән! Авыр әйбер
Сорый калсам, «соранасың» дияр идең...

Глостер

Бу кылыч бит йөртер өчен авыр сиңа.

Герцог Йорк

Мин моннан да авыррагын җиңел йөртәм.

Глостер

Алыр идеңмени минем коралны син,
Бәләкәй лорд?

Герцог Йорк

Алыр идем. Ә аннан соң
Рәхмәт әйтер идем сиңа үзем кадәр.

Глостер

Ничек инде үзең кадәр?

Герцог Йорк

Бәп-бәләкәй.
Син бит үзең һаман миңа шулай дисең.

Принц Уэльс

Безнең Йорк ул шулай инде, сүзгә үткен.
Ә син, абый, ничек шуны күтәрәсең?

Герцог Йорк

Шулай димсең? Күтәрергә мөмкин дә бит,
Атландырып алып бару җиңел түгел!
Күрче, абый, ул сине дә һәм мине дә
Хурлап тора! Чөнки менә маймыл кебек
Нәни генә булсам да мин, син җилкәңдә
Мине һич тә атландырып баралмыйсың.

Букингэм
(читкә карап)

Кара, ничек үткен итеп акыл сата!
Абыйсының ачуын азрак басар өчен
Үз-үзеннән оста итеп көлгән була!
Шундый яшь тә, шундый зирәк, исең китәр!

Глостер

Галиҗәнап, барырсызмы ялгыз гына?
Без Букингэм белән икәү бергә хәзер
Китәчәкбез әнкәң янына монастырьга.
Үтенербез без аңардан, сине бүген
Ул Товерда каршы алыр. Әйдә, син бар!

Герцог Йорк

Нәрсә, милорд, сез Товерга барасызмы?

Принц Уэльс

Протекторның сүзе шулай. Димәк, барам.

Герцог Йорк

Мин Товерда тыныч кына йоклый алмыйм.

Глостер

Нигә алай? Син нәрсәдән куркасың соң?

Герцог Йорк

Анда абыем Кларенсның рухы йөри, —

Ул Товерда суелган, дип, әбием әйтте.

Принц Уэльс

Миндә үлгән абыйлардан һич курку юк!

Глостер

Һәм шулай ук исән булган абыйлардан!

Принц Уэльс

Шундый исән абыйларым бар чагында
Шүрләмим мин һичнәрсәдән. Әйдә, милорд,
Абыйларны уйлый-уйлый, менә шулай
Авыр хисләр белән барыйк без Товерга.

Торба тавышы. Принц Уэльс, герцог Йорк, Гэстингс, кардинал һәм яраннар чыгып китәләр.

Букингэм

Ни дисез сез, лыгырдавык бу нәни Йорк
Сезне шулай мыскылларга һәм хурларга
Озын телле әнкәсеннән өйрәнгән бит!

Глостер

Һич шигем юк. Ай, ул шундый хәтәр малай!
Үткен, җитез, сәләтле һәм бик хәйләкәр, —
Нәкъ әнисе, гел суйган да каплаган күк!

Букингэм

Ярый. Әйдә, болар азрак калып торсын.
Әй, син, Кэтсби, якынрак кил. Син ант иттең
Булышырга безнең барлык ниятләргә, —
Юлда чакта бездән белгән бөтен серне
Күз караңдай нык сакларга вәгъдә иттең.
Әйтче, ничек уйлыйсың син, бик читенме
Безнең эшкә тарту Вильям Гэстингсны?
Менә шушы асыл затлы бөек герцог
Безнең шанлы утравыбыз тәхетенә
Король булып утыра калса, ул ни дияр?

Кэтсби

Эдвардны ул озак еллар хөрмәт итте,
Принцтан да шуңар күрә йөз чөермәс.

Букингэм

Стэнли ничек? Ул да безгә булышмасмы?

Кэтсби

Гэстингстан бер адым да узмас шул ул.

Букингэм

Һем, күз күрер. Ярый, булды. Бар син, Кэтсби.
Әйләнмәле юллар белән мыштым гына
Гэстингсны капша азрак: безнең эшкә
Ничек карар, нәрсә дияр? — Син шуны бел.
Товерга дип чакыр үзен. Иртә белән

Килеп җитсен тәхет бирү мәҗлесенә.
Сизсәң аның безнең сүзгә күнгәнлеген,
Котырт үзен, сөйлә безнең бөтен уйны.
Сизсәң аның кургашындай авырлыгын,
Салкынлыгын, сүзгә күнмәс кирелеген,
Син үзең дә шундый ук бул. Сүзне туктат.
Һәм бу хакта безгә тулы хәбәр китер.
Тәхет бирү мәҗлесеннән аерым итеп
Иртәгесен җыярбыз без бүтән мәҗлес, —
Анда безгә синең бик зур ярдәм кирәк.

Глостер

Вильямга син миннән дә әйт кайнар сәлам.
Һәм шуны да өстә, Кэтсби: иртәгесен
Аның явыз, бөтен иске дошманнары
Помфретта каннарына тончыгачак.
Һәм әйт аңар: сөенеп шушы зур хәбәрдән
Миссис Шорны тагын бер кат кочып үпсен.

Букингэм

Бар син, Кэтсби, әйбәт итеп башкар шуны!

Кэтсби

Була, лордлар. Бу эш өчен җаным фида.

Глостер

Безгә, Кэтсби, төнгә чаклы хәбәр китер.

Кэтсби

Була, лордлар.

Глостер

Безне озак эзлисе юк:
Кросби-плацта булачакбыз икебез дә.

Кэтсби китә.

Букингэм

Ярый, милорд. Әгәр дә без Гэстингсның
Безнең якка аумаслыгын белеп алсак,
Нихәл итик аның белән?

Глостер

Нихәл итик?
Башын кистек һәм вәссәлам! Нәрсә тагын?
Хәзер тыңла: әгәр дә мин король булсам,
Оныттырма, сора Герфорд графлыгын, —
Сора мәрхүм королебез Эдвард милкен.
Мин бирермен.

Букингэм

Мин онытмам сезнең шушы

Юмарт кулдан миңа биргән вәгъдәгезне.
Вәгъдә икән — чын күңелдән үтәрмен мин.
Әйдә киттек. Ашап алыйк. Соңыннан без
Серебезне күши-күши уйлашырбыз.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лорд Гэстингс йортының капка төбе. Хәбәр ташучы керә.

Хәбәр ташучы
(капка шакып)

Милорд! Милорд!

Гэстингс
(капка артыннан)

Кем бар анда? Кайсы шакый?

Хәбәр ташучы

Лорд Стэнли йомышчысы.

Гэстингс
(капка артыннан)

Сәгать ничә?

Хәбәр ташучы

Хәзер менә дүрткә суга.

Гэстингс керә.

Гэстингс

Шомлы төннәр!
Безнең лордны, ахры, бер дә йокы алмый.

Хәбәр ташучы

Шулай төсле. Тапшырачак сүзем шундый!
Әүвәл сезгә ул күп итеп сәлам әйтте.

Гэстингс

Аннан соң ни?

Хәбәр ташучы

Аннан соң ул сез милордка
Кушты шуны белдерергә: бүген төнлә
Ул төш күргән. Һәм төшендә кыргый кабан
Аның шлемын умырып читкә аткан, имеш.
Аннан соң ул болай диде: «Бүген иртән
Ике урында ике Мәҗлес җыела икән.
Шуның берсе кабул итсә берәр карар,
Безнең башка булмагае, үкенмик, — ди...
Шуңа күрә тәкъдим итә сез-милордка,
Уңай чакта, йөгерек атка менеп тизрәк,
Җаным сизгән куркынычтан качар өчен,
Минем белән төн ягына юнәлсен», — ди...

Гэстингс

Бар, бар, егет, кайт та сөйлә лордыңа син:
Курыкмасын. Ике җирдә Мәҗлес, имеш!
Берсендә мин Глостер белән бергә булам,
Тегесендә дустым Кэтсби катнашачак.
Безгә анда куркыр өчен һичнәрсә юк!
Шуңар күрә мин бу хакта уйламыйм да!
Син әйт аңар: курыкканга куш күренә.
Гаҗәпләнәм, каян мондый самимилек?..
Җыен көлке, юк-бар төшкә ышанган бит!
Безнең өскә ташланырга уйламагач,
Нигә качыйк шул кабаннан? Әгәр качсак,
Үртәү генә түгелме соң? Дуңгыз, безне
Эзәрлекләп арттан чабар, ул бу хакта
Һич кенә дә уйламаган булып чыгар...
Миңа килсен, бар син, егет, әйт хуҗаңа.
Товерга без икәү бергә барачакбыз.
Күреп торыр ничек итеп ул кабанның
Безнең янда сырпаланып йөргәнен дә!

Хәбәр ташучы

Китәм, лорд, сезнең сүзне җиткерермен.

Китә. Кэтсби керә.

Кэтсби

Хәерле иртә сезгә, милорд!

Гэстингс

Хәерле иртә!
Бүген, Кэтсби, бигрәк иртә уянгансың...
Нихәл безнең тетрәп торган патшалыкта?

Кэтсби

Дөнья тетри, чайкала шул хәзер, милорд.
Мин инанам, тизрәк патша такыясын
Ричард кисә, дәүләт төзрәк торыр иде.

Гэстингс

Нәрсә? Такыя? Әллә тажны әйтәсеңме?

Кэтсби

Әйе, милорд, тажны әйтәм.

Гэстингс

Шулай димсең?
Лаексызның таш башында таҗ булганчы,
Минем шушы иңбашымда баш булмасын!
Чынмы соң бу? Ул тажга ук ымсынамы?

Кэтсби

Әйе, чын, чын! Моңардан тыш ул бу эшкә
Көтеп тора сезнең якын булышлыкны.
Инде сезгә аннан шәп бер яңа хәбәр:

Сезгә дошман королева кардәшләре
Бүген бар да Помфретта җан бирәчәк!

Гэстингс

Бу рас булса, алар өчен елап тормам,
Чөнки алар бик күптәнге дошманнарым.
Ричард өчен тавышың бир, дисәң инде,
Эдвард король варислары өчен әгәр
Хак тәхеткә киртә куй син, дисәң инде,
Ходa шаһит! Үлсәм үләм, ансы булмас!

Кэтсби

Тотсын Ходай сезне, милорд, бу шәп уйда!

Гэстингс

Нәкъ унике ай үткәч тә көләрмен мин
Король белән арам бозган адәмнәрдән,
Бүген менә алар күргән фаҗигадән!
Шулай, Кэтсби, ай да ундүрт көнлек булып
Тулып җитмәс, кайберәүләр сизәр минем
Башларына китермәгән рәхмәтемне!

Кэтсби

Бик авыр шул, хөрмәтле лорд, уйламаган,
Искәрмәгән җирдән кинәт үлеп китү!

Гэстингс

Ah, коточкыч, йөрәк яргыч! Шундый үлем
Килде бүген Риверс, Воган, Грэйларга.
Шундый үлем күрер тагын үзләрен гел
Имин санап йөри торган кайберәүләр!
Безнең өчен бер хәвеф юк. Син беләсең:
Безне Ричард һәм Букингэм якын күрә!

Кэтсби

Һәр икесе дә тота сезнең исемегезне
Биек җирдә!
(Читкә карап.)
Башыгызны күрмәкчеләр
Биек Лондон күперендә, баганада!

Гэстингс

Беләм, шулай. Мин казандым чөнки моны.

Стэнли керә.

Әйдә, әйдә! Син кабаннан куркасың бит,
Кайда сөңгең, батыр егет, ник алмадың?

Стэнли

Хәерле иртә сезгә, милорд, саумы, Кэтсби?
Шаяртыгыз, бер сүзем юк. Тик ант итәм
Изге Гайсә кадакланган тәре белән:
Сезнең мондый киңәшләрне һич яратмыйм.

Гэстингс

Сезнең күк үк мин дә сөям тормышымны, —
Әйтим, милорд, әлегә чаклы һич тә аны
Бүгенгедәй кыйбат итеп күрми идем.
Шуны уйла: безнең хәлләр имин торса,
Болай гына көләч булыр идеммени?

Стэнли

Помфреттагы ул лордлар да, башкаладан
Көләч булып кайткан чакта, хәлебез шәп,
Язмышыбыз тыныч булыр, дигәннәрдер...
Хәзер менә ялгышырга бер нигез юк:
Күрәсездер, алар күген болыт басты.
Шикләнәм мин, бу бер явыз җинаятьтер...
Бир бер Хода, куркуларым юкка булсын!
Нәрсә, хәзер без Товерга барабызмы?
Инде хәзер көн яктырды.

Гэстингс
Әйдә, милорд.
Беләсеңме, син әйткән ул кешеләрнең
Башларына бүген балта төшәчәген?

Стэнли

Үзләрендә бер гөнаһ та булмаганга,
Алар өчен баш алай ук авыр түгел.
Тик аларны гаепләгән кешеләрнең
Башларында эшләпәләр авыр, ахры.
Ярый, әйдә киттек, милорд.

Хәбәр ташучы керә.

Гэстингс
Сез барыгыз.
Мин сөйләшим шушы чибәр егет белән.
Әй син, нихәл? Көнең ничек үткәрәсең?

Хәбәр ташучы

Яхшы. Бик шәп. Рәхмәт, милорд, сорашканга.

Гэстингс

Әйтим, егет, минем хәл дә шәбрәк хәзер,
Син соңгы кат күргәнгедән бик күп әйбәт!
Хәзер нәрсә? Ул чакта мин, тоткын булып,
Тик Товерга бара идем! Моңар мине
Дучар итте королева кардәшләре...
Инде әйтим, тик сер итеп сакла моны, —
Дошманнарым тора бүген үлем көтеп.
Элеккедән йөз мәртәбә хәлем яхшы!

Хәбәр ташучы

Игелекләр бирсен Ходай сезгә, милорд!

Гэстингс

Рәхмәт, егет, мә эч минем исәнлеккә!
(Янчык ыргыта.)

Хәбәр ташучы

Рәхмәт сезгә, рәхмәт сезгә, затлы милорд!

Китә. Рухани керә.

Рухани

Хәерле көн! Сезне күреп шатмын, милорд.

Гэстингс

Ах, сэр Джон! Чын күңелдән рәхмәт сиңа!
Синең соңгы хезмәт өчен бурычлымын,
Килеп чык син якшәмбедә, санашырбыз.

Букингэм керә.

Букингэм

Нәрсә, милорд, дин әһелен дәштегезме?
Хәзер инде аны сезнең Помфреттагы
Дусларыгыз сездән битәр көтә булыр.
Сезгә, милорд, тәүбә өчен иртәрәк бит!

Гэстингс

Хода шаһит! Шушы изге җанны күргәч,
Шул сез әйткән бичаралар искә төште.
Сез дә шунда, Товергамы?

Букингэм

Шунда таба.
Тик аз торам. Сездән алда кайтачакмын.

Гэстингс

Ә мин анда төшке ашка калмагаем.

Букингэм
(читкә карап)

Кичке аш та көтә сине шунда гына...
Атладыкмы?

Гэстингс

Ярый, милорд, киттек әйдә.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Помфрет крепостеның ишегалды. Рэтклифф керә. Аның артыннан — сак астында — Риверс, Грэй һәм Воган. Аларны җәзалау урынына алып баралар.

Рэтклифф

Тизрәк илтик, җәза өчен вакыт җитте.

Риверс

Әй, сэр Ричард Рэтклифф, сез тыңлагызчы!
Сезнең алда үләм бүген инсафлыгым,
Тугрылыгым, гаделлегем өчен генә...

Грэй

Раббым Алла ике яп-яшь шаһзадәне
Имин кылсын сезнең явыз ниятләрдән!
Нәләтләнгән канечкечләр өере бит сез!

Воган

Килер ул көн, бу эш өчен зар еларсыз!

Рэтклифф

Ул көн килде. Син зар ела, вакыт көтми.

Риверс

Әй Помфрет, әй Помфрет, канлы төрмә!
Затлы пэрлар башын куйган шомлы урын!
Синең хаин диварларың арасында
Үтерделәр король Ричард Икенчене!
Кара төрмә, җәй тагын да яман атың;
Эч син бүген безнең хәләл каныбызны!

Грэй

Маргарита бәддогасы төште безгә, —
Аның улын Ричард чәнчеп үтергәндә,
Шунда гына торган өчен сезне, мине,
Гэстингсны нәләт итте ул шул чакта!

Риверс

Ул бит анда Глостерны ләгънәтләде,
Букингэмга, Гэстингска каргыш әйтте.
Әй бер Ходам, Маргарита бәддогасын
Безнең күк үк хәтерләсен шул явызлар!
Сакла, Тәңрем, апам белән хәләл канны,
Үзең шаһит, бер гөнаһсыз кан түгәбез!

Рэтклифф

Тиз булыгыз, җитте үлем сәгатегез!

Риверс

Грэй, Воган, килегез, бер кочаклашыйк!
Инде күктә очрашырбыз. Хуш! Бәхил бул!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Товердагы бер бүлмә. Мәҗлес бара. Букингэм, Гэстингс, Стэнли, Элий епископы, Рэтклифф, Ловель һәм башка лордлар өстәл янында
утыралар. Яраннар, сарай кешеләре аларга хезмәт күрсәтәләр.

Гэстингс

Менә шулай, затлы пэрлар, без җыелдык
Таҗ багышлау тантанасын билгеләргә.
Киңәш итик. Ходай өчен әйтегез сез:
Патша көнен кайчангарак тәгаенлик?

Букингэм

Бу көн өчен һәммә нәрсә әзер микән?

Стэнли

Барсы әзер. Көнен генә алдан уйлыйк.

Епископ

Иртәгә! Нәкъ бәхетле бер көн инде!

Букингэм

Протектор ни ди икән, кем белеште?
Аның белән аныкъ кына кем киңәште?

Епископ

Сезгә, герцог, бәлки, күбрәк билгеледер.

Букингэм

Без кешенең йөзен генә күрәбез шул,
Күңелендә нәрсә барын беркем белми.
Сезнең уйны мин белмәгән шикелле үк,
Ул да белми минем уйда нәрсә барын, —
Аның эчен мин белмәгән шикелле үк,
Сез белмисез минем эчне, гали затлар!

Гэстингс

Рәхмәт аңар, мине ул бик якын күрә!
Тик мин аның таҗ багышлау турындагы
Фикерләрен ишетмәдем. Ул бу эшне
Ничек уйлап хәл иткәнен белдермәде.
Билгеләгез, гали затлар, патша көнен, —
Герцог өчен үзем хәзер тавыш бирәм,
Мин уйлыйм ки, моның өчен шат булыр ул.

Епископ

Менә, гомере озын икән, герцог үзе!

Глостер керә.

Глостер

Хәерле иртә, гали затлар, тугандашлар!
Озаклабрак йоклаганмын. Тик ышанам:
Минем юклык туктатмагач бу зур эшне,
Үзем барда аны бик тиз хәл итәрбез.

Букингэм

Сез, гали зат, төпле бер уй уйлаганчы,
Таҗ багышлау тантанасын тәгаенләп,
Лорд Гэстингс сезнең өчен тавыш бирде.

Глостер

Тик ул гына һәммәгездән кыюрак шул, —
Ул бит мине бик шәп белә, якын күрә!

Гэстингс

Рәхмәт сезгә, рәхмәт, милорд!

Глостер

Әй, лорд Элий!
Гольборнда соңгы тапкыр булган чакны

Бакчагызда күргән идем җир җиләге.
Китертсәгез икән азрак! Бик үтенәм.

Епископ

Була, милорд. Рәхәтләнеп! Хәзер әйтәм.
(Чыгып китә.)

Глостер

Кил, Букингэм, бер-ике сүз әйтәсем бар.
(Читкә алып китә.)
Кэтсби әйткән Гэстингска безнең уйны.
Ул гади зат шулкадәрле кайнарланган, —
Даһиларча шулай диеп раслый икән:
Короленең варислары Англиянең
Таҗ-тәхетен югалтсалар, лорд, янәсе,
Үз башын да югалтырга риза икән!

Букингэм

Әйдә, милорд, бераз гына чыгып керик.

Глостер һәм Букингэм чыгып китәләр.

Стэнли

Без шулай да триумф көнен нык белмибез.
Мин уйлыйм ки, иртәгә шул бик тиз булыр.
Әүвәл моңар мин үзем үк әзер түгел, —
Азрак соңга калдыруны теләр идем...

Элий епископы керә.

Епископ

Кая киткән затлы милорд, герцог Глостер?
Җир җиләге китерергә әмер бирдем.

Гэстингс

Герцог бүген аеруча шат, көләч йөзле!
Шатлыгы бар йә нидер бик ошый аңар, —
Безнең белән бик күңелле исәнләште.
Мин уйлыйм ки, христианнар дөньясында
Нәфрәтен һәм мәхәббәтен аның кебек
Ачык итеп белдерүче кем дә юктыр, —
Йөзен күрдең — җанын инде тиз аңлыйсың!

Стэнли

Йөзен күрдең, җаны ничек? Белдеңме соң?
Яхшы якка охшаш нәрсә сиздеңме соң?

Гэстингс

Абау! Ул бит беркемгә дә сүз әйтмәде!
Ачуы булса карашыннан сизәр идең...

Глостер һәм Букингэм керәләр.

Глостер

Сорыйм сездән, әйтмәссезме, әгәр берәү,

Мине һәлак итәр өчен фетнә корып,
Нәләт төшкән сихер белән, ырым белән,
Иблисләрчә мәкер белән күзем буса;
Әгәр аның шушы шомлы сихерләве
Минем тәнне зыяндашка дучар итсә,
Шул бәндәгә нинди җәза лаек икән?

Гэстингс

Сезне гел мин якын күрәм, затлы милорд,
Шуңар әйтәм сезнең алда иң элек мин:
Сихерчегә минем хөкем: кем булса да —
Аңар, милорд, үлем генә лаек җәза!

Глостер

Кил, шаһит бул, кара син дә алар эшен!
Күрегез, күр: менә ничек сихерләндем! —
Кулым корый җилдә сынган яшь ботак күк.
Эдвард хатыны кара эчле бер аждаһа,
Һәм Шор дигән өстерәлчек бер фахишә
Икәүләшеп мине шулай хур иттеләр!..

Гэстингс

Әгәр алар ырымлаган булса сезне?..

Глостер

«Әгәр», «әгәр»! Син дә шушы нәләт төшкән
Азгын җанны яклыйсыңмы? Миңа каршы
«Әгәр» диеп ничек телең күтәрәсең?
Хыянәтче! Әйдә, палач башын чапсын!
Изге Павел исме белән ант итәм мин:
Аның башын күрми торып, ашка кермим!
Әйдә, Ловель һәм Рэтклифф, башкарыгыз!
Кем миңа дус — торып чыксын минем белән!

Глостер, Букингэм һәм мәҗлестә катнашучылар чыгып китәләр.

Гэстингс

Хәсрәт! Хәсрәт! Миңа түгел, Англиягә!
Үзем дә соң, ышанучан тинтәк икән, —
Бу хәлне бит булдырмаска тиеш идем!
Стэнли төше раска килде: явыз кабан
Теше белән аның шлемын йолкып алган.
Мин бу төштән көлдем генә. Качыйк, дигәч,
Мыскыл иттем. Бүген иртән минем атым
Никтер өч кат таеп китте. Мине бүген
Үләр өчен китергәнен сизенгәндәй,
Товер эчен күрү белән өркеп куйды...
Ой, бик кирәк хәзер миңа бер рухани!
Теге хәбәр ташучыга бая әйткән
Шалтыравык сүзләремнән тәүбә итәм!
Имеш, бүген дошманнарым Помфретта
Кан түгәчәк, җан бирәчәк! Имеш, минем
Иминлегем ышанычлы, эш ал да гөл!
Маргарита! Маргарита. Синең каргыш

Ашый мескен Гэстингсның газиз башын!

Рэтклифф

Иман китер, герцог көтә синең башны!
Тиз бул, юкса ашый алмый төшке ашны!

Гэстингс

Ой, бу ялган! Нигә бәндә мәрхәмәтен
Өстен куйдым бер Ходаның шәфкатеннән?
Очраклы бер якты йөзгә карап кына
Бозга язган өмет белән йөргән кеше
Мачтадагы нәкъ исерек матрос инде, —
Кораб кинәт бер селкенсә, очып төшә
Дөм караңгы тирән диңгез упкынына...

Ловель

Әйдә тизрәк! Юкка гына карганасың!

Гэстингс

О син, Ричард, канлы Ричард! О син, илем,
Минем газиз Англиям, юрыйм сиңа,
Пәйгамбәрлек итәм сиңа авыр еллар,
Күрер моны хур ителгән минем буын!
Әйдә, әйдә, ятыйм үлем кискәсенә, —
Бар, илтегез минем башны, көлсен миннән.
Кемнәр көлә — һәлак булыр бар да тиздән!

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Товер стенасы яны. Тутыккан килбәтсез калканнар кигән Глостер белән Букингэм керәләр.

Глостер

Кил, әйт, туган, синең кулдан килер микән,
Куркуыннан акылы очкан җүләр төсле,
Тетрәп китү, төсне бик тиз алмаштыру,
Ярты юлда сүзне бүлеп тынны кысу,
Аннан тагын сөйли башлап, тагын тыну?

Букингэм

Ух, минме? Мин! Кирәк булса, андый эштә
Узып китәм трагедия актеряннан!
Сүзем әйтәм, карыйм артка, як-якларга;
Бер сискәнәм, бер дерелдим салам төсле,
Сизәм, имеш, бик тирән бер хәвеф барын.
Юрамалый якты караш, ап-ак калган
Көлсу чырай — барсы әзер минем өчен,
Ялчы алар минем хәйлә-мәкерләргә.
Әмма, тукта, безнең Кэтсби китте микән?

Глостер

Китте, китте. Менә мэрны алып килә.

Лорд-мэр белән Кэтсби керәләр.

Букингэм
Кхм, лорд-мэр...

Глостер

Чү, күперне төшерсеннәр!

Букингэм

Ах, барабан! Ни бар анда?

Глостер
Әй, син, Кэтсби,
Стеналарны яхшы кара, сакчы бармы?

Букингэм

Кхм, лорд-мэр... Сезне шуңар чакырдык без...

Глостер

Артка кара, сакланыгыз, дошман килә!

Букингэм

Ходай яклар, гадел ният саклар безне!

Гэстингсның башын тотып, Ловель белән Рэтклифф керәләр.

Глостер

Тынычланыйк. Болар безнең дусларыбыз
Ловель белән Рэтклифф икән.

Ловель

Менә булды!
Бу — кабахәт бер хаиннең күпме еллар
Рыяланган Гэстингсның башы инде!

Глостер

Елыйм бүген аның өчен! Мин бит аны
Шундый якын күрә идем! Мин бит аны
Яхшы җанлы, тәкъва булып җиргә иңгән
Эчкерсез һәм чын дус итеп белә идем!
Мин бит аны җанымдагы бөтен серем
Язылa барган китап итеп саный идем!
Ә ул ничек тышкы яхшы күңел белән
Бизәп торган бөтен эчке шакшылыгын!
Дөрес, аның бер гөнаһын белә идем:
Ул һаман да Шор хатынын сөеп йөрде.
Юкса аңа бер дә болай шик юк иде...

Букингэм

Шулай! Шулай! Дөньясында аның кадәр
Яшерен эчле бер мөртәт тә булмас инде!
Әйе, лорд-мэр, фараз итеп ышаныгыз, —
Әгәр дә без сакланмасак, сезгә моны
Исән килеш сөйли алыр идекмени?
Шушы елгыр хыянәтче ниятләнгән
Бүген сарай мәҗлесендә мине үтереп,
Затлы милорд Глостерны юк итәргә!

Лорд-мэр

Расмы соң бу? Чыннан шулай иттеме ул?

Глостер

Ничек «расмы»? Әллә соң без төрекләрме?
Әллә бездә иман юкмы? Ничек соң без
Бер дә хөкем итми генә шул мөртәтне
Бик тиз генә үтерергә базыр идек?
Хаин шундый хәтәр булгач, өлгер булгач,
Англиянең тынычлыгы, үзебезнең
Исән-имин калуыбыз шул мөртәтне
Җәзаларга мәҗбүр итсә гаепмени?

Лорд-мэр

Ярый, әйбәт. Үлем аңар лаек җәза!
Шәп иткәнсез, гали затлар! Инде бу хәл,
Аның төсле астан фетнә кормас өчен,
Бүтән яшерен явызларга сабак булыр!
Миссис Шорга башын игәч, мин аңардан
Артык бер дә яхшы нәрсә көтми идем.

Букингэм

Милорд, аның сез килгәнче дөмегәсен
Без башка да китермәдек. Ләкин безнең
Дусларыбыз безнең сүзгә колак салмый,
Кабаланып эшне бик тиз бетергәннәр.
Лорд-мэр үзе, монда килеп, шул хаиннең
Сүзен тыңлап калсын диеп уйлый идек.
Шулай булса, соңра сезнең телегездән
Аның сүзен шәһәр халкы ишетер иде;
Безгә гаеп ыргытырга, хас дошманны
Кызганырга бер сәбәп тә калмас иде.

Лорд-мэр

Минем өчен сезнең сүз дә җитә, милорд.
Күреп торам, бөтен хәлне ишетеп торам.
Шикләнмәгез, гали затлы шаһзадәләр,
Шушы эшнең гаделлеген, төгәл итеп,
Җиткерермен шәһәрдәге бар халыкка.

Глостер

Без шуңар да сез милордны дәшкән идек,
Юк-бар сүзгә, гайбәтләргә урын калмас.

Букингэм

Бу хәлне бик соң күрсә дә сезнең күзләр,
Инде моңар шаһит булсын сезнең сүзләр.
Ярый, милорд, хөрмәтле мэр, сау булыгыз.

Лорд-мэр чыгып китә.

Глостер

Бар, бар, туган, артыннан бар, Букингэм, син!

Мэр ук булып очып китте Ратушага.
Анда баргач, уңай вакыт чыгу белән
Телгә ал син әлеге Эдвард әнчекләрен.
Сөйлә шуны: ничек беркөн король Эдвард
Бер бәндәне гаепсездән һәлак итте, —
Нәрсә өчен? Бер сүз өчен! Теге әйткән,
Үзем үлгәч, улыма тажны бирәм, дигән.
Тажы нәрсә? Шул адәмнән капка башын
Бизәп торган таҗ билгесе! Ягъни мирас!
Исләренә төшер тагын, аның ничек
Кәеф-сафа, хәрәм малда йөзгәнлеген;
Хатын-кызга Иблис төсле ымсынганын;
Бүтәннәрнең хатыннарын, асрауларын,
Яшь кызларын рисвай итеп ташлаганын;
Азгын күзе, кыргый җаны кайда йөрсә —
Шунда аның корбаннары калганлыгын.
Уңай чыкса, син миңа да азрак кагыл.
Шулай диген: минем әнием шушы ач күз,
Бозык җанлы Эдвардына йөкле чакта,
Гали затлы әтием Йорк озак вакыт
Франциядә яуда йөргән. Кайту белән
Көн-сәгатен санап алгач, ачык белгән,
Юк, бу, дигән, минем балам түгел, дигән.
Чөнки аның йөзендәге бер сызык та,
Бер сыйфат та Йоркныкына охшаш түгел.
Ләкин саграк кагыл моңа. Тирән кермә.
Чөнки минем әнкәй һаман дөньяда бит!

Букингэм

Шикләнмәгез моңа, милорд. Мин үземне
Шундый итеп танытырмын. Әйтерсең мин
Алтын бүләк казанган бер мут оратор!
Ярый, милорд, сау булыгыз.

Глостер

Эшең чыкса,
Иярт тә кил барсын Бэйнард крепостена,
Сез килгәндә минем янда булыр фәкать
Изге аталар, галим, зирәк епископлар.

Букингэм

Китәм, милорд. Сәгать өчтә-дүрттә инде
Ратушадан яңалыклар көтегез сез!
(Китә.)

Глостер

Йөгер, Ловель, бик тиз генә доктор Шоуга,
Ә син, Кэтсби, бар да монах Пенкерга әйт:
Ашыксыннар тизрәк крепостена!

Ловель белән Кэтсби чыгып китәләр.

Хәзер бирәм яшерен әмер: күз алдымнан
Кларенсның әнчекләре ерак булсын.

Әйтәм тагын фәрман итеп, бер адәм дә,
Ярдәм сорап, принцларга сыенмасын.
(Китә.)

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Лондон. Урам. Язгын керә.

Язгын

Менә монда Гэстингсның бар тәкъдире!
Кул куелган. Лорд — гаепле. Инде үлгән.
Изге Павел чиркәвендә укый бүген...
Әллә ничек... Барсы монда сәер төсле.
Кичә кичен Кэтсби миңа моны биргәч,
Баш күтәрми унбер сәгать күчердем мин.
Төп нөсхә дә бик озаклап язылган шул!
Тик шулай да бер биш сәгать элек кенә
Лорд Гэстингс яши, йөри, сулый иде, —
Тыныч иде, азат иде, бер табым да,
Бер керем дә юк минем дип уйлый иде.
Дөнья нинди сәер хәзер! Нинди ахмак
Бу ап-ачык явыз эшне күрми икән?
Күрсә ни соң? Күрдем, диеп әйтер өчен
Кемдә генә дәрт, кыюлык җитәр икән?
Дөнья шыксыз, җитеп килә ахырзаман,
Хәтәр эшләр ешайгачтын илдә һаман...
(Китә.)

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лондон. Бэйнард крепостеның ишегалды.
Бер яктан — Глостер, икенче яктан Букингэм керә.

Глостер

Эшләр ничек? Эшләр ничек? Халык ни ди?

Букингэм

Мәрьям-ана исеме белән ант итәм мин:
Шәһәр халкы таш сын төсле сүзсез торды.

Глостер

Әйттеңме соң теге Эдвард балаларын
Һич тә патша нәселеннән түгел, диеп?

Букингэм

Ничек кенә! Аның леди Люси белән
Бәйләнешен, Франциянең принцессасы
Бона белән багланышын әйтеп бирдем.
Аның туймас гуҗ шикелле кыйланышын,
Аның бик күп хатын-кызны көчләүләрен,
Юк-бар өчен кансызлыгын — барын әйттем.
Әйттем шуны, ул үзе дә ят кан, дидем;

Атасы Йорк Франциядә сугышканда
Әйткән көне туры килми туган, дидем.
Герцог белән бер дә охшаш түгел, дидем.
Шуннан сезнең охшашлыкны искә алдым,
Төсе белән, гали рухы, җаны белән,
Бер дә шиксез, нәкъ әткәсе инде, дидем.
Әйттем сезнең Шотландиядә җиңүләрне,
Сугыштагы батырлыкны, тынычтагы
Зирәклекне бәйнә-бәйнә сөйләп үттем.
Сезне юмарт, изге җанлы, тыйнак, дидем.
Ихлас менә, сезнең шушы ният өчен
Кулай булгач, һичнәрсәне онытмадым!
Сүзем очлар чакта гына шулай дидем:
Әгәр дә кем сөйсә илнең мәнфәгатен,
Минем арттан әйтсен дидем: «Мең яшәсен
Бөек Ричард, Англиянең чын короле!»

Глостер

Ничек, бар да кычкырдымы? Нишләделәр?

Букингэм

Ярдәмең бир, Раббым Алла! Юк шул, милорд!
Беркем бер сүз кычкырмады! Торды барсы
Телсез сыннар, сулый торган ташлар төсле.
Бер-берсенә күз терәшеп катты бар да,
Мәет төсле, һәммәсенең йөзе ап-ак!
Моны күргәч, мин аларга ачуландым,
Сорау бирдем аннан мэрга: әйтче, дидем,
Мондый тирән, шикле тынлык ни дигән сүз?
Җавап бирде: безнең халык тыңлый, диде,
Хәбәр әйтеп йөрүчеләр сүзен генә, —
Имеш, алар күнекмәгән! Аннан соң мин
Куштым аңар минем сүзне кабатларга.
Мыгырданды халыкка мэр: «Герцог әйтте,
Герцог уйлый»... фәлән, имеш, төгән, имеш,
Тик үзеннән ярты сүз дә өстәмәде.
Ул бетергәч, минем кайбер әшнәләрем,
Залның арткы почмагында торган килеш,
Бүрекләрен чөеп куйды. Унлап кеше
Кычкырдылар беравыздан: «Мең яшәсен
Бөек Ричард, Англиянең чын короле!»
Мин, шуңардан файдаланып, болай дидем:
«Рәхмәт сезгә, шәһәрдәшләр, якын дуслар!
Шушы дәртле, күтәренке шат тавышлар
Сезнең якты зирәклекне һәм Ричардка
Сезнең җылы мәхәббәтне раслый», — дидем;
Аерылдым да бик тиз генә монда чаптым.

Глостер

Нинди телсез бүкәннәр бит! Дәшмиләр, диң!
Мэр һәм аның яраннары килмимени?

Букингэм

Мэр хәзер үк килеп җитәр. Ә сез аңар
Борчулырак күренегез. Бик тиз генә
Алар белән сөйләшмәгез. Ялынсыннар.
Кулыгызга тотып изге догалыкны,
Торыгыз сез ике остаз арасында, —
Ә мин сездән кабат-кабат үтенермен.
Әмма безнең гозерләргә тиз күнмәгез,
Ни әйтсәк тә, гел «юк!» диегез, кызлар кебек.

Глостер

Ярый, китим. Мин «юк, булмый» дигән саен,
Мине тагын куәтлерәк үгетләрсең, —
Һич шөбһә юк: безнең бу эш тәмам уңар!

Букингэм

Сез барыгыз. Әнә лорд-мэр шакылдата.

Глостер китә. Лорд-мэр һәм шәһәр аксакаллары керәләр.

Әйдүк, милорд. Күптән монда биеп торам.
Ахры, герцог безне бүген кабул итмәс.

Крепостьтан Кэтсби чыга.

Ничек, Кэтсби? Минем сүзгә герцог ни ди?

Кэтсби

Иртәгә дип сорап калды сездән, милорд,
Яки соңрак, бүтән көнне килсен, диде.
Эчтә утыра ике галим остаз белән, —
Бар ихластан иелгәннәр догалыкка.
Шушы изге фигыленнән аны һичкем,
Һичбер дөнья мәшәкате аера алмый.

Букингэм

Кэтсби туган, бар тагын да сөйлә аңар, —
Мин, Букингэм, шәһәр мэры һәм өлкәннәр
Сезнең янга гадәттән тыш зур эш белән,
Безнең уртак максат өчен мөһим булган
Кичектермәс йомыш белән килгән, диген.

Кэтсби

Киттем тагын. Шулай диеп әйтәчәкмен.
(Китә.)

Букингэм

Ай-һай, милорд, бу принц шул Эдвард түгел!
Изрәп ятмый хәрәм сарай түшәгендә, —
Догалыклар укып тора тез өстендә!
Төчеләнми ике фәхеш хатын белән, —
Каршысында ике остаз вәгазь укый.
Йоклап ятмый тәнен майга каплар өчен, —
Дога кыла җанын һаман сафлар өчен!
Шул изге җан дәүләт эшен кулга алса,
Һай бәхетле булыр иде Англиябез!
Ләкин куркам, ризалатып булмас, ахры.

Лорд-мэр

Сакла, Ходам! Кире генә какмасынчы!

Букингэм

Куркам, кагар. Менә тагын Кэтсби килә.

Кэтсби керә.

Нихәл, Кэтсби, әйт, гали зат нәрсә диде?

Кэтсби

Гажәпләнә, шундый бер зур төркем җыеп,
Ни өчен соң минем янга килгән ул, ди.
Алдан беркем белдермәде бу хакта, ди.
Начар ният белән килгән бугай ул, ди.

Букингэм

Эх, авыр шул, туган кешең менә шулай
Шөбһә тотса, күрсә синдә начар ният!
Хода шаһит! Аңар килдем саф хис белән.
Бар, хәзер үк җиткер шуны гали затка!

Кэтсби китә.

Тирән диндар изге җаннар тәсбих тартып
Дога кылып утырганда бик кыен шул, —
Алар өчен бик ләззәтле изге вакыт!

Глостерны ике ягыннан култыклаган килеш галереядан ике епископ төшә.
Кэтсби керә.

Лорд-мэр

Кара, кара, ихтирамлы герцогыбыз
Атлап килә ике остаз уртасында!

Букингэм

Чын христиан принц өчен алар икесе
Ныклы ике терәк төсле. Шуңар да ул —
Изге адәм, гөнаһлардан азат кеше.
Күр син аның кулындагы догалыкны, —
Изге өчен иң лаек бер бизәк бит ул.
Бөек принц шан-шәрәфле плантагенет!
Сал мөбарәк колагыңны безнең сүзгә!
Кичер, зинһар, сине тирән гыйбадәттән,
Саф христиан фигыленнән аерып алдык!

Глостер

Нигә, милорд? Монда сезнең бер гаеп юк!
Сорыйм сездән, зинһар, мине кичерегез:
Мин бик тирән, тын сәждәгә киткән идем,
Сез дусларны көттерергә мәҗбүр булдым.
Монысы калсын. Ни йомыш бар сездә, милорд?

Букингэм

Сорыйм сездән Хак Тәгалә теләгәнне,
Үтенәм сездән падишаһсыз ятим калган
Утравыбыз кешеләре эстәгәнне...

Глостер

Куркам, әллә шәһәр халкы күз алдында
Абруемны төшергән бер эшем бармы, —
Мин аңсызны орышыр өчен килдегезме?

Букингэм

Сез бик хаклы. Гаебегез бар шул сезнең!
Әмма хәзер, безнең сүзгә колак салып,
Төзәтергә була моны, затлы милорд!

Глостер

Шикләнмәгез, төзәтермен. Сезнең күк үк
Христианнар торган илдә яшим ич мин!

Букингэм

Яхшы тыңла, синең гаеп менә шунда:
Ваз кичәсең сиңа лаек таж-тәхеттән,
Баш тартасың бабаларың мирас иткән
Киң хокуклы варислыктан, тумышыңнан,
Данлы король токымының бурычыннан!
Ваз кичәсең — патша йорты агачының
Төптән черек бер тармагы файдасына!
Син, төш күреп, сабыйларча йоклаганда,
Бу газиз ил мохтаҗ калды сау ботакка;
Аның йөзен мәсхәрәләп кутыр басты,
Патша ыруы шәҗәрәсен гөмбә сарды.
Патша йорты мәңгелеккә онтылырга
Җилкәсеннән төшеп батты дөм упкынга.
Шуны уйлап, илебезнең бәхете өчен
Килдек бүген сине тизрәк уятыйк дип.
Сорыйбыз без чын күңелдән, галиҗәнап,
Ил турында кайгыртуны, падишалык —
Хакимлекне алмассыңмы үз кулыңа?
Протектор, урынбасар булып түгел,
Васый булып, өлкән абза булып түгел,
Патшалыкка каны, җаны, тумышы да,
Сафлыгы да шөбһәсез бер варис булып!
Шуңар күрә, шәһәр халкы бик сорагач,
Синең якын, чын дусларың бик үтенгәч,
Кире какмый шушы кайнар теләкләрне,
Килдем монда, син гали зат каршысына.

Глостер

Нәрсә диим? Берни әйтми ташлап китим?
Әллә инде «хурлама» дип ачуланыйм?
Сезнең шушы сүзегезгә һәм үземнең
Тыйнак кына дәрәҗәмә кайсы лаек?
Җавап бирми китеп барсам, сез уйларсыз,
Патшалыкның алтын йөген күтәрергә
Бу, дансөяр, эчтән инде бик риза, дип, —
Чөнки шуны салмакчысыз минем өскә.
Әгәр сезнең шушы сүзгә ачулансам?

Булмый! Чөнки үтенәсез якын күреп, —
Дусларымны кыерсытып җибәрермен...
Дәшми китеп, сезне шиккә салмас өчен,
Оршып китеп, үкенечкә калмас өчен,
Бирәм сезгә шушы катгый җавабымны:
Сезнең хөрмәт лаек минем рәхмәтемә,
Тик хезмәтем лаек түгел шул хөрмәткә, —
Шуңар сезнең үтенечтән артка чигәм.
Минем юлда киртә-фәлән тормаса да,
Хаклы принц, яшькә җиткән варис булып,
Язмыш мине һаман тажга китерсә дә,
Мин бу шанлы дәрәҗәдән качар идем.
Чөнки минем башым җитми андый эшкә,
Кимчелекле ягым дисәң — артып китә.
Чал диңгездә чыдый алмый минем каек,
Мин җитәчәк биеклеккә башын бәреп,
Шан-шәрәфем томанында хур булачак...
Әмма, шөкер, миңа мохтаҗ түгелсез сез,
Үзем әзер сез-дусларым хезмәтенә!..
Ләкин безнең патшалыкның карт агачы
Патшалыкка лаек булган җимеш бирде.
Сулар агар, җилләр исәр һәм бу җимеш,
Пешеп җитеп, тажны кияр. Хаким булып
Безне, шиксез, бик бәхетле, шат итәр ул.
Миңа түгел, аңар тиеш андый абруй!
Сакла, Ходам, аның бәхет йолдызына,
Аның хәләл тәхетенә кул тидермәм!

Букингэм

Ярый, милорд, Сезнең телдән намус сөйли.
Әмма шушы, сез китергән күп дәлилләр,
Барсы да вак, нәтиҗәгез ышандырмый.
Эдвард принц туганымның улы, дисез,
Ярый, без дә шулай дибез. Әмма бит ул
Король Эдвард хатынының улы түгел!
Ярәшкән ул башта леди Люси белән, —
Кирәк булса — моңа шаһит карт анагыз.
Аннан килеп, Франция короленең
Сеңелкәше Бона белән ярәшкән ул.
Аннан соң бу кәләшләрне читкә кагып,
Эдвард җанын биләп алды беләмсең кем?
Бер саилче, матурлыгы шиңеп беткән,
Күп балалы, җыерчыклы бер тол хатын,
Акыл җуйган бер ирдәүкә — менә кем ул!
Ул, Эдвардның туймас күзен ымсындырып,
Менеп аның бөек мөнбәр баскычына, —
Никах бозу языгына тәгәрәтте...
Һич никахсыз шул тәхеттә хәзер халык
Принц диеп атап йөргән Эдвард туды!
Сезгә тагын күпне исбат итәр идем,
Ярый инде, бүген исән кешеләрнең
Намусларын хөрмәт итеп телем тыям.

Шулай, милорд, әйдә кабул кылыгыз сез
Без кыстаган шушы бөек дәрәҗәне!
Безнең өчен, Ватан өчен түгел икән,
Булсын әйдә династиябез хөрмәтенә, —
Даулы еллар өйгән шушы сасылыктан
Мәңгелеккә патша йортын сафлау өчен!
Булсын әйдә хаклы, лаек варисларга
Тажны бирү гадәтләрен саклау өчен!

Лорд-мэр

Зинһар, милорд! Сездән моны халык сорый!

Букингэм

Кире какма безнең шушы ихтирамны!

Кэтсби

Сөенсеннәр, күрсәтегез кече күңел!

Глостер

Ah, ник миңа шундый йөкне күтәртәсез?
Миңамы соң патша хәтле патша булу?
Үтенәм мин, зинһар, начар уйламагыз:
Булмый миннән! Юк, мин моңа риза түгел!

Букингэм

Тыйнаклыгың, йомшаклыгың аркасында
Туганыңның улын әгәр таҗ-тәхеттән
Мәхрүм итеп калдырырга теләмәсәң, —
Безнең сүз бер. Без беләбез йөрәгең саф,
Күңелең пакь, үзең — затлы, мәрхәмәтле,
Кызлар төсле назлы, иркә. Без күрәбез:
Туганнарың өчен дә син һәм шулай ук
Бөтен халык өчен дә син яхшы җанлы!
Тагын шуны беләбез без, безнең сүзне
Тыңлыйсыңмы, әллә юкмы — синең энекәш
Беркайчан да безнең илдә король булмас!
Тәхет өчен табарбыз без бүтән кеше, —
Йортыгызның даны төшәр, исеме черер!
Без китәбез шушы катгый карар белән!
Әйдә, дуслар, җитәр инде, күп ялындык!

Букингэм, Лорд-мэр һәм шәһәр аксакаллары чыгып китәләр.

Кэтсби

Милорд, кире чакырыгыз, килешегез!
Юкса бу хәл бөтен илгә каза булыр.

Глостер

Һем, сез миңа дөнья йөген күтәртмәкче!
Ярый, әйдә чакырыгыз...

Кэтсби китә.

Мин таш түгел.
Шундый каты ялваргачтын риза инде,
Тик вөҗданым риза түгел, җаным каршы.

Букингэм, Лорд-мэр, Кэтсби һәм башкалар керәләр.

Син, Букингэм, һәм сез, зирәк, зур хуҗалар,
Минем шушы тар җилкәмә дөнья кадәр
Дәүләт йөген саласыз бит! Мин ни эшлим?
Булдыраммы, юкмы моны — чыдыйм инде!
Сезнең шушы зур вазифа аркасында
Булса әгәр кара гауга, юк-бар гайбәт, —
Онытмагыз: сез үзегез мәҗбүр иткәч,
Мин азатмын пычрак сүздән, кара таптан.
Алла белә, сез дә моны күрәсез бит:
Хакимлеккә сусаудан мин ерак торам!

Лорд-мэр

Ходай сезгә ярдәм бирсен, галиҗәнап!
Күреп тордык, шулай диеп әйтербез дә!

Глостер

Шулай диеп әйтсәгез дә, тик дөресен!

Букингэм

Тәбрик итәм сезне бөек исем белән!
Мең яшәсен король Ричард, Англиянең
Чын короле!

Барысы да

Амин.

Букингэм

Ничек, сез иртәгә
Король тажын башыгызга киярсезме?

Глостер

Сезнең өчен кайчан яхшы — шуңа риза.

Букингэм

Алай булгач, иртәгә дип карар бирик,
Сезне ипләп карарбыз без, галиҗәнап!
Ярый, китим. Җаным тулы шатлык минем!

Глостер

(епископларга)
Әйдә укыйк моның тагын бу битләрен!
(Башкаларга.)
Сау бул, туган! Сау булыгыз, дус-ишләрем!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Товер алды. Бер яктан королева Елизавета, герцогиня Йорк һәм маркиз Дорсет, икенче яктан Кларенсның бәләкәй кызы леди Маргарита

Плантагенетны җитәкләп леди Анна керәләр.

Герцогиня

Кемнәр болар? Нәни кызым, Плантагенет?
Күр, җиңгәсе Анна ничек җитәкләгән!
Биллəһи, ант, алар ашыга Товерга дип,
Принцларны саф күңелдән сәламләргә!
Хәерле көн сиңа, кызым!

Леди Анна

Ходай сезгә
Хәерле көн бүләк итсен, бәхет бирсен!

Елизавета

Мин дә сезгә шуны телим! Кая болай?

Леди Анна

Без Товерга бара идек. Ялгышмасам,
Сез дә затлы принцларга сагынычлы
Кайнар сәлам әйтер өчен барасыз күк?

Елизавета

Шулай, дөрес, сеңелкәшем. Әйдә бергә!

Брэкенбери керә.

Бик шәп булды! Менә Товер коменданты!
Сорыйм, милорд, әйтмәссезме принц белән
Минем улым — нәни Йоркым ничек калды?

Брэкенбери

Бик шәп, мадам. Сезнең хәер-фатихада.
Ләкин сезгә керер өчен рөхсәт булмас.
Чөнки король шулай диеп кисеп әйтте.

Елизавета

Король? Кем ул?
Брэкенбери

Ягъни дәүләт башлыгыбыз.

Елизавета

Тик дәүләткә баш итмә син, Ходай, аны!
Сакла, Раббым, аны король исеменнән!..
Шул киртәме хәзер безнең арабызда?
Мин аларны тапкан ана, — каршы төшмә!

Герцогиня

Мин аларның аталарын тапкан кеше, —
Күрим бүген мин аларны, киртә куйма!

Леди Анна

Кардәшлектә алар өчен бер апа,
Мәхәббәттә ләкин инде мин бер ана.
Җибәрегез яннарына! Сез күрәчәк
Тәнбиһләрне, сез бирәчәк җавапларны

Курыкмыйча алам әйдә үз өстемә!

Брэкенбери

Булмый, мадам. Ничек сезгә рөхсәт итим?
Әмер шундый. Эшем шундый. Гаепләшмик.

Китә. Стэнли керә.

Стэнли

(герцогиня Йоркка)
Әгәр монда тик бер сәгать соңрак килсәм,
Ике гүзәл королева ханым өчен —
Тугрылыклы, мәрхәмәтле ана күреп,
Анабыз Йорк, сезне тәбрик итәр идем...
(леди Аннага.)
Әйдә, мадам, вестминистр сезне көтә, —
Анда, король-королева исмен алып,
Таҗ киясез Ричард белән икегез дә!

Елизавета

Ah, чиш әйдә билемдәге шул тасманы!
Юл бир әйдә, ныграк типсен тоткын йөрәк!
Юкса хәзер шул үтергеч хәбәрдән соң
Мин һушымнан язачакмын!..

Леди Анна

Шомлы хәбәр!
Шундый авыр, миһербансыз яңалыклар!

Дорсет

Тынычланыйк. Әнкәй, ничек көн итәсез?

Елизавета

Улым Дорсет, бер сүз әйтмә. Бар, тиз йөгер!
Һәлакәтнең, ач үлемнең шашкан эте
Табаныңа басып килә, бар, кач, ычкын!
Әнкәгезнең исеме шомлы сезнең өчен!
Һәлакәттән кача алсаң, диңгезләр кич!
Җәһәннәмнән ерак тор син, Ричмондны тап!
Бар, тизрәк кач канлы үлем туфрагыннан,
Илдә корбан кимрәк булыр бер кешегә!
Маргарита каргышының колы булып,
Бер баласыз, ирсез калып, Англиянең
Тәхетеннән мәхрүм булып үлмим инде!

Стэнли
(Дорсетка)

Бар, форсатны ычкындырма, йөгер әйдә!
Мин хат бирәм сиңа улым Ричмонд өчен,
Ул бик якын. Очрар синең юлда гына...
Мыштырдама мәгънәсезгә. Соңга калма.

Герцогиня

Ай кайгының дулап торган азгын җиле!

Ой бәдбәхет, нәләт төшкән шул карыным!
Әй рәхимсез үлем биргән шул түшәгем! —
Кара елан тудырдыгыз сез бу җиргә,
Үлем генә сибә аның күз карашы...

Стэнли
(леди Аннага)

Китик, ханым. Миңа тизрәк бул, диделәр.

Леди Анна

Барам, ләкин йөрәк кушмый, күңел тартмый.
Әй бер Ходам, алтын таҗның тар бөҗрасы,
Уттай кызган тимер булып маңгаемны
Кысып алсын, мием эреп аксын икән!
Маңгаема сөртелгән май агу булсын! —
Ялагайлар: «Мең яшә син, королева!» —
Дип әйткәнче, Ходай җаным алсын икән!

Елизавета

Көнләшмим мин бәхетеңнән, көлмим синнән!
Үзеңә үзең бәла дәшмә, бичара җан!

Леди Анна

Ничек инде? Хәзер ирем булган кеше,
Генрих мәетен күмәр өчен озатканда,
Минем янга килеп чыкты. Кулларыннан
Минем гүзәл фәрештәдәй яшь иремнең,
Үзен елап алып барган чал атамның
Изге каны тамчы-тамчы саркый иде...
Әйттем шунда, туры карап, мин Ричардка
Һәм теләдем тик бер теләк: сиңа, дидем,
Нәләт төшсен мине шулай япь-яшь көем
Чал чәчле бер тол иткәнең өчен, дидем.
Әгәр дә син никахлансаң, түшәгеңне
Кайгы-хәсрәт эзәрлекләп торсын, дидем.
Сиңа чыгар бер тиле баш хатын булса,
Синең белән бергә торып көн иткәндә,
Минем ирем, әткәм үлгәч, мин күргәннән
Мең кат артык авыр газап чиксен, дидем.
Бәддогамны кабат әйтим дигән идем,
Шунда бик тиз хатын-кызга хас йөрәгем
Аның татлы сүзләренә әсир булды, —
Үзем әйткән шушы каргыш үземә төште...
Шул көннән соң керфекләрем йома алмыйм,
Чөнки аның түшәгендә бер сәгать тә
Татый алмыйм саф йокының алтын ямен,
Ул төш күреп кычкыруга — кылт уянам...
Озакламый ул мине дә юлдан алыр, —
Күрә алмый әтием Варвик аркасында.

Елизавета

Хуш, бичарам. Синең хәлне бик кызганам.

Леди Анна

Аннан күбрәк синең өчен мин кайгырам.

Дорсет

Сау бул, мескен. Данны елап каршылыйсың.

Леди Анна

Хуш, фәкыйрем. Даннан елап аерыласыз.

Герцогиня

(Дорсетка)
Йөгер әйдә Ричмондыңа. Юлың уңсын!
(леди Аннага.)
Ашык әйдә Ричардыңа, бик борчылма, —
Саклар анда сине изге фәрештәләр!
(Королева Елизаветага.)
Юнәл әйдә монастырьга, изге уйлар
Юлдаш булыр анда сиңа. Ә мин инде
Сыенырмын соңгы урыным — тар кабергә, —
Кочып ятар мине анда ял һәм тынгы...
Мин сиксән ел гомер иттем. Яшьтән бирле
Шат бер сәгать бер атналык хәсрәт бирде.

Елизавета

Тукта, китмә. Кил, Товерга карыйк икәү!
Әй борынгы авыр ташлар, кызганыгыз,
Көнче куллар калын, биек дивар белән
Урап куйган газизләрем — улларымны!
О син, Товер, улларымның таш бишеге,
Тупас сүзле, ярсу канлы тәрбияче!
О таш төрмә, принцларга шомлы иптәш,
Алар өчен чытык йөзле бер уендаш!
Зинһар өчен, сакла минем бәбкәйләрне!
Акыл китте, кайгы килде башларыма, —
Сау бул инде, баш иям мин ташларыңа!

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Король сарае. Тәхет залы. Торба тавышлары. Ричард король тәхетендә утыра.
Аның каршысында — Букингэм, Кэтсби, Паж һәм башкалар.

Король Ричард

Бар, читтәрәк торыгыз сез. Әй, Букингэм!

Букингэм

Әйе, тыңлыйм, ни бар, патша хәзрәтләре?

Король Ричард

Бир кулыңны, мине мондый биеклеккә
Алып менде синең киңәш, синең ярдәм.
Синең Ричард хәзер король тәхетендә!
Ләкин бу дан безнең өчен бер көнгәме,
Әллә бу шат, рәхәт вакыт бик күпкәме?

Букингэм

Бу бик күпкә. Көнгә түгел, мәңгелеккә!

Король Ричард

Ах, Букингэм! Ярый, сине тагын сыныйм:
Син чыннан да саф коелган алтын микән?
Нәни Эдвард һаман исән! Төшендеңме?

Букингэм

Әйе, тыңлыйм, галиҗәнап.

Король Ричард

Ах, Букингэм!
Яхшы тыңла! Тизрәк король булыр идем...

Букингэм

Король ич сез, минем шанлы хөкемдарым!

Король Ричард

Һа, мин король! Шулай. Ләкин Эдвард исән!

Букингэм

Рас бу, рас бу, затлы принц!

Король Ричард

Ох, шулай шул!
Никадәрле начар мәгънә синең сүздә!
Димәк, Эдвард һаман яшәр, исән йөрер?
Рас бу, имеш, принц, имеш, харап инде!
Син, гадәттә, болай аңсыз түгел идең, —
Ачык итеп әйтимме әллә сиңа, кардәш?
Беләмсең, мин шул уйнаштан туганнарның
Үлүен телим. Бүген булсын! Хәзер булсын!
Син ни дисең? Әйт хәзер үк, тик кыска тот!

Букингэм

Падишаһым нәрсә тели — шуны кылыр.

Король Ричард

Ай-һай, туган! Синең җаның боз икән шул!
Яхшы җаның хәзер тәмам туңып каткан!
Әйт, мин сиңа ышаныммы шушы эшне?

Букингэм

Сезгә, милорд, уңай җавап бирер өчен,
Бераз гына тын алыйм да уйлап керим.
Минем карар тиз вакытта әзер булыр!
(Чыгып китә)

Кэтсби
(күршесенә.)

Король никтер ачуланган. Иренен тешли.

Король Ричард

(тәхетеннән төшә-төшә)

Юк! Мин хәзер сер әйтермен башкаларга!
Тимер җанлы, чүпрәк башлы ахмакларга,
Мәми авыз малайларга ышанырмын!
Күпне белгән караш белән шулай миңа
Күзен текәп караучылар кирәк түгел!
Букингэм да түрә булды! Сак кыйлана!
Әй син, малай!

Паж

Әйе, тыңлыйм, галиҗәнап.

Король Ричард

Белмисеңме, черегән бер алтын биреп,
Кемнән кеше үтертергә мөмкин икән?

Паж

Ах, мин беләм шундый усал бер бәндәне!
Төскә — батыр, әмма инде кесә такыр!
Алтының бир, кирәк түгел йөз үгетчең,
Кем ни куша — һәммәсенә риза инде!

Король Ричард

Исеме ничек?

Паж

Джемс Тиррель, галиҗәнап.

Король Ричард

Азрак беләм. Бар, чап, егет, чакыр үзен!

Паж чыгып китә.

Зирәк уйлы, тирән эчле Букингэмны
Моннан болай үзем өчен сердәш итмәм!
Минем белән армый-талмый күпме чапты,
Тын алыйм дип туктый хәзер! Ярый, тукта!

Стэнли керә.

Лорд Стэнли, нәрсә синдә, нинди хәбәр?

Стэнли

Галиҗәнап, мин ишеттем, маркиз Дорсет,
Качып китеп, Ричмонд белән кушылган, ди.

Король Ричард

Әй син, Кэтсби, тирә-якка хәбәр тарат:
Минем хатын Анна бик нык авырып тора.
Аны бикләп тотарга, дип әмер бирәм.
Эзлә, күзәт: Кларенсның кызы өчен
Юкмы шунда уртачарак берәр кияү, —
Өйләндерәм хәзер үзен шушы кызга!
Улы — тинтәк. Курыкмаска була аннан.
Йоклап торма! Кабат әйтәм: хәбәр тарат,
Королева бик нык чирли, үләр, ахры.

Шулай диген. Миңа зыян итәр өчен
Бүтәннәрдә бер өмет тә калмас инде...

Кэтсби китә.

Үзем алам туган абыем Эдвард кызын,
Шунсыз минем патшалыгым ышанычсыз,
Нәкъ пыяла валчыгында тора төсле...
Туганнарын кырып бетер, үзенә өйлән!
Бик үк тигез юл түгел шул! Инде канга
Шулкадәрле тирән баттым, гөнаһ өсте
Гөнаһ эшләп, шулкадәрле төпкә киттем —
Белми күзем кызганудан яшь түгүне!

Паж һәм Тиррель керәләр.

Исемең ничек? Теге Джемс Тиррельме син?

Тиррель

Джемс Тиррель. Итагатьле бер колыгыз.

Король Ричард

Чынлап торып Тиррельме син?

Тиррель
Нәкъ шул үзе.
Тикшерегез, галиҗәнап.

Король Ричард

Ризамы син,
Әйтик, минем берәр дусны үтерергә?

Тиррель

Боерыгыз. Әмма тизрәк әзермен мин
Сезнең ике хас дошманны юк итәргә!

Король Ричард

Ярый, әйбәт! Беләсеңме, шат көнемне
Ике дошман бозып тора; төн йокымны,
Рәхәтемне шулар гына борчып тора.
Бирәм, Тиррель, синең кулга мин аларны,
Ягъни шушы Товердагы әнчекләрне!

Тиррель

Берәр ачык сәбәп табып керә алсам,
Коткарам мин сезне алар хәвефеннән!

Король Ричард

Әйбәт, Тиррель. Синең сүзең матур бер җыр!
Менә кәгазь. Тор, монда кил. Яхшы тыңла.
(Пышылдап.)
Бөтен боерык менә шунда. Эшне бетер.
Сине көтә якты чырай, лаек бүләк!

Тиррель

Мин хәзер үк! Бик тиз тотам!

Тиррель китә. Букингэм керә.

Букингэм
Галиҗәнап!
Сезнең соңгы боерыкны ялгыз гына
Бөтен яклап уйлап килдем.

Король Ричард

Калып торсын!
Дорсет качып, Ричмонд белән кушылган, ди.

Букингэм

Мин ишеттем. Шулай ди шул, галиҗәнап.

Король Ричард

Кара, Стэнли! Кем ул Ричмонд? Син онытма:
Ул бит синең хатыныңның килгән улы!

Букингэм

Хөкемдарым! Хәтерләтим вәгъдәгезне, —
Сез, нык итеп, намус белән сүз бирдегез,
Миңа Герфорд графлыгын, король Эдвард
Биләмәсен бүләк итмәк булдыгыз сез.

Король Ричард

Хатыныңны күзәт, Стэнли. Әгәр дә ул
Ричмондына хатлар язса — син җаваплы!

Букингэм

Падишаһым ни ди минем хак таләпкә?

Король Ричард

Минем истә бер ел Генрих Алтынчының
Ричмонд, имеш, король булыр дигән сүзе.
Ричмонд әле селәгәй бер малай иде...
Король диген! Алай булгач...

Букингэм
Галиҗәнап!

Король Ричард

Алай булгач, миңа шуны әйткән икән,
Ник миңа ук әйтмәгән соң шул әүлия
Үзенең менә минем кулдан үләчәген?

Букингэм

Теге графлык турындагы сезнең вәгъдә...

Король Ричард

Ричмонд диген! Күптән түгел, Экзетерда
Соңгы тапкыр булган чакта, шәһәр мэры,
Бер замокка кулы белән ишарәләп:
«Күрәсезме, әнә Руджмонт!» — диде миңа.
Таныш исем! Ишеткәчтен тетрәп киттем.
Чөнки элек Ирландиянең бер җырчысы:
«Ричмонд йөзен күрү белән дөньяда син
Артык озак яшәмәссең!» — дигән иде...

Букингэм
Хөкемдарым!

Король Ричард

Әү, нәрсә бар? Сәгать ничә?

Букингэм

Батырчылык итәм, милорд, миңа биргән
Вәгъдәгезне исегезгә төшерергә...

Король Ричард

Сәгать ничә?

Букингэм

Хәзер менә унны суга.

Король Ричард

Ярый, суктыр.

Букингэм

Ничек инде? «Суктыр» дисез.

Король Ричард

Чөнки һаман, саилче күк хәер сорап,
Синең гозер, минем фикер уртасында
Чайкалсын, гүя зур бер сәгать теле!
Минем бүген юмартлыкка кәеф начар.

Букингэм

Әйтегез соң, ризамы сез, каршымы сез?

Король Ричард

Борчыма, дим. Бүген минем кәеф начар.

Король Ричард һәм башкалар чыгып китәләр.

Букингэм

Барсы шулмы? Миңа күпме хезмәт өчен
Менә шулай нәфрәт белән түлимени?
Шуның өчен үзен король иттемме мин?
Гэстингсны искә алыйм, качып китим, —
Баш сау чакта Брекнокка барып җитим!
Китә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә. Тиррель керә.

Тиррель

Башкарылды канлы бер эш, зур залимлек...
Ак мәкерле, куркынычлы адәм суеш! —
Бу гөнаһны безнең ил дә белми иде...
Дэйтон белән Форрест инде мин җибәргәч
Эшләделәр шул рәхимсез җинаятьне!
Пычак тоткан шул итчеләр, канлы этләр,
Хәтта менә алар да бит шул кайгылы

Һәлакәтне миңа килеп сөйләгәндә, —
Кызганудан эреп китеп, йомшап калып,
Сабыйларча өзелеп-өзелеп еладылар!
Дэйтон әйтте: «Без кергәндә яшь бәбәйләр
Менә шулай икәү бергә яткан иде...»
«Менә шулай, — диде Форрест, — бер-берсенә
Кар төсле ак саф кулларын салган килеш!
Иреннәре җәйге көнне бер сабакта
Үбешеп үскән дүрт чәчәккә охшый иде...
Яннарында ачылып тора изге китап...»
«Моны күргәч, — диде Форрест, — көчем бетте,
Китмәк булдым, ләкин шайтан вәсвәсәсе...»
Шунда явыз туктап калды. Дэйтон аңар
Өстәп куйды: «Шулай, — диде, — табигатьнең
Моңар чаклы беркайчан да тудырмаган
Шушы гүзәл җимешләрен будык», — диде...
Шундый тирән үкенечтән, зур ояттан
Бүтән берни әйтә алмый, алар китте.
Мин дә киттем, бу канечкеч хөкемдарга
Шушы канлы вакыйганы сөйләр өчен...
Чү, үзе дә килә менә!

Король Ричард керә.

Ходай сезгә
Саулык бирсен, галиҗәнап!

Король Ричард

Тиррель туган,
Ни хәбәр бар? Минем өчен шатлыклымы?

Тиррель

Сезнең миңа ышанган һәм мин кылган эш
Әгәр сезгә шатлык булса, шатланыгыз, —
Ул эш тәмам!

Король Ричард

Мәетләрен күрдеңме соң?

Тиррель

Күрдем, милорд.

Король Ричард

Син күмдеңме, Тиррель туган?

Тиррель

Юк шул. Товер капелланы илтеп күмде.
Кайда күмгән, ансын инде әйтә алмыйм.

Король Ричард

Кичен, Тиррель, ашап-эчкәч, син миңа кил,
Алар анда ничек үлде — син барын да
Бәйнә-бәйнә сурәтләрсең. Шуңа чаклы
Сиңа нинди бүләк кирәк, яхшы уйла.

Теләгеңне әйбәт итеп үтәрмен мин.
Хәзергә хуш.

Тиррель

Озын гомер сезгә, милорд.
Китә.

Король Ричард

Кларенсның улын тыктым ташкапчыкка,
Кызын ярлы бер бәндәгә иргә бирдем, —
Дөнья белән саубуллашты хатыным Анна!
Ләкин беләм: Бретаньдагы теге Ричмонд,
Эдвард кызы Елизавета өчен янып,
Тизрәк аңар өйләнергә теләп йөри.
Никахланып, таҗ-тәхеткә үрелмәкче!
Юк, мин барам шат, бәхетле кияү булып!

Кэтсби керә.

Кэтсби

Галиҗәнап!

Король Ричард

Шәп хәбәрме, начар хәлме?
Нигә болай дөбер-шатыр бәреп кердең?

Кэтсби

Начар! Элий епископы Мортон качты!
Ричмонд янына китеп барган. Букингэмның
Уэльстагы зур гаскәре яуга чыккан, —
Коралы күп, көче һаман артып тора.

Король Ричард

Башсыз өерен җыеп чыккан Букингэмнан
Ричмонд белән Элий миңа куркынычрак!
Алга әйдә! Болай курку, хәвефләнү
Кургаш төсле тарта һаман ялкаулыкка.
Мондый акрын мыштырдауны, ташбакадай
Акрын атлап, алып килә дәрмансызлык.
Минем уттай җитезлегем канат булсын,
Меркурийдай алга очып, ерак ларга
«Король килә, король!» диеп хәбәр бирсен!
Җыйнал, гаскәр! Киңәшчем бер — ул да калкан!
Тизрәк булыйк, хаин җаннар яуга чыккан!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сарай алды. Королева Маргарита керә.

Маргарита

Инде менә пешеп җитте җимешләре,

Өзелеп төште шакшы үлем бугазына.
Качкын булып, яшерен генә мин бик озак
Дошманнарым һәлакәтен көтеп йөрдем.
Хәзер моның башлангычын күреп торам,
Өметләнәм: моның ахыры йөз мәртәбә
Куркынычлы, фаҗигале, шомлы булыр...
Китәм хәзер Франциягә. Чү, кеше бар!
Кач, бичара Маргарита, кемдер килә...

Королева Елизавета һәм герцогиня Йорк керәләр.

Елизавета

Ah бичара принцларым, бәбкәйләрем!
Ah ачылып өлгермәгән гөлкәйләрем! —
Тик бик азга җиргә иңгән гүзәлләрем!
Киң һавада очса газиз җаннарыгыз,
Ирешмәгән булса Ходай дәргаһына, —
Минем өстә фәрештәдәй канат кагып,
Әнкәгезнең зар елавын тыңлагызчы!

Маргарита
(үзалдына)

Әйтегез сез: бүтәннәрнең хакын хаклап,
Караңгы төн китте сезнең таңны каплап!

Герцогиня

Күп кайгы-зар карлыктырды тавышымны,
Кайгы сөйләп арган телем — сүзгә ярлы.
Ah, ник үлдең, нәни Эдвард Плантагенет?

Маргарита
(үзалдына)

Эдвард өчен Эдвард үлеп бурыч түли,
Плантагенет өчен түли Плантагенет!

Елизавета

Әй бер Ходам, ник ташладың оланнарым,
Ник ыргыттың шул ач бүре бугазына? —
Ничек булды, кайчан гына йокладың соң?

Маргарита
(үзалдына)

Ирем Генрих, улым Эдвард үлгән чакта!

Герцогиня

Тере мәет, күзле сукыр, җанлы өрәк,
Кайгы йөге, адәм хуры, мескен карчык,
Инде үзен гүр оныткан, исән йөргән,
Кайгы-зарлы күп көннәрне эченә җыеп,
Күңеленә язып барган чал бер кортка,
Ял ит, утыр хаклы илең — Англиянең
Бер хаксызга кан түгелгән туфрагына!

(Җиргә утыра.)

Елизавета

Әй кара җир, ялмы соң бу минем өчен?
Кайчан гына ачарсың син кабереңне?
Синең өстә елап-сыкрап утырганчы,
Синең аста сөяк булып ятар идем!..
Кемдә кайгы, безнең чаклы кем елый соң?
(Җиргә утыра.)

Маргарита
(алар янына килә)

Кем кайгыдан чәч агарткан — шуңа хөрмәт!
Кем хәсрәттә күбрәк янган — шул өлкәнрәк!
Әгәр газап безне бергә кушкан икән —
Зар-сагышны сөйләгәндә мин өстенрәк!
(Алар янына утыра.)
Сөйләгез сез әйдә бөтен кайгыгызны,
Шуңар каршы мин дә әйтим хәсрәтемне:
Улым Эдвард бар иде — Ричард үтерде;
Ирем Генрих бар иде — Ричард үтерде;
Синең Эдвард бар иде — Ричард үтерде;
Синең яшь Ричард бар иде — Ричард үтерде.

Герцогиня

Минем менә бер Ричардым бар иде дә,
Ләкин аны, Маргарита, син үтердең.
Минем тагын бер Рутлэндым бар иде,
Ләкин аны үтертергә дә син булыштың.

Маргарита

Кларенсың да бар иде, ләкин аның
Җанын алды шакшы, явыз синең Ричард.
Безне талар, чәйнәр өчен тәмуг эте
Үрләп чыкты мәлгунь ояң — карыныңнан.
Аның күзе ачылганчы теше үскән,
Көчсезләрне ботарлап, кан эчәргә.
Хак Тәгалә гөл иткәнне көл итүче,
Җир йөзендә аты чыккан бер изүче,
Көн-төн елап ыңгырашкан кешеләрнең
Күз алдында патша булып көн итүче, —
Безне гүргә куар өчен менә шундый
Явыз этне чыгардың син карыныңнан!
Кодрәтең киң, хөкемең хак, Тәңрем синең,
Рәхмәт сиңа, күзем белән күреп торам
Канечкеч эт талый хәзер әнкәсенең
Бәгыреннән өзелеп төшкән балаларны,
Минем янга кайгыдашлар өстәп тора!

Герцогиня

Гарри хатыны, көлмә минем күз яшемнән,
Ходай шаһит, мин гел сине җәлли идем!

Маргарита

Кичер мине. Мин шулкадәр үчкә сусыйм,
Шул үч белән сусынымны басам бүген!
Эдвардымны һәлак иткән Эдвард үлде,
Улым өчен тагын синең Эдвард үлде.
Нәни Йоркың моңар өстәү. Тик алар да
Каплый алмый минем бөек югалтуны!..
Минем улым — Эдвардымны һәлак иткән
Кларенсны үлем алды. Шаһзадәмнең
Фажигасен күреп торган азгын җанлы
Гэстингсны, Риверс, Воган, Грейларны
Кысан кабер кочып алды, яшь димичә!
Ричард исән, җәһәннәмнең бер илчесе,
Кара шымчы, яшерен эчле бер ялчысы, —
Җан ала да илтеп сата җәһәннәмгә...
Якын инде, якын инде хәзер аның
Кызганычсыз һәм кызганыч һәлакәте!
Җирләр тетри, күкләр күкри, җеннәр улый,
Шәһит киткән изге җаннар теләк тели,
Шул залимне җир йөзеннән куар өчен!
Кис, илаһым, тизрәк аның гомер җебен,
«Канечкеч эт тончыкты» дип сөенер идем!

Елизавета

О! Син әйттең, килер, дидең шундый вакыт:
Шул еланны, бөкре, кәрлә үрмәкүчне
Каргашырга чакырырсың мине, дидең...

Маргарита

Аннан соң мин шулай дидем: ясап куйган,
Буяп куйган королева, дидем сиңа.
Минем данга юкка гына кулын сузган,
Бер күләгәм, кызганыч бер шәүләм, дидем.
Мин бардан юк, син юктан бар булдың, дидем.
Эх син, ханча! Тышкы бизәк, ялтыравның
Куркынычын күрсәтмәгән ялган көзге, —
Биек мендең, тирән базга очып төштең!
Язмыш көлеп бала биргән мескен ана,
Үткән данның, бөеклекнең бер шәүләсе;
Теләсә кем үлем угын атар өчен
Әллә каян ялтыраган чуар чүпрәк;
Дәрәҗәнең бер калдыгы, бер тузаны,
Тиз ярылган сабын куыгы, көлке өчен,
Сәхнә өчен королева — менә кем син!
Кайда ирең, кайда хәзер туганнарың?
Кайда синең ике балаң, шат көннәрең?
Кайда, сиңа тезен чүгеп, «Мең яшә син,
Королева!» дигән җыен ялагайлар?
Кайда сиңа баш оручы төче пәрлар?
Синең арттан көтү-көтү йөрүчеләр?
Шуны уйла: син кем идең, хәзер син кем!
Син бәхетле хатын түгел, кайгылы тол,

Син шатлыклы ана түгел, зар елаучы.
Син бүләкче түгел хәзер, бер сораучы!
Син тажлы да түгел хәзер, синең башта
Нәләт төшкән кайгы, сагыш, моң такыясы.
Син җирәндең миңа карап, хәзер инде
Синең өскә карап торып мин җирәнәм.
Син куркыттың, инде үзең куркасың син,
Син тыңлаттың, инде сиңа кем буйсына?
Язмыш — гадел, бик тиз аның тәгәрмәче
Атты сине моң-зар өчен корбан итеп.
Син кем идең — инде моны уйламыйсың,
Син кем хәзер — шуны уйлап сыкранасың.
Талап алдың тәхетемне, инде хәзер
Кил, хуҗа бул зур бер өлеш хәсрәтемә!
Хәзер синең горур муеның кияр инде
Минем ярты газабымның зур камытын!
Тик алҗыдым. Тиздән инде ул йөкне мин
Бар кебеген синең өскә салачакмын.
Ярый, сау бул, Йорк хатыны. Син дә сау бул,
Газап-моңга, кайгы-зарга королева!
Франциядә сезгә хәсрәт теләрмен мин,
Англиянең күз яшеннән көләрмен мин!

Елизавета

Бәддогага син бик оста, тукта, зинһар,
Дошманнарым нәләтләргә өйрәт мине!

Маргарита

Төннәреңдә йокы күрмә, көндез ач йөр,
Кайгырганда шат чагыңны исеңә төшер.
Уйла һаман, минем газиз оланнарым
Үзләреннән мең мәртәбә яхшырак, дип.
Һәлак иткән явыз мең кат явызрак, дип.
Югалтуның зур кайгысын йөз кат күтәр,
Кабахәтнең кансызлыгын йөз кат үстер, —
Шулай итсәң, өйрәнерсең бәддогага!

Елизавета

Каргаш миңа, минем телем үткен түгел!

Маргарита

Кайгы белән үткенләнер. Шундый булыр:
Минем тел күк, әллә ниең тишеп керер!
(Китә.)

Герцогиня

Бәла килгәч, инде күп сүз нигә кирәк?

Елизавета

Сүзләр алар зарлы җанның танышлары,
Шат вакытның васыятьсез варислары, —
Казаларның кызганыч бер соң тавышы.
Әйдә, сүзләр агыла бирсен, бушка түгел:
Файдасызга булса да гел, җанга җиңел!

Герцогиня

Шулай дисәң, карга әйдә! Барыйк бергә
Синең гүзәл улларыңны буып аткан,
Миннән туган нәләт төшкән шушы этне
Безнең зәһәр бәддогабыз буып салсын!

Гаскәр башлыклары белән хәрби тәртиптә король Ричард керә.

Король Ричард

Чү, кем монда минем юлны буып тора?

Герцогиня

Мин буам, мин! Нәләт яуган карынымда
Буып аткан булсам әгәр яралгыңны, —
Үзем буган булыр идем шул чакны ук
Канлы суеш, үтерешләр кылган юлың!

Елизавета

Шул алтын таҗ киеп йөргән маңгаеңа
Кызган тимер тирән тамга салса икән!
Андый тамга лаек сиңа. Шушы таҗның
Хак хуҗасын син үтердең! Туганнарым,
Улларымны вәхшиләрчә һәлак иттең!
Әйт, кыргый кол, кайда минем балаларым?

Герцогиня

Әйт, әшәке, шакшы бака, сасы бака,
Кая куйдың туган абыең Кларенсны?
Аның улын — Плантагенет нәни Нядны?

Елизавета

Кая илттең Риверс, Воган, Грэйларны?

Герцогиня

Кая тыктың яхшы җанлы Гэстингсны?

Король Ричард

Уйнат әйдә торбаларны, как барабан!
Тәкъдиреңдә Ходай язган хөкемдарга
Шушы телдәр хатыннарның нахак сүзен
Якты дөнья ишетмәсен! Көчлерәк как!

Торба, барабан тавышлары.

Йә чыдыйсыз, матур гына сөйләшәсез,
Йә гел шулай, сезнең барлык сүзегезне
Басып торыр сугыш-гауга тавышлары!

Герцогиня

Син кем улы? Минекеме?

Король Ричард

Әйе, нәкъ шул!
Бер Ходайга, атам белән сиңа рәхмәт.

Герцогиня

Мин чыдамсыз сөйлим икән, димәк, чыда!

Король Ричард

Миндә, мадам, шул ук сезнең холык-гадәт,
Авыр сүзгә, тәнбиһләргә чыдый алмыйм.

Герцогиня
Сүзем әйтим!

Король Ричард

Сез әйтегез. Мин ишетмим.

Герцогиня

Минем сүзем йомшак булыр, җиңел булыр.

Король Ричард

Әнкәй, ләкин бик кыска тот. Мин ашыгам.

Герцогиня

Ашыгасың? Алла белә, син туганны
Мин тилмереп, газап чигеп озак көттем.

Король Ричард

Мин тугач ук җиңеләеп калмадыңмы?

Герцогиня

Һич юк, һич юк! Гайсә белән ант итәм мин!
Якты көнем җәһәннәмгә әйләндердең.
Туган чагың булды синең авыр газап,
Сабый чакта киребеткән елак идең;
Үсмер чакта усал, кыргый, азгын идең,
Егет чакта башсыз, тиле, ярсу идең.
Син ир булдың, борын чөйгән бер хәйләкәр,
Кара эчле, канечкеч бер явыз булдың.
Юаш чакта бик куркыныч, усал чакта
Ачу белән эчтән тынган елан булдың.
Әйт син миңа, булды микән шул гомердә
Синең белән рәхәт үткән тик бер сәгать?

Король Ричард

Әйе, юк шул. Хәер, көнгә бер сәгать бар:
Ашны иртән аерым-аерым ашый идек.
Күзегездә арпа булып торам икән, —
Китим, мадам, мыскыл итмим артык сезне.
Уйнат әйдә торбаларны, как барабан!

Герцогиня

Сорыйм синнән, колак сал, дим сүзләремә!

Король Ричард

Сүзләрегез зәһәр сезнең.

Герцогиня

Бер сүз генә!
Соңгы бер сүз. Бүтән бер дә ишетмәссең.

Король Ричард

Әйдә сөйлә.

Герцогиня

Ходай Тәгалә ирке белән
Йә шул яуда син үләрсең, җиңә алмый,
Кайта алмый, кара җиргә баш салырсың.
Йә мин үләм — әҗәл җитте, кайгым — тирән,
Моннан соң мин бер дә сине күрмәм инде.
Ал син хәзер минем авыр бәддогамны, —
Яуда синең бөтен тимер кораллардан
Күбрәк сине минем каргыш талчыктырыр,
Минем догам яклар синең дошманнарны!
Улым Эдвард улларының яшь рухлары
Дошманнарың җаннарына пышылдарлар,
«Бәхет сезгә, җиңү сезгә!» дип әйтерләр.
Синең гомер канлы булды, канда бетәр!
Сиңа һаман ялчы булды мең мәсхәрә,
Инде үлем хезмәт итсен бер мәртәбә!
(Китә.)

Елизавета

Минем каргыш зур булса да, рухым җитми,
Телем — көчсез. Амин аның сүзләренә!

Китә башлый.

Король Ричард

Тукта азрак, сиңа, ханым, бер сүзем бар.

Елизавета

Сиңа минем суяр өчен әзер булган
Патша канлы бер улым да юк бит хәзер!
Инде, Ричард, кызларым бар, алар калды.
Ләкин алар изге йортта дога кылыр,
Королева-фәләк булып яшь агызмас!
Алар күкне үтертүдән бер мәгънә юк.

Король Ричард

Бер кызың бар. Аның исеме — Елизавета.
Гүзәл, күркәм! Тамырында патша каны!

Елизавета

Шуның өчен үтерәмсең? Ah, ул калсын!
Холкын бозып, матурлыгын пычратырмын,
Мин Эдвардны алдадым, дип нахак әйтеп,
Аның кызы түгел ул, дип кычкырырмын!
Шушы пычрак кара пәрдә өстен япкач,
Кызым синең пычагыңнан имин калыр.
Эдвард кызы түгел ул, дип сөрән салам!

Король Ричард

Нахак әйтмә. Ул чын-чыннан патша кызы!

Елизавета

Мин түгел, дим! Аның җанын саклау өчен.

Король Ричард

Патша кызы булган өчен ул имин дә!

Елизавета

Энекәшләре шуның өчен хур булды да!

Король Ричард

Нишләтәсең, бәхетләре кире килде...

Елизавета

Абыйлары каршы килде, яшәтмәде...

Король Ричард

Язмышыннан бер бәндә дә кача алмый.

Елизавета

Әйе, бик хак! Әгәр менә шул язмышны
Ходасыннан качкан кеше ясап торса!
Сиңа язмыш биргән булса хак бер яшәү,
Улларыма бирер иде хак бер үлем...

Король Ричард

Ни дисең син? Янәсе, мин үтергәнмен
Шул ике яшь туганымны...

Елизавета

Туганыңны!
Шулай, дөрес. Яшерәсеңме син аларның
Бәхет, тәхет, гомерләрен буганыңны?
Явыз кулга синең башың әмер биргәч.
Йөрәкләрен кисеп керде канлы пычак.
Тик ул пычак башта тупас, үтмәс булган,
Улларымның күкрәкләрен айкар өчен
Чарлаганнар синең каты таш йөрәктә.
Тоташ кайгы кыргый хисне иләштерә, —
Юкса хәзер балаларым исемен әйтеп,
Менә шушы тырнакларым якорь итеп,
Күзләреңә көймә булып асылыр идем.
Ялгыз көймә гранит ташка бәрелгәндәй,
Син этәргәч, таштай каты күкрәгеңә
Башым бәреп, кисәк-кисәк ярылыр идем...

Король Ричард

Әгәр дә мин сезгә иткән начарлыктан
Мең кат күбрәк игелекләр эшләмәсәм, —
Шушы зур яу миңа җиңү китермәсен,
Канлы сугыш миңа бәхет өстәмәсен!

Елизавета

Нәрсәне соң миннән болыт каплап тора?
Нинди бәхет мине көтеп, саклап тора?

Король Ричард

Кызларыңның дәрәҗәгә менүләре.

Елизавета

Эшафотка менүләре, диген инде!..

Король Ричард

Юк, юк, аңла: бөеклеккә, зур абруйга,
Дөньялыкның иң зур даны — патшалыкка!

Елизавета

Юк-бар белән юмалыйсың хәсрәтемне!
Әйт син миңа, нинди абруй-дәрәҗәләр
Бирер идең минем газиз балаларга?

Король Ричард

Миндә ни бар, хәтта менә үз-үзем дә
Бирер идем сезнең чибәр балаларга.
Сез уйлаган, имештер, мин сезгә иткән
Бөтен-бөтен начарлыкның хатирәсен
Ярсуланган җаныгыздан чыгарыгыз!

Елизавета

Син кыска тот, юкса тышкы яхшылыгың
Сүнеп калып, явызлыгың өскә чыгар.

Король Ричард

Алайса, шул: өзелеп сөям... кызыгызны!

Елизавета

Мин ана бит. Өзелеп уйлыйм мин дә шуны.

Король Ричард

Нәрсә диеп уйлыйсың син? Әйтче, мадам!

Елизавета

Энекәшләрен өзелеп-өзелеп яраткан күк,
Син кызым да өзелеп-өзелеп сөясеңдер.
Шуның өчен чын күңелдән рәхмәт сиңа!

Король Ричард

Ашыкмагыз. Әйтер сүзем бүлдермәгез.
Кызыгызны өзелеп-өзелеп сөям, дим, мин.
Мин ул кызны королева итәр идем...

Елизавета

Алай икән! Аңар король кем булыр соң?

Король Ричард

Аның үзен королева иткән кеше.
Бүтән тагын кем булсын ди?

Елизавета
Әллә синме?

Король Ричард

Әйе, мин, мин! Сез ни дисез моңа, мадам?

Елизавета

Ничек итеп кызны үзеңә каратырсың?

Король Ричард

Моны сездән өйрәнермен. Чөнки бит сез
Аның холык-гадәтләрен шәп беләсез.

Елизавета

Ничек? Миннән өйрәнәсең?

Король Ричард

Чын йөрәктән!

Елизавета

Энеләрен һәлак иткән бәндә аша
Җибәр кызга каны аккан ике йөрәк;
Пычак белән берсенә яз «Эдвард» диеп,
Берсенә яз «Йорк» диеп. Ул яшь түгәр...
Аннан соң син бервакытны Маргарита
Рутлэндыгыз каны белән сугарылган
Кулъяулыкны әтиең Йоркка аткан төсле
Ыргыт аңар иске яулык. Моңар, диген,
Энеңнәрнең алсу каны сеңгән, диген,
Яшьләреңне шуның белән сөртче, диген.
Ул шулай да сиңа күңел якмый икән, —
Санап барлык матур эшең, хат яз аңар;
Синең абыең Кларенсны суйдым, диген,
Абыең Риверс минем кулдан кичте, диген,
Синең хакта апаң Анна Глостерны
Бик тиз генә гүргә тыгып куйдым, диген.

Король Ричард

Сез көләсез миннән, мадам. Кызыгызга
Бу юл белән ошап булмас.

Елизавета
Башка юл юк.
Чөнки бит син үзгәрмисең, син һаман шул,
Шул ук Ричард, шул ук канлы җинаятьләр!

Король Ричард

Әгәр шушы гөнаһларны аңар булган
Сөюем өчен кылган булсам?

Елизавета
Ах, юк инде!
Нәфрәт кенә итәр сине. Канга каткан
Бүләк бирер яуламыйлар мәхәббәтне!

Король Ричард

Үткән эшкә салават, дип дога кылыйк.
Бәндә кыла кайвакытны ялгыш эшләр,
Тик, соңыннан тәүбә итеп, саф кала ул.
Улыгыздан алган булсам таҗ-тәхетне,

Хатам аңлап, бирәм сезнең кызыгызга.
Карыныгыз җимешләрен мин юк итсәм,
Токымыгыз үссен өчен сезнең каннан
Кызыгызда бар итәм мин бүтән бала.
Ана исеме — бик сөйкемле, әйбәт исем,
Әби исеме — күркәмлектә кимме аннан?
Онык булыр, бер баскычка ерак булыр,
Тик синең кан, син тудырган бала булыр;
Аналарын тапкан чакта, син әрнешеп
Ыңгырашкан бер төн өчен бүләк булыр.
Бала табу газап булса яшь чагыңда,
Минем олан рәхәт бирер картлыгыңда.
Әгәр улың король булмый калды икән,
Бер зыян юк, кызың булыр королева!
Хата булган, нишлим инде, эш узган шул!
Хәл барынча эшлим хәзер яхшылыклар.
Улың Дорсет курку катыш хаслык белән
Йөри хәзер чит-ят җирдә зар каңгырып.
Безнең никах, туган илгә дәшеп аны,
Зур абруй һәм дәрәҗәләр бирер иде.
Синең кызга «хатыным» дип дәшкән король
Дорсетыңа якын итеп «кардәш» дияр.
Син тагын да, король өчен ана булып,
Кайгы-газап көннәренең хәрабәсен
Ике-өч өлеш шәбрәк итеп каплар идең.
Их, нинди күп безнең алда рәхәт көннәр!
Син агызган сыек яшьләр Көнчыгышның
Энҗеләре булып сиңа кире кайтыр, —
Син ah орган шушы авыр көннәрдән соң
Ун кат артык бәхет булып кайтыр алар.
Бар син, әнкәй, бар син аңар, ул яшь кызга
Тәҗрибәңне, хатын булу серен сөйлә, —
Рух бир аңар, минем хискә әзер торсын.
Назлы йөрәк, ләкин алтын хакимлекнең
Ымсындыргыч ялкыннарын сал син аңар.
Сөйлә аңар иргә чыгу шатлыкларын,
Мәхәббәтнең төнге татлы тын сәгатен.
Вак фетнәче, бер кибәк баш Букингэмны
Менә шушы кулым белән изеп аткач,
Җиңү лаврын киеп, өйгә кайту белән
Түшәгемдә күрер идем синең кызны.
Бүләк итәм аңар җиңү ганимәтен, —
Тик ул булыр җиңүченең җиңүчесе,
Цезарь өчен иң бөек бер Цезарь булыр!

Елизавета

Мин ни диим? Әтиеңнең туган энесе
Яучылады сине, димме? Әллә синең
Абыең, димме? Әллә синең энеңнәрне,
Абыеңнарны үтергән бер бәндә, димме?
Алла, канун, минем намус, аның холкы
Синең сүзне йөрәгенә салсын өчен

Сиңа нинди исем биреп тел ачыйм соң?

Король Ричард

Шул никахта Англиянең тынычлыгы!

Елизавета

Кызым андый тынычлыкны озак сугыш,
Кайгы-сагыш күреп кенә алыр инде.

Король Ричард

Син әйт аңар, әмер бирә торган король
Сиңа бүген ялына, диген.

Елизавета

Ләкин бит ул
Корольләргә король икән — риза түгел!

Король Ричард

Әйт, ул бөек королева булып китәр!

Елизавета

Әнкәсе күк абруй алгач, кан-яшь түгәр!

Король Ричард

Әйт, мин аны мәңге-мәңге яратырмын!

Елизавета

Синең мәңгең ничә көнгә дәвам итәр?

Король Ричард

Аның асыл гомеренең ахырынача!

Елизавета

Гомеренең асыл ахыры ничә көннән?

Король Ричард

Ходай Тәгалә һәм табигать кайчан кушар.

Елизавета

Тәмуг белән Ричард икесе кайчан теләр.

Король Ричард

Әйт, мин аның хөкемдары, аңар бер кол!

Елизавета

Тик андый кол кире кага хөкемдарны.

Король Ричард

Минем өчен бик матурлап сөйлә инде!

Елизавета

Намуслы сүз гади булса тизрәк үтә.

Король Ричард

Алайса, син минем тирән мәхәббәтне
Гади генә аңлатып бир.

Елизавета

Гади генә һәм намуссыз! Бик тупас шул.

Король Ричард

Ашыгыч бик фикерегез. Һәм бик сай да.

Елизавета

Минем фикер шундый тирән, шундый тирән,
Балаларым каберәдәй, бигрәк тирән!

Король Ричард

Чиертмәче бу кылны син, үткән нәрсә!

Елизавета

Гомер кылым өзелгәнче чиертермен!

Король Ричард

Инде менә изге Георг, Король тасмам,
Шушы таҗым белән сезгә ант итәм мин...

Елизавета

Георг исемен мыскылладың, тасмаң — пычрак,
Таҗны урлап, талап алдың!

Король Ричард

Мин ант итәм!..

Елизавета

Нәрсә белән? Берниең юк ант итәргә!
Изге Георг мыскылланды, аның исемен
Этлек өчен файдаландың. Король тасмаң
Мәсхәрәгә калып бетте, аның күрке,
Рыцарьларга хас сафлыгы юкка чыкты.
Таҗ урланган, хәзер аның даны сүнде,
Ышандырмак булсаң әгәр, ант ит әйдә
Кулың тиеп пычранмаган нәрсә белән!

Король Ричард

Дөнья белән!

Елизавета

Дөнья тулы синең этлек!

Король Ричард

Әтиемнең үлеме белән!

Елизавета
Синең яшәү
Аның үлемен мыскыллады.

Король Ричард
Үзем белән!

Елизавета

Син үзең бер зур явызлык!

Король Ричард

Алла белән!

Елизавета

Син Алланы барыннан күп мыскыл иттең!
Аңар биргән антың әгәр бозмасаң син,
Ирем Эдвард урнаштырган тату дуслык
Һичбер вакыт бозылмаган булыр иде, —
Туганнарым үтерелмәгән булыр иде...
Аңар биргән антың әгәр бозмасаң син,
Башыңдагы патша күрке — алтын таҗ да
Улларымның маңгайларын бизәр иде.
Син аларны өрдең якты җир өстеннән,
Хәзер алар йоклый тузан түшәгендә.
Син хаиннең мөртәтлеге аркасында
Җир кортына азык булды ике принц!
Инде тагын нәрсә белән ант итәрсең?

Король Ричард

Киләчәгем, бөтен алгы көнем белән!

Елизавета

Киләчәгең мыскыл иттең үткәнеңдә!
Алгы көнеңдә юыйм дисәм, яшем җитмәс,
Үткәндә син кылдың чөнки күп явызлык.
Ата-анасы үтерелгән күпме бала
Тәрбиясез калды хәзер җир йөзендә,
Картайгачтын шуны уйлап елар өчен!
Балалары үтерелгән күпме кеше
Калды хәзер чәчәк бирмәс гөлләр төсле,
Картайгачтын шуны уйлап елар өчен!
Алгы көнең белән, зинһар, ант итмә син,
Мыскылладың син ул көнне күрмәс борын,
Рисвай иттең чөнки узган барлык чорың!

Король Ричард

Телим хәзер тәүбә итеп саф калырга! —
Куркынычлы сынауларда дошманнарны
Җиңәм дигән теләгем күк бу сүзем хак!
Әгәр дә мин саф мәхәббәт, изге уйлар
Кер-карасыз чын тугрылык, намус белән
Синең сылу принцессаны яратмасам, —
Үземә-үзем хурлыклы бер үлем табыйм;
Ходай, язмыш бер сәгать тә шат итмәсен,
Көн бирмәсен якты нурын, төн — йокысын,
Күпме йолдыз — барсы миңа каршы булсын!
Синең бәхет, минем бәхет шунда хәзер!
Ансыз калсам, сиңа, миңа һәм аңарга,
Бөтен илгә, бар христиан дөньясына
Килер үлем, бәла-каза, хәрабәләр!..
Аннан башка мин бу хәлдән кача алмыйм,
Аннан башка мин бу хәлдән һич котылмам!
Шулай итеп, сөекле әнкәй, — сезне хәзер
Шулай диеп атыйм инде! — булыгыз сез
Аңар минем мәхәббәтнең бер илчесе! —
Мин кем булган — аны әйтмә, буласын әйт,

Мин ни кылган, аны әйтмә, кыласым әйт.
Заман шулай, дәүләт өчен зарур бу, диң,
Бу зур эштә калып торсын ярсу үпкә!

Елизавета

Бу ни? Мине әллә шайтан котырттымы?

Король Ричард

Бик шәп, әгәр шайтан әйтсә — яхшылыкка!

Елизавета

Мин кем идем? Үз-үземне оныттыммы?

Король Ричард

Бик шәп. Оныт. Истәлекләр зыян иткәч...

Елизавета

Ләкин минем балаларны син үтердең...

Король Ричард

Мин аларны синең кызың карынына
Тирән итеп күмеп куйдым. Тиздән алар,
Синең өчен кире кайткан бәхет булып,
Килеп чыгар асыл кошлар оясыннан!

Елизавета

Кызымны мин синең якка аударыймммы?

Король Ричард

Калырсың син бәхетле бер ана булып!

Елизавета

Ярый, китим. Син, хат язып, кеше җибәр.
Җавабымда белдерермен кыз фикерен.

Король Ричард

Кил, бер үбим. Тапшыр үзенә шул үбүне!

Елизаветаны үбә.

Ярый, сау бул!

Королева Елизавета чыгып китә.

Әх чүпрәк баш, әй сай акыл!
Тотрыксыз җүләр хатын!

Рэтклифф керә. Аның артыннан Кэтсби.

Нинди хәбәр?

Рэтклифф

Падишаһым, көнбатыштан безнең ярга
Килеп чыкты бик көчле бер дошман флоты.
Безнең шикле, буш йөрәкле дусларыбыз
Төркем-төркем бар да хәзер ярга чаба, —
Үзләрендә корал да юк, дошманнарга
Каршы чыгар ният тә юк. Димәк, яуның

Адмиралы Ричмонд үзе булса кирәк.
Тагараклар көткән бугай Букингэмның
Булышлыкка ярдан килеп кушылганын.

Король Ричард

Кем җитезрәк, йөгер герцог Норфолькка!
Рэтклифф, син яки Кэтсби. Кайда соң ул?

Кэтсби

Монда, патша хәзрәтләре, боерыгыз!

Король Ричард

Кэтсби, әйдә йөгер герцог Норфолькка!

Кэтсби

Чабам, милорд, бар куәтем, көчем белән!

Король Ричард

Кил, Рэтклифф. Ычкын әйдә Сэйльсберига.
Аннан кайткач...
(Кэтсбига.)
Әй тавык баш, аңгыра җан!
Ник торасың, ник герцогка ашыкмыйсың?

Кэтсби

Башта миңа әйтегез сез, галиҗәнап,
Анда барып, сездән нинди сүз әйтим соң?

Король Ричард

Ах, син хаклы, Кэтсби туган! Син әйт аңар:
Мөмкин чаклы зур көч белән гаскәр җыеп,
Сэйльсберида мине көтсен. Бик тиз, диген.

Кэтсби

Киттем, милорд.
Чыгып китә.

Рэтклифф

Китим мин дә, галиҗәнап.
Сэйльсберига бару белән мин нишләрмен?

Король Ричард

Нәрсә? Анда мин барганчы син бармакчы?

Рэтклифф

Миңа анда китәргә дип куштыгыз бит!

Стэнли керә.

Король Ричард

Үзгәрттем мин фикеремне. Нихәл, Стэнли?
Синдә нинди яңалыклар?

Стэнли
Галиҗәнап!

Әйтсәң тагын, сөенерлек яхшы да юк,
Сөйләп сезгә, көенерлек яман да юк.

Король Ричард

Чын табышмак! Яхшысы да юк, яманы да юк!
Якын торып хәлне әйтеп бирер чакта,
Әллә каян, ераклардан әйләнәсең!
Сөйлә, ни бар?

Стэнли

Ричмонд диңгез өстендә, ди.

Король Ричард

Батсын төпкә! Диңгез булсын өстендә дә!
Ертык сукбай! Ни эшли ул анда шулай?

Стэнли

Әйтә алмыйм, хөкемдарым, сизәм генә...

Король Ричард

Яхшы. Нәрсә сизәсең соң? Сөйлә әйдә!

Стэнли

Дорсет, Мортон, Букингэмнар чакыргачтын,
Англиянең король тажын кимәкчедер...

Король Ричард

Нәрсә? Әллә тәхет бушмы? Әллә тажга,
Дәүләтебез кылычына хуҗа юкмы?
Король үлеп, империябез хакимсезме?
Әллә исән түгелме мин, Йорк варисы?
Йорк варисы мин булмыйча, Англиядә
Кем соң король? Йә, әйт миңа, җавап бир син!
Нишли анда синең Ричмонд?

Стэнли

Падишаһым,
Шуннан башка мин берни дә әйтә алмыйм.

Король Ричард

Шуннан башка әйтим сиңа: ул бит синең
Падишаһың булыр өчен монда килә!
Уэльслылар яуга чыккан, моны сизми!
Фетнәче син! Куркам, шунда сыпыртырсың.

Стэнли

Юк, юк, патша хәзрәтләре. Нахак сүз бу.

Король Ричард

Дошманнарны куар өчен кайда синең
Гаскәрләрең, яраннарың, юлдашларың?
Беләм, алар бар да хәзер көнбатышта,
Колач җәеп, котлап каршы алыр өчен

Кораблардан дошман явын көтәләрдер.

Стэнли

Дөрес түгел, галиҗәнап. Минем дуслар
Бөтенесе төньяк ярда.

Ричард

Димәк, алар
Минем өчен салкын дуслар. Нигә алар
Төньякта соң? Үзләренең корольләрен
Көнбатышта каршыларга тиеш алар.

Стэнли

Сездән боерык булмый торды, бөек патша,
Әгәр рөхсәт итсәгез сез, мин китәм дә
Җыям бөтен гаскәремне. Сез — хөкемдар!
Кайда, кайчан теләсәгез, без шушында
Сезне көтеп торачакбыз.

Король Ричард

Әйе, бик хуп!
Ричмонд белән кушылырга, качарга, диң!
Юк, мин сиңа һич ышанмыйм!

Стэнли

Сезгә миннән
Шикләнергә һич нигез юк, галиҗәнап.
Хыянәтче булганым юк һәм булмам да!

Король Ричард

Бар алайса, гаскәрең җый. Ләкин монда
Улың Георг Стэнлины калдырырсың.
Бел, сүзеңдә ныk тор. Синең Георгның
Башы юксa җилкәсендә бик ныk тормас!

Стэнли

Ялганласам, аның башы сезнең кулда.

Китә. I хәбәр ташучы керә.

I хәбәр ташучы

Хөкемдарым, Девонширдан минем аша
Дусларыбыз шундый хәбәр җибәрделәр:
Эдвард Кортней һәм аның бер карт абыйсы,
Кәперенгән чал Экзетер епископы
Күп көч белән анда фетнә күтәргәннәр.

II хәбәр ташучы керә.

II хәбәр ташучы

Галиҗәнап! Кент шәһәре гильдфордлары
Баш күтәргән. Көтү-көтү халык җыела.
Фетнәчеләр сәгать саен артып тора.

III хәбәр ташучы керә.

III хәбәр ташучы

Падишаһым! Букингэмның зур гаскәре...

Король Ричард

Югалыгыз күз алдымнан, ябалаклар!
Үлем, фетнә... һаман бер җыр. Бүтән юкмы?

Сугып җибәрә.

Әйбәт хәбәр китергәнче сабак сиңа!

III хәбәр ташучы

Галиҗәнап! Әйбәт хәбәр китердем бит!
Кинәт кенә елга ташып, зур су басып,
Букингэмның бар гаскәре тар-мар килеп,
Тирә-якка тузып беткән. Тик ул үзе
Кай яккадыр качып киткән. Беркем белми.

Король Ричард

Кичер мине. Менә янчык. Нык сугылган,
Сызлый торган җирләреңне дәваларсың.
Шул мөртәтне тоткан өчен безнең берәр
Төплерәк дус бүләк игълан итте микән?

III хәбәр ташучы

Булды, булды андый игълан, галиҗәнап!

IV хәбәр ташучы керә.

IV хәбәр ташучы

Хөкемдарым! Томас Ловель, маркиз Дорсет
Йоркширда сезгә каршы баш күтәргән.
Тик, гали зат, шәп хәбәр дә китердем мин:
Зур давылда Бретон флоты тирә-якка
Тузып беткән. Ричмонд исә Дорсетширга,
Яуда булган гаскәрләрнең аның яклы
Булып-булмауларын сорап белер өчен
Бер көймәсен җибәргән, ди. Ярдагылар,
Букингэмнан килдек, диеп сөйләгәннәр.
Ләкин моңар Ричмонд үзе ышанмаган,
Җилкәннәрен күтәргән дә кире киткән,
Ары, Бретань ярларына...

Король Ричард

Җыйнал әйдә!
Алга әйдә, коралыбыз кулда чакта! —
Килмешәкне кыйный алмый калдык икән,
Баш күтәргән хаиннәрне көл итәрбез!

Кэтсби керә.

Кэтсби

Галиҗәнап! Букингэмны эләктердек!
Монысы әйбәт. Ләкин начар хәбәр дә бар:

Граф Ричмонд гаять көчле гаскәр белән
Инде Мильфорд тирәсендә ярга төшкән.
Суык хәбәр, тик әйтмичә мөмкин түгел...

Король Ричард

Әйдә алга, Сэйльсберига! Акыл сатмыйк.
Без сугышта инде күптән җиңәр идек, —
Һич булмаса, җиңелергә вакыт инде!
Букингэмны Сэйльсберига җибәрегез,
Калганыгыз минем белән! Алга, алга!

Китәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Лорд Стэнли йортының бер бүлмәсе.
Стэнли белән сэр Кристофер Юрсвик керәләр.

Стэнли

Сэр Кристофер, сиңа менә шушы йомыш, —
Әйт Ричмондка миннән шуны: канлы кабан
Улым Георг Стэнлины бикләп тота;
Баш күтәрсәм, аның башын кисәчәкләр.
Шушы курку әлегә минем кулны тота, —
Бик тиз генә аңар барып кушыла алмыйм.
Ярый, син бар. Минем өчен кулын үп тә,
Королева чын күңелдән риза, диген,
Сине кызы Елизавета көтә, диген.
Әйт әле син, принц Ричмонд кайда хәзер?

Юрсвик

Пемброкта яки Герфорд-вечтта булыр,
Ерак түгел, шул Уэльста...

Стэнли

Анда тагын
Аның белән кемнәр бар соң?

Юрсвик

Барсы анда!
Сугышларда дан казанган Вальтер Герберт,
Гильберт Гальбот, аның белән Вильям Стэнли.
Оксфорд анда. Данлы Пемброк, Джемс Блант;
Курку белмәс отряд белән Райс ап-Томас.
Тагын бик күп гали затлар, зур исемнәр!
Бөтен гаскәр Лондонга дип туры бара,
Әгәр юлда бәрелешләр очрамаса...

Стэнли

Ашык, туган, Ричмонд янына. Сәлам, диген.
Менә бу хат сөйләр бөтен хәлне минем!
Ярый, сау бул!

Китәләр.

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сэйльсбери. Мәйдан.
Шэриф һәм сакчылар Букингэмны җәзалау урынына алып баралар.

Букингэм

Король Ричард минем белән сөйләшмәсме?

Шэриф

Юк, милорд, буйсынырга туры килә.

Букингэм

Тыңлагыз сез, королебез изге Генрих,
Һәм син, аның гүзәл улы — принц Эдвард,
Һәм сез, мескен король Эдвард балалары,
Сез, Гэстингс, һәм сез, Грэй, Риверс, Воган!
Һәм сез, пычрак яла белән, ялган белән
Үтерелгән бичаралар, ишетегез!
Сезнең мескен, кимсетелгән җаннарыгыз
Әгәр хәзер, шул сәгатьтә, күктән торып
Карый икән җиргә болыт арасыннан —
Нәкъ вакыты сезгә үчне алыр өчен,
Көлеп торып минем дансыз һәлакәттән!
Егеткәйләр, ни көн бүген? Әрвахларны
Искә төшерү көне бугай?

Шэриф

Әйе, милорд.

Букингэм

Шулаймыни? Димәк, бу көн минем өчен
Гөнаһлардан хисап бирү көне икән!
Мин бу көнне королебез Эдвард барда
Антым бирдем: әгәр аның балаларын,
Хатынының туганнарын алдыйм икән, —
Каргышлары үз башыма төшсен, дидем.
Мин бу көнне, ник ышанган дусларымның
Хыянәтләре үз башыма булсын, дидем.
Шулай икән, шулай икән! Димәк, бүген
Әрвахларны искә төшерү көне икән!
Бу көн минем дәһшәт тулы җаным өчен,
Ялганнарым, ялам өчен бер чик икән!
Ходай минем ялган антым, догаларым
Дучар итте бүген менә үз башыма, —
Юрамалый сораганым чыннан бирде.
Шулай менә бер Ходаның киң кодрәте
Явыз җанлы кешеләрнең хәнҗәрләрен

Үзләренең күкрәгенә бора икән!
Маргарита каргышлары төште миңа!
Ул бит әйтте: «Әгәр Ричард йөрәгеңне
Авыр кайгы, хәсрәт белән чәнчи икән,
Маргарита — әүлия ул, дип уйла», — диде.
Әйдә, сэрлар, илтегез сез мине тизрәк, —
Башым куям оят, хурлык кискәсенә.
Явызлыкка явызларча җәза лаек,
Гаепләүгә лаек икән һәрбер гаеп.

Китәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тэмуорс кыры. Барабаннар һәм әләмнәр белән Ричмонд, Оксфорд, сэр Джемс Блант, сэр Вальтер Герберт һәм башкалар керә. Алар артыннан, марш басып, гаскәрләр килә.

Ричмонд

Яудашларым! Явыз тиран коллыгында
Күп интеккән дусларым һәм туганнарым!
Менә хәзер һичбер төрле каршылыксыз
Килеп кердек туган илнең йөрәгенә.
Һәм мин монда бүген әткәм Стэнлидан
Дәрт, юаныч бирә торган хәбәр алдым.
Таҗ урлаган бәдбәхет һәм канлы дуңгыз,
Сезнең җәйге уңдырышлы кырыгызны,
Виноград бакчагызны казып йөреп,
Сезнең хәләл кайнар канны су күк эчкән,
Сезнең үпкә-бавырларны теше белән
Суырып алган шул коточкыч дуңгыз хәзер
Британиянең үзәгендә ятып тора.
Белгәнемчә, Лейсестердан ерак түгел, —
Тэмуорстан анда чаклы бер көнлек юл.
Алга, Ходай исеме белән! Дәрт, кыюлык
Юлдаш булсын сезгә, батыр сугышчылар!
Бер зур сугыш, соңгы, канлы тартыш белән
Яулап алыйк без мәңгелек тынычлыкны!

Оксфорд

Һәр кешенең саф вөҗданы — мең кылыч ул,
Сугышканда шушы канлы җәллад белән!

Герберт

Беләм, аның бар дуслары безгә күчәр.

Блант

Бер дусты да юк бит аның! Булганнары
Аңар фәкать куркып кына хезмәт итә.
Авыр килсә — бар да аннан очачак бит!

Ричмонд

Барсы безнең файдабызга. Ярый, дуслар,
Алга, Ходай исеме белән алга атлыйк!
Хаклы өмет бик тиз вакыт чынга аша,
Ул карлыгач канатында алга оча;
Хаклы өмет патшаларны Алла итә,
Иң билгесез гадиләрне патша итә.

Китәләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Босуорс кыры. Гаскәрләр белән король Ричард, герцог Норфольк, граф Сэррей һәм башкалар керәләр.

Король Ричард

Корыгыз, кор шушы җирдә палаткамны!
Без — Босуорс калкуында. Граф Сэррей,
Нигә болай чыраегыз бик караңгы?

Сэррей

Тик күңелем чыраемнан йөз кат якты.

Король Ричард

Норфольк кайда?

Норфольк

Мин биредә, галиҗәнап.

Король Ричард

Әйтче, Норфольк, таяк бүген ничек төшәр?
Төшәр микән? Йә, әйт!

Норфольк

Бик нык төшерербез,
Һәм безгә дә бик нык төшәр, галиҗәнап.

Король Ричард

Палатка, дим! Мин биредә төн үткәрәм.

Солдатлар король өчен палатка куя башлыйлар.

Иртәгесе көнне кайда? Хәер, нигә?
Кайда гына төн кунсам да барыбер бит!
Фетнәчеләр күпме икән, кем белеште?

Норфольк

Алты меңме, җиде меңме — артык түгел.

Король Ричард

Алай булгач, безнең көчләр өч тапкыр күп!
Инде тагын өстик шуңар король исемен, —
Шул үзе дә зур бер терәк, нык таш кыя!
Андый зур көч дошман өчен хыял гына.
Палатка, дим! Әйдә, тизрәк маташыгыз!

Әйдә, хәзер, гали затлар, карап килик, —
Сугыш кыры безнең өчен җайлы микән?
Чакырыгыз белә торган кешеләрне,
Тикшерегез, һәрнәрсәдә тәртип булсын.
Калдырмагыз ярты юлда һичбер эшне, —
Чөнки иртән безне көтә урак өсте!

Китәләр. Сугыш кырының икенче ягыннан Ричмонд, сэр Вильям Брэндон, Оксфорд һәм башка лордлар керәләр. Солдатларның кайберләре
Ричмонд өчен палатка куя башлыйлар.

Ричмонд

Алтын нурга чумып бата арган кояш!
Һәм ул бүген ялтыр утлы арбасының
Нурга чумган, киң сузылган эзе белән
Туар көннең шәп буласын хәбәр итә.
Вильям Брэндон, әләмне мин сиңа бирәм.
Китерегез палаткама кәгазь, каләм, —
Төзеп алыйм сугыш кыры харитасын.
Кирәк җиргә куйыйм гаскәр башлыкларын,
Бүлеп чыгыйм аз көчне дә тигез итеп.
Лорд Оксфорд, һәм сез, сэрлар Вильям Брэндон,
Вальтер Герберт, булачаксыз минем янда.
Граф Пемброк хәзер үзенең отрядында.
Син хәзер үк юнәл анда, капитан Блант,
Бар да телә миннән аңа хәерле төн.
Һәм әйт графка: төнге сәгать икедән соң
Гәпләшергә палаткама килеп чыксын.
Капитан Блант, тагын бер сүз: белмисеңме,
Лорд Стэнли гаскәрләре кайда икән?

Блант

Ялгышмасам... Юк, юк, моны анык беләм,—
Күрдем бая кырда аның әләмнәрен.
Король Ричард гаскәреннән ярты мильгә
Көньяктарак тора аның дружинасы.
Ричмонд, әгәр үзең бик хәвефкә куймый гына
Аның янына бара алсаң, сөекле Блант,
Сөйләш бүген аның белән, тапшыр аңар
Минем шушы бик-бик мөһим кәгазemне.

Блант

Җаным фида сезнең өчен, галиҗәнап.
Үтәрмен мин бурычымны. Ярый, китим.
Хода бирсен бүген сезгә тыныч йокы!

Ричмонд

Хәерле төн, капитан Блант. Гали затлар,
Әйдәгез без иртәгесе эшне уйлыйк.
Миңа керик. Юкса суык. Томан төшә.

Палатка эченә керәләр. Король Ричард үз палаткасы янына килә. Аның артыннан
Норфольк, Рэтклифф һәм Кэтсби керәләр.

Король Ричард

Сәгать ничә?
Кэтсби

Кичке ашка вакыт инде, —
Сәгать тугыз тулып килә, галиҗәнап.

Король Ричард

Юк, мин бүген кичке ашны ашап тормыйм.
Китерегез хәзер миңа кәгазь, каләм!
Җиңеләйтеп эшләндеме тимер киеме?
Палаткама куелганмы коралларым?

Кэтсби

Барсы, барсы әзер тора, галиҗәнап.

Король Ричард

Әйдә, Норфольк, эшне кара, ашык тизрәк.
Яхшы күзәт, ышанычлы сакчылар куй!

Норфольк

Китәм, милорд.

Король Ричард

Ярый, Норфольк, бүген таңда
Тургайлардан иртәрәк тор.

Норфольк

Була, милорд.

Король Ричард

Әй син, Кэтсби!
Кэтсби

Әйдә тыңлыйм, галиҗәнап.

Король Ричард

Лорд Стэнли отрядына илче җибәр, —
Коралланып барсын ләкин. Һәм ул әйтсен:
Иртән, кояш чыгар-чыкмас, лорд Стэнли
Дружинасын алып килсен минем янга.
Юкса аның улы Георг минем кулдан
Мәңгелек төн упкынына дөмегәчәк!

Кэтсби китә.

Китерегез миңа шәраб! Сак куегыз!
Яу өчен дип иртән-иртүк сугыш атым
Ак Сэррейны бик әйбәтләп иярләрсез.
Сөңгеләрем чыдам булсын, җиңел булсын!
Әй, Рэтклифф!

Рэтклифф

Әйе, тыңлыйм, галиҗәнап.

Король Ричард

Белдеңме син, Норсомберлэнд ник төшенке?

Рэтклифф

Ул һәм граф Томас Сэррей икәү бергә,
Эңгер-меңгер җиткәнгәчә, гаскәр буйлап
Дружинадан дружинага күчә-күчә,
Солдатларның кәефләрен күтәрделәр.

Король Ричард

Мин канәгать. Бир бер савыт шәраб миңа.
Әллә ничек, йөрәгемнең дәрте бик аз,
Күңелемдә әүвәлгедәй илһам да юк...
Куй шушында. Кәгазь белән каләм бармы?

Рэтклифф

Бар, бар, милорд.

Король Ричард

Калдыр мине, хуш, Рэтклифф!
Сакчыларны тикшереп чык. Минем янга
Ярты төннәр тирәсендә тагын әйләнә, —
Коралларым җайлашырсың. Бетте. Бар. Хуш.

Король Ричард палаткага керә. Рэтклифф китә. Ричмонд палаткасы ачыла.
Анда Ричмонд һәм аның яраннары. Стэнли керә.

Стэнли

Бәхет белән җиңү кунсын синең шлемга!

Ричмонд

Бу кара төн бирә алган бар шатлыкны
Сиңа телим, газиз әткәм. Сөйлә миңа,
Сөекле әнкәм анда минем ничек тора?

Стэнли

Фатихамны бирәм сиңа әнкәң өчен, —
Ричмонд диеп, ул һәрдаим дога кыла.
Ярый, булды. Бу хакта сүз җитеп торыр,
Чөнки бәхет сәгатьләре бик тиз уза.
Көнчыгышта тонык күккә тасма-тасма
Алсу юллар төште инде. Вакыты шундый:
Сүзгә — кыска, әмма эшкә оста бул, ди.
Иртәгә син иртүк торып сугыш башла,
Кискен тартыш, канлы үлем сугышының
Киң иркенә тапшыр бөтен язмышыңны.
Миңа калса, мин хәзергә көтеп торам.
Сайлап алып менә дигән җайлы вакыт, —
Гаскәрләрнең иң хәлиткеч сугышында,
Иң шәп чакны сиңа килеп кушылырмын.
Мин хәзергә синең якта була алмыйм.
Юкса синең сөйгән энең мескен Георг
Явыз кулдан күз алдымда җан бирәчәк...
Ярый, сау бул. Бу аз вакыт, бу хәтәр төн

Тугрылыкка, мәхәббәткә ышандырган
Көяз антлар бирешергә, теләгәнчә
Җылы сүзләр алмашырга рөхсәт итми.
Озак вакыт аерым яшәп кавышкачтын,
Дус-иш өчен тансык сүзләр күп булса да,
Язсын Ходай моның өчен шәп бер көнне!
Хуш, мин китәм. Батыр ир бул, җитез ир бул!

Ричмонд

Озатыгыз үзен, лордлар, отрядына!
Ә мин ятыйм. Күңелемдә — шомлы уйлар.
Калгымаммы бераз гына. Юкса мине,
Җиңү белән канатланып очар чакта,
Кургаш йокы җиргә басар иртәгесен.
Сүзем бетте. Ярый, лордлар, хәерле төн!

Лордлар Стэнлины озата китәләр.
Йә бер Ходам, мин бит синең сәргаскәрең,
Төшер минем гаскәрләргә гали күзең, —
Ярсу белән үчтән койган кылычларың
Син аларның кулларына тоттыр бүген!
Дәһшәт белән ватсын алар, изсен алар
Дошманнарның урлап кигән шлемнарын!
Безне, Тәңрем, җәзалаучы кулың ит син,
Шул җиңүең белән сине олылыйк без!
Уяу калган саф җанымны сиңа баглап,
Ябам хәзер күзләремнең тәрәзләрен, —
Йокымда да, көнемдә дә сакла мине!

Йоклап китә. Ике палатка арасыннан Генрих VI ның улы принц Эдвард өрәге күтәрелә.

Эдвард өрәге

(король Ричардка)
Бел, иртәгә төшәр сиңа минем каргыш!
Уйла шуны: Тьюксбери кырында син
Чәчәк кебек яшь чагымда суйдың мине.
Газап сиңа, үлем сиңа!
(Ричмондка.)
Яшә, Ричмонд!
Һәлак булган принцларның гаепсезгә
Хур ителгән әрвахлары синең якта.
Король Генрих баласыннан сәлам сиңа!

Король Генрих VIның өрәге торып баса.

Генрих өрәге
(король Ричардка)

Үзем исән, сау чагымда, маңгаема
Май сыланган патша чакта, син килдең дә
Минем тәнне пычак белән тишкәләдең...
Товерны тот хәтереңдә, мине уйла!
Газап сиңа, үлем сиңа! Газап, үлем!
Патшаң Генрих VI дан сүз шул сиңа!

(Ричмондка.)
Син изге җан, син затлы ир! Җиңүче бул!
Тиздән король булырсың, дип, бервакытны
Пәйгамбәрлек иткән Гарри бүген сине
Татлы йокың вакытында тәбрик итә, —
Мең яшә син, бәхет белән чәчәк ат син!
(Кларенс өрәге пәйда була.)

Кларенс өрәге
(король Ричардка)

Бел, иртәгә төшәр сиңа минем каргыш!
Бу — мин, абыең. Шакшы шәраб мичкәсенә
Син батыртып һәлак иткән гаепсез җан,
Мәкер белән син үтерткән Кларенс мин!
Иртәгесен яуга чыккач, мине уйла,
Тупасланган кылычыңны җиргә төшер!
Газап сиңа, үлем сиңа!
(Ричмондка.)
Кыю Ричмонд!
Ланкастерлар йортына син үз булсаң да,
Гаепсезгә үтертелгән Йорк уллары
Бер Ходадан сорый бүген синең өчен:
Сакласыннар яуда сине фәрештәләр!
Мең яшә син, бәхет белән чәчәк ат син!

Риверс, Грэй, Воган өрәкләре күтәрелә.

Риверс өрәге
(король Ричардка)

Бел, иртәгә төшәр сиңа минем каргыш!
Бу — мин, Риверс, Помфретта үлгән Риверс!
Газап сиңа, үлем сиңа!

Грэй өрәге
(король Ричардка)

Бу — мин, Грэй.
Мине уйла, газап белән җаның чыксын!

Воган өрәге
(король Ричардка)

Бу — мин, Воган. Мине төшер хәтереңә!
Гөнаһыңнан котың очып, кулларыңнан
Сөңгең төшсен! Газап сиңа, үлем сиңа!

Өч өрәк тә бергә
(Ричмондка)

Уян, Ричмонд! Уйла безне, гаепсезгә
Ричард явыз һәлак иткән мескеннәрне!
Уян, Ричмонд, гафил булма! Син җиңәрсең!

Гэстингс өрәге торып баса.

Гэстингс өрәге

(король Ричардка)

Гел явызлык, гел кан гына кылган эшең,
Явызлыкта күзләреңне ачып бүген,
Канлы кырда көннәреңне очларсың син!
Исеңә төшер Гэстингсны шул чагыңда!
Газап сиңа, үлем сиңа!
(Ричмондка.)
Уян, Ричмонд!
Тор, тор, уян! Тыныч күңел, гөнаһсыз җан!
Коралларың кулга ал да сугыш һәм җиң
Безнең гүзәл Англиябез бәхетенә!

Ике яшь принцның өрәкләре пәйда була.

Ике өрәк бергә
(король Ричардка)

Төшеңдә күр безне, Товер корбаннарын!
Күкрәгеңдә кургаш булып сине, Ричард,
Һәлакәткә һәм хурлыкка басып төшик!
Без, ике яшь кардәшеңнең әрвахлары,
Бүген сиңа газап тели, үлем сорый!
(Ричмондка.)
Тыныч йокла, шатлык белән уян, Ричмонд!
Фәрештәләр саклый сине шул кабаннан!
Мең яшә син, башлап җибәр үзең белән
Патшаларның бәхетле бер зур токымын!
Сиңа Эдвард балалары бәхет тели!

Королева Анна өрәге күтәрелә

Анна өрәге
(король Ричардка)

Тыңла, Ричард.
Синең янда бер сәгать тә
Тыныч йокы күрми үлгән мин, хатының,
Бүген үзем синең йокың бимазалыйм.
Иртәгесен мине дә тот хәтереңдә, —
Тупасланган кылычыңны җиргә төшер!
Газап сиңа, үлем сиңа!
(Ричмондка.)
Тыныч йокла,
Чөнки синең җаның тыныч. Төшеңдә син
Уңышлар күр һәм шатлыклы җиңүләр күр!
Дошманыңның хатыны сиңа бәхет тели!

Букингэм өрәге торып баса.

Букингэм өрәге
(король Ричардка)

Мин беренче булып сиңа таҗ кидердем,
Һәм, ниһаять, иң соңгы бер корбаның мин.
О, иртән син Букингэмны исеңә төшер!
Гаепләреңдәһшәтеннән дөмек, тиран!
Төшләреңә керсен үлем, җинаятьләр,

Иртәгесен газапларда башың югалт,
Газапланып чыгар соңгы сулышыңны!
(Ричмондка.)
Сиңа барып кушылганчы һәлак булдым,
Инде, дустым, син батыр бул, курку белмә.
Ышан, Ричмонд, бер Хода һәм фәрештәләр
Сине яклап сугышырлар, Ричард үзенең
Горурлыгы түбәсеннән аска очар!

Өрәкләр югалалар. Король Ричард йокысыннан уяна.

Король Ричард

Бүтән ат бир! Бәйлә минем җәрәхәтне!
Кызган, Гайсә! Тукта, бу ни? Төш кенә ич!
О, син ничек газаплыйсың, куркак вөҗдан!
Әллә нинди зәңгәр утлар янып тора...
Шундый тыныч, аулак бер чак, төн уртасы...
Калтыранам. Бөтен тәнем салкын тирдә.
Чү, нәрсәдән куркам соң мин? Үз-үземнән?
Монда бүтән беркем дә юк. Ричард сөя
Тик Ричардны. Бу кем дисәң, бу — мин, үзем!
Юк, монда юк бер палач та! Бар, бар! Ул — мин!
Качыйммыни? Кемнән качыйм? Үчтәнмени?
Кем үч алыр? Минме? Кемнән? Үз-үземнән?
Ах, гафу ит, мин үземне бик нык сөям!
Нәрсә өчен? Үземә үзем ни булса да
Бер яхшылык эшләдемме? О юк, һич юк!
Нәфрәт итәм мин үземне, үзем кылган
Нәләт төшкән эшләр өчен. Мин — бер ерткыч.
Алдыйм, алдыйм! Юк, мин бер дә ерткыч түгел!
Җүләр соң мин, үземә үзем яхшы сөйлим,
Ахмак соң мин, үземә үзем табан ялыйм!
Вөҗданымның йөз теле бар: һәркайсы да
Гел бертөрле әкият сөйли. Һәр әкият тә,
«Син — ерткыч» дип, минем өскә гаеп ташлый.
Мөртәт, мөртәт! Мин шуның да иң тулысы!
Җәллад, җәллад! Мин шуның да иң зурысы!
Һәм шул көе кылган барлык гөнаһларым
Бүген мине хөкем итеп кычкыралар:
«Гаеплесең, гаеплесең, гаеплесең!»
Газап чиксәм, һичкем мине якын күрми,
Үлсәм, һичкем минем өчен яшь агызмас.
Һа, юк! Ни дип алар мине жәлләсеннәр?
Һичвакыт мин үз-үзем дә кызганмагач?
Килде төсле бүген минем палаткама
Мин үтерткән кешеләрнең әрвахлары, —
Һәркайсы да янап торды төсле миңа:
«Ричард, — диеп, — безнең хак үч төште сиңа!»

Рэтклифф керә.

Рэтклифф

Галиҗәнап!

Король Ричард

Кем бар анда?

Рэтклифф

Бу — Рэтклифф.
Инде авыл әтәчләре, таңны котлап,
Ике тапкыр сөрән салды. Дусларыгыз,
Күптән торып, коралларын кулга алды.

Король Ричард

Ах, Рэтклифф, шундый хәтәр бер төш күрдем!
Син ни дисең, дуслар безгә тугры микән?

Рэтклифф

Шик юк, милорд.

Король Ричард

Ой, Рэтклифф, куркам, куркам!

Рэтклифф

Юк, юк, тәкъсир, өрәкләрдән өрекмәгез!

Король Ричард

Изге Павел! Шул өрәкләр бүген төнлә
Минем җанны шундый каты кыйнадылар,
Сай акыллы Ричмондыгыз җитәкләгән
Шәп кораллы ун меңлек бер зур гаскәр дә
Кыйный алмас иде шулай Ричард җанын!
Әлегә иртә. Төн караңгы. Әйдә чыгыйк,
Тыңлап йөрик палаткалар тирәсендә, —
Минем яннан качар өчен сүзләр юкмы.

Король Ричард һәм Рэтклифф чыгып китә. Ричмонд уяна. Оксфорд һәм башка лордлар керәләр.

Лордлар

Хәерле иртә! Сәлам сиңа, галиҗәнап!

Ричмонд

Рәхмәт сезгә, уяу йөргән гали затлар,
Йоклап калган мин-ялкауны торгыздыгыз.

Лордлар

Милорд, ничек йокладыгыз?

Ричмонд

Ах, нинди шәп!
Бая, дуслар, минем яннан сез киткәч тә,
Гел-гел йокы капчыклары күрә торган
Шундый гаҗәп, гүзәл төшләр күрдем бүген!
Канлы Ричард һәлак иткән кешеләрнең
Әрвахлары палаткама килде, имеш, —
Һәм барсы да әйтте, имеш: «Җиң син!» — диеп.

Ант итәм мин: йөрәгем шат, җанга рәхәт
Хәтерләве менә шундый әйбәт төшне!
Ничек, дуслар, таң атканмы? Сәгать ничә?

Лордлар

Хәзер менә дүрткә суга.

Ричмонд

Димәк, вакыт
Кораллану, боерыклар бирү өчен.

Гаскәрләр алдына чыга.

Илдәшләрем, бу шундый бер җаваплы чак,
Сезгә элек сөйләгәннән артык итеп
Мин бер сүз дә әйтә алмыйм. Онытмагыз:
Бер Ходa һәм изге ният безнең якта!
Изгеләрнең, шәһитләрнең гыйбадәте
Безнең алда бастиондай басып тора.
Яудашларым! Каршы чыккан дошманнардан
Ричард кына тели безнең җиңелүне...
Иярганнәр алар бүген кемгә диген! —
Бер тиранга, кулы канлы бер палачка.
Канга басып күтәрелгән узурпатор,
Канга катып, ныгып калган тәхет корты, —
Иң явыз бер ният тотып, хәтта үзенең
Сердәшләрен һәлак иткән бер явыз җан!
Англиядән урлап алган таҗ-тәхеттә
Асылташтай балкымакчы шул кара таш! —
Алланың да, бәндәнең дә хас дошманы!
Шул тиранны җиңәр өчен сугышсагыз —
Ватан сезне юмарт итеп ризалатыр.
Сөйгән ярларыгыз өчен сугышсагыз —
Каршы алыр алар сезне колач җәеп.
Улларыгыз өчен әгәр сугышсагыз —
Картайгачтын оныклардан хөрмәт булыр.
Әйдә, Ходай исеме белән, хак эш өчен!
Биек итеп күтәрегез әләмнәрне!
Кылычларны кыннарыннан чыгарыгыз!
Әгәр үлсәм шул кыю һәм зур сынауда,
Салкын җиргә ятыйм суык гәүдә булып!
Әгәр җиңсәм, бәхет килсә зур сынауда,
Һичберәү дә өлешеннән коры калмас!
Көчле булып дөбердәсен барабаннар,
Дәртле булып яңгырасын фанфаралар!
Изге Георг һәм бер Ходa! Без һәм җиңү!

Китәләр. Яңадан король Ричард, Рэтклифф, яраннар һәм гаскәрләр керә.

Король Ричард

Норсомберлэнд нәрсә ди соң? Ричмонд ничек?

Рэтклифф

Ричмонд, ди ул, хәрби эшне бер дә белми.

Король Ричард

Дөрес әйтә. Ә соң Сэррей нәрсә диде?

Рэтклифф

Көлә генә. Безнең өчен шунысы шәп, ди.

Король Ричард

Ул да хаклы. Һәм чыннан да шулай бит ул!

Сәгать суга.

Ничә сукты? Бирче миңа календарьны.
Кояш ничек? Кемнәр күрде?

Рэтклифф

Мин күрмәдем.

Король Ричард

Әллә кояш яктыртырга хурланамы? —
Календарьга караганда, аның инде
Көнчыгыштан чыкканына бер сәгать бар.
Караңгы көн булыр бүген кем өчендер...
Әй, Рэтклифф!

Рэтклифф

Әйе, тыңлыйм, галиҗәнап!

Король Ричард

Кояш бүген күренмәскә охшый, ахры.
Күк тә карый гаскәремә чырай сытып.
Шушы томан кырау гына булсын икән!
Бүген кояш нурын сипми. Миңа ни соң?
Ричмондка да шулай ич ул! Күк тә шул ук!
Әгәр миңа йөзен чытып карый икән,
Ричмондка да караңгы йөз күрсәтә бит!

Норфольк керә.

Норфольк

Тизрәк, тизрәк, галиҗәнап, дошман инде
Сугыш кырын каплап алды.

Король Ричард

Тизрәк, тизрәк!
Иярләгез минем атны. Тизрәк әйдә,
Стэнлины табып монда китерегез!
Гаскәрләрен минем янга алып килсен.
Сугышка мин солдатларны үзем кертәм.
Һәм белегез: шушы булыр минем боерык:

Атлылар һәм җәяүлеләр тигез булган
Алгы отряд бертуктамый сулдан бара,
Укчыларны җибәрербез урта җиргә.
Сезгә, герцог Джон Норфольк, әмер шулай,
Сез дә, граф Томас Сэррей, онытмагыз:
Уңнан барыр сезнең атлы-җәяүлеләр.
Ә мин үзем юнәлермен сезнең арттан.
Минем көчле һәм канатлы отрядымны
Чапкын атым алып барыр кирәк җиргә.
Бу фәрман һәм изге Георг җиңү бирер!
Ничек моңар, Джон Норфольк, синең караш?

Норфольк

Яхшы боерык, галиҗәнап. Менә моны
Бүген иртән палаткамнан табып алдым.

Кәгазь кисәге бирә.

Король Ричард

«Кабаланма, Джон Норфольк, күрсәт саклык,
Хуҗаң Диккон бер кат түгел, йөз кат сатлык!»
Дошманнарның чираттагы кыйланышы!
Әйдә, тизрәк һөҗүм итик, гали затлар,
Юк-бар уйлар безнең җанны өркетмәсен!
Намус бит ул көчлеләрне куркытырга
Куркак кеше әйтә торган бер сүз генә.
Безнең намус — безнең көчле кулларыбыз!
Безнең канун — безнең үткен кылычыбыз!
Әйдә, бергә дошманнарны басып сытыйк,
Оҗмахкамы, тәмугкамы — сәфәр тотыйк!
Әйткәннәрдән артык тагын нәрсә диим?
Беләсездер, безгә каршы кемнәр тора.
Эшлексезләр, карак башлар, качак этләр,
Франциянең калдык-постык сукбайлары,
Түбән җанлы азгын коллар, ач лакейлар!
Күбенгәнче туйган Бретань шул пычракны
Авызыннан косып, читкә ыргыткан да
Башсыз эшкә, һәлакәткә дучар иткән.
Сезнең тыныч йокыгызны шулар бозды!
Сезгә Ходай җир бирде дә бакча бирде —
Тик шуларны дошман һәлак итмәк була.
Сезгә Ходай бирде матур сөйгән ярлар —
Тик аларны дошман харап итмәк була.
Башлыклары кем дисезме, йолкыш малай,
Франциядә минем әнкәй хисабына
Озак еллар яшәп яткан сөтле борын.
Тормыштагы авырлыкны елый-елый
Икмәк капкан чакта гына сизгән өтек!
Чыбыркылыйк диңгез арты сукбайларын,
Камчы белән куыйк моннан Франциянең
Кәперәйгән өтекләрен, дөньясыннан
Туеп беткән, ачка кипкән ялчыларын!

Бичаралар! Башсыз эшкә өметләре,
Ниятләре бетсә әгәр, күптән инде
Асылырлар иде нәкъ гел күсе кебек!
Без җиңелсәк, җиңсен безне чын кешеләр,
Тик нәселсез бретонлылар түгел инде!
Ул дошманны аталарыбыз, бабаларыбыз
Үз җирендә таптаганнар, кыйнаганнар.
Һәм үзләрен, тарих өчен ядкарь итеп,
Хурлыклы бер токым итеп калдырганнар.
Алсынмыни шулар безнең хатыннарны?
Хур итсенме шулар безнең яшь кызларны?

Ераста барабан тавышы.

Тукта, менә яңрый алар барабаны!
Зур көрәшкә, Англиянең каймаклары!
Хак сугышка, илнең җитез солдатлары!
Укчыларым, алга әйдә! Явызларның
Йөрәгенә барып керсен укларыгыз!
Чапсын горур атлы гаскәр канлы кырга,
Сөңгеләрнең шатыр-шотыр сынуыннан
Җир дә, күк тә таңга калсын! Алга, алга!

Хәбәр ташучы керә.

Лорд Стэнли нәрсә диде? Гаскәр белән
Кайчан килә?

Хәбәр ташучы

Юк, килми ул, галиҗәнап.

Король Ричард

Бар, тиз йөгер, Георгның башын кистер!

Хәбәр ташучы

Дошман анда сазлык аша үтеп чыкты,
Георг Стэнли качмас иде аннан соң да.

Король Ричард

Күкрәгемдә тибә төсле мең зур йөрәк!
Алга чыгар әләмнәрне, кыр дошманны!
Изге Георг! Шушы безнең борынгы сүз —
Батырлыкка өнди торган дәртле аваз —
Без, ут чәчкән драконнарга ярсу бирсен,
Алга, алга! Безнең шлемга җиңү килсен!

Китәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сугыш кырының бүтән өлешендә. Тревога тавышлары. Каты сугыш бара.
Дружинасы белән Норфольк керәләр. Аңар каршы Кэтсби килә.

Кэтсби

Ярдәм безгә, лорд Норфольк, ярдәм, ярдәм!
Король анда, хәвефләргә күзен йомып,
Күрсәтә гел таң калырлык могҗизалар!
Инде атын үтерделәр, җәяү килеш
Сугыша-сугыша гел Ричмондны эзләп йөри.
Ярдәм, милорд! Юкса харап! Бар да бетте!

Тревога. Король Ричард керә.

Король Ричард

Ат, китер ат! Тәхетем бирәм бер ат өчен!

Кэтсби

Бар, качыгыз, галиҗәнап. Ат мин бирәм.

Король Ричард

Җирәнгеч кол! Мин биредә тормышымны,
Язмышымны кол өстенә куйдым инде, —
Курыкмыйча үлем белән уйныйм хәзер!
Әллә кырга алты Ричмонд чыкты микән?
Бишәвесен юк иттем мин. Тик ул исән...
Ат, китер ат! Тәхетем бирәм бер ат өчен!

Китәләр. Тревога тавышлары. Кара-каршы яктан король Ричард һәм Ричмонд керә. Алар сугыша-сугыша чыгып китәләр. Король Ричард армиясе чигенә. Фанфаралар тавышы. Ричмонд яңадан керә. Аның артыннан, король тажы тотып,
Стэнли, аның артыннан башка лордлар һәм гаскәрләр керәләр.

Ричмонд

Тәңрегә дан, сезгә мактау, җиңүчеләр!
Көн безнеке! Дөмектердек канлы этне!

Стэнли

Кыю Ричард! Бу зур данга үзең лаек!
Менә кара, король тажы! Озак вакыт
Узурпатор мәсхәрәләп йөрде моны.
Мин бу тажны шушы канлы бәдбәхетнең
Суынып калган маңгаеннан суырып алдым.
Инде бу таж бизәп торыр синең башны!
Ки син моны, йөрет моны, рәхәтен күр, —
Моны кигәч, безнең өчен күпне эшлә!

Ричмонд

Ходай синең сүзләреңә «Амин!» дисен!
Тик әйт миңа: Георг Стэнли исән микән?

Стэнли

Исән, исән. Тыныч тора Лейсестерда.
Сез әйтсәгез, анда бүген барачакбыз.

Ричмонд

Затлылардан бүген кемнәр һәлак булды?

Стэнли

Герцог Джон Норфольк һәм лорд Вальтер Феррес,
Сэрлар: Роберт Брэкенбери, Вильям Брэндон...

Ричмонд

Гәүдәләрен нәсел-нәсәп, затларына
Лаек булган хөрмәт белән җирләсеннәр.
Белдерегез: качып киткән солдатларны, —
Әгәр алар буйсынсалар, — гафу итәм.
Аннан соң без ныклы никах җебе белән
Кушачакбыз Ак һәм Кызыл розаларны.
Елмай, кояш, шушы гүзәл бердәмлеккә,
Бик күп инде йөзең чыттың дошманлыкка.
Кайсы мөртәт, моны күреп, «Амин!» димәс?
Англиябез, шашып күпме акылыннан,
Гел үз-үзен җәрәхәтләп, турап торды.
Сукыр кардәш кардәшенең канын түкте,
Шашкан улы әткәсенең җанын алды,
Тинтәк ата, ярсып, үзенең улын суйды.
Йорк белән Ланкастерның дошманлыгы
Иң коточкыч, иң дәһшәтле каза булды.
Әйдә хәзер Ричмонд белән Елизавета,
Шул ике йорт, патша йорты варислары,
Кушылсыннар бер Ходаның әмере белән!
Кушылсыннар һәм аларның токымнары,
Ходай биреп, бар заманны бизәсеннәр
Муллык белән чәчәк аткан шат көннәргә,
Якты йөзле һәм мәңгелек тынычлыкка!
Йә бер Аллам, шушы канлы заманнарны
Кайтарырга ниятләнгән мөртәтләрнең,
Англияне адәм каны ташкынында
Елатырга исәп иткән дошманнарның
Хыянәтчән кылычларын бәреп сындыр!
Ирек бирмә син аларга яшәр өчен,
Безнең җиңү җимешләрен ашар өчен, —
Туган илгә хыянәт һәм мәкер белән
Тынычлыкны янган утка атар өчен!
Яралардан кан туктады, бетте сугыш,
Тынычлыкта алабыз бер иркен сулыш.
Тормыш мәңге тыныч булыр иртән-кичен,
Безнең сүзгә Хак Тәгалә «Амин!» дисен!

Литературно-художественное издание

Шекспир Уильям

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В двух томах

Том 1

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Шекспир Уильям

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Ике томда

1 том

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, С.Н.Галимуллина, Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.09.2006. Форматы 70x1001/16. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 50,05+вкл.2,28. Шартлы буяу-оттиск 111,15. Нәшер-хисап табагы 60,85+вкл.2,0. Тиражы 2000. Заказ З-740.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.